10

География

В. П. Максаковский

# ГЕОГРАФИЯ



10

## Халкы 1 млн кешедән арткан илләрнең «ВИЗИТ КАРТОЧКАЛАРЫ»

| Илләр | Дәүләт флагы | Мәйданы, мең км² | Халкы, млн кеше | Башкаласы | Идарә итү формасы | Админ.-террит. төзелеш формасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Россия | | 17075 | 143 | Мәскәү | Р | Ф |
| Белоруссия | | 207,6 | 10,3 | Минск | Р | У |
| Украина | | 603,7 | 46,7 | Киев | Р | У |
| Молдавия | | 33,7 | 4,5 | Кишинев | Р | У |
| Казахстан | | 2717 | 15,2 | Астана | Р | У |
| Үзбәкстан | | 447,4 | 27,3 | Ташкент | Р | У |
| Кыргызстан | | 198,5 | 5,2 | Бишкек | Р | У |
| Таҗикстан | | 143 | 7,3 | Душанбе | Р | У |
| Төрекмәнстан | | 488 | 5,0 | Ашхабад | Р | У |
| Азәрбайҗан | | 86,6 | 8,0 | Баку | Р | У |
| Әрмәнстан | | 29,8 | 3,0 | Ереван | Р | У |
| Грузия | | 69,7 | 4,7 | Тбилиси | Р | У |
| **ЕВРОПА ЧИТ ИЛЛӘРЕ** | | | | | | |
| ГФР | | 357 | 82,4 | Берлин | Р | Ф |
| Франция | | 552 | 60,9 | Париж | Р | У |
| Бөекбритания | | 244 | 60,6 | Лондон | КМ | У |
| Ирландия | | 70 | 4,1 | Дублин | Р | У |
| Нидерланд | | 41 | 16,2 | Амстердам | КМ | У |
| Бельгия | | 31 | 10,4 | Брюссель | КМ | Ф |

| Илләр | Дәүләт флагы | Мәйданы, мең км² | Халкы, млн кеше | Башкаласы | Идарә итү формасы | Админ.-террит. төзелеш формасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Швейцария | | 41 | 7,5 | Берн | Р | Ф |
| Австрия | | 84 | 8,2 | Вена | Р | Ф |
| Дания | | 43 | 5,5 | Копенгаген | КМ | У |
| Норвегия | | 387 | 4,6 | Осло | КМ | У |
| Швеция | | 450 | 9,0 | Стокгольм | КМ | У |
| Финляндия | | 338 | 5,2 | Хельсинки | Р | У |
| Эстония | | 45 | 1,3 | Таллинн | Р | У |
| Латвия | | 64 | 2,3 | Рига | Р | У |
| Литва | | 65 | 3,6 | Вильнюс | Р | У |
| Польша | | 313 | 38,5 | Варшава | Р | У |
| Чехия | | 79 | 10,2 | Прага | Р | У |
| Словакия | | 49 | 5,4 | Братислава | Р | У |
| Венгрия | | 93 | 10,0 | Будапешт | Р | У |
| Румыния | | 238 | 22,3 | Бухарест | Р | У |
| Болгария | | 111 | 7,4 | София | Р | У |
| Сербия | | 8,8 | 9,4 | Белград | Р | Ф |
| Хорватия | | 57 | 4,5 | Загреб | Р | У |
| Словения | | 20 | 2,3 | Любляна | Р | У |
| Босния һәм Герцеговина | | 51 | 4,5 | Сараево | Р | Ф |

## Халкы 1 млн кешедән арткан илләрнең «ВИЗИТ КАРТОЧКАЛАРЫ»

| Илләр | Дәүләт флагы | Мәйданы, мең км² | Халкы, млн кеше | Башкаласы | Идарә итү формасы | Админ.-террит. төзелеш формасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Македония | | 26 | 2,1 | Скопье | Р | У |
| Албания | | 29 | 3,6 | Тирана | Р | У |
| Греция | | 132 | 10,7 | Афины | Р | У |
| Италия | | 301 | 58,1 | Рим | Р | У |
| Испания | | 505 | 40,4 | Мадрид | КМ | У |
| Португалия | | 92 | 10,6 | Лиссабон | Р | У |
| **АЗИЯ ЧИТ ИЛЛӘРЕ** | | | | | | |
| Кытай | | 9572 | 1314 | Пекин | Р | У |
| Монголия | | 1565 | 2,8 | Улан-Батор | Р | У |
| Япония | | 372 | 127 | Токио | КМ | У |
| КХДР | | 121 | 23,1 | Пхеньян | Р | У |
| Корея Республ. | | 98 | 48,8 | Сеул | Р | У |
| Вьетнам | | 330 | 84,4 | Ханой | Р | У |
| Лаос | | 237 | 5,4 | Вьентьян | Р | У |
| Камбоджа | | 181 | 13,9 | Пномпень | КМ | У |
| Филиппин | | 300 | 89,5 | Манила | Р | У |
| Индонезия | | 2027 | 246,5 | Джакарта | Р | У |
| Сингапур* | | 0,6 | 4,5 | Сингапур | Р | У |
| Малайзия* | | 330 | 24,4 | Куала-Лумпур | КМ | Ф |

| Илләр | Дәүләт флагы | Мәйданы, мең км² | Халкы, млн кеше | Башкаласы | Идарә итү формасы | Админ.-террит. төзелеш формасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Таиланд | | 514 | 64,6 | Бангкок | КМ | У |
| Мьянма | | 678 | 47,4 | Янгон | Р | Ф |
| Бангладеш | | 144 | 147,4 | Дакка | Р | У |
| Һиндстан* | | 3288 | 1095 | Дәһли | Р | Ф |
| Шри-Ланка* | | 66 | 20,2 | Коломбо | Р | У |
| Непал | | 141 | 28,3 | Катманду | КМ | У |
| Бутан | | 47 | 2,3 | Тхимпху | КМ | У |
| Пакистан | | 804 | 165,2 | Исламабад | Р | Ф |
| Әфганстан | | 652 | 31,1 | Кабул | Р | У |
| Иран | | 1648 | 64,5 | Тәһран | Р | У |
| Төркия | | 781 | 70,4 | Әнкара | Р | У |
| Сүрия | | 185 | 18,9 | Дамаск | Р | У |
| Гыйрак | | 435 | 26,8 | Багдад | Р | У |
| Ливан | | 10 | 3,9 | Бәйрут | Р | У |
| Израиль | | 14 | 6,4 | Тель-Авив | Р | У |
| Иордания | | 98 | 5,9 | Амман | КМ | У |
| Согуд Гәрәбстаны | | 2150 | 27,0 | Әр-Рияд | АМ | У |
| Кувейт | | 18 | 2,4 | Әль-Кувейт | КМ | У |
| БГӘ | | 84 | 2,7 | Әбу-Даби | АМ | Ф |

В. П. Максаковский

# ГЕОГРАФИЯ

## ДӨНЬЯНЫҢ ИКЪТИСАДИ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ГЕОГРАФИЯСЕ

**Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек**

*Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән*

КАЗАН • «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
МОСКВА • «ПРОСВЕЩЕНИЕ»
2009

УДК 373.167.1:913(100)*10
ББК 65.04 я72
М17

**Максаковский В. П.**
География. Экономическая и социальная география мира : учеб. для 10 кл. общеобразоват. учреждений /В.П.Максаковский.— 16-е изд., испр.— М.: Просвещение, 2009.

Дәреслеккә 1997 елда Россия Федерациясе Президентының мәгариф өлкәсендәге премиясе бирелде.

Дәреслектә А. А. Ростовцев, С. Ф. Кулик, В. Ф. Семенов слайдлары, РИА «Новости», Халыкара мәгърифәтчелек мәгълүматы җәмгыяте (ISEL, Токио) фотохроникалары файдаланылды.

Дөньяның сәяси картасындагы барлык мәгълүматлар 2007 елның 1 ноябренә кадәр булганча китерелде.

*Охраняется действующим законодательством об авторских и смежных правах (Гражданский кодекс РФ, ч. 4, гл. 70). Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.*

Переводное издание учебника выпущено в свет по Сублицензионному договору №3/89 от 15.07.09. Экземпляры переводного издания подлежат распространению исключительно в Республике Татарстан, а также среди татарской диаспоры на территориях других субъектов Российской Федерации.

**Максаковский В. П.**
М17 География. Дөньяның икътисади һәм социаль географиясе : Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 10 нчы с-фы өчен д-лек / В. П. Максаковский; Русчадан Р. А. Шаһморатова, Г. И. Фазлыйәхмәтова, Ф. Г. Зыятдинова, Ф. С. Зыятдинов тәрҗ.— Казан : Мәгариф, 2009.— 397 б.: рәс. б-н.
ISBN 978-5-7761-2027-5

ISBN 978-5-7761-2027-5

© Издательство «Просвещение», 2004
© Издательство «Просвещение», 2008, с изменениями
© Художественное оформление. Издательство «Просвещение», 2004
Все права защищены
© Татарчага тәрҗемә. «Мәгариф» нәшрияты, 2009

## ЭЧТӘЛЕК


Кереш ........................................................................ 5

I кисәк
**ДӨНЬЯГА ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКА**

**1 нче тема. Дөньяның хәзерге сәяси картасы** .................... 9
1. Хәзерге дөньяда илләрнең күптөрлелеген тикшерәбез .................. 9
2. Дөньяның сәяси картасына халыкара мөнәсәбәтләрнең йогынтысын характерлыйбыз .................. 14
3. Илләрнең дәүләт төзелеше белән танышабыз .................. 17
4. Сәяси географияне өйрәнәбез.................. 19

**2 нче тема. Дөньяның табигый ресурслары географиясе. Мохитне саклау һәм аның пычрануы** .................. 25
1. Җәмгыять һәм табигатьнең үзара тәэсир итешүен өйрәнәбез ..... 25
2. Дөньяның табигый ресурсларын бәялибез .................. 28
3. Әйләнә-тирәне саклау һәм аның пычрануы мәсьәләләрен тикшерәбез .................. 41
4. Ресурслар географиясен һәм геоэкологияне өйрәнәбез.................. 46

**3 нче тема. Дөнья халкы географиясе**.................. 57
1. Халык саны һәм халыкның яңарып торуы белән танышабыз...... 57
2. Халыкның составын (структурасын) күзәтәбез.................. 66
3. Халыкның урнашуына һәм миграциясенә характеристика бирәбез .................. 71
4. Шәһәр һәм авыл халкын чагыштырабыз .................. 74

**4 нче тема. Фәнни-техник революция һәм бөтендөнья хуҗалыгы** ........ 91
1. Фәнни-техник революциягә характеристика бирәбез .................. 91
2. Бөтендөнья хуҗалыгын өйрәнәбез .................. 98
3. Дөнья хуҗалыгының тармак һәм территориаль структурасын өйрәнәбез .................. 103
4. Урнашу факторлары белән танышабыз .................. 110

**5 нче тема. Бөтендөнья хуҗалыгы тармаклары географиясе** .................. 123
1. Промышленность географиясен өйрәнәбез.................. 123
2. Авыл хуҗалыгы һәм балыкчылык географиясен күзәтәбез.................. 140
3. Транспорт географиясен өйрәнәбез .................. 150
4. Дөньякүләм икътисади мөнәсәбәтләр белән танышабыз.................. 159

## II кисәк
## ДӨНЬЯ РЕГИОННАРЫНА ХАРАКТЕРИСТИКА

**6 нчы тема. Европа чит илләре** ........ 179
1. Европа чит илләренә гомуми характеристика бирәбез ........ 179
2. Халык урнашу һәм хуҗалыгының географик сурәтен өйрәнәбез ........ 197
3. Европаның субрегионнары һәм илләре белән танышабыз ........ 202

**7 нче тема. Азия чит илләре. Австралия** ........ 223
1. Азия чит илләренә гомуми характеристика бирәбез ........ 223
2. Кытайны өйрәнәбез ........ 235
3. Японияне өйрәнәбез ........ 242
4. Һиндстанны «ачабыз» ........ 250
5. Австралия белән танышабыз ........ 257

**8 нче тема. Африка** ........ 273
1. Африкага гомуми характеристика бирәбез ........ 273
2. Төньяк һәм Тропик Африка субрегионнарын һәм чагыштырып карыйбыз. КАР ........ 281

**9 нчы тема. Төньяк Америка** ........ 295
1. Америка Кушма Штатларына гомуми характеристика бирәбез ........ 295
2. АКШ макрорайоннарын тикшерәбез ........ 311
3. Канада белән танышабыз ........ 316

**10 нчы тема. Латин Америкасы** ........ 331
1. Латин Америкасына гомуми характеристика бирәбез ........ 331
2. Бразилия белән танышабыз ........ 340

## III кисәк
## КЕШЕЛЕКНЕҢ ГЛОБАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ
(белемнәрне гомумиләштерү)

**11 нче тема. Кешелекнең глобаль проблемалары** ........ 351
1. Кешелекнең глобаль проблемаларын нигезлибез ........ 351
2. Глобаль фаразлар, гипотезалар һәм проектлар белән танышабыз ........ 364
3. Тотрыклы үсеш стратегиясе белән танышабыз ........ 367

**XXI гасыр башындагы дөньяны аңлыйбыз (Йомгаклау урынына)** ........ 375

**Курсны тирәнрәк үзләштерү өчен өстәмә әдәбият** ........ 376

**Терминнар һәм кыскартулар күрсәткече** ........ 378

**КУШЫМТА** ........ 379

# КЕРЕШ

Дөньяның икътисади һәм социаль географиясе — иҗтимагый географик фән ул. Бу фән тулаем бөтен дөньяда, шулай ук аерым регионнарда һәм илләрдә халыкның һәм хуҗалыкның урнашуын һәм үсешен өйрәнә. Халыкара мөнәсәбәтләр, кешелекнең глобаль проблемалары, җәмгыять белән табигатьнең үзара йогынтысы мәсьәләләрен күтәреп, ул дөнья үсешенең хәзерге этабын яхшырак аңларга ярдәм итә. Аның фән булып формалашуы безнең илебездә бик күп географ-галимнәрнең исемнәре белән бәйләнгән. Күренекле галимнәрдән Николай Николаевич Баранскийны (1881—1963) һәм Иван Александрович Витверны (1891—1966) аеруча билгеләп үтү зарур. Алар — мәктәп дәреслекләренең авторлары буларак та танылган галимнәр.

Бу дәреслек өч кисәктән тора. Беренче кисәк — дөньяның гомуми, икенчесе региональ икътисади-географик һәм социаль-географик характеристикасына багышлана. Өченче кисәктә кешелекнең глобаль проблемалары тасвирлана, аның максаты — белемнәрне гомумиләштерү.

Дәреслекнең һәр темасы (бүлеге) план-схемадан башлана. План-схема — шул бүлекнең график рәвештәге эчтәлеге генә түгел, бәлки теманың логик конспекты да. Аның белән танышу өйрәнеләсе материалны яхшырак күзалларга ярдәм итәчәк. Аннары төп текст — теманың төп фәнни эчтәлеге бирелә. Бу текст бүлек һәм бүлекчәләрдән тора. Текст эчендә рубрикалар бар, алары сирәкләп җыелган. Болай эшләү текстны мәгънәдәш кисәкләргә аеруны җиңеләйтә. Нәтиҗәләрне, төп идея һәм фикерләрне аерып күрсәтү өчен курсив (авыш басма хәрефләр) кулланыла. Үтә әһәмиятле фәнни төшенчәләр төп текстта үзенә бертөрле аерып күрсәтелгән. Башка төшенчәләр һәм терминнар (төп сүзләр) шулай ук шрифты белән аерылып тора. Яңа фәнни атамаларга һәм терминнарга аңлатмалар китап битенең аскы өлешендә сылтама рәвешендә бирелә.

Төп текстка өстәп, махсус тупланган карталар, графиклар, статистик таблицалар һәм фотоиллюстрацияләр бирелеп бара. Кагыйдә буларак, алар дәреслекнең төп текстын кабатламый, бәлки тулыландыра гына. Моны форзацлардагы материалга — илләрнең «визит карточкасына» карата да әйтергә кирәк. Шуңа күрә алардан да текст белән бер үк дәрәҗәдә мөстәкыйль белем чыганагы итеп файдаланырга тырышыгыз. 10 нчы сыйныф өчен географик атласны куллану тәкъдим ителгән очраклар да бар.



Н. Н. Баранский



И. А. Витвер

Төп тексттан соң шул теманың эчтәлегенә караган кызыклы фактлар тупланмасыннан торган өстәмә текст бирелә. Ул кечкенә «уку китабы» булып хезмәт итә. Өстәмә текст, нигездә, өйдә уку өчен бирелә. Төп текстта сез квадрат җәяләр эченә алынган тәртип номерларын күрерсез. Бу тамга өстәмә текстны кирәкле урында файдаланырга ярдәм итәчәк.

Аннары китап киштәсе урнаштырылган. Тәкъдим ителгән китапларны, белемнәрегезне тирәнәйтү һәм шулай ук мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен үстерү өчен, мөмкин кадәр күбрәк файдаланырга тырышыгыз.

Белем һәм күнекмәләр үзләштерү өчен тупланмага аеруча игътибар итегез. Дәреслекнең төп текстында сез үзләштерергә тиешле белемнәрнең фәкать бер өлеше генә бирелә. Калган мәгълүматны текст, карта, графиклар һәм таблицалар, өстәмә әдәбият белән даими эш иткәндә, шулай ук дәфтәрдә, контурлы картада биремнәрне үтәгәндә, сез үзегез табарга тиеш. Моның өчен сезгә текстта сан белән күрсәтелгән биремнәр ярдәм итәр. Ул биремнәр төрле характерда булулары белән дә (текст, карталар, дәреслектәге таблицалар, төрле белем чыганаклары белән эшләү), шулай ук катлаулылык дәрәҗәсе белән дә берберсеннән аерылалар. Алар арасында сездән аеруча максатчанлыкны һәм уку материалын үтә тирән үзләштерүне таләп иткән иҗади биремнәр дә бар. Исәпләүләр таләп ителә торган кайбер биремнәрне үтәгәндә, компьютер яисә микрокалькулятор кулланырга тырышыгыз.

Үзегезнең һәм бер-берегезнең белемнәрен тикшерү тупланмасына конкрет сораулар, телдән һәм язма биремнәр керә. Алар ярдәмендә сез белем һәм күнекмәләр туплау буенча кайбер

эш нәтиҗәләрегезне үзегез яисә иптәшләрегез булышлыгында тикшерә аласыз.

Дәреслектәге һәр тема (бүлек) ахырында бирелгән методик ачкычлар да сезгә зур ярдәм итәчәк. Анда сез, теманы аңлау өчен, алдагы сыйныфларда өйрәнелгән география курсларыннан һәм башка фәннәрдән нәрсәләрне искә төшерергә, теманы өйрәнү нәтиҗәсендә нәрсәләрне үзләштерергә, нинди практик күнекмәләр алырга кирәклеге турында киңәшләр табарсыз. Биремнәрне мөстәкыйль үтәү өчен, күрсәтмәләр һәм планнар да шунда ук бирелә.

Дәреслектән файдаланганда шуны истә тоту зарур: дәреслек материалы ике дәрәҗәгә бүлеп бирелгән. Мәсәлән, төп текстта ярдәмче материалны аерып бирү өчен вак шрифт (петит) кулланыла. Барлык биремнәр дә шулай ук төп һәм ярдәмче өлешләргә бүлеп бирелгән.

Дөньяның сәяси һәм икътисади карталарында барган мөһим вакыйгаларның күбесе дәреслек битләрендә шундук чагылыш таба алмый. Шуңа күрә дә газета-журналлар, радио һәм телевидение материалларына, энциклопедия, белешмә-сүзлекләр, географик атласларга даими рәвештә мөрәҗәгать итеп тору аеруча мөһим. Шулай өстәмә белем чыганаклары белән эшләү сезнең дөньяга карашыгызны киңәйтүгә, гомуми культурагыз һәм географик фикерләвегезне үстерүгә булышыр, хәзерге вакытта һәркем өчен зарур булган мөстәкыйль иҗади эшчәнлек күнекмәләре булдыруга ярдәм итәр.

Илебездәге гомуми белем бирү мәктәпләрендә бара торган реформаларның культурологик юнәлеше аермачык күренә. Географик культура формалаштыруда мәктәптә өйрәнелә торган география курсларының барысы да, шул исәптән «Дөньяның икътисади һәм социаль географиясе» дә катнаша. Дөрестән дә, дөньяның хәзерге сәяси картасын аңламый торган кешене чынлыкта культуралы дип санарга мөмкинме соң? Шулай ук дөньяның табигый байлыклары һәм халкы турында бернәрсә дә белмәгән кеше культуралымы? Фәнни-техник революциянең мәгънәсен, дөнья хуҗалыгын, дөньяның аерым регионнары һәм илләренең социаль-икътисади үзенчәлекләрен һәм, ниһаять, кешелекнең глобаль проблемаларын белми торган кешене дә культуралы дип әйтеп буламы?

Шуңа күрә дә сезнең бу курска тиешле игътибар белән каравыгыз аеруча зур әһәмияткә ия. Нинди һөнәр сайлаган булуыгызга карамастан, географияне өйрәнгәндә алган белемнәр сезнең һәркайсыгызга тормышта кирәк булачак.

## 1 НЧЕ ТЕМАНЫҢ ПЛАН-СХЕМАСЫ

# I кисәк. ДӨНЬЯГА ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКА

## 1 нче тема. ДӨНЬЯНЫҢ ХӘЗЕРГЕ СӘЯСИ КАРТАСЫ

Дөньяның сәяси картасын сез инде 7 нче сыйныфта география курсында һәм 9 нчы сыйныфта тарих курсында өйрәнгән идегез. Аның формалашуы — озакка сузылган тарихи процесс, һәм ул кешелек җәмгыятенең бөтен үсеш юлын чагылдыра. Күп гасырлар дәвамында үзгәрә барып, ул дәүләтләрнең барлыкка килүен һәм таркалуын, чикләренең үзгәрүен, яңа җирләр табылуны һәм аларны колонияләргә әверелдерүне, метрополияләр һәм колонияләр барлыкка килүне, дөньяның территориясен бүлү һәм яңадан бүлүне чагылдыра. Әмма дөньяның сәяси картасы, — барыннан да элек, икътисади һәм социаль географиянең үзенә бер тармагы булган сәяси география өйрәнә торган предмет ул.

### 1. ХӘЗЕРГЕ ДӨНЬЯДА ИЛЛӘРНЕҢ КҮПТӨРЛЕЛЕГЕН ТИКШЕРӘБЕЗ

**1. Илләрнең саны һәм төркемнәре.** Ил, дәүләт — дөньяның сәяси картасында төп объект. Бу картада илләрнең гомуми саны XX гасыр дәвамында сизелерлек артты: моның беренче сәбәбе — Беренче бөтендөнья сугышы нәтиҗәләренә бәйле үзгәрешләр; икенчесе — Икенче бөтендөнья сугышыннан соң империализмның колониаль системасы җимерелү нәтиҗәсендә туган үзгәрешләр: 1945—2002 елларда 102 ил сәяси бәйсезлеккә ирешә («Кушымта»дагы 1 нче таблицаны карагыз); өченчесе — 90 нчы еллар башында Советлар Союзы, Югославия һәм Чехословакиянең таркалуы. Шуңа күрә XXI гасыр башында дөньяның сәяси картасындагы илләр һәм территорияләрнең гомуми саны 230 га җитте.

Сан ягыннан үсеш белән беррәттән, сыйфат ягыннан да мөһим үзгәрешләр күзәтелә. Әйтик, әгәр 1900 елда дөньяда нибары 57 ***суверен дәүләт***[1] булса, Икенче бөтендөнья сугышы алдыннан ул сан 71 гә, ә инде 2007 елда 194 кә җитә. Калганнары — үзидарәсез дип йөртелә торган территорияләр, күбесенчә элеккеге колониаль империяләрнең — Бөекбритания, Франция, Нидерланд һәм АКШның «кыйпылчыклары». [1].

---

[1] Суверен дәүләт (франц. *souverain* — югары, баш) — эчке һәм тышкы эшләрен мөстәкыйль башкаручы, сәяси яктан бәйсез дәүләт.

Аңлашыла ки, илләр саның шулкадәр күп булуы аларны төркемнәргә бүлү кирәклеген тудыра. Моны иң элек төрле санча күрсәткечләргә таянып башкаралар. Илләрне территорияләренә һәм халык санына карап төркемләү аеруча киң таралган.

**1 нче мисал.** Территорияләренең зурлыгы буенча иң зур җиде ил аерылып тора. Аларның һәркайсының мәйданы 3 млн км$^2$ дан артыграк, ә алар барысы бергә барлык коры җирнең 1/2 өлешен алып торалар. [2].

**2 нче мисал.** Халык саны буенча иң зур 11 ил аерылып тора. Бу илләрнең һәркайсының халкы 100 млн кешедән артыграк, һәм барысы бергә Җир шарындагы халыкның 3/5 өлешен тәшкил итәләр.

Шулай да сәяси картада уртача зурлыктагы һәм кечкенә илләр күбрәк. (Хәер, бу төшенчә, әйтик, Европа өчен бертөрле булса, Африка яки Азия өчен — башка.) Территорияләре бик кечкенә, халкы 10—30 мең кеше һәм аннан да кимрәк булган илләр дә бар. Аларны, гадәттә, микродәүләт дип йөртәләр.

**Мисал.** Аларның иң танылганнары — Европада урнашкан микродәүләтләр: Андорра, Лихтенштейн, Монако, Сан-Марино, Ватикан. Ләкин утрау микродәүләтләре Африкада (Маврикий, Сейшель утраулары һ.б.), Америкада (Барбадос, Гренада, Сент-Люсия һ.б.), шулай ук Океаниядә (Тонга, Науру һ.б.) дә бар. [3].

Илләрне географик урынының үзенчәлекләре буенча төркемләү дә еш кулланыла. Диңгез буе, ярымутрау, утрау һәм архипелаг илләре шундыйлардан санала. Диңгезгә чыкмаган илләр (барлыгы 42 ил) аерым бер төркем тәшкил итәләр. Мондый илләрнең күбесе Тропик Африкада, Европа чит илләрендә һәм БДБ илләрендә. (1 нче бирем.)

**2. Илләрнең типологиясе.** Илләрне санча күрсәткечләр буенча классификацияләүдән (төркемнәргә бүлүдән) аермалы буларак, типология нигезенә теге яисә бу илнең дөнья сәяси һәм икътисади картасында тоткан урынын билгеләүче аеруча әһәмиятле сыйфат күрсәткечләре алына.

Үз нәүбәтендә алар да гаять күп төрле булырга һәм илләрнең социаль-икътисади үсеш дәрәҗәләрен, аларның сәяси ориентациясен, хакимиятнең демократлашу дәрәҗәсен, дөнья икътисадына керүкермәвен һ.б. ны исәпкә алырга мөмкиннәр.

90 нчы еллар башына кадәр дөньядагы барлык илләрне өч типка бүлеп йөртү кабул ителгән иде: 1) социалистик, 2) алга киткән капиталистик һәм 3) үсеп килүче илләр. Дөньяда социалистик система таркалганнан соң, бу типологиягә алмашка башкалар килде. Аларның берсе шулай ук дөнья илләрен өч төргә: икътисади нык үскән, үсеп килүче һәм икътисади күчеш, ягъни үзәкләштерелгән планлы икътисадтан базар икътисадына күчеп баручы илләргә бүлә. (Соңгысына, барыннан да элек, постсоциалистик илләр дип йөртелә торган Көнчыгыш Европа һәм БДБ илләре керә.)

Моның белән беррәттән, ике төргә бүлүче типология дә киң кулланыла, һәм ул барлык илләрне икътисади үсеш алган һәм үсеп килүче илләргә бүлә. Бу типология өчен төп критерий булып теге яисә бу дәүләтнең социаль-икътисади үсеш дәрәҗәсен билгеләүче җан башына туры килә торган ***тулай эчке продукт***[1] күрсәткече санала.

Соңгы вакытта Берләшкән Милләтләр Оешмасы (БМО) һәм башка халыкара оешмалар, дөньядагы илләрнең социаль-икътисади үсеш дәрәҗәсен билгеләү өчен, кешелекнең үсеш индексы (КҮИ) дип исемләнгән яңа синтетик күрсәткеч куллана башладылар. Ул кешеләрнең җан башына туры килә торган керем дәрәҗәсен генә түгел, бәлки аларның уртача гомер озынлыгын, шулай ук белем дәрәҗәсен дә исәпкә ала. Канада, АКШ, Төньяк Европа илләре һәм Япония КҮИ күрсәткече иң югары илләрдән санала, ә иң түбәне Африка илләрендә: Бурунди, Сьерра-Леоне һәм Нигер. Бу исемлектә Россия КҮИ күрсәткече уртача булган илләр төркеменең башында тора.

*Бу дәреслектә дөньядагы илләрне икегә: 1) икътисади үсеш алган һәм 2) үсеп килүче илләргә бүлү типологиясе нигез итеп алынды.* Ләкин өч төргә бүлә торган типология дә файдаланыла.

**3. Икътисади нык үскән илләр.** Берләшкән Милләтләр Оешмасы Европа, Азия, Африка, Төньяк Америка, Австралия һәм Океаниядәге 40 лап илне икътисади нык үскән илләр рәтенә кертә. Алар барысы да икътисади һәм социаль үсеш дәрәҗәсенең һәм шуңа тиңдәшле рәвештә җан башына туры килә торган тулай эчке продуктның югары булуы белән аерылып торалар. Ләкин бу илләр төркеме эчке яктан бериш булмавы белән аерылып тора, һәм монда дүрт төркемчәне аерып күрсәтергә мөмкин.

Аларның беренчесе — Көнбатышның «зур җиделеге». Аңа АКШ, Япония, ГФР, Франция, Бөекбритания, Италия һәм Канада керә. Болар — көнбатыш дөньясының әйдәүче илләре, икътисади һәм сәяси эшчәнлек масштабларының иң зур булуы белән аерылып торалар.

**Мисал.** Бөтен дөньядагы тулай милли продуктның һәм промышленностьта җитештерелгән продукциянең 40%ы, авыл хуҗалыгы продукциясенең 25% ы шушы җиде илгә туры килә. Бу илләрдә тулай эчке продукт (ТЭП) җан башына 20 меңнән алып 40 мең долларга кадәр җитә.

Икенче төркемчәгә Көнбатыш Европаның бик зур булмаган илләрен кертергә мөмкин. Аерым алганда, аларның һәркайсының сәяси һәм икътисади куәтләре артык зур түгел, ләкин, тулаем алганда, әһәмиятләре зур, бөтендөнья эшләрендә аларның роле һаман арта бара. Җан башына туры килгән ТЭП аларның күпчелегендә «зур җиде» илдәге шикелле үк.

[1] Тулай эчке продукт (ТЭП) — нинди дә булса ил территориясендә бер ел эчендә чыгарылган ахыргы продуктның суммар кыйммәтен характерлаучы күрсәткеч (халыкара чагыштыру өчен, гадәттә, АКШ долларларында исәпләнә).

Европадан читтәге илләр — Австралия, Яңа Зеландия һәм Көньяк Африка Республикасы (КАР) өченче төркемчәне тәшкил итә. Алар — Бөекбританиядән күчеп килүчеләр урнашкан элекке колонияләр (доминионнар). Аларда чынлыкта феодализм чоры булмаган, әле хәзер дә сәяси һәм икътисади үсешләре аерым үзенчәлеккә ия. Гадәттә, бу төркемчәгә Израильне дә кертәләр.

Дүртенче төркемчә әлегә формалашу стадиясендә. Ул 1997 елда Корея Республикасы, Сингапур, Гонконг (Сянган) һәм Тайвань кебек Азия илләрен һәм территорияләрен икътисади нык үскән илләр рәтенә кертү нәтиҗәсендә барлыкка килде. Бу дәүләтләр җан башына исәпләнгән тулай эчке продукт (ТЭП) күрсәткече белән икътисади нык үскән илләргә бик нык якынлашты. Алар, хезмәт күрсәтү секторын да кертеп, күп төрле структуралы икътисадка ия, шулай ук дөнья сәүдәсендә актив катнашалар. 2001 елда бу төркемчәгә Кипр кертелде.

**4. Үсеп килүче илләр.** Үсеп килүче илләргә 150 чамасы ил һәм территория керә, барысы бергә алар бөтендөнья коры җир мәйданының яртысыннан күбрәген биләп торалар, һәм бөтендөнья халкының 4/5 өлеше шунда тупланган. Бу илләр дөньяның сәяси картасында Азия, Африка, Латин Америкасы һәм Океания буйлап экваторның төньягына, бигрәк тә көньягына таба гаять киң пояс булып сузылган мәйданны билиләр. Аларның кайберләре (Иран, Таиланд, Эфиопия, Мисыр, Латин Америкасы илләре һ. б.) Икенче бөтендөнья сугышына кадәр үк бәйсез булалар. Ләкин күпчелеге сугыштан соңгы чорда гына бәйсезлек ала.

Үсеп килүче илләрнең гаять зур күп төрле дөньясы (бөтен дөнья социалистик һәм капиталистик системага бүленгән заманда аны «өченче дөнья» дип йөртә иделәр) эчке яктан бик тә үзгәлекле. Ә бу — төркемчәдәге илләрне типологияләүне читенләштерә. Күп кенә галимнәр бу илләрнең төрле типологияләрен тәкъдим итеп карады, тик бер генә тәкъдим дә киң кулланыш тапмады. Шулай да үсеп килүче илләрне якынча түбәндәге алты төркемчәгә бүлеп күрсәтергә мөмкин.

Беренче төркемчәне табигый, халык һәм икътисади потенциалы гаять зур булган һәм үсеп килүче илләр арасында лидерлар булып саналган төп илләр — Һиндстан, Бразилия, Мексика, шулай ук Кытай тәшкил итә.

**Мисал.** Бу дүрт ил үсеп килүче калган илләрнең барысы бергә җитештергән кадәр диярлек промышленность продукциясе эшләп чыгара. Ләкин җан башына туры килгән эчке тулай продукт, икътисади үсеш алган Көнбатыш Европа, Төньяк Америка, Австралия һәм Океания илләрендәгегә, шулай ук Японияга караганда, шактый ким.

Кытайның сәяси төзелешендә дә (социалистик ил), социаль-икътисади үсешендә дә үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Соңгы вакытта бик югары темплар белән үсеш алган Кытай дөнья сәясәтендә генә түгел, ә дөнья хуҗалыгында да

чын мәгънәсендә бөек державага әверелде. Ләкин халкы бик күп булган бу илдә җан башына килгән ТЭП әлегә артык югары түгел. Халыкара статистика Кытайны үсеп килүче илләр санына кертә. (2 нче бирем.)

Икенче төркемчәгә социаль-икътисади үсеш дәрәҗәсе чагыштырмача югары булган һәм җан башына исәпләнгән ТЭП күрсәткече 10 мең, ә кайчак 15 мең доллардан артып киткән кайбер үсеп килүче илләр керә.

Бу илләрнең күбесе Латин Америкасында (Аргентина, Уругвай, Чили, Венесуэла һ.б.), әмма алар Азиядә дә һәм Төньяк Африкада да бар.

Өченче төркемчәгә яңа индустриаль илләр дип аталган илләрне кертергә мөмкин. 80—90 нчы елларда зур сикереш ясап үсеп киткән бу илләрне «азия юлбарыслары» дип атый башладылар. Бу илләрнең «беренче эшелонын» инде искә алынган Корея Республикасы, Сингапур, Тайвань һәм 1997 елда Сянган атамасы астында Кытай составына кергән Гонконг тәшкил итә. Ә «икенче эшелонга», гадәттә, Малайзия, Таиланд, Индонезия һәм Филиппинны кертәләр.

Дүртенче төркемчәне нефть экспортлаучы илләр тәшкил итә. «Нефть доллары» агып керүдән бу илләрдә җан башына тулай эчке продукт күрсәткече 10—20 мең, ә кайчак хәтта 50 мең долларга һәм аннан да артыкка җитә. Болар — иң элек Фарсы култыгындагы илләр (Согуд Гарәбстаны, Кувейт, Катар, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре), шулай ук Ливия, Бруней [4] һәм кайбер башка илләр.

Бишенче төркемчәгә «классик» үсеп килүче илләрнең күпчелеге керә. Алар — үсешләре белән шактый артта калган һәм җан башына ТЭП елына 5000 доллардан да кимрәк булган илләр. Аларда феодализм калдыкларының йогынтысы көчле булган шактый артта калган күп укладлы икътисад өстенлек итә. Бу илләрнең күбесе Африкада, әмма алар Азиядә дә, Латин Америкасында да бар.

Алтынчы төркемчәне якынча 50 ил тәшкил итә (гомуми халык саны 800 млн нан артыграк). БМО классификациясе буенча бу илләр үтә аз үсешле илләргә керә (кайвакыт аларны «дүртенче дөнья» дип атап йөртәләр). Аларда кулланучы авыл хуҗалыгы өстенлек итә, эшкәртү промышленносте бөтенләй диярлек юк, балигъ булган халыкның 2/3 өлеше укыйяза белми, җан башына ТЭП елына 500—1500 доллар тәшкил итә.

**Мисал.** Бу төркемчәгә Азиядә — Бангладеш, Непал, Әфганстан, Йәмән, Африкада — Мали, Нигер, Чад, Эфиопия, Сомали, Мозамбик, ә Латин Америкасында Гаити керә. (2 нче бирем.)

**5. Икътисади күчеш илләре**. Бу типка, гадәттә, барлык постсоциалистик илләрне, ягъни элек Советлар Союзына кергән 15 илне, Үзәк-Көнчыгыш Европаның 12 элеккеге социалистик илен һәм Монголияне керттеләр. Алар барысы да 80 нче еллар ахырында — 90 нчы еллар башында авторитар дәүләт төзелешеннән күп партияле, кеше хокукларын саклауга нигезләнгән чын

демократик дәүләт төзелешенә күчә башладылар. Элеккеге административ-команда системасы һәм үзәктән планлаштырудан базар икътисадына күчеп баручы икътисадта да шундый ук революцион үзгәрешләр күзәтелә. Бу күчеш дәвере инде ахырына якынлаша.

## 2. ДӨНЬЯНЫҢ СӘЯСИ КАРТАСЫНА ХАЛЫКАРА МӨНӘСӘБӘТЛӘРНЕҢ ЙОГЫНТЫСЫН ХАРАКТЕРЛЫЙБЫЗ

**1. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң дөньяның сәяси картасы.** Икенче бөтендөнья сугышыннан соң дөньяның сәяси картасында социалистик дәүләтләр барлыкка килү, колониаль системаның җимерелүе һәм уннарча илләрнең азатлык алуы, кушылмау хәрәкәтенең үсүе кебек аеруча әһәмиятле процесслар чагылыш таба. Ләкин Көнчыгыш белән Көнбатыш арасында глобаль капмакаршылык, алар арасында башланган «салкын сугыш» сугыштан соңгы еллардагы үзгәрешләрнең төп эчтәлегенә әверелә. Күп санлы хәрби-сәяси союзлар барлыкка килә, шул исәптән ике төп союз: Төньяк Атлантика Килешүе Оешмасы (НАТО)[1] һәм Варшава Килешүе Оешмасы (ОВД). Җир шарының төрле нокталарында йөзләрчә хәрби базалар төзелә, әле анда, әле монда локаль сугышлар булып тора. Бөтендөнья картасында күп санлы халыкара киеренкелек учаклары кабына, **региональ конфликтлар** туа.

**Мисал.** Сугыштан соңгы чорның бөтен дәвамында Якын Көнчыгыш дөньяның төп «кайнар ноктасы» булып кала, моңа Фарсы култыгы районы да керә. Тарихи үсеш дәверендә мәдәният һәм диннәрнең үтә катлаулы бәйләнешләре барлыкка килгән бу район планетабызның иң сизгер нерв төененә әверелде. Монда гарәп илләре һәм Израильнең генә түгел, башка бик күп дәүләтләрнең дә мәнфәгатьләре бәрелешә.

**2. Халыкара мөнәсәбәтләрнең хәзерге этабы һәм дөньяның сәяси картасы.** 80 нче елларның икенче яртысында халыкара мөнәсәбәтләрдә конфронтациядән үзара аңлашуга һәм хезмәттәшлеккә күчү сизелә башлый. Бер-береңә ышанмаучылыкка, шикләнеп карауга һәм дошманлашуга күршеләрчә дуслык алмашка килә. Хәзер ул Россия, БДБ илләре һәм АКШ арасындагы, шулай ук Европа илләре белән Азия-Тын океан регионы (АТР) илләре һәм башка регионнар арасындагы мөнәсәбәтләргә кагыла. Дөньяның сәяси картасында Германиянең берләшүе, БДБ барлыкка килүе, реаль коралсызлануның башлануы, ОВДның тара-

[1] НАТО хәрби-политик блогы (North Atlantic Treaty Organization — NATO) 1949 елда төзелә, соңгы вакытка кадәр 16 илдән торды: АКШ, Канада, ГФР, Бөекбритания, Франция, Италия, Норвегия, Исландия, Дания, Бельгия, Нидерланд, Люксембург, Испания, Португалия, Греция, Төркия. 1999 елда аңа Польша, Чехия һәм Венгрия, ә 2004 елда Словакия, Румыния, Болгария, Словения, Латвия, Литва һәм Эстония керде.

1 нче рәсем. Нью-Йоркта БМО бинасы

2 нче рәсем. Капитолий — Вашингтонда АКШның Конгресс бинасы

3 нче рәсем. Бөекбритания королевасының тантаналы чыгуы

тылуы, НАТО илләренең Россия катнашында «Тынычлык хакына партнерлык» программасын игълан итүе кебек аеруча әһәмиятле процесслар һәм күренешләр чагылыш тапты.

Европада куркынычсызлык саклауда мөһим роль уйнаучы «Россия — НАТО» Советы даими эшләп килә. Россия һәм АКШ мөнәсәбәтләре стратегик партнерлык характерында булу бөтендөнья хәленә уңай йогынты ясады. Күп кенә региональ конфликтларның тыгыз төеннәрен сәяси чаралар кулланып чишәргә мөмкин булды.

**Мисал.** Үзәк Америкадагы (Никарагуа, Сальвадор), Африканың көньягындагы (Намибия), Көньяк-Көнчыгыш Азиядәге (Камбоджа) һәм БДБ илләрендә шундый конфликтлар сөйләшүләр юлы белән хәл ителде.

*Нәтиҗәдә халыкара киеренкелек кими башлады, дөньяда тынычлык һәм куркынычсызлык атмосферасы урнашты.*

Киеренкелекне йомшартуда Берләшкән Милләтләр Оешмасының (БМО) роле гаять зур (штаб-квартирасы Нью-Йоркта). (1 нче рәсемне карагыз.) 2007 елның башында БМОның 193 әгъзасы бар иде.

Ирешелгән казанышларга карамастан, дөньяның хәзерге сәяси картасында чагылыш тапкан күп кенә халыкара мәсьәләләр үзләренең чишелешен көтә.

Беренчедән, бу — бөтендөнья җәмгыятенә каршы чыгучы, күп илләрдә һәм районнарда сәяси хәлне кискенләштерүче, соңгы вакытта активлашкан халыкара терроризм белән көрәш.

**Мисал.** 2001 елның сентябрендә Согуд миллионеры халыкара «беренче номерлы террорист» Усама бен Ладен җитәкләгән «Аль-Каида» террористик оешмасы Нью-Йорк һәм Вашингтонга һавадан вәхшиләрчә һөҗүм итте. Дөньяның күпчелек илләре моны хөкем итеп чыктылар. Шуннан соң халыкара терроризм белән көрәш өчен күп илләр катнашында киң коалиция төзелде.

Икенчедән, региональ һәм локаль конфликтлар башланып китү. Алар ил чикләренә бәйле дәгъвалашулар яки дини-этник каршылыклар яки сепаратизм[1] нигезендә барлыкка килә. Бу конфликтларның күбесе Азиягә (Һиндстан, Шри-Ланка, Индонезия, Әфганстан, Израиль, Гыйрак һ.б.) һәм Африкага (Конго ДР, Судан, Эфиопия, Либерия һ. б.) кагыла, ләкин алар башка регионнарда да бар.

**1 нче мисал.** Һиндстан белән Пакистан арасында Кашмир өчен конфликт күп кенә елларга сузылды. Бу дәгъвалы өлкә даими киеренкелек тудыра, берничә хәрби бәрелеш, хәтта сугышка сәбәпче булды.

**2 нче мисал.** 1991 елда Югославия таркалганнан соң, аның урынында биш суверен дәүләт барлыкка килде, бу сәяси һәм милләтара мөнәсәбәтләрнең бик нык кискенләшүенә китерде. 90 нчы елларның беренче яртысында Босния белән Герцеговина җирендә Босния мөселманнары белән серблар арасында чын

---

[1] Сепаратизм (лат. *separatus* — аерылу) — аерылуга, бүленеп чыгуга юнәлтелгән һәм милли дәүләт төзүне төп максат итеп куйган сәясәт.

сугыш башланды. Ә 90 нчы еллар ахырында шундый каршылыклар үзәге Сербиядәге албаннар яши торган Косово җиренә күчте.

Өченчедән, атом-төш коралын таратуга каршы көрәш. Аны таратмау турында 1968 елда ук төзелгән Договор буенча атом-төш державалары «клубына» керү хокукы фәкать биш илгә — АКШ, СССР, Бөекбритания, Франция һәм Кытайга бирелде. Әмма атом-төш коралын эшләү белән рөхсәтсез Һиндстан, Пакистан, Иран, Гыйрак, Израиль, Төньяк Корея һәм башка илләр дә шөгыльләнә. XX һәм XXI гасырлар арасында Һиндстан һәм Пакистан фактик яктан атом-төш кораллы дәүләткә әверелделәр. 2003 елда КХДР үзендә атом бомбасы булу турында игълан итте. Дөнья җәмәгатьчелеге фикеренчә, мондый корал булдыруга Иран да омтыла. Гыйракның шундый коралы булуы турында фараз 2003 елда бу илгә каршы АКШ һәм аның союзниклары сугыш башлауга китерде. 2008 елда Кавказдагы сугыштан соң дөньяда хәл катлауланды. Бу шартларда Россия дөньяның күпполюслыгына нигезләнгән халыкара куркынычсызлык булдыруны яклап чыга. (3 нче иҗади бирем.)

## 3. ИЛЛӘРНЕҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕ БЕЛӘН ТАНЫШАБЫЗ

**1. Идарәнең төп ике формасы: республика һәм монархия.** Һәр илнең дәүләт төзелеше иң элек *идарә итү формасы* белән билгеләнә. Идарә формасының төп ике төре бар.

Идарә итүнең республика формасы аеруча киң таралган: дөньяда барлык бәйсез илләрнең 4/5 е — республикалар. **Республика** — дәүләт белән идарә итүнең шундый формасы: анда законнар чыгаручы югары хакимият — сайлап куелган вәкилле орган — парламент кулында (2 нче рәсемне карагыз), ә башкарма хакимият хөкүмәт кулында була. Республика дәүләт төзелеше Европада барлыкка килә. [5]. Азатлык алган күп кенә илләр, сәяси мөстәкыйльлеккә ирешкәннән соң, идарәнең республика формасын кабул итте. Хәтта меңнәрчә еллар буена монархия яшәп килгән Мисыр, Эфиопия һәм Иран кебек илләрдә дә республика игълан ителде.

Республикалар үз нәүбәтендә ике төргә: президент һәм парламент республикаларына бүленә. *Президент республикасында* (АКШ, Аргентина, Бразилия, Иран, Пакистан һ. б.) президентка бик зур хокуклар бирелә, һәм хөкүмәт белән ул үзе идарә итә. *Парламент республикасында* исә (ГФР, Италия, Израиль, Һиндстан һ. б.) президент түгел, бәлки хөкүмәт башлыгы төп фигура булып санала. Ләкин, асылда, парламент республикаларының күбесендә премьер-министр җитәкчелегендә эшләүче хөкүмәтләр булса да, президентларга бик зур вәкаләтләр бирелә, нәтиҗәдә бу республикалар президент республикаларыннан бик аз аерыла. Мәсәлән, Франция, Мисыр, шулай ук Россия һәм БДБ илләренең күпчелеге шундыйлардан санала.

Өстәп шуны әйтергә мөмкин: бөтендөнья социалистик системасы таркалуга карамастан, идарә формасы буенча Кытай, Вьетнам, КХДР һәм Куба әле дә *социалистик республикалар* рәтендә саналырга тиеш.

Идарәнең монархия формасы азрак таралган: дөньяда нибарысы 29 монархия бар. («Кушымта»дагы 2 нче таблицаны кара). **Монархия** ул идарәнең шундый формасы: анда император, король, герцог, кенәз, солтан һ.б. дәүләт башлыгы булып санала. Югары хакимият нәселдән-нәселгә күчә бара. Алар арасында *конституцион монархияләр* күбрәк очрый. Монда законнар чыгаручы реаль хакимият парламент карамагында, башкарма хакимият — хөкүмәт кулында, ә монарх үзе «патшалык итә, ләкин идарә итми». Мондый дәүләтләрдә монархия үзенә бертөрле мәңгеллык традиция буларак, кайчагында элеккеге «Таҗ-тәхет» бөеклеген искә төшерү өчен саклана.

**1 нче мисал.** Бөекбритания — дөньядагы иң өлкән конституцион монархия. Король (хәзер королева Елизавета II) дәүләт һәм хөкем системасының, дәүләт англикан чиркәвенең, шулай ук Бөекбритания җитәкчелегендәге Бердәмлек оешмасының башлыгы, кораллы көчләрнең башкомандующие булып исәпләнә. Элек Британия империясе составына кергән 50 ил бу Бердәмлекнең әгъзасы булып санала. [6]. Король парламент кабул иткән законнарга кул куя. Нормандия яулап алулары вакытыннан бирле король санкциясе формасы үзгәрми, «Король (королева) шулай тели!» дип бирелә. [7].

**2 нче мисал.** Япониядә — конституцион монархия. Традиция буенча император дәүләт һәм милләт бердәмлеге символы булып хезмәт итсә дә, законнар чыгаручы хакимият тулысынча парламент, ә башкарма хакимият министрлар кабинеты кулында. [8].

*Абсолют монархияләрдә*, киресенчә, монарх хакимлеге берни белән дә чикләнми. Дөньяның хәзерге сәяси картасында мондый илләр бик аз калган, нигездә, алар Фарсы култыгы районында күзәтелә.

**Мисал.** Согуд Гарәбстаны — абсолют монархия. Дәүләт башлыгы (король) — үзе законнар чыгаручы һәм башкарма хакимият эшләрен башкаручы, бер үк вакытта премьер-министр, кораллы көчләрнең башкомандующие, югары судья һәм шулай ук рухани башлык. Хөкүмәт, нигездә, король гаиләсе әгъзаларыннан формалаша. [9].

Абсолют монархиянең аеруча сирәк очрый торган төрләреннән берсе — ***теократик монархия***[1]. Аның мисаллары — Римдагы шәһәр-дәүләт Ватикан, Согуд Гарәбстаны корольлеге, Көньяк-Көнчыгыш Азиядәге Бруней солтанлыгы.

Дөньядагы монархияләрнең гомуми саны чагыштырмача стабиль саклана. Гадәттә, элеккеге монархияләр республикага әвереләләр. Ләкин соңгы чирек гасыр дәвамында шулай да яңа ике монархия

[1] Теократик монархияләрдә (грек. *theos* — алла) монарх бер үк вакытта дөньяви патша да, чиркәү башлыгы да.

игълан ителә. Испания белән озак еллар идарә иткән генерал Франко үлгәннән соң, 1975 елда бу илдә Бурбоннар династиясеннән король Хуан Карлос I башлыгындагы монархия урнаша. 1993 елда Камбоджада 23 ел буена яшәп килгән республика урынына идарәнең монархия формасы торгызыла.

**2. Административ-территориаль төзелешнең төп формалары: унитар һәм федератив дәүләтләр.** Теләсә нинди илнең дәүләт строе административ-территориаль төзелеш (бүленеш) формалары белән дә характерлана. Бу яктан барлык илләр ***унитар***[1] һәм ***федератив***[2] дәүләтләргә бүленә. Дөньяның күпчелек илләрендә унитар төзелеш урнашкан. Фәкать 24 ил генә федератив төзелешле. Аларның кайберләрендә (Россия, Швейцария, Һиндстан һәм Нигерия) бу милли-этник принципларга, ә башкаларында (ГФР, Австрия, АКШ) исә тарихи-географик үзенчәлекләргә бәйләнгән.

Хәзерге көндә административ-территориаль төзелеш мәсьәләсе күп кенә илләрдә мөһим сәяси проблемага әверелде. Бу иң элек Россия, Һиндстан, КАР, Канада кебек федератив төзелешле дәүләтләргә кагыла. (4 нче бирем.)

**Мисал.** Әле күптән түгел Бельгия унитар дәүләтләр рәтендә иде. Ләкин анда яшәүче валлоннар һәм фламандлылар арасында милли каршылыкларның кискенләшүе аркасында, парламент 1993 елда махсус закон белән илдә федератив административ-территориаль төзелеш урнаштыра.

## 4. СӘЯСИ ГЕОГРАФИЯНЕ ӨЙРӘНӘБЕЗ

**1. Сәяси география фәнни юнәлеш буларак. Сәяси география** — икътисади һәм социаль географиянең политология белән тоташкан урынындагы бер тармагы. Мөстәкыйль фәнни юнәлеш буларак ул XIX һәм XX гасырлар чигендә формалаша. Хәзерге вакытта аны, гадәттә, *сәяси күренешләр һәм процессларның территориаль дифференциациясе* турындагы фән дип билгелиләр. Ягъни сәяси география түбәндәгеләрне өйрәнә: а) дөньяның һәм аерым регионнарның сәяси картасы формалашу, б) сәяси чикләрнең үзгәрүе, в) дәүләт төзе-

---

[1] Унитар дәүләт (лат. *unitas* — бердәмлек мәгънәсендә) — административ-территориаль төзелеш формасы буенча илдә бердәм законнар чыгаручы һәм башкарма хакимият урнашкан дәүләт.

[2] Федератив дәүләтнең (лат. *foederatio* — союз, берләшмә мәгънәсендә) административ-территориаль төзелеш формасы буенча бердәм (федераль) законнар чыгаручы һәм хакимият органнары белән бергәттән, аерым үзидарәле территориаль берәмлекләре (республикалар, провинцияләр, җирләр, штатлар һ. б.) бар. Аларның үзләренең законнар чыгаручы, башкарма һәм хөкем хакимияте органнары бар.

лешенең үзенчәлекләре, г) сәяси партияләр, төркемнәр һәм блоклар, д) массакүләм сайлау кампанияләренең территориаль аспектлары (ул «электораль» география дип йөртелә). Барлык бу мәсьәләләр төрле дәрәҗәләрдә — глобаль, региональ, аерым ил һәм локаль дәрәҗәдә карала ала. Безнең илдә аерым илләргә, гадәттә, аларны сәяси-географик өйрәнүгә багышланган хезмәтләр күбрәк.

Илләр һәм районнарның **сәяси-географик (геосәяси) хәлен,** ягъни аларның сәяси хезмәттәшләренә һәм дошманнарына, төрле сәяси конфликтларга һ. б. га карата урнашуын бәяләү шулай ук әһәмияткә ия. Сәяси-географик хәл вакыт узу белән үзгәрә, һәм, димәк, ул — тарихи категория.

**Мисал.** 1991 елда СССР таркалганнан соң, Россиянең сәяси-географик хәле начар якка таба бик нык үзгәрде. Күп кенә элекке территорияләренең һәм акваторияләренең югалуы аның бигрәк тә көнбатыш чикләрендә үзен сиздерә.

**2. Сәяси география һәм геосәясәт. Геосәясәт** — сәяси географиянең состав өлеше. Ул беренче чиратта ил чикләренә һәм башка илләр, иң элек күрше илләр, арасындагы мөнәсәбәтләргә карата дәүләт сәясәтен белдерә.

Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышлары, шулай ук «салкын сугыш» чорында геосәясәт концепцияләре территорияләр яулап алуны, хәрби базалар төзүне, башка илләрнең эшләренә сәяси һәм хәрби тыкшынуны нигезләүгә юнәлгән иде. Мондый юнәлеш беркадәр дәрәҗәдә әле хәзер дә саклана, ләкин акцентлар әкренләп халыкара куркынычсызлыкны тәэмин итү сферасына таба күчә башлады. Россиядәге хәзерге геосәяси тикшеренүләр иң элек аның тышкы сәясәтенең төп юнәлешләре, халыкара мөнәсәбәтләрнең тулы системасы белән бәйләнгән. (5 нче иҗади бирем.)

**Төп нәтиҗә.** *Дөньяның сәяси картасы — чорның үзенә бер көзгесе. Ул һәрвакыт үзгәреп тора. Ләкин кешелек дөньясы тарихында бу картаның беркайчан да XX гасыр дәвамындагы кебек нык үзгәргәне юк иде.* (6 нчы йомгаклау биреме.)

### ӨСТӘМӘ ТЕКСТ (Кызыклы фактлар)

[1] Беренче бөтендөнья сугышыннан соң колонияләр һәм ярымколонияләр барлык коры җир территориясенең 72 % ын алып торган һәм анда Җирдәге барлык халыкның 70 % ы яшәгән. Бөекбританиянең 70 колониясе дөньяның барлык кисәкләрендә дә булган. Аларның мәйданы метрополиянекеннән 170 тапкыр зуррак, ә халкы 9 тапкыр чамасы артыграк. БМО мәгълүматлары буенча, XXI гасыр башында үзидарәсез территорияләрнең гомуми мәйданы һәм халкы 0,1 % тәшкил итә.

[2] Чит илләр арасында иң зур территориале дәүләт — Канада. Аның көньяк чиге Рим киңлеге буйлап уза, ә төньяк архипелаг-

тагы утрауларыннан Төньяк полюска кадәр фәкать 700 км ара кала. Канада гербындагы тасмага «Дәрьядан алып дәрьяга кадәр» дип язылган, әләмендәге ике кызыл юл да — нәкъ шуның символы. Австралия әләмендәге зәңгәр төс — шулай ук бу материк-илнең һәр яктан океан белән юылу символы.

[3] Тын океанның көнбатышында мәрҗән утрауда урнашкан Науру Республикасының мәйданы — 21 км$^2$ һәм халкы — 13 мең кеше.

[4] Нефть чыгаручы илләр белән идарә итүче югары катлау кешеләре «нефть долларлары» аркасында бик байый. Мәсәлән, Бруней солтаны дөньяда иң бай кешеләрдән санала. Аның тулы исеме: Муда Хассанал Болкиях Муизаддин Ваддаулах. Аның мал-мөлкәте 16 млрд доллар исәпләнә. 2005 елда үлгән Согуд Гарәбстаны короле Фахд Ибн-Әбдел Әзиз әл-Согуд тагын да баерак булган. Аның шәхси мал-мөлкәте 30 млрд доллар тәшкил иткән. Алар, дөньяда иң бай монархлар буларак, Гиннесс рекордлар китабына кертелгән. Шунда ук солтан сараенда 1778 бүлмә, 257 бәдрәф һәм 153 машинага гараж булуы турында язылган.

[5] Безнең көннәргә кадәр сакланган иң борынгы республика булып Сан-Марино микродәүләте санала. Бу республика 301 елда барлыкка килгән.

[6] Бердәмлек оешмасындагы илләрнең 16 сында Бөекбритания королевасы формаль рәвештә — дәүләт башлыгы, ә генерал-губернатор аның вәкиле булып санала. Бөекбританиянең Канада, Австралия, Яңа Зеландия кебек элекке доминионнарында да бу шулай ук. Алар элегрәк «Англия ана» атрибутларын, шул исәптән «И Тәңрем, королеваны сакла!» дигән гимнны бигрәк тә киң файдаланганнар. Хәзер инде Канаданың да, Австралиянең дә үз гимннары бар: алар «О Канада!» һәм «Алга, гүзәл Австралия!» дип башлана.

[7] Лондонда була торган иң тантаналы һәм матур йолаларның берсе — һәр елның ноябрь аенда королеваның үз резиденциясеннән — Букингем сараеннан парламент бинасына — Вестминстерга килеп тәхет нотыгын сөйләве. Королеваның каретасына парпар итеп алты ак ат җигелә. Атка урта гасыр камзуллары кигән форейторлар утыра. Королеваны Ватерлоо сугышы заманындагы парад формасы — ялтыравыклы кирасалар һәм каурыйлы шлем кигән драгуннарның атлы гвардия эскадроны озата бара. (3 нче рәсемне карагыз.)

[8] 1947 елгы конституцияне кабул иткәнгә кадәр Япониядә абсолют монархия яшәп килә. Ә аның законнары императорга чикләнмәгән хакимият биргән һәм аны аллалар нәселеннән дип санаган. 1947 елда абсолют монархия юкка чыгарыла, ләкин сакланып калган традицияләр аркасында илдә рәсми кабул

ителгән ел исәбе системаларының берсе («гэнго») чираттагы императорның идарә итү вакытына туры килә. 1989 ел башында 125 нче император Акихитоның тәхеткә утыруына бәйләнгән ел исәбенең яңа системасы «хэйсэй» дип атала, ә аны «җирдә һәм күктә гомуми тынычлык урнашу» дип тәрҗемә итәргә мөмкин.

[9] Согуд Гарәбстанының беренче короле Әбдел Әзиз Ибн-Согуд 1932 елдан алып 1953 елга кадәр ил белән идарә итә. Мәгълүм булганча, аның 17 рәсми хатыны булган, аларның бишесе «беренче хатын» титулын йөрткән. Хәзерге вакытта король гаиләсендә төрле туганлык дәрәҗәсендәге 5 мең ир заты бар, һәм дәүләтнең барлык җаваплы эш урыннары шул ир туганнар арасында бүленгән.

**Китап киштәсе**

1. Максаковский В. П. Географическая картина мира.— М.: Дрофа, 2008.— Ч.1.— Тема 1.
2. Максаковский В. П. Новое в мире: цифры и факты: Дополнительные главы к учебнику 10 кл.— М.: Дрофа, 2006.— Раздел 1.
3. Холина В. Н., Наумов А. С. География для школьников и абитуриентов: политическая карта мира: Пособие для учащихся.— М.: Просвещение, 2005.

## БЕЛЕМ һӘМ КҮНЕКМӘЛӘР ҮЗЛӘШТЕРҮ ӨЧЕН ТУПЛАНМА

**1 нче бирем.** Атласта дөньяның сәяси картасыннан һәм форзацта күрсәтелгән илләрнең «визит карточкаларыннан» файдаланып, а) территорияләре буенча дөньядагы иң зур җиде илне, б) халык саны 100 млн кешедән арткан 11 илне, в) ярымутрау, утрау һәм архипелаг-илләргә мисаллар, г) континент эчендәге илләргә мисалларны дәфтәрегезгә язып куегыз. Эш нәтиҗәләрен дәреслек текстын конкретлаштыру өчен файдаланыгыз. Сезнеңчә ничек, алар дәреслектәге нинди фикерләрне раслыйлар?

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** «Дөнья илләре» темасына кроссворд төзегез.

**2 нче бирем.** Дәреслектәге тексттан һәм атластагы дөньяның сәяси картасыннан файдаланып, дәфтәрегезгә төрле төркемчәләргә караган, үсеш алган һәм үсеш килүче илләргә берничәшәр мисал языгыз. Бер-берегезнең биремне ничек үтәвен тикшерегез.

**3 нче иҗади бирем.** Дәреслек текстыннан, вакытлы матбугат һәм телетапшырулар материалларыннан файдаланып, түбәндәге күренешләргә ачык мисаллар китерегез:

а) халыкара мөнәсәбәтләрдә уңай күренешләр;

б) мөнәсәбәтләрнең кискенләшүенә китерүче низаглы хәлләр.

**4 нче бирем.** Дәреслек форзацында бирелгән илләрнең «визит карточкасыннан» файдаланып, түбәндәге форма буенча «Дөньядагы илләрнең дәүләт төзелеше»н системалаштыручы (белешмә-конспект) таблица төзегез:

| Идарә формасы | | | Административ-территориаль төзелеш формасы | |
|---|---|---|---|---|
| Республикалар | Монархияләр | | Унитар дәүләтләр | Федератив дәүләтләр |
| | конституцион | абсолют | | |

Һәр графага мисал итеп берничә илнең исемен языгыз. Эш нәтиҗәләрен дәреслектәге материалны конкретлаштыру өчен файдаланыгыз.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** «Кушымта»дагы 2 нче таблицаны анализлагыз. Тарих фәненнән алынган белемнәрдән файдаланып, идарәнең монархия формасы ни өчен күбесенчә Европа һәм Азия чит илләрендә очрый, ә Төньяк Америкада бөтенләй юк икәнен аңлатыгыз.

**5 нче иҗади бирем.** Төрле мәгълүмат чыганакларыннан файдаланып, XX гасыр ахырында — XXI гасыр башында бөтендөнья җәмәгатьчелеге алдында торган әһәмиятле геосәясәт проблемаларына мисаллар китерегез.

**6 нчы йомгаклау биреме.** 1 нче теманың төп текстына анализ ясагыз. Аның бүлекләргә һәм бүлекчәләргә, аерым мәгънәви өлешләргә ничек бүленүен күздән кичерегез. Ни өчен бу текстта сирәкләп, курсив белән җыю, төп сүзләрне аерып күрсәтү кулланылуын аңлатыгыз.

## ҮЗЕГЕЗНЕҢ ҺӘМ БЕР-БЕРЕГЕЗНЕҢ БЕЛЕМНӘРЕН ТИКШЕРҮ ТУПЛАНМАСЫ

**Ничек аңлатырсыз:**

1. Хәзерге дөньяның күптөрлелеге нидән гыйбарәт?

2. Идарә итү һәм административ-территориаль төзелеш формасы ягыннан дөньядагы илләр нәрсә белән аерыла?

**Беләсезме:**

1. АКШ, ГФР, Франция, Бөекбритания һәм Япония арасында нинди уртаклык бар?

2. Түбәндә саналган илләрнең кайсылары иң характерлы мисал була ала:

а) идарә итүнең республика формасы урнашкан илләргә: Болгария, Польша, Бөекбритания, Франция, Япония, Согуд Гарәбстаны; б) федератив административ-территориаль төзелешле

илләргә: Бөекбритания, АКШ, ГФР, Франция, Һиндстан, Мисыр, Бразилия?

**Булдыра аласызмы:**

1. Текстта яки андагы карталарда искә алынган илләрне: Россия, Франция, Кытай, Япония, Согуд Гарәбстаны, Нигерия, АКШ, Канада, Бразилия һәм Австралияне контурлы картага хәтердән төшерә аласызмы?

2. Бу илләрнең кайсылары Икенче бөтендөнья сугышыннан соң сәяси бәйсезлек яулаганын билгели аласызмы: Иран, Һиндстан, Индонезия, Таиланд, Мисыр, Алжир, Колумбия, Мексика?

3. «Мең утрау иле» дигән атама туры килгән ике-өч илгә мисал китерегез.

4. Яңа индустриаль илләргә мисаллар китерә аласызмы?

5. «Суверен дәүләт», «республика», «федератив дәүләт», «сәяси география» терминнарына аңлатма бирә аласызмы?

## 1 НЧЕ ТЕМАГА МЕТОДИК АЧКЫЧЛАР

### Боларны исегезгә төшерегез

1. Иң яңа заман чорында дөньяның сәяси картасы формалашуның төп үзенчәлекләре. (Тарих, 9 нчы сыйныф.) 2. Евразия, Африка, Төньяк һәм Көньяк Америкадагы төп илләр. (География, 7 нче сыйныф.) 3. Хәзерге Россиянең геосәяси хәле. (География, 8 нче һәм 9 нчы сыйныфлар.)

### Боларны үзләштерегез

**1 нче теманың төп идеяләре**

1. Дөньяда сугыштан соң ике «бөек держава»ның көрәше белән характерлана торган гомуми тәртипнең үзгәрүе һәм халыкара климатның җылынуы — хәзерге чорның иң әһәмиятле үзенчәлеге. 2. Азия, Африка һәм Латин Америкасындагы йөздән артык илнең халыкара аренага чыгуы — хәзерге дөньяның бөек чынбарлыгы.

**1 нче темадагы төп фәнни белемнәр**

1. Хәзерге дөньяның күптөрлелеге һәм илләрнең типлары. 2. Халыкара мөнәсәбәтләрнең яңа этабы һәм хәзерге дөньяның сәяси картасында аның чагылышы. 3. Дөньядагы илләрнең идарә итү һәм административ-территориаль төзелеш формалары. 4. Сәяси география һәм геосәясәт. 5. Теманың төп сүзләре: 1) суверен дәүләт, 2) икътисади үсеш алган ил, 3) үсеп килүче ил, 4) региональ конфликт, 5) республика, 6) монархия, 7) унитар дәүләт, 8) федератив дәүләт, 9) сәяси география, 10) сәяси-географик хәл, 11) геосәясәт.

## 2 нче тема. ДӨНЬЯНЫҢ ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАРЫ ГЕОГРАФИЯСЕ. МОХИТНЕ САКЛАУ һӘМ АНЫҢ ПЫЧРАНУЫ

Табигый ресурслар һәм экологик проблемалар белән сез түбән сыйныфларда география курсыннан таныша башлаган идегез инде. Без аларны өйрәнүне дәвам итәрбез. Моның әһәмияте аеруча зур, чөнки бу проблема хәзерге география фәнендә иң әһәмиятлеләрдән, «дирижерлардан» санала. Ул географияне, барыннан да бигрәк, практика һәм фаразлау (прогнозлау) белән бәйли. Соңгы унъеллыкта география фәнендә табигый ресурслар географиясе, геоэкология, медицина географиясе, рекреацион география һ.б. кебек яңа фәнни юнәлешләр барлыкка килде.

### 1. ҖӘМГЫЯТЬ һӘМ ТАБИГАТЬНЕҢ ҮЗАРА ТӘЭСИР ИТЕШҮЕН ӨЙРӘНӘБЕЗ

**1. Географик тирәлек (мохит) төшенчәсе.** «Табигать» һәм «географик тирәлек», ягъни географик мохит төшенчәләре, нигездә, охшаш. Әмма «табигать» төшенчәсе киңрәк мәгънәдә.

Географик мохит «икенчел табигать», ягъни шәһәрләр, заводлар, каналлар, транспорт магистральләре һ.б. төзү, антропоген тәэсирендә географик тышчаның дәвамлы эволюциясе нәтиҗәсендә барлыкка килгән.

**Җирдәге табигатьнең кешелек җәмгыяте үзенең яшәве һәм җитештерү эшчәнлегендә билгеле бер тарихи үсеш этабында турыдан-туры тәэсир итешкән өлеше географик мохит дип атала.**

Географик мохит — кешелек җәмгыятенең яшәеше һәм эшчәнлеге өчен зарури шарт. Ул яшәү тирәлеге, табигый байлыкларның әһәмиятле чыганагы булып тора һәм кешеләрнең рухи дөньясына, сәламәтлегенә, кәефенә зур йогынты ясый.

Шуңа да карамастан географик мохитнең җәмгыять тормышындагы ролен билгеләгәндә еш кына ике төрле хата ясалды һәм әле дә ясала: аның әһәмиятен күпертеп бәяләү һәм, киресенчә, аны бәяләп җиткермәү.

Географик мохитнең әһәмиятен арттырып бәяләү *географик детерминизм*, яки, Н. Н. Баранскийча, *географик фатализм* дип атала. Ул XVIII—XIX гасырларда аеруча күренә, ләкин XX гасырның беренче яртысында да Франция, Германия, Россия һәм АКШның географларына аның йогынтысы зур була. Географик фатализм безнең көннәрдә, гадәттә, ярым яшерен формаларда очрый.

# 2 НЧЕ ТЕМАНЫҢ ПЛАН-СХЕМАСЫ



Географик мохитнең әһәмиятен бәяләп җиткермәүне Н. Н. Баранский *географик нигилизм* дип атаган. Бу бигрәк тә Советлар Союзына хас булгандыр, мөгаен, чөнки монда озак еллар буена түбәндәге лозунг хакимлек итте: «Без табигатьтән рәхим-шәфкать көтеп тормыйбыз, безнең бурыч — аны тартып алу».

Соңгы вакытта, географик мохит төшенчәсе белән беррәттән, **әйләнәтирә мохит** төшенчәсе дә кулланылышка керде. *Әйләнә-тирә мохит төшенчәсе кешелек җәмгыятенең барлык яшәү һәм җитештерү эшчәнлеге тирәлеген һәм, табигать белән антропоген тирәлекне дә кертеп, кеше әйләнәсендәге барлык материаль дөньяны үз эченә ала.*

Табигать тирәлеге турында гына сүз барганда, безне әйләндереп алган табигый мохит дип әйтү дөресрәк булыр.

**2. Җәмгыять белән табигать арасында «матдәләр алмашы»нда сыйфат ягыннан яңа этап.** *Кешелек җәмгыятенең барлык яшәү тарихы — аның табигать һәм географик мохит белән тәэсир итешү тарихы.* Бу үзара тәэсир итешү процессында җәмгыять һәрвакыт актив көч булып санала. К. Маркс әйткәнчә, алар арасында һәрдаим гаять катлаулы һәм күбесенчә каршылыклы «матдәләр алмашы» булып тора.

XX гасырда җәмгыять белән табигатьнең үзара тәэсир итешүендә сыйфат ягыннан яңа этап башлана. Җәмгыятьнең табигатькә «басымы» нык арта. Табигый ландшафтларның антропоген, ягъни шәһәрләр, тау промышленносте (5 нче рәсемне карагыз), авыл хуҗалыгы, урман хуҗалыклары, рекреацион ландшафтка әверелүе гадәттән тыш тизләшә, һаман яңа киңлекләргә тарала бара.

Шулай булуга карамастан географик мохитнең «кешеләшә» бару дәрәҗәсе әле һаман да бәхәсле килеш кала. Бу мәсьәләне академиклар Л. С. Берг (1876—1950), А. А. Григорьев (1883—1968), С. В. Калесник (1901—1977), И. П. Герасимов (1905—1985) һәм илебезнең башка бик күп географлары өйрәнде. Кайбер галимнәр инде безнең чорда Җирнең барлык табигый ландшафтлары яки барысы да диярлек антропогенга әверелгән дип исәплиләр. Бу мәсьәләдә алар Ф. Энгельсның Германиянең германлылар килгәнче булган табигый мохитеннән XIX гасыр ахырына «шайтаным да калмаган» дигән фикеренә таяналар. Икенчеләре андый ук катгый бәя бирүдән саклыналар.

**1 нче мисал.** Мәскәү университеты географ-галимнәренең исәпләүләренә караганда, хәзерге вакытта антропоген ландшафт коры җирнең 60 % тан артыграгын били. Шул территориянең 20 % ы чамасы тамырдан үзгәртелгән: анда хәзер шәһәрләр, авыллар, кырлар һәм бакчалар, юллар, тау эшләре алып барыла торган урыннар, утыртылган урманнар һәм ял итү урыннары. [1].

**2 нче мисал.** Россиядә актив хуҗалык эшчәнлеге кагылмаган

җирләрнең өлеше, төрле бәяләүләр буенча, илнең барлык территориясенең 50 % тан 60 % ка кадәрен алып тора. Бу исә «кыргый» җирләрнең гомуми мәйданы буенча Россиянең Канада, Австралия, Кытай һәм Бразилияне артта калдырып, дөньяда 1 нче урында торуын күрсәтә.

Кешелек җәмгыяте табигать байлыкларыннан торган саен күбрәк файдалана һәм бер үк вакытта үз эшчәнлегенең гаять күп санлы калдыкларын табигатькә күбрәк кайтара башлады.

*Шулай итеп, үзара бәйләнгән ике проблема барлыкка килде: 1) табигый байлыкларны рациональ файдалану; 2) мохитне пычранудан саклау.*

## 2. ДӨНЬЯНЫҢ ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАРЫН БӘЯЛИБЕЗ

**1. Ресурслар белән тәэмин ителеш төшенчәсе.** Җирнең географик тышчасында гаять күп төрле **табигый ресурслар** бар. Ләкин аларның һәрберсенең запасы бер үк дәрәҗәдә түгел, өстәвенә тигез дә урнашмаган. Нәтиҗәдә аерым төбәкләр, илләр, регионнар, хәтта материклар да ресурслар белән төрлечә тәэмин ителгән.

**Ресурслар белән тәэмин ителеш — табигый ресурсларның күләме белән аларны файдалану күләменең нисбәте. Ул бирелгән ресурс җитәргә тиешле еллар саны белән, яки аның җан башына исәпләнгән запасы белән билгеләнә.**

Әлбәттә, ресурслар белән тәэмин ителеш күрсәткече иң элек территориянең табигый ресурсларга бай яки ярлы булуына бәйле. Ләкин ул шул ук вакытта аларны чыгару (куллану) масштабларына да бәйле булганлыктан, бу төшенчәне *табигый төшенчә дип түгел, бәлки социаль-икътисади төшенчә итеп кабул итәргә кирәк.*

**Мисал.** Галимнәрнең исәпләүләренә караганда, дөньядагы минераль ягулыкның гомуми геологик запасы 5,5 трлн тонна шартлы ягулыктан артып китә. Бу исә, чыгару хәзерге темплар белән дәвам иткәндә, әлеге запас 350—400 елга җитәчәк дигән сүз! Әгәр дә ул запасларның чыгарырга мөмкин булганнарын гына (шул исәптән аларның ничек урнашуын), шулай ук кулланунын даими арта баруын исәпкә алсак, бу тәэмин ителеш берничә тапкыр кимрәк булыр.

Аңлашыла ки, озак вакытка исәпләнгән перспективада тәэмин ителешнең дәрәҗәсе файдалы казылмаларның теге яисә бу төре табигый ресурсларның кайсы классына керүенә дә бәйле: бетә (торгызыла алмый) торганынамы, әллә бетми (торгызыла ала) торганынамы. (1 нче иҗади бирем.)

**2. Минераль ресурслар җитәрлекме?** Минераль ресурсларның кайберләрен кешеләр бик борынгы заманнардан бирле файдалана белгәннәр. Без моның шулай икәнен кешелек цивилизациясе үсешенең таш гасыры кебек тарихи чорлары исемнәрендә күрәбез. Безнең көннәрдә минераль ресурсларның 200 дән артыграк төре файдаланыла. Академик А. Е. Ферсман (1883—1945), бик образлы итеп, хәзер




4 нче рәсем. Җир астыннан чыгарыла торган минераль чимал күләме



5 нче рәсем. КМА бассейнында тимер рудасы карьеры

1 нче таблица

**Кайбер төр файдалы казылмаларның деньядагы запаслары**

| Файдалы казылмаларның төрләре | Үлчәү берәмлеге | Гомум геологик запаслар | Шул исәптән тикшерелгән запаслар |
|---|---|---|---|
| Күмер | млрд т | 4000 | 1000 |
| Нефть | млрд т | 500 | 190 |
| Табигый газ | трлн $м^3$ | 400 | 175 |
| Тимер рудасы | млрд т | 350 | 165 |

кешелек дөньясының аяк астында Менделеев периодик системасының тулы өеме дип әйткән. [2].

Шулай да Җир кабыгын үз хәзинәләрен теләгән кадәр биреп торучы тылсымлы ашъяулык дип уйларга ярамый. Беренчедән, *минераль ресурсларның барысы да диярлек яңадан торгызыла алмый торган категориягә керә.* Икенчедән, аларның аерым төрләренең бөтен дөньядагы запасы бертигез түгел (1 нче таблицаны карагыз). Ниһаять, өченчедән, кешелек җәмгыятенең «нәфесе» дә гел артып тора. [3]. (2 нче бирем.)

Белгәнегезчә, Җир кабыгында файдалы казылмаларның таралып урнашуы геологик (тектоник) закончалыкларга буйсына.

Янучан файдалы казылмалар утырма токым рәвешендә барлыкка килгәннәр һәм, гадәттә, борынгы платформа тышлыгы, аның эчке һәм кырыйдагы бөгелешләре янында яталар.

Җир йөзендә 3,6 мең күмер бассейны һәм чыганагы билгеле, алар коры җирнең 15 % ын алып торалар. Бер геологик яшьтәге күмер бассейннары еш кына меңнәрчә километрга сузылган күмер туплану поясларын тәшкил итәләр. Күмер ресурсларының төп өлеше төньяк ярымшарга — Азия, Төньяк Америка һәм Европага туры килә, һәм ул бик зур ун бассейнда тупланган.

600 дән артыграк нефть һәм газ бассейннары эзләп табылган, ә нефть ятмаларының гомуми саны 50 меңгә җитә. Аның төп запаслары — төньяк ярымшарда, нигездә, мезозой ятмаларында. Бу запасларның төп өлеше шулай ук аз санлы гаять зур бассейннарда тупланган. Гигант нефть бассейннарының саны һәм запасы буенча бигрәк тә Фарсы култыгы районы («Кушымта»дагы 3 нче таблицаны карагыз), ә газ бассейннары саны буенча Россиядә Көнбатыш Себер аерылып тора («Кушымта»дагы 4 нче таблицаны карагыз).

Атом энергетикасы өчен кирәкле уран Җир кабыгында шактый күп таралган, ләкин 1 кг уран чыгаруның үзкыйммәте 80 доллардан артмаган чыганакларда гына моны эшләү икътисади файдалы. Мондый уранның дөньяда тикшереп табылган запасы 3,5 млн тонна исәпләнә. Ул, нигездә, Австралия, Казахстан, Канада, АКШ, КАР, Нигер, Бразилия, Намибия, шулай ук Россия һәм Үзбәкстан арасында бүленгән. (3 нче бирем.)

Рудалы файдалы казылмалар, гадәттә, борынгы платформалар нигезенә, калкан кебек чыгынтыларына һәм шулай ук җыерчыклы өлкәләренә тупланган. Мондый өлкәләрдә алар еш кына бик еракларга сузылган рудалы (металлогеник) пояслар тәшкил итәләр, ә аларның килеп чыгышы Җир кабыгының бик тирәндә ярылган урыннарына бәйле. Андый поясларның территорияләре (Альп-Һималай, Тын океан пояслары) тау һәм металлургия промышленносте өчен чимал базасы хезмәтен үтиләр. Аерым төбәкләрнең, хәтта аерым илләрнең хуҗалык юнәлешен еш кына шулар билгели.

Тимер рудасының иң зур запаслары — Россия, Австралия,

Украина, Кытай һәм Бразилиядә, («Кушымта»дагы 5 нче таблицаны карагыз), бокситларның — Гвинея, Австралия, Бразилия, Ямайкада, бакыр рудасының — Чили, АКШ, Канадада.

Руда булмаган файдалы казылмалар да (фосфоритлар, калий һәм аш тозы, күкерт һ. б.) киң таралган. Аларның чыганаклары платформалы өлкәләрдә дә, җыерчыклы өлкәләрдә дә очрый.

Литосфера ресурсларына Җирнең бик тирәндәге җылылык энергиясен, ягъни геотермаль энергияне дә кертергә кирәк. Аның ресурслары 50 илдә табылган. Сейсмик һәм вулканик активлыгы зур булган районнарда (Исландия, Италия, Яңа Зеландия, Филиппин, Мексика, Россиядә Камчатка һәм Төньяк Кавказ, АКШта — Калифорния) аларның запасы аеруча зур.

Хуҗалык максатларында үзләштерү өчен *файдалы казылмаларның территориаль бергә туры килүе* бигрәк тә отышлы, чөнки мондый очракта чималны комплекслы эшкәртү, эре территориаль-җитештерү комплексларын булдыру эше җиңеләя. Казылма байлыкларның территориаль бергә туры килүе турында география-галимнәр тәкъдим иткән фәнни концепциянең практик әһәмияте гаять зур.

Хәзерге вакытта файдалы казылмаларны эзләү төп ике юнәлештә: «тирәнгә» һәм «киңлеккә» таба алып барыла.

«Тирәнгә» юнәлеше Европа чит илләренә, Россиянең Европа өлешенә, Украинага, АКШка хас, чөнки монда Җир кабыгының югары катламнарындагы чыганаклар һәм бассейннар инде бик ярлыланган. Ул җирләрдә файдалы казылмалар чыгаруның тау-геологик шартлары начарая, шахта тирәнлеге арта бара.

«Киңлеккә» таба эшкәртү юнәлеше минераль ресурсларны үзләштерү соңрак башланган илләрдә: Россиянең Азия өлешендә, Канада, Австралия һәм Бразилиядә күбрәк кулланыла. Кагыйдә буларак, мондагы тау-геологик шартлар уңайлырак, эшкәртү тирәнлеге артык зур түгел.

**3. Җир ресурслары: ике капма-каршы процесс.** Җир — табигатьнең иң төп ресурсларыннан берсе, яшәү чыганагы. «Муллыкның атасы — хезмәт, ә анасы — җир»,— дип юкка гына әйтмиләр бит. Җир ресурслары кешеләрнең яшәве һәм хуҗалыкның барлык тармаклары өчен кирәк.

Кешелекнең җир белән тәэмин ителеше дөньяның җир фонды белән билгеләнә, ә ул фонд 13,4 млрд гектар исәпләнә. 6 нчы рәсемнән күргәнегезчә, тулаем алганда, аның структурасы бик үк уңайлы түгел. Кешегә кирәкле туклану продуктларының 88 % ын биргән эшкәртелә торган җирләр аеруча югары бәяләнә. Эшкәртелә торган җирләр (иң әлек сөрү җирләре) планетабызның, нигездә, урман, урман-дала һәм дала зоналарында тупланган. Шулай ук болыннар һәм көтүлек җирләренең дә әһәмияте зур: алар кешеләр куллана торган азыкның 10 % ын бирәләр.

3 НЧЕ ТУПЛАНМА

6 нчы рәсем. Дөньядагы җир фондының зурлыгы һәм структурасы

7 нче рәсем. Җир ресурслары белән тәэмин ителеш

8 нче рәсем. Елга суы ресурслары белән тәэмин ителеш

9 нчы рәсем. Урман ресурслары белән тәэмин ителеш




КАНАДА
87
США
8
НОРВЕГИЯ
90
ПОЛЬША
1
ФРГ
2
ФРАНЦИЯ
3
ИСПАНИЯ
3
РОССИЯ
26
КИТАЙ
2
ЕГИПЕТ
менее 1
САУДОВСКАЯ АРАВИЯ
0,1
ИНДИЯ
1,5
ВЕНЕСУЭЛА
60
СУРИНАМ
470
ЛИБЕРИЯ
70
КОНГО
310
БРАЗИЛИЯ
42
ИНДОНЕЗИЯ
12
МАДАГАСКАР
23
ЮАР
1
90
НОВАЯ ЗЕЛАНДИЯ
Елга суы ресурслары белән тәэмин ителеш
(җан башына мең м³ елына)
5 тән ким
кытлык
5—25
уртача
25 тән артык
җитәрлек һәм артык
48 Аерым илләр һәм аларның өлешләренең тәэмин ителеше
7,0 Бөтендөньяда уртача

8


КАНАДА
14
США
1,0
МЕКСИКА
0,7
ШВЕЦИЯ
3,0
ФИНЛЯНДИЯ
4,0
ПОЛЬША
0,3
ФРГ
0,06
ВЕЛИКОБРИТАНИЯ
0,03
ИТАЛИЯ
0,1
РОССИЯ
6
ЯПОНИЯ
0,2
КИТАЙ
0,1
ЛИВИЯ
0,07
САУДОВСКАЯ АРАВИЯ
0,1
0,03
АФГАНИСТАН
ИНДИЯ
0,08
СУРИНАМ
36,0
144
ГВИАНА
ГАБОН
36,0
0,06
СОМАЛИ
ПАПУА-НОВАЯ ГВИНЕЯ
15
ИНДОНЕЗИЯ
0,7
БРАЗИЛИЯ
3,4
КОНГО
28
АВСТРАЛИЯ
7
БОЛИВИЯ
9,0
ЮАР
0,06
2,0
АРГЕНТИНА
Ылыслы урманнар
Тропик һәм экваториаль урманнар
Бөтендөньяда уртача күрсәткеч
0,6
Уртача пояснның катнаш урманнары
0,3 урман ресурслары белән тәэмин ителеш (җан башына га)

9

Ләкин *планетабыздагы җир фондының структурасы үзгәрешсез калмый.* Аңа даими рәвештә капма-каршы характерлы и к е п р о ц е с с тәэсир итә.

Бер яктан, кешеләр меңнәрчә еллар буена яшәү һәм авыл хуҗалыгында файдалану өчен яраклы җирләрне арттыру-киңәйтү эшен алып барганнар. XX гасыр дәвамында гына да сөрүле җир мәйданы ике тапкыр арткан. Бу яктан чирәм җирләрне үзләштерү масштабы буенча бигрәк тә элекке Советлар Союзы, АКШ, Канада, Кытай, Бразилия аерылып тора. Аз җирле, халкы тыгыз урнашкан илләр (Нидерланд, Япония һ.б.) диңгез яр буйларын актив үзләштерәләр.

Икенче яктан, җирләр һаман начарая, уңдырышсызлана бара. Эрозиядән ел саен 6—7 млн гектар җир, яраксызга әйләнеп, авыл хуҗалыгы әйләнешеннән чыга. Җирләрнең сазлыкка әверелүеннән, тозлылануыннан тагын 1,5 млн гектар җир әйләнештән төшеп кала. Шәһәрләр үсә барган саен, торак йортлар, промышленность һәм транспорт төзелеше авыл хуҗалыгы җирләренә күбрәк керә.

Дөньяның корылыклы регионнарында чөлләнү күп «җирләрне ашый».

**Мисал.** Берничә дистә илдә, күбесенчә үсеп килүче илләрдә, инде 1 млрд гектар җир чүлгә әйләнде, тагын 3 млрд гектар җир чүлгә әйләнү алдында тора. Сахара, Атакама, Тар, Намиб һәм башка чүлләрнең чикләре һаман киңәя бара. Галимнәр исәпләвенчә, әгәр чүлләнү шундый ук темплар белән барса, тагын 30 елдан Көнбатыш Европаның яртысы кадәр территориянең чүлгә әверелүе ихтимал. [4].

Галимнәр чүлләнүне дүрт дәрәҗәгә бүләләр: көчсез, уртача, көчле һәм бик көчле. Чүлләнүнең көчлесе Азия, Африка, Төньяк һәм Көньяк Америка, Австралиядә (атластагы картаны карагыз) таралган.

Чүлгә әверелү көчле булган җирләрне яңадан торгызу өчен бик күп капитал кертүләр таләп ителә һәм торгызу эше бик озакка сузыла. Ә чүлләнү бик көчле барган җирләр торгызыла алмый, деградацияләнә. Шуңа карамастан көчле һәм бик көчле чүлләнү барган районнарда 1 млрд чамасы кеше яши.

*Бу процесслар нәтиҗәсендә җиргә төшкән «йөкләмә» һаман арта, ә җир ресурслары белән тәэмин ителү кими бара.*

**Мисал.** Җирдә яшәүче һәр кешегә 70 нче елларда 0,45 гектар эшкәртелә торган җир туры килә иде, бу күрсәткеч 90 нчы еллар башында — 0,28 гектарга, ә XXI гасыр башында 0,20 гектарга кадәр кимеде.

Бәлагә очраганда бирелә торган SOS (save our souls) сигналын сез, мөгаен, беләсездер инде. Аның инглизчәдән тәрҗемәсе «безнең җаннарыбызны коткарыгыз» дигәнне аңлата. Хәзерге вакытта бөтен дөньядагы туфрак белгечләре тормышка ашыра торган программа да SOS (save our soils) дип атала, ягъни «безнең туфракларны коткарыгыз» дигән девиз астында бара. БМО даирәләре җитәкчелегендә чүлләнүгә каршы зур эшләр

алып барыла. Анда географлар да актив катнашалар. (4 нче бирем.)

**4. Коры җирдәге су ресурслары: төче су проблемасы.** Әле күптән түгел су, һава шикелле үк, табигатьнең бушлай килгән хәзинәләреннән берсе санала иде; ул ясалма сугарулы төбәкләрдә генә һәрвакыт югары бәяләнеп килде. Соңгы вакытта коры җирдәге су ресурсларына мөнәсәбәт үзгәрде. Бу хәл гидросфераның гомуми күләмендә төче су ресурсларының өлеше 2,5% кына булу белән аңлатыла. Аның абсолют зурлыкларда исәпләнгән микъдары (35 млн км$^3$) гаять зур һәм кешелекнең хәзерге таләбеннән күп тапкырлар артып китә. Ләкин төче суның төп өлеше Антарктида, Гренландия, Арктика бозлыкларында, шулай ук тау түбәләре бозлыкларында тупланган һәм үзенә бертөрле «кагылгысыз запас» тәшкил итә, әлегә аны файдаланып булмый.

Проблеманың асылы менә нәрсәдә: кешеләрнең төче суга ихтыяҗын канәгатьләндерүче төп чыганак булып гомер буена елга сулары саналды һәм хәзер дә шулай, ә аның планетадагы өлеше 48 мең км$^3$. Бу әллә ни зур сан түгел, чөнки чынлыкта аның фәкать яртысын гына файдаланырга мөмкин. Ә төче су куллану күләме гел артып тора, һәм 2005 елда аны куллану 6 мең км$^3$ дан артып китте. Өстәвенә суны иң күп кулланучы — авыл хуҗалыгы, ә анда суның күп өлеше табигатькә кире кайтмый, бигрәк тә сугару өчен сарыф ителгән су. Суны промышленностьта, энергетикада һәм коммуналь көнкүрештә куллану күләме дә шулай ук һәрвакыт арта бара. Икътисади үсеш алган илләрдә бер шәһәр кешесе тәүлеккә 300—400 литр су сарыф итә. *Елга ресурслары үзгәрешсез калып, су куллану күләменең шулай һаман артуы төче су җитмәү куркынычын тудыра.*

Шуның белән беррәттән, суның күләмен генә түгел, ә сыйфатын да исәпкә алырга кирәк. Үсеп килүче илләрдә яшәүче һәр өченче кеше су кытлыгыннан җәфалана. Барлык авыруларның 3/4 енең һәм үлү очракларының 1/3 енең сәбәбе — пычрак су куллануда.

**Мисал.** Азиядә 1 млрд тан артыграк кеше, Африкада исә Сахарадан көньякка таба 350 млн һәм Латин Америкасында 100 млн кеше чиста су файдалана алмый.

Өстәвенә төче су запаслары Җирдә бик тигезсез таралган. Экваториаль пояста һәм уртача поясның төньяк өлешендә су җитәрлек күләмдә, хәтта артыграк та. Монда күп сулы илләр урнашкан, һәм җан башына елына 25 мең м$^3$ дан артыграк су туры килә. Коры җир территориясенең 1/3 өлешен алып торган корылыклы пояста су кытлыгы үзен аеруча нык сиздерә. Монда җан башына елына 1 мең м$^3$ дан да азрак су туры килгән иң сусыз илләр урнашкан. Әлеге илләрдә авыл хуҗалыгы ясалма сугару булганда гына мөмкин.

Кешелекнең су проблемасын хәл итүнең берничә юлы бар. Аларның иң әһәмиятлесе — җитештерү процессларының сусыешлыгын һәм су югалуларны киметү. Беренче чиратта бу корыч, синтетик сүсләр, целлюлоза һәм кәгазь җитештерү кебек технологик процесс-

ларга, энергоблокларны суытуга, дөге һәм мамык үстерү кырларын сугаруга кагыла. Су проблемасын хәл итүдә, елга суларын куллануны көйләү өчен, сусаклагычлар төзүнең әһәмияте зур.

**Мисал.** Дөньяда барлыгы 60 меңнән артыграк сусаклагыч бар. Аларның гомуми күләме (6,6 мең км$^3$) Җир шарындагы барлык елгалардагы суның бер вакыт аралыгында исәпләнгән күләменнән 3,5 тапкыр артыграк. Барлык сусаклагычларның гомуми мәйданы 400 мең км$^2$ тәшкил итә, ә ул Азов диңгезе мәйданыннан 10 тапкыр зуррак. Зур сусаклагычларның саны ягыннан АКШ, Канада, Россия, Африка һәм Латин Америкасындагы кайбер илләр аерылып тора.

АКШ, Канада, Австралия, Һиндстан, Мексика, Кытай, Мисыр һәм БДБга кергән кайбер илләрдә елга суларын күчерү юлы белән аның территориядә яңача бүленешенең күп санлы проектлары эшләнә. Ләкин соңгы вакытта эшнең икътисади ягын һәм табигатьне саклау мәсьәләләрен истә тотып, суны бассейнара күчерү буенча төзелгән зур масштаблы проектлар кире кагылды. Фарсы култыгы һәм Урта диңгез буе илләрендә, Төркмәнстанда, Каспий диңгезендә, АКШның көньягында, Япониядә, Кариб диңгезе утрауларында диңгез суын төчеләндерү ысулы кулланыла; мондый суны дөньяда иң күп җитештерүче ил — Кувейт. Төче су бөтен дөньяда сәүдә товарына әверелде: аны диңгез танкерлары белән ташыйлар, сууткәргеч торбалар буйлап бик еракларга озаталар. [5]. Корылык поясындагы илләргә Антарктикадан буксирлап айсбергларны китертү проектлары эшләнә. Поляр җәй җитү белән, бирелән ел саен 1200 млн тонна төче су тупланган айсберглар юлга чыга. [6].

Белгәнебезчә, елгалар **су энергиясе** алу өчен киң кулланыла. Дөньяда файдаланырга яраклы *гидроэнергетик потенциал* 8 трлн кВт·сәг чамасы электр энергиясе җитештерерлек дип бәяләнә. Бу потенциалның 1/2 чамасы нибары 6 илгә: Кытай, Россия, Һиндстан, Конго ДР, Канада һәм Бразилиягә туры килә. (5 нче бирем.)

**5. Биологик ресурсларның ярлылануын туктатырга!**

Җирнең биомассасын үсемлек һәм хайван организмнары булдыра.

**Үсемлек ресурслары** культуралы һәм кыргый үсемлекләрдән тора. Якынча барысы 6 мең культуралы үсемлек төре исәпләнә. Ләкин Җирдә авыл хуҗалыгы культураларының нибары 80—90 төре генә киң таралган, ә иң күп таралганнары фәкать 15—20 генә: бодай, кукуруз, арпа, батат, соя һ.б.

Кыргый үсемлекләрнең күбесе урманнарда үсә, һәм алар **урман ресурсларын** тәшкил итә. Алар җир ресурслары кебек үк тотыла, яңартыла һәм күп төрле максатларда файдаланыла. Дөньядагы урман ресурслары төп ике күрсәткеч белән характерлана: урман мәйданының зурлыгы (4,1 млрд га) һәм тамырдагы агач запасы (330 млрд м$^3$). Даими үсеп торганлыктан, бу запас ел саен 5,5 млрд м$^3$ га арта бара. Мондый шартларда урман ресурсларының бетүе турында сөйләү

урынсыз кебек. Ләкин ул бер дә алай түгел.

Агач бик күптәнге вакытлардан бирле төзү, агач әйберләре җитештерү материалы буларак бик киң кулланылып килде; хәзер ул бигрәк тә күп кулланыла. [7]. Әле безнең көннәрдә дә утынга ихтыяж зур. Дөньяда җитештерелә торган агачның 1/2 чамасы шул максатта тотыла. Ниһаять, меңләгән еллар буена — игенчелек дөньяга килгән неолит чорыннан башлап — урманнар сөрү җирләренә, плантацияләргә әверелдерелеп килә. Соңгы ике йөз ел эчендә генә дә коры җирнең урманлы өлеше ике тапкыр кимеде, һәм бу хәл **урманнар бетү** куркынычын тудырды. Туфрак эрозиясенең киңәюе, атмосферада кислород запасы кимү дә урманнар азаюга бәйләнгән.

**Мисал.** Дөньядагы урманнар мәйданы ел саен аз дигәндә 15 млн га га, ягъни 0,4 % ка кими. Бөтен дөньяда агач җитештерү якын киләчәктә 5 млрд $м^3$ га җитәргә мөмкин. Бу исә — агачның дөньядагы еллык артымы тулысынча тотылып бетәчәк дигән сүз.

*Дөньядагы урманнар гаять озын ике пояс — төньяк һәм көньяк урман поясларын тәшкил итә.*

Төньяк урман поясы уртача һәм беркадәр салкын һәм субтропик климатлар зонасына урнашкан. Дөньядагы барлык урман массивларының 1/2 е һәм агач запасының шулкадәр үк диярлек өлеше шушы урман поясына туры килә. Монда төп агач әзерләү эшләре бара, барыннан да элек, аеруча кыйммәтле ылыслы агачлар токымы эшкәртелә. Интенсив кисүгә карамастан, урманны торгызу һәм үрчетү эшләре даими алып барылу сәбәпле (АКШ, Канада, Финляндия һәм Швециядә), төньяк пояс урманнарының гомуми мәйданы кимеми.

Көньяк урман поясы, нигездә, тропик һәм экваториаль климатлар зонасына урнашкан. Дөньядагы урман массивларының һәм гомуми агач запасының 1/2 е шушы поястагы урманнарга туры килә. Аны элек, нигездә, утын итеп файдаланганнар. Соңгы вакытта агач Япониягә, Көнбатыш Европага һәм АКШка чыгарыла һәм агач экспорты күп тапкырлар артты. Йөзләрчә еллар буена урманны төптән кисеп яндыру юлы белән алып барыла торган игенчелек системасы һәм урманнарны көтүлекләргә әверелдерү шулай ук көньяк пояс урманнарына зур зыян китерә. Болар бу пояс урманнарының катастрофалы рәвештә бик тиз кимүенә сәбәп була.

**Мисал.** Мәңге яшел дымлы тропик урманнар 1 млрд гектардан артыграк мәйдан алып торалар, аның яртысыннан артыграгы Латин Америкасында. Ләкин Латин Америкасы һәм Азия мондый урманнарның 40 % ын, ә Африка 50 % ын инде югалтты. Галимнәр фикеренчә, бу урманнарга XXI гасыр урталарында бөтенләй юкка чыгу куркынычы яный. [8].

Тропик урманнарны саклау буенча БМО җитәкчелегендә зур эшләр башланды, ләкин әле хәзергә аларның көтелгән нәтиҗәләргә китергәне юк. *Шуңа күрә дә урман ресурсларыннан рациональ файдалану чаралары әле һаман*

*да аеруча актуаль мәсьәләләрдән санала.* (6 нчы бирем.)

Хайваннар дөньясы ресурслары, биосфераның состав өлеше буларак, яшәү өчен аеруча әһәмиятле тагын бер ресурс булып санала, һәм ул торгызыла торган категориягә керә. Җир шарында хайваннарның берничә миллион төре исәпләнә (үсемлекләр төреннән күпкә артыграк), аларның беркадәресе — йорт хайваннары, икенчеләре — ау хайваннары һ.б. Үсемлекләр һәм хайваннар барысы бергә планетаның ***генетик фондын (генофонд)***[1] тәшкил итәләр, ул да шулай ук кимүдән саклауга мохтаҗ.

**Мисал.** 1600 елдан 1995 елга кадәр Җир йөзендәге хайваннарның 600 дән артыграк төре юкка чыккан, тагын 3,5 мең төргә (умырткасызларны санамаганда) юкка чыгу куркынычы яный. Европадагы хайваннар дөньясы аеруча көчле басым астында, бигрәк тә имезүче хайваннарның бик күп төрләре, барлык кош төрләренең 30 % тан 50 % ка кадәре юкка чыгу чигенә җиткән. Африкада һәм Азиядә фил көтүләренең бик тиз кими баруы да — генофонд фәкыйрьләнүенең ачык мисалы. [9].

*Биологик төрлелекне саклау, генофонд «эрозиясен» булдырмау — бик әһәмиятле мәсьәлә.*

**6. Дөнья океаны ресурслары: хәзинәләр чыганагы.** Ихтимал, сезнең ишеткәнегез дә бардыр: соңгы берничә дистә елда бөтен дөньядагы галим-океанологлар, шул исәптән ватан океанологиясенә нигез салучылар Ю. М. Шокальский (1856—1940), В. Ю. Визе (1886—1954), Н. Н. Зубов (1885—1960), П. П. Ширшов (1905—1953), К. К. Марковның (1905—1980) тикшеренүләре һәм дистәләрчә экспедицияләрнең эше нәтиҗәсендә кешеләр Дөнья океанының бик күп серләренә төшенделәр. Диңгез геологиясе ярдәмендә *Океанның гаять зур табигый ресурслар чыганагы икәнлеге һәм аның потенциалы коры җир ресурсларына тиң булуы исбатланды.*

Бу — иң элек диңгез суы үзе. Аның запасы гаять зур һәм ул 1370 млн км$^3$, яки барлык гидросфера күләменең 96,5 % ын тәшкил итә. [10]. Моннан тыш, диңгез суы — үзенә бертөрле «тере руда», анда 80 төрле химик элемент бар. Борынгы Мисырда һәм Кытайда инде бик күптәннән бирле диңгез суыннан тоз алырга өйрәнгәннәр һәм әле хәзер дә аны бик күп микъдарда алалар.

**Мисал.** Кытайның яр буенда тоз чыгару промыселлары 5 мең елдан артыграк эшли. Ул яр сызыгы буйлап 8 мең км га сузылган һәм 400 мең гектардан артыграк мәйдан били, ә тоз чыгаруның еллык күләме 20 млн тоннага җитә.

Диңгез суы шулай ук, магний, бром, йод һәм башка химик элементлар табу өчен, әһәмиятле чыганак булып хезмәт итә. [11].

Океан төбендәге минераль ресурслар да шуңа керә. Конти-

---

[1] Генофонд (лат. «ген» һәм франц. *fond* — нигез сүзләреннән) — билгеле бер популяция хасил итүче затларның геннары җыелмасы. Биосфера генофонды — хәзерге вакытта Җирдә яши торган барлык төрләрнең җыелмасы.

нентАль шельф ресурсларыннан нефть һәм табигый газ иң әһәмиятлеләреннән санала; күп кенә бәяләүләргә караганда, алар гомумдөнья запасының 1/3 ен тәшкил итәләр. Шельфның каты токымлы файдалы казылмаларын авыш шахталар һәм драгалар ярдәмендә чыгаралар (әлбәттә, чын-чыннан «алтын катламы», ягъни баткан суднолар байлыгын санамаганда, ә алар хәзерге вакытта еш кына «бәхет эзләүче рыцарьлар» табышына әйләнә). [12]. Тирән сулы Океан төбенең төп байлыгы — тимер-марганец конкрецияләре.

Тимер-марганец конкрецияләре XIX гасырның 70 нче елларында «Гломар Челленджер» инглиз фәнни-тикшеренү судносы ярдәмендә Дөнья океанының тирән төбендә табыла. Моннан соң да аны өйрәнү дәвам итә, шул исәптән ватаныбызның «Витязь», «Академик Курчатов», «Дмитрий Менделеев» экспедиция суднолары һ.б. бу эшне дәвам иттерәләр. Нәтиҗәдә бу конкрецияләрнең түгәрәк формалы коңгырт төстәге минерал икәнлеге, аларның барлык океан төпләрендә дә булуы һәм төпкә тушәлеп ятуы мәгълүм була. Аларның тулаем запасы 2—3 трлн тонна бәяләнә, ә чыгарырга мөмкин микъдары 250—300 млрд тонна исәпләнә. Конкреция каплап алган иң зур мәйданнар Тын океан төбендә урнаша. Хәзерге вакытта аны промышленностьта эшкәртү мөмкинлекләре өйрәнелә.

Дөнья океанының энергетик ресурслары океан суларының тәүлек эчендә күтәрелеш һәм чигенү хәрәкәтләрендә, диңгез дулкыннары һәм температура градиенты энергиясендә тупланган. Аның потенциалы гаять зур.

Планетабыздагы су күтәрелешенең суммар егәрлеген галимнәр 1 млрд тан 6 млрд кВт ка кадәр дип бәялиләр, өстәвенә бу егәрлек Җир шарындагы барлык елгалар энергиясеннән артып китә. Су күтәрелеше энергиясе белән эшли торган куәтле электр станцияләре төзү өчен, 25—30 урын яраклы дип табылган. Су күтәрелеше энергиясенең иң зур ресурслары Россия, Франция, Канада, Бөекбритания, Австралия, Аргентина һәм АКШта. Бу илләрдә су 10—15 м биеклеккә күтәрелә торган яр буе районнары бар.

Ниһаять, Дөнья океанының биологик ресурслары. Моңа хайваннар (балыклар, имезүчеләр, моллюсклар, кысласыманнар) һәм океан суларындагы үсемлекләр керә. Океанның биологик массасында 180 мең төр, ә аның гомуми күләме 35—40 млрд тонна исәпләнә. Ләкин аның төп өлеше — фитопланктон һәм зообентос, ә нектонга исә (балыклар, имезүчеләр, кальмарлар, креветкалар һ.б.) 1 млрд тоннадан бераз гына артыграк туры килә.

Дөнья океанында, коры җирдәге кебек үк, продуктлылыгы азрак һәм күбрәк булган өлкәләр — акваторияләр бар. Бу билгегә таянып, акваторияләрне бик югары, уртача, аз һәм бигрәк тә аз продуктлы дип бүлеп йөртәләр. Дөнья океанының иң күп продуктлы

акваторияләре төньяк киңлекләрдәге Норвегия, Беринг, Охота һәм Япон диңгезләрендә, шулай ук Атлантик һәм Тын океанның төньяктагы ачык өлешендә урнашкан. Югары продуктлы бу акваторияләрне В.И.Вернадский *тереклек куертмалары* дип атады.

Ләкин Дөнья океанындагы промысел балыкларының һәм хайваннарының күпчелеге шулай ук саклауга мохтаҗ. [13]. (7 нче бирем.)

**7. Климатик һәм космик ресурслар — киләчәк ресурслары.** Кояш — гаять зур термик-төш реакторы, ул — җирдәге барлык тереклекнең генә түгел, бәлки барлык энергетик ресурсларның иң беренчел чыганагы да. Кояш нурларының җылысын кешеләр файдасына эффектив куллану мөмкинлеген Гелиосны олылаучы борынгы греклар да белгән. Легендаларда Архимедның Сиракузда Рим корабльләренә каршы сугышта кояш нурларын корал итеп файдалануы турында сөйләнә.

Кояш нурларының атмосфераның түбәнге катлауларына һәм җир өстенә килеп җиткән еллык агышы энергиясе гаять зур сан белән үлчәнә ($10^{14}$ кВт), һәм ул җир астында тикшереп табылган ягулык запасларында тупланган энергиядән уннарча тапкыр, ә дөньяда энергия куллануның хәзерге дәрәҗәсеннән меңнәрчә тапкыр артып китә. Табигый ки, кояш энергиясеннән файдалану өчен иң уңайлы шартлар Җирнең коры климатлы поясында, чөнки Кояшның иң дәвамлы яктыртуы шунда.

Җил энергиясен кешеләр, бик күптәннән бирле җил тегермәннәрендә, җилкәнле көймәләрдә файдаланып килгәннәр, аның потенциалы кояш энергиясе кебек үк чикләнмәгән, өстәвенә ул чагыштырмача арзан һәм мохитне пычратмый. Ләкин вакыт һәм пространствога карата үзгәрүчән табигатьле булуы аркасында аны «кулга ияләштерү» бик читен. Кояш энергиясеннән аермалы буларак, аның ресурслары, нигездә, уртача пояста тупланган.

Агроклиматик ресурслар — җылылык, дым һәм яктылык — климатик ресурсларның аерым төрен тәшкил итә. Бу ресурсларның географик бүленеше агроклиматик картада чагылыш тапкан.

**8. Рекреацион ресурслар — ял һәм туризмның нигезе.** Табигыйрекреацион ресурслар килеп чыгыш үзенчәлекләре белән түгел, бәлки файдалану характеры белән аерылалар. Аларга ял, туризм һәм дәвалану максатларында файдаланырга мөмкин булган табигый, шулай ук антропоген объектлар һәм күренешләр керә. Шуңа бәйле рәвештә алар төп дүрт типка бүленә: 1) рекреацион дәвалау (мәсәлән, минераль сулар белән дәвалау), 2) рекреацион сәламәтләндерү (мәсәлән, пляжлы су коену урыннары), 3) рекреацион-спорт (чаңгы шуу базасы), 4) рекреацион танып белү (мәсәлән, тарихи истәлекләр). Рекреацион ресурсларны табигыйрекреацион һәм тарихи-мәдәни истәлекләргә бүлү дә шулай ук киң кулланыла.

Табигый-рекреацион ресурсларга диңгез яр буйлары, елга һәм күл буйлары, таулар, урман массивлары, минераль су, ши-

фалы ләм чыганаклары керә. Анда ял итүчеләр һәм туристлар табигый ландшафтның гаять күптөрлелеге һәм матурлыгы, үсемлекләрнең күптөрлелеге, шифалы климаты белән танышалар, ял итү, спорт белән шөгыльләнү, ауга йөрү, балык тоту һ.б. өчен уңайлы мөмкинлекләр табалар.

Табигый-рекреацион территорияләрнең төп формалары — зур шәһәрләр тирәсендәге яшел зоналар, тыюлыклар, милли парклар.

Тарихи-мәдәни истәлекләр ул — тарих, археология, архитектура һәм сәнгать истәлекләре. **Мисал.** Мәскәү Кремлен, Санкт-Петербург янындагы Петергофны, Лондондагы Вестминстерны, Париж янындагы Версаль сарай-парк комплексын, Рим Колизеен, Афина Акрополен, Мисыр пирамидаларын, Аградагы (Һиндстан) Таҗ-Махал гүрстанын, Нью-Йорктагы Хөррият сынын, дөньядагы иң зур музейларны карарга ел саен миллионнарча кеше килә.

Туристлар һәм ял итүчеләрне күбрәк Италия, Испания, Франция, Швейцария, Болгария, Һиндстан, Мексика, Мисыр һ.б. кебек илләр җәлеп итә, чөнки, табигый рекреацион ресурсларның бай булуы белән беррәттән, монда тарихи-мәдәни истәлекләр дә күп. Кайбер аерым районнарда да шул ук хәл күзәтелә. (8 нче иҗади бирем.)

## 3. ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘНЕ САКЛАУ ҺӘМ АНЫҢ ПЫЧРАНУЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕН ТИКШЕРӘБЕЗ

**1. Әйләнә-тирәлекнең антропоген пычрануының сәбәпләре һәм нәтиҗәләре. Әйләнә-тирәнең, ягъни мохитнең пычрануы** турында сез инде үткән сыйныфлар географиясеннән күп нәрсәләр белдегез, һәм бу хәл сезне борчымый кала алмый. Оясын пычраткан кош — начар кош, ди халык мәкале. Барлык кешелек һәм без үзебез дә шул кошка охшап калдык түгелме?

*Әйләнә-тирәнең пычрануы — антропоген юл белән төрле матдәләр, кушылмалар әләгүе нәтиҗәсендә аның үзлекләренең кирәкмәгән якка үзгәрүе ул.* Мондый үзгәрешләр киләчәктә литосфера, гидросфера һәм атмосферага, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына, биналар, конструкцияләр һәм материалларга, шулай ук кешенең үзенә дә зарарлы йогынты ясавына китерә яки китерергә мөмкин. Ул табигатьнең үзенә хас үзлекләрен үзе торгызу сәләтен кимәтә.

Кешенең әйләнә-тирәне пычрата башлавы бик күптәннән килә. Борынгы Римда яшәүче кешеләр шул вакытларда ук Тибр елгасы суының пычрануына зарланганнар. Ә Афинада һәм Борынгы Грециядә яшәүчеләрне Пирей порты акваториясенең пычрануы борчыган. Шуңа күрә Урта гасырларда ук әйләнә-тирәне саклау законнары барлыкка килгән. [14].

Пычрануның төп чыганагы — кешелек җәмгыятенең җитештерү һәм куллану процессында барлыкка килгән гаять зур күләмдәге калдыкларны табигатькә кире кайтару. Инде 1970 елларда ук калдыклар 40 млрд тонна тәшкил итә иде, ә XXI гасыр башында ул сан 300 млрд тоннага җитте.

Мохитнең микъдари һәм сыйфат ягыннан пычрануы аерыла. *Мохитнең микъдари пычрануы* табигатьтә табигый хәлдә, ләкин бик аз микъдарда очрый торган матдәләрнең һәм кушылмаларның табигатькә кире әйләнеп кайтуы нәтиҗәсендә барлыкка килә (мәсәлән, тимер һәм башка металларның кушылмалары). *Мохитнең сыйфат ягыннан пычрануы*, нигездә, органик синтез промышленносте тудырган һәм моңа кадәр табигатьтә мәгълүм булмаган матдәләр яки кушылмаларның табигатькә эләгүе нәтиҗәсендә туа.

Литосфераның (туфрак катламының) пычрануы промышленность, төзелеш һәм авыл хуҗалыгы эшчәнлеге нәтиҗәсендә килеп чыга. Монда туфракны төп пычратучылар: металлар һәм аларның кушылмалары, ашламалар, агулы химикатлар, радиоактив матдәләр. Аларның концентрациясе туфракның химик составы үзгәрүгә китерә. Көнкүреш калдыклары туплану проблемасы торган саен катлаулана бара. Көнбатышта безнең заманга карата кайчакта «чүпле цивилизация» термины кулланылуы очраклы хәл түгел. [15].

Ачык ысул белән тау эшләре алып барганда, туфрак катламы тулысынча юкка чыга. Аларның тирәнлеге, шул исәптән Россиядә дә, кайчакта 500 метрга җитә һәм хәтта аннан да артып китә. Үзләренең продуктивлыгын тулысынча яки тулысынча диярлек югалткан мондый җирләрне бедленд (яман җирләр) дип йөртәләр, һәм алар коры җирнең инде 1 % ын алып торалар. Коры җирдә пычранган җирләрнең гомуми мәйданы 13 млн км$^2$ дан артты, бу җир фондының 1/10 ен тәшкил итә.

Гидросфераның пычрануы, барыннан да элек, елга, күлләр һәм диңгезләргә промышленность, авыл хуҗалыгы һәм көнкүрешнең пычрак суларын агызудан килеп чыга.

XX гасырның 90 нчы еллар ахырына дөньядагы барлык пычрак су күләме елына 3—4 мең км$^3$ дан артып китте, ә бу Җирнең «су паеның» 20 % ын тәшкил итә. Шул агынтыларны сыегайту максатында аларга үз күләменнән 10 тапкыр артыграк чиста су өстәргә кирәк, ягъни асылда агымсу тагын да зуррак күләмдә пычрана дигән сүз. *Төче су проблемасының кискенләшүенең төп сәбәбе нәкъ менә шунда икәнлеге, ә турыдан-туры су куллануның артуында гына түгеллеге аңлашыла булса кирәк.*

Күп кенә елгалар бик нык пычранган елгалар рәтенә керә: Рейн, Дунай, Сена, Темза, Тибр, Миссисипи, Огайо, Идел, Днепр, Дон, Днестр, Нил, Ганг һ.б. Дөнья океаны да һаман саен ныграк пычрана, аның «сәламәтлегенә» берьюлы ярдан да, өстән дә, төптән дә, елгалардан һәм атмосферадан куркыныч яный. Океанга

ел саен гаять күп микъдарда төрле калдыклар элэгэ. Диңгезлэрнең нык пычранганнары эчке һэм читтэге диңгезлэр — Урта, Төньяк, Ирландия, Балтыйк, Кара, Азов, Эчке Япон, Ява, Сары, Кариб диңгезлэре, шулай ук Бискай, Фарсы, Мексика һэм Гвинея култыклары.

Урта диңгез — Җир йөзендэге иң зур эчке диңгез, берничэ бөек цивилизация бишеге. Аның яр буйларында 18 ил урнашкан, анда 130 млн кеше яши, 260 порт бар. Моннан тыш, Урта диңгез дөньяда судноլар йөри торган иң зур һэм эһэмиятле зоналарның берсе: анда берьюлы 2,5 мең еракка йөзүче һэм 5 мең каботаж судно була ала. Аның трассалары буйлап ел саен 300—350 млн тонна нефть ташыйлар. Шуның нэтиҗэсендэ бу диңгез 60—70 нче елларда Европаның иң «шакшы су чокырына» эверелде дип эйтергэ мөмкин.

Пычрануга эчке диңгезлэр генэ түгел, океаннарның үзэк өлешлэре дэ дучар булды. [16]. Тирэн сулы иңкүлеклэргэ дэ хэзер куркыныч янау арта бара; анда агулы матдэлэр һэм радиоактив материаллар күму очраклары бар.

*Эмма Океан суларының нефть белэн пычрануы аеруча зур куркыныч тудыра.* Нефтьне чыгарганда, ташыганда һэм эшкэрткэндэ Дөнья океанына ел саен (төрле чыганаклардан) 3 млн нан 10 млн тоннага кадэр нефть һэм нефть продуктлары элэгэ. Космостан төшерелгэн фоторэсемнэр Дөнья океаны өслегенең 1/3 өлешен май элпэсе каплап алуын күрсэтэ, э ул парга эйлэнүне киметэ, планктон үсешенэ комачаулый, океан белэн атмосфераның үзара йогынтысын чикли. Атлантик океан нефть белэн күбрэк пычранган. [17]. Океан өсте суларының һэрвакыт хэрэкэттэ булуы бу пычрануның бик еракларга таралуына китерэ. Берьюлы күп нефть югалтуга китерэ торган зур танкерлар һэлакэте аеруча куркыныч.

Моннан тыш, озак вакыт кайбер иллэрнең океан суына радиоактив калдыкларны күмүе белэн бэйле Дөнья океанының *радиоактив пычрануы* күзэтелэ.

**Атмосфераның пычрануы** промышленность, транспорт, шулай ук төрле мичлэрнең эшлэве нэтиҗэсендэ килеп чыга. Алар барысы бергэ елына миллиардларча тонна каты һэм газсыман кисэкчеклэрне «җилгэ очыралар». Атмосфераны, нигездэ, минераль ягулык янганда аерылып чыккан углерод оксиды (CO) һэм сульфит газы ($SO_2$), шулай ук күкерт, азот, фосфор оксидлары, кургаш, терекөмеш, алюминий һэм башка металлар пычрата.

Европада һэм Төньяк Америкада киң таралган *кислоталы яңгырларның* төп чыганагы сульфит газы икэнен сез белэсез инде. Кислоталы явым-төшем уңышны киметэ, урман-кырларга зур зыян китерэ, төче сулыклардагы тереклекне һэлак итэ, биналарны җимерэ, кешелэрнең сэламэтлегенэ тискэре йогынты ясый.

**Мисал.** Скандинавиядэ, нигездэ, Бөекбритания һэм ГФРдан килгэн кислоталы явым-төшемнэр аркасында, 20 мең күлдэ тереклек сүнэ: сөлэйман балык, форель

һ.б. балыклар бетеп бара. Көнбатыш Европаның күп кенә илләрендә урманнар котылгысыз рәвештә юкка чыга. Россиядә дә урманнарның һәлакәте башланды.

Кислоталы явым-төшемнәр тәэсиренә тере организмнар гына түгел, хәтта таш та чыдамый. [18].

Атмосферага углерод диоксиды ($CO_2$) чыгарылу күләменең артуы аеруча зур проблема тудыра. XX гасыр урталарында бөтен дөнья күләмендә $CO_2$ нең эмиссиясе 6 млрд тонна булса, XXI гасыр башында ул 27 млрд тоннадан артып китте. Моңа, нигездә, төньяк ярымшардагы икътисади үсеш алган илләр җаваплы. Ләкин соңгы вакытта кайбер үсеп килүче илләрнең промышленносте һәм бигрәк тә энергетикасы үсә бару аркасында аларның да атмосферага углерод чыгарулары шактый артты. («Кушымта»дагы 9 нчы таблицаны карагыз.) Белгәнебезчә, атмосферага шундый чыгарулар аркасында кешелек дөньясына парник эффекты һәм климатның глобаль җылынуы яный. Ә инде хлор-фтор углеродларының (фреоннарның) арта барган эмиссиясе гаять зур «озон тишекләре» ясалуга һәм «озон барьерының» өлешчә җимерелүенә китерде. 1986 елда Чернобыль АЭСндагы авария атмосфераның радиоактив пычрана алу очракларын онытмаска кирәклекне күрсәтте.

Атмосферада бара торган төрле циркуляция процесслары нәтиҗәсендә һаваның пычрану проблемасы дөньякүләм төс алды.

**2. Табигатьне саклау проблемаларын хәл итүнең төп өч юлы.** Кешелек үз «оясын» бер яктан пычратса, икенче яктан мохитне саклау чараларын эшләде һәм аларны тормышка ашыра башлады.

Беренче юл — төрле чистарту корылмалары төзү, аз күкертле ягулык куллану, чүп-чарны юк итү яисә яңадан эшкәртү, 200—300 метрлы һәм аннан да биегрәк төтен торбалары кую, җирләрне рекультивацияләү һ. б. Ләкин хәтта үтә заманча эшләнгән корылмалар да тулысынча чистартуны тәэмин итә алмыйлар. Ә инде бик биек төтен торбалары, зарарлы матдәләрнең шул урындагы концентрациясен киметсәләр дә, тузан һәм кислоталы яңгырларның шактый киң территорияләргә таралуына булышлык итәләр: 250 м биеклегендәге торба төтен таралу радиусын 75 км га кадәр арттыра.

Икенче юл — нигездә табигатьне саклый торган яңа («чиста») җитештерү технологиясен куллану, аз калдыклы һәм калдыксыз производство процессларына күчү. Мәсәлән, предприятиегә суны турыдан-туры (елга — предприятие — елга) түгел, әйләнешле бирүгә, ә иң яхшысы — «коры» технологиягә күчү. Әлеге ысул пычрак суларны елгаларга яки сулыкларга агызуны башта өлешчә, ә аннары тулысынча туктатырга мөмкинлек бирәчәк.

*Бу — төп юл, чөнки ул мохитнең пычрануын киметеп кенә калмый, бәлки аны кисәтә дә.* Ләкин ул гаять күп чыгымнар таләп итә, күп кенә илләрнең моңа хәле җитмәскә мөмкин.

Өченче юл — әйләнә-тирәгә тискәре йогынты ясаучы **«пычрак» производстволарны** төптән уйлап, рациональ урнаштыру. «Пычрак» производстволарга беренче чиратта химия һәм нефть химиясе, металлургия, целлюлоза-кәгазь промышленностьлары, җылылык энергетикасы, төзү материаллары җитештерү керә. Мондый предприятиеләрне урнаштыру өчен географик экспертиза бигрәк тә кирәк.

**3. Табигатьне саклау эшчәнлеге һәм экологик сәясәт.** Табигый ресурсларның талануы һәм әйләнә-тирә мохитнең пычрана баруы җитештерүнең үсешенә тоткарлык булып кына калмый. Ул еш кына кешеләрнең яшәвенә дә куркыныч тудыра. Шуңа күрә 70—80 нче елларда ук инде икътисади нык үскән илләрнең күбесе табигатьне саклау буенча төрле эшчәнлек, **экологик сәясәт** үткәрә башлады. Табигатьне саклау буенча катгый законнар кабул ителә, мохитне яхшыртуның озак вакытка исәпләнгән программалары эшләнә, штрафлар системасы кертелә («кем пычрата, шул түли» дигәннән чыгып), махсус министрлыклар һәм башка дәүләт органнары оештырыла. Болар белән бер үк вакытта җәмәгатьчелекнең әйләнә-тирә мохитне саклауга юнәлтелгән массакүләм хәрәкәтләре башлана. Күп кенә илләрдә барлыкка килгән «яшелләр» партиясенең йогынтысы зур, төрле җәмәгать оешмалары, мәсәлән, Гринпис[1] барлыкка килде.

Шуның нәтиҗәсендә 80—90 нчы елларда икътисади нык үскән илләрдә әйләнә-тирәнең пычрануы акрынлап кими башлады. Ләкин үсеп килүче күпчелек илләр һәм икътисади күчеш илләре, шул исәптән Россия дә, әле һаман элеккеге кебек үк куркыныч хәлдә.

**Мисал.** Ватаныбыз географлары Россия территориясендә экологик яктан аеруча куркыныч хәлдәге 16 районны аерып күрсәтәләр, бергә исәпләгәндә, алар ил территориясенең 15% ын алып тора. Аларның күбесе промышленностьлы шәһәр агломерацияләре, ләкин авыл хуҗалыгы һәм рекреацион районнар да бар.

Безнең заманда табигатьне саклау эшләрен алып бару һәм экологик сәясәтне үткәрү өчен аерым илләрнең тырышлыгы гына җитми. Бу эштә БМО координациясендәге бөтендөнья бердәмлеге оешмаларының һәм башка халыкара оешмаларның тырышлыгы кирәк. 1972 елда Стокгольмда БМОның табигатьне саклау проблемалары буенча беренче конференциясе булды. Аның ачылу көне — 5 июнь — Бөтендөнья табигатьне саклау көне дип игълан ителде. Анда барлык илләрнең киңәйтелгән эш программасы теркәлгән бик мөһим документ — «Табигатьне саклауның бөтендөнья стратегия-

[1] Гринпис (ингл. *greenpeace* — яшел дөнья) — бәйсез халыкара җәмәгать оешмасы, 1971 елда әйләнә-тирә мохитнең деградациясенә юл куймау максатларында оештырыла. Гринпис атом-төш коралы сынауларын үткәрүгә, мохитнең промышленность калдыклары һәм башка калдыклар белән пычрануына каршы чыгышлар ясый, хайваннар дөньясын, диңгезне саклауны яклап чыга.

се» кабул ителде. 1992 елда Рио-де-Жанейро шәһәрендә икенче конференция узды. Анда «XXI гасырга көн тәртибе» һәм башка бик әһәмиятле документлар кабул ителде. БМО системасында махсус орган эшли: мохит буенча БМО Программасы (ЮНЕП). Ул төрле илләрдә бара торган эшләрне координацияли, дөньякүләм тәҗрибәне гомумиләштерә. Табигатьне саклау эшендә «Халыкара табигатьне саклау союзы» (ХТСС), Халыкара географик союз (ХГС) һәм башка оешмалар актив катнашалар. XX гасырның 80—90 нчы елларында углерод, фреон һәм башка матдәләрне атмосферага чыгаруны киметү турында халыкара килешүләр төзелә. Кабул ителгән чараларның кайберләре, нигездә, географик күзлектән чыгып эшләнә.

**1 нче мисал.** XXI гасыр башында дөньяда 12 мең чамасы табигате аеруча саклана торган территорияләр исәпләнә (ТАСТ). Аларның күбесе АКШ, Австралия, Канада, Кытай һәм ГФРда. Милли паркларның гомуми саны — 2 меңгә, ә биосфера тыюлыклары 500 гә якынлаша.

**2 нче мисал.** 1972 елдан ЮНЕСКОның Бөтендөнья мәдәният һәм табигать мирасын саклау конвенциясе гамәлгә керде. Бөтендөнья мирасының ел саен тулылана барган исемлегенә 2007 ел ахырында 851 объект кергән («Кушымта»дагы 10 нчы таблицаны кара), шуларның 660ы — мәдәни, 166 сы — табигый, 25е — мәдәни-табигый объектлар. [19].

Ләкин сезнең һәркайсыгыз, яңа XXI гасыр гражданнары буларак, «Рио-92» конференциясендә кабул ителгән йомгаклауны һәрвакыт исегездә тотарга тиешсез: «Җир планетасы моңарчы беркайчан да күрелмәгән куркыныч астында». (9 нчы бирем.)

## 4. РЕСУРСЛАР ГЕОГРАФИЯСЕН ҺӘМ ГЕОЭКОЛОГИЯНЕ ӨЙРӘНӘБЕЗ

Соңгы вакытта география фәнендә үзара бәйләнгән ике юнәлеш формалашты: ресурсларны өйрәнү һәм геоэкология.

**Ресурслар географиясе** *табигый ресурсларның аерым төрләре һәм җыелмаларының урнашуын, структурасын, шулай ук аларны саклау, торгызу, икътисади бәяләү, рациональ файдалану һәм ресурслар белән тәэмин ителеш мәсьәләләрен өйрәнә.*

Бу юнәлештә эшләүче галимнәр табигый ресурсларның төрле классификацияләрен эшләделәр, ***табигый ресурс потенциалы***[1],

---

[1] Территориянең табигый ресурс потенциалы (ТРП) — территориянең хуҗалык эшчәнлегендә фәнни-техник прогрессны исәпкә алып кулланырга мөмкин булган табигый ресурслары җыелмасы. Ул ике төп күрсәткеч — күләме һәм структурасы белән сыйфатлана һәм минераль-чимал, җир-су һәм башка аерым потенциалларны үз эченә ала.

***ресурс цикллары***[1], табигый ресурсларның, табигый-техник (геотехник) системаларның территориаль бердәмлеге концепцияләрен тәкъдим иттеләр. Алар шулай ук табигый ресурслар кадастрын төзүдә, аларны икътисади бәяләүдә катнаштылар.

**Геоэкология** *табигый мохиттә антропоген катнашудан барлыкка килгән процесслар һәм күренешләрне* географик күзлектән чыгып өйрәнә. Геоэкология концепцияләренә, мәсәлән, ***әйләнә-тирә мохит мониторингы***[2] концепциясе, экологик-географик экспертиза концепциясе керә.

**Төп нәтиҗә.** *Җәмгыять белән табигатьнең үзара тәэсир итешүе безнең көннәрдә мөһим гомумкешелек проблемаларының берсенә әверелде. Антропоген үзгәрешләр, планетабызның географик тышчасына бик нык тәэсир итеп, прогресска гына түгел, бәлки мохитнең пычрануына, табигый ресурсларның кимүенә, экологик проблемаларның кискенләшүенә китерделәр. Шуңа күрә табигатьтән файдалануны камилләштерү, фәнни нигезләнгән экологик сәясәт үткәрү — кешелек алдында торган иң әһәмиятле бурычларның берсе.* (10 нчы йомгаклау биреме.)

## ӨСТӘМӘ ТЕКСТ (Кызыклы мәгълүматлар)

[1] Күптән түгел Америка географлары, космик фоторәсемнәрне өйрәнеп, барлык коры җир мәйданының 48 млн км$^2$ да (яки аның 1/3 ендә диярлек) кеше эшчәнлегенең күзгә күренерлек бернинди дә эзе юк дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Бу — Төньяк Америка территориясенең 38 % ын, БДБ илләренең 34 % ын, Азия чит илләренең 19 % ын, Европа чит илләренең 3 % ын тәшкил итә. Антарктикага бөтенләй кеше кулы тимәгән диярлек.

[2] Кешеләр урта гасырларда Җир кабыгыннан фәкать 18 төрле элементны һәм аларның кушылмаларын таба белгән булсалар, XVII гасырда — 25, XVIII гасырда — 29, XIX гасырда — 47, XX гасыр башында — 54, XX гасырның икенче яртысында 80 нән артыграк элемент алганнар.

[3] Галимнәрнең исәпләүләренә караганда, кешелек тарихында Җир куеныннан 200 млрд тонна күмер, 100 млрд тоннадан артыграк нефть, 50 млрд тонна тимер рудасы, 2 млрд тонна

---

[1] Ресурс цикллары — табигый цикллар әйләнешенең бер-бер артлы килгән стадияләрен күзәтергә мөмкинлек бирә: ресурсны табу, чыгару, эшкәртү, файдалану, калдыкларны кире әйләнә-тирә мохиткә кайтару. Ресурслар циклына мисаллар: энергоресурслар һәм энергия циклы, металл рудалары һәм металл ресурслары циклы, урман ресурслары һәм урман материаллары циклы.

[2] Мониторинг (лат. *monitor* — күзәтүче) — тикшерү, саклау һәм фаразлау максатларында мохитнең (гидросфера, атмосфера, туфрак-үсемлек капламы, шулай ук техник системалар) хәлен күзәтеп тору системасы. Мониторингның глобаль, региональ һәм локаль дәрәҗәләрен аерып йөртәләр.

бокситлар, 300 млн тонна бакыр рудасы, 100 мең тонна-дан артыграк алтын алынган. Бу микъдарларның 50 % тан 90 % ка кадәресе (алтынны кертмичә) соңгы 30—40 елга туры килә.

[4] Чүлләнү процессы сәгатькә 7 км$^2$, яки елга 6,9 млн га тизлек белән бара. Моннан тыш, ел саен 20 млн га чүл һәм ярымчүл җирләре бөтенләй яраксызга чыга.

[5] АКШ төче суны — Канададан, ГФР — Швециядән, Нидерланд — Норвегиядән (аның бәясе якынча Рейн шәрабы — «Рейнвейн» бәясе кадәр!), Согуд Гарәбстаны Малайзиядән китертә. Төче суны Гренландия белән Антарктидадан Европага, Амазонка тамагыннан Африкага океан аша торбалар буйлап агызып китерүнең инженерлар тарафыннан ярымфантастик проектлары эшләнгән.

[6] Уртача зурлыктагы айсбергларны (озынлыгы — 1000 м, киңлеге — 600 м, биеклеге — 300 м) күчерүнең техник проектлары эшләнгән. Моның өчен куәтле биш-алты буксир кирәк булачак. Эрүдән саклау өчен, айсбергның өстен пластик материал белән каплау күздә тотыла. Күчереп китергәндә айсберг, хәтта бик нык «ябыгып», массасының күбрәк өлешен югалтса да, бу икътисади яктан үзен аклаячак. Кирәк урында айсбергның эрүе бер ел чамасы дәвам итәргә мөмкин.

[7] Җилкәнле бер хәрби судно төзү өчен, Урта гасырларда кимендә 400 имән агачы кисәргә кирәк булган. XVI гасырда Җиңелмәс армаданы төзегәндә, Испаниядә йөзәр еллык ярты миллионлап агач тотылган. XIX гасыр уртасында агачтан 4,5—5 мең төрле продукт алынган булса, безнең көннәрдә 20 меңнән артыграк төр продукт алына. Исәпләүләргә караганда, торак, мебель, уенчык, дәфтәр, китап, газета, шырпы һ. б. өчен бер кеше үз гомерендә 200 ләп төп агач «сарыф итә» икән. Планетабызда яшәүчеләр фәкать шырпы рәвешендә генә дә елына 1,5 млн м$^3$ агач яндыралар.

[8] 80 нче елларда ел саен 11 млн га дан артыграк тропик урман бөтенләй һәм 4,5 млн га да сайлап киселгән (15,5 млн га — ул Швейцария мәйданыннан 4 тапкыр чамасы зуррак). Минут саен дөньяда 14—15 га шундый урман юкка чыга. 90 нчы елларның беренче яртысында көньяк урман поясы чикләрендә тагын 65 млн га мәйданда урман киселде.

[9] 1970 елда Африкада филләр саны 5 млн чамасы булган. 1980 елда алар 1,3 млн чамасы гына калган, ләкин әле шуннан соң бу сан тагын да кимегән. Азиядә хәзер аларның фәкать 15 меңе генә сакланып калган. Мондый һәлакәтле кимүнең төп сәбәбе — аучылык һәм браконьерлык (казык тешләре өчен), һәм шулай ук филләрнең яшәү мохите бозылу.

[10] Җирдә яшәүче һәр кешегә уртача 270 млн м$^3$ чамасы диңгез суы туры килә. Ул Мәскәү елгасындагы Можайск диңгезе кебек җиде сусаклагыч суына тигез.

[11] Диңгез суының һәр км$^3$ да 37 млн т эрегән матдәләр була, аларның 20 млн т сы — хлор һәм натрий тозлары, 9,5 млн т — магний, 6 млн т — күкерт һәм шактый күп микъдарда йод, бром, уран, алюминий, бакыр, торий, калий, алтын, көмеш. Дөнья океаны суларында эрегән минераль матдәләрнең гомуми микъдары $4,8 \cdot 10^{16}$ т тәшкил итә. Әле анда эрегән алтын гына да 8—10 млн т исәпләнә, яки Җирдәге һәр кешегә якынча 1,5 кг туры килә дигән сүз.

[12] 70—80 нче елларда энтузиаст-эшмәкәрләр иң алдынгы техника ярдәмендә Флорида бугазында испанлыларның 1622 елда баткан «Аточа» һәм «Санта-Маргарита» исемле галеон калдыкларын табалар. Аннан күп санлы алтын һәм көмеш коелмалар, акчалар һәм зәбәрҗәт күтәртелә. 1985 елда Американың эзләнүчеләр командасы Атлантик океан төбендә 4 км дан артыграк тирәнлектә 1912 елда баткан данлыклы «Титаник»ны табуга ирешәләр. Аның бортында шулай ук гаять күп байлыклар тупланган, хәзер аларны чыгарырга тырышалар.

[13] Дөнья океанында кит аулау кәсебе 1868 елда башлана, һәм шул вакытлардан бирле барлык төрдәге 2 млн нан артык кит тотылган. 1962 елда кит аулау буенча «рекорд» куела: 66 мең кит тотыла. Үрчүләренә караганда күбрәк аулау, кит көтүләренең кискен кимүенә китерде. Кит аулау буенча Халыкара комиссия тарафыннан куелган кискен чикләү чаралары гына рациональ хуҗалык итүгә күчәргә мөмкинлек бирде. Башта кит аулау чикләнде, ә 1982 елдан ул тыелды.

[14] Англия короле Эдуард I нең 1273 елда кабул ителгән Лондонда йортларны җылыту өчен ташкүмер ягуны тыючы указын мохитне саклау буенча беренче закон дип исәпләргә мөмкин. Ул замандагы тәртип буенча указны үтәмәгән кешегә үлем җәзасы бирелергә тиеш булган. Ә король Эдуард III заманында парламент 1338 елда Темзага чүп ташлауны тыючы закон кабул иткән. XV гасыр башында Франция короле Сена елгасына карата шундый ук указ чыгарган. Петр I указы буенча Нева елгасына чүп ташлаган кеше җәзага тартылган.

[15] Мәскәүдә яшәүче һәр кешегә елына уртача 300—350 кг, ә Көнбатыш Европа илләрендә исә 150—300 кг, АКШта 700 кг чүп туры килә.

[16] Америка галимнәре 80 нче еллар башында Тын океанның фәкать төньяк өлешендә генә дә миллионнарча пластик пакет, 35 млн пластик һәм 70 млн пыяла шешә, башка төрле бик күп

пластмасс әйберләр, 5 млн иске ботинка йөзеп йөрүен тикшереп белгәннәр.

[17] Танылган Норвегия галиме һәм сәяхәтчесе Тур Хейердал 1947 елда Тын океан аша «Кон-Тики» салында йөзгәндә анда бернинди дә пычранулар күрми. Ә инде 1969 елны папирустан ясалган «Ра» көймәсендә Атлантик океанны кисеп узганда, ул океанның нәкъ үзәк өлешендә 1400 миль араның нефть элпәсе белән капланып алынуын билгеләп үтә.

[18] Афина Акрополе соңгы берничә дистә ел эчендә меңнәрчә еллар дәверендәгегә караганда да күбрәк җимерелгән. Мисырдан Лондонга китерелгән Клеопатра сыны хакында да шуны ук әйтергә мөмкин. Кельн соборы да соңгы 50 ел эчендә алдагы йөзләрчә еллардагыга караганда күбрәк зарар күргән.

[19] Иң күп Бөтендөнья мирасы объектлары булган илләр санына түбәндәгеләр керә: Испания (40), Италия (41), Германия (32), Кытай (35), Франция (31), Һиндстан (27). Россиядә алар әлегә — 23.

**Китап киштәсе**


1. Максаковский В.П. Географическая картина мира.— М.: Дрофа, 2008.— Ч. I. — Тема 2.
2. Максаковский В.П. Новое в мире: цифры и факты: Дополнительные главы к учебнику 10 кл. — М.: Дрофа, 2006.— Раздел 1.
3. Розанов Л.Л. Геоэкология: Учеб. пособие для 10—11 кл. — М.: Дрофа, 2005.
4. Залогин Б. С. Океаны.— М.: Просвещение, 1996.
5. Максаковский В.П. Всемирное культурное наследие.— М.: Просвещение, 2003.
6. Максаковский Н.В. Всемирное природное наследие.— М.: Просвещение, 2005.


## БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘР ҮЗЛӘШТЕРҮ ӨЧЕН ТУПЛАНМА

**1 нче иҗади бирем.** Алдагы сыйныфларда география курсларыннан алган белемнәрегезгә һәм бу дәреслекнең 1 нче темасына таянып, табигый ресурсларга ярлы, ләкин югары икътисади һәм социаль үсеш дәрәҗәсенә ирешкән илләргә мисаллар китерегез. Ресурслар белән тәэмин ителешнең җәмгыять яшәешендәге роле турында нәтиҗә ясагыз.

**2 нче бирем.** 1 (текстта), 3, 4, 5 һәм 20 нче таблицалар («Кушымта»да) мәгълүматларын анализлагыз. Хәзерге дәрәҗәдә чыгарганда күмер, нефть, табигый газ һәм тимер рудасының дөньядагы гомумгеологик һәм тикшерелгән запасларының ничә елга җитәчәген исәпләп чыгарыгыз (55 нче биттәге күрсәтмәне карагыз). Моңа бәйле рәвештә нинди проблемалар барлыкка килә?

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** 4 нче рәсем һәм 2 нче таблицаны анализлагыз. 1900, 1980 һәм 2000 елларда, җан башына китереп исәпләгәндә, күпме минераль чимал чыгарылганын исәпләгез. Бу өч санны үзара чагыштырып карагыз, үсеш юнәлешен билгеләгез һәм аны аңлатып бирегез.

**3 нче бирем.** Дәреслек текстыннан һәм «Кушымта»дагы 3, 4, 5 нче таблицалардан файдаланып, янучан файдалы казылмаларның урнашуын аңлатыгыз. Гаять бай күмер, нефть запасларына ия булган илләрне, аларның иң зур күмер һәм нефть бассейннарын әйтегез. Бу анализга нигезләнеп, нинди нәтиҗәләр ясарга була?

**4 нче бирем.** 7 нче рәсемне һәм атластан дөньяның җир ресурслары картасын һәм «Кушымта»дагы 6 нчы таблицаны анализлагыз. Аерым регионнар һәм илләрнең сөрү җирләре белән тәэмин ителешен чагыштырыгыз. Күп җирле һәм аз җирле илләргә мисаллар китерегез. Материклар һәм океаннар географиясе курсыннан алган белемнәрегездән файдаланып, мондый аермаларның сәбәпләрен аңлатыгыз. Фикерегезне исбатлагыз.

**5 нче бирем.** 8 нче рәсем буенча дөньядагы зур регионнарның елга сулары ресурслары белән тәэмин ителүен чагыштырыгыз. Төче су белән күп һәм аз тәэмин ителгән илләргә мисаллар китерегез. Атластагы картадан дөньядагы зур сусаклагычларның урнашуын карагыз, нәтиҗә ясагыз һәм аны дәреслек материалын раслау өчен файдаланыгыз.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** «Кушымта»дагы 7 нче таблица мәгълүматларын анализлагыз һәм дөньядагы иң зур регионнарның гидроэнергетик потенциалларына чагыштырма характеристика бирегез.

**6 нчы бирем.** 9 нчы рәсемне анализлагыз. Бу рәсем һәм төп текст ярдәмендә планетабызның төп ике урман поясын сыйфатлагыз. Аерым илләрнең урман ресурслары белән тәэмин ителешен бәяләгез, урман ресурсларына иң бай һәм иң ярлы илләрне әйтегез. «Кушымта»дагы 8 нче таблицаны да файдаланыгыз.

**7 нче бирем.** Атластагы Дөнья океаны минераль ресурслары картасын анализлагыз. Бу ресурсларга гомуми характеристика бирегез. Океанның минераль ресурсларга иң бай континенталь шельф һәм тирән сулы районнарын билгеләгез. Үткәрелгән анализ нигезендә диңгездә чыгару промышленностеның үсеш перспективаларын билгеләп буламы?

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Дәреслек текстыннан файдаланып, дәфтәрегезгә «Дөнья океанының табигый ресурслары» классификацион схемасын төзегез. Бу схеманы «Дөнья океаны — төрле табигый хәзинәләр чыганагы» дигән фикерне исбатлау өчен файдаланыгыз.

**8 нче иҗади бирем.** Үзегез яши торган республика, край яки өлкәнең физик, икътисади һәм социаль географиясе буенча белемнәрегезгә таянып: 1) рекреацион-дәвалау, 2) рекреацион-сәламәтләндерү, 3) рекреацион-спорт, 4) рекреацион-танып белү характерындагы территорияләргә мисаллар китерегез. Монда үзегез күреп күзәткәннәрне, алган тәэсирләрегезне мөмкин кадәр файдаланырга тырышыгыз. Бу территориягә багышланган альбом (транспарант) әзерләгез. Сезнең республикада, крайда, өлкәдә Бөтендөнья мирасы объектлары бармы?

**9 нчы бирем.** Массакүләм информация чаралары мәгълүматларыннан файдаланып: а) табигатьне саклау эшчәнлегенә һәм экологик сәясәтне тормышка ашыруга бәйле уңай нәтиҗәләргә; б) әйләнә-тирә мохиткә антропоген катнашуның тискәре йогынтысына берничә мисал китерегез.

**10 нчы йомгаклау биреме.** 1. Алган белемнәрегезгә нигезләнеп, түбәндәге күренешләрнең сәбәпләрен әйтегез: а) XX гасырның икенче яртысында географик мохитнең «кешеләшү» дәрәҗәсе кискен артты; б) файдалы казылмаларны чыгарганда, аларның территориаль бергәлегеннән файдалану отышлырак; в) хәзерге заманда җиргә «йөкләмә» арта бара, ә җир ресурслары белән тәэмин ителеш кими; г) су куллануның арта баруы төче су дефицитын тудыра.

2. Тема тексты буенча кимендә өч проблемалы сорау уйлап табыгыз. Аларга җавап бирегез һәм иптәшләрегез белән фикер алышыгыз.

3. Текстта һәм атласта дөньядагы табигый ресурсларны сыйфатлаучы карталарны өйрәнегез. Аларның нинди картографик ысул белән төзелүен билгеләгез.

4. Тема буенча өстәмә библиография төзегез һәм аны эшегездә файдаланыгыз.

## ҮЗЕГЕЗНЕҢ ҺӘМ БЕР-БЕРЕГЕЗНЕҢ БЕЛЕМНӘРЕН ТИКШЕРҮ ТУПЛАНМАСЫ

**Ничек аңлатырсыз:**

1. «Табигать» һәм «географик мохит» төшенчәләре арасындагы охшашлык һәм аерма нидән гыйбарәт?
2. Ни өчен ресурслар белән тәэмин ителеш турында аларның запасына карап кына фикер йөртергә ярамый?
3. Дөньядагы җир ресурслары фондындагы үзгәрешләрнең асылы нәрсәдә?
4. Кешелек дөньясында су проблемасының кискенләшү сәбәпләре нәрсәдә?
5. Кислоталы яңгырның тискәре йогынтысы нидән гыйбарәт?
6. Экология проблемаларын хәл итүдә ни өчен халыкара хезмәттәшлек кирәк?

**Ничек уйлыйсыз:**

1. Ни өчен җәмгыять белән табигатьнең үзара йогынтысын биологик проблема буларак кына түгел, бәлки иң элек иҗтимагый, социаль проблема итеп карарга кирәк?

2. Торгызыла ала һәм торгызыла алмый торган табигый ресурслардан рациональ файдалану нидән гыйбарәт?

3. Бөек немец географы Александр Гумбольдтның «Кешене урманнар каршы ала, чүлләр озатып кала» дигән сүзләре нәрсәне аңлата?

4. Табигатьтән файдалануда һәм экология проблемаларын хәл итүдә география фәне нинди роль уйный?

**Беләсезме:**

1. Карта-схемада файдалы казылмаларның түбәндәге төрләреннән кайсыларының дөньядагы иң зур бассейннары күрсәтелгән: 1) күмер, 2) нефть, 3) тимер рудасы?

2. Бу илләрнең кайсылары сөрү җирләренә бик бай, ә кайсыларында ул бик чикле: Австралия, Япония, ГФР, Кытай, Аргентина?

3. Бу илләрнең кайсысында су ресурслары бик мул, ә кайсыларында бик аз: Канада, Бразилия, Конго, Согуд Гарәбстаны, Мисыр?

**Булдыра аласызмы:**

1. Текстта һәм текстагы карталарда телгә алынган түбәндәге илләрне хәтердән дөньяның контурлы картасына төшерегез: Бөекбритания, Нидерланд, Испания, Швеция, Һиндстан, Мисыр, Конго Демократик Республикасы, КАР, Мексика, Аргентина.

2. «Географик мохит», «ресурс белән тәэмин ителеш», «ресурслар географиясе» төшенчәләренә билгеләмә бирегез.

3. Нефть ятмаларына бай булган илләрне дөньяның контурлы картасына хәтердән төшерегез.

4. Түбәндәге раслаулар дөреслеккә ни дәрәҗәдә туры килә, шуны ачыклагыз, кирәк урында дөресләп җавап бирегез: а) дөньядагы гомумгеологик күмер ятмалары нефть ятмаларыннан бик күпкә артыграк; б) дөньяның җир фонды стуктурасында сөрүле җирләр күбрәк; в) Җирдәге төче су запасы планетадагы барлык су ресурсларының 10 % ын гына тәшкил итә; г) экологик проблемаларны хәл итүнең төп юлы җитештерүнең, нигездә, яңа технологиягә күчүеннән гыйбарәт.

## 2 НЧЕ ТЕМАГА МЕТОДИК АЧКЫЧЛАР

### Боларны исегезгә төшерегез

1. Җирнең географик тышчасының төзелеше һәм үзлекләре. (География, 6, 7 нче сыйныфлар.) 2. Материклар һәм океаннар табигатенә кеше йогынтысының үзенчәлекләре. (География, 7 нче сыйныф.) 3. Су ресурсларының төрләре. (География, 8 нче сыйныф.) 4. Җир кабыгында файдалы казылмалар урнашуының төп үзенчәлекләре. (География, 6, 7, 8 нче сыйныфлар.) 5. Җирдә табигый зоналар һәм климатик поясларның урнашуы (География, 7 нче сыйныф.) 6. Россиянең табигый ресурслары географиясенең төп үзенчәлекләре. (География, 8 нче сыйныф.) 7. Төшенчәләр һәм терминнар: географик тышча, табигый комплекс, табигый зона, табигый ресурслар, агроклиматик ресурслар, рекреацион ресурслар, табигатьтән файдалану, антропоген ландшафт, экология.

### Боларны үзләштерегез

**2 нче теманың төп идеяләре**

1. Географик мохит ул — кешеләрнең яшәве, халыкның һәм хуҗалыкның урнашуы һәм үсеше өчен кирәкле шарт. 2. Кешелек цивилизациясенең киләчәге күбесенчә бөтендөнья табигатьне саклау стратегиясен тормышка ашыруга, төпле уйланган милли һәм халыкара экологик сәясәт алып баруга бәйле.

**2 нче темадагы төп фәнни белемнәр**

1. Хәзерге этапта җәмгыять белән табигатьнең үзара тәэсире үзенчәлекләре. 2. Географик (әйләнә-тирә) мохит төшенчәсе. 3. Ресурслар белән тәэмин ителеш төшенчәсе. 4. Минераль, җир, су, үсемлек, климатик ресурсларның, Дөнья океаны ресурслары урнашуының төп билгеләре һәм кешеләрнең алар белән тәэмин ителү дәрәҗәсе. 5. Әйләнә-тирә мохитнең пычрану характеры һәм дәрәҗәсе, табигатьне саклау проблемаларын хәл итүнең төп юллары. 6. Табигатьне саклау эшчәнлеге һәм экологик сәясәтнең асылы. 7. Ресурслар географиясе һәм геоэкология төшенчәләрен кузаллау. 8. Теманың төп төшенчәләре: 1) географик (әйләнә-тирә) мохит, 2) табигый ресурслар, 3) ресурслар белән тәэмин ителеш, 4) чүлләнү, 5) урманнар бетү, 6) мохитнең (микъдар һәм сыйфат ягыннан) пычрануы, 7) «пычрак» производство, 8) экологик сәясәт, 9) ресурслар географиясе, 10) геоэкология.

### Сез нәрсәләр эшли белергә тиеш

1. Табигый ресурс төрләренең ничек урнашуына, төп илләрне һәм районнарны күрсәтеп, кыскача сыйфатлама

бирергә. 2. Дөньяның һәм аның аерым регионнарының төрле минераль ресурслар белән тәэмин ителешенә гомуми һәм чагыштырма бәя бирергә, мондый тәэмин ителешне исәпләп таба белергә. 3. Мохитнең пычрануына, табигатьтән рациональ һәм рациональ булмаган файдалануга мисаллар китерергә. 4. Башка сыйныфларда өйрәнгән география курслары арасында эчке бәйләнешләр таба белергә. 5. Мәктәпнең китапханә фондын өйрәнергә һәм шушы тема буенча өстәмә библиография төзергә.

### Мөстәкыйль эш күнекмәләре булдыру буенча күрсәтмәләр һәм планнар

Дөньяның һәм аерым регионнарның төрле минераль ресурслар белән тәэмин ителешен ничек бәяләргә. Эш тәртибе:

1. Таблицадан яки картадан берәр төр файдалы казылма запасларын бөтен дөнья яки берәр регион өчен билгеләргә. 2. Ресурсның шушы төре елына күпме чыгарылуын (кулланылуын) билгеләргә. 3. Запаслар күрсәткечен җир астыннан чыгару (куллану) күрсәткеченә бүләргә. Табылган сан шушы файдалы казылманың, хәзерге темплар белән файдаланганда, ничә елга җитәчәген күрсәтә. 4. Ресурс белән тәэмин ителеш турында нәтиҗә ясарга.

## 3 НЧЕ ТЕМАНЫҢ ПЛАН-СХЕМАСЫ



## 3 нче тема. ДӨНЬЯ ХАЛКЫ ГЕОГРАФИЯСЕ

Халык географиясе белән сез алдагы сыйныфларда география дәресләрендә таныша башлаган идегез инде. Әле бу теманы өйрәнү һаман дәвам итәчәк. 40 нчы елларда Н.Н.Баранский география китаплары авторларын халыкка бәйле мәсьәләләргә игътибар биреп җиткермәүләре өчен кискен тәнкыйтьләп: «Кешене онытканнар!!!» — дип язган иде. Хәзер халык географиясе икътисади һәм социаль географиянең зур үсеш алган төп тармакларыннан берсе санала. Халык географиясе белән *этнология (этнография)*[1] чигендә этногеография фәне үсеп чыкты. Моннан тыш, халык географиясе ***демография***[2] һәм шулай ук тарих, икътисад, экология, культурология һәм башка күп кенә фәннәр белән тыгыз бәйләнгән.

### 1. ХАЛЫК САНЫ ҺӘМ ХАЛЫКНЫҢ ЯҢАРЫП ТОРУЫ БЕЛӘН ТАНЫШАБЫЗ

**1. Дөньяда халык саны бик тиз арта!** Географлар һәм демографлар үз эшләрендә халык санын алу мәгълүматларыннан бик киң файдаланалар. XIX гасыр башыннан алып дөньяда халык санын алу барысы 2 мең тапкырдан артыграк үткәрелгән, хәзерге вакытта ул алга киткән илләрнең күбесендә биш яисә ун елга бер тапкыр үткәрелә. [1].

Демограф-статистикларның исәпләүләренә караганда, кешелек тарихы дәвамында Җирдә барлыгы 100 млрд кеше туган. Ләкин бу тарихның бөтен дәвамында диярлек халык саны бик акрынлап арткан, яңа заман һәм бигрәк тә иң яңа заман чорына кергәч кенә тизләнеш башлана. Мәсәлән, соңгы мең ел эчендә халык санының беренче тапкыр икеләтә артуы өчен — 600 ел, икенче тапкырга — 250 ел, өченчесенә — 100 ел чамасы, ә дүртенчесенә 40 елдан артыграк вакыт кирәк булды. *Димәк, бу — халык санының XX гасыр уртасында һәм икенче яртысында беркайчан да булмаганча бик тиз артуын күрсәтә.* 1950 елда ул — 2,5 млрд, ә 1980 елда — 4,4 млрд, 2006 елда 6,5 млрд кешегә җитте. [2].

**Мисал.** Әгәр XX гасыр башында Җирдәге халыкның еллык абсолют артуы 10—15 млн тәшкил иткән

---

[1] Этнология (этнография, грек. *ethnos* — кабилә, халык сүзләреннән) — халыкларның (этносларның) килеп чыгуы, характерлы үзенчәлекләре һәм аларның этник процесслар белән билгеләнүче үзара мөнәсәбәтләре турындагы фән.

[2] Демография (грек. *demos* — халык һәм *grapho* — язам дигән сүзләрдән) — халык санының табигый артуын, халыкның яшен, җенси составын, аның арту яки кимү закончалыкларын өйрәнүче фән.

булса, гасыр уртасында ул 40—50 млн, ә XX гасырның 80—90 нчы елларында 80—85 млн кешегә җитә [3], ә бу, Россиядән тыш, Европадагы теләсә кайсы илнең халык саныннан күпкә артып китә.

Ләкин безнең заманда дөньяның төрле регионнарында халык саны бертигез артмый: ул бер регионда акрын, икенчеләрендә — тизрәк, ә өченчеләрендә бик тиз арта. Бу хәл аның яңарып торуының төрле характерда булуы белән аңлатыла. (1 нче бирем.)

**2. Халыкның яңарып торуы төшенчәсе.** Халык турындагы фәнни теория хезмәттә катнашучы халыкны *җәмгыятьнең төп җитештерүче көче,* бөтен иҗтимагый җитештерүнең нигезе итеп карый. Табигать (географик мохит) белән даими тәэсир итешеп, халык аны үзгәртүдә актив роль уйный. Шул ук вакытта халык — моны һәркайсыбыз үзендә тоя — *булдырылган барлык материаль байлыкларны төп кулланучы булып та санала.* Менә шуңа күрә дә халык саны — һәрбер илнең, шулай ук барлык кешелек дөньясының үсеше өчен иң әһәмиятле факторларның берсе.

Халык санының артуы үз чиратында аның яңарып тору характерына бәйләнгән.

**Халыкның яңарып торуы (табигый үзгәрүе) дигәндә туу, үлү һәм табигый арту процесслары бердәмлеген аңлыйлар; бу процессларның бердәмлеге кешеләрнең буыннан-буынга өзлексез яңарып һәм алмашынып торуын тәэмин итә.**

Туу, үлү, халыкның табигый артуы — үзенең табигате белән биологик процесслар. Ләкин шулай да *кешеләрнең социаль-икътисади яшәү шартлары, җәмгыятьтәге һәм гаиләдәге мөнәсәбәтләре бу процессларга хәлиткеч йогынты ясый.* Үлүчеләр саны иң элек кешеләрнең материаль тормыш шартларына: туклануга, хезмәт һәм көнкүрешнең санитария-гигиена шартларына, сәламәтлек саклауның куелышына бәйле. Туучыларның саны да җәмгыятьнең социаль-икътисади структурасына, кешеләрнең тормыш-көнкүреш шартларына бәйләнгән. Ләкин бу бәйлелек үтә катлаулы һәм каршылыклы, фәндә ул бик күп бәхәсләр кузгата. Кагыйдә буларак, халык мул яшәгән һәм культурасы үскән саен, хатын-кызлар җитештерүгә һәм иҗтимагый эшкә күбрәк тартылган саен, балаларның мәктәп еллары арткан һәм, гомумән, «баланың бәясе» күтәрелгән саен, туучылар саны кими бара. Ләкин керемнәрнең артуы туучылар санын арттыруда этәргеч булуы ихтимал.

Халыкның яңарып торуына сугышлар, бигрәк тә бөтендөнья сугышлары, аеруча тискәре йогынты ясый. Ул турыдан-туры сугыш хәрәкәтләре нәтиҗәсендә, шулай ук ачлык һәм авырулар таралу, гаилә элемтәләре өзелү нәтиҗәсендә дә кешеләрне бик күп югалтуларга китерә.

*Халыкның яңарып торуын, бик гадиләштереп һәм гомумиләштереп, ике типка аерып күрсәтергә мөмкин.*

**3. Халык яңарып торуның беренче тибы: демографик кризис. Халык яңарып торуның беренче**

**тибына** туу, үлү һәм табигый арту күрсәткечләренең чагыштырмача түбән булуы характерлы. Беренче чиратта ул өлкән яшьтәгеләрнең һәм картларның өлеше даими артып торган икътисади үсеш алган илләрдә таралган; бу күренеш үзеннән-үзе туу күрсәткеченең кимүенә һәм үлү күрсәткеченең югары булуына китерә.

Ләкин демографик фактордан башка социаль-икътисади характердагы сәбәпләрнең дә роле зур, чөнки төрле авырулар, яшәү шартларының тәртипкә салынмавы, хәрби конфликтлар, җинаятьчелекнең артуы, производство травматизмы, табигатьтәге һәм техноген катастрофалар һ.б. бәхетсезлекләр [4], шулай ук мохит начараю да үлүчеләр санының артуына китерә.

Халык яңарып торуның беренче тибына кергән илләрне дә өч төркемчәгә аерырга мөмкин.

Беренчедән, болар халыкның елына уртача табигый арту күрсәткече 0,5% (яки 1000 кешегә 5 кеше, яки 5‰) булган илләр. Моңа АКШ, Канада, Австралия кебек илләр мисал була ала, аларда халыкның арту күрсәткече шактый югары.

Моңа ирешү өчен, барлык гаиләләрнең чама белән яртысында — ике бала, ә икенче яртысында өч бала булу кирәк. Вакыт узу белән, ике бала эти-әнисен «алыштыра», ә өченчесе авырудан, бәхетсезлек очракларыннан һ. б. дан вакытсыз югалтуны «каплап» кына калмый, бәлки баласыз гаиләләргә «компенсация» була, шуның белән җитәрлек гомуми үсеш тәэмин ителә.

Икенчедән, моңа табигый үсеш күрсәткече нуль яки аңа якын булган илләр керә. Мондый үсеш күрсәткече халыкның киңәйтелгән үсешен тәэмин итә алмый, ул ирешелгән дәрәҗәдә кала.

**Мисал.** Икенче төркемчәгә кергән илләр барысы да Европада урнашкан. Болар — Бельгия, Дания, Португалия, Польша, Швеция. Бу илләрдә халык саны инде артмый.

Өченчедән, халыкның табигый үсеш дәрәҗәсе тискәре, ягъни үлү саны туу саныннан күбрәк булган илләр. Моның нәтиҗәсе буларак халык саны артмый, киресенчә, кими бара. Бу күренешне демографлар ***депопуляция***[1] (яки **демографик кризис**) дип йөртәләр. Ул аеруча Европа илләренә хас.

**Мисал.** XXI гасыр башында Европада инде 15 илдә халыкның табигый үсеш дәрәҗәсе тискәре булды. Алар санына БДБ илләреннән Россия, Украина, Белоруссия керә. Аларда халыкның табигый үсеше дәрәҗәсенә XX гасырның 90 нчы елларындагы социаль-икътисади кризис йогынты ясады. («Кушымта»дагы 12 нче таблицаны кара).

Күп балалы гаиләләрдән торган иске Россиянең [5] аз балалы гаиләләргә күчү күренеше Советлар Союзы яшәп килгән елларда

[1] **Депопуляция** (франц. *dépopulation*) — халыкның яңарып тору күрсәткече кимү нәтиҗәсендә илдә, регионда, районда халыкның азая баруы. Бу хәл халыкның абсолют санының кимүенә китерә.

ук башланды. Ләкин 90 нчы елларда, иң элек социаль-икътисади кризис башлануга бәйле рәвештә, халыкның табигый үсеш күрсәткече «ишелде». XXI гасыр башында да туучылар саны Россиядә (1000 кешегә 10,4 кеше) бик түбән.

Әле күптән түгел генә икътисади үсеш алган илләрдәге халыкның яңарып тору тибын рациональ дип атыйлар иде. Ләкин XX гасырның 90 нчы елларында бу күрсәткеч 2‰ ка кадәр төште, ә XXI гасыр башында фактик яктан нульгә тигезләште. Шул ук вакытта Европадагы күп илләр *демографик кризис* полосасына керделәр, ә бу аларның үсешенә тискәре йогынты ясый һәм алдагы көндә ясаячак.

**4. Халык яңарып торуның икенче тибы: «демографик шартлау».** **Халык яңарып торуның икенче тибына** туу һәм табигый арту күрсәткечләренең югары һәм бик югары, ә үлүчеләр санының чагыштырмача аз булуы хас. Бу — иң элек үсеп килүче илләрдә шулай.

Бәйсезлек яулап алганнан соң, бу илләр заманча медицина, санитария һәм гигиена казанышларын, беренче чиратта йогышлы авыруларга каршы көрәштә киңрәк куллану мөмкинлеген алдылар. Бу — үлүчеләр санының бик нык кимүенә китерде. Туучылар саны күпчелек очракта югары дәрәҗәдә калды.

Әлбәттә, бу күбесенчә меңнәрчә еллардан бирле сакланып килгән иртә өйләнешү һәм күп балалы гаиләләр традицияләре белән аңлатыла. [6]. Әле хәзер дә гаиләдә уртача 6 кеше исәпләнә; кагыйдә буларак, бу өч буын кешеләреннән торган гаилә (әти-әниләре, балалары һәм оныклары). Шуның өстенә мондый гаилә яшәү минимумын саклауда төп чара булып кала, һәм балалар элеккечә ата-аналарының картлык көннәрендә ышанычлы терәк булып саналалар. Бу илләрдә әле һаман да балалар күп үлә. Монда авыл хуҗалыгының өстенлек итүе, белем дәрәҗәсенең җитәрлек булмавы, хатын-кызларның җитештерүгә аз тартылуы үзен нык сиздерә.

XXI гасыр башында үсеп килүче илләрдә халыкның уртача еллык табигый арту күрсәткече 1,6 % тәшкил итә, ягъни икътисади үсеш алган илләр күрсәткеченнән 16 тапкыр артып китә.

Ләкин аеруча артта калган илләр хәтта әлеге илләрдән дә бик нык аерылып тора, ә анда 800 млн кеше, планетадагы барлык халыкның 1/10 өлеше яши. Алар башкалардан туу һәм табигый үсеш күрсәткечләренең гаять югары булуы (2,4 %) белән аерылып торалар. Шуңа күрә дә «дөнья рекордчыларын» нәкъ шул илләр арасыннан эзләргә кирәк.

Халыкның уртача еллык табигый арту күрсәткече буенча «рекорд куючыларны» сез Тропик Африка һәм Көньяк-Көнбатыш Азия илләре арасыннан табарсыз. [7]. (2 нче бирем.)

Халык яңарып торуның икенче

тибы күзәтелгән илләрдә халыкның шулай тиз арту феноменын XX гасыр урталарыннан башлап әдәбиятта **демографик шартлау** дип йөртә башладылар. Безнең көннәрдә бу илләргә (Кытай белән бергә) планетадагы барлык халыкның чама белән 4/5 өлеше һәм халыкның еллык артуының 95% туры килә. Димәк, һәр ел дөньяга килгән 130 млн баланың 124 млн ны үсеп килүче илләрдә туа. Шул исәптән Азиядә халык ел саен 40 млн кешегә, Африкада — 30 млн га диярлек, Латин Америкасында 9 млн нан күбрәккә арта.

Әгәр 1900 елда дөньяда иң күп халыклы 15 илнең җидесе Европада, бишесе Азиядә һәм өчесе Америкада булса, 2005 елда бу исемлектә фәкать Европаның ике иле генә (ГФР һәм Россия) калды, ләкин аның каравы бу исемлеккә Азиянең сигез иле (Кытай, Һиндстан, Индонезия, Пакистан, Бангладеш, Япония, Вьетнам, Филиппин) һәм шулай ук Америкадагы өч ил (АКШ, Бразилия, Мексика), Африкадагы ике ил (Нигерия, Мисыр) өстәлә («Кушымта»дагы 14 нче таблицаны карагыз).

Шуның белән беррәттән, кайбер иң «алга киткән» үсеп килүче илләрдә халыкның табигый артуы сизелерлек кимүенә игътибар итәргә кирәк. Моңа мисал булып Бразилия, Һиндстан, Төркия, Марокко, Тунис хезмәт итә. Ә Кытай, Аргентина, Чили, Шри-Ланка, Таиланд фактик яктан халык яңарып торуның беренче тибы илләре төркеменә күчте.

*Шуңа да карамастан дөньядагы халык санына һәм халыкның яңарып торуына хәлиткеч йогынтыны үсеп килүче илләр ясый, киләчәктә дә шулай дәвам итәчәк һәм беренче чиратта бөтен дөньядагы демографик хәлне билгеләячәк.* (3 нче иҗади бирем.)

**5. Демографик сәясәт — халыкның яңарып торуы белән идарә итү**. Безнең көннәрдә дөньядагы илләрнең күпчелеге, дәүләт **демографик сәясәтен** үткәреп, халыкның яңарып торуы белән идарә итәргә омтылалар. *Демографик сәясәт ул — дәүләтнең үзе өчен кирәкле юнәлештә халыкның табигый хәрәкәтенә (иң элек — туугa) йогынты ясый торган административ, икътисади, пропаганда һәм башка чаралар системасы.* Аңлашыла ки, демографик сәясәтнең юнәлеше теге яки бу илдәге *демографик хәлнең* торышына бәйләнгән.

Халык яңарып торуның беренче тибы илләрендә туу күрсәткечен һәм халыкның табигый артуын күтәрүгә юнәлтелгән демографик сәясәт өстенлек итә. Мондый сәясәт, нигездә, стимул бирүче икътисади чаралар ярдәмендә үткәрелә: яңа өйләнешүчеләргә бер тапкыр ссуда бирү, һәр туган балага акчалата ярдәм күрсәтү, ай саен балаларга акчалата ярдәм итеп тору, түләүле яллар бирү h.б. Демографик сәясәтне актив үткәрүче илләргә Франция, Япония һәм Россия мисал була ала.

Халык яңарып торуның икенче тибына кергән илләрнең күпчелегендә соңгы унъеллыкларда тууны һәм халыкның табигый артуын киметүгә юнәлтелгән сәясәт алып барыла башлады. Бу юнәлештә иң




10

10 нчы рәсем. Безнең эра башыннан алып Җир шарындагы халык санының үсеше



11

11 нче рәсем. Һиндстан балалары эштә

2 нче таблица

**XX гасырда дөньяда халык санының артуы (млн кеше)**

| Дөнья регионнары һәм бөтен дөнья | Еллар | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1950 | 1960 | 1970 | 1980 | 1990 | 2000 | 2005 |
| Россия, СССР, БДБ | 180 | 214 | 243 | 266 | 289 | 280 | 273 |
| Европа чит илләре | 392 | 425 | 460 | 484 | 498 | 518 | 521 |
| Азия чит илләре | 1392 | 1715 | 2140 | 2569 | 3108 | 3610 | 3840 |
| Африка | 220 | 275 | 356 | 475 | 648 | 796 | 905 |
| Төньяк Америка | 166 | 199 | 226 | 249 | 280 | 316 | 331 |
| Латин Америкасы | 164 | 216 | 283 | 354 | 466 | 520 | 561 |
| Австралия һәм Океания | 13 | 16 | 19 | 23 | 27 | 31 | 33 |
| Бөтен дөнья | 2527 | 3060 | 3727 | 4430 | 5294 | 6071 | 6464 |

12 нче рәсем. Халык яңарып торуның беренче һәм икенче тибы илләрендә яшь-җенес пирамидалары

13 нче рәсем. Дөнья халкының яңарып тору типлары

14 нче рәсем. Дөнья халкының яшь составы

12


СЕВЕРНАЯ АМЕРИКА
14–8=6
ЛАТИНСКАЯ АМЕРИКА
22–6=16
ЗАРУБЕЖНАЯ ЕВРОПА
10–10=0
С Н Г
11–12=–1
ЗАРУБЕЖНАЯ АЗИЯ
20–8=12
АФРИКА
37–15=22
АВСТРАЛИЯ И ОКЕАНИЯ
18–8=10
Халык яңарып торуның I тибы илләре (табигый арту 1000 кешегә 10 кешегә кадәр)
Халык яңарып торуның II тибы илләре (табигый арту 1000 кешегә 10 кешедән артык)
Халык яңарып торуның «формуласы»
23–8=15
туу
үлү
табигый арту 1000 кешегә
Уртача күрсәткечләр:
Бөтен дөнья
22–8=14
Халык яңарып торуның I тибы илләре
11–10=1
Халык яңарып торуның II тибы илләре
24–8=16

13


%
100
90
80
70
60
50
40
30
20
10
0
10
60
30
13
64
23
20
63
17
9
61
30
5
52
43
16
62
22
8
60
32
13
62
25
Бөтен дөнья
БДБ
Европа чит илләре
Азия чит илләре
Африка
Төньяк Америка
Латин Америкасы
Австралия һәм Океания
Балалар (0–14 яшь)
Олылар (15–59 яшь)
Картлар (60 яшь һәм аннан артык)

14

зур тырышлыкны, мөгаен, дөньядагы ике иң зур ил — Кытай белән Һиндстан күрсәтә торгандыр.

**1 нче мисал.** КХРның Конституциясендә ир белән хатын баланы планлы тудырырга тиеш дип әйтелгән. Баланы планлы тудыру буенча комитет төзелгән, бала тудыру өчен җирле хакимияттән рөхсәт алырга кирәк. Никахка керү олырак яшькә күчерелгән. Институтта укыганда, кагыйдә буларак, өйләнешү рөхсәт ителми. КХРның демографик сәясәтенең төп девизы: «Бер гаилә — бер бала». Бу сәясәтне тормышка ашыру инде шактый нәтиҗәләр бирде.

**2 нче мисал.** Һиндстан үсеп килүче илләрдән беренче булып 1951 елда ук рәсми дәүләт сәясәте сыйфатында гаиләне планлаштыруның милли программасын кабул итте. Анда бик яшьтән өйләнешү тыелган, халыкны ирекле рәвештә массакүләм стерильләштерү каралган, дүрт кешелек гаилә пропагандалана: «Икебезгә — ике бала». Шушы чаралар нәтиҗәсендә туучылар саны һәм халыкның табигый артуы беркадәр кимеде, ләкин шулай да бөтен дөньяда яңа туган балаларның 1/5 е чамасы — Һиндстанда дөньяга килгән балалар.

Әмма демографик сәясәтне тормышка ашыруда күп кенә кыенлыклар туа, алар финанс һәм икътисадка гына түгел, әдәп-əхлакка да бәйле. 90 нчы елларда хатын-кызларга йөклелекне өзү хокукы бирелү мәсьәләсе аеруча зур бәхәс кузгатты. Моңа католик чиркәве бигрәк тә кискен каршы төште. [8]. Күпчелек мөселман гарәп илләре, бигрәк тә Көньяк-Көнбатыш Азия дәгеләре, дини әхлактан чыгып, «гаиләне планлаштыруның» барлык чараларын кире кагалар. Тропик Африкадагы иң аз үскән илләрнең күпчелегендә берниндн демографик сәясәт үткәрелми.

**6. Демографик күчеш теориясе.** Демографик процессларның алышыну эзлеклелеген аңлатучы **демографик күчеш** теориясе демографик сәясәтне үткәрүдә әһәмиятле фәнни нигез булып хезмәт итә. Мондый күчеш схемасы бер-бер артлы алышынып баручы дүрт этапны эченә ала.

Беренче этап кешелек тарихының бөтен дәверен диярлек үз эченә ала. Аңа туу һәм үлү күрсәткечләренең үтә югары һәм шуңа тиңдәшле рәвештә халыкның табигый артуы бик түбән булуы хас; мондый этап хәзер бөтенләй диярлек очрамый.

Икенче этап үлүчеләр санының кискен кимүе (нигездә, медицина казанышлары ярдәмендә), ә туу күрсәткеченең традиция буенча һаман югары булып калуы белән характерлана. Беренче һәм икенче күрсәткечләр арасында туган мондый аерма демографик шартлау килеп чыгуның башлангыч сәбәбе булып тора.

Өченче этапка үлү күрсәткеченең түбән килеш саклануы хас (ә кайчакта халыкның «картаюыннан» аның хәтта беркадәр артуы күзәтелә). Туу күрсәткече дә түбәнәя, ләкин бу күрсәткеч үлү күрсәткеченнән беркадәр югарырак булып кала, шуның белән халыкның уртача яңарып торуы һәм халык санының артуы тәэмин ителә.

Дүртенче этапка күчкәндә туу һәм үлү күрсәткечләре үзара тәңгәл киләләр. Бу халык санының *стабильләшүенә* күчүне күрсәтә. (4 нче бирем.)

**7. Халык сыйфаты — яңа комплекслы төшенчә.** Соңгы вакытта фәндә һәм практикада халыкның санын гына түгел, бәлки **халык сыйфатын** характерлаучы күрсәткечләр аеруча зур әһәмияткә ия. Бу — комплекслы катлаулы төшенчә, һәм ул кешеләрнең *икътисади* (эш белән тәэмин ителү, җан башына керем, туклану калорияләлеге), *социаль* (сәламәтлекне саклау дәрәҗәсе, кешеләрнең куркынычсызлыгы, демократик институтларның үсеше), *мәдәни* (укымышлылык дәрәҗәсе, мәдәният учреждениеләре, басма продукция белән тәэмин ителеше), *экологик* (әйләнә-тирә мохит халәте) һәм башка яшәү шартларын исәпкә ала.

Соңгы вакытта БМО һәм башка халыкара оешмалар илнең халык сыйфатын билгеләгәндә төп игътибарны аның сәламәтлегенә бирәләр, ә ул сәламәтлек саклау дәрәҗәсенә һәм гомуми тормыш дәрәҗәсенә бәйле. XX гасырның икенче яртысында бу өлкәдә сизелерлек уңышка ирешелде, шул исәптән үсеп килүче илләрдә дә. Ләкин күп кенә проблемалар әлегә кадәр чишелмәгән.

**Мисал.** Дөньяда уртача яңа туган балалар үлү күрсәткече — 1000 исән туган балага 55 бала. Икътисади үсеш алган илләрдә ул нибары 8 бала, үсеп килүче илләрдә — 60, ә иң аз үсеш алганнарда — 100. Шунысын искәртергә кирәк: Африка һәм Азиядә бу күрсәткеч 150—160 ка җиткән илләр бар (Либерия, Нигер, Сьерра-Леоне, Әфганстан).

Теләсә нинди халыкның сәламәтлек дәрәҗәсен билгеләгәндә ***уртача гомер озынлыгы***[1] гомумиләштерүче төп күрсәткечләрнең берсе булып санала. XXI гасыр башында бөтен дөньяда уртача гомер озынлыгы 66 яшь (ирләр 64 яшь, хатын-кызлар 68 яшь) исәпләнә. Икътисади үсеш алган илләрдә ул тиңдәшле рәвештә 72 һәм 80 яшь, үсеп килүче илләрдә 62 һәм 66 яшь, ә аз үсеш алган илләрдә 51 һәм 53 яшь.

**1 нче мисал.** Дөньяда иң озын уртача гомер күрсәткече Япониядә, һәм ул 82 ел булыр дип көтелә (ирләр өчен 79, хатын-кызлар өчен 86 яшь). Исландия, Испания, Швеция һәм Канадада шундый ук диярлек күрсәткечләр («Кушымта»дагы 15 нче таблицаны карагыз).

**2 нче мисал.** Көтелгән иң кыска уртача гомер озынлыгы Замбия һәм Сьерра-Леонеда (32—34 яшь). Тропик Африканың кайбер башка илләрендә бу күрсәткечләр моннан аз гына югарырак («Кушымта»дагы 15 нче таблицаны карагыз).

---

[1] Уртача гомер озынлыгы — халыкның киләчәктәге гомер озынлыгы, аны ихтималлык теориясенә нигезләнеп фаразлыйлар. Ә ул биологик һәм нәселдәнлек үзенчәлекләренә, шулай ук туклану, хезмәт һәм көнкүреш шартларына бәйле. Гомер озынлыгы еллар белән исәпләнә.

90 нчы елларда Россиядә социаль-икътисади кризис йогынтысыннан халыкның уртача гомер озынлыгы сизелерлек кимеде: 2005 елда якынча 65,3 ел тәшкил итте (ирләр өчен 59 яшь һәм хатын-кызлар өчен 72 яшь). Сүз уңаенда шуны искәртик: ике җенес күрсәткечләре арасындагы мондый зур аерманы дөньяның бер илендә дә очратырга мөмкин түгел.

Халыкның сыйфатын билгеләүче тагын бер күрсәткеч — **укымышлылык дәрәҗәсе**. Икътисади үсеш алган илләрдә укый-яза белмәү бөтенләй яки бөтенләй диярлек бетерелгән. Ләкин үсеп килүче илләрдә, соңгы вакытта ирешелгән уңышларга карамастан, тулаем алганда, белем дәрәҗәсе, бигрәк тә авыл халкы арасында, әлегә шактый түбән.

**Мисал.** Нигер, Мали һәм Буркина-Фасода яшәүче барлык халыкның 80% ы, Сомалида 70% тан артыграгы, Сенегал, Либерия, Эфиопия, Пакистанда һәм Бангладешта яшәүче халыкның 50% тан артыгы укый-яза белми.

БМО мәгълүматларына караганда, 1990 елда 960 млн чамасы кеше укый да, яза да белмәгән. Демографик шартлау шартларында укый-яза белмәүчеләр саны 150 млн га кимеде. Көнчыгыш һәм Көньяк Азиядә, Африканың Сахарадан көньяктагы өлешендә мондый кешеләрнең абсолют саны бигрәк тә зур. Көньяк Азиядә укый-яза белмәүчеләр анда-гы барлык халыкның яртысыннан артыграгын тәшкил итә.

## 2. ХАЛЫКНЫҢ СОСТАВЫН (СТРУКТУРАСЫН) КҮЗӘТӘБЕЗ

**1. Җенси состав: ирләр һәм хатын-кызлар нисбәте.** Табигатьтә ике җенес тә тигез кыйммәтле. Уртача алганда 100 кызга 104—107 малай туса да, 18—20 яшькә җиткәндә аларның саны тигезләшә. Аннан өлкәннәр арасында җенси составның формалашуы төрле илләрдә төрлечә бара.

Дөньядагы илләрнең 2/3 сендә диярлек хатын-кызлар саны күбрәк. Бу аерма БДБ илләрендә, Европа чит илләрендә, Төньяк Африкада бигрәк тә зур. Бу хәл иң элек хатын-кызларның ирләргә караганда берничә елга артыграк яшәүләре белән аңлатыла. Әлеге регионнарның күп кенә илләрендә бу хәл Икенче бөтендөнья сугышында ирләрнең бик күп һәлак булуына бәйле. Әмма, дөньяга яңа буыннар килү белән, аларның сан аермасы акрынлап кими бара, ләкин бу кагыйдәдән чыгармалар да була.

**Мисал.** 2006 ел башына Россиядә хатын-кызлар саны ирләр саныннан 10 млн га артыграк була. Исәпләүләргә караганда, бу аерма 2010 елда 11 млн га җитәчәк, ул, барыннан да элек, ирләрнең күбрәк үлүе белән аңлатыла.

Африка, Латин Америкасы, Австралия һәм Океаниядә ирләр һәм хатын-кызларның саны якынча тигез.

Ә менә Азия чит илләрендә ирләр саны шактый артык. Бу хәл күбесенчә хатын-кызларның

гаиләдә һәм җәмгыятьтә элек-электән кимсетелгән авыр хәлдә (иртә кияүгә чыгу, ачлык һәм фәкыйрьлектә бик яшьли күп бала табу, авырулар) булуы белән аңлатыла. Соңгы вакытта Азия илләренә читтән миграция агышы да халыкның җенси составына зур йогынты ясады.

**Мисал.** Фарсы култыгындагы нефть чыгаручы илләргә читтән эшче ир-атлар күпләп килү сәбәпле, мондагы барлык халыкның 55—65% ын ирләр тәшкил итә. Мондый артыклыкның доньяда беркайда да күренгәне юк. [9].

Шулай да бөтендөнья йомгаклау күрсәткечләре буенча халкы иң күп саналган илләрдә — Кытай (38 млн га) һәм Һиндстанда (35 млн га) — ирләр саны шактый күпкә өстенлек итә. Нәкъ менә шушы ике ил исәбенә бөтен дөньяда 100 хатын-кызга 101 ир-ат туры килә. (5 нче бирем.)

**2. Яшь составы: хезмәт ресурсларына йогынтысы.** Борынгы грек математигы һәм философы Пифагор кеше гомерен, ел фасылларына тиңләштереп, дүрт «фасылга» бүләргә тәкъдим иткән: яз (балалык), җәй (яшьлек), көз (җитлеккәнлек) һәм кыш (картлык). Безнең көннәрдә дә галимнәр халыкның демографик яшьлеге, җитлеккәнлеге һәм картлыгы турында сүз алып баралар. Илне (регионны) шушы «фасылларның» берсенә кертү иң элек туу, үлү һәм табигый арту күрсәткечләренә бәйле. Шуңа күрә дә халыкның яшь составының төрләре, гомумән алганда, аның яңарып тору типларына туры килә.

**Мисал.** Үсеш алган илләрдә балалар барлык халыкның уртача 18 % ын, ә картлар 19 % ын тәшкил итә, үсеп килүче илләрдә исә ул тиңдәшле рәвештә 33 % һәм 8 %. [10].

Халыкның яшь һәм җенес составына график анализ ясау өчен, диаграмманың махсус төре — яшь-җенес пирамидасы киң кулланыла (12 нче рәсемне карагыз).

Халыкның төп җитештерүче өлешен — хезмәт ресурсларын билгеләгәндә, кешенең яше төп критерий булып санала. Ә аларның җитештерүдә катнашу дәрәҗәсе ***икътисади актив халык***[1] күрсәткече белән билгеләнә.

Дөньядагы халыкның икътисади актив өлешенә барлык халыкның уртача 49 % чамасын кертергә мөмкин, ул — 3 млрд чамасы кеше. Россиядә, Европа чит илләрендә, Төньяк Америкада хатын-кыз хезмәтенең киң, ә кайчакта хәтта бик киң кулланылуы аркасында, бу күрсәткеч (50—70%) дөньяның уртача күрсәткеченнән югарырак. Азия, Африка һәм Латин Америкасы илләрендә исә ул дөньядагы уртача күрсәткечтән (40—50%) түбәнрәк. Бу — аларның икътисади артталыгы, халыкның күбрәк өлеше балалар яшендә булуы белән, анда миллионнарча балалар һәм яшүсмерләр эшләп тә (11 нче рәсемне карагыз), хатын-кызларның иҗтимагый җитештерүгә бик аз катнашуы белән аңлатыла. (6 нчы бирем.)

[1] Икътисади актив халык (ИАХ) — хезмәткә сәләтле халыкның материаль байлыклар җитештерүче һәм материаль байлыклар җитештермәүче сфераларда катнашкан өлеше.

**3. Этник лингвистик состав: катлаулы проблемалар.** Дөньяда 4—5 мең төрле халык, ягъни ***этнос***[1] исәпләнә, аларның кайберләре, берләшеп, аерым милләтләр хасил иткән, ә башкалары халыклар һәм кабиләләр булып берләшкән. Табигый ки, халыкларның гаять төрлелеге аларны классификацияләүне таләп итә. Халыклар географиясе өчен халыкларны, беренчедән, саны буенча, икенчедән, телләре буенча бүлү әһәмиятле.

Халыкларны саны буенча классларга бүлү иң элек алар арасында гаять зур аерма барлыгын күрсәтә: мәсәлән, кытайлар 1,3 млрд тан артыграк исәпләнсә, Шри-Ланкадагы ведд кабиләсенең яки Бразилиядәге ботокудлар кабиләсенең нибары 1 әр мең чамасы гына кешесе бар. Җирдәге халыкның төп өлешен күп санлы һәм аеруча күп санлы халыклар тәшкил итә, ә йөзләрчә аз санлы халыклар Җир шарындагы барлык халыкның фәкать берничә процентын гына алып тора. Ләкин бөтендөнья мәдәнияте үсеше өчен халыкларның зуры да, кечесе дә бер, алар үзләреннән өлеш кертеп килделәр һәм кертәләр.

Халыкларны телләре буенча классификацияләү аларның якынлыгы принцибына нигезләнә.

Мондый якынлык, гадәттә, бер башлангыч — «баба тел» саналган телдән берничә тел барлыкка килүгә бәйләнгән. Көньяк Европада барлыкка килгән роман телләре Борынгы Римда һәм ул яулап алган илләрдә хакимлек иткән латин теле нигезендә туган. Борынгы рус теле көнчыгыш славян телләре өчен башлангыч булып санала.

Бу очракта, белгәнебезчә, барлык телләрне тел семьялыкларына берләштерәләр, ә алары тел төркемнәренә бүленә. Аларның иң киң таралганы — *һинд-европа телләре семьялыгы.*

**Мисал.** Бу телләрдә барысы 2,7 млрд кешедән торган 150 халык сөйләшә. Алар дөньяның барлык кисәкләрендә таралган 11 тел төркеменә керә. Европа чит илләрендә һәм Америкада бу телләрдә барлык халыкның 95% ы сөйләшә. [11].

*Сино-тибет семьялыгы* телләрендә, нигездә кытай телендә, 1,4 млрд тан артык кеше, ә *афразия семьялыгы* телләрендә, күбесенчә гарәп телендә, 370 млн нан артыграк кеше сөйләшә. Калган тел семьялыклары вәкилләре саны шактый кечерәк. (7 нче бирем.)

Милли (этник) чикләр сәяси чикләр белән туры килгән очракларда, **бер милләтле дәүләт** барлыкка килә; ул дәүләтләрнең күпчелеге Европада, Латин Америкасында, Австралия һәм Океаниядә, Якын Көнчыгышта урнашкан. Шулай ук ике милләтле дәүләтләр дә бар: мәсәлән, Бельгия, Канада һ.б. Алар белән беррәттән **күп милләтле дәүләтләр** дә бар; аларның кайберләрендә уннарча һәм хәтта йөзләрчә милләт халкы яши. Күбесенчә

---

[1] Этнос (грек. *éthnos*) — кешеләрнең тел, территория, хуҗалык, мәдәният һәм милли үзаң берлеге нигезендә тарихи барлыкка килгән тотрыклы бергәлеге.

алар — федератив (яки конфедератив) административ-территориаль төзелешле дәүләтләр.

Күп милләтле һәм ике милләтле илләрдә бик катлаулы милләтара мөнәсәбәтләр мәсьәләсе туа.

Беренче чиратта бу үсеп килүче илләргә кагыла. Монда кардәш кабиләләрнең халыкларга, ә халыкларның милләтләргә берләшүе кебек прогрессив процесс бара.

**Мисал.** Иң кискен милләтара (һәм дини) низаглар Азия чит илләренә — Һиндстан, Индонезия, Шри-Ланка, Әфганстан, Гыйрак, Иран, Төркия, Кытайга, Африкада КАР, Зимбабве, Нигерия, Суданга хас.

70 нче елларның урталарыннан башлап икътисади үсеш алган күп кенә илләрдә дә милли мәсьәлә нык кискенләште. Моңа анда яшәүче милләтләр һәм халыклар арасында икътисади һәм социаль тигезсезлек сәбәп булды. Беренче чиратта бу Бөекбританиягә, Франция, Канада, Бельгия, Испаниягә кагыла.

Канадада төп ике милләт — инглизләр һәм французлар яши; инглиз һәм француз телләре — дәүләт телләре. Французлар Квебек провинциясендә тупланып яшиләр һәм «француз Канадасын» тәшкил итәләр. Калган барлык провинцияләр — «инглиз Канадасы». Ләкин инглиз-канадалылар югарырак социаль баскычта торалар, икътисадта төп позицияләрне билгелиләр, һәм бу хәл милләтара мөнәсәбәтләрнең даими кискенләшеп торуына китерә. Француз-канадалыларның бер өлеше хәтта суверен Квебек, ягъни мөстәкыйль франко-Канада дәүләтен төзү таләбен куя.

80 нче еллар ахырыннан башлап Россиядә һәм элеккеге СССР территориясендә барлыкка килгән кайбер дәүләтләрдә, шулай ук Көнчыгыш Европа илләрендә, бигрәк тә элеккеге Югославия республикаларында, милләтара мөнәсәбәтләр аеруча катлауланды.

**4. Дини состав: дөньякүләм таралган һәм милли диннәр.** Үзләренең таралуына, тоткан урынына карап, барлык диннәр *дөньякүләм* таралган һәм *милли* диннәргә бүленә. Дөньяда диннәрнең иң киң таралганы — христиан дине (аңа өч тармак — католик, протестант һәм православие диннәре керә). Христиан динен күбесенчә Европа, Америка һәм Австралия халкы — барлыгы 2,4 млрд чамасы кеше тота. Дин тотучылар саны буенча (1,5 млрд) икенче урынны ислам дине (мөселманлык) алып тора. Ислам дине дөньяның күп илләрендә, нигездә Азия һәм Африка илләрендә, дәүләт дине дип игълан ителгән. Дөньякүләм таралган диннәр арасында буддизм (370 млн) өченче урында. Ул Үзәк, Көньяк-Көнчыгыш һәм Көнчыгыш Азиядә таралган.

Соңгы вакытта ислам факторы барлык дөнья үсешенә аеруча зур йогынты ясый башлады. Хәзер ислам дөньясына 50 ил керә, ә 120 илдә мөселман җәмгыятьләре бар.

**Мисал.** Халык саны иң күп булган ислам дәүләтләре — Индонезия,

Пакистан, Бангладеш, Нигерия (100 дән алып 200 млн га кадәр дин тотучылар), Иран, Төркия, Мисыр (50 млн нан 70 млн га кадәр). Массакүләм булуы һәм әһәмияте ягыннан ислам дине Россиядә христианлыктан кала икенче урында тора.

«Ислам» — гарәпчә «буйсынучанлык» дигәнне аңлата. Шуңа карамастан күп кенә киеренке сәяси һәм дини конфликтларны нәкъ менә шул ислам дине белән бәйлиләр. Бу хәл *ислам экстремизмы* — гражданнар җәмгыятен шәригать законнарына буйсынучы ислам җәмгыятенә алыштырырга омтылу белән аңлатыла.

**Мисал.** Соңгы вакытта ислам экстремизмы эчке һәм халыкара терроризмга төп нигез булып тора. Моны Израильдәге, Һиндстандагы, Филиппиндагы, Россиядәге (Чечня), Таҗикстандагы хәлләр дәлилли. «Аль-Каида» ислам оешмасы бөтен дөньяны тетрәндергән терактларны Нью-Йоркта һәм Вашингтонда 2001 елның 11 сентябрендә үткәрде.

Икенче яктан, *уртачыл ислам* гражданнар җәмгыяте белән җитәрлек тату яши.

Милли диннәргә Һиндстандагы индуизм (900 млн дин тотучы), Кытайдагы конфуцианлык, Япониядәге синтоизм һ.б. керә. Шулай ук иң борынгы диннәрнең берсе — яһүд дине дә киң таралган. Аның күп кенә тәгъбирләре христиан диненә дә күчкән. (8 нче бирем.)

Үзгәреп торучы шартларга яраклашып, дин кешеләрнең әхлак, гореф-гадәт һәм шәхси тормышларына, гаилә мөнәсәбәтләренә бик зур йогынты ясый. Аерым алганда, халыкның яңарып торуына аның йогынтысы гаять зур.

Протестант дине таралган илләрдә, кагыйдә буларак, өйләнешү яше шактый зур, ә инде аерылышуны рәсмиләштерү артык катлаулы эш түгел. Кайбер католик дине таралган илләрдә (Испаниядә, Латин Америкасы илләрендә) закон ирләргә 14 яшьтән, ә кызларга 12 яшьтән никахка керергә рөхсәт итә. Хәзер католикларга да аерылышу мәсьәләсе җиңеләйде, ә 20—30 ел элек аерылышу, гомумән, тыелган була. Мөселман илләрендә никах яше бик түбән, дин иртә өйләнешүне һәм никахлашуның мәҗбүрилеген, күп бала табуны, күп хатынлылыкны яклый, ә демография сәясәтенә күбесенчә тискәре караш яшәп килә. Индуизм да иртә өйләнешүне һәм аның мәҗбүрилеген, күп бала табуны хуплый, ләкин аерылышулар һәм кабат өйләнешүләрне тыя. Һиндстанда элек 14 яшькә кадәрге кыз балаларның яртысы инде кияүдә булган. Хәер, анда әле хәзер дә кызларның күбесе кияүгә 18 яшькә җиткәнче үк чыгалар. Ә Кытайда конфуциан әхлагы демографик сәясәтне үткәрүдә булышлык күрсәтә.

Дини низаглар, еш кына милли һәм раса каршылыклары белән үрелеп, «кайнар нокталар» барлыкка китерәләр.

**Мисал.** Төньяк Ирландиядә (Ольстерда) инде күп еллардан бирле сәяси киеренкелек яшәп килә. Бөекбританиянең бу кайнар ноктасында аның төп халкы булып саналуына карамастан, кимсетелгән католик-

лар һәм икътисади-сәяси тормышта төп урынны алган протестантлар (Англия һәм Шотландиядән күчеп килүчеләрнең токымнары) арасында дини низаглар басылмый.

## 3. ХАЛЫКНЫҢ УРНАШУЫНА ҺӘМ МИГРАЦИЯСЕНӘ ХАРАКТЕРИСТИКА БИРӘБЕЗ

**1. Халыкның урнашуы һәм тыгызлыгы: кискен аермалар.** *Дөнья халкы гаять тигезсез урнашкан:* барлык халыкның 2/3 чамасы коры җир территориясенең 8 % ында яши. Шуның белән бергә, кеше яши торган коры җирнең яртысында диярлек халыкның тыгызлыгы 1 км$^2$ га 5 кешедән дә кимрәк тәшкил итә. Коры җир территориясенең 15 % ы бөтенләй үзләштерелмәгән. Болар — иң элек табигый шартлары экстремаль булган өлкәләр. Табигый ки, кешеләр беренче чиратта яшәү өчен уңайлырак һәм төрле ресурсларга бай территорияләрне үзләштергәннәр, алар анда төрле антропоген ландшафтлар булдырганнар.

**Мисал.** Җирдәге һәр 100 кешенең 80 е диңгез өсте тигезлегеннән 500 м биеклектәге түбәнлекләрдә һәм тигезлекләрдә яши. Мондый урыннар коры җирнең нибары 28 % ын гына алып тора. Кайбер аерым очракларны исәпкә алмаганда, таулы өлкәләрдә халык сирәгрәк урнашкан. [12].

Кешеләрнең урнашуына бик борынгы заманнардан ук аларның авыл хуҗалыгына мөнәсәбәте зур йогынты ясаган.

**Мисал.** Сугарулы кырларда күп хезмәт таләп итә торган дөге игүнең таралуы Көнчыгыш һәм Көньяк Азиядә халык бик тыгыз урнашкан җирләр барлыкка килүгә сәбәп булды. Анда әле хәзер дә авыл халкының тыгызлыгы 1 км$^2$ га 200 кешедән артып китә, ә кайбер районнарда исә 1500—2000 һәм аннан да күбрәк кешегә җитә.

Промышленность үсү белән, Европада һәм АКШта халык үтә тыгыз урнашкан районнар формалаша. Кайбер промышленность районнарында халык тыгызлыгы шулай ук 1 км$^2$ га 1000—1500 кешегә җитә.

Ниһаять, кешелек цивилизациясенең бөтен тарихында кешеләрнең транспорт һәм сәүдә юллары тирәсенә тартылуы аларның урнашуына зур йогынты ясый.

**Мисал.** Океан һәм диңгез буйларының 200 км лы полосасында бөтен дөньядагы халыкның яртысыннан артыграгы, ә 50 км лы полоса буйлап (ул коры җирнең 12 % ын били) халыкның 30 % чамасы урнашкан (15 нче рәсемне карагыз). Аерым районнарда, бигрәк тә утраудагы һәм ярымутраудагы илләрдә, бу күрсәткеч тагы да югарырак. [13].

Җирдәге халыкның уртача тыгызлыгы — 1 км$^2$ га 48 кеше. Ләкин, аңлавыгызча, бу уртача күрсәткечтә аерым илләр арасында бик зур аерма яшеренгән булуы мөмкин.

**Мисал.** Халкы иң тыгыз урнашкан ил буларак еш кына Бангладешны атыйлар, анда халык тыгызлыгы күрсәткече 1 км$^2$ га 1000 кешедән артып китте. Ләкин зур булмаган, башлыча утрау дәүләтләрендә ул тагын да югары: Сингапурда —

1 км$^2$ га 6500 кешедән артык, Мальдив утрауларында — 1100, Мальтада — 1200 кеше. (Ә Монакода — 1 км$^2$ га 16 400 кеше!)

Кайбер илләрнең үз эчендә халыкның урнашуында һәм тыгызлыгындагы аерма тагын да зуррак. **Мисал.** Канада халкының 2/3 өлеше АКШ чиге буйлап сузылган 150 километрлы көньяк зонада яши, һәм ул халыкның төп урнашу полосасын тәшкил итә. Илнең төньягында исә 20—25 км$^2$ территориягә фәкать 1 кеше туры килә. Мондый кискен аермалар Австралиягә дә хас (16 нчы рәсемне карагыз).

*Халыкның билгеле бер саны һәм тыгызлыгы — һәр илнең үсеше өчен иң кирәкле алшарт.* Ләкин халык тыгызлыгының ролен арттырып бәяләүче һәм хәтта аның белән социаль-икътисади үсеш дәрәҗәсе арасында турыдан-туры бәйләнеш урнаштырырга тырышучы галимнәр һич хаклы түгелләр. (9 нчы бирем.)

**2. Халыкның миграциясенең төрләре һәм географиясе.** *Халыкның аерым илләрдә һәм бөтен дөньядагы санына, составына һәм урнашуына аның күчеп йөрүе — миграциясе зур йогынты ясый.* «Кешеләр күчмә кошлар түгел, аларның күчеп йөрүе биологик законнар белән түгел, бәлки иҗтимагый законнар белән аңлатыла»,— дип язды Н. Н. Баранский. Миграцияләрнең төп сәбәбе — икътисади сәбәп, ләкин аларның сәяси, милли, дини, экологик һәм башка сәбәпләрдән дә булуы мөмкин.

Халыкның халыкара (тышкы) миграцияләре бик борынгы заманнарда ук барлыкка килгән, урта гасырларда исә, күбесенчә Бөек географик ачышларга бәйле рәвештә дәвам иткән, ә инде капитализм чорында аеруча зур үсеш алган.

Иң зур «миграцион шартлау» XIX гасырда башлана. Эмиграциянең төп учагы Европа була, чөнки анда капитализмның үсеше халыкның бер өлешен хуҗалык тиз үскән, эшче куллар таләп ителгән буш җирләргә «этеп чыгару» юлы белән барган. Эмиграция башланганнан алып Икенче бөтендөнья сугышына кадәр Европадан барлыгы 60 млн кеше китә. [14]. Эмиграциянең икенче учагы Азиядә барлыкка килә. Биредә Кытай һәм Һиндстан эшчеләре (кули) плантацияләрдә һәм рудникларда ялланып эшлиләр. Иммиграциянең төп учаклары исә АКШ, Канада, Бразилия, Аргентина, Австралия, Яңа Зеландия, Көньяк Африкада була.

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң халыкара миграция яңадан үсә һәм XX гасыр ахырында яңа «миграцион шартлау» масштабына ирешә. Элеккеге кебек үк бу миграцияләрнең төп сәбәбе икътисадка бәйләнгән: кешеләр яхшырак эш һәм яшәү урыны эзләп читкә китәләр. Мондый миграцияләр **хезмәт миграциясе** дип атала. Нәтиҗәдә XXI гасыр башында 35—40 млн кеше даими яисә вакытлыча үз илләреннән читтә эшлиләр. Ә инде аларның гаилә әгъзаларын, сезонлы һәм легаль булмаган эмигрантларны да исәпләсәк, бу сан 4—5 тапкыр артачак. *Мондый хезмәт эмигрантларының төп агымы үсеп килүче илләрдән икътисади үсеш алган илләргә юнәлә.*

Ләкин икътисади үсеш алган илләр арасында, шулай ук үсеп килүче илләр арасында да хезмәт миграциясе булып тора.

Эшче көчләренең мондый халыкара миграциясенең төп сәбәбе — икътисади нык үскән һәм үсеп килүче илләрдә тормыш һәм эш хакы дәрәҗәләре арасында аерманың зур булуында. Әмма АКШта һәм Көнбатыш Европада иммигрантлар, аеруча яшьләр, еш кына теләсә нинди, шул исәптән иң авыр, иң аз түләнә торган «дәрәҗәсез» эшләргә дә ялланырга мәҗбүр булалар. Әлбәттә, аларны заманча предприятиеләрдә дә очратырга мөмкин. Ләкин күпчелеге шахталарда һәм төзелештә яисә хезмәт күрсәтү сферасында сатучы, азык таратучы, официант, лифтер, каравылчы, шофер, чүп җыючы булып эшләргә урнашалар.

*Хәзерге вакытта дөньяда хезмәт ресурсларын үзенә тартучы дүрт төп үзәк бар. Беренчедән,* ул Көнбатыш Европа илләре (аеруча ГФР, Франция, Бөекбритания, Швейцария). Монда Көньяк Европа, Көнбатыш Азия һәм Төньяк Африка илләреннән чыккан эшче иммигрантларның шактый зур катлавы формалашкан; 90 нчы елларда Көнчыгыш Европа һәм БДБ илләреннән мигрантлар агышы шактый артты. *Икенчедән,* АКШ, монда хәтта легаль иммиграция генә дә (бигрәк тә Латин Америкасы, Азия һәм Европадан) елына 1 млн кеше тәшкил итә, ә инде легаль булмаганнары аннан да күбрәк. *Өченчедән,* ул — Фарсы култыгындагы нефть чыгаручы илләр. Монда эшләүче мигрантларның саны (Мисыр, Һиндстан, Пакистан һәм башка илләрдән) җирле халык санынннан күпкә артып китә. *Дүртенчедән,* бу — Россия. Канада һәм Австралия дә иммигрантларны шактый күп кабул итүче илләрдән санала. Бигрәк тә Израиль аерылып тора, БДБ илләреннән иммиграция агышының шактый зур булуы аркасында Израильдә халык саны 2/3 өлешкә артты. (10 нчы бирем.)

XX гасырның икенче яртысында тышкы миграциянең яңа формасы барлыкка килә. «Мускуллар китү» иммиграциясеннән аермалы буларак, бу форма **«миләр китү»** (яки «акыл күчерү») дигән исем ала. Аның асылы чит илләрдән галимнәр, инженерлар, табиблар һәм югары квалификацияле башка белгечләрне китерүдән гыйбарәт. Ул Көнбатыш Европа илләреннән АКШка кешеләр агылудан башлана. Ләкин соңрак үсеп килүче илләр мондый «интеллектуал»-иммигрантларны төп җибәрүчеләргә әверелде. Интеллигенциясе болай да бик аз булган бу илләрнең икътисады һәм мәдәниятенә «миләр китү» гаять тискәре йогынты ясый. 80 нче еллар ахырында — 90 нчы еллар башында сәяси һәм икътисади кризис аркасында Россия, Украина һәм элекке СССР составына кергән башка илләрдән «миләр китү» аеруча көчәйде.

Хезмәт миграцияләре белән бергә(ә)ттән сәяси, этник, дини, экологик һәм башка сәбәпләр аркасында массакүләм миграцияләр дәвам итә. Соңгы вакытта *качаклар агымы* нәкъ шуңа бәйле рәвештә барлыкка килде һәм аларның саны дистәләгән

миллион кешедән артып китте. Аңлашыла ки, иң элек кешеләр кискен сәяси һәм хәрби конфликтлы районнардан китәләр.

**Мисал.** XXI гасыр башында илдән киткән качаклар саны буенча Әфганстан, Израиль (Палестина) һәм Руанда аерым урын алып тора, монда качаклар саны миллионнар белән исәпләнә. 500 меңнән 1 млн га кадәр качак Югославия һәм Гыйракны ташлап китте. Әчке качаклар (күчеп китәргә мәҗбүр булганнар) саны Судан, Ангола һәм Колумбиядә күп, монда этник-сәяси бәрелешләр дәвам итә.

Халыкнын әчке (дәүләт эчендәге) миграциясе берничә төрле була. Аңа халыкның авыл җирләреннән шәһәрләргә күчеп килүе керә, күп кенә илләрдә бу күренеш шәһәрләр үсешенең төп чыганагы булып тора. Миграциянең бу әчке төре безнең көннәрдә шундый масштабларга җитте ки, хәтта аны «XX гасыр халыкларының бөек күчеше» дип атый башладылар. Халыкларның территориаль яктан яңадан бүленүе шулай ук зур һәм кечкенә шәһәрләр арасында да бара. Яңа җирләрне үзләштерү һәм колонияләштерү дә миграциягә бәйле. Миграциянең бу төре иң элек халык урнашу тыгызлыгында кискен аермалар булган зур территорияле илләргә — Россия, Казахстан, Канада, Бразилия, Австралия һәм Кытайга хас.

Соңгы вакытта кешеләрнең төрле «кайнар нокталардан» китү күренеше массакүләм төс ала бара. Моңа хәрби-сәяси конфликтлар гына түгел, экологик һәлакәткә тарыган районнар да керә. Асылда, алар — шундый ук качаклар (мәсәлән, *экологик качаклар*), ләкин аларны, гадәттә, *күчерелгән затлар* дип атыйлар.

## 4. ШӘҺӘР ҺӘМ АВЫЛ ХАЛКЫН ЧАГЫШТЫРАБЫЗ

**1. Шәһәр халкы роле арту.** Тарих дәреслекләреннән белгәнегезчә, шәһәрләр бик борынгы заманнарда Нил, Тигр һәм Евфрат дельталарында, борынгы Яһүдия, Һиндстан, Кытайда административ хакимият, сәүдә һәм һөнәр үзәкләре, хәрби ныгытмалар буларак барлыкка килгәннәр. Капитализмның һәм эре машина индустриясенең, транспорт һәм дөнья базарының үсүе белән шәһәрләрдә промышленность күбрәк туплана башлый, алар транспорт һәм сәүдә үзәкләренә әверелә. Аларның административ һәм мәдәни үзәк буларак рольләре тагын да арта. XX гасырның икенче яртысында, барыннан да элек, материаль байлык җитештермәүче сфера тармаклары үсеш алу нәтиҗәсендә, шәһәрләрнең функцияләре тагын да киңәя. Гадәттә, хәзерге шәһәрләрнең функцияләре берничә төрле. Ләкин тау промышленносте, фәнни, курорт һәм хәтта башкала кебек бер генә функцияне башкаручы шәһәрләр дә бар. [15]. Башкала итеп махсус төзелгән шәһәрләр дә бар. [16].

*Хәзерге вакытта халыкның урнашуын шәһәрләр географиясе торган саен күбрәк билгели*, ә Җир шарында аларның саны ун меңнәрчә. [17].

Шәһәрләрнең үз тирәсендәге табигый мохиткә һәм шулай ук авылларга да йогынтысы арта бара. Шуңа күрә Н. Н. Баранскийның шәһәрләрне һәр ил территориясенең «команда составы» дип атавы очраклы түгел.

**2. Урбанизация төшенчәсе.** Хәзерге заманның иң әһәмиятле социаль-икътисади процессларыннан берсе — урбанизация (шәһәрләшү).

**Шәһәрләрнең үсүе, һәр илдә, регионда, дөньяда шәһәр халкы санының чагыштырмача артуы, шәһәрләрнең һаман катлаулана барган челтәре һәм системасы барлыкка килүе һәм үсүе урбанизация** (лат. *urbs* — шәһәр) **дип атала.** Димәк, урбанизация (шәһәрләшү) ул — җәмгыять тормышында шәһәрләрнең роле күтәрелүне билгеләүче тарихи процесс, халыкның хезмәт һәм яшәү рәвеше, мәдәнияте, җитештерүне урнаштыру үзенчәлекләре буенча җәмгыятьне шәһәрләштерүне күздә тота. *Урбанизация — социаль-икътисади үсешнең иң әһәмиятле состав өлешенең берсе.*

Хәзерге урбанизациянең, бөтен дөньяда барган процесс буларак, күпчелек илләргә хас гомуми өч үзенчәлеге бар.

Беренче үзенчәлек — *шәһәр халкының, бигрәк тә акрын үсеп килүче илләрдә, югары темплар белән артуы.*

**Мисал.** 1900 елда дөнья халкының — 13 % чамасы, 1950 елда — 30 %, 1980 елда — 39 %, ә 2007 елда 50 % ы шәһәрләрдә яшәгән. Шәһәр халкы елына якынча 60 млн кешегә арта.

Икенче үзенчәлек — *халыкның һәм хуҗалыкның, нигездә, зур шәһәрләрдә тупланыуы.* Бу иң элек җитештерүнең характеры, аның фән һәм мәгариф белән бәйләнешләре катлаулану белән аңлатыла. Болардан тыш, зур шәһәрләр, гадәттә, кешеләрнең рухи ихтыяҗларын тулырак канәгатьләндерә, төрле товарлар һәм хезмәт күрсәтү белән яхшырак тәэмин итә, өстәвенә мәгълүматлар саклау урыннарыннан киңрәк файдаланырга мөмкинлек бирә. «Зур шәһәрләр — рухи һөнәрханәләр алар, Галәмнең иң яхшы әсәрләре шунда иҗат ителә»,— дип язган күренекле француз архитекторы Ле Корбюзье.

**Мисал.** XX гасыр башында дөньяда барлыгы 360 зур шәһәр (халкы 100 мең кешедән артыграк) булган һәм анда барлык халыкның фәкать 5 % ы яшәгән. 80 нче еллар ахырында исә андый шәһәрләр саны 2,5 меңгә җитә һәм аларда дөнья халкының 1/3 еннән артыгы яши. XXI гасыр башына зур шәһәрләр саны 4 меңгә җитте.

Зур шәһәрләр арасында, гадәттә, иң зурларын, халкы 1 млн нан арткан миллионер шәһәрләрне аерып күрсәтү кабул ителгән. Юлий Цезарь заманында Рим тарихта шундый беренче шәһәр булган. XX гасыр башында алар нибары 10 булса, 80 нче еллар башында 200 дән артып китә, 1995 елда — 325, ә XX гасыр ахырында бу сан 400 гә җитте. Россиядә шундый 17 шәһәр исәпләнә иде.

Өченче үзенчәлек — *шәһәрләрнең «җәелүе», территорияләренең киңәюе.* Хәзерге




15

16

15 нче рәсем. Диңгездән ераклашу дәрәҗәсенә карап, дөнья халкының урнашуы

16 нчы рәсем. Австралиядә халыкның урнашуы

17 нче рәсем. Дөньяның иң зур шәһәрләре




17




18

18 нче рәсем. Дөньядагы илләрдә урбанизация дәрәҗәсе

19 нчы рәсем. Тропик Африкадагы авыл

19



3 нче таблица

**1950—2005 елларда шәһәр халкының артуы (млн кеше)**

| Дөнья регионнары һәм бөтен дөнья | Еллар | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1950 | 1960 | 1970 | 1980 | 1990 | 2005 |
| СССР, БДБ | 70 | 104 | 133 | 166 | 193 | 178 |
| Европа чит илләре | 224 | 256 | 292 | 341 | 365 | 405 |
| Азия чит илләре | 235 | 362 | 503 | 733 | 989 | 1475 |
| Африка | 33 | 51 | 84 | 136 | 202 | 353 |
| Төньяк Америка | 110 | 139 | 167 | 191 | 213 | 264 |
| Латин Америкасы | 70 | 106 | 163 | 238 | 311 | 432 |
| Австралия һәм Океания | 8 | 11 | 14 | 17 | 19 | 24 |
| Бөтен дөньяда | 750 | 1027 | 1356 | 1822 | 2292 | 3113 |

урбанизациягә җыйнак («ноктасыман») гадәти шәһәрләрнең *шәһәр агломерацияләренә* әверелүе — шәһәр һәм авылларның территория ягыннан төркемләнүе хас. Эре шәһәр агломерацияләренең үзәкләре булып еш кына башкалалар, мөһим промышленность һәм порт үзәкләре санала.

**Мисал.** 1970 елда дөньяда халкы 10 млн кешедән артып киткән нибары өч шәһәр агломерациясе — Токио, Нью-Йорк һәм Шанхай булса, 1999 елда мондый «супершәһәрләр» саны 12 гә, ә XXI гасыр башында 21 гә җитте. Шул ук вакытта Токио — дөньяның иң зур агломерациясе дә һәм ул шулай булып кала.

Бу агломерацияләрнең күпчелеге һаман үсә барып, тагын да зуррак шәһәрләшкән районнарга һәм зоналарга әверелә. (11 нче бирем.)

**3. Урбанизация дәрәҗәсе һәм темплары: аларны ничек көйләргә?** Бөтен дөньяда бара торган процесс буларак, урбанизациянең уртак сыйфатлары булуга карамастан, төрле илләр һәм регионнарда аның үзенә генә хас үзенчәлекләре дә бар, ә алар исә урбанизациянең төрле дәрәҗәсендә һәм темпларында чагылыш таба.

Урбанизация дәрәҗәсе буенча дөньядагы барлык илләрне өч зур төркемгә бүләргә мөмкин (18 нче рәсемне карагыз). Әмма төп бүленеш сызыгы шулай да үсеш алган һәм үсеп килүче илләр арасыннан уза. 2005 елда үсеш алган илләрдә урбанизация дәрәҗәсе уртача 74 %, ә үсеп килүче илләрдә 43 % тәшкил итә. (12 нче бирем.)

Урбанизация темплары күбесенчә аның дәрәҗәсенә бәйле. Югары урбанизация дәрәҗәсенә ирешкән, икътисади үсеш алган илләрнең күбесендә соңгы вакытта шәһәр халкының үсеше чагыштырмача акрын бара, ә башкалада һәм башка зур шәһәрләрдә халык саны, кагыйдә буларак, хәтта кими. Шәһәр кешеләренең күпчелеге зур шәһәрләрнең үзәгендә түгел, бәлки шәһәр читендәге районнарда һәм авыл җирләрендә яшәүне өстен күрәләр. Бу хәл инженерлык корылмаларының кыйммәтләнүе, инфраструктураның искерүе, транспорт проблемаларының бик нык катлаулануы, әйләнә-тирәнең пычрануы белән аңлатыла.

Ләкин урбанизация, яңа формалар алып, «тирәнгә» таба үсә.

Урбанизация дәрәҗәсе шактый түбән булган үсеп килүче илләрдә ул «киңлеккә» үсә, шәһәр халкы бик тиз арта. Алар өлешенә барлык шәһәр халкының еллык артымының 9/10 ы туры килә, ә шәһәр халкының абсолют саны икътисади үсеш алган илләрдәгедән инде күпкә артып китте.

**Мисал.** Шәһәр халкының гомуми саны буенча үсеп килүче илләр 70 нче еллар урталарында ук икътисади үсеш алган илләр белән тигезләште, ә 2005 елда аларны ике тапкырдан күбрәккә узып китте: 2 млрд һәм 925 млн шәһәр кешесе. «Миллионер» һәм «супершәһәрләрнең» дә күпчелеге хәзер үсеп килүче илләрдә. Азия чит илләрендә аларның өлеше (47 %) бигрәк тә зур. [18].

Фәндә **«шәһәрләр шартлавы»** дип аталган бу күренеш үсеп

килүче илләрнең социаль-икътисади үсешендә иң әһәмиятле факторларның берсенә әверелде. *Ләкин бу регионнарда шәһәр халкының артуы аларның реаль үсешеннән алда бара.* Ул шактый дәрәҗәдә артык авыл халкын даими рәвештә шәһәрләргә, бигрәк тә аларның зурларына, «этеп чыгару» аркасында килеп чыга. Фәкыйрь халык, гадәттә, зур шәһәр читләренә килеп урнаша, анда фәкыйрьләр поясы, ярлылар кварталлары барлыкка килә. Мондый урбанизация, аны «ярлы кварталлар урбанизациясе» дип тә әйтәләр, бик киң таралыш алган. (13 нче бирем.)

Менә шуңа күрә дә күп кенә халыкара документларда үсеп килүче илләрдәге урбанизация кризисы турында әйтелгән. Ул, нигездә, һаман да стихияле, тәртипкә салынмаган күренеш булып кала.

Икътисади үсеш алган илләрдә, киресенчә, урбанизация процессын көйләүгә, аның белән идарә итүгә күп көч куела. Бу эшнең еш кына сынап караулар һәм ялгышулар методы белән үткәрелүенә карамастан, аңа дәүләт органнары белән беррәттән архитекторлар, демографлар, географлар, икътисадчылар, социологлар һәм башка бик күп фән вәкилләре катнаша. Бер тикшеренүче сүзләре белән әйткәндә, «барысы да бер елгага ташлана, әмма ярның төрле урыннарыннан».

Зур шәһәр проблемаларын хәл итү юлларының берсе буларак, үтә биек биналар төзелә һәм проектлаштырыла. [19]. Шулай ук җир асты шәһәрләре, йөзмә шәһәрләр, су асты шәһәрләре, конус-шәһәрләр һәм агач-шәһәрләр, башня-шәһәрләр, күпер-шәһәрләр төзү кебек ярымфантастик проектлар да тәкъдим ителә.

**4. Авыл халкы: авыл һәм ферма.** Шәһәрләрнең тиз үсүенә карамастан, дөнья халкының 1/2 е әле һаман да авыл җирендә яши, ә авыл торак пунктларының гомуми саны 15—20 млн исәпләнә.

Авыл халкы урнашуның төп ике төрле формасы бар: төркемләп һәм сибелеп утыру. Аларның нинди формада булуы табигать зонасының үзенчәлекләренә, регионның тарихи һәм икътисади үсешенә бәйле.

Халыкның төркемләп урнашуы (авыл) формасы Россиядә, Европа чит илләрендә, Кытайда, Япониядә һәм үсеп килүче илләрнең күпчелегендә өстенлек итә (19 нчы рәсемне карагыз). Авылларның планы гаять күп төрле булырга мөмкин. Фермалар күбесенчә АКШ, Канада һәм Австралиядә таралган. [20]. Халык урнашуының катнаш формалары да бар, ә күчмә терлекчелек районнарында, гомумән, даими торак пунктлары юк.

**5. Халык һәм мохит: урбанизация йогынтысы.** Инде сезгә мәгълүм булганча, урбанизация мохитне үзгәртүче төп факторларның берсенә әверелде. Гомуми пычрану күләменең 3/4 өлеше нәкъ шуңа бәйләнгән. Әгәр коры җир мәйданының 2—3%ын гына шәһәрләр алып торуын, ә аларда

дөньядагы халыкның яртысы диярлеге яшәвен, җитештерүнең төп өлеше дә шунда урнашуын исәпкә алсак, гаҗәпләнергә урын калмый. Зур шәһәрләр һәм агломерацияләр, табигатьне төп пычратучылар буларак, әйләнә-тирәгә аеруча көчле йогынты ясыйлар. [21]. Монда һаваның пычрануын, мөгаен, беренче урынга куярга кирәктер.

Химик тикшеренү мәгълүматларына караганда, шәһәрләрнең пычрак һәм җылы һавасы йогынтысы 50 км ераклыкка, ягъни 800—1000 км² мәйданга тарала. Шул вакытта аның иң көчле тәэсиренә дучар ителгән мәйдан шәһәрнең үз мәйданыннан 1,5—2 тапкыр артып китә. Лос-Анджелес, Мехико кебек шәһәрләргә «смогополис» кушаматын бирү очраклы хәл түгел. Шәһәр кешеләренә шаяртып, «һәркем бик аз, фәкать иң кирәк чакта гына суласын» дию дә юкка түгелдер.

Соңгы вакытта икътисади үсеш алган илләрдә рәсми органнар һәм җәмәгатьчелек тарафыннан шәһәр мохитен саклау һәм яхшырту буенча төрле чаралар күрелә.

Үсеп килүче илләрдә исә мәсьәлә катлаулырак тора. Алар аз калдыклы технологиягә күчүне генә түгел, хәтта чистарту корылмалары, чүп-чар эшкәртү заводлары төзүне дә тәэмин итә алмыйлар.

**6. Халыклар географиясе белән кызыксынабыз.** *Халыклар географиясе җәмгыятьтә халыкның яңарып тору һәм әйләнә-тирә табигать мохитендә яшәү процессында аның санын, структурасын, урнашуын өйрәнә.* Соңгы вакытта халыклар географиясендә ике төп юнәлеш формалашты.

Беренчесе — *геодемографик юнәлеш.* Ул дөньяда, аерым регионнарда һәм илләрдәге халык санын, төп демографик күрсәткечләрне (үлү, туу, табигый үсеш, уртача гомер озынлыгын) һәм халыкның яңарып торуын, демографик хәлне һәм демографик сәясәтне өйрәнә.

Икенче юнәлеш — *география үзе.* Ул дөньяда, аерым регионнарда һәм илләрдә халыклар урнашуының гомуми географик картинасын һәм бигрәк тә халыкның таралып урнашу һәм торак урыннары географиясен өйрәнә. Бу юнәлештә **геоурбанистика** бигрәк тә зур үсеш алды. Ул түбәндәге мәсьәләләрне өйрәнә: 1) шәһәрләр үсешенең төп тарихи этаплары, 2) хәзерге урбанизация процессының төп үзенчәлекләре, 3) урбанизациянең географик аспектлары һәм дөньяда шәһәрләшкән иң зур зоналарның үсеше, 4) шәһәрләр челтәре һәм системасы, 5) шәһәрләрне проектлаштыру һәм шәһәр төзү нигезләре.

Халыклар географиясе тикшеренүләренең өр-яңа юнәлешләре: рекреацион география, медицина географиясе, мәдәният географиясе, диннәр географиясе, яшәү рәвеше географиясе һ.б. белән тыгыз бәйләнгән.

**Төп нәтиҗә.** *Халык саны арту, аның составы һәм урнашуның хәзерге процесслары күп кенә катлаулы проблемалар китереп чыгара. Аларның кайберләре бөтен дөньяга хас, ә кайберләре төрле тип илләр өчен генә үзенчәлекле. Шулардан*

*иң әһәмиятлеләре — бөтендөнья халкының тиз арта баруы, милләт-ара мөнәсәбәтләр һәм урбанизация.* (14 нче йомгаклау биреме.)

**ӨСТӘМӘ ТЕКСТ (Кызыклы мәгълүматлар)**

[1] Хәзерге вакытта халык исәбе алынмаган илләр юк диярлек. 1975—1984 елларда (бу еллар БМО тарафыннан халык исәбен алу унъеллыгы дип игълан ителә) 191 илдә кимендә берәр тапкыр халык саны исәпкә алына: ул бөтен дөнья халкының 95 % ына кагылды.

[2] 1820 елда халык саны 1 млрд ка житә. 1927 елда Җирдә халык саны 2 млрд кеше, 1960 елда — 3 млрд, 1974 елда — 4 млрд, 1987 елда — 5 млрд, ә 1999 ел ахырында 6 млрд кешегә җитте.

[3] Дөньяда ел саен 130 млн чамасы кеше туа. Бу минут саен — 144, сәгать саен — 8,6 мең, ә тәүлек саен 207 мең яңа кеше дөньяга килә дигән сүз (якынча Якутск яки Псков шәһәрләрендәге халык санына тигез). Моны атна саен Җирдә Харьков яки Новосибирск кебек яңа шәһәр, ай саен Израиль яки Лаос илләре кебек яңа ил барлыкка килүгә тиңләргә мөмкин.

[4] Автомобиль һәлакәтләреннән ел саен 250 мең чамасы кеше һәлак була, шул исәптән БДБ илләре территорияләрендә юл-транспорт һәлакәтләреннән 60 мең кеше дөнья куя (шуларның 30 меңе Россиядә).

[5] XX гасыр башына кадәр Россиядә күп балалы гаиләләр традицияләре яшәп килгән. Атаклы врач А. И. Пирогов — гаиләдә 13 нче бала, бөек химик Д. И. Менделеев 17 нче бала булган! Лев Толстойның 13 баласы булган.

[6] Демографик статистика материалларына караганда, 80 нче елларда дөньяда иң күп балалы ана Чилида яшәгән һәм барлыгы 55 бала тудырган. Ул һәрвакыт икешәр, өчәр игез бала тапкан.

[7] Үлүчеләр саны күрсәткече «рекордлары»да шушы ук илләрдә. Аның иң югары күрсәткече (1000 кешегә 30) 2005 елда Африкадагы Ботсвана дәүләтендә булган. Бер үк вакытта шуны күздә тотарга кирәк: үлүчеләр саны дөньяда уртача 1000 кешегә 8 кеше тәшкил итә.

[8] XXI гасыр башында дөньяда ел саен 50—60 млн аборт ясалды. Дөньяда хурлыклы беренче урынны бу күрсәткеч буенча Россия алып тора. Соңгы унъеллыкта абортлар саны ике тапкыр кимесә дә, әле һаман 1,8 млн аборт ясала. Европа

илләре бала тудыру яшендәге 1000 хатын-кызга туры килгән абортлар саны буенча бик нык аерылалар: Румыния һәм Россиядә 80—90 булса, Бөекбритания һәм Германиядә бу сан — 15.

[9] Хәтта Фарсы култыгы илләре арасында зур булмаган Катар дәүләте бу яктан нык аерылып тора. Ул Гиннесс рекордлар китабына «Хатын-кызларга кытлык» номинациясендә кертелгән. Чыннан да, Катарда ирләр барлык халыкның 67,2% ын тәшкил итәләр.

[10] Дөньяда балалар иң аз ил — Италия, анда балалар халыкның бик аз өлешен (14 %) алып торалар, иң күбе — Нигерда (50 %). Өлкән яшьтәгеләрнең иң күбе Италиядә (24 %), иң азы Йәмән һәм Кувейтта (4 %). Абсолют күрсәткечләрдә исә балаларның иң күбе Кытайда һәм Һиндстанда (350 шәр млн). Күптән түгел планетабызда иң өлкән кеше Франциядә яшәүче Жанна Кальман иде, 1997 елда 122 яшендә ул вафат булды. Үзенең бик озын гомерендә аңа Франциянең 20 президентын күрү насыйп булган.

[11] Һинд-европа телләреннән иң киң таралганы — инглиз теле, бу телдә 520 млн кеше сөйләшә, аннан кала һинди һәм урду телләре (440 млн), испан (400 млн), бенгал (225 млн), португал (210 млн), рус (200 млн), француз (120 млн) һәм немец (100 млн) телләре. Халыкара аралашуда төп тел булып хәзер инглиз теле (борынгы заманда латин теле кебек) хезмәт итә, 1,3 млрд кеше төрле дәрәҗәдә бу телдә сөйләшә ала.

[12] Дөньяда берничә илдә генә (Боливия, Мексика, Перу, Эфиопия, Әфганстан) халыкның күпчелеге диңгез өсте тигезлегеннән 1000 м дан артыграк биеклектә яши. Фәкать Боливия, Перу һәм Кытайда гына (Тибет) диңгез өсте тигезлегеннән 5000 м дан да биектә кешеләр яши.

[13] Япония халкының 9/10 өлеше диңгездән 50 км дан артмаган ераклыкта яши, Бөекбританиядә — 3/4 өлеше. Норвегия, Дания, Ирландия, Португалия, Чили, Яңа Зеландия, Куба һәм Филиппинда барлык халык, ә Австралия һәм Мисырда халыкның 9/10 өлеше диңгездән 200 км дан артмаган ераклыкта яши.

[14] XIX гасырда Ирландия классик эмиграция иле булып санала иде. 40 нчы еллардагы Бөек ачлыктан соң берничә дистә ел узгач, бу илнең халкы эмиграция аркасында икеләтә диярлек кимеде. Барлык халыкка карата эмигрантларның өлеше буенча ул дөньяда беренче урында тора. Инде хәзер Ирландиядә ирландлыларның яртысы гына яши. АКШта 40 млн нан артык ирландлы яши, ә бу Ирландиядә яшәүчеләрдән 12 тапкыр артыграк.

[15] Тарих дәвамында кайбер илләрдә башкала функцияләре ике шәһәр арасында бүленә. Нидерландта Амстердам король резиденциясе булып санала, ә парламент һәм хакимият — Гаагада. КАРда исә Претория — сәяси хакимият үзәге, ә парламент — Кейптаунда. Сукре шәһәре конституция буенча Боливиянең башкаласы санала, ә, асылда, башкала (хакимият резиденциясе белән) Ла-Пас шәһәрендә урнашкан.

[16] Кайбер шәһәрләр башкала функциясен үтәү өчен махсус төзелә. Австралия башкаласы Канберра моның классик үрнәге була ала. Аны XX гасыр башында махсус сайланган урында төзиләр. Шулай итеп, илнең башкаласы булуны дәгъвалаучы Сидней белән Мельбурн арасындагы бәхәс хәл ителә. Канада башкаласы — Оттава, АКШ башкаласы — Вашингтон да шуның ачык мисалы.

[17] «Шәһәр» төшенчәсе барлык илләр өчен дә бертөрле түгел. Мәсәлән, Дания, Швеция, Финляндиядә халкы 200 кешедән арткан торак пунктлар шәһәр булып санала; Канада һәм Австралиядә — 1 меңнән, ГФР, Франция һәм Кубада — 2 меңнән, АКШ һәм Мексикада — 2,5 меңнән, Австрия, Һиндстан, Иран һәм Мадагаскарда — 5 меңнән, Швейцария, Малайзиядә — 10 меңнән, Россиядә — 12 меңнән, Нигериядә — 20 меңнән, Япониядә — 50 меңнән артса, шәһәр исәбенә керә.

[18] 2005 елда ук инде Кытайда шәһәр халкының саны — 515 млн, Һиндстанда 310 млн кешегә җитеп, АКШтагы күрсәткечне (240 млн) күпкә узып китте. Индонезиядә шәһәр халкының саны 103 млн, ягъни ГФР дагы кадәр, ә Бөекбритания, Франция яки Италиянекеннән күпкә артыграк.

[19] Нью-Йорктагы Эмпайр Стейт Билдинг бинасы (102 катлы, 381 м биеклектә) 1931 елдан бирле иң биек бина булып саналып килде. 1972 елда шул ук Нью-Йоркта төзелгән Халыкара сәүдә үзәге (110 катлы, 417 м)[1] күпкә биек, беренчелек аңа бирелде. 1974 елда Чикагода салынган Сиэрс Тауэр бинасы (110 катлы, 442 м) 1998 елга кадәр иң биек бина исемен йөртте, Малайзия башкаласы Куала-Лумпурда «Петронас» нефть компаниясе 450 м биеклектәге (антеннасы белән) 88 әр катлы игезәк ике гигант бина торгызды. Соңрак үтә биек биналар Шанхайда (492 м), Сянганда (415 м), Тайваньнең Тайбэенда (448 м) төзелде, ә 2005 елда БГӘ дә 160 катлы (810 м) бина төзелә башлады.

[1] Нью-Йорктагы Халыкара сәүдә үзәгенең ике бинасы да 2001 елның 11 сентябрендә террористик акция вакытында җимерелде.

Мәскәүнең Москва-Сити эшлекле районында 600 м биеклектәге «Россия» манарасы 2011 елга төзелеп бетергә тиеш.

[20] Австралия фермаларында яшәүчеләр үзара бик аз аралашалар. Күршеләре һәм, гомумән, тышкы дөнья белән күбесенчә телефон һәм радио аша элемтәгә керәләр. Врач радио аша киңәшләр бирә, бик кирәк чакта гына аны авыру янына чакырталар. Фермер балаларын 15 яшькә кадәр шулай ук радио аша укыталар. Һәр укучының үзенең махсус радиостанциясе бар, кирәк чакта ул киңәш сорап укытучыга яки башка укучыларга мөрәҗәгать итә ала. Атнага бер тапкыр үзенең язма эшләрен «радиомәктәп» укытучысына тикшерергә җибәрә.

[21] Дөньядагы барлык шәһәрләр ел саен әйләнә-тирәгә 3 млрд тоннага кадәр каты промышленность һәм көнкүреш калдыклары, 500 км$^3$ промышленность һәм көнкүреш сулары һәм 1 млрд тонна чамасы төрле аэрозольләр чыгара. Чагыштыру өчен: Җирдә 578 актив вулкан барлыгы билгеле, алар атканда 2,5 млрд тонна лава, көл, су парлары һәм газлар чыга.

**Китап киштәсе**


1. Максаковский В. П. Географическая картина мира.— М.: Дрофа, 2008.—Ч. 1.— Тема 3.
2. Максаковский В. П. Новое в мире: цифры и факты: Дополнительные главы к учебнику 10 кл.— М.: Дрофа, 2006.— Раздел 3.
3. Копылов В. А. География населения: Учеб. пособие.— М.: Маркетинг, 1998.
4. Народы и религии мира: Энциклопедия.— М.: БРЭ, 1998.
5. Атлас языков мира.— М.: Лик Пресс, 2001.
6. Религии мира: Пособие для учащихся 10—11 кл.— М.: Дрофа, 1997.
7. Религии мира: Энциклопедия для детей. Т. 6.— М.: Аванта +, 1998.
8. Все столицы мира: Популярный справочник/ Сост. Л. М. Еремина.— М.: Дрофа, 2001.


## БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘР ҮЗЛӘШТЕРҮ ӨЧЕН ТУПЛАНМА

**1 нче бирем.** 10 нчы рәсемне анализлагыз. Безнең эра башыннан 2005 елга кадәр Җир шарында халык санының ничә тапкыр артканын исәпләп чыгарыгыз. XIX һәм XX гасырларда ул ничә миллионга арткан? Дәреслектәге мәгълүматларны исбатлау һәм чагыштырып карау өчен кирәкле исәпләүләрне башкарыгыз. «Кушымта»дагы 11 нче таблицадан файдаланыгыз.

**2 нче бирем.** 13 нче рәсемнән файдаланып, дәреслектә бирелгән мәгълүматларны ачыклагыз. Халык яңарып торуның беренче һәм икенче типлары таралышын шул рәсем буенча сыйфатлагыз. Аерым регионнарда халык яңарып торуның уртача санлы күрсәткечләренә («формулаларга») анализ ясагыз, үзара чагыштырыгыз, аерманы аңлатыгыз. «Кушымта»дагы 12 нче һәм 13 нче таблицаларны да файдаланыгыз.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Атластан халыкның туу, үлү һәм табигый артуы картасын табып ачыклагыз: аерым бер ил өчен нинди күрсәткечләрне югары, уртача һәм түбән дип санарга мөмкин? Мисаллар белән күрсәтегез.

**3 нче иҗади бирем.** 2 нче таблица мәгълүматларыннан файдаланып, Җир шарының аерым зур регионнарындагы халык саны динамикасын чагыштырыгыз. Җирнең барлык халкында аларның өлеше ничек үзгәрүен исәпләгез; бу үзгәрешләрне аңлатыгыз. Таблицадан мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат алыгыз. Дәфтәрегездә диаграмма төзегез, кайбер күрсәткечләрне контурлы картага төшерегез. Алар сезгә нинди нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә? Фикер йөртеп карагыз.

**4 нче иҗади бирем.** Демографик күчеш схемасын конкретлаштыру өчен, дәреслек текстын һәм башка мәгълүмат чыганакларын файдаланыгыз. XXI гасыр башында бу күчешнең төрле этапларындагы регионнарга һәм илләргә мисаллар китерегез.

**5 нче бирем.** Атластан халыкның җенси составы картасын табып анализлагыз. Аны дәреслек текстындагы мәгълүматларны ачыклау һәм сурәтләү өчен файдаланыгыз.

**6 нчы бирем.** 13 нче һәм 14 нче рәсемнәрне чагыштырыгыз. Алар ярдәмендә халыкның яңарып тору типлары аның яшь составына йогынты ясавы турында дәреслектә әйтелгәннәрне исбатлагыз. Бу үзара йогынтыны ничек аңлатырга?

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** 14 нче рәсемне анализлагыз. Дөньяда халык яңарып торуның беренче һәм икенче тибына кергән илләрнең яшь-җенес пирамидалары арасындагы аерманы аңлатыгыз.

**7 нче бирем.** Халыкның милли составы картасыннан төп телләр семьялыкларын һәм аларның Җир шарында таралу ареалларын өйрәнегез. Европа һәм Азия чит илләрендә, Африкада, Төньяк һәм Көньяк Америкада, Австралия һәм Океаниядә нинди тел семьялыгындагы халыклар күбрәк булуын билгеләгез. Нәтиҗәне дәфтәрегезгә языгыз.

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** Дөньяның төрле кисәкләрендә яшәүчеләр еш кына бер үк телдә сөйләшә. Тарих һәм география дәресләрендә өйрәнгән материалларны исегезгә төшерегез һәм аңлатыгыз: 1. Ни өчен инглиз телендә инглизләр генә түгел, АКШ, Канада, Австралия,

Яңа Зеландия, Көньяк Африкада яшәүчеләр дә сөйләшә? Нилектән инглиз теле Һиндстан, Пакистан, Бангладеш һәм башка күп кенә илләрдә таралган? 2. Ни өчен испан теле XVI гасырга кадәр Испаниядә генә өстенлек иткән, ә хәзер Латин Америкасының күпчелек халыклары өчен ул дәүләт теле һәм туган тел булып санала? 3. Ни өчен VII гасырга кадәр Гарәбстан ярымутравы халкы гына сөйләшкән гарәп теле соңыннан бөтен Төньяк Африкага таралган?

**8 нче бирем.** Атласта бирелгән диннәр картасы буенча дөньякүләм таралган диннәрнең таралу ареалларын сыйфатлагыз. Җирнең аерым эре регионнарында нинди дин өстенлек итүен билгеләгез.

**9 нчы бирем.** Атласта халык тыгызлыгы картасын анализлагыз. Халык бик тыгыз урнашкан регионнарны билгеләгез һәм аларның барлыкка килү сәбәпләрен аңлатырга тырышып карагыз. Халык тыгызлыгы картасына дөньяның физик картасын куеп, халыкларның урнашуына нинди экстремаль шартлар комачаулавын ачыклагыз. Бер үк ил территориясендә халыкларның төрлечә урнашуының сәбәпләрен аңлатыгыз. Мондый илләргә мисаллар китерегез.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Башкарылган эш нәтиҗәләреннән файдаланып, халык тыгызлыгы күрсәткече буенча гына теге яисә бу илнең социаль-икътисади үсеш дәрәҗәсе турында фикер йөртеп булмауны конкрет мисаллар белән аңлатыгыз. Нәтиҗәләрегезне иптәшләрегез белән тикшерегез.

**10 нчы бирем.** Дәреслекнең төп текстыннан файдаланып, дәфтәрегездә хезмәт иммиграциясенең төп регионнарын контурлы картага төшерегез. Бу районнарга эшче кулларның кайдан килүен уклар белән күрсәтегез.

**11 нче бирем.** 17 нче рәсемнән һәм «Кушымта»дагы 16 нчы таблицадан файдаланып, дөньяның иң зур шәһәрләренең урнашуын өйрәнегез. Аларны регионнарның һәм илләрнең зурлыкларына карап урнаштырыгыз һәм үзгәрешләрнең уртак тенденциясен характерлагыз.

**12 нче бирем.** 18 нче рәсемне һәм атластагы дөнья урбанизациясе картасын дәреслек текстындагы мәгълүматларны ачыклау һәм сурәтләү өчен файдаланыгыз. Урбанизация дәрәҗәсенең нинди күрсәткечләрен билгеле бер ил өчен бик югары, югары, уртача, түбән һәм бик түбән дип санарга мөмкин? Аларга мисаллар китерегез. Урбанизация дәрәҗәсе югары, уртача һәм түбән булган илләрнең ничек урнашуын аңлатырга тырышыгыз.

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** «Миллионер шәһәрләр» темасына кроссворд төзегез.

**13 нче бирем.** 3 нче таблицадагы мәгълүматларны анализлагыз. 1950—2005 елларда дөньяның аерым регионнарында шәһәр халкы санының ничә тапкыр артуын исәпләгез. Аерым регионнардагы шәһәр халкының саны бөтен дөньядагы шәһәр халкы санының күпме өлешен алып торуын исәпләп табыгыз. Дәфтәрегездә таблица төзегез. Аның мәгълүматлары дәреслектәге нинди фикерләрне раслый? «Кушымта»дагы 17 нче таблицаны да файдаланыгыз.

**14 нче йомгаклау биреме.** 1. (Дәфтәрдә эшләү.) Алган белемнәрегезгә таянып, түбәндәге формада «урбанизация» төшенчәсенең төп билгеләре таблицасын төзегез.

| Билгеләр | Алар чагылышына конкрет мисаллар |
|---|---|

2. (Дәфтәрдә эшләү.) Алган белемнәрегез нигезендә түбәндәге күренешләрнең сәбәпләрен әйтегез: а) үсеп килүче илләрдә соңгы берничә ун елда үлүчеләр саны кимеде, ә туучылар саны элеккечә югары калды; б) Кытай белән Һиндстан дәүләтләре демография сәясәтен аеруча актив үткәрәләр; в) дөньяда халык тигез урнашмаган; г) шәһәр халкы күбрәк зур шәһәрләрдә тупланган.

3. 3 нче тема материалын башкача урнаштырып, бүтән эзлеклелектә сөйләп карагыз, үзегезнең тәкъдимнәрегезне яклап дәлилләр китерегез.

4. (Дәфтәрдә эшләү.) 3 нче теманы өйрәнгәндә очраган яңа терминнар сүзлеге төзегез.

5. Текстта һәм атласта китерелгән, дөнья халкын характерлаган карталарны өйрәнегез. Аларның нинди картографик ысул белән төзелүен ачыклагыз. Сезнеңчә ничек, аларны анализлау нәтиҗәсендә нинди мәгълүмат алырга була?

6. «Демографик шартлау һәм аның нәтиҗәләре» яисә «Хәзерге дөньяда урбанизация» дигән темага телдән кыскача чыгыш әзерләгез.

7. Шушы тема буенча тәкъдим ителгән китапларның берсенә (яки аның берәр бүлегенә) аннотация төзегез.

## ҮЗЕГЕЗНЕҢ ҺӘМ БЕР-БЕРЕГЕЗНЕҢ БЕЛЕМНӘРЕН ТИКШЕРҮ ТУПЛАНМАСЫ

**Ничек аңлатырсыз:**

1. Халык яңарып торуның беренче һәм икенче типларының төп билгеләре һәм күрсәткечләре нинди?

2. Дөнья халкының җенси составында географик яктан нинди аермалар бар?

3. Дөнья халкының урнашуына һәм тыгызлыгына нинди сәбәпләр йогынты ясый?

4. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң дөнья халкының тышкы миграциясе характерында һәм географиясендә нинди үзгәрешләр булды?

5. Бөтендөнья урбанизациясе процессына нинди төп гомуми сыйфатлар хас?

**Ничек уйлыйсыз:**

1. Күренекле рус географы А. И. Воейков: «Халыкның таралып урнашуында кешене чолгап алган мохиттән бигрәк кеше үзе хәлиткеч фактор булып тора»,— дип язган. Ул нәрсәне күздә тоткан?

2. Җирдәге халыкның уртача тыгызлыгы күрсәткеченең ни өчен даими үсеш тенденциясе бар?

3. Ни өчен БМО отчетларының берсе «Безнең демографик яктан бүленгән дөнья» дип исемләнгән?

4. XXI гасыр Җирдәге халыкның картаю гасыры булачак дип уйлаучы демографлар хаклымы?

**Беләсезме:**

1. Түбәндә бирелгән «формулалар»ның кайсысы халык яңарып торуның икенче тип илләренә карый:

14 – 8 = 6, 24 – 8 = 16?

2. Түбәндәге илләр арасында нинди уртаклык бар: а) Кения, Кувейт, Индонезия, Вьетнам, Алжир, Никарагуа; б) Франция, Канада, Болгария, Австралия, Куба, Япония?

3. Түбәндә саналган халыкларның кайсылары һинд-европа телләре семьялыгына керә: кытайлар, һиндләр, руслар, японнар, бразилиялеләр, АКШтагы америкалылар, инглизләр?

4. Карта-схемада билгеләнгән районда яши торган халык нинди телдә сөйләшә: инглиз, француз, немец, испан, португал, гарәп теле?



5. Түбәндә саналган кайсы илләрдә халыкның күбрәк өлеше католик динендә: 1) Украина, 2) Нидерланд, 3) Италия, 4) Греция, 5) Филиппин, 6) Индонезия, 7) Судан, 8) Аргентина?

**Булдыра аласызмы:**

1. Текстта һәм тексттагы карталарда телгә алынган түбәндәге илләрне дөньяның контурлы картасында хәтердән билгеләгез: Чехия, Словакия, ГФР, Бельгия, Индонезия, Пакистан, Шри-Ланка, Эфиопия, Кения һәм Куба.

2. «Халыкның яңарып торуы» һәм «урбанизация» төшенчәләренә билгеләмә бирегез.

3. Дөньяның контурлы картасында хәтердән дөньядагы иң зур ун шәһәрне билгеләгез.

4. Түбәндәге илләрне урбанизация дәрәҗәләре кими бару тәртибендә урнаштырыгыз: Австралия, Кытай, АКШ, Бөекбритания, Эфиопия, Аргентина, ГФР.

5. Түбәндәге раслауларның дөреслеген тикшерегез, кирәк урында дөресләп җавап бирегез: а) 1000 кеше исәбеннән туу күрсәткече буенча Кытай — «дөнья рекордсмены»; б) үсеп килүче илләрнең күпчелеге туучылар санын һәм халыкның табигый артуын киметүгә юнәлтелгән демографик сәясәт алып бара; в) урбанизациянең югары темплары — алга киткән илләргә, ә иң түбән темплары үсеп килүче илләргә хас.

6. Түбәндәге җөмләләрдә төшеп калган сүзләрне тутырып языгыз (дәфтәрдә эшләгез):

а) Халыкның туууы, үлүе һәм табигый артуы процессларына кешеләрнең ________ яшәү шартлары хәлиткеч йогынты ясый.

б) Милли (этник) чикләр сәяси чикләр белән тәңгәл килгән очракларда ________ дәүләтләр барлыкка килә.

в) Урбанизациянең хәзерге этабына «ноктадай» шәһәрдән ________ күчү хас.

## 3 НЧЕ ТЕМАГА МЕТОДИК АЧКЫЧЛАР

### Боларны исегезгә төшерегез

1. Табигать шартларына һәм килеп утыру тарихына бәйле рәвештә, халыкның материклар территорияләрендә урнашуы. (География, 7 нче сыйныф.) 2. Халыкның раса составы һәм зур расаларның таралуы. (География, 6 нчы сыйныф.) 3. Россия халкының милли составы. (География, 9 нчы сыйныф.) 4. Россия халкының урнашуы, торак пунктларның төрләре. (География, 9 нчы сыйныф.) 5. Төшенчәләр һәм терминнар: халыкның тыгызлыгы, раса, халык, хезмәт ресурслары, халыкның миграциясе, шәһәр халкы, авыл халкы, шәһәр агломерациясе. (География, 6, 7, 8 һәм 9 нчы сыйныфлар.)

## Боларны үзләштерегез

**3 нче теманың төп идеяләре:**

1. Халык җәмгыятьнең материаль яшәешенең нигезен тәшкил итә, ул — планетабызның актив элементы.

2. Барлык раса, милләт һәм халыклар материаль җитештерүдә һәм рухи тормышта катнашуга бертигез сәләтле.

**3 нче темадагы төп фәнни белемнәр:**

1. Халыкның яңарып торуы төшенчәсе. Дөнья халкының табигый хәрәкәтенең асылы һәм географик үзенчәлекләре. 2. Хезмәт ресурсларының, дөнья халкының җенес, яшь составының асылы һәм географик үзенчәлекләре. 3. Дөнья халкын телләр семьялыгына карап классификацияләү һәм алар таралуның төп билгеләре. 4. Коры җир территориясендә халыклар урнашуының төп билгеләре һәм аның тигезсезлегенең төп сәбәпләре. 5. Халык миграциясенең төрләре һәм тышкы миграциянең төп районнары. 6. Урбанизация төшенчәсе. Бөтен дөньяда һәм аның аерым регионнарында шәһәрләшү дәрәҗәсе һәм темплары. 7. Халыклар географиясен икътисади һәм социаль географиянең тармагы итеп күзаллау. 8. Теманың төп төшенчәләре: 1) халыкның яңарып торуы, 2) халык яңарып торуының беренче тибы, 3) халык яңарып торуының икенче тибы, 4) демографик кризис (депопуляция), 5) демографик шартлау, 6) демографик сәясәт, 7) демографик күчеш, 8) халыкның сыйфаты, 9) икътисади актив халык, 10) этнос, 11) бер милләтле дәүләт, 12) күп милләтле дәүләт, 13) халыкның хезмәткә бәйле миграциясе, 14) «миләр китү», 15) урбанизация, 16) «шәһәрләр шартлавы», 17) геоурбанистика.

## Сез нәрсәләр эшли белергә тиеш

1. Дөньяга, аерым регионнарга һәм илләргә характеристика биргәндә халыкның яңарып торуы, составы, урбанизация дәрәҗәсе һәм темплары күрсәткечләрен кулланырга. 2. Дәреслек текстындагы аерым мәгълүматларны анализлау, ачыклау һәм исбатлау өчен карталар, графиклар һәм таблицалардан файдаланырга, кирәкле исәпләүләр һәм чагыштырулар ясарга. 3. Яшь-җенес пирамидасын укып анализларга. 4. Дәреслектәге текст һәм карталар буенча таблицалар төзергә. 5. Текст буенча мөстәкыйль рәвештә биремнәр төзергә. 6. Өйрәнелгән тема буенча телдән кыскача чыгыш әзерләргә. 7. Укылган текстка аннотация төзергә.

# 4 нче тема. ФӘННИ-ТЕХНИК РЕВОЛЮЦИЯ һӘМ БӨТЕНДӨНЬЯ ХУҖАЛЫГЫ

Сез фәнни-техник революция (ФТР) турында һәм аның хәзерге дөньяга гаять зур йогынты ясавын, әлбәттә, беләсез инде. ФТРның үзенчәлекләре, әһәмияте хакында тулырак мәгълүматлар белән шушы теманы өйрәнгәндә танышырсыз. Бөтендөнья хуҗалыгы төшенчәсе дә сезнең өчен яңа булыр.

Бөтендөнья хуҗалыгын һәм ФТРны күп кенә табигать фәннәре, иҗтимагый һәм төгәл фәннәр өйрәнә. Ләкин аларга хас географик аспектларны икътисади һәм социаль география фәненең бер тармагы буларак бөтендөнья хуҗалыгы географиясе өйрәнә.

## 1. ФӘННИ-ТЕХНИК РЕВОЛЮЦИЯГӘ ХАРАКТЕРИСТИКА БИРӘБЕЗ

**1. Фәнни-техник революция төшенчәсе.** Кешелек цивилизациясенең барлык үсеше *фәнни-техник прогресс* белән тыгыз бәйләнгән. Ләкин бу прогресс фонында җитештерүче көчләр бик тиз һәм тирән үзгәрешләр кичергән чорлар була. XVIII—XIX гасырларда күп илләрдә промышленностьны шундый тамырдан үзгәртеп кору чоры булды. Ул кул хезмәтеннән куәтле машиналар ярдәмендә җитештерүгә күчү чоры булып тарихка кереп калды. Бигрәк тә XX гасыр урталарында башланган хәзерге ФТР шундый чорлардан санала.

**Фәнни-техник революция — фәнне турыдан-туры җәмгыятьнең җитештерүче көчләренә әвереләдерү нигезендә кешелекнең җитештерүче көчләрен сыйфат ягыннан тамырдан үзгәртү ул.**

Кешенең материаль һәм рухи мөмкинлекләренең нык үсешенә башлангыч бирү өчен, ФТР акрынлап өлгерде. Хәзер без аның тагын да тирәнәю чорында яшибез.

**2. ФТРга хас сыйфатлар һәм состав өлешләре: төп дүрт сыйфат.** Хәзерге ФТРның дүрт төп үзенчәлеге бар.

Беренчедән, ул *универсаль, бөтен өлкәләрне үз эченә ала.* Барлык тармакларны һәм сфераларны, хезмәт рәвешен, кешеләрнең культурасын, көнкүрешен, психологиясен үзгәртә. Промышленностьны үзгәртеп коруның символы булып элек пар машинасы исәпләнсә, хәзер исә ЭВМ да, космик корабль дә, атом электростанциясе дә, реактив самолет, телевизор [1] һәм Интернет ФТР символы булып санала ала. Хәзерге ФТРның барлык өлкәләргә дә кагылуын географик яктан да карарга була, чөнки ул теге яисә бу дәрәҗәдә дөньяның барлык илләренә, Җирнең барлык географик сурүләренә һәм шулай ук космик киңлекләргә дә үтеп керде.

# 4 НЧЕ ТЕМАНЫҢ ПЛАН-СХЕМАСЫ



Икенчедән, *фәнни-техник үзгәрешләрнең гадәттән тыш тизләшүе.* Бу тизләнеш фәнни ачыш белән аны производствога кертү арасындагы вакытның бик нык кыскаруында, продукциянең элеккегә караганда тизрәк мораль искерүендә һәм, димәк, продукциянең даими яңарып торуында чагыла.

Өченчедән, ФТР *хезмәт ресурсларының квалификация дәрәҗәсенә* таләпләрне арттырды, ә бу сезнең һәрберегезгә турыдан-туры кагыла. Ул шулай ук кешеләр эшчәнлегенең барлык сфераларында да акыл хезмәтенең күбрәк урын алуына, ягъни хезмәтнең интеллектуальләшүенә китерде.

Дүртенчедән, ФТРның аеруча мөһим үзенчәлеге шул, ул Икенче бөтендөнья сугышы елларында ук *хәрби-техник революция* буларак дөньяга килде: аның башлануын иң элек 1945 елда Хиросимада атом бомбасы шартлавы хәбәр итте. Аннан соңгы «салкын сугыш» елларында ФТР фәнни-техник фикерләүнең өр-яңа казанышларын күбрәк сугыш максатларында куллануга юнәлтте. Бу юнәлеш безнең көннәрдә дә саклана. Моны Россия армиясе мисалында күреп була.

Хәзерге ФТР — үзара тыгыз бәйләнгән дүрт өлештән: 1) фән, 2) техника һәм технология, 3) җитештерү, 4) идарә итүдән торган катлаулы бердәм система ул.

**3. Фән: фәнсыешлыкның үсүе.** Фәнни-техник революция чорында фән белемнәрнең бик катлаулы комплексына әверелде. Шуның белән бергә, ул кеше эшчәнлегенең гаять зур өлкәсен тәшкил итә; бөтен дөньяда фәнни хезмәткәрләр саны 10 млн чамасы, ягъни төрле дәверләрдә Җир йөзендә яшәгән фәнни хезмәткәрләрнең 9/10 өлеше — безнең замандашлар. Фәннең җитештерү белән элемтәсе бигрәк тә үсте, ә җитештерү торган саен күбрәк ***фәнсыешлырак***[1] була бара. Ләкин икътисади үсеш алган һәм үсеп килүче илләр арасында аерма гаять зур.

**Мисал.** Галимнәр һәм инженерларның абсолют саны буенча дөньяда беренче урынны АКШ алып тора, аннан соң Япония һәм Көнбатыш Европа илләре. Бу илләрдә фәнгә җибәрелгән чыгымнар ТЭПның (тулай эчке продукт) 2—3 % ын тәшкил итә. 90 нчы елларда фәнни хезмәткәрләр санының шактый кимүенә карамастан, лидерлар төркеменә Россия дә керә. XXI гасыр башында бу төркемгә Кытай да керде. Үсеп килүче илләрдә исә фәнгә тотылган чыгымнар 0,5 % тан артмый.

**4. Техника һәм технология: үсешнең ике юлы.** Фәнни белемнәр һәм ачышлар техника һәм технологиядә чагылыш таба. Яңа техника һәм технологияне файдалануның төп максаты — җитештерүнең нәтиҗәлелеген һәм хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү. Соңгы елларда, техника һәм технологиянең *хезмәтне саклау* функциясе белән беррәттән, *ресурсларны саклап*

---

[1] Фәнсыешлык *(наукоемкость)* — теге яисә бу продукцияне җитештерүдә тотылган чыгымнарның фәнни тикшеренүләргә киткән өлеше.

*тоту, табигатьне саклау һәм информацион функцияләре* торган саен зуррак роль уйный башлады.

**1 нче мисал.** Бөекбритания һәм Италиядә корычның 2/3 өлешен металл ватыкларыннан, Бөекбритания һәм ГФРда кәгазьнең 2/3 өлешен макулатурадан, АКШ һәм Японияда алюминийның күп өлешен икенчел алюминий буларак алалар.

**2 нче мисал.** Табигатьне саклау техникасын житештерү һәм табигатьне саклау технологиясен гамәлгә кертү буенча ГФР һәм АКШ бигрәк тә аерылып торалар, ә мондый техниканы экспортлауда ГФР беренче урында.

ФТР шартларында техника һәм технологиянең үсеше *ике төрле юл белән* бара.

Эволюция юлы моңа кадәр билгеле булган техника һәм технологияне тагын да камилләштерүдән, машина һәм җиһазларның җитештерүчәнлеген, транспорт чараларының йөк күтәрүчәнлеген арттырудан гыйбарәт.

**Мисал.** 50 нче еллар башында төзелгән иң зур диңгез танкеры 50 мең т нефть сыйдырган. 60 нчы елларда йөк күтәрүчәнлеге — 100, 200, 300 мең т, ә инде 70 нче елларда 400, 500, 550 мең т күтәрә ала торган супертанкерлар барлыкка килә. Аларның иң зурлары Японияда һәм Франциядә җитештерелә [2] (20 нче рәсемне карагыз).

Ләкин мондый гигантлар белән мавыгу икътисади файдалы булуына карамастан, үзен һәрвакыт аклап бетерми. Икътисадның килачәген, могаен, эре, уртача һәм кечкенә предприятиеләрнең тыгыз хезмәттәшлегендә күрергә кирәктер.

Революция юлы *өр-яңа техника һәм технологиягә күчүдән* гыйбарәт. Ул электрон техникасы җитештерүдә, күрәсең, күбрәк чагылыш таба. Дөрестән дә, элек «текстиль гасыры», «корыч гасыры», «автомобиль гасыры» дип сөйләнгән булса, хәзер «микроэлектроника гасыры» турында күбрәк сүз бара. *ФТРның 70 нче елларда башланган «икенче дулкынын» еш кына микроэлектроника революциясе дип атап йөртүләре очраклы түгел.* Аны шулай ук *микропроцессорлар революциясе* дип тә атыйлар, чөнки микропроцессорлар уйлап табуны кешелек тарихында тәгәрмәч, басма станок, пар машинасы һәм электр уйлап табу белән генә чагыштырырга мөмкиндер. Хәзерге җәмгыятьнең яшәешен җитештерүдә, хәрби техникада һәм көнкүрештә кулланыла торган электроникадан башка күз алдына китерергә мөмкин түгел, ә аның казанышлары безне гаҗәпкә калдыра. [3].

Яңа технологияләргә юл ачылуның әһәмияте гаять зур.

Машиналар төзүдә ул металл эшкәртүнең механик ысулыннан механик булмаган ысулларга — электрохимик, плазма, лазер, радиация, ультратавыш һәм вакуум ярдәмендә эшкәртү ысулларына күчү дигән сүз. Металлургиядә иң алдынгы ысуллар белән чуен, корыч кою һәм прокат җитештерү, авыл хуҗалыгында җирне нуленче эшкәртү дип йөртелә торган сабансыз игенчелек, коммуникация сферасында — радиореле һәм пыяла сүсле элемтә, телекс,

телефакс, электрон почта, пейджинглы һәм кәрәзле элемтә.

**1 нче мисал.** XXI гасыр башында Көнбатышның алдынгы илләрендә барлык корыч кислородлы конвертерларда һәм электр мичләрендә җитештерелә; корыч әзерләнмәләрнең 95—100 % ы өзлексез агызу ысулы белән табыла.

**2 нче мисал.** Цифрча технологияләргә күчү фото- һәм киноаппаратлар, телевизорлар, барлык видеотехниканы җитештерүдә чын революция ясады.

*Революция юлы — ул ФТР чорында техника һәм технология үсешенең төп юлы.*

**5. Җитештерү: үсешнең төп алты юнәлеше.** ФТР чорында җитештерү төп алты юнәлештә үсеш ала. Беренче юнәлеш — электронлаштыру, ягъни кеше эшчәнлегенең барлык өлкәләрен электрон-хисаплау техникасы белән җитәрлек күләмдә тәэмин итү. Электронлаштыру (компьютерлаштыру) нәтиҗәсендә күпчелек җитештерү процессларының технологиясе тамырдан үзгәрә. Ул мәгариф, сәламәтлек саклау өлкәсенә, кешеләрнең көнкүрешенә [4] тирәнрәк үтеп керә, шулай ук стационар чараларны гына түгел, күчмәләрен дә үз эченә ала.

Электрон промышленносте — тулы мәгънәсендә ФТР баласы. ФТР башында ул электротехника составында гына була, ә 80 нче еллар уртасында аның продукциясе бәясе ягыннан нефть промышленностена тиңләшә, 90 нчы еллар башында автомобиль промышленностен, ә 90 нчы еллар ахырында исә химия промышленностен узып китә. Хәзерге вакытта бу төр продукциянең бәясе 2 трлн доллардан артып китә.

ФТРның юлын электрон промышленносте билгели. Бу тармак АКШта [5], Япония, ГФР һәм кайбер яңа индустриаль илләрдә аеруча үсеш алды.

Икенче юнәлеш — комплекслы автоматлаштыру. Ул, ЭВМ барлыкка килүгә бәйле рәвештә, 50 нче елларда башланды. Комплекслы автоматлаштыруның сыйфат ягыннан яңа этабы 70 нче елларда микроЭВМ һәм микропроцессорлар барлыкка килү белән бәйле. Хәзер инде алар җитештерүче һәм җитештерүче булмаган сфераларның күп кенә тармакларында кулланыла. 20 нче елларда ук инде чех язучысы К. Чапек тарафыннан робот дип аталган төрле электрон-механик манипуляторлар куллануда өр-яңа эра башлану микропроцессорларга бәйләнгән. Үз чиратында роботлар техникасы барлыкка килү тиз үзгәртелүчән җитештерү системалары, автомат-заводлар төзүне китереп чыгарды.

Роботлар төзү хәзерге көндә шулай ук күп фәнсыешлы бик мөһим җитештерү тармакларының берсенә әверелде. XXI гасыр башында промышленность роботларының дөньядагы гомуми саны 1 млн га җитте. Мондый роботларның иң зур паркы — Япониядә, АКШ, ГФР, Италиядә һәм Корея Республикасында.

**Мисал.** Япония промышленность роботларының саны (дөнья паркының 40%) белән генә түгел, бәлки җитештерүнең алар белән җиһазланышы ягыннан да дөньядагы барлык илләрдән алда.

Эшкәртү промышленностенда һәр 10 мең эшчегә 270 робот туры килә, АКШта исә — 50.

Роботлар, промышленность белән беррәттән, кеше эшчәнлегенең башка сфераларында да шактый киң кулланыла. [6].

Өченче юнәлеш — энергетика хуҗалыгын үзгәртеп кору. Ул энергияне саклау, ягулык-энергетика балансы структурасын камилләштерү, яңа энергия чыганакларын киңрәк файдалануга нигезләнгән. Атом энергетикасының үсеше аеруча күп проблемалар тудыра. XXI гасыр башында дөньяда 440 тан артыграк атом-төш энергоблогы эшли иде. Бу тармак АКШ, Франция, Япония, ГФР һәм Россиядә бигрәк тә зур үсеш алды. 1986 елда Чернобыль АЭСында булган авариядән соң күп илләр АЭС төзүгә мораторий игълан иттеләр, ләкин XXI гасыр башында аларны төзү тизләнеш алды, аеруча Кытай һәм Һиндстанда.

Дүртенче юнәлеш — яңа материаллар җитештерү. Хәзерге җитештерү иске конструкцион материалларга — кара һәм төсле металларга, соңгы вакытта күбрәк кулланыла башлаган синтетик полимерларга шактый югары таләпләр куя башлады. Ләкин шул ук вакытта җитештерүгә төрле композицион, ярымүткәргеч, керамик материаллар һәм оптик сүсләр, шулай ук «XX гасыр металлары» — бериллий, литий, титан (аэрокосмик промышленностьта иң кирәкле металл) кебек бик күп шундый металлар кулланышка керде.

Бишенче юнәлеш — биотехнологиянең тизләтелгән үсеше. Бу юнәлеш 70 нче елларда барлыкка килде, һәм ул иң перспективалылардан санала. ФТРның аеруча күп фәнсыешлы төрле-яңа тармакларыннан саналган биотехнология һәм биоиндустрия бигрәк тә АКШта, шулай ук Япония, ГФР һәм Франциядә уңышлы үсеп килә.

Биотехнология куллануның төп өлкәләре: авыл хуҗалыгының продуктлылыгын күтәрү, туклану продуктлары исемлеген арттыру, энергетик ресурсларны күбәйтү, мохитне биотехнологик ысуллар белән саклау.

Алтынчы юнәлеш — космослаштыру. Космонавтиканың үсеше фәнсыешлы тагын бер төр-яңа тармак — аэрокосмос промышленностен барлыкка китерде. Шушы юнәлешкә бәйле рәвештә бик күп яңа машиналар, приборлар, эретмәләр барлыкка килде һәм аларның кайберләре космоска бәйләнеше булмаган тармакларда киң кулланыла башлады. Космонавтика тормышка космик технологияләр һәм Җирне космостан өйрәнүне кертте. Космик тикшеренүләрнең нәтиҗәләре фундаменталь фәннәр үсешенә бик зур йогынты ясый.

Шушы гаять әһәмиятле яңа юнәлешләр белән беррәттән, ФТР чорында җитештерүне камилләштерү, аны *механикалаштыру, электрлаштыру, химияләштерү* дә зур роль уйный. (1 нче бирем.)

**6. Идарә итү: югары информацион культурага юл.** ФТРның хәзерге этабы идарә итүгә яңа таләпләр куя. Хәзер инде искечә, «чама белән» идарә итеп булмый. Информатика курсыннан белгәне-

гезчә, практик ихтыяҗларга җавап буларак, идарә итү турындагы аерым фән — кибернетика барлыкка килде. Шул ук вакытта ул — информация турындагы фән дә.

Без фәнни белемнәр күләме, информация (мәгълүмат) чыганакларының саны бик тиз үскән «информацион шартлау» чорында яшибез. Шуңа күрә гадәти (кәгазьдәге) информациядән машина информациясенә күчү аеруча мөһим.

Төрле информацион техника эшләп чыгару җитештерүнең фәнсыешлы өр-яңа тармакларыннан берсенә әверелде, ә аңа хезмәт күрсәтү дөньяда программист, оператор һәм башка белгечлекләр барлыкка килүгә сәбәп булды. Информатика системалылыкны тормышка ашырырга, икътисади-математик модельләштерүне кулланырга мөмкинлек бирә.

Җитештерүне урнаштыруга да аның йогынтысы зур. Мәсәлән, фәнсыешлы тармакларның күбесе, беренче чиратта яхшы оешкан төрле информация чыганакларына якынрак булырга омтылалар, ә андый чыганаклар, кагыйдә буларак, зур шәһәрләрдә һәм шәһәр агломерацияләрендә туплана.

И. А. Витвер 1854 елдагы Кырым сугышы турындагы хәбәрнең Австралиягә 114 көндә барып җитүе турында яза. Хәзер исә коммуникация өлкәсендә фәнни-техник алгарыш Җирнең теләсә кайсы ноктасындагы информацияне теләсә кайсы илгә яшен тизлеге белән тапшырырга мөмкинлек бирә. Европа чит илләрендә, Япония, Америка, Австралиядә урамдагы автомат телефоннан һәр континент белән элемтәгә керергә мөмкин.

Безнең көннәрдә *бөтендөнья информацион пространствосы* яшәп килә.

Аны булдыруда 1969 елда АКШ башлап җибәргән бөтендөнья компьютерлы аралашу системасы — *Интернетның* роле гаять зур булды. 2007 елда аны бөтен дөньяда 1,2 млрд кеше файдаланды.

**Мисал.** АКШта Интернеттан барлык халыкның 70% ы файдалана. Бу күрсәткеч буенча АКШ Көнбатыш Европа белән Японияне артта калдырды. Кәрәзле телефон элемтәсе үсеше буенча да АКШ дөньяда беренче урында.

Интернет системасы белем алу максатларында да торган саен күбрәк кулланыла.

Гомуми информатизацияләштерү география фәнен дә читләтеп үтмәде, һәм анда яңа юнәлеш — географик информатика, ягъни *геоинформатика* барлыкка килде.

Геоинформатиканың үсеше үз нәүбәтендә ***геоинформатик системалар*** (ГИС)[1] булдыруга китерде. Географиягә ГИС техно-

[1] Геоинформатик система (ГИС) мәгълүматлар җыя, саклый, эшкәртә, сайлап ала һәм тиешле географик мәгълүмат бирә торган үзара бәйләнгән чаралар комплексыннан гыйбарәт.

логияләрен кертү аның күп кенә тармакларына, беренче чиратта картографиягә үзгәрешләр кертте. **Мисал**. Инде бөтендөнья электроник атласлары эшләнгән, алар берберсеннән характеры һәм теле белән аерылып торалар. АКШ, Канада, Япония, Швеция һәм Кытайда, шулай ук күп кенә башка илләрдә милли электроник атласлар нәшер ителгән.

Геоинформатика — география фәнен ФТР казанышларына бәйләүдә иң төп юнәлеш.

## 2. БӨТЕНДӨНЬЯ ХУҖАЛЫГЫН ӨЙРӘНӘБЕЗ

**1. Бөтендөнья хуҗалыгы төшенчәсе**. Дөнья (бөтендөнья) хуҗалыгының формалашуы, асылда, кешелекнең бөтен тарихын үз эченә ала.

Бөек географик ачышлар нәтиҗәсендә халыкара сәүдә Европа һәм Азиядән соң Җир шарының башка регионнарына үтеп керә. Алар арасында продукт алмашу бөтендөнья базарын барлыкка китерә.

Транспорт үсеше базарның тагын да киңәюенә булышлык итә. Диңгез транспорты барлык материкларны бер-берсе белән тоташтыра. XIX гасырның икенче яртысында тимер юлларның озынлыгы бик тиз арта, алар, континентларның эчке өлешләрен тоташтырып, Генрих Гейне әйткәнчә, «пространствоны үтерәләр». [7].

Ләкин бөтендөнья хуҗалыгы формалашуда төп роль эре машина индустриясенә туры килә. Ул XVIII—XIX гасырларда Көнбатыш Европаның кайбер илләрендә һәм АКШта промышленностьны үзгәртеп корудан соң барлыкка килә. Димәк, *бөтендөнья хуҗалыгы XIX гасыр ахырында — XX гасыр башында эре машина индустриясе, транспорт һәм бөтендөнья базары үсеше нәтиҗәсендә барлыкка килә.*

**Бөтендөнья хуҗалыгы — барлык илләрнең милли хуҗалыкларының тарихи формалашкан бөтендөнья икътисади мөнәсәбәтләре белән бәйләнгән берлеге ул.**

**Дөнья хуҗалыгы географиясе**, икътисади һәм социаль географиянең бер тармагы буларак, үз нәүбәтендә түбәндәгеләрне эченә ала: 1) *дөнья хуҗалыгының гомуми географиясе*, ул үсешнең гомуми мәсьәләләрен тикшерә; 2) *дөнья хуҗалыгының тармак географиясе* дөнья промышленносте, авыл хуҗалыгы, транспорт һ. б. географиясен өйрәнә, һәм 3) *дөнья хуҗалыгының региональ географиясе*, ул хәзерге дөньяның эре регионнары масштабында шул ук мәсьәләләрне тикшерә.

**2. Хезмәтнең халыкара географик бүленеше төшенчәсе.** Хезмәтнең географик бүленеше төшенчәсен тирәнтен һәм һәрьяклы өйрәнеп, Н. Н. Баранский аны *икътисади географиянең төп төшенчәсе* дип атый.

*Хезмәтнең географик (территориаль) бүленеше* — кешелек җәмгыятенең товар җитештерү һәм алмашу белән бәйле үсешенең котылгысыз нәтиҗәсе. Аның котылгысызлыгы төрле территорияләр

20 нче рәсем. Супертанкер рейста

20

21 нче рәсем. Диңгездәге бораулау платформасы

21

22 нче рәсем. Үсеп килүче ил хуҗалыгының территориаль структурасы моделе

22

арасында һәрвакыт аерма булудан килеп чыга: ул беренчедән, географик урынга, икенчедән, табигый шартларга һәм ресурсларга, өченчедән, социаль-икътисади шартларга — үсеш дәрәҗәсенә, хуҗалык структурасына, хезмәт ресурсларына, тарихи традицияләргә һәм башкаларга бәйле. Мондый аермалар промышленность һәм авыл хуҗалыгы производствосының бик күп төрләрен аерым территорияләргә беркеткәндәй итәләр.

Бу хәл аерым икътисади районнарга да, шулай ук аерым илләргә дә кагыла, чөнки алар халыкара географик хезмәт бүленеше белән үзара бәйләнгән. Мондый хезмәт бүленеше борынгы заманнарда ук туган һәм бөтендөнья хуҗалыгы барлыкка килү белән бөтен дөньяны чолгап алган.

**Хезмәтнең халыкара географик бүленеше аерым илләрнең үзенә хас аерым төр продукция җитештерүенә, аерым төр хезмәт күрсәтүенә һәм шуларны алмашуга специальләшүе белән билгеләнә.**

Хезмәтнең халыкара географик бүленеше вакыт узган саен үзгәреп тора.

**3. Халыкара специальләшү тармагы — хезмәтнең географик бүленеше нәтиҗәсе.** Аерым илләрнең билгеле бер төр продукция җитештерүе һәм аерым төр хезмәт күрсәтүгә специальләшүе аларны үз ихтыяҗларына караганда шактый күбрәк җитештерүне күздә тота. Атап әйткәндә, ул **халыкара специальләшү тармакларын** формалаштырудан, ягъни продукцияне күбрәк дәрәҗәдә чит илгә чыгаруга — экспортка юнәлтеп җитештерүдән һәм хезмәтнең халыкара географик бүленешендә беренче чиратта илнең «йөзен» билгеләүче тармакларны үстерүдән гыйбарәт.

**1 нче мисал.** Автомобильләр җитештерү буенча Япония дөньяда беренче урынны алып тора. Җитештерелгән автомобильләрнең яртысын диярлек ул башка илләргә чыгара. Автомобиль промышленносте — аның халыкара специальләшү тармагы.

**2 нче мисал.** Канада бөртекле культуралар җыеп алу буенча — җиденче урынны, ә аларны чит илләргә чыгару — экспортлау буенча икенче урынны алып тора. Аның халыкара специальләшү тармагы — бөртекле ашлык җитештерү.

Халыкара специальләшү үз чиратында халыкара товар һәм хезмәт күрсәтү алмашы ихтыяҗын тудыра. Бу алмашу халыкара икътисади элемтәләрнең алга китүендә, йөк агышларының саны һәм куәте артуда чагылыш таба, өстәвенә *җитештерү урыны белән куллану урыны арасында һәрвакыт зур яки кечкенә территориаль өзеклек барлыкка килә.* (2 нче бирем.)

**4. Халыкара икътисади интеграция: региональ һәм аерым тармак төркемнәре.** Бөтендөнья хуҗалыгы һәм хезмәтнең халыкара географик бүленеше дөньядагы барлык илләрне эченә алып, соңгы берничә унъеллыкта киңлеккә генә түгел, күбрәк тирәнлеккә үсә башлады. Алар катлаулана, яңа формалар ала бара. Халыкара специальләшү һәм алмашуның тирәнәюе күп кенә илләрнең милли хуҗалыкларының аеруча тыгыз «кушылып үсүенә» китерде. Шулай

итеп, хезмәтнең халыкара географик бүленеше иң югары, яңа баскычка күтәрелде — **халыкара икътисади интеграция** барлыкка килде. *Ул аерым илләр төркеменең узара килешүле дәүләтара сәясәтенә нигезләнгән аеруча тирән һәм тотрыклы элемтәләре үсешенең объектив процессыннан гыйбарәт.*

XX гасырның икенче яртысында бөтендөнья хуҗалыгы үсешендә региональ икътисади интеграция тенденциясе өстенлек алды. Дөнья хуҗалыгы күбесенчә интеграцияләнгән икътисади төркемнәрнең кушылуыннан тора. Аларның иң әһәмиятлеләренә шундый биш төркем керә.

Европада — ул *Европа Союзы* (ЕС), аңа 2004 ел башында 15 ил[1] керде. 1957 елда «Уртак базар» буларак барлыкка килгән бу интеграцион берләшмә акрынлап һәм киңлеккә, һәм тирәнлеккә үсә. 1999—2001 елларда Европа союзында бердәм валюта — *евро* кертелде.

2004 елның маенда ЕС составына рәсми рәвештә тагын ун Европа чит иле керде: Польша, Чехия, Венгрия, Словакия, Словения, Литва, Латвия, Эстония, Мальта һәм Кипр. Хәзерге вакытта ЕС илләре халкы 500 млн тәшкил итә, ә бу интегральләшкән төркемнең бөтендөнья ТЭПында өлеше – 1/5 дән артык.

Европа Союзы, бер үк вакытта икътисади, сәяси һәм хәрби оешма буларак, күп кенә үз органнары белән идарә ителә. Европа Союзының законнар чыгару органы Европа парламенты (Европарламент) халык тарафыннан турыдан-туры сайлана. Ул Франциядәге Страсбург шәһәрендә урнашкан. Моннан тыш, ЕС башкарма хакимиятенең күп санлы органнары, үз байрагы, гимны, бердәм паспорты бар.

Азия-Тын океан регионында *Көньяк-Көнчыгыш Азия дәүләтләре Ассоциациясенә* (АСЕАН)[2] шул регионның гомуми халык саны 570 млн булган 10 иле керә. Ә *Азия-Тын океан икътисади хезмәттәшлеге* (АТЭС — Азиатско-Тихоокеанское экономическое сотрудничество) 21 илне, шул исәптән Россияне, үз эченә ала.

Төньяк Америкада *Төньяк Америка ирекле сәүдә ассоциациясе* (НАФТА) оештырыла. Ул АКШ, Канада һәм Мексиканы берләштерә: халкы 435 млн кеше, дөньядагы ТЭПның 1/4 өлешен тәшкил итә. ЕСтан аермалы буларак, бу ассоциациянең бернинди үз органнары юк, һәм ул иң элек уртак базар булып тора.

---

[1] ЕС формалашуында 5 этапны күрсәтергә мөмкин: 1957 елда аңа ГФР, Франция, Италия, Нидерланд, Бельгия һәм Люксембург; 1973 елда — Бөекбритания, Дания һәм Ирландия; 1981 елда — Греция; 1986 елда — Испания һәм Португалия; 1995 елда Австрия, Швеция һәм Финляндия керә.

[2] АСЕАН составындагы илләр: Индонезия, Малайзия, Сингапур, Таиланд, Филиппин (1967 елдан), Бруней (1984 елдан), Вьетнам (1995 елдан), Лаос һәм Мьянма (1997 елдан), Камбоджа (1999 елдан).

Ниһаять, Латин Америкасында — *Латин Америкасы интеграциясе ассоциациясе* (ЛАИ — Латиноамериканская ассоциация интеграции)[1] региондагы халкы 450 млн булган 11 илне берләштерә, төп максаты — бу илләр өчен уртак базар булдыру.

БДБ илләрендә дә берничә региональ төркем бар. 2003 елда Россия, Украина, Казахстан һәм Белоруссия арасында бердәм икътисади пространство (БИП) формалаштыру Концепциясе кабул ителде.

Дөнья хуҗалыгы системасында, региональ төркемнәрдән тыш, күп кенә икътисади тармак төркемнәре дә бар. Аларның иң әһәмиятлесе — нефть экспортлаучы илләр оешмасы (ОПЕК)[2], ул 13 илне берләштерә. (3 нче бирем.)

**5. Хуҗалыкның интернационализацияләшүе: ТНКның роле.** Дөнья хуҗалыгының үсеш процессы һәм халыкара географик хезмәт бүленешенең, икътисади интеграциянең тирәнәя баруы *хуҗалыкның күбрәк интернациональләшүенә* китерә. Бу процесста ***транснациональ корпорацияләр***[3] (ТНК) хәлиткеч роль уйный. XXI гасыр башында аларның гомуми саны 65 меңгә, ә чит илләрдәге филиалларының саны 850 меңгә җитте. Дөнья промышленность җитештерүенең 2/5 һәм сәүдәсенең 2/3 сеннән артыграгы, барлык яңа техника һәм технология патентларының 4/5 өлеше ТНКга туры килә. Ләкин ТНК экспансиясенең төп юлы — капитал чыгару белән бәйле финанс эшчәнлеге. Академик Н. Н. Моисеевның хәзерге дөнья хуҗалыгын «ТНК дөньясы» дип атавы һич очраклы түгел.

Әле күптән түгел ТНКлар, нигездә, транснациональ булганнар һәм алар үз йогынтыларын дөньяның аерым регионнарына гына җиткергәннәр. Ләкин соңгы вакытта аларның глобаль дип аталырлыклары барлыкка килде. Хәзер алар базар икътисадлы күпчелек илләр, хәтта барлык илләр белән эшлиләр.

**Мисал.** «Дженерал Моторс» дөньяда иң зур промышленность корпорациясе, аның еллык табыш суммасы 200 млрд доллар тәшкил итә, ә ул Дания белән Чехиянең ТЭПыннан артып китә. Корпорациянең Америка һәм Европадагы 258 заводында 750 мең кеше эшли.

Бу корпорацияләрнең бөтен дөнья хуҗалыгы географиясенә хәлиткеч йогынты ясавын сез, мөгаен, аңлыйсыздыр.

---

[1] ЛАИ әгъзалары: Аргентина, Боливия, Бразилия, Венесуэла, Колумбия, Мексика, Парагвай, Перу, Уругвай, Чили, Эквадор.

[2] ОПЕК составына Көньяк-Көнбатыш Азиядә — Согуд Гарәбстаны, Иран, Гыйрак, Кувейт, БГӘ, Катар, Көньяк-Көнчыгыш Азиядә — Индонезия, Африкада — Алжир, Ангола, Ливия, Нигерия һәм Латин Америкасында Эквадор һәм Венесуэла керә.

[3] Транснациональ корпорация (ТНК) — халыкара компания (концерн). Ул дөнья хуҗалыгының төрле илләрдәге бер яки берничә тармакка караган күп санлы предприятиеләрен берләштерә.

## 3. ДӨНЬЯ ХУҖАЛЫГЫНЫҢ ТАРМАК ҺӘМ ТЕРРИТОРИАЛЬ СТРУКТУРАСЫН ӨЙРӘНӘБЕЗ

**1. Индустриясез җәмгыятьтән индустриаль һәм постиндустриаль җәмгыятькә: структураның өч тибы.** *Тарихи тәҗрибәдән күренгәнчә, кешелек җәмгыяте үзенең үсешендә бер-бер артлы килгән өч стадияне үтә: индустриясез, индустриаль һәм постиндустриаль.* Аларның һәркайсына үзенә генә хас типтагы хуҗалык структурасы хас.

Индустриясез җәмгыятьтә икътисадның **аграр** структурасы һичшиксез, өстенлек итә, анда авыл хуҗалыгы һәм аңа эргәдәш тармаклар (урман хуҗалыгы, аучылык, балыкчылык) материаль байлыклар табуның төп чыганагы булып тора. XVIII гасырның икенче — XIX гасырның беренче яртысында промышленностьны үзгәртеп корулардан соң, Европа илләрендә һәм АКШта төп рольне промышленность уйнаган **индустриаль хуҗалык структурасы** барлыкка килә. XX гасырның икенче яртысында ФТР йогынтысында әр-яңа структура формалаша башлый, аны **постиндустриаль** (яки **информацион) структура** дип атыйлар. *Аның иң характерлы үзенчәлеге — җитештермәүче сфераларның җитештерү сфераларыннан өстен булуында.*

Бу структураларның һәркайсы хәзерге дөньяда яшәп килә.

Сез инде чамалагансыздыр, икътисадның аграр структурасы хәзерге вакытта фәкать кайбер илләрдә, бигрәк тә аз үсеш алган илләрдә генә өстенлек итә.

**Мисал.** Сомали, Эфиопия, Әфганстан, Лаос, Камбоджа һәм Непалда авыл хуҗалыгының ТЭП структурасындагы өлеше әле һаман да 40—50% тан югарырак. Бу өлкәдә эшләүче икътисади актив халык өлеше, гадәттә, тагын да югарырак, тропик Африка илләрендә ул 80—90% тәшкил итә.

Икътисадның индустриаль структурасы XX гасыр урталарында әле барлык икътисади үскән илләрдә өстенлек итә иде. Аннары промышленностьның әһәмияте кими башлый. Хәзер дөньяда бер генә илдә дә бу тармак ТЭПның 50% ыннан артыграгын бирә алмый. Бу шулай ук икътисади актив халыкның эш белән тәэмин ителүенә дә кагыла.

Ихтимал, индустриаль структурасы аермачык беленеп торган илләрнең җыйнак төркемен нефть чыгаручы һәм экспортлаучы Фарсы култыгы районы илләре (Согуд Гарәбстаны, Кувейт, БГӘ, Гыйрак, Катар) барлыкка китерә, анда ТЭП структурасында промышленность өлеше 50—80%. Кайбер индустриальләштерү сәясәтен тормышка ашыручы яңа индустриаль илләрдә һәм Кытайда бу өлеш шулай ук шактый югары. Күптән түгел бу төркемгә икътисади көчеш хәлендәге күп кенә илләр керә иде (БДБ һәм Үзәк-Көнчыгыш Европа илләре), ләкин соңгы вакытта аларның ТЭПында промышленность өлеше 25—30 % ка кадәр төште.

Хуҗалыкның (дөресрәге, җәмгыятьнең) постиндустриаль структурасы ФТР этабына көчү белән формалаша башлады. *Ул түбәндәге төп билгеләр белән*

*характерлана:* 1) икътисад сферасында — товар җитештерүдән хезмәт күрсәтүләр җитештерүгә күчү, 2) *эш* белән тәэмин ителеш сферасында — акыл хезмәте белән шөгыльләнүчеләр өстенлек итү, 3) фән сферасында — иң элек фәнсыешлы җитештерүләр үсешен тәэмин итүче фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләрнең рациональ бергәлеге, 4) идарә сферасында — өр-яңа информацион техника һәм технологияләргә таянып карар кабул итү, 5) экология сферасында — кешенең әйләнә-тирә мохиткә тыкшынуына ышанычлы контроль урнаштыру. Җитештермәүче сфераның үзендә дә хезмәт күрсәтүләр сферасы: кулланучы (көнкүреш, мәгърифәт, сәламәтлекне саклау) һәм эшлекле (информациягә, рекламага бәйле һ.б.) гаять тиз үсә.

Хәзер кешеләрнең күбесе интеллектуаль сферада эшли. Бу — урта мәктәп һәм югары белем бирү системасы, белемнәрне популярлаштыру, нәшер итү эшчәнлеге, радио һәм телевидение. Җитештерүче көчләр һәм кешенең үсешендә аның физик һәм иҗади сәләтен торгызу (сәламәтлекне саклау, физкультура, спорт, ял, туризм, күңел ачу) әһәмиятле фактор булып санала. Озак файдалану товарларына (автомобильләр, телевизорлар, компьютерлар) ихтыяҗ арту хезмәт күрсәтү сферасының киңәюенә китерде. Хәзер банклар, иминият компанияләре, авиакомпанияләр, кунакханә һәм туризм фирмалары хезмәтеннән кешеләр торган саен күбрәк файдалана башлады. Кулланучыларның ихтыяҗларын өйрәнү (маркетинг) хәзер эшлекле хезмәт күрсәтүнең иң әһәмиятле төрләреннән санала.

**Мисал.** XXI гасыр башында АКШ, Франция, Бөекбритания, ГФР, Япония һәм Канадада хезмәт күрсәтү сферасының ТЭП дагы өлеше 70 % ка, хәтта 80 % ка җитте. Көнбатыш Европаның күпчелек башка илләрендә ул 60—70 % тәшкил итә. XXI гасыр башында Россиядә хезмәт күрсәтү сферасының өлеше 60 % ка кадәр үсте. [8].

Шунысы игътибарга лаек: туризм, төрле финанс эшләре белән шөгыльләнү һәм башка төрле хезмәт күрсәтү исәбенә яшәүче бик кечкенә илләрдә, хәтта еш кына микродәүләтләрдә ТЭП структурасында хезмәт күрсәтү сферасының өлеше тагын да зуррак. [9].

Хезмәт күрсәтү сферасының ТЭП составындагы өлешен характерлаучы йомгаклау күрсәткечләре: бөтен дөньяда 1/3 дән аз гына артыграк, икътисади үсеш алган, базар икътисадлы илләрдә 2/3 дән артыграк, икътисади күчеш илләренеке 1/2 дән аз гына артык, үсеп килүче илләрдә — 1/2. (4 нче бирем.)

**2. Материаль җитештерүнең тармак структурасына ФТРның йогынтысы: прогрессив үзгәрешләр.** ФТР материаль җитештерү структурасында зур үзгәрешләр китереп чыгарды. Бөтен дөньяда бу сферада 1,5 млрд кеше эшли.

Промышленностьның тармак структурасында эшкәртү тармакларының өлеше тагын да ныграк арта, хәзер бу тармак барлык продукция бәясенең 9/10 чамасын бирә. Монда «өч авангард» тармак аеруча өстенлек итә: машина төзү, химия промышленносте һәм электр энергетикасы. Фәнни-техник прогресс беренче чиратта нәкъ шуларга бәйле. Чыгару промышленносте өлешенең 1/10 дән артыгракка түбәнәюе җитештерүдә энергия һәм материал сыешлыгының даими кимүе һәм шулай ук табигый чимал урынына синтетик чимал куллану артуы белән аңлатыла.

Промышленностьның аерым тармаклары составында да катлаулы процесслар бара. Кайбер тармаклар, гомумән, «төшеп кала» (мәсәлән, паровозлар төзү), ә икенчеләре исә — алар күбрәк — яңадан барлыкка килә һәм шуның белән структураның даими «ваклануына» китерә. БМО классификациясе буенча хәзерге промышленность 300 дән артыграк тармак һәм тармакчаны үз эченә ала. Икенче яктан, ФТР чорына төрле тармакларның үзара берләшеп тармакара комплекслар: ягулык-энергетика, машина төзү, агропромышленность комплекслары барлыкка килү хас, сез аларны географиянең алдагы сыйныф курсында өйрәнгән идегез инде.

Авыл хуҗалыгы тармаклары структурасында үзгәрешләр акрынрак бара. Ләкин шулай да интенсивлаштыру үсә барган саен, кагыйдә буларак, терлекчелек өлеше арта бара, ә ул исә икътисади үсеш алган илләрнең күбесендә бу тармактагы тулай продукциянең 3/4 ен бирә. Ә үсемлекчелектә техник һәм азык культураларының, яшелчә һәм җиләк-җимеш үстерүнең роле арта.

ФТР транспортның аерым төрләре арасында «хезмәт бүленешенә» зур үзгәрешләр кертте. Тулаем алганда, тимер юл транспортының роле кимеде. Ул күбрәк промышленность һәм авыл хуҗалыгы йөкләрен күпләп ташу өчен, уртача ераклыкка, шулай ук шәһәр эчендә, бигрәк тә зур шәһәрләрдә һәм агломерацияләрдә, пассажирлар ташу өчен әһәмиятле булып кала. [10]. Автомобиль транспорты шәһәр эчендә һәм шәһәр тирәсендә пассажирлар ташуда өстенлек итә. Эксплуатациянең яхшы куелуы, ягъни товарның «ишектән ишеккә» тоткарсыз китерелүе аркасында, шәһәрара һәм халыкара йөк ташуда да аның роле арта бара. Диңгез транспорты халыкара сәүдәнең күпчелек өлешен тәэмин итә, ләкин ул пассажирлар ташуда, туристлардан кала, бөтенләй катнашмый диярлек. Пассажирларны уртача ераклыкка, бигрәк тә ерак араларга ташуда һава транспортының роле гаять зур.

**3. Дөнья хуҗалыгының төп модельләренең мөмкин булган вариантлары.** Дөнья хуҗалыгының аерым кисәкләре халыкара географик хезмәт бүленеше аркасында үзара тыгыз бәйләнгән, ягъни аларның чагыштырмача бердәм булуларына карамастан, ул кисәкләр арасында, һичшиксез, билгеле аер-

малыклар булмыйча калмый. Монда Козьма Прутковның бер афоризмын искә төшерү урынлы булыр: «Җир шарының барлык кисәкләрендә үзләренең, хәтта үтә кызыклы, башка кисәкләре бар». *Бу кисәкләрне дөнья хуҗалыгының пространство модельләре дип атарга була, һәм алар арасындагы пропорцияләр ике, өч һәм күп буыннан торырга мөмкин.*

Дөнья хуҗалыгының ике буыннан торган моделе дөньядагы илләрнең ике буынлы типологиясенә туры килә, һәм ул илләрнең ике зур төркемгә — икътисади үсеш алган һәм үсеп килүче илләргә бүленүен күздә тота. Географик урынының күзгә күренеп торган үзенчәлекләреннән чыгып, әдәбиятта аларның беренчесен еш кына шартлыча — Төньяк, ә икенчесен Көньяк илләр дип исемлиләр. Икътисади бик югары темплар белән үсүе нәтиҗәсендә, соңгы вакытта дөнья ТЭПында Көньякның өлеше сизелерлек артты. Ләкин бу күренеш Кытай, Һиндстан, Азиянең яңа индустриаль илләренә бурычлы, ә күп илләр акрын үсәләр. Үтә аз үскән илләрнең хәле бигрәк тә аяныч, аларны кайчакта «дөнья икътисадыннан ычкынып калган вагон» дип атыйлар. Ә Н. Н. Моисеев әйтүенчә, алар «мәңгегә артта калганнар».

Дөнья хуҗалыгының өч буынлы моделендә Көнбатышның икътисади нык үскән илләре, үсеп килүче илләр һәм икътисади күчеш илләре аерылып тора. Соңгы вакытта дөнья хуҗалыгының өч буынлы тагын бер моделе таралыш ала. Ул беренчесенә охшаган булса да, аннан аерылып тора: *Үзәк, Периферия, Ярымпериферияга бүлү*. **Үзәкне** гомуми халык саны 850 млн кеше яшәгән Төньякның 25—30 иле тәшкил итә. Бөтен дөньяда фәнни-техник прогрессны һәм дөнья икътисадының постиндустриаль стадиягә күчүен беренче чиратта алар билгели. Аның нигезен «зур җиделек» составындагы илләр, яисә Европа Союзы илләре, АКШ һәм Япония тәшкил итүе мөмкин. **Периферия** составына аграр икътисад өстенлек иткән, азык-төлек чималы җитештерүгә халыкара специальләшкән, ләкин ФТР бик аз кагылган, үсеп килүче 100 ләп Көньяк иле керә. Алар арасындагы чиктә **Ярымпериферия** урнашкан. Аңа, гадәттә, Азиянең яңа индустриаль илләре, нефть экспортлаучы ОПЕК илләре, Латин Америкасы, Азия һәм Африканың иң «алга киткән», шулай ук кайбер икътисади күчеш илләре керә. Ярымпериферия илләре әле һаман да үсешнең индустриаль стадиясендә.

Географиядә дөнья хуҗалыгының ун буыннан торган моделе дә файдаланыла. Аның төп ун үзәге бар, алар акрынлап формалашканнар.

XIX гасыр ахырына кадәр барлык күрсәткечләр буенча бердәнбер үзәк — Европа өстенлек иткән: И. А. Витверның бу периодны «европоцентрик» дип атавы очраклы түгел. Аннары дөньякүләм әһәмияткә ия икенче үзәк — АКШ барлыкка килә, күп тә үтми, ул төп үзәккә әверелә. Ике бөтендөнья сугышлары арасындагы чорда дөньякүләм әһәмияткә ия булган яңа үзәкләр — СССР, Япония барлыкка килә. Икенче бөтендөнья сугышын-

нан соң Кытай, Һиндстан, Көньяк-Көнбатыш Азиядәге нефть чыгаручы илләр, Канада, Мексика, Бразилия кебек үзәкләр формалаша. Соңгы ике дистә ел эчендә «Азиянең дүрт юлбарысы» — Корея Республикасы, Тайвань, Гонконг (хәзер Сянган) һәм Сингапур җитәкләгән Азиянең яңа индустриаль илләре дөнья аренасына чыга.

Үз чиратында бу үзәкләр арасындагы пропорцияләр икътисад үсешенең темпларына бәйле рәвештә үзгәреп тора. Мәсәлән, 90 нчы елларда үсеш темплары иң югары булган Кытайның өлеше шактый артып китә, ә үсеш темплары бик түбән булган БДБ илләренең өлеше кими. XXI гасыр башында бу ун үзәк дөньяның ТЭПындагы өлешләре буенча түбәндәге тәртиптә урнаша: Төньяк Америка, Европа чит илләре, Кытай, Япония, Һиндстан, Азиянең яңа индустриаль илләре, БДБ, Бразилия, Фарсы култыгы илләре, Мексика. Моңа бәйле рәвештә Көньякның «зур җиделеге» дигән яңа термин барлыкка килде. Аңа Кытай, Һиндстан, Бразилия, Индонезия, Мексика, Корея Республикасы һәм Таиландны кертәләр.

Соңгы ике-өч унъеллыкта дөнья хуҗалыгында ***Азия-Тын океан регионының***[1] роле өзлексез үсә бара, һәм ул аеруча динамик үсүче регионнарның берсенә әверелә. Хәзерге вакытта халкы 3,5 млрд кеше исәпләнгән АТР илләренә дөнья тулай продуктының 60% ы һәм дөнья сәүдәсе күләменең 40% ы туры килә. Нәкъ менә күбесенчә АТР дөнья хуҗалыгының үсеш перспективасын да билгели. Шуңа күрә фаразларда XXI гасырны еш кына «Тын океан гасыры» дип атаулары очраклы түгел. (5 нче бирем.)

**4. Дөнья хуҗалыгының территориаль структурасы: ике төркем илләре арасында аерма.** Дөнья һәм аерым илләрнең хуҗалык географиясен характерлау өчен, төрле терминнар кулланыла: җитештерүнең (җитештерүче көчләрнең) урнашуы, территориаль оештыру һ.б. Ләкин икътисади һәм социаль географиядә хуҗалыкның территориаль структурасы төшенчәсенең әһәмияте аеруча зур. *Хуҗалыкның территориаль структурасы* (ХТС) — *үзара билгеле бер тәртиптә урнашкан һәм үзара катлаулы бәйләнештә булган территориаль элементлар җыелмасы.* Мондый элементларга — зур шәһәр агломерацияләре, промышленность районнары, рекреацион зоналар, төп транспорт магистральләре керә, ә алар беренче чиратта халык һәм аның хуҗалык эшчәнлеге урнашуындагы *географик сурәтне* билгели. Бу сурәт *моноцентрик* (бер үзәкле), *полицентрик* (күп үзәкле) яки катнаш булырга мөмкин.

Икътисади үсеш алган илләрдә үзенең югары «өлгергәнлек» дәрәҗәсе белән аерылып

---

[1] Азия-Тын океан регионы (АТР) — аеруча әһәмиятле сәяси-географик төшенчә. Ләкин АТРның контурлары аңа 30 дан 45 кә кадәр илләрнең ничәсе керүгә карап төрлечә билгеләнә. Шуңа күрә бу регионның санлы күрсәткечләре дә беркадәр шартлы.

торган территориаль хуҗалык структурасы шактый озак вакыт дәвамында формалашкан. Димәк, аларның территориясе шул территориянең үзенә бертөрле *терәк каркасын* тәшкил иткән промышленность районнары һәм үзәкләре, шәһәр агломерацияләре, транспорт узеллары һәм магистральләре, интенсив авыл хуҗалыгы, рекреация һәм туризм районнары, технологик паркларга бай. Бу илләрдә төп дүрт төрдәге икътисади районнар системасы барлыкка килгән.

Беренчедән, алар көчле үсеше белән аерылып торган **нык үсеш алган районнар.** Алар, фәнсыешлы промышленность тармакларын, фән һәм фәнни хезмәт күрсәтүне, җитештермәүче сфераны үзләренә тарту өчен, үтә уңайлы шартларга ия. Аеруча зур фирмаларның штаб-квартиралары шушы районнарда урнашкан, кыскасы, биредә «карарлар кабул ителә».

**Мисал.** АКШның Калифорния штаты халык саны һәм икътисади куәте ягыннан илдә иң зурлардан санала. Әгәр аны «дәүләт эчендә дәүләт» итеп карасак, ул үзенең ТЭП күрсәткече белән бик алга киткән берничә илдән генә калыша, ә җан башына исәпләнгәне буенча беренче урында. Калифорния — иң фәнсыешлы тармаклар урнашкан район.

Икенчедән, **иске промышленность районнары,** алар промышленностьта әүвәлге кискен үзгәрешләр чорында ук барлыкка килгәннәр. Монда ташкүмер һәм тимер рудасы чыгару, судносы төзү, туку промышленносте кебек гади тармаклар аларның фәнсыешлыларыннан өстенлек итә. Мондый иске промышленность районнарының күбесе беренче кискен үзгәрешләр ватанында — Көнбатыш Европада урнашкан.

Өченчедән, индустрияләшү бик аз кагылган, постиндустриягә бөтенләй тартылмаган **аграр районнар.**

Дүртенчедән, **яңа үзләштерелеп килә торган районнар.** Экстремаль табигый шартлар аркасында барып җитү кыен булган, яшәүгә аз җайлашкан, ләкин күп төрле табигать ресурсларына бай районнар алар. Техника һәм технология өлкәсендә ФТР казанышлары мондый районнарны үзләштерү мөмкинлеген ачтылар.

**Мисал.** Яңа үзләштерелгән төп районнар рәтенә Төньяк Канада һәм Аляска, Австралиянең үзәк, төньяк һәм көнбатыш өлешләре, Россиядә Себер, Ерак Көнчыгыш керә.

Әлбәттә, икътисади үсеш алган илләрдә аның алдынгы һәм артта калган районнары арасындагы территориаль диспропорция әле һаман да саклана, әмма ул аерма әкренләп бетә. Ә аларның халык урнашу һәм хуҗалыкның географик сурәте, территориясенең терәк каркасы катлаулана бара.

Үсеп килүче илләрдә халыкның урнашуы һәм хуҗалык итүнең географик сурәте бөтенләй башка. Азия, Африка һәм Латин Америкасы илләрендә хуҗалыкның территориаль структурасының төп үзенчәлекләре бу илләр колониаль яки ярымколониаль бәйлелектә чакта ук барлыкка килгән. *Территориаль структураның колониаль*

*төре* аларның күбесендә әле хәзер дә саклана. Аларның «өлгергәнлек» дәрәҗәсе бик түбән, ягъни промышленность һәм авыл хуҗалыгы районнары, транспорт магистральләре аз тупланган. Аларга аерым өлешләренең читләшеп яшәве һәм территорияне урыны-урыны белән генә файдалану хас. Шул ук вакытта бу илләрнең күпчелегендә җитештерүнең һәм халыкның территориаль тупланышы икътисади үсеш алган илләрдәгегә караганда югарырак.

Географ-галимнәрнең тикшеренүләре күрсәткәнчә, *үсеп килүче ил территориясенең «фокусы», ягъни төп үзәге ролен, гадәттә,аның башкаласы үти.* Ә ул еш кына чамасыз үсеп башка шәһәрләрнең үсешен тоткарлый. Диңгез буендагы илләрдә башкала, гадәттә, төп диңгез капкасы хезмәтен дә үти.

**Мисал.** Буэнос-Айреста Аргентина халкының 1/3 е һәм промышленность җитештерүенең 1/2 е тупланган. Халык саны ягыннан ул илдәге икенче шәһәрдән 12 тапкыр өстен. Буэнос-Айрес — Аргентинаның төп диңгез порты.

Кайбер очракларда «икътисади башкала» илнең башкаласы булмаска да мөмкин. Мәсәлән, Һиндстанда Мумбаи (Бомбей) һәм Колката (Калькутта), Бразилиядә Сан-Паулу, Мароккода Касабланка шундый шәһәрләрдән санала. Мондый шәһәрләр тирәсендәге территория, гадәттә, илнең иң алга киткән районын тәшкил итә; аның еш кына халыкара сәүдәдә актив катнашучы шактый ук үскән промышленносте була.

Территориянең ярдәмче үзәге («фокусы») ролен экспортка җайлашкан районнар да үти ала. Бу тау промышленносте яки плантацияле авыл хуҗалыгы районнары булырга мөмкин. Алар үзләре тирәсендәге территорияләр белән бик аз бәйләнгән, дөнья базарына үз продукцияләрен башкала яисә специальләшкән башка порт аша чыгаралар.

Периферия ролен, гадәттә, традицион кулланучы авыл хуҗалыгы өстенлек иткән гаять киң эчке территорияләр үти. Болар артык халыкны башкала һәм зур портлы шәһәрләргә, плантация һәм рудникларга «этеп чыгаручы» төп районнар булып санала. Әдәбиятта аларны еш кына «эчке колония» дип тә атыйлар.

*«Бер ил эчендә ике ил» — бу тәгъбир үсеп килүче күпчелек илләрнең географик сурәтендәге төп үзенчәлекне бик яхшы сыйфатлый.* Зур шәһәрләр дөньясы монда калган территориягә капма-каршы тора кебек. (6 нчы бирем.)

**5. Региональ сәясәт: диспропорцияләрне киметү.**

Икътисади үсеш алган Көнбатыш илләрендә, хуҗалыкның территориаль структурасын яхшырту өчен, дәүләт күләмендә **региональ сәясәт** үткәрелә. *Региональ сәясәт ул җитештерүче көчләрне рациональ урнаштырырга, кешеләрнең тормыш дәрәҗәсен тигезләргә булышлык итүче законнар чыгарудан, административ, икътисади һәм табигатьне саклау чаралары комплексын булдырудан гыйбарәт.*

Бу сәясәт, иң элек, нык алга киткән районнар белән артта калган аграр һәм *депрессив*[1] районнар арасындагы региональ диспропорцияне киметүгә юнәлтелгән. Артта калган районнарда үзенә бер *«үсеш полюслары»* ролен үтәүче зур промышленность предприятиеләре төзелә. Депрессив районнарда исә фәнсыешлы заманча производстволар, эре фирмаларның филиалларын төзергә тырышып карыйлар.

Региональ сәясәт шулай ук 60—70 нче елларда үзәк районнары таркалыш хәленә килгән, экология мәсьәләләре үтә кискенләшкән зур шәһәрләрнең һәм шәһәр агломерацияләренең, иң элек, башкалаларның үсешен чикләү һәм аларны «бушатуны» күздә тота. Болардан тыш, ул яңа районнарны, бигрәк тә аларның читтәгеләрен, перифериядәгеләрен үзләштерүгә булышлык итә. (7 нче бирем.)

Хуҗалыкның территориаль структурасының иске колониаль төрен үзгәртү өчен, үсеп килүче илләр дәүләт региональ сәясәтен үткәрәләр. Бу сәясәтнең төп максаты: илнең аерым өлешләренең таркаулыгын бетерү, үзәк белән аннан читтәге районнар арасындагы диспропорцияләрне киметү, шәһәрләрнең дәүләт системасын формалаштыру һәм урбанизация процессы белән идарә итү, эчкәреге район ресурсларын үзләштерүдән гыйбарәт.

Башкалаларны, әйтик, Бразилия, Нигерия һәм башка илләрдәге кебек, диңгез буендагы шәһәрләрдән эчкәреге районнарга күчерү дә эчкәреге территорияләрне үзләштерүгә булышлык итәргә тиеш. [11]. Әмма никадәр генә тырышлык күрсәтелмәсен, үсеп килүче илләрнең күбесендә үтә кискен территориаль диспропорция әле һаман да саклана.

## 4. УРНАШУ ФАКТОРЛАРЫ БЕЛӘН ТАНЫШАБЫЗ

**1. Урнашу факторлары: искеләр һәм яңалар.** Дөнья хуҗалыгының аерым тармакларын (аннары кайбер илләрнең һәм регионнарның) өйрәнә башлаганга кадәр җитештерүче көчләр **урнашуның төп факторлары** белән танышу зарур. «Россия географиясе» курсында аларның кайберләре белән сез танышкан идегез инде, ләкин калганнарын сез бу курстан белерсез.

*Барлык урнашу факторлары искегә һәм яңага бүленә.* Аларның беренчеләре, әлбәттә инде, күптән, ә икенчеләре, нигездә, ФТР чорында барлыкка килгән. Мондый бүленеш шактый дәрәҗәдә шартлы, чөнки аларның элеккегеләре ФТР чорында күп кенә яклары белән яңа эчтәлеккә ия булды.

**2. Урнашуның иске факторлары.** Аларга территория, икътисади-

[1] Депрессив район — ул, гадәттә, элек шактый югары үсеш алган, ләкин шулар аркасында ФТР чорында икътисади үсеш стимулын югалткан иске промышленность районнары. «Депрессив район» төшенчәсе 1929—1933 еллардагы бөтендөнья икътисади кризис чорында туа.

географик урын, табигый ресурслар, транспорт, хезмәт ресурслары һәм территориаль тыгызлык факторлары кирә.

1. Территория факторы. *Территория — җәмгыятьнең географик мохитенең иң әһәмиятле элементларыннан берсе.* Табигый ки, территория никадәр зур булса, табигый ресурслары да баерак һәм төрлерәк, халык һәм производство урнашуның төрле вариантлары күбрәк була. Бу иң элек Россиягә, Канада, Бразилия, Австралия, АКШ, Кытай һәм Һиндстанга кагыла. Бу мәйданы буенча зур илләр, гадәттә, икътисади зона, макрорегион, регионнар кебек аерым зур кисәкләргә бүленә.

Территориянең зурлыгы кешеләрнең психологиясенә дә беркадәр йогынты ясый дигән фикерләр бар. Россиягә карата бу турыда танылган тарихчы В. О. Ключевский язып калдырган. Ә философ Н. А. Бердяев: «Россия җиренең күз күреме җитмәс гаять зур булуы, ә чикләрнең булмавы русларның холкында чагыла»,— дип язган. [12].

Территорияләре чагыштырмача артык зур булмаган илләрдә бик еракка йөк ташу проблемасы юк. Алар территориаль структураларының «өлгергәнлегенә» тизрәк ирешәләр, икътисади интеграция өчен уңайлы алшартлар күбрәк була. Икенче яктан, андый илләрнең күпчелеге инде территория «кытлыгы» кичерә башлады.

Хуҗалыкның территориаль структурасына кайчакта территориянең конфигурациясе, аның җыйнаклык дәрәҗәсе шактый зур йогынты ясый. (8 нче бирем.)

2. Икътисади-географик урын факторы. Икътисади-географик урын (ИГУ) төшенчәсен фәнгә Н. Н. Баранский керткән. *Ул икътисади-географик урынның* илләр, районнар һәм шәһәрләргә карата кулланыла ала торган *дүрт төрен аерып күрсәткән:* 1) үзәктә урнашу, 2) үзәктән читтә (периферийдә) урнашу, 3) күршедә урнашу, 4) диңгез буенда урнашу. Үзәктә һәм диңгез буенда урнашу ИГУны отышлы яктан сыйфатлый. Үзәктән читтә (периферийдә) урнашу, киресенчә, икътисади үсешне тоткарларга мөмкин. Күршедә урнашуның йогынтысы күбесенчә дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләргә бәйле.

Диңгез буенда урнашу (Арктика диңгезләреннән тыш) элек-электән ИГУның уңайлы үзенчәлеге булып саналган. ФТР чорында аның әһәмияте тагын да артты. 50—70 нче елларда Көнбатыш Европаның күп кенә илләрендә, Япония, беркадәр АКШта җитештерү һәм халыкның урнашуы диңгез буена тартыла башлады. Бу беренче чиратта читтән китерелгән чимал һәм ягулыкка исәп тоту белән аңлатыла. Хәтта *«диңгез яны урбанизациясе»* термины кулланышка керде.

**Мисал.** Халкы 1,5 млн кеше булган барлык шәһәрләрнең 2/3 се диңгез буе зонасында урнашкан, ә 20 «супершәһәрнең» фәкать алтысы диңгез порты түгел.

Н. Н. Баранский: «Һәрбер ил үзенең икътисади-географик урынын

төзәтә һәм яхшырта ала»,— дип язган. Мисал итеп, ул Панама каналы төзелүне һәм АКШта континент аша тимер юл уздыруны китерә. (9 нчы иҗади бирем.)

3. Табигый ресурслар факторы. Индустрияләштерүнең башлангыч этапларында авыр промышленностьның урнашуын күбесенчә табигый ресурслар географиясе, беренче чиратта файдалы казылмалар географиясе билгеләгән. Чөнки авыр промышленностька ташкүмер, тимер рудасы кирәк булган. ФТР чорында андый янәшәлеккә омтылыш сизелерлек кимеде. Бу, барыннан да бигрәк, фәнсыешлы иң яңа тармакларга кагыла.

Ләкин чыгару промышленносте тармакларын урнаштыруда табигый ресурслар факторы һаман да төп фактор булып кала. Күп кенә иске бассейннар һәм чыганаклар, агач әзерләү районнары бик нык ярлыланганлыктан, *нәкъ менә беренче чиратта чыгару промышленносте, юллары булмаган, яшәргә җайлашмаган, табигый шартлары экстремаль булган яңа үзләштерелә торган районнарга күчә башлады.*

**1 нче мисал.** Дөньяның төньяк районнары 21 млн км$^2$ мәйдан били, ә аның 11 млн км$^2$ ы Россиянең төньягына туры килә. ФТР биредә яңа территорияләрне үзләштерергә, анда кешеләр яшәргә һәм табигый ресурслардан файдаланырга мөмкинлек бирде.

**2 нче мисал.** Бөтен дөньядагы континенталь шельф 31 млн км$^2$ мәйдан алып тора. Шельф районнарын үзләштерү нәтиҗәсендә, XXI гасыр башында бөтен дөньяда чыгарылган нефть һәм газның — 1/3 е «диңгез нефте»нә, 1/4 е «диңгез газы»на туры килде. [13]. Нефть һәм газ чыгаручы төп районнар булып Төньяк, Кариб һәм Каспий диңгезләре, Фарсы һәм Мексика култыклары исәпләнә.

Төньякны һәм диңгез акваторияләрен үзләштерү өчен, махсус техника эшләнә. [14]. Ләкин бу районнарның табигый ресурсларын үзләштерү һәм файдалану бик зур чыгымнар таләп итүен һәм мохитне пычратуын да истән чыгарырга ярамый.

4. Транспорт факторы. ФТР чорына кадәр производствоны урнаштыруда бу фактор хәлиткеч йогынты ясаган. Юлларны һәм транспорт чараларын камилләштерү транспорт чыгымнарын шактый киметте. Шулай итеп, «транспорт революциясе» специальләшкән эре предприятиеләрнең продукциясен күп меңнәрчә километр радиуста сату, халыкның күчмәлеген арттыру, производстволарны диңгезгә якынайту, табигый ресурсларны кирәкле урынга күчерү, яңа үзләштерү районнарын формалаштыру һәм нәтиҗәдә продукция *житештерүче районнар белән кулланучы районнар арасында территориаль өзеклекне бетерү мөмкинлеген бирде.*

**Мисал.** Россиядә БАМ төзелү ресурсларга бай яңа районнарны үзләштерүгә бәйле. Канадада транспорт төзелеше программаларының берсе «Ресурсларга юл» дип атала.

Димәк, ФТР чорында да транспорт факторы, бигрәк тә зур территорияле илләрдә, производствоны урнаштыруга зур йогынты ясавын дәвам итә.

5. Хезмәт ресурслары факторы. Бу фактор производство урнашуга һәм хуҗалыкның территориаль структурасына һәрвакыт йогынты ясап килде һәм хәзер дә ясый. Аңлавыгызча, ирекле эшче куллар булу, гадәттә, хуҗалык эшчәнлеген тартып китерә, ә аның булмавы, киресенчә, читкә кагуга китерә, бу беренче чиратта хезмәтсыешлы тармакларга карый.

ФТР чорында хезмәт ресурслары факторының йогынтысы ике төрле була. Беренче очракта промышленностька, җитештермәүче сферага башка илләрдән өстәмә эшче көчләр тартыла. Икенче очракта исә җитештерүне арзанлы хезмәт ресурслары чыганакларына күчерү отышлырак була.

**1 нче мисал.** Көнбатыш Европаның зур икътисади потенциалы һәм яхшы үскән инфраструктурасы булган эре промышленность районнары һәм шәһәр агломерацияләре Европаның башка илләреннән һәм аннан читтәге илләрдән өстәмә хезмәт ресурсларын үзенә тартуның төп үзәкләренә әверелделәр.

**2 нче мисал.** Арзанлы эшче көчләргә бай Көнчыгыш һәм, бигрәк тә Көньяк-Көнчыгыш Азия регионнары, Япония, Көнбатыш Европа һәм АКШ промышленностеның хезмәтсыешлы тармакларын үзләренә тартучы төп үзәкләргә әверелде. [15].

ФТР чорында арзанлы эшче көчләрне, шул исәптән хатын-кызлар көчен куллану кимемәде. Хатын-кыз көченнән файдалану әзлексез җитештерүле яңа тармакларда да күзәтелә башлады. Ләкин *югары квалификацияле кадрларга, эшче көчнең «сыйфатына»* таләп артканнан-арта бара.

6. Территориаль тупланыш (концентрация) факторы. Предприятиеләрне эреләтү юнәлешендә барган җитештерү тупланышы икътисади нәтиҗәле. Эре промышленность үзәкләрендә һәм районнарында, транспорт узелларында һәм шәһәр агломерацияләрендә хуҗалыкның һәм халыкның бер территориядә урнашуы да җитештерү тупланышы белән тыгыз бәйләнгән. Башкала шәһәрләре һәм күмер бассейннары тирәсендә инде күптән формалашкан *иске промышленность районнарының* әһәмияте гаять зур.

Әмма халык һәм хуҗалыкның иске промышленность районнарында кирәгеннән артык тупланунын тискәре яклары да бар: бу бигрәк тә әйләнә-тирәнең сыйфаты үзгәрүдә чагыла. *Шуңа күрә фәнни-техник революция чорының тагын да үзенчәлеклерәк билгесе булып кечкенә һәм уртача предприятиеләр*, мини заводлар, мини ГЭСлар һ.б. булдыру юлы белән җитештерүне төрле территорияләргә урнаштыру процессы тора. «Иң яхшысы — кечкенә предприятие!» — хәзерге заман чакыруы, моның дөреслеге алга киткән илләр тәҗрибәсендә расланды.

**3. Урнашуның яңа факторлары.** Аларга иң элек фәнсыешлык һәм экологик факторлар керә.

Фәнсыешлык факторы. ФТР чорында фәнни-техник база җитештерүне урнаштыруның бик әһәмиятле факторына әверелә бара. Бу беренче чиратта эре фән үзәкләренә, ягъни зур шәһәрләргә

һәм шәһәр агломерацияләренә тартылучы фәнсыешлы иң яңа тармакларга кагыла; специальләшкән «фәнни шәһәрләр» дә барлыкка килә. Кайбер илләргә фәнни тикшеренүләрнең бер территориягә туплануы, ә кайберләренә исә, киресенчә, таралып урнашуы хас.

**Мисал.** Россиядә төп фәнни-тикшеренү үзәкләре — Мәскәү, Санкт-Петербург һәм Новосибирск. Франциянең барлык фәнни хезмәткәрләренең яртысы — Парижда, ә Япониянеке Токиода тупланган. Ә АКШта исә төп фәнни тикшеренүләр ил буйлап таралып урнашкан университетларда алып барыла.

ФТР чорында фәнне территориаль оештыруның яңа формалары да барлыкка килде. Беренче чиратта үзара охшаш характердагы ***технопарклар***[1] һәм ***технополислар***[2], аларда фундаменталь тикшеренүләрдән алып фәнсыешлы продукцияне сатуга кадәр барлык технологик процесслар башкарыла. «Парклар шау-шуы» 50 нче еллар башында ук АКШта (танылган Силикон үзәндә) башлана, аннары ул Көнбатыш Европага, Азиянең яңа индустриаль илләренә һәм башка илләргә күчә. Хәзерге вакытта технопарклар дөньяның дистәләрчә илләрендә бар.

Технополис идеясе 80 нче еллар башында Япониядә туа, аннары ул да шулай ук киң таралыш таба. Технопарклар һәм технополисларның интенсив үсүе ФТР казанышларына бәйле рәвештә электронлаштыру, автоматлаштыру, яңа материаллар, яңа технологияләр барлыкка килү белән аңлатыла.

Россиянең бик күп фәнни-җитештерү шәһәрләре, асылда, технополислар: Мәскәү янындагы Дубна, Пущино, Обнинск, Черноголовка, Протвино, Жуковский, Королев һәм Себердә — Новосибирск янындагы Академгородок. Атом энергиясе министрлыгы карамагындагы ябык ун шәһәрне, шулай ук технополислар рәтенә кертергә мөмкин: Идел буенда (Арзамас, Пенза), Уралда (Екатеринбург, Чиләбе, Златоуст) һәм Себердә (Томск, Красноярск). Гадәттә, аларны фән шәһәрләре дип атыйлар.

Э к о л о г и я   ф а к т о р ы. Элек тә булган бу факторның ФТР чорында әһәмияте тагын да артты. Территориянең, суның җитәрлек булмавы, промышленность калдыкларын чистартуга киткән чыгымнарның үсүе, индустрияләшкән һәм шәһәрләшкән районнарда мохитнең гомуми начараюы аларда җитештерүне һәм халык тупланышын чикләү өчен җитди сәбәп булды. Аерым очракларда «пычрак» производствоның бер өлеше башка районнарга күчерелә яисә бөтенләй бетерелә.

---

[1] Технопарк (фән, тикшеренү, технология паркы) — ул эре университетлар, институтлар һәм лабораторияләр янында төркемләп урнашкан фәнсыешлы фирмалар агломерациясе. Паркның төп бурычы — «фән — эшмәкәрлек» принцибы буенча фәнни идеяләрне тормышка ашыру срокларын кыскарту.

[2] Технополис — инновацион технологияләр эшләү, фәнсыешлы җитештерүләрне үстерү һәм фәнни кадрлар әзерләү белән шөгыльләнү өчен махсус төзелгән комплекслы фәнни-җитештерү шәһәрчеге.

**Мисал.** Германиянең индустриаль йөрәге дип йөртелә торган Рур районы, Икенче бөтендөнья сугышына кадәр һәм аннан соң да, Европадагы иң «пычрак» районнарның берсе иде. Табигатьне саклау буенча үткәрелгән нәтиҗәле чараларның тулы системасы аркасында андагы экологик халәт шактый яхшырды. Аерым алганда, «Рур өстендә — чиста күк йөзе» девизы астында атмосфераны саклауның махсус программасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә күп кенә производстволар ябыла яки бу районнан чыгарыла.

**Төп нәтиҗә.** *ФТР хәзерге заман производствосының барлык якларына, бөтен иҗтимагый мөнәсәбәтләр системасына, кешенең үзенә һәм яшәгән мохитенә бик нык йогынты ясый. Бөтендөнья хуҗалыгы бердәм организмга әверелә, чөнки иҗтимагый системасы һәм икътисади үсеш дәрәҗәсе нинди булуга карамастан, бер генә дәүләт тә аннан башка нормаль үсә алмый.* (8 нче йомгаклау биреме.)

## ӨСТӘМӘ ТЕКСТ (кызыклы мәгълүматлар)

[1] Олимпия уеннарыннан беренче телевизион тапшырулар 1956 елда, бу уеннар Мельбурнда барганда оештырылды. Ул тапшыруларны Австралиядә яшәүчеләр генә карады. 1960 елда Рим Олимпиадасын исә берничә күрше ил, ә 1980 елда Мәскәүдә, 1984 елда Лос-Анджелеста һәм 1988 елда Сеулда булган Олимпиадаларны 2 млрд чамасы, ә инде 1992 елда Барселонадагысын 3 млрд чамасы кеше карады. Наганодагы кышкы Олимпиаданы һәм 1998 елда Франциядә үткәрелгән футбол чемпионатын 3 млрд тан артыграк кеше карады. 2000 елда Сиднейдагы җәйге Олимпия уеннарын, 2002 елда Солт-Лейк-Ситидагы кышкы уеннарны һәм Япония белән Корея Республикасындагы бөтендөнья футбол чемпионатын — 3,5 млрд тан 4 млрд ка кадәр кеше, 2008 елда Кытайдагы җәйге Олипиаданы 4 млрд кеше карады.

[2] Йөк күтәрүчәнлеге 550 мең т булган танкерның озынлыгы 480 м, киңлеге 63 м, йөк төягәч, суга утыру тирәнлеге 30 м чамасы. Мондый судноның ишү винты өч катлы йорт биеклегендә, ә палубаларының мәйданы — 2,5 гектар.

[3] Суперкомпьютерларның тизлеге бер секундка триллион операцияләр белән исәпләнә! Шуңа да карамастан кеше интеллекты алар белән ярыша тора. Шахмат буенча дөнья чемпионнары күп тапкыр суперкомпьютерлар арасындагы «чемпионнар» белән бу уенны уйнадылар. 1996 елда Гарри Каспаров үз матчында ота, 1997 елда җиңелә, ә 2003 елда уртак нәтиҗә була. 2002 елда Владимир Крамник компьютер белән уйнаганда да җиңүче булмый.

[4] Шәхси компьютерларны (ПК) 70 нче еллар уртасында АКШ та җитештерә башлыйлар, ә хәзер аларны ел саен 200 млн данә чыгаралар. 100 кешегә исәпләгәндә иң күп компьютер Швейцариядә (90), АКШ һәм Швециядә (80), Нидерландта (72).

[5] АКШның компьютерлар җитештерүче иң зур корпорацияләре: ИБМ, «Интел» (микропроцессорлар) һәм «Майкрософт» (информацион технологияләр). «Майкрософт» корпорациясенең президенты Билл Гейтс планетаның иң бай кешесе булып санала: 2007 елда аның байлыгы 59 млрд доллар чамасы дип бәяләнде.

[6] Япониядә 6000 метрга кадәр океан тирәнлегендә эшли ала торган робот-геолог һәм ноталар «укып» электр гитарасында уйный торган робот-музыкант, ә Австралиядә сарык йонын кыркучы робот ясаганнар. АКШта роботлар водолазларны алыштыралар. ГФРда алар полициядә «эшли»: роботларга шартлаткыч куелу шиге булган автомашиналарны ачтыралар. Шулай ук укытучы-роботлар, официант-роботлар, савыт-саба юучы, җыештыручы, хезмәтче кебек роботлар бар. Хирург-роботлар барлыкка килүе медицинада сенсация ясады.

[7] Тимер юлда пар көче беренче тапкыр Англиядә 1825 елда кулланыла. Беренче тимер юл линиясе АКШта — 1830 елда, Франциядә — 1832 елда, Бельгия һәм Германиядә — 1835 елда, Австриядә 1837 елда ачыла. Россиядә гомуми куллану өчен, беренче тимер юл 1837 елда Петербург белән Царское Село арасында ачыла.

[8] 90 нчы еллар башыннан Мәскәүдә башкала өчен традицион хезмәт тармакларын — промышленность, транспорт, фән һәм мәдәният, мәгърифәт өлкәләрен кыскартулар күзәтелә. Шул ук вакытта финанслар, хезмәт күрсәтү, идарә итү һәм сәүдә сферасында эшләүчеләр саны күпкә арта. Эшлекле хезмәт күрсәтү сферасында гомумроссия күләмендә эшләүчеләрнең 1/3 еннән 1/2 енә кадәресе Мәскәүдә тупланган.

[9] Монакода, Багам, Бермуд, Мальдив утрауларында һәм Кече Антиль утрауларының күпчелегендә хезмәт күрсәтү сферасының тулай эчке продукт структурасындагы өлеше 75—90 % ка җитә.

[10] Дөньяда беренче метрополитен линиясе — Лондонда 1863 елда, ә икенчесе Нью-Йоркта 1868 елда төзелә. Хәзерге вакытта дөньяның 70 шәһәрендә метрополитен бар. Метрополитен линияләренең иң озыннары Лондон, Нью-Йорк, Париж һәм Мәскәүдә. Пассажирлар ташу күрсәткече буенча дөньяда беренче урынны (елына 3 млрд чамасы кеше) Мәскәү метрополитены алып тора.

[11] Моңа ачык мисал — Бразилиянең башкаласын Рио-де-Жанейродан бу максат белән илнең эчке өлешендә махсус төзелгән Бразилиа шәһәренә күчерү. Моннан башка илләр дә үрнәк алдылар: Нигериядә башкала Лагостан Абуджуга күчерелде, Кот-д'Ивуарда — Абиджаннан Ямусукрога, Танзаниядә — Дар-эс-Саламнан Додомага. Аргентинада да башкаланы күчерү турында карар кабул ителде, ләкин үтәлми калды.

[12] Россия Федерациясенең кайбер субъектлары территорияләрен Европа чит илләре территорияләре белән чагыштырып карасак, Архангельск өлкәсенең якынча — Франциягә, Томск өлкәсенең — Польшага, Мәскәү өлкәсенең — Даниягә, ә Краснодар краеның Австриягә тиң булуын күрербез.

[13] 90 нчы еллар башында континенталь шельфта йөздән артыграк ил нефть һәм табигый газ эзләде, ә 50 ләп ил нефть һәм газ чыгарды. Барысы 2 меңнән артыграк нефть һәм газ ятмалары, ачылып, файдалануга тапшырылды, 40 мең диңгез скважинасы бораулаңды, диңгездә корычтан һәм бетоннан ясалган берничә мең бораулау платформасы файдаланылды. Нефть һәм газ чыгару районнарында диңгезнең тирәнлеге 80 нче елларда 100 м дан 90 нчы елларда 1800 м га кадәр артты.

[14] Диңгездә бораулау платформасының биеклеге, корыч «аякларының» нигезеннән алып бораулау вышкасының очына кадәр санаганда, күп катлы йорт биеклегендә була. Мондый платформаларның авырлыгы 500—800 мең т га җитә, аларга 200—300 кеше хезмәт күрсәтә. Платформада бер-ике бораулау вышкасы, торак биналар, резервуарлар һәм вертолет өчен махсус мәйдан була (21 нче рәсемне карагыз). 90 нчы ел ахырында Канадада эшләнгән бораулау платформасының авырлыгы 1,2 млн т исәпләнә һәм ул 1 млн т авырлыктагы айсбергка каршы тора ала!

[15] Япония, АКШ һәм Көнбатыш Европа фирмалары телевизор, магнитофон һәм башка көнкүреш электрон техникасы чыгаруны Корея Республикасы, Гонконг (хәзер Сянган), Сингапур, Малайзия, Филиппин, Тайвань һәм башка дәүләтләрдә оештырдылар. Мәсәлән, Швейцариянең данлыклы «Омега» сәгать фирмасы үз капиталының беркадәр өлешен Гонконг белән Сингапурга күчерде. Голландиянең «Филипс» фирмасы Тайваньда дөньяда иң зур кинескоплар заводы салды (елына 4 млн данә).

**Китап киштәсе**

1. Максаковский В. П. Географическая картина мира.— М.: Дрофа, 2006.— Ч. 1.— Тема 4.
2. Моисеев Н.Н. Есть ли у России будущее? — М.: Зеленый мир, 1996.
3. Моисеев Н.Н. Слово о научно-технической революции.— М.: Молодая гвардия, 1985.

## БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘР ҮЗЛӘШТЕРҮ ӨЧЕН ТУПЛАНМА

**1 нче бирем.** Дәреслек текстыннан файдаланып, «Фәнни-техник революция чорында производство үсешенең төп юнәлешләре» дигән системалаштыручы таблица төзегез.

**2 нче бирем.** Алдагы сыйныфлардагы география курсларыннан алган белемнәрегезгә таянып, районнар һәм илләрнең районара һәм халыкара географик хезмәт бүленешендә специальләшүе аларның табигый шартлары үзенчәлегенә һәм ресурсларына бәйле икәнлегенә: 1) тау промышленностеннан һәм 2) авыл хуҗалыгыннан мисаллар китерегез.

**3 нче бирем.** Дәреслектә китерелгән региональ икътисади төркемнәрне һәм шулай ук ОПЕК әгъзасы булган илләрне контурлы картага төшерегез. Бу картаны халыкара икътисади интеграцияне тасвирлау өчен файдаланыгыз.

**4 нче бирем.** «Кушымта»дагы 18 нче таблицадан файдаланып, аграр, индустриаль, постиндустриаль икътисадлы илләргә мисаллар табыгыз. Аларны дәфтәрегездә таблица рәвешендә урнаштырыгыз.

**5 нче бирем.** «Кушымта»дагы 19 нчы таблицадан файдаланып, дөнья хуҗалыгының төп ун үзәген дөньяның контурлы картасына төшерегез. Аларның формалашу тарихына һәм үсеш перспективасына кыскача характеристика бирегез.

**6 нчы бирем.** Дәреслек текстыннан һәм 22 нче рәсемнән файдаланып, үсеп килүче илләрдә хуҗалыкның территориаль структурасын тасвирлагыз.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Дөньяның контурлы картасында: а) башкаласы (яки «икътисади башкала») зур шәһәр һәм шул ук вакытта диңгез порты да; б) башкаласы (яки «икътисади башкала») диңгез буена урнашмаган, ә диңгез капкасы ролен бүтән шәһәр башкаручы үсеп килүче илләрне билгеләгез. Табылган карта-схемаларны анализлап, хикәя төзегез.

**7 нче бирем.** Дәреслек текстыннан файдаланып, икътисади үсеш алган илләрдә региональ сәясәтнең төп дүрт максатын әйтегез һәм аларга кыскача характеристика бирегез.

**8 нче йомгаклау биреме.** 1. (Дәфтәрдә эшләү.) Алган белемнәрегезгә таянып, аерым факторларның производствоны урнаштыруга йогынтысын тасвирлагыз (таблица рәвешендә).

2. «Фәнни-техник революция һәм производствоны урнаштыру» дигән темага проблемалы чыгыш әзерләгез.

3. Шушы тема буенча тәкъдим ителгән берәр китапның (яки китаптагы берәр бүлекнең) язма конспектын төзегез.

## ҮЗЕГЕЗНЕҢ ҺӘМ БЕР-БЕРЕГЕЗНЕҢ БЕЛЕМНӘРЕН ТИКШЕРҮ ТУПЛАНМАСЫ

**Ничек аңлатырсыз:**

1. Ни өчен ФТР чорында производство үсешендә революция юлы төп юл булып тора?

2. Икътисадның постиндустриаль структурасы индустриаль структурадан нәрсәсе белән аерыла?

3. Хәзерге дөнья хуҗалыгының географик моделе нәрсәсе белән үзенчәлекле?

4. ФТР чорында җитештерү сферасы белән җитештермәүче сфера арасында нисбәт ни сәбәпле үзгәрде?

5. Хуҗалыкның территориаль структурасының колониаль төре нәрсәсе белән үзенчәлекле?

**Ничек уйлыйсыз:**

1. Ни өчен ФТР чорында энергетика, машина төзү һәм химия промышленносте «өч авангард» тармак санала?

2. Ни өчен 1 млн т йөк күтәрүчән супертанкер төзү проектлары тормышка ашырылмый кала?

3. Мәскәү, Париж, Лондон, Мадрид һәм Праганы мисал итеп китергәндә, Н. Н. Баранский икътисади-географик урынның нинди төрен күздә тоткан?

4. Чыгару промышленностен ни өчен еш кына пионер тармак дип атыйлар?

5. Фәнсыешлык факторын ни өчен яңа факторлар рәтенә кертергә кирәк?

**Беләсезме:**

1. Түбәндәге районнарның кайсылары яңа үзләштерелә торган районнарга керә: Канаданың төньягы, Лондон һәм Рур районнары, Россиянең төньягы, Австралиянең көнбатышы?

2. Түбәндәге диңгез акваторияләренең кайсылары төп нефть һәм табигый газ чыгару районнары: Төньяк диңгез, Балтыйк диңгезе, Урта диңгез, Фарсы култыгы, Гарәп диңгезе, Мексика култыгы?

**Булдыра аласызмы:**

1. Текстта һәм тексттагы карталарда телгә алынган түбәндәге илләрне дөньяның контурлы картасына хәтердән төшерегез: Норвегия, Швейцария, Италия, Бангладеш, Непал, БГӘ, Марокко, Чад, Танзания, Венесуэла.

2. Фәнни-техник революция, дөнья хуҗалыгы, хезмәтнең халыкара географик бүленеше, хуҗалыкның территориаль структурасы, региональ сәясәт төшенчәләренә билгеләмә бирегез.

3. Түбәндәге раслауларның ни дәрәҗәдә дөрес булуын ачыклагыз, кирәк урыннарда дөресләп җавап бирегез:

а) роботлар техникасы — ФТРның фәнсыешлы иң яңа тармакларыннан берсе;

б) бөтендөнья хуҗалыгы XVIII һәм XIX гасыр чикләрендә барлыкка килгән;

в) Япониядә халыкара специальләшү тармагы — күмер промышленносте;

г) чыгару промышленносте тармакларының урнашуына табигый ресурслар факторының йогынтысы гаять зур.

4. Түбәндәге җөмләләрне тутырып языгыз:

а) ФТР чорында фәннең производство белән бәйләнешләре аеруча үсте, производство торган саен __________ була бара.

б) Н. Н. Баранский географик хезмәт бүленешен __________ дигән.

в) Үсеп килүче илдә барлык территориянең төп үзәге, ягъни «фокусы» ролен __________ үти.

## 4 НЧЕ ТЕМАГА МЕТОДИК АЧКЫЧЛАР

### Боларны исегезгә төшерегез

1. XV—XVIII гасырларда Бөек географик ачышларның әһәмияте һәм нәтиҗәләре. (География, 6—7 нче сыйныф; Тарих, 7 нче сыйныф.) 2. Яңа заман чорында промышленность, авыл хуҗалыгы һәм транспорт үсеше. (Тарих, 7—8 нче сыйныфлар.) 3. Хәзерге җәмгыятьтә ЭВМның роле. (Информатика һәм хисаплау техникасы нигезләре, 9, 10 нчы сыйныфлар.) 4. Төшенчәләр һәм терминнар: җитештерүче сфера, җитештермәүче сфера, халык хуҗалыгы тармагы, тармакара комплекс, хезмәтнең географик (территориаль) бүленеше, территориаль планлаштыру, милли доход, концентрация.

**4 нче теманың төп идеяләре:**

1. Хәзерге фәнни-техник революция кешелек җәмгыятенә, производствога, җәмгыять белән әйләнә-тирә мохитнең үзара бәйләнешенә тамырдан үзгәрешләр кертте. 2. Хуҗалык итүнең интернациональләшүе базар икътисадының бердәм глобаль системасын барлыкка китерә.

**Төп фәнни белемнәр:**

1. Фәнни-техник революция төшенчәсе. 2. ФТР чорында производство үсешенең төп юнәлешләре. 3. Дөнья хуҗалыгы төшенчәсе. 4. Хезмәтнең халыкара географик бүленеше төшенчәсе. 5. Халыкара икътисади интеграция. 6. Дөнья хуҗалыгы структурасының төп өч тибы. 7. Дөнья хуҗалыгының пространстволы модельләре. 8. Дөнья хуҗалыгының территориаль структурасы. 9. Региональ сәясәт. 10. Урнашу факторлары.

11. Теманың төп сүзләре: 1) фәнни-техник революция, 2) дөнья хуҗалыгы, 3) дөнья хуҗалыгы географиясе, 4) хезмәтнең халыкара географик бүленеше, 5) халыкара специальләшү тармагы, 6) халыкара икътисади интеграция, 7) икътисадның аграр структурасы, 8) икътисадның индустриаль структурасы, 9) икътисадның постиндустриаль структурасы, 10) дөнья хуҗалыгының Үзәге, Периферияse, Ярымпериферияse, 11) хуҗалыкның территориаль структурасы, 12) нык алга киткән район, 13) иске промышленность районы, 14) яңа үзләштерелеп килә торган район, 15) региональ сәясәт, 16) урнашу факторы, 17) технопарк, технополис.

## Сез нәрсәләр эшли белергә тиеш

1. Гомуми төшенчәләргә анык билгеләмәләр биреп, фәнни-техник революциягә һәм бөтендөнья хуҗалыгына характеристика бирә белергә. 2. Аерым фикерләрне һәм гомумиләштерүләрне чагыштыру һәм исбатлау өчен текст материалларын, картографик һәм график материалларны куллана белергә. 3. Укылган китапның (бүлек, кисәк) язма конспектын төзи белергә. 4. Билгеле бер темага проблемалы чыгыш әзерләргә.

## 5 НЧЕ ТЕМАНЫҢ ПЛАН-СХЕМАСЫ



## 5 нче тема. БӨТЕНДӨНЬЯ ХУҖАЛЫГЫ ТАРМАКЛАРЫ ГЕОГРАФИЯСЕ

Фәнни-техник революция, бөтендөнья хуҗалыгы, хезмәтнең халыкара географик бүленеше кебек бик әһәмиятле төшенчәләрне үзләштереп, производство урнашу факторлары белән танышканнан соң, бөтендөнья хуҗалыгы тармаклары географиясен өйрәнүгә күчү табигый булыр. Алар бөтендөнья хуҗалыгының икътисади һәм социаль географиясе, шулай ук бөтендөнья икътисады нигезендә географ-галимнәр һәм икътисад белгечләре тарафыннан өйрәнелә.

### 1. ПРОМЫШЛЕННОСТЬ ГЕОГРАФИЯСЕН ӨЙРӘНӘБЕЗ

**1. Промышленность — материаль җитештерүнең беренче әйдәп баручы тармагы.** Бөтендөнья промышленностенда 500 млн чамасы кеше эшли. Соңгы йөз ел эчендә промышленность җитештерүе 50 тапкыр үсте, үсешнең 3/4 е XX гасырның икенче яртысына туры килә («Кушымта»дагы 20 нче таблицаны кара). Кайчан барлыкка килүенә карап, барлык промышленность тармаклары, гадәттә, өч төркемгә бүленә.

**Иске тармаклар** дип йөртелә торган беренче төркем промышленностьта кискен үзгәрешләр елларында барлыкка килә, һәм аңа ташкүмер, тимер рудасы, металлургия, тимер юлның хәрәкәт итүче составларын җитештерү, суднолар төзү һәм туку промышленносте керә. Безнең көннәрдә бу тармак, кагыйдә буларак, кими баручы темплар белән үсә. Ләкин бөтендөнья промышленносте географиясенә аның йогынтысы әле һаман да шактый ук зур.

Икенче төркемгә XX гасырның беренче яртысындагы фәнни-техник прогрессны билгеләүче **яңа тармаклар** — автомобиль төзү, алюминий эретеп табу, пластмасса һәм химик сүсләр җитештерү керә. Кагыйдә буларак, алар кызурак темплар белән үсә (конвейерлардан бөтен дөньяда көн саен 200 мең чамасы автомобиль төшә). Ләкин соңгы вакытта темплар элеккеге кебек үк зур түгел. Алар, нигездә, икътисади үсеш алган илләрдә тупланган, шул ук вакытта үсеп килүче илләрдә дә инде шактый киң таралган булулары аркасында, бөтендөнья промышленносте географиясенә зур йогынты ясауларын дәвам итәләр.

Ниһаять, өченче төркемне ФТР чорында барлыкка килгән һәм күбесенчә фәнсыешлы тармакларга, ягъни югары технология тармакларына караган **иң яңа тармаклар** тәшкил итә. Алар — микроэлектроника, хисаплау техникасы, роботлар төзү, информатика

индустриясе, атом һәм аэрокосмос производстволары, органик синтез химиясе, микробиология промышленносте — ФТРны тизләтүчеләр. Кагыйдә буларак, алар безнең көннәрдә аеруча кызу һәм тотрыклы темплар белән үсә. Фәнсыешлы һәм югары технологияле тармакларның эшкәртү промышленностендагы тулай эчке продуктта алып торган өлеше югары булган илләргә мисал — ГФР, АКШ һәм Япония. Аларның бөтендөнья промышленносте географиясенә йогынтысы арта бара, тик бу йогынты әлегә икътисади үсеш алган һәм яңа индустриаль илләр белән чикләнә.

ФТР чорында промышленность тармаклары структурасында үзгәрешләр иске тармаклар өлешенең кимүе, яңаларының, бигрәк тә иң яңаларының өлеше артуы белән бәйләнгән. Аның территориаль пропорцияләре дә үзгәрә. Индустрияләшү нәтиҗәсендә үсеп килүче илләрнең өлеше шактый тиз арта: XXI гасыр башында ул 35—40 % ка җитте (Кытай белән). Хәзерге вакытта Көньякның күпчелек илләре дөнья илләренең «беренче унлыгына» һәм, билгеле инде, «беренче егермесенә» керәләр («Кушымта»дагы 21 нче таблицаны карагыз).

Әмма шулай да югары технологияләр тармагы продукциясен җитештерү, нигездә, әлеккеге кебек үк, Төньяк илләрендә тупланган.

Бөтендөнья промышленностеның территориаль структурасы беренче чиратта эре промышленность районнарының урнашуы белән билгеләнә. Алар дөньяда йөздән артыграк. Мондый районнарның күплеге ягыннан Европа чит илләре, БДБ, Көнчыгыш Азия һәм Төньяк Америка аерылып тора. Алар шулай ук Көньяк, Көньяк-Көнбатыш һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиядә, Латин Америкасында, Австралиядә һәм Африкада да бар.

**2. Ягулык-энергетика промышленносте: производствоның үсүе һәм куллануның артуы, үсешнең өч этабы.** Кешелек цивилизациясенең бөтен тарихы ягулык һәм энергиянең төрле төрләрен үзләштерүгә бәйле икәнен сез инде беләсез. Энергетика ФТР чорында да производствоны үстерү һәм урнаштыруга гаять зур йогынты ясый. Бу яктан караганда, хәтта ул «дөнья белән идарә итә» дип әйтәләр.

Дөньяда беренчел энергия ресурсларын җитештерү һәм куллану һаман арта бара: 1900 елда 1 млрд т чамасы шартлы ягулыктан 2005 елда 15 млрд т га җитте. Бу үсеш темплары **бөтендөнья энергетика кризисы**, барыннан да бигрәк, нефть кризисы башланган 70 нче еллар уртасына кадәр аеруча зур булды. Кризистан соң үсеш кискен акрынайды.

Ләкин бу дөньякүләм тенденцияләр артында бик зур географик төрлелек яшеренгән. Беренчедән, Төньяк белән Көньяк арасындагы аерма, икенчедән, зур регионнар арасындагы аерма (бигрәк тә Азия чит илләре), өченчедән, аерым илләр арасындагы аерма.

Үсеп килүче илләрдә җитештерелә торган энергия ресурсларының, бигрәк тә нефтьнең, күбрәк өлеше АКШ, Көнбатыш Европа һәм Япониягә җибәрелә; бу илләр үзләре импортка бәйлелекләрен киметергә тырышсалар да, әле ул һаман да

югары. Нәтиҗәдә күп кенә илләр һәм континентлар арасында тотрыклы «энергетик күперләр» барлыкка килде.

Соңгы ике гасырда ягулык-энергетика промышленносте үзенең үсешендә төп ике этап узды. XIX гасырда һәм XX гасырның беренче яртысында *күмер этабы* күзәтелде: бөтендөнья ягулык-энергетика балансында күмер ягулык буларак нык өстенлек итте. Аннары икенче, *нефть-газ этабы* башланды. Бу нефть һәм газның, каты ягулык белән чагыштырганда, өстенлекләре күп булу белән аңлатыла.

70 нче еллар урталарындагы кризис бөтендөнья энергетикасы үсешенең яңа, өченче этапка күчә башлавын — минераль ягулыктан атом-төш энергетикасына, яңадан торгызыла торган, традицион булмаган ягулык чыганакларына күчүне тизләтер дип фараз ителгән иде. Әмма көтелгәнчә булып чыкмады. Аңа шактый дәрәҗәдә нефтьнең яңадан арзанаюы сәбәп булды, күрәсең XXI гасыр башында аның бәясе яңадан кискен күтәрелсә дә, *якын киләчәктә бөтендөнья энергия куллану структурасында радикаль үзгәрешләр, мөгаен, булмастыр.* (1 нче бирем.)

**3. Нефть, газ, күмер промышленносте — бөтендөнья энергетикасының нигезе.** Нефть промышленностеның әһәмияте аеруча зур.

Нефть кешегә бик борынгы заманнардан билгеле булган. Аның яктырту, җылыту, дарулар ясау өчен кулланылуы турында Геродот һәм Плутарх язмаларында искә алына. Керосин лампасы, ә аннары эчке янулы двигатель уйлап табылу XIX гасырда нефть чыгаруны үстерүгә этәргеч була. XX гасырда беренчел энергия ресурсларының бер генә төре дә кешелекнең икътисади һәм иҗтимагый үсешенә нефть ясаган кадәр йогынты ясамады.

Хәзерге вакытта нефть дөньяның 100 дән артыграк илендә чыгарыла. Дөньяда чыгарыла торган нефть (аның күләме 3,9 млрд т га якын) икътисади үсеш алган һәм үсеп килүче илләр арасында 35 : 65 нисбәтендә бүленә. Аның 40 % чамасы ОПЕК илләренә туры килә, аерым эре регионнардан Азия илләре, беренче чиратта Фарсы култыгы илләре аркасында аерылып тора.

**Мисал.** Дөньядагы барлык тикшерелгән нефть запасының 2/3 се һәм бөтен дөньяда чыгарыла торган нефтьнең 1/3 е Фарсы култыгы илләренә туры килә. Бу региондагы дүрт илнең һәркайсы елына 100 әр млн т нефть чыгара (Согуд Гарәбстаны, Иран, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Кувейт).

Нефть чыгару күләмнәре буенча калган регионнарның урнашу тәртибе: БДБ, Латин Америкасы, Африка, Төньяк Америка, Европа чит илләре, Австралия һәм Океания. Аерым илләрне карасак, 2005 елда беренче өч урынны Согуд Гарәбстаны, Россия һәм АКШ били. Шулай ук Иран, Мексика, Кытай, Венесуэла 150 млн нан 200 млн тоннага кадәр нефть чыгара (24 нче рәсем).




23

23 нче рәсем. XX гасыр дәвамында дөньяда беренчел энергия ресурсларын файдалану структурасындагы үзгәрешләр

24 нче рәсем. Дөньяда төп нефть чыгаручы районнар

25 нче рәсем. Халыкара нефть сәүдәсе

4 нче таблица

**2005 елда дөньяда ягулыкның төп төрләрен һәм энергия җитештерү**

| Җитештерү | Дөнья-да | Шул исәптән | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | БДБ | Европа чит илләре | Азия чит илләре | Африка | Төньяк Америка | Латин Америкасы | Австралия һәм Океания |
| Нефть, млн т | 3900 | 575 | 265 | 1570 | 467 | 455 | 518 | 30 |
| Табигый газ, млрд м$^3$ | 2760 | 765 | 300 | 615 | 160 | 705 | 175 | 40 |
| Күмер, млн т | 5865 | 465 | 685 | 2900 | 255 | 1100 | 85 | 375 |
| Электр энергиясе, млрд кВт-сәг | 18 200 | 1280 | 3660 | 6320 | 500 | 4840 | 1260 | 280 |


КАНАДА
145
НОРВЕГИЯ
140
РОССИЯ
480
ВЕЛИКОБРИТАНИЯ
85
США
310
КАЗАХСТАН
65
АЗЕРБАЙДЖАН
25
КИТАЙ
200
ИРАН
180
МЕКСИКА
190
85
80
35
АЛЖИР
ЛИВИЯ
ЕГИПЕТ
ИНДИЯ
35
ВЕНЕСУЭЛА
155
130
ОАЭ
КОЛУМБИЯ
27
125
НИГЕРИЯ
90
ИРАК
МАЛАЙЗИЯ
40
130
КУВЕЙТ
БРАЗИЛИЯ
85
АНГОЛА
60
ИНДОНЕЗИЯ
55
505
САУДОВСКАЯ АРАВИЯ
АВСТРАЛИЯ
20
АРГЕНТИНА
35
55
Нефть чыгару (елына млн т)




КАНАДА
145
Западная Европа
220
310
РОССИЯ
США
550
600
270
ЯПОНИЯ
КИТАЙ
130
Сев. Африка
230
1200
Ближний и Средний Восток
Карибский район
160
160
Зап. Африка
Юго-Вост. Азия
120
Южная Америка
45
АВСТРАЛИЯ
Төп халыкара нефть һәм нефть продуктлары ташу юнәлешләре
150
Нефть һәм нефть продуктлары экспорты (елына млн т)
260
Нефть һәм нефть продуктлары импорты (елына млн т)


США
НОРВЕГИЯ
НИДЕРЛАНДЫ
ВЕЛИКОБРИТАНИЯ
185
85
60
90
656
КАНАДА
РОССИЯ
КАЗАХСТАН
25
520
США
60
55
УЗБЕКИСТАН
ТУРКМЕНИЯ
ЯПОНИЯ
МЕКСИКА
90
АЛЖИР
90
ИРАН
2
КИТАЙ
50
40
35
ЕГИПЕТ
70
ИНДИЯ
30
60
3
ВЕНЕСУЭЛА
30
45
ОАЭ
45
КАТАР
МАЛАЙЗИЯ
12
БРУНЕЙ
20
НИГЕРИЯ
САУДОВСКАЯ АРАВИЯ
75
ИНДОНЕЗИЯ
АВСТРАЛИЯ
35
45
АРГЕНТИНА
Цифрлар белән күрсәтелгән:
1 ГФР 15
2 Пакистан 30
3 Таиланд 20
45 Табигый газ чыгару млрд м³ да
Төп халыкара газ ташу юнәлешләре

26

КАНАДА
65
160
ПОЛЬША
200
ФРГ
РОССИЯ
310
1030
США
80
85
КАЗАХСТАН
УКРАИНА
60
60
ТУРЦИЯ
ЧЕХИЯ
КИТАЙ
2200
ЯПОНИЯ
ИНДИЯ
430
60
КОЛУМБИЯ
135
ИНДОНЕЗИЯ
АВСТРАЛИЯ
250
ЮАР
350
80 Күмер чыгару (елына млн т)
Төп халыкара күмер ташу юнәлешләре

27

Барлык нефтьнең 40—45 % ы халыкара сәүдәгә чыга. Бөтендөнья хуҗалыгында аны чыгару районнары белән кулланучы районнар арасында гаять зур *территориаль өзеклек* барлыкка килде. Шунлыктан нефтьне диңгез юлы белән ташу торган саен арта барып, «нефть күперләре» ясалуга китерде. (2 нче бирем.)

Бөтендөнья газ промышленносте шулай ук шактый нык үсеш алды. Ул төп өч сәбәп белән аңлатыла: табигый газның тикшереп табылган запасларының гаять зур, аны транспортлауның чагыштырмача арзан, күмер һәм нефтькә караганда экологик яктан «чистарак» ягулык булуы. Шуңа күрә дә XX гасыр урталарыннан дөньяда табигый газ чыгару 14 тапкыр артты һәм 2,7 трлн $м^3$ дан артып китте (4 нче таблицаны карагыз).

Әле күптән түгел генә табигый газның барлыгы диярлек Төньяк илләрендә, беренче чиратта АКШта, Канадада, шулай ук Европа чит илләрендә һәм БДБ илләрендә чыгарылып килде.

Ләкин соңгы вакытта Көньякның кайбер илләре, башлыча Көньяк-Көнчыгыш һәм Көньяк-Көнбатыш Азия, Төньяк Африка һәм Латин Америкасы илләре газны гаять зур күләмдә җитештерүчеләргә әверелделәр.

Табылган барлык газның 30 % ы халыкара сәүдәгә чыга. Аның күп өлеше Россия, Төркмәнстан, Нидерланд, Алжир һәм башка илләрдән магистраль газүткәргечләр буйлап экспортка китә. [1]. Газның калган өлеше сыекландырыла һәм сыегайтылган килеш метан ташучы махсус танкерларда экспортка җибәрелә. Гадәттә, сыегайтылган табигый газны үсеп килүче илләр экспортлыйлар, бу хәл «газ күперләре» ясалуга китерде.

**Мисал.** 70 нче елларда Алжир беренче булып сыегайтылган табигый газны Көнбатыш Европага экспортлый башлый. Соңрак аны БГӘ Япониягә чыгара башладылар. Ләкин 90 нчы елларда беренче урынга Индонезия һәм Малайзия чыкты, алар газның төп импортеры Японияне тәэмин итәләр.

Фаразларга караганда, табигый газны чыгару һәм куллану тагын да үсәчәк. (3 нче бирем.)

Нефть һәм газ промышленностьлары конкуренциясенә карамастан, күмер промышленностеның әһәмияте югалмый, бөтен дөньяда күмер чыгару күләме 6 млрд т га якынлашты. Күмер чыгаручы аерым регионнардан Азия чит илләре, Төньяк Америка, Европа чит илләре, БДБ илләре, ә аерым илләрдән Кытай, АКШ, Россия, Һиндстан, Австралия бигрәк тә аерылып тора.

Күмер, нигездә, аны чыгаручы илләрнең үзләрендә күбрәк кулланыла; шулай да аның 10 % ы чамасы дөнья базарына җибәрелә. Ташкүмерне экспортлауга Австралия, АКШ, КАР, Индонезия, Колумбия, Кытай һәм Канада специальләшкән. Нәтиҗәдә бу тармакта да тотрыклы диңгез «күмер

26 нчы рәсем. Дөньяда төп табигый газ чыгаручы районнар
27 нче рәсем. Дөньяда төп күмер чыгаручы районнар

күперләре» формалаша. Ташкүмер экспортлаучы илләргә Россия дә керә, ләкин аның күләме электкегедән кимрәк. (4 нче бирем.)

**4. Электр энергетикасы — «авангард өчлек» тармакларының берсе.** ФТР чорында, бигрәк тә электронлаштыру, комплекслы автоматлаштыру, информатикалаштыру үсә барган саен, дөньяда электр энергиясен җитештерү кызу темплар белән тотрыклы рәвештә арта һәм 2005 елда 18 трлн кВт·сәг кә җитте. Моңа тиңдәшле рәвештә ***дөнья ягулык-энергетика балансы***[1] электрлашуы да артачак.

Дөньяда җитештерелә торган электр энергиясенең 55 % ы Төньяк илләренә, ә 35 % ы Көньяк илләренә (Кытай белән) туры килә. Бу күрсәткеч буенча «беренче ун ил» рәтенә Төньякның җиде, Көньякның өч иле керә. Ләкин җитештерелгән электр энергиясенең җан башына исәпләнгән кыйммәтләре аермасы әле һаман да бик зур.

**Мисал.** Дөньяда электр энергиясе кеше башына уртача 3 мең кВт · сәг исәбеннән җитештерелә. Икътисади үсеш алган илләрдә ул 5—15 мең кВт · сәг чикләрендә тирбәлә, ә Азия һәм Африка илләренең күпчелегендә 1 мең кВт · сәг кә дә җитми (Һиндстанда — 700 кВт · сәг). [2].

Электр энергиясе җитештерү структурасында бөтен дөньяда һәм аерым алынган илләрдә күмер, мазут һәм табигый газда эшләүче *җылылык электростанцияләре* (ҖЭС) өстенлек итә. Тулаем бөтен дөньяда җитештерелгән электр энергиясенең 63 % ы аларга туры килә. Ә инде ҖЭСларда энергия җитештерү күләме буенча АКШ, Кытай, Россия, Япония, Һиндстан һәм ГФР лидерлардан санала. Ләкин ҖЭСларның барлык энергия күләмендәге өлеше буенча дөньядагы башка илләр аерылып тора.

**Мисал.** Польша һәм КАР кебек «күмерле», Согуд Гарәбстаны, Кувейт, БГӘ һәм Алжир кебек «нефтьле» илләрдә җитештерелгән электр энергиясенең барысын да диярлек җылылык электростанцияләре бирә.

Дөньяда җитештерелә торган барлык электр энергиясенең 19 % ы чамасын *гидроэлектростанцияләр* (ГЭС) биреп тора. ГЭСта җитештерелгән энергиянең гомуми күләме буенча бигрәк тә Канада, АКШ, Бразилия, Россия һәм Кытай аерылып тора. Ләкин гидроэнергетикага юнәлгәнлек ГЭСның өлеше гаять югары булган илләрдә күренә.

**Мисал.** Дөньяның икътисади үсеш алган илләреннән фәкать Норвегиядә генә барлык электр энергиясен гидроэлектростанцияләр бирә. [3]. Үсеп килүче илләр арасында андый мисалларны шактый күп китереп була. Аңа иң ачык мисал — Бразилия, анда электр энергиясенең 95 % ын ГЭС бирә. БДБ илләреннән бу төркемгә Кыргызстан һәм Таҗикстан керә.

Күпчелек Төньяк илләрендә икътисади гидропотенциал шактый

---

[1] Ягулык-энергетика балансы электрлашуы — ул электр энергиясен җитештерү өчен сарыф ителгән беренчел энергетик ресурсларның өлеше белән үлчәнә. 90 нчы еллар ахырында бөтен дөньяда бу өлеш инде 1/3 дән артып китте.

дәрәҗәдә, хәтта тулысынча диярлек файдаланыла. *Шуңа күрә дөнья гидроэнергетикасының төп үсеш перспективасы Көньяк илләре,* беренче чиратта Бразилия һәм Кытай *белән бәйләнгән.* [4].

Өченче урында — *атом электростанцияләре* (АЭС), дөньяда җитештерелгән барлык электр энергиясенең 17 % ы аларга туры килә. Алар дөньяның 31 илендә эшли. Атом электростанциясендә җитештерелгән энергиянең иң күбе АКШ, Франция, Япония, ГФР, Россиягә туры килә. Җитештерелгән тулай энергия күләмендә АЭСның тоткан өлеше буенча Литва, Франция һәм Бельгия алда. [5]. Атом энергетикасы кирәкле чимал белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителгән. Канада, Австралия, Нигер, Намибия, АКШ һәм Россия — АЭС өчен кирәкле уран концентратын ($U_3O_8$) төп җитештерүчеләр. 1986 елда элеккеге СССРның Чернобыль АЭСында булган авариядан соң дөнья атом энергетикасының үсеш темплары сизелерлек түбәнәйде. Күп илләр АЭС төзүгә мораторий игълан иттеләр. Ләкин Кытай, Һиндстан, Япония, Корея Республикасында АЭС төзү тукталып тормады, ә соңгы вакытта Россия һәм АКШта бу эшкә керештеләр.

Энергиянең традицион булмаган (альтернатив) чыганакларына дөньяда җитештерелә торган барлык электр энергиясенең фәкать 1 % ы чамасы туры килә. Монда сүз иң элек *геотермаль электростанцияләр* (ГеоТЭС) турында бара. Үзәк Америка илләрендә, Филиппинда һәм Исландиядә электр энергиясенең шактый өлешен шул электр станцияләре бирә. Исландиядә геотермаль сулар биналарны җылыту, җылы су белән тәэмин итү һ. б. максатларда кулланыла. [6]. *Су күтәрелешенә нигезләнгән электростанцияләр* фәкать берничә илдә — Франция, АКШ, Канада, Россия, Һиндстан һәм Кытайда гына бар. *Кояш электростанцияләре* (КЭС) 30 дан артыграк илдә эшли. Күп кенә илләр соңгы вакытта *җил энергиясеннән* киңрәк файдалану чараларын күрәләр. Аларның күбесе Көнбатыш Европа илләрендә (Дания, ГФР, Бөекбритания, Нидерланд), АКШта (Калифорния), Һиндстанда һәм Кытайда. [7]. Альтернатив энергия чыганакларын киңрәк куллану перспективасы күбесенчә аларның экологик яктан «чиста» булуына бәйләнгән.

Электр энергиясен халыкара күчерүләр магистраль энергия тапшыру линияләре (ЛЭП) ярдәмендә башкарыла. Ул бигрәк тә Европа чит илләренә, АКШ һәм Канадага хас. Аңа Россия дә катнаша. (5 нче бирем.)

**5. Тау (чыгару) промышленносте.** Бөтендөнья промышленность производствосында тау промышленносте өлешенең акрынлап кими баруына карамастан, ул *халыкара географик хезмәт бүленешенә, халык хуҗалыгы географиясенә гаять зур йогынты ясавын дәвам итә.*

Файдалы казылмаларны чыгару районы белән аларны файдалану районнары арасындагы территориаль өзеклекне бетерү, континентара йөк агышларын булдыру, ресурсларга бай яңа җирләрне үзләштерү беренче чиратта нәкъ менә тау промышленностена бәйләнгән.

Бөтен дөньяда (БДБ илләреннән башка) 10 мең чамасы зур һәм уртача зурлыктагы ягулык, руда һәм руда булмаган чимал чыганаклары ачыкланган. Тау промышленностеның ассортиментында уннарча төр чимал, ләкин алар күләм ягыннан бер-берләреннән бик күпкә аерылалар. Билгеле булганча, дөньяда күмер һәм нефть кенә дә ел саен 1 млрд тоннадан артыграк чыгарыла, тимер рудасы чыгару бу дәрәҗәдән артты. Бокситлар һәм фосфоритларның еллык чыгарылышы йөзләрчә миллион тонна, марганец рудасы, күкерт, бакыр (файдалы компонентка күчереп исәпләгәндә) уннарча миллион тонна, полиметаллар — миллионнарча, аккургаш һәм никель — йөз меңнәрчә, уран, кобальт — ун меңнәрчә тонна, алтын меңнәрчә тонна исәпләнә. [8].

70 нче еллар урталарына кадәр икътисади алга киткән Көнбатыш илләрен минераль чимал белән, нигездә, үсеп килүче илләр тәэмин итеп килде. Әмма 70 нче елларда **бөтендөнья чимал кризисы** башлану белән минераль-чимал хуҗалыгына карата Көнбатышның фикере тамырдан үзгәрде. *Ул чималны саклап тотуга һәм күбрәк үз ресурсларын куллануга йөз тотты.* Нәтиҗәдә Канада, Австралия һәм КАРның роле күтәрелде, һәм бу илләрдә чимал мәсьәләсенә зур игътибар бирелә.

Безнең көннәрдә Көнбатыш Европа илләре, АКШ һәм Япония минераль чималга булган ихтыяҗларының 1/3 өлешен үсеп килүче илләрдән китерү юлы белән канәгатьләндерәләр, ә җитмәгән өлешен үзләрендә чыгаралар һәм шулай ук Канададан, Австралиядән һәм КАРдан китертәләр.

**Мисал.** Дөнья базарына ел саен 650 млн т тимер рудасы чыгарыла. Аның иң зур экспортерлары, бер яктан, Бразилия, Венесуэла, Һиндстан булса, икенче яктан — Австралия, Канада һәм КАР. «Тимер рудасы күперләренең» тотрыклы формалашуы беренче чиратта нәкъ шул илләргә туры килә.

Халыкара географик хезмәт бүленеше нәтиҗәсендә бөтендөнья хуҗалыгында сигез **«тау промышленносте булган бөек держава»** барлыкка килә. Аңа икътисади үсеш алган илләрдән — АКШ, Канада, Австралия һәм КАР, үсеп килүче илләрдән — Кытай, Бразилия, Һиндстан, ә икътисади күчеш илләреннән Россия керә. Тау промышленносте үсеш алган Украина, Казахстан, Мексика һәм кайбер башка илләр беркадәр дәрәҗәдә аларга якынлаша. Ә «өченче эшелонны» халыкара специальләшүнең зуррак берәр тармагы белән аерылып торган илләр тәшкил итәләр.

**Мисал.** Чили, Перу һәм Замбия өчен бу — бакыр промышленносте, Малайзия — аккургаш чыгару, Гвинея һәм Ямайка — бокситлар чыгару, ә Марокко — фосфоритлар чыгару.

ФТР казылма байлыкларның тупланышына, бассейн һәм чыганакларның икътисади-географик урынына, аларны ачык юл белән чыгару мөмкинлегенә таләпләрне арттырды. Ләкин монда ачык юл белән чыгару урыннарының мохиткә тискәре йогынтысын да исәпкә алырга кирәк (6 нчы бирем.)

**6. Металлургия промышленносте: ориентлашу типлары.** Озак вакытлар буена теләсә кайсы илнең икътисади куәте беренче чиратта диярлек металл кою күләмнәре белән билгеләнеп килде.

70 нче елларда энергетика һәм чимал кытлыгы йогынтысында, типик иске тармак буларак, металлургиянең үсеш темплары кискен акрынайды.

Беренче чиратта ул кара металлургиягә кагыла. 70 нче елларның урталарына кадәр бу тармак югары темплар белән үсте. [9]. Аннары темплар кискен акрыная. Мондый акрынаюның сәбәпләре күп: ФТР чорында производствоның металлсыешлыгы кимү, мохитне саклау чаралары үткәрелү һ. б. Шулай да XXI гасыр башында бөтен дөньяда корыч кою 1100 млн т га җитте.

*Шул ук вакытта Төньяк һәм Көньяк илләре арасында пропорцияләр үзгәрә башлый.* Дөньяда эретеп табылган барлык корычның 1/2 е инде хәзер Көньяк илләренә (Кытай белән бергә) туры килә. Кара металлургиянең үсеп килүче илләргә шундый миграциясе, бер яктан, аларның индустрияләштерү ихтыяҗларыннан булса, икенче яктан, «пычрак» производстволарны Япониядән, Көнбатыш Европадан, АКШтан үсеп килүче илләргә күчерү сәясәте белән бәйле.

Корыч кою күләме буенча дөнья регионнарында бигрәк тә Азиядәге чит илләр аерылып тора, чөнки анда Кытай, Япония, Корея Республикасы һәм Һиндстан кебек эре җитештерүчеләр бар.

**Мисал.** Кытайда кара металлургия бигрәк тә тиз үсә. Кытай Халык Республикасы игълан ителгән 1949 елда илдә кара металлургия бөтенләй диярлек булмый. 1970 елда корыч кою — 18 млн т, 2000 елда 128 млн т га җитә. Ә 2006 елда бу күрсәткеч 420 млн т була. Бу күрсәткеч буенча Кытай хәзер дөньяда беренче урынны алып тора.

Европа чит илләрендә (бигрәк тә ГФР, Италия, Франция, Бөекбритания), Төньяк Америкада (АКШ, Канада), БДБ илләрендә (Россия, Украина) корыч кою масштаблары зур.

Бөтендөнья кара металлургия географиясенең тарихи формалашуы төрле типтагы ориентлашу йогынтысында булды. Гасыр ярым дәвамында ул *ташкүмер бассейннарына ориентлашып* үсте. АКШта, Европа чит илләрендә, Россиядә, Украина һәм Кытайдагы төп металлургия базалары шулай барлыкка килде. Икенче урында «тарту көченә» карап, тимер рудасы бассейннарын күздә тоту торды. *Ләкин ФТР чорында тармакның ягулык-чималга исәп тотуы, гомумән, кими. Баштарак тимер рудасы һәм кокслана торган ташкүмер* ташу юнәлешләренә ориентлашу өстенлек итте. Нәтиҗәдә Япония, Көнбатыш Европа илләренең һәм шулай ук өлешчә АКШның кара металлургиясе диңгез портларына якын урында төзелә башлый. Соңгы вакытта *кулланучыны исәпкә алу* бигрәк тә көчәеп китте. Бу күбесенчә гаять зур комбинатлар кору урынына җиңелрәк урнаштырыла торган специальләшкән мини-заводлар төзүгә күчү белән аңлатыла.

Дөнья базарына ел саен 350 млн т кара металл прокаты чыгарыла. Аны төп экспортлаучылар — Россия, Германия, Украина һәм Япония, ә импортлаучылар — АКШ һәм Кытай. (7 нче бирем.)

Җитештерү күләме ягыннан төсле металлургия кара металлургиядән 20 тапкыр чамасы калыша. Төсле авыр, легирлаучы һәм затлы металлар рудасында, кагыйдә буларак, файдалы компонентлар аз була һәм төсле металлургия, гадәттә, шул руда чыгарыла торган илләргә һәм районнарга бәйле була. Азия, Африка һәм Латин Америкасының күп кенә илләрендә төсле металлургиянең колониаль чорда ук барлыкка килүе нәкъ шуның белән аңлатыла.

**Мисал.** Бакыр промышленностеның дөньяда иң зур районнарыннан берсе Үзәк Африкада барлыкка килгән. Ул Бакыр поясы дип атала һәм Конго ДР белән Замбия территориясеннән борынгы диңгезнең яр сызыгы буйлап 500 км га сузыла. Бу ятмалар моннан 600 млн еллар элек барлыкка килгән. Хәзер монда бакыр рудасы чыгарыла, кара һәм чистартылган бакыр коела (30 нчы рәсемне карагыз).

Авыр металл рудаларыннан аермалы буларак, төсле җиңел металлар рудалары, аеруча алюминий рудасы, файдалы компонентлар микъдары буенча, тимер рудасына якын тора, ташу өчен уңайлы. *Шунлыктан тармакның алюминий промышленносте — чималның чыккан урыны белән әзер продуктны куллану урыны бер-берсеннән ерак урнашканлыкка тагын бер мисал.* Дөньяда чыгарыла торган бокситларның 1/3 еннән артыграгы экспортка китә, аны диңгез буйлап ташу юллары уртача 7 мең км дан ким түгел.

**Мисал.** Дөньяда иң күп боксит чыгаручы район — Төньяк Австралиядәге Йорк ярымутравында. Биредә арзанлы ачык ысул белән чыгарыла торган бокситларны, эшкәртеп, глиноземга әверелдерәләр һәм башка илләргә озаталар.

АКШ, Көнбатыш Европа һәм Япониядә соңгы ике-өч унъеллыкта төсле металлургиянең үсеше, кара металлургия кебек үк, бик нык кимеде. Үсеп килүче илләрдә исә, киресенчә, бу тармак шактый тиз үсә башлады. Күп кенә яңа үзләштерелгән районнар барлыкка килүе нәкъ шуңа бәйләнгән. Әлбәттә, бу — әлеге илләрнең индустрияләштерү юлына басуларын күрсәтүче билгеләрнең берсе. Шул ук вакытта бу икътисади үсеш алган Көнбатыш илләренең табигатьне саклау сәясәтенә үтә таләпчәнлек күрсәтеп «пычрак» производстволарның экологик зыянын шушы юл белән киметергә омтылу нәтиҗәсе. (8 нче бирем.)

**7. Машина төзү: тармак һәм территориаль структурада уңай үзгәрешләр.** Машина төзү тармагының 200 ел элек Англиядә промышленность революциясе вакытында барлыкка килүен сез тарих курсыннан хәтерлисездер. *Безнең көннәрдә эшләүчеләр саны буенча да (100 млн нан артык кеше), продукциянең бәясе буенча да ул бөтендөнья промышленностеның барлык тармаклары арасында беренче урынны алып тора.* Бөтендөнья промышленность про-

дукциясе бәясенең 1/3 өлеше машина төзүгә туры килә.

Машина төзүнең тармак структурасында барлык тармакларның иске, яңа һәм иң яңага бүленүе аермачык күренә. Шуңа тиңдәшле рәвештә аларның үсеш темплары да бер-берсеннән кискен аерыла. Иске тармаклар я стабильләшкән, я төшенкелек хәлендә.

**Мисал.** Дөньядагы суднолар төзү промышленностенда күтәренкелек 60 нчы елларга һәм 70 нче елларның беренче яртысына туры килә. Энергетика кризисы башланып, нефть ташулар кискен кимегәч, бу тармак озакка сузылган торгынлык хәленә төшә.

Кагыйдә буларак, *яңа тармакларда* җитештерүнең беркадәр үсеше күзәтелә. Автомобиль промышленносте моңа мисал була ала. [10]. ФТРның төп этәргечләреннән саналган *иң яңа тармаклар* исә тиз һәм тотрыклы үсеш күрсәтәләр.

**Мисал.** 50 нче еллар уртасында бөтен дөньяда электроника промышленносте 10 млрд доллар продукция җитештергән, ә XXI гасыр башында — 1,5 трлн долларлык. Хәзер ул машина төзү структурасында беренче урынга чыкты.

Дөньяда машина төзүнең территориаль структурасы да бик мөһим үзгәрешләр кичерә. Әле күптән дә түгел бу тармак продукциясенең 9/10 ын Төньяк илләре, беренче чиратта «зур җиделек» әгъзалары, бигрәк тә АКШ, ГФР һәм Япония бирә иде. Аннары Көньяк илләренең, иң әлек яңа индустриаль илләрнең — Кытай, Һиндстан, Бразилия, Мексика һәм Аргентинаның өлеше арта башлады. Хәзер ул 1/4 дән артты.

Бөтендөнья икътисади картасында машина төзү промышленностеның дүрт регионын аерып күрсәтергә мөмкин. Беренче регион — Төньяк Америка. Анда машина төзү продукциясенең төрле катлаулылыктагы барлык төрләре дә җитештерелә. Икенче регион — Европа чит илләре. Алар, нигездә, машина төзүнең киң куллану продукциясен җитештерәләр, ләкин шул ук вакытта кайбер иң яңа тармакларда үз позицияләрен дә саклыйлар. Өченче регион — Көнчыгыш һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия. Монда Япония алда бара. Ул да шулай ук, машина төзүнең киң куллану продукциясе белән бергәттән, иң югары технологияле әйберләр дә җитештерә. Бу регионга иң әлек көнкүреш электроникасы әйберләре җитештерүгә специальләшкән «Азия юлбарыслары» һәм Кытай керә.

**Мисал.** Көнчыгыш һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия илләре 90 нчы еллар урталарында ук инде бөтендөнья электроника промышленносте продукциясенең 15% тан артыграгын эшләп биргәннәр, ә 2005 елда — 50% ка якынын. Персональ ЭВМ эшләп чыгару буенча Корея Республикасы һәм Тайвань бөтендөнья лидерлары рәтенә керде. Ә видеомагнитофоннар эшләп чыгару буенча Корея Республикасы Япониядән кала икенче урынны алды. Телевизорлар һәм радиоалгычлар җитештерү буенча Кытай дөньяда беренче урынга чыкты.

28


КАНАДА
США
55
30
23
ШВЕЦИЯ
РОССИЯ
95
70
УКРАИНА
19
КАЗАХСТАН
КИТАЙ
370
ЯПОНИЯ
140
ИНДИЯ
11
МАВРИТАНИЯ
22
ВЕНЕСУЭЛА
300
БРАЗИЛИЯ
40
ЮАР
280
АВСТРАЛИЯ
Тимер рудасы чыгару (елына млн т)
Төп халыкара тимер рудасы ташу юнәлешләре

29


КАНАДА
16
США
92
15
МЕКСИКА
ВЕЛИКОБРИТАНИЯ
16
ФРГ
44
ПОЛЬША
8
РОССИЯ
66
42
УКРАИНА
14
ТУРЦИЯ
20
ФРАНЦИЯ
КИТАЙ
333
113
ЯПОНИЯ
ИНДИЯ
34
БРАЗИЛИЯ
22
Цифрлар белән күрсәтелгән:
1 Италия 23
2 Испания 11
3 Бельгия 11
4 Корея Респ. 48
Корыч кою (елына млн т)
Корыч прокаты экспортының төп юнәлешләре

30

5 нче таблица

**2000 елда дөньяда кара металлургия**

| Житештерү | Бөтен дөнья | Шул исәптән | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | БДБ илләре | Европа чит илләре | Азия чит илләре | Африка | Төньяк Америка | Латин Америкасы | Австралия һәм Океания |
| Тимер рудасы, млн т | 1520 | 185 | 25 | 440 | 60 | 85 | 345 | 280 |
| Корыч, млн т | 1100 | 115 | 213 | 573 | 18 | 109 | 63 | 9 |

28 нче рәсем. Дөньяда төп тимер рудасы чыгаручы районнар

29 нчы рәсем. Дөньяда төп корыч кою районнары

30 нчы рәсем. Үзәк Африкада бакыр поясы

6 нчы таблица

**2005 елда машина төзү продукциясенең кайбер төрләрен житештерү**

| Бөтен дөнья һәм «беренче унлык» илләре | Жиңел автомобильләр, млн данә | Бөтен дөнья һәм «беренче унлык» илләре | Телевизорлар, млн данә |
|---|---|---|---|
| Бөтен дөнья | 66,5 | Бөтен дөнья | 150,0 |
| АКШ | 12,0 | Кытай | 58,0 |
| Япония | 10,8 | Төркия | 12,5 |
| ГФР | 5,8 | Малайзия | 9,6 |
| Кытай | 5,7 | Корея Респ. | 9,2 |
| Корея Респ. | 3,7 | Польша | 7,8 |
| Франция | 3,5 | АКШ | 7,6 |
| Испания | 2,8 | Испания | 6,0 |
| Канада | 2,8 | Франция | 5,4 |
| Бразилия | 2,5 | Бразилия | 5,4 |
| Бөекбритания | 1,8 | Япония | 5,3 |

Дүртенче регион — Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге. Бу регионга кергән илләрнең күпчелеге өчен машина төзү халыкара специальләшүдә төп тармак булып санала.

АКШ һәм ГФРда машина төзү барлык экспортның 1/2 ен, Японидә 2/3 сен тәшкил итә. Азиянең яңа индустриаль илләрендә җитештерелгән көнкүреш электроникасы тулысынча диярлек экспортка китә. (9 нчы бирем.)

**8. Химия промышленносте: төп регионнар.** XX гасыр химия промышленносте көчле үсеш алган гасырга әверелде. Машиналар төзелеше белән беррәттән, ул хәзерге индустриянең иң динамик үсүче тармагыннан санала.

Машина төзү тармагындагы кебек, химия промышленностенда да төп регионнар аерылып тора: Европа чит илләре, Төньяк Америка, Көнчыгыш һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия. Аларның һәркайсында таухимия промышленносте, минераль ашламалар, төп химия продукциясе, бигрәк тә органик синтез һәм полимер материаллар җитештерү үсеш алган. Үсеп килүче илләрдә әле күптән түгел генә бу тармак, нигездә, чимал табудан гыйбарәт иде. Ләкин энергетик кризистан соң, химия промышленносте нефть һәм газ ресурсларына бай булган Азия, Африка һәм Латин Америкасы илләрендә бик күпкә тизрәк үсә башлады. Фарсы култыгы, Төньяк Африка илләрендә, Мексика һәм Венесуэлада эре нефть химиясе комплекслары сафка басты.

Хезмәтнең мондый бүленеше нәтиҗәсендә төп органик синтез продуктлары һәм полимер материаллар җитештерү үсеп килүче илләрдә туплана бара, ә фәнсыешлы катлаулы «югары кат» продукциясе АКШ, Көнбатыш Европа һәм Японидә эшләп чыгарыла. (10 нчы бирем.)

**9. Урман һәм агач эшкәртү промышленносте: ике пояс.** Дөньяның урман һәм агач эшкәртү промышленносте географиясе, нигездә, урман ресурсларының урнашуына бәйле.

Төньяк урман поясы чикләрендә башлыча ылыслы токымнарның үзагачыннан такта, агач плитәләр, целлюлоза, кәгазь, картон ясыйлар. Россия, Канада, Швеция һәм Финляндия өчен урман һәм агач эшкәртү промышленносте — халыкара специальләшүнең бик мөһим тармаклары.

Көньяк урман поясы чикләрендә яфраклы агачларны эшкәртәләр. Анда урман промышленностеның өч ареалы бар: Бразилия, Тропик Африка, Көньяк-Көнчыгыш Азия. Анда әзерләнгән агач диңгез юлы белән Японидә, Көнбатыш Европага җибәрелә, ә калганы күбесенчә утынга тотыла.

Көньяк пояс илләрендә кәгазь җитештерү өчен еш кына агач булмаган чимал файдаланыла: бамбук (Һиндстанда), багасса (Перуда), сизаль (Бразилия һәм Танзаниядә), джут (Бангладешта). Шулай булуга карамастан бу илләр кәгазь җитештерү буенча, бигрәк тә җан башына исәпләгәндә, бик нык калышалар. [11].

**10. Җиңел промышленность: географиядәге үзгәрешләр.** Җиңел промышленностьта географик үзгәрешләр аның төп тармагында — туку промышленностенда

аеруча ачык күренә. XXI гасыр башында дөньяда табигый һәм химик сүслэрдән 130 млрд $м^2$ дан артыграк тукыма җитештерелде. Әгәр вак һөнәрчеләрне дә исәпкә алсак, бу тармак барлык илләрдә дә бар.

Бөтендөнья туку промышленностенда биш төп регион барлыкка килгән: Көнчыгыш Азия, Көньяк Азия, БДБ, Европа чит илләре һәм АКШ. Аларның һәркайсында киҗемамык тукыма һәм химик сүс тукымалары җитештерү өстенлек итә, ә калган тармаклар (йон, җитен, ефәк) азрак урын алган. Әмма соңгы вакытта бу регионнар арасындагы нисбәт сизелерлек үзгәрде. 50 нче еллардан башлап тукымалар һәм киемнәр җитештерү буенча икътисади үсеш алган илләрнең бөтен дөньядагы өлеше туктаусыз кими бара; иске промышленность районнары бетү алдында тора. Тукымалар чыгару буенча элек дөньяда беренче урынны алып торган Бөекбритания хәзер тукыма җитештерүче илләрнең икенче унлыгы ахырында. Ул тукымаларны иң күп читкә чыгаручыдан читтән кертүчегә әверелде.

Төньяк илләреннән аермалы буларак, арзан эшче көчләргә нигезләнгән Көньяк илләренең туку промышленносте бик тиз үсә. Киҗемамык тукымалар эшләп чыгару буенча беренче урынны — Кытай, икенче урынны Һиндстан алып тора. Көньяк илләрендә җитештерелгән тукымаларның күп өлеше Көнбатыш илләренә экспортка китә. Моның шактый өлеше әзер киемгә дә кагыла. АКШ, Көнбатыш Европа, Япония кибетләрендә Кытайдан (Сянган белән), Бангладеш, Төркия, Һиндстан, Мексика һәм башка үсеп килүче илләрдән алынган арзан киемнәр һәм трикотаж сатыла. (11 нче бирем.)

**11. Промышленность һәм мохит.** Кешелек дөньясының промышленность эшчәнлеге мохит белән бик тыгыз бәйләнгән. Нәкъ менә промышленность — күпчелек табигый ресурсларны төп кулланучы. Антропоген ландшафтларны — тау промышленносте, шулай ук шәһәр ландшафтларын нәкъ менә промышленность барлыкка китерде. *Шуның белән беррәттән, промышленность үсеше табигатьтән файдалануның күп кенә проблемаларын кискенләштерде.* Беренче чиратта бу «пычрак» производстволарга кагыла.

Җылылык энергетикасы әйләнәтирәгә гаять күп микъдарда зарарлы матдәләр чыгара, атмосфераның газ составын үзгәртә, суларның температурасын күтәрә. Атом энергетикасы барлыкка килү радиоактив калдыкларны күмүдә гаять зур проблема тудыра. АЭСлардагы аварияләр, бигрәк тә Чернобыльдәге (Украина) кебек, коточкыч зур масштаблы һәлакәтләр мохиткә тагы да зуррак куркыныч тудыра. Алар тыныч атомны да сак куллану зарурлыгын аңлатты. Гидроэнергетика башкалардан күпкә «чистарак» санала, ләкин аңа бәйләнгән гидротехник корылмалар, бигрәк тә биек плотиналар (буалар) һәм сусаклагычлар, еш кына экологик тигезләнешнең башка төрле бозылуларына китерә.

Тау промышленностеның үсеше туфрак катламын боза, табигать ландшафтларын «ашый», ә соңыннан ул җирләрне зур чы-

гымнар тотып торгызу зарурлыгын тудыра. Диңгездән файдалы казылмалар чыгару да бөтендөнья океаны экологиясе өчен куркыныч. Агач эшкәртү барышында да туфрак катламы бозыла. Металлургия үсеше мохиттә тимер, кургаш, аккургаш, бакыр, терекөмеш һәм башка металлар микъдарын арттыра, ә бу кешеләрнең сәламәтлегенә зур куркыныч тудырырга мөмкин. Химия һәм нефть химиясе промышленностеның үсеше еш кына һава, су һәм туфрак катламының агулануына китерә; мондый предприятиеләрдәге аварияләр аеруча куркынычлы. [12]. Бу шулай ук целлюлоза-кәгазь промышленностена да кагыла.

Ләкин шуны да онытырга ярамый: галимнәр һәм инженерлар, югарыда саналган проблемаларга җавап итеп, табигатьне саклау технологияләрен эшләп кенә калмадылар, бәлки производствоны экология факторын исәпкә алып урнаштыру принципларын да эшләделәр. Бу беренче чиратта «пычрак» производстволарны урнаштыруга карый.

## 2. АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ БАЛЫКЧЫЛЫК ГЕОГРАФИЯСЕН КҮЗӘТӘБЕЗ

**1. Авыл хуҗалыгы — материаль җитештерүнең икенче төп тармагы.** Авыл хуҗалыгы — материаль җитештерүнең иң борынгы гына түгел, бәлки аеруча киң таралган тармагы. Дөрестән дә, авыл хуҗалыгы һәм аңа эргәдәш тармаклар — урман хуҗалыгы, аучылык, балыкчылык белән шөгыльләнмәгән бер генә ил дә юк. Бөтен дөньяда болар белән 2,5 млрд кеше шөгыльләнә.

Авыл хуҗалыгы киң таралган һәм бик күптөрле дә: галимнәр аның 50 ләп төрен аералар. Ләкин аларның барысын ике зур төркемгә берләштерергә мөмкин. Беренчедән, ул — **товарлыклы авыл хуҗалыгы.** Аңа орлык алмашлы чәчү әйләнешле интенсив игенчелек, азык әзерләүле интенсив терлекчелек, бакчачылык һәм яшелчәчелек, шуның белән бергә парга калдырулы һәм яткын җирле экстенсив авыл хуҗалыгы һәм көтүлекле терлекчелек керә. Икенчедән, **кулланучы (аз товарлыклы) авыл хуҗалыгы.** Ул артта калган сабанлы һәм китмәнле игенчелек, көтүлекле терлекчелек, күчмә яки ярымкүчмә терлекчелек, примитив җыючылык, аучылык һәм балыкчылыкны үз эченә ала.

Икътисади үсеш алган илләрдә, бигрәк тә постиндустриаль стадиягә ирешкәннәрендә, товарлыклы авыл хуҗалыгы аеруча өстенлек итә. ФТР чорында ул механикалаштыру һәм химиялаштерүнең мөмкин саналган иң югары дәрәҗәсенә ирешә [13], ә хәзер микроэлектроника, автоматлаштыру (бройлер чебешләре җитештерү), селекция, генетика һәм биотехнологиянең иң яңа казанышларын производствога кертү аның үсешендә төп роль уйный. Бу төркемдәге илләрнең агропромышленность комплексы **агробизнес** формасын алды, ул, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү белән бергә, аны эшкәртү,

саклау, кирәкле урынга илтү һәм сатуны, шулай ук техника, ашламалар эшләп чыгаруны үз эченә ала. *Эшнең болай куелышы авыл хуҗалыгына индустриаль характер бирә.*

Үсеп килүче илләрдә товарлыклы да һәм кулланучы да авыл хуҗалыгы очрый.

Товарлыклы хуҗалык — ул иң әйбәт җирләрне алып торган, яхшы оештырылган эре плантацияләр һәм фермалар. Алар ялланган эшче көчләрне, машиналар, ашламалар һәм ясалма сугаруны киң файдаланалар. Продукцияне эчке, бигрәк тә тышкы базарны исәпкә алып җитештерәләр, шуның белән үзенә бертөрле дәүләт эчендә дәүләт тәшкил итәләр. Ләкин мондый плантацияләр теге яисә бу культураны үстерү өчен уңайлы шартлар булган урыннарда, гадәттә, аерым утраулар рәвешендә урнашалар.

*Үсеп килүче илләрдә традицион кулланучы (яки аз товарлыклы) авыл хуҗалыгының үсемлекчелек юнәлеше өстенлек итә.* АКШ һәм Европадан аермалы буларак, ул терлекчелектән аерым алып барыла. Аз товарлыклы сектор йөз миллионнарча вак һәм үтә вак аерым хуҗалыклардан тора. Алар, нигездә, иң «арзан» калория бирүче куллану культуралары үстерәләр һәм, кагыйдә буларак, гаиләне чак-чак кына тәэмин итәләр. Бу секторда шулай ук урманнарны кисеп-яндырып игенчелек белән шөгыльләнү дә сакланып калган. Ә җир эшкәртүдә төп корал булып һаман да агач сука, яхшы дигәндә тимер калаклысы, һәм китмән хезмәт итә. Авыл хуҗалыгын интенсивлаштыру дәрәҗәсе буенча көньякның шулкадәр артта булуы бер дә гаҗәп түгел.

Бөтендөнья трактор паркында 26—27 млн машина исәпләнә, ләкин үсеп килүче илләргә аның 5—6 млн гына туры килә. Фәкать АКШта гына да тракторлар саны барлык үсеп килүче илләрдәгедән күбрәк. Күпчелек алга киткән илләрдә 1 га сөрү җиренә 60—80 кг минераль ашлама кертәләр, ә Африкада Сахарадан көньяккарак — 10 кг гына. Аларда бөртекле ашлыкның уртача уңышы 15—20 ц/га, ә икътисади алга киткән Көнбатыш илләрендә 35—50 ц/га исәпләнә. Авыл хуҗалыгында хезмәт җитештерүчәнлеге икътисади үсеш алган илләрдәгедән 20—25 тапкыр түбәнрәк.

**2. «Яшел революция» төшенчәсе.** «Яшел революция» икътисади үсеш алган илләрдә башлана. 60 нчы елларда ул үсеп килүче илләргә дә күчә, һәм шул вакыттан башлап бу төшенчә киң кулланыш тапты.

**«Яшел революция» ул — авыл хуҗалыгын заманча агротехника нигезендә үзгәртеп кору. Бу — фәнни-техник революциянең аерым бер чагылышы.**

«Яшел революция» төп өч өлештән тора. Ул — бөртекле культураларның тиз өлгерә торган яңа сортларын булдыру. Бу юнәлеш уңышны кискен күтәрергә булышлык итә һәм ул чәчүне ике, өч һәм хәтта дүрт тапкыр үткәрү мөмкинлеген ача. Икенчедән, ирригацияне киң куллану, чөнки яңа сортларның иң яхшы сыйфатлары ясалма сугару шартларында гына

ачылуы ихтимал, һәм, ниһаять, өченчесе — заманча техника, ашламалар һәм башка химикатларны киң файдалану.

*«Яшел революция»,— һичшиксез, бик әһәмиятле һәм прогрессив күренеш.* Шуның нәтиҗәсендә үсеп килүче кайбер илләр бөртекле ашлыкка булган ихтыяҗларын үзләре канәгатьләндерүгә ирештеләр. Бөртекле культураларның уңышы ике-өч тапкыр артты. Машиналар һәм ашламалар да күбрәк кирәк була башлады. Шуңа да карамастан «яшел революция» өметне тулысынча аклый алмады.

Беренчедән, ул аерым урыннарда гына, күбесенчә Мексикада, Көньяк, Көнчыгыш һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиянең кайбер илләрендә генә киң таралды, ә башка регионнарга исә бөтенләй диярлек кагылмады.

«Яшел революция»не Мексикада башланды дип әйтергә мөмкин, чөнки 60 нчы елларда югары уңыш бирүче кыска сабаклы, кызгылт төстәге бодай сорты Мексикада табылды. Аннары ул Һиндстан, Пакистан һәм башка кайбер Азия илләрендә тарала. Шул вакытта диярлек Филиппинда яңа «могҗиза дөге» сортын чыгаруга ирештеләр, ул да шулай ук уңышның нык артуын тәэмин итте.

Икенчедән, ул эре хуҗалар һәм чит ил компанияләре кулындагы җирләрдә генә тарала, ә традицион кулланучы сектор исә бөтенләй диярлек үзгәрешсез кала. Икенче төрле әйтсәк, *ул үсеп килүче илләрдә авыл хуҗалыгының арттыгын, табигать шартларына караганда, күбрәк социаль-икътисади сәбәпләрдән булуын ачык күрсәтте.*

**3. Үсемлекчелек. Бөртекле культуралар — бөтендөнья авыл хуҗалыгының нигезе.** Бөртекле культуралар бөтен дөньяда эшкәртелә торган барлык мәйданның 1/2 өлешен алып тора. Чәчүлекләр, нигездә, кешеләрнең таралып урнашуына туры килә. Дөнья күләмендә бөртекле ашлык җитештерү даими рәвештә арта бара һәм 90 нчы елларның икенче яртысыннан елына 2,3 млрд т дәрәҗәсендә кала. *Бөртекле ашлык хуҗалыгы, образлы итеп әйткәндә, өч икмәктән — бодай, дөге һәм кукуруздан тора.* Алар тулай җыемның 4/5 ен бирә (31 нче рәсемне карагыз) һәм кешеләрнең азык энергиясенең яртысын диярлек тәэмин итә.

Бодай — кешелек дөньясының яртысының диярлек төп икмәге.

Инде белгәнегезчә, академик Н. И. Вавилов (1887—1943) бу культураның килеп чыгу үзәкләре Алгы Азиядә һәм Урта диңгез буенда булуын ачыклаган. Моннан ул акрынлап бөтен дөньяга таралган. Безнең көннәрдә бодай кеше яши торган барлык континентларда үстерелә. Бодай кырларының төп поясы — төньяк ярымшар буйлап, ә аннан кечкенәрәк икенче пояс көньяк ярымшар буйлап сузылган. Ел әйләнәсенең һәр аенда да Җир шарының төрле почмакларында бу культура уңышы җыела. [14].

Бодай 70 кә якын илдә игелә, әмма аның тулай җыемының күп

өлеше берничә илгә генә туры килә. АКШ, Канада, Австралия, Кытай, Франция һәм шулай ук Россия һәм Украинада махсус бодай игү районнары барлыкка килде.

**Мисал.** Бодайны иң күп үстерүче җирләрнең берсе — АКШның Үзәк тигезлекләре. Ул төньякта Канаданың дала провинцияләренә барып тоташа. Бу иксез-чиксез киңлекләр, XX гасыр башында ук, «бодай бизгәге» кузгалган чорда сукаланып беткән. Биредә, нигездә, югары сыйфатлы, каты бодай игәләр. Виннипег шәһәрен Канаданың «бодай башкаласы» дип йөртәләр.

Дөге — шулай ук барлык халыкның яртысы өчен диярлек икмәкне алыштыручы төп азык. Ул — безнең эрага кадәр Кытайда игелә башлаган бик борынгы культураларның берсе. Бодай кебек үк, дөге дә соңрак башка континентларга тарала. Безнең көннәрдә дөге үстерү белән йөзләгән илләр шөгыльләнсә дә, бөтендөнья җыемының 9/10 өлеше Азиядәге «дөге» илләренә туры килә. Дөньядагы барлык сугарулы мәйданнарның 2/3 өлешен дөге алып тора.

**Мисал.** Индонезия һәм Япониядәге дөге кырлары эшкәртелә торган мәйданның 2/3 өлешен, ә Филиппинда 9/10 өлешен алып тора.

Кукуруз Мексикада «туган», Яңа Дөнья ачылганнан соң, дөньяның башка районнарына да күчерелгән. Бу культура чәчүлекләре территориаль яктан күбесенчә бодай чәчүлекләре белән туры килә. Кукурузны бөртеккә генә түгел, бәлки яшел масса алу өчен дә үстерү соңгы вакытта аның таралу зонасын киңәйтте. Ләкин төп җитештерүче илләр булып АКШ, Кытай һәм Бразилия санала.

**Мисал.** Дөньяда кукуруз игүнең төп районы — АКШның Олы күлләреннән көньяктарак урнашкан кукуруз поясы. Монда бу культураны үстерү өчен шартлар бик уңай. Аны үстерүдә Айова штаты бигрәк тә дан тота.

Дөньяда җитештерелә торган бөртекле ашлыкның, башлыча бодай белән кукурузның, 10—15 % ы бөтендөнья базарына чыгарыла. Аны төп экспортлаучылар — бөртекле ашлык хуҗалыгы халыкара специальләшү тармагы булып саналган АКШ, Канада, Австралия, Франция, Аргентина. Мәсәлән, Канада һәм Австралия — бодайның, ә Аргентина кукурузның еллык җыемының 80 % ын башка илләргә чыгара.

Терлек азыгы өчен үстерелгән ашлык, нигездә, Көнбатыш Европа илләренә һәм Япониягә, ә азык-төлек ашлыгы үз ашлыгы җитмәгән үсеп килүче илләргә чыгарыла. Россия уңыш күп җыелган елларда ашлыкны экспортка чыгара башлады.

Соңгы вакытка кадәр Россия һәм БДБның башка илләре терлек азыгы һәм азык-төлек өчен күпләп ашлыкны чит илләрдән керттеләр. Ләкин соңгы елларда бу импорт шактый кимеде.

**4. Үсемлекчелек. Башка азык-төлек культуралары.** Кешеләрне азык-төлек белән тәэмин итүдә бөртеклеләрдән тыш майлы үсемлекләр, бүлбеле, шикәрле, тонус

31

31 нче рәсем. Бөртекле культураларның тулай җыемы структурасы

32 нче рәсем. Дөньяда бодай җитештерелә торган төп районнар

33 нче рәсем. Дөньяда дөге җитештерүче төп районнар

34 нче рәсем. Дөньяда шикәрле культуралар җитештерүче төп районнар

7 нче таблица

**2005 елда дөньяның бөртекле ашлык хуҗалыгы**

| Җитештерү | Бөтен дөнья | Шул исәптән | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | БДБ | Европа чит илләре | Азия чит илләре | Африка | Төньяк Америка | Латин Америкасы | Австралия һәм Океания |
| Бодай, млн т | 600 | 90 | 125 | 235 | 15 | 90 | 25 | 20 |
| Дөге, млн т | 600 | 3 | 10 | 540 | 15 | 10 | 20 | 2 |
| Кукуруз, млн т | 640 | 20 | 70 | 170 | 25 | 270 | 75 | бик аз |




32


США
10
БРАЗИЛИЯ
10
КИТАЙ
160
КНДР
6
ЯПОНИЯ
10
9
РЕСПУБЛИКА КОРЕЯ
ИНДИЯ
130
30
МЬЯНМА
35
БАНГЛАДЕШ
25
ТАИЛАНД
12
ФИЛИППИНЫ
35
ВЬЕТНАМ
50
ИНДОНЕЗИЯ
Дөге игүнең төп районнары
Дөгенең ватаны
Дөге җитештерү (елына млн т)
Төп халыкара дөге ташу юнәлешләре

33


ПОЛЬША
13
ФРГ
27
ВЕЛИКОБРИТАНИЯ
8
ФРАНЦИЯ
31
ИСПАНИЯ
8
УКРАИНА
19
РОССИЯ
22
США
28
33
КУБА
32
МЕКСИКА
46
48
КОЛУМБИЯ
350
БРАЗИЛИЯ
82
6
КИТАЙ
ЯПОНИЯ
ИНДИЯ
ПАКИСТАН
48
280
62
ТАИЛАНД
ФИЛИППИНЫ
24
23
ИНДОНЕЗИЯ
МАВРИКИЙ
АВСТРАЛИЯ
32
1
2
Цифрлар белән күрсәтелгән:
1 Италия 8
2 Төркия 14
Шикәр камышы җитештерүнең төп районнары
Шикәр чөгендере җитештерүнең төп районнары
25 Шикәр камышы җитештерү (елына млн т)
15 Шикәр чөгендере җитештерү (елына млн т)
Шикәр камышының ватаны
Төп халыкара шикәр камышы ташу юнәлешләре

34

35



35 нче рәсем. Дөньяда төп сүсле культуралар һәм табигый каучук җитештерүче районнар

36 нчы рәсем. Кайбер илләрдә мөгезле эре терлекләрнең баш саны



бирүче үсемлекләр, яшелчә, җиләк-җимеш культуралары да киң кулланыла. Бөртекле культуралардан алар күп хезмәт куюны таләп итүләре белән аерыла.

Майлы культуралар кешенең азык рационында бөртеклеләрдән соң икенче урынны алып тора. Кулланыла торган майларның якынча 2/3 өлеше — үсемлек мае; Азия, Африка һәм Латин Америкасы илләре халыкларының рационында аның өлеше бигрәк тә зур. Соя җыю буенча дөньяда беренче урынны — АКШ (дөньядагы җыемның 1/2 өлешеннән күбрәк), арахис буенча — Һиндстан, зәйтүн буенча Италия алып тора.

Бүлбеле азык культураларының иң киң таралганы — бәрәңге. Аның туган җире — Көньяк Америка, ләкин хәзер инде бу культура башлыча төньяк ярымшарның урта поясы культурасына әверелде. Бәрәңге җыемы буенча дөньяда беренче урынны Кытай, Россия, Һиндстан, АКШ, Украина һәм Польша алып тора.

Халыкның туклануында шикәрле культуралар зур роль уйный. Дөньяда ел саен 145—150 млн т дан артыграк шикәр җитештерелә: якынча 2/3 се — шикәр камышыннан, 1/3 е шикәр чөгендереннән алына. Бу культураның икесе дә күп хезмәт куюны таләп итә, һәм икесе дә бер үк төрле продукт — шикәр бирә, ләкин аларның үсү ареаллары бөтенләй үзгә. Шикәр камышын күбесенчә аның «икенче ватаны» булган Америкада, тропик һәм субтропик климатлы районнарда үстерәләр. Шикәр чөгендере — урта пояс культурасы. Аны төп җитештерүчеләр — Россия, Украина, Европа чит илләре һәм Төньяк Америка илләре (34 нче рәсемне карагыз).

Тонус күтәрүче культуралар сыйфатында, гадәттә, чәй, кофе һәм какао кулланыла. Аларның барысы да тропикларда (чәй шулай ук субтропикта да) үстерелә һәм аларның ареалы шактый чикләнгән.

Чәйнең туган җире — Кытай. Ул Европада XVII гасырда гына мәгълүм була, ләкин аны тиз йөрешле, өч мачталы җилкәнле чәй суднолары (чәй клиперлары) белән китертә башлагач, ул гаять тиз популярлашып китә. Хәзер дөньяда җыелган барлык чәйнең 4/5 ен Азия илләре, аеруча Һиндстан, Кытай, Шри-Ланка бирә. Ә кофе һәм какао культуралары, вакыт үтү белән, үзләренең «тору урыннарын» алыштырдылар. Кофеның туган җире — Африка, ләкин безнең көннәрдә барлык кофеның 2/3 сен Латин Америкасы илләре, бигрәк тә Бразилия, Колумбия бирә. [15]. Какао, киресенчә, чыгышы белән Америкадан, ләкин хәзер башлыча Африканың Гвинея яр буенда җитештерелә.

Кешеләрнең тормыш хәле яхшыра барган саен, аларның туклануында яшелчә һәм җиләк-жимешнең роле арта бара. [16]. Аларда сәламәтлек өчен кирәкле микроэлементлар һәм витаминнар бар.

Майлы, шикәрле культураларның, җиләк-җимешнең һәм бигрәк тә тонусны күтәрүче культураларның шактый өлеше дөнья базарына чыгарыла. Үсеп килүче илләр күбесенчә төп экспортер, ә икътисади үсеш

алган илләр төп импортерлар булып торалар.

**5. Үсемлекчелек. Азык булмаган культуралар.** Сүсле культуралардан аеруча әһәмиятлесе — мамык; дөньяда мамык җитештерү 25 млн тоннага җитә. Мамык культурасын үстерү буенча беренче урында иң борынгы мамыкчылык районы — Азия илләре, аннан кала — Америка һәм өченче урында Африка илләре тора (35 нче рәсемне карагыз).

Сүсле башка культуралар — җитен, бигрәк тә сизаль һәм джут бик киң таралмаган. Бөтен дөньяда җитен үстерүнең 3/4 өлеше — Россия һәм Белоруссиягә, джутның Бангладешка туры килә. Табигый каучук җитештерү бигрәк тә бер урында тупланган булуы белән аерылып тора, аның 85 % ын Көньяк-Көнчыгыш Азия илләре, аеруча Таиланд, Индонезия һәм Малайзия бирә. Мамык, джут, табигый каучук — дөнья сәүдәсендә әһәмиятле товарлар. Наркотиклар белән контрабанда сәүдәсе бик зур масштаб алды. Колумбия һәм Азиянең кайбер илләре — аның төп җитештерүчеләре. «Яшерен икътисадның» бер тармагы буларак, наркобизнес гаять зур күләмдә керем ала. Аңа каршы кискен көрәш алып барыла.

**6. Терлекчелек: төп өч тармак.** Терлекчелек, бөртекле культуралар кебек, һәркайда диярлек таралган, өстәвенә болыннар һәм көтүлекләр мәйданы сөрү җирләреннән өч тапкыр зуррак. Терлекчелек продукциясенең төп өлешен уртача пояс илләре бирә. Шуны да исәпкә алырга кирәк: җитештерелгән бөртекле ашлыкның яртысы диярлек фураж буларак файдаланыла.

Бөтендөнья терлекчелек географиясе беренче чиратта терлекләрнең урнашуына бәйле. Аларның гомуми саны 4,5 млрд башка якынлашып килә. Биредә өч тармак төп рольне уйный.

Сөтнең барлыгын да диярлек һәм итнең 1/3 еннән күбрәге мөгезле эре терлек үрчетү (1,3 млрд баш) нәтиҗәсендә алына. Интенсив сөт һәм ит-сөт терлекчелеге урта поясның урманлы һәм урман-далалы зоналарында ныграк үсеш алган. Биредә терлекләрне аранда яки көтүлектә асрыйлар. Иткә терлекне уртача һәм субтропик поясларның корылыклы районнарында үрчетәләр, анда экстенсив күчмә көтүлекле терлекчелек өстенлек итә. АКШ, Канада, Аргентина һәм Австралиянең кайбер районнарында зур мәйданлы товарлыклы хуҗалыклар (ранчо) — чын мәгънәсендә «ит фабрикалары» барлыкка килде.

Дуңгызчылык (1,1 млрд баш) дөньядагы барлык ит продукциясенең 2/5 сен бирә. Ул бигрәк тә халык тыгыз урнашкан өлкәләрдә һәм эре промышленность үзәкләрендә, интенсив терлекчелек һәм бәрәңге үстерү районнарында күбрәк үсеш алган. Бөтен дөньяда дуңгыз үрчетүнең яртысы чамасы Азиягә, күбрәге Кытайга туры килә.

Ит-йон юнәлешендәге сарык асраучылык (1 млрд баш чамасы) — дымлы һәм чагыштырмача йомшак климатлы районнарда, ә инде нәфис һәм ярымнәфис йонлы сарыклар асрау корырак районнарда урнашкан.

Дөньяда ел саен 250 млн тоннадан артыграк ит җитештерелә: аның иң күбе дуңгыз ите, аннары сыер, кош һәм сарык ите. Бу күрсәткеч буенча иң алда баручы илләр төркеменә Кытай, АКШ, Бразилия, Франция һәм Россия керә. Ләкин гомуми һәм җан башына ит куллану күләме буенча аерым илләр бик нык аерылып торалар.

**Мисал.** Көнбатышның икътисади үсеш алган илләрендә елына җан башына уртача 80—100 кг, ә үсеп килүче илләрдә 15—20 кг ит туры килә. Моның рекордсмены — Яңа Зеландия, анда җан башына 400 кг га кадәр ит кулланыла!

Дөньяда елына — 500 млн т сөт (иң алда АКШ, Россия, Һиндстан, ГФР, Франция), 700 млрд данә йомырка (Кытай, АКШ, Япония), 2,5 млн т йон җитештерелә (Австралия, Кытай, Яңа Зеландия). (13 нче бирем.)

**7. Авыл хуҗалыгы һәм мохит.** Кешеләрнең мең еллар дәвамында авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүләре мохиткә гаять зур йогынты ясады, кыр һәм көтүлек антропоген ландшафтлары барлыкка килде.

Авыл хуҗалыгының экстенсив үсеше чорында җирләрне сөрү һәм урманнарны кисү мохиткә йогынтының төп юлы булды. Азия, Африка һәм Латин Америкасының күпчелек илләре өчен ул хәзер дә шулай булып кала.

XX гасыр урталарыннан интенсив авыл хуҗалыгы илләрендә терлекчелекнең алга китүе әйләнәтирә мохитнең пычрануына китерде. Ләкин авыл хуҗалыгын химияләштерүнең мохиткә тискәре йогынтысы бигрәк тә зур булды.

**Мисал.** Безнең көннәрдә бу тармакта 100 меңләп төрле химик препаратлар кулланыла. Басуларга ел саен 150 млн т химик ашламалар һәм 2—3 млн т төрле агулы химикатлар сибелә.

Авыл хуҗалыгын химияләштерүнең икътисади файдасы бик зур. Ләкин, шуның белән беррәттән, химик ашламаларны күп һәм контрольсез куллану аларның шактый өлеше елга һәм күлләргә, җир асты суларына эләгүенә китерә, үсемлекләр үсешенә һәм туфрак катламына тискәре йогынты ясый, сулыкларда һәм диңгезләрдә суүсемнәрнең тиз үрчүе аркасында суның «чәчәк атуы»н, диңгез суының кызыл һәм яшел төскә керүен китереп чыгара.

Бу аеруча пестицидларга, бигрәк тә ДДТга кагыла. Шуңа күрә АКШта һәм күпчелек Европа илләрендә аларны куллану тыелган. Чүп үләннәр һәм бөҗәкләргә каршы көрәшнең яңа методлары эшләнә, шул исәптән биотехнологик ысуллар да. Шуңа да карамастан дөньяда ел саен 500 меңнән алып 2 млн га кадәр кеше пестицидлар белән агулана, шуларның 10 нан 40 меңгә кадәре үлә. Аларның күбесе — үсеп килүче илләрнең авыл халкы.

**8. Балыкчылык.** Балыкчылык — кешелек дөньясының иң борынгы кәсепләренең берсе. Хәзерге вакытта ул бөтендөнья хуҗалыгының әһәмиятле тармакларыннан санала һәм 100 млн кешенең тук-

лану чыганагы булып хезмәт итә. Дөнья күләмендә тотылган балык һәм башка диңгез продуктларының күләме елына 125 млн т га җитте.

Аның якынча 4/5 өлешен — диңгез һәм океан суднолары, ә 1/5 ен елга-күлләрдә балык тоту тәэмин итә. Балык һәм башка «диңгез хәзинәләре» аксымга бай булуы ягыннан терлек һәм кош итеннән калышмый. Кешелекнең аксымга булган ихтыяҗының 1/4 е балык белән канәгатьләндерелүе шуның белән аңлатыла. Үсеп килүче илләрдә дөгеле ризыктагы каклаган балык кисәге еш кына терлек аксымының бердәнбер чыганагы булып тора.

*XX гасырның икенче яртысында бөтендөнья диңгез балыкчылыгы географиясендә зур үзгәрешләр булды.* Икенче бөтендөнья сугышына кадәр һәм аннан соң да төп балык тоту районы Төньяк Атлантикада иде (ә илләрдән, әлбәттә, Норвегия, Дания, Бөекбритания, Германия, АКШ), соңрак бу тармакның «эпицентры» Тын океанның төньяк өлешенә күчте. Бу океанның Көньяк Америкага орынып торган көнчыгыш өлеше әһәмиятле балык тоту районына әверелде. «Беренче унлык»ны тәшкил иткән балык тотучы дәүләтләрнең күбесе хәзерге вакытта нәкъ шул акваториядә урнашкан («Кушымта»дагы 30 нчы таблицаны карагыз).

Ләкин шуны да искәртик: алар балыкны үзләренең шельф суларында гына түгел, бәлки ерактагы суларда да тоталар (экспедициядә тоту). Ләкин илләрне җан башына тотылган балык күрсәткече буенча тезеп кую бүтән сурәт бирә. [17].

Бөтен дөньяда тотыла торган балык һәм диңгез продуктларының 30 млн тонна чамасы — балык үрчетү хуҗалыкларына яки *аквакультурага*[1], шул исәптән яртысыннан артыграгы диңгез мохитендә диңгез балыгы һәм тере организмнар үрчетүгә (марикультурага) туры килә. Аквакультура моннан 4 мең еллар элек Кытайда барлыкка килгән, һәм әле һаман да бу ил үзенең дөнья беренчелеген саклый. Гомумән, барлык аквакультура продукциясенең 9/10 өлешен Азия илләре бирә.

## 3. ТРАНСПОРТ ГЕОГРАФИЯСЕН ӨЙРӘНӘБЕЗ

**1. Транспорт — материаль җитештерүнең әйдәп баручы өченче тармагы.** Транспорт географик хезмәт бүленешенең нигезе булып торуын сез инде беләсез. Транспортта йөк ташу күләме, структурасы, кагыйдә буларак, икътисадның дәрәҗәсен һәм структурасын, ә транспорт челтәре һәм йөк агышлары географиясе исә җитештерүче көчләрнең урнашуын чагылдыра. Транспорт үзе дә мондый урнашуга актив

[1] Аквакультура (лат. *aqua* — су һәм *cultura* — үрчетү) — су асты «фермаларында» һәм «плантацияләрендә» балык, моллюсклар, кысласыманнар, энәтиреләр, суүсемнәр үрчетү һәм энҗе үстерү.

йогынты ясый, предприятиеләр, тармаклар, төбәкләр һәм илләрнең специальләшүенә һәм кооперацияләшүенә булышлык итә. *Аннан башка товар җитештерү белән куллану һәм хезмәт күрсәтү арасындагы территориаль өзеклекне бетерү һәм, гомумән, кешеләр аралашуы да мөмкин булмас иде.*

Барлык юллар, транспорт предприятиеләре һәм транспорт чаралары барысы бергә **бөтендөнья транспорт системасын** тәшкил итә. Аның масштабы гаять зур.

**Мисал.** Бөтендөнья транспорт челтәрендә 100 миллионнан артык кеше эшли. Дөньядагы транспорт челтәренең (диңгез трассаларыннан башка) озынлыгы 50 млн км га якынлаша. Дөньяда ел саен барлык төр транспортта 100 млрд тоннадан артыграк йөк һәм триллионлаган пассажир ташыла. Моңа миллионнарча транспорт чарасы катнаша. [18].

Сез транспортның аерым төрләре арасындагы «хезмәт бүленеше»нә ФТРның нинди үзгәрешләр кертүен беләсез инде. Ул шулай ук транспорт юлларының үткәрү мөмкинлеге үсүенә, нигездә, яңа транспорт төрләре барлыкка килүгә, аларның сыйдырышлылыгы һәм хәрәкәт тизлеге артуга китерде. ФТРга бәйле мондый күренешләрне сез, мөгаен, үзегез дә көндәлек тормышта очратасыздыр әле.

Тимер юлларны электрлаштыру дәвам итә. Һава мендәрендә, магнитлы асылмада «очучы» үтә тиз йөрешле поездлар барлыкка килде. [19].

Автомобиль транспортында, бигрәк тә бензин бәясе күтәрелгәннән соң, электромобильләргә, дизельле, газ баллонлы һәм башка төр двигательле машиналарга игътибар артты.

Су транспортында атомоход-суднолар, су асты канатлы, һава мендәрле суднолар, горизонталь ысул белән төяү һәм бушату (ролкерлар) һәм шулай ук сибелүчән, авучан йөкләрне ташуга көйләнгән суднолар (балкерлар), лихтеровозлар, автомобилевозлар файдаланыла башлады.

Берьюлы 300—500 һәм аннан да артыграк пассажир йөртә ала торган киң фюзеляжлы самолет-аэробуслар бар. Соңгы вакытта тавыштан тизрәк очучы үтә зур тизлекле пассажир авиалайнерларына игътибар арта башлады. [20].

Барлык төр транспорт үсешенә аны *контейнерлаштыру*[1] гаять зур йогынты ясады, һәм ул хезмәт җитештерүчәнлеген 7—10 тапкыр арттырды.

**2. Бөтендөнья транспорт системасында географик аермалар: илләрнең ике төркеме, регионнар.** Бөтендөньяда йөк ташу һәм пассажирлар йөртү географик яктан бик тигезсез бүленгән.

Икътисади үсеш алган илләрнең транспорты, кагыйдә буларак, техник дәрәҗәсе югары

[1] Контейнерлаштыру (ингл. *contain* — сыйдыру) — даналап сатыла торган йөкләрне ташуда махсус зур металл савытлар — контейнерлар куллану. Яңа транспорт чаралары — контейнер ташыгычлар һәм махсус йөк төяү станцияләре — контейнер терминаллары барлыкка килү нәкъ шуңа бәйләнгән.

булу һәм төрле тармакчаларның үзара бәйләнгәнлеге белән аерылып тора. Бөтендөнья транспорт челтәре озынлыгының, барлык йөк әйләнеше һәм пассажирлар әйләнешенең 70—80 % ы шушы илләргә туры килә. Транспорт челтәре белән тәэмин итеш, аның тыгызлыгы һәм халык хәрәкәте дә монда зуррак.

Соңгы ике-өч унъеллыкта үсеп килүче илләрдә дә бик күп үзгәрешләр булды. Шуңа карамастан бу илләрнең күбесендә транспорт — артта калган тармак.

Транспорт системаларының тиешенчә оештырылмавы үсешне кыенлаштыра, табигый ресурсларны үзләштерүне, икътисади районнарның формалашуын тоткарлый. Транспортның аерым төрләре генә булу хас: Һиндстан, Пакистан, Бразилия, Аргентинада — тимер юл; Якын һәм Урта Көнчыгыш илләрендә — үткәргеч торбалар; тропик Африка илләрендә — елга транспорты. Тимер юлларда составны паровоз белән йөртү, колеяларның төрле киңлектә булуы сакланган. Бу илләрдә халыкның транспорттан файдалануы бөтендөнья белән чагыштырганда берничә тапкыр кимрәк. Йөк ташу өчен, җигүле һәм йөк төяүле транспорт, кул хезмәте киң кулланыла.

Бөтендөнья транспорт системасын әһәмияте ягыннан тигез булмаган ике өлешкә бүлүдән тыш, **региональ транспорт системалары** турында да сөйләргә мөмкин. Аларга БДБ, Төньяк һәм Латин Америкасы илләре, Европа чит илләре, Көньяк Азия илләренең транспорт системалары керә.

Барлык транспорт төрләрен әһәмияте һәм үсеш дәрәҗәсе буенча гына түгел, бәлки аларны куллануның географик сфералары буенча да төркемнәргә бүләләр. Бу очракта *коры җир (җир өсте), су һәм һава транспортын* аерып күрсәтергә мөмкин.

**3. Коры җир транспорты: төп өч төре.** Автомобиль транспортын хаклы рәвештә XX гасыр транспорты дип әйтеп була. Ул, гасыр башында барлыкка килеп, безнең көннәрдә цивилизациянең аерылгысыз элементларыннан берсенә әверелде. Автомобиль юлларының озынлыгы һаман арта бара, хәзер ул 32 млн км га җитте, аның яртысы чамасы биш илгә — АКШ, Һиндстан, Бразилия, Япония һәм Кытайга туры килә, алардан соң Канада, Франция, Австралия, Россия тора. Бөтендөнья пассажирлар әйләнешендә автомобиль транспортының өлеше, кешеләрнең шәхси җиңел автомобильләре булу аркасында, 4/5 кә җитә. Ләкин автомобильләшү дәрәҗәсе иң элек паркларның үлчәмнәренә карап билгеләнүе сәбәпле, дөньядагы илләр һәм регионнар бер-берләреннән бигрәк тә нык аерылалар («Кушымта»дагы 31 нче таблицаны карагыз).

**Мисал.** Көнбатыш Европа илләрендә, Япония, АКШ, Канада, Австралиядә һәр 1000 кешегә 400—600 җиңел автомобиль туры килә, Көнчыгыш Европа илләрендә — 200—250, Россиядә — 180, дистәләгән үсеп килүче илләрдә, Кытай һәм Һиндстанны кертеп, 10 нан да ким.

*Димәк, дөньяны автомобильләштерүдә резервлар әле гаять зур, һәм ул XXI гасырда дәвам иттереләчәк.*

Тимер юл транспорты, йөк һәм пассажирлар ташуда аның өлешенең якынча 1/10 гә кимүенә карамастан, әле һаман да ул коры җир транспортының әһәмиятле төре булып кала. Бөтендөнья тимер юл челтәре, нигездә, XX гасыр башында формалаша. Аның гомуми озынлыгы күп еллардан бирле кими, һәм ул тигезсез урнашкан. Тимер юллар 140 илдә булуга карамастан, аның гомуми озынлыгының 1/2 өлеше «беренче унлык» илләренә: АКШ, Канада, Россия, Һиндстан, Кытай, ГФР, Аргентина, Австралия, Франция һәм Бразилиягә туры килә. Тимер юл челтәренең тыгызлыгы ягыннан Европа илләре аерылып тора.

Шуның белән бергә, тимер юл челтәре бик сирәк булган яки бөтенләй булмаган гаять зур киңлекләр дә бар. Шулай да XXI гасыр башында берничә трансконтиненталь тимер юл магистрале уздыру проектлана.

**Мисал.** Данлыклы Бөек ефәк юлы буенча Истанбулдан Ташкент аша Пекинга кадәр 10 мең км озынлыгындагы тимер юл магистрале үткәрү эшләре бара. Шулай ук Азия-Тын океан магистрален төзүгә әзерлек башланган: Сингапур — Бангкок — Пекин — Якутск — Беринг бугазы астындагы туннель — Ванкувер — Сан-Франциско.

Үткәргеч торба транспорты нефть һәм табигый газ чыгаруның бик тиз артуы һәм нефть чыгарыла торган район белән кулланучы районнар арасында территориаль өзеклек булу аркасында үсеш ала. Бөтен дөньяда үткәргеч торбалар магистраль челтәренең озынлыгы 2 млн км дан артык. Аларның 4—5 мең километрга җиткән иң озыннары БДБ илләрендә [21], Канада, АКШ һәм Якын Көнчыгыш илләрендә салынган. (14 нче бирем.)

**4. Су транспорты: диңгез транспортының үзенчәлекле роле.** Диңгез транспорты — бөтендөнья транспорт системасының бик әһәмиятле состав өлеше. Диңгез транспортының үсүе нәтиҗәсендә, Дөнья океаны инде илләрне аерып торучы түгел, бәлки илләр һәм континентларны бер-берсенә тоташтыручыга әверелде. *Ул халыкара сәүдәнең 4/5 е чамасына хезмәт күрсәтә.*

Диңгез трассаларының гомуми озынлыгы миллионнарча километрга җитә. Диңгез судноларым, башлыча зур күләмле сыек (нефть һәм нефть продуктлары), сибелүчән йөкләрне (күмер, руда, ашлык һ. б.), гадәттә, 8—10 мең км ераклыкка ташыйлар. Ләкин «контейнер революциясе» диңгез транспортында аеруча әһәмиятле йөкләр, ягъни әзер әйберләр һәм ярымфабрикатлар ташуның бик тиз артуына китерде (40 нчы рәсемне карагыз). Хәзерге вакытта бу йөкләрнең яртысы диярлек контейнерлар белән ташыла, ә аларның гомуми әйләнеше елга 200 млн т тәшкил итә.

Бөтен Җир шарын әйләндереп алган контейнер линияләре арасында инде дөнья әйләнә даими линияләр дә бар. Кайбер океан контейнер

линияләре аерым илләр арасындагы транспорт «күперенең», мәсәлән, Япония белән Көнбатыш Европа, Япония белән АКШның көнчыгыш яр буе линиясенең состав өлеше булып тора. Монда БДБ һәм АКШ территорияләре аша уза торган коры юл транспорты Атлантик, Тын океан һәм Япон диңгезе аша диңгез транспорты белән үзара бәйләнгән. [22].

Диңгездә йөк ташуны диңгез сәүдә флоты башкара, аның гомуми йөк күтәрү сәләте (тоннаж, сукуышлыгы) 600 млн тоннадан артып китә. 70 нче еллар уртасына кадәр бу тоннажның яртысын диярлек танкерлар тәшкил итте. Хәзер аларның өлеше сизелерлек кимеде. Диңгез суднолары 160 ка якын илнең әләмнәре астында йөзәләр, ләкин монда да төп рольне «беренче унлык» илләре уйный, ә аларга Панама һәм Либерия күптән җитәкчелек итә.

Кайбер үсеп килүче илләрнең, бигрәк тә Либерия белән Панаманың, зур диңгез флоты булуы — чынлыкта бу илләр әләме астында АКШ, Япония, Греция, Норвегия, ГФР, Бөекбритания, Италия, Швеция кебек илләрнең суднолары йөзү белән аңлатыла. Флотның шулай «качып» йөзүе традицион диңгез державалары судно хуҗаларының налог һәм диңгезчеләргә эш хакы түләүдә экономия ясарга омтылулары белән аңлатыла. Димәк, «уңайлы» («арзан», «ялган») әләмнәр астында йөзүче флот чынлыкта үсеп килүче илләрнеке түгел, бәлки алга киткән Көнбатыш илләрнеке, беренче чиратта Греция, Норвегия, Германия һәм АКШныкы.

Эре һәм уртача зурлыктагы диңгез портларының гомуми саны 2,2 меңнән артып китә. Ләкин аларның **дөнья порты** дип аталганнары, ягъни елына 50 млн тоннадан артыграк йөк төяп озатучы гигант портлар күп түгел, 50 чамасы гына. Шуларның 27 сендә йөк әйләнеше 100 млн тоннадан артып китә. Алга киткән илләргә теләсә нинди йөкләр кабул итә һәм озата ала торган *универсаль портлар* хас. Үсеп килүче илләрдә, Канада, Австралия, КАР да исә зур портлар нефть, руда, күмер экспортлауга гына көйләнгән (39 нчы рәсемне карагыз).

*Бөек географик ачышлар чорыннан башлап, суднолар йөреше буенча беренчелекне Атлантик океан алып тора.* Хәзерге вакытта бу океанның суднолар йөрү трассалары диңгез буенда урнашкан 70 ил аша уза, андагы халык саны 1,5 млрд кеше исәпләнә, диңгез юлы буйлап барлык йөк ташуның 1/2 өлеше шушы трассага туры килә. Бу океан бассейнында дөньядагы барлык диңгез портларының 2/3 се урнашкан, шул исәптән йөк әйләнеше буенча өченче порт (Сингапурдан һәм Шанхайдан кала) — Роттердам.

Әмма һава транспорты конкуренциясе аркасында, пассажирлар ташуда Атлантик океанның роле соңгы вакытта нык кимеде. XX гасырның беренче яртысында пассажир суднолары Европа белән Төньяк

Америка арасында гына елына 2—3 млн пассажир ташый иде. Аеруча уңайлы һәм тиз йөрешле пассажир лайнерлары, чын мәгънәсендә йөзүче сарайлар — «Нормандия» һәм «Франс» (Франция), «Куин Мэри» һәм «Куин Элизабет» (Бөекбритания), «Юнайтед Стейтс» (АКШ), «Микеланджело» (Италия) судносары «Атлантиканың зәңгәр тасмасы» исемле призны алу өчен ярышалар иде. XIX гасырда оештырылган бу приз Атлантик океанны иң кыска вакытта кисеп узучы судного бирелгән. Соңгы тапкыр моңа «Юнайтед Стейтс» лайнеры лаек була. Океанны ул 3 тәүлек 10 сәгать 40 минут эчендә кисеп уза. Мондый трансатлантик ярышлар хәзер инде уздырылмый, ә бу лайнерларның күбесе сүтелгән.

Диңгездә йөк ташу күләме буенча икенче урынны әһәмияте һаман арта барган — Тын океан, ә өченче урынны Һинд океаны алып тора. Тын океанда гаять зур йөк агышы — Япония, АКШ һәм Австралия яр буйларында, ә Һинд океанында Фарсы култыгында формалаша. Тын океан бассейнының әһәмияте Россия өчен дә, бигрәк тә аның көнчыгыш районнары өчен арта бара.

Диңгез транспорты географиясенә халыкара диңгез каналлары — бөтендөнья диңгез трассаларының үтә әһәмиятле кисешү урыннары аеруча зур йогынты ясый. Бу бигрәк тә аларның икесенә — Европа һәм Азия арасындагы юлны 2—3 тапкыр кыскартучы Сүәеш (41 нче рәсемне карагыз) һәм Панама каналларына карый.

Диңгез бугазлары Ла-Манш, Гибралтар, Ормуз, Малакка һәм башкалар әһәмиятле роль уйныйлар. Әмма аларның кайберләре көн саен бугаз аша үтеп йөри торган йөзләрчә судносар өчен «тар» була башлады, кайберләренең тирәнлекләре дә зуррак судносар узарлык түгел. [23]. (15 нче бирем.)

Эчке су транспорты — транспортның иң борынгы төре. Ләкин ул безнең көннәрдә йөк әйләнеше (һава транспортын кертмичә) буенча да, шулай ук пассажирлар йөртүе һәм челтәренең озынлыгы буенча да бөтендөнья транспорт системасында ахыргы урында тора.

Эчке елга транспортының үсеше һәм урнашуы беренче чиратта табигый алшартлар — судносар йөрү өчен яраклы елгалар һәм күлләр булуы белән бәйле. Амазонка, Парана, Миссисипи, Обь, Енисей, Янцзы, Конго елгаларының йөк уздыру сәләте иң куәтле тимер юл магистральләренекеннән шактый өстенрәк. Ләкин ул алшартлардан файдалану мөмкинлеге гомуми икътисади үсешкә бәйләнгән. Шуңа күрә дә эчке су юлларының йөк әйләнеше буенча дөньяда АКШ, Россия, Канада, ГФР, Нидерланд, Бельгия, Кытай аерылып тора. Азия, Африка һәм Латин Америкасы илләрендәге гигант елга системаларына барлык йөк әйләнешенең нибары 5 % ы туры килә.

Файдаланыла торган эчке су юлларының 1/10 өлеше чамасы ясалма юллардан (шлюзлан-


Валдиз
Ванкувер
Сиэтл
Сан-Франциско
США
Лос-Анджелес
Новый Орлеан
Хьюстон
Тампа
Тампико
Нью-Йорк
Филадельфия
Лондон
Амстердам
Роттердам
Гамбург
Антверпен
Гавр
Марсель
Генуя
Новороссийск
Александрия
Мина-Эль-Ахмади
Харк
Рас-Таннура
КИТАЙ
Тяньцзинь
Циндао
Шанхай
Нинбо
Сянган
Гуанчжоу (Кантон)
Гаосюн
Ульсан
Пусан
ЯПОНИЯ
Токио
Тиба
Кавасаки
Иокагама
Нагоя
Кобе
Осака
Куре
Китакюсю
Сингапур
Порт-Хедленд
Дампир
Ньюкасл
Сантус
Тубаран
Ричардс-Бей
Йөк әйләнеше елына 50 млн тоннадан артык булган диңгез портлары
Суднолар йөрүнең иң мөһим юнәлешләре
37

0 200 400 км
КАНАДА
о.Ньюфаундленд
оз.Верхнее
Дулут
оз.Гурон
оз.Мичиган
р.Св.Лаврентия
Квебек
Монреаль
Ливерпуль
Лондон
Кейптаун
Буэнос-Айрес
Рио-де-Жанейро
Торонто
оз.Онтарио
Чикаго
Детройт
оз.Эри
Бостон
С Ш А
Кливленд
Нью-Йорк
оз.Эри
оз.Верхнее
оз.Мичиган и оз.Гурон
оз.Онтарио
р.Св.Лаврентия
Шлюзлар
Диңгездә судно юллары
38

39

40

37 нче рәсем. Бөтен дөньяның диңгез транспорты

38 нче рәсем. Изге Лаврентий елгасында тирән су юлы

39 нчы рәсем. Япония. Заманча поездлар Токио белән Кюсю арасындагы 1100 км юлны 7 сәгатьтә үтәләр

40 нчы рәсем. Контейнер терминалы

41 нче рәсем. Сүәеш каналы

41

ган елгалар һәм каналлардан) гыйбарәт. Аларның зурлары АКШ, Кытай, Россия һәм Европа чит илләрендә.

Дөньяда судно йөрешле күлләрнең төп районы — АКШта һәм Канададагы Олы күлләр системасы. Алар Изге Лаврентий елгасының тирән су юлы аша Атлантик океанга тоташкан. Ә ул диңгез судноларына 4 мең километрга континент эченә керергә мөмкинлек бирә (38 нче рәсемне карагыз).

**5. Һава транспорты — транспортның иң яңа һәм динамик төре.** Мондый раслау белән сез, ихтимал, килешерсез. Дөрестән дә, әгәр 1950 елда бөтен дөньяда һава транспорты белән 30 миллион чамасы пассажир ташылган булса, 2000 елда ул 2,2 млрд ка җитә. Ә бу исә — җирдә яшәүче һәр өченче кеше елына бер тапкыр булса да авиатранспортта сәяхәт итә дигән сүз. Даими авиалинияләр челтәре хәзер бөтен Җир шарын чолгап алган, һәм ул 11,5 миллион диярлек километрга сузыла. Пассажирлар ташу күләме буенча беренче урынны — Төньяк Америка, икенче урынны Европа алып тора, ә калган илләрдән АКШ иң алда, аннан кала Бөекбритания, Япония, Кытай һәм Франция бара.

Һава транспорты географиясе беренче чиратта аэропортлар челтәре белән билгеләнә. Аларның саны күп меңнәрчә, шул исәптән халыкара аэропортлар саны меңнән артыграк. Аларның иң зурлары ел саен уннарча миллион пассажирга хезмәт күрсәтә. [24]. Континентара пассажирлар йөртүдә һава транспорты, диңгез элемтәләрен артта калдырып, инде күптән беренче урынга чыкты. Күпчелек пассажирлар Атлантик океан өстеннән үтүче авиалинияләрдән файдаланалар: гадәттә, бер үк вакытта һавада йөздән артык авиалайнер була.

**6. Транспорт һәм мохит.** Транспортның территориядәге табигать шартларына бәйлелеге гаять зур һәм күптөрле. Ләкин ФТР үсә барган саен, ул яңа формалар ала. Коры җир транспортының үсешенә биек таулар, зур елгалар, күлләр, тропик урманнар, чүлләр, хәтта диңгез бугазлары да үтә алмаслык киртә була алмыйлар. Ясалма су юллары уздырып «табигать ялгышларын» төзәтү су транспортын үстерүгә ярдәм итә.

*Шуның белән бергә, транспортның әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысы арта.* Транспортның һәр төре табигатьне үзенчә пычрата. Атмосфераны төп пычратучы — автомобиль транспорты: зур шәһәрләрдә һава бассейнына чыгарылган барлык зарарлы матдәләрнең 2/3 өлеше автомобильләргә туры килә. Атмосфераны шулай ук һава транспорты да, тимер юл транспорты да, бигрәк тә паровозлар, каты кисәкчәләр белән пычрата. Моннан тыш, транспортның барлык төрләре дә мохитнең «тавыш белән пычрану»ын китереп чыгара, коры җир транспорты җирләрнең «кимүенә» китерә. Су транспорты гидросфераны нык пычрата. Диңгезләрдә төп нефть ташу трассалары уза торган акваторияләр аеруча нык пычрана.

Күп кенә илләрдә транспорт пычратуыннан мохитне саклау максатында катгый чаралар кү-

релә. Автомобиль бензинында кургаш микъдарын киметү, электромобильләргә күчү, ягулык итеп водород һәм газ куллану, һава мендәрендәге поездлардан файдалану кебек чаралар күрелә башлады.

## 4. ДӨНЬЯКҮЛӘМ ИКЪТИСАДИ МӨНӘСӘБӘТЛӘР БЕЛӘН ТАНЫШАБЫЗ

**1. Гомуми характеристика.** Бөтендөнья хуҗалыгы барлыкка килү, халыкара географик хезмәт бүленешенең тирәнәюе **дөньякүләм икътисади мөнәсәбәтләр (ДИМ)** формалашуга китерде. Бу мөнәсәбәтләрне бөтендөнья хуҗалыгының «кан әйләнеше системасы» дип атарга мөмкин.

ДИМнең үсеш темплары материаль җитештерүнең үсеш темпларыннан югарырак, һәм ул хуҗалык итүнең интернациональләшүе күрсәткече булып тора, ә аларның географиясе беренче чиратта сез алдарак өйрәнгән дөнья хуҗалыгының ике төркемле моделен чагылдыра. Халыкара икътисади элемтәләрдә, бигрәк тә икътисади интеграция шартларында, «ияртеп баручы» ролен һәрвакыт икътисади мөнәсәбәтләрнең барлык формалары да зур үсеш алган Төньяк илләре үтәп килде, һәм хәзер дә үти, ә «ияреп баручы» ролендә — Көньяк. Әлбәттә, элеккеге колониаль һәм ярымколониаль уннарча ил сәяси бәйсезлеккә ирешкәч, аларның ДИМдәге хәле уңай якка таба үзгәрде (дөнья энергетикасында ОПЕКның ролен искә төшерик), ләкин бу процесс әлегә акрын бара. Шуңа күрә дә Көньяк илләре 70 нче еллар урталарында БМО тарафыннан игълан ителгән *яңа дөньякүләм икътисади тәртип* урнаштыру программасы өчен көрәшләрен дәвам итәләр.

Төньяк — Көньяк (Үзәк — Периферия) арасындагы мөнәсәбәтләрдән тыш, Төньяк — Төньяк һәм Көньяк — Көньяк юнәлешендәге мөнәсәбәтләрнең дә әһәмияте гаять зур. Икътисади көчеш илләре бу мәсьәләдә аерым урын алып торалар.

Дөньякүләм икътисади мөнәсәбәтләргә аеруча нык бәйләнгән, аңа «тирәнтен үрелеп үскән» илләрне **ачык икътисадлы илләр** дип атау кабул ителгән. Үз нәүбәтендә мондый ачыклык дәрәҗәсе иң элек илнең тулай эчке продуктын (ТЭП) булдыруда экспорт өлешенең күпме булуы — *экспорт квотасы* белән билгеләнә. Көнбатыш Европадагы алга киткән кайбер кечкенә илләрнең һәм Азия яңа индустриаль илләренең бу квотасы шактый югары, ә инде күп сыешлы эчке базары булган зур илләрнең квотасы, гадәттә, кечкенәрәк.

**Мисал.** Сингапурда экспорт квотасы 80 % чамасы, Бельгиядә һәм Нидерландта — 65—75 %, ГФР һәм Франциядә 30—35 % тәшкил итә, ә АКШта — 11 %. Соңгы вакытта Россиядә ул 46 % ка җитте һәм аннан да арта.

Ачык икътисадның уңышлы чагылышларыннан берсе — **ирекле икътисади зоналар** булдыру. *Ирекле икътисади зона (ИИЗ) ул — икътисади географик урыны уңайлы булган район яки шәһәр, анда фи-*

*нанс һәм материаль байлыкларны, технология һәм хезмәт ресурсларын тарту — җәлеп иту өчен льготалы салым һәм таможня режимы урнаштырыла.* Ирекле икътисади зона иң элек чит ил капиталын һәм иң яңа технологияләрне тарту, валюта керүен арттыру һәм эчке базарны конкуренциягә сәләтле товарлар, хезмәт күрсәтүләре белән күбрәк баету өчен булдырыла. XXI гасыр башында мондый зоналар бөтен дөньяда чама белән 3 меңнән артыграк һәм анда 30 млн кеше хезмәт күрсәтә. Ирекле икътисади зонаның бөтендөнья товар әйләнешендәге өлеше 1/3 дән артып китте. Бу зоналарның аеруча уңышлы эшчәнлегенә Кытай һәм Азия яңа индустриаль илләре мисал була ала. ИИЗлар Россиядә дә шулай ук башлады.

ДИМнең формалары хәзерге вакытта һаман саен төрләнә бара. Аларның кимендә биш формасы турында сөйләшергә мөмкин.

**2. Бөтендөнья сәүдәсенең әйләнеше, структурасы, географик бүленеше.** *Бөтендөнья сәүдәсе — бөтендөнья хуҗалыгының инде күптәнге тармагы. ФТР чорында аның чын мәгънәсендә «икенче сулышы» ачылды.* Тышкы сәүдә әйләнешенең үсеш темплары тулаем җитештерү темпларын шактый узып китә, ә бу исә халыкара хезмәт бүленеше географиясенең тирәнәюе турында сөйли. 1950—2005 елларда дөньяда сәүдә әйләнеше 125 млрд тан 18 трлн долларга кадәр, ягъни 114 тапкыр артты.

**ФТР** чорында бөтендөнья сәүдә структурасында да үзгәрешләр күзәтелә, ул күбрәк товарлар сәүдәсенә һәм хезмәт күрсәтү сәүдәсенә бүленә бара. Товар структурасында әзер әйберләр өлешенең артуы, ә чимал һәм азык-төлек өлешенең кимүе күзәтелә (42 нче рәсемне карагыз). Башкача әйтсәк, структураның яхшыруы дәвам итә. Дөнья сәүдәсендә әзер товарлардан — электроника һәм электротехника товарлары, автомобильләр, ә чималдан нефть һәм нефть продуктлары беренче урыннарны алып торалар.

Хезмәт күрсәтү сәүдәсе товар сәүдәсенә караганда тизрәк үсә, һәм аңа бөтендөнья сәүдәсенең 1/3 е чамасы туры килә.

Халыкара хезмәт күрсәтү ул яңа күренеш түгел. Инде күптәннән бирле портларга керүче чит ил судноларына хезмәт күрсәтү, зур керемнәр бирә торган диңгез судноларын яллау (фрахт) яшәп килә. Башка илләр портлары арасында йөк ташу өчен үзләренең диңгез флотларын биреп торучы илләрне «диңгез олаучысы» дип атыйлар.

**Мисал.** Мондый илләргә Греция, ГФР, Бөекбритания, Франция, Нидерланд, Швеция һәм Дания керә. Ләкин төп «диңгез олаучысы» — Норвегия. [25].

Безнең көннәрдә судолар гына түгел, самолетлар яллау да (чартер рейслары) кулланыла. Төзелеш хезмәте күрсәтү дә киң таралган. Ләкин халыкара хезмәт күрсәтүнең иң киң таралганы иминият, реклама, кинопрокат өлкәсендә, шулай ук фәнни һәм производство җиһазларын арендага алуны, фәнни информация эшкәртүне, космик элемтәдән файдалануны күрсәтергә мөмкин. Производство тәҗрибәсе белән уртаклашуның махсус формасына «ноу-хау» («ничек икәнен белү») дип халыкара атама бирелде.




42




43

42 нче рәсем. Бөтендөнья сәүдәсенең товар структурасы

43 нче рәсем. Халыкара туризмның үсеше

44 нче рәсем. Халыкара туризмның төп регионнар арасында бүленеше

45 нче рәсем. Әдриан диңгез буендагы курорт

44

45

Закон нигезендә сату-алу тыелган товарлар: наркотиклар, порнография, валюта, ювелир әйберләр, сәнгать әсәрләре, корал сәүдәсе һ.б. белән шөгыльләнүче *яшерен базарның* булуы халыкара сәүдәнең эшен бик нык катлауландыра. Урланган автомобильләр дә бу базарда бик үтемле товар булып санала.

Халыкара сәүдә географиясендә үзгәрешләр булуга карамастан, аның территориаль структурасының төп үзенчәлекләре элеккечә калды. Бу сәүдәдә *беренче урынны* аның суммар товар әйләнешенең 70 % ын диярлек тәэмин итеп торучы икътисади үсеш алган Көнбатыш илләре алып торды һәм алып тора. Шуңа күрә бу күрсәткеч буенча «беренче унлыкка» «көнбатышның зур җиделеге», Нидерланд, Бельгия һәм Корея Республикасының керүе бер дә гаҗәп түгел. Бу илләр арасында АКШ алда бара, ләкин ул пассив ***сәүдә балансына***[1] ия. Дөньяда иң зур йөк агышлары да шул илләр арасында бара (АКШ — Канада, АКШ — Япония, ГФР — Франция һ.б.). Халыкара сәүдәдә *икенче урынны* Көньяк илләре алып тора, ләкин моңа беренче чиратта Азия яңа индустриаль илләре һәм нефть экспортлаучы илләр — ОПЕК әгъзалары аркасында ирешелә. *Өченче урында* — икътисади күчеш илләре, алар арасында Россия аерылып тора. Әмма Россиянең халыкара товар әйләнешендәге өлеше 90 нчы елларда шактый кимеде, хәзер ул 2 % тан артмый (АКШның өлеше 12—13 % тәшкил итә).

Бөтендөнья базары — ул товарларның даими конкуренциясе дә әле. Шуңа күрә дә базар чикләрендә еш кына чын мәгънәсендә «сәүдә сугышлары» булып тора.

**Мисал.** Япониядән аеруча ышанычлы, экономияле, уңайлы һәм «чиста» (атмосферага зарарлы матдәләр чыгару буенча) автомобильләр экспорты аркасында, 80 нче еллар башында ук АКШтагы һәр бишенче җиңел машинаның япон маркалы булуына китерде. Япониянең «Хонда» һәм «Ниссан» фирмалары АКШта автомобиль заводлары төзеде, ә ул ике ил арасында дәвамлы «автомобиль сугышына» китерде.

Дөнья сәүдәсен көйләү максатында *Бөтендөнья сәүдә оешмасы* (БСО) төзелә, аңа дөньяда товар әйләнешенең 95 % алып торган 150 дән артыграк ил керә. Россия БСОга кабул ителмәде әлегә.

**3. Халыкара финанс-кредит мөнәсәбәтләре структурасындагы һәм географиясендәге үзгәрешләр.** Халыкара финанс-кредит элемтәләре бөтендөнья икътисади мөнәсәбәтләрнең иң яңа формасы буларак безнең көннәрдә беренче дәрәҗәдәге әһәмияткә ия. *Бу мөнәсәбәтләр, барыннан да бигрәк, транснациональ корпорация эшчәнлеге нәтиҗәсендә бөтен дөньяны әйләндереп алды.*

---

[1] Сәүдә балансы — бер ел эчендә илгә кертелгән һәм илдән читкә чыгарылган товар бәяләре арасындагы нисбәт. Әгәр илдән чыгарылган товар бәясе, илгә кертелгән товар бәясеннән артык булса, баланс *актив* була. Моңа капма-каршы очракта баланс *пассив* була.

Бу мөнәсәбәтләр кредитлар һәм заемнар бирү, шулай ук капитал экспортлау рәвешендә, бигрәк тә производство һәм хезмәт күрсәтү объектларын булдыру өчен **турыдан-туры инвестицияләр** формасында да булырга мөмкин. XXI гасыр башында бөтен дөньяда тупланган мондый инвестицияләрнең гомуми күләме 3,5 трлн доллардан артып китте.

Финанс агышлары географиясендә (яисә капитал миграциясендә) зур үзгәрешләр булып тора. Икенче бөтендөнья сугышы алдыннан капитал метрополия илләреннән тау промышленносте, плантация хуҗалыгы тармакларына кертү өчен колониаль һәм ярымколониаль илләргә җибәрелгән булса, ФТР чорында, аны фәнсыешлы тармакларга, хезмәт күрсәтү сфераларына кертү отышлырак булу сәбәпле, капитал хәрәкәтенең «төп урамы» Көнбатыш Европаны АКШ һәм Япония белән тоташтырды. Финанс операцияләренең гомуми масштаблары буенча Көнбатыш Европа барыннан да алда (бигрәк тә Бөекбритания, ГФР, Франция, Бельгия, Нидерланд), икенче урында — АКШ, өченче урында — Япония.

Көньяк илләренең финанс хәле бик авыр: аларның Төньяк илләренә суммар бурычы 2,5 трлн доллардан артып китте. Ләкин соңгы ун еллар эчендә Көньякта да капитал экспортлаучы ике зур үзәк барлыкка килде. Беренчедән, алар Фарсы култыгындагы экспортка нефть чыгаручы илләр, ә аннан нефть долларлары Көнбатыш Европага, күп кенә Азия һәм Африка илләренә агыла башлады. Икенчедән, «Азия юлбарыслары» — иң элек Сингапур, Сянган һәм Тайвань.

Чит илдән инвестицияләр кертү буенча Көньяк илләре арасында беренчелекне Кытай һәм Һиндстан тота. Күчеш икътисадлы илләр арасында дөнья финанс базарында алдынгылардан Россия санала. Россия икътисадына чит ил инвестицияләре 2005 елда 50 млрд доллардан артып китте. Ул чит ил кредитларын түләп бетерде.

***Бөтендөнья банкы төркеме***[1], шулай ук ***Халыкара валюта фонды***[2] — капиталның халыкара хәрәкәтен әһәмиятле көйләүчеләрдән санала. Ләкин 1997 ел урталарында АСЕАН илләрендә башланып, Корея Республикасына, Япониягә һәм башка регионнардагы күп кенә

---

[1] Бөтендөнья банкы төркеменә дүрт финанс оешмасы керә. Ләкин төп рольне Халыкара реконструкцияләү һәм үстерү банкы уйный, ул үзенең эшчәнлеген озак сроклы структурага кагылышлы проектлар белән бәйли. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң бу проектлар Көнбатыш Европа илләре хуҗалыкларын торгызуга һәм оештыруга юнәлтелгән иде, ә соңрак — үсеп килүче илләргә икътисади ярдәм күрсәтүгә. Шулай ук бу банк финанс кыенлыклары булган илләргә ярдәм итә. Аның идарәсе АКШ башкаласы Вашингтонда урнашкан.

[2] Халыкара валюта фонды (МВФ) — хөкүмәтара валюта-кредит оешмасы. Ул илләр арасындагы валюта-финанс элемтәләрен тәртипкә салу, валюта курсын саклауга булышлык итү һәм валютага мохтаҗ илләргә валюта белән ярдәм итү өчен булдырылган. Аңа, Россияне һәм БДБ илләрен исәпләп, барысы 180 ил керә. МВФның идарәсе шулай ук Вашингтонда урнашкан.

илләргә барып җиткән бөтендөнья финанс кризисы шартларында аларга үзләренең кредиторлык һәм дөньядагы финанс агышларын көйләү вазифаларын үтәү читенләшә. Шуңа күрә хәзер дөньяның барлык финанс системасын үзгәртеп кору мәсьәләсе куела. [26].

**4. Дөньякүләм икътисади мөнәсәбәтләрнең башка төрләре.** Аларга иң элек берничә төрле формада тормышка ашырыла торган халыкара производство хезмәттәшлеге керә. Ул, беренчедән, *җитештерүнең халыкара специальләшүе һәм кооперацияләшүе.* Бу форма автомобиль промышленностенда бигрәк тә киң кулланыла. Икенчедән, *продукцияне күпьяклы нигездә бергәләп җитештерү.*

**Мисал.** Франция, Бөекбритания, ГФР, Нидерланд, Бельгия һәм Испания «гасыр проектын» — супер заманча А-300 аэробусын бергәләп җитештерүне тормышка ашыралар. Бу эштә һәр ил комплектлаучы детальләрнең билгеле бер өлешен җитештерә, ә самолетны җыю Франциянең Тулуза шәһәрендә башкарыла. Бу проектта Россия дә катнаша.

Өченчедән, *капиталь төзелеш өлкәсендә* хуҗалык объектларын төзүдә *булышлык итү*. Элеккеге СССР күп дистәләрчә социалистик һәм үсеп килүче илләргә шундый булышлык күрсәтеп килде. Ә хәзер Россия Кытайга, Һиндстан, Иран, Куба һәм башка илләргә, мәсәлән, атом энергетикасын үстерүдә ярдәм итә.

Халыкара җитештерүдәге хезмәттәшлек еш кына *уртак предприятиеләр* төзелүгә китерә. Аңа бу ил һәм чит ил партнерларының капиталы кертелә.

Фәнни-техник хезмәттәшлек — халыкара икътисади мөнәсәбәтләрнең тагын бер әһәмиятле формасы. Ул ФТР йогынтысында һәм дәүләтара специальләшүнең җитештерүгә генә түгел, бәлки фәнни-тикшеренү өлкәсенә дә үтеп керүе нәтиҗәсендә барлыкка килде. Ул фәнни-техник белемнәр (патентлар, лицензияләр) белән халыкара алмашудан, шулай ук фәнни тикшеренүләрне, проектлар төзүне бергә тормышка ашырудан гыйбарәт. Мәсәлән, космосны тикшереп өйрәнү (Халыкара космик станция — МКС), мохитне саклау өлкәләрендә булырга мөмкин.

**5. Халыкара туризм: туристларның өзлексез агышы.** Халыкара туризм халыкара хезмәт күрсәтүләр алмашуның иң киң таралган формасы булып санала. *Соңгы унъеллыкта туризм чын мәгънәсендә гөрләп үсә.* Сәяхәткә омтылу, бер яктан, җитештерүче көчләрнең үсешен, атап әйткәндә, транспорт чараларының камилләшүен чагылдырса, икенче яктан, ул — урбанизация, кешеләрнең тормыш һәм культура дәрәҗәсе күтәрелү нәтиҗәсе булып торуын аңлыйсыздыр. Моны кешеләрнең башка илләрне, халыкларны якыннан күреп белүгә омтылышының үсүе белән аңлаталар.

Халыкара туризм үзенең *максаты ягыннан* түбәндәгеләргә бүленә: а) сәламәтләндерү (рекреацион), б) танып белү (экскурсия), в) эшкә бәйле, г) фәнни, гәрчә соңгы вакытта аның башка төрләре барлыкка килде. Мәсәлән, экологик туризм яисә экстремаль туризм —

Арктикага, Антарктикага диңгез сәяхәтләре, парашют белән төньяк полюска сикерү. *Космик туризм* тормышка аша башлады.

Нинди *транспорт төре* куллануга карап, автомобиль, тимер юл, диңгез, һава һәм елга туризмы була. Халыкара туризмда төп рольне автомобиль (җиңел автомобильләр, автобуслар) һәм авиация туризмы уйный. Ләкин соңгы вакытта диңгез круизлары туризмы тиз үсә, аның өчен махсус уңайлы судноляр төзелә. [27]. Шуның белән беррәттән, *«туризм индустриясе»* дә үсә (яки «кунак итү индустриясе») — кунакханәләр, мотельләр, кемпинглар, туризм фирмалары, информация һәм реклама хезмәтләре, сувенирлар җитештерү предприятиеләре һ. б. челтәре киңәя бара.

Халыкара туризм әһәмиятле керем чыганагына әверелде, аның бөтен дөньядагы керем күләме елына 500 млрд долларга якынлаша. Керемнәрнең абсолют зурлыгы буенча беренче урынны АКШ алып тора. Ләкин аның ТЭП өлешенә күчереп исәпләгәндә, әйтеп үтелгәнчә, туризм хезмәте күрсәтүләре сату исәбенә яшәүче зур булмаган «курорт» илләр» алда бара.

*Европа бөтен дөньяда чит ил туристларын үзенә иң күп җәлеп итүче регионнардан саналып килде һәм әле дә санала.* Европа илләре арасында бу яктан «иң зур өч ил» — Испания, Франция, Италия аерылып тора.

Азиядә туристларның иң күбен Малайзия, Таиланд, Кытай, Төньяк Америкада — АКШ, Латин Америкасында Мексика кабул итә. (16 нчы бирем.)

**Төп нәтиҗә.** *Бөтендөнья хуҗалыгының аерым тармаклары географиясе озак вакытлар дәвамында төрле факторлар йогынтысында формалашты. Ул безнең көннәрдә дә, барыннан да бигрәк ФТР йогынтысында һәм халыкара сәяси климатның йомшаруы нәтиҗәсендә үзгәрүен дәвам итә.* (17 нче йомгаклау биреме.)

## ӨСТӘМӘ ТЕКСТ (Кызыклы мәгълүматлар)

[1] 80 нче еллар башында Алжир белән Италия арасында, диңгез аша 2,5 мең км озынлыгында беренче газүткәргеч магистраль төзелә. Аның күп өлеше 500—600 м тирәнлектә Урта диңгез төбеннән уза. Трасса сайлап алу өчен, башта диңгез төбе су асты көймәләре ярдәмендә тикшерелә. Торбалар махсус көйләнгән торба үткәрүче судноляр ярдәмендә салына. XXI гасыр башында тагын ике «диңгез» газүткәргече төзү тәмамланды: Гибралтар бугазы аша Алжирдан Испаниягә һәм Россиядән Төркиягә Кара диңгез аша («Зәңгәр агым»).

[2] Җан башына электр энергиясе җитештерү буенча Норвегия — дөнья рекордсмены, монда бу күрсәткеч 28 000 кВт · сәгкә җитә. Икенче полюста — Тропик Африкадагы Чад Республикасы, ә монда җан башына сарыф ителә торган электр

энергиясе фәкать 14 кВт·сәг. Димәк, ул Норвегиядән 2300 тапкыр калыша.

[3] Норвегия — икътисади үсеш алган илләр арасында үзенең электр энергиясенә булган ихтыяҗын 99,5 % ын ГЭС җитештергән энергия исәбенә канәгатьләндерүче бердәнбер ил. Шунысы игътибарга лаек: андагы 200 ләп гидростанция, ягъни аларның күпчелеге җир астында урнаштырылган. Бу — икътисади сәбәпләр һәм инженерлык уйлап табулары белән аңлатыла.

[4] Кытайда Янцзы елгасының югарыгы агымында гаять зур гидроузел Санься («Өч тарлавык») белән 18 млн кВт егәрлекле гидростанция төзү эшләре башланган. Эченә 26 турбина урнаштырылачак плотинасының биеклеге 180 м, ә озынлыгы 2,5 км. Плотина 600 км озынлыгындагы сусаклагыч хасил итә. Аңа су тутыру 2003 елда башланды, ә бөтен төзелешне 2009 елда тәмамлау планлаштырылган.

[5] XXI гасыр башында дөньяның фәкать биш илендә барлык электр энергиясенең яртысыннан артыграгын атом электростанцияләре бирә: Литва (80 %), Франция (78 %), Словакия (57 %), Бельгия (56 %) һәм Швеция (50 %). АКШта бу өлеш 21 %, Россиядә — 15 %.

[6] Исландия — җылыту һәм кайнар су белән тәэмин итү максатында термаль суларны күп файдаланучы бердәнбер дәүләт. Бу максатта 30 нчы еллардан башлап илнең башкаласы Рейкьявикта су үткәрү торбалары һәм махсус резервуарлар системасы эшләнгән. Бу резервуарлардан кайнар су насос ярдәмендә кулланучыларга җибәрелә. Геотермаль җылытулы теплицалары булу аркасында, Исландия үз халкын алма, помидор, кавын, хәтта банан белән тулысынча тәэмин итә.

[7] Даниядә 4 меңнән артыграк җил энергетикасы җайланмалары эшли, алар барлык җитештерелә торган электр энергиясенең 4—5 % ын биреп торалар. 2030 елда аларның өлешен 25—30 % ка җиткерү көтелә, ә бу атмосферага углерод чыгаруны икеләтә киметергә мөмкин. Ләкин соңгы вакытта җил энергетикасы үсеше буенча Германия Данияне артта калдырды. Германиядә дөньяда иң зур «җир энергетикасы паркы» төзелде.

[8] Барлык кешелек тарихы дәвамында дөньяда 130 мең т чамасы алтын чыгарылган. Хәзерге вакытта: КАР (295 т), Австралия (260 т), АКШ (255 т), Кытай (225 т), Перу (210 т), Россия (170 т), Индонезия (140 т) һәм Канада (120 т) алтынны иң күп чыгаручылардан санала. Шул ук вакытта 90 нчы елларда алтын чыгару Австралиядә һәм Кытайда күпкә арта, ә Россиядә һәм КАРда кими.

[9] Бөтен дөньяда корыч коюны 100 дән 200 млн т га кадәр арттыру өчен 24 ел (1927—1950) таләп ителгән. Ә инде 200 дән

300 млн т га җиткерү өчен нибары 8 ел (1950—1958) кирәк булган. 1964 елда дөньяда 400 млн т, 1968 елда — 500 млн т, 1970 ел — 600 млн т, 1973 елда 700 млн т корыч җитештерелгән.

[10] 1950 елда дөньяда 10 млн автомобиль җитештерелгән, 60 нчы еллар башында — 20 млн, 1970 елда — 30 млн, 1980 елда — 40 млн, 1990 елда — 48 млн һәм 2005 елда — 66 млн.

Елына 66 млн автомашина җитештерү — көн саен автомобиль заводларының конвейерларыннан 200 мең машина төшә дигән сүз. Әмма ел саен 25 млн машинаның кулланылыштан чыгып, чүплеккә элегүен дә белеп торырга кирәк.

[11] Һиндстанда җан башына 7 кг кәгазь тотыла, Әфганстанда һәм Малида — 0,1 әр кг. Чагыштыру өчен: бөтен дөньяда уртача күрсәткеч 55 кг тәшкил итә, Көнбатыш Европада — 200 кг, ә АКШта — 315 кг га җитә.

[12] 1984 елның декабрендә Һиндстанның Бхопал шәһәрендә Америка компаниясенең химия заводында зур авария була. Нәтиҗәдә шәһәрнең 6,3 мең кешесе һәлак була, ә уннарча меңе зыян күрә. Бу иң зур агулы болыт хасил булу очрагы, хәтта Гиннесс рекордлар китабына иң хәтәр һава пычрануы мисалы буларак кертелә.

[13] Көнбатыш Европаның чагыштырмача кечкенә илләрендә һәм Япониядә авыл хуҗалыгын механикалаштыру һәм химияләштерү дәрәҗәсе аеруча югары. XXI гасыр башында ук 1000 га чәчүлек җиргә Япониядә 450 трактор (бакчада кулланыла торганнары белән), ГФРда — 200, Италиядә 150 трактор туры килгән. 1 гектар чәчүлек җиргә минераль ашламаларның иң күбе Нидерландта (360 кг), Бельгиядә һәм Япониядә (300 кг), ГФРда (220 кг) кертелгән. Болыннарга һәм көтүлекләргә дә ашлама кертелә торган Яңа Зеландиядә 1 гектар җиргә 1000 кг ашлама туры килә.

[14] Бодай уңышын апрель — июнь айларында — АКШның көньяк районнарында, Урта диңгез буенда, Кытай һәм Һиндстанда; июль-августта — АКШның калган районнарында, Европаның күп өлешендә; сентябрьдә — Канадада, Төньяк Европада, декабрь — март айларында Аргентина, Австралия һәм Яңа Зеландиядә җыеп алалар.

[15] Кофе агачлары үстерү һәм кофе сату 25 миллион кешегә яшәү чыганагы булып тора. 50 гә якын ил аны читкә (экспортка) чыгара. Азык-төлек товарлары арасында халыкара сәүдәдә бәясе буенча кофе, бодайдан кала, икенче урынны алып тора. Латин Америкасында күбрәк кофенең аеруча тәмле «арабика» сорты, ә Африка һәм Азиядә «робуста» сорты үстерелә, ә ул күбесенчә тиз эрүчән кофе әзерләүгә китә.

[16] Дөньяда ел саен 425 млн тонна җиләк-җимеш җыела. Шул исәптән 65 млн тонна әфлисун (иң күбе Бразилия һәм АКШта), 60 млн тонна банан, 57 млн тонна виноград, 55 млн тонна алма, 46 шар млн тонна карбыз һәм кокос, 22 млн тонна манго, 16 млн тонна мандарин, 13 млн тонна груша һәм 10 млн тонна лимон җыялар.

[17] Беренче урында Исландия (6500 кг!) була, икенче урында — Фарер утраулары (5560 кг), өченче урында — Даниянең Гренландия утравы (2065 кг). Алардан соң Фолкленд утраулары (780 кг), Норвегия (650 кг), Кирибати (390 кг), Мальдив утраулары (385 кг), Перу (370 кг), Дания (365 кг) һәм Чили (310 кг) бара.

[18] Тимер юл буйлап йөк һәм пассажирлар ташу 200 мең локомотив һәм берничә миллион вагон ярдәмендә, автомобиль юлларында — 800 млн чамасы автомобиль, диңгез трассаларында — 80 меңнән артыграк судно, һава юлында 15 меңнән артыграк рейс самолетлары ярдәмендә башкарыла. Бөтен дөньяда йөк ташучы транспорт чараларының гомуми йөк күтәрүчәнлеге 1,5 млрд т га якынлашып килә.

[19] Тиз йөрешле тимер юл магистральләре төзүдә иң зур уңышларга Франция һәм Япония ирешә. Пассажир поезды тизлегенең дөнья рекорды 2007 елда Франциядә куелды — 585 км/сәг! 2003 елда Япониядә магнитлы тимер юл поездының тизлеге 581 км/сәг га җитте! Гади тиз йөрешле поездлар кайбер илләрдә сәгатенә 200—250 км, хәтта 300 км тизлек белән йөри.

[20] Тавыш тизлегеннән зуррак тизлек белән очучы пассажир лайнерлары (инглиз-француз самолеты «Конкорд» һәм совет самолеты Ту-144) 60 нчы еллар ахырында эшләнә, ләкин төрле сәбәпләр белән тиз арада эксплуатациядән алына. Ә 90 нчы еллар урталарында аларның эксперименталь очышлары яңадан башлана. 1995 елда реклама максатларында «Конкорд» лайнеры Нью-Йорк — Нью-Йорк маршруты буенча (алты тукталыш белән) Җир әйләнә очыш ясый һәм бу вакытта 40 717 км юл уза. Бу очыш 31 сәгать 27 минут 40 секунд дәвам итә. Лондоннан Нью-Йоркка кадәр араны «Конкорд» 3 сәгать 40 минут эчендә уза. 2003 ел азагында «Конкорд»лар очуы туктатыла, чөнки аларны эксплуатацияләү бик кыйбатка төшә. Россиядә Ту-144 лайнерының сынау очышлары уздырыла, аңа нигезләнеп яңа Ту-244 самолеты эшләнә, ул крейсер тизлеге, ягъни сәгатькә 2300—2500 км тизлек белән оча.

[21] Яңа төзелгәннәрен генә күздә тотсак, алар санына Россиядә Байкал алдыннан Приморье краеның Находка портына кадәр нефтьүткәргеч, Балтыйк газ транспорты системасы керә. Казахстанда Каспий диңгезе аша, ә Төркмәнстанда Һиндстанга кадәр газүткәргеч төзү планлаштырыла.

[22] Көнбатыш Европа белән Япония арасында транзитлы

йөк ташулар өчен БДБ территориясе аша Транссебер «күпере» салынган. Көнбатыш Европадан җибәрелгән йөк дөньяда иң озын Транссебер тимер юл магистрале (9322 км) буенча Находка һәм Восточный портларына кадәр бара, аннары диңгез буйлап Токио — Иокогамага китә. Бу юлның гомуми озынлыгы 13 мең км, ә инде йөкне Көнбатыш Европадан Японияга Сүәеш каналы аша җибәргәндә бу ара — 20 мең км, Африка тирәли 26 мең км булыр иде.

[23] Ла-Манш бугазы аша тәүлек эчендә 800 судно, ә Эресун (Зунд) аша — 175, Гибралтар аша — 200, Ормуз аша — 100, Малакка аша — 80, Босфор бугазы аша 40 судно уза. Ла-Манш бугазының гарантияле тирәнлеге 30—35 м, Каттегатныкы — 26 м, Босфорныкы — 27 м, Малакка бугазыныкы — 25 м. Шунлыктан Фарсы култыгыннан Көнбатыш Европага баручы гаять зур супертанкерлар, гадәттә, Бөекбритания һәм Франциянең көнбатыш ярларына барып җитә, ә Японияга бару өчен Малакка бугазы аша түгел, бәлки тирән сулы Зонд һәм Макасар бугазлары аша чыгып, зур әйләнгеч ясарга мәҗбүр булалар.

[24] Дөньядагы иң зур ун аэропорт санына АКШның 6 аэропорты, шул исәптән Атланта (елына 80 млн пассажир) һәм Чикаго (73 млн) керә. Көнбатыш Европа аэропортларыннан бу исемлеккә Лондонның «Хитроу» (65 млн), Майнадагы Франкфуртның «Рейн-Майн» һәм Парижның «Шарль де Голль» аэропортлары керә. Токионың «Ханеда» аэропорты елына 65 млн пассажир кабул итә. (Мәскәүнең «Шереметьево» аэропорты өчен бу күрсәткеч — 11—12 млн.)

[25] Норвегиянең барлык диңгез флоты диярлек чит ил портлары арасында йөк ташу белән шөгыльләнә. Ә бу — меңнән артык Норвегия судносы үз иленең портларына беркайчан да яки беркайчан да диярлек керми дигән сүз.

[26] 2007 елда Россиядә чит ил фирмалары катнашында төзелгән 20 автомобиль җыю заводы эшли иде: Мәскәүдә («Рено»), Санкт-Петербургта («Тайота», «Ниссан», «Шевроле»), Ленинград өлкәсендә («Форд»), Калининградта («БМВ», «КИА»), Калуга өлкәсендә («Фольксваген»), Таганрогта («Хёндаи»).

[27] Гиннесс рекордлар китабында 2001 елда пассажирлар йөртә торган иң зур лайнер «Мореплаватель» диелә. Аның озынлыгы 311 м, киңлеге 48 м, гомуми тоннажы 142 мең тонна. Ул берьюлы 3114 пассажир һәм 1181 команда кешесен йөртә. Ләкин моннан соң француз шәһәре Сен-Назер верфендә тагын бер лайнер Америка фирмасы оештыра торган диңгез сәяхәтләре өчен төзелгән. Аның биеклеге 23 катлы йорт кадәр, ә киңлеге — 345 м. 15 палубасында җәяү йөрү өчен мәйданнар, рестораннар, бию заллары, бассейннар урнашкан.

**Китап киштәсе**

1. Максаковский В. П. Географическая картина мира — М.: Дрофа, 2006.— Ч. 1.— Тема 5.

2. Максаковский В. П. Новое в мире: цифры и факты: Дополнительные главы к учебнику 10 кл.— М.: Дрофа, 2006.— Раздел 4.

## БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘР АЛУ ӨЧЕН ТУПЛАНМА

**1 нче бирем.** 23 нче рәсемгә анализ ясагыз. XX гасыр дәвамында беренчел энергия ресурслары кулланудагы үзгәрешләргә характеристика бирегез, үсеш этаплары чикләрен билгеләгез.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** «Кушымта»дагы 22 нче таблицадан файдаланып, беренчел энергия ресурсларының төрле илләрдә җан башына исәпләнгән күрсәткечләрен чагыштырып карагыз. Бу күрсәткечләр буенча төрле илләрдә аерманың шактый зур булуы турында дәреслектәге фикерләрне раслаучы мисаллар китерегез.

**2 нче бирем.** Дәреслек тексты, 1 нче һәм 4 нче таблица мәгълүматлары, 24 нче һәм 25 нче рәсемнәр, шулай ук атластагы дөнья энергетикасы картасы, «Кушымта»дагы 20 нче таблица нигезендә бөтендөнья нефть промышленностена җәелдерелгән характеристика бирегез. Нефть чыгаручы «беренче унлык» илләрен, «нефть күперләрен» әйтегез. Уйлагыз: алар нәрсәне раслыйлар? Бөтендөнья хуҗалыгы тармагын сыйфатлаучы махсус планнан файдаланыгыз (177 нче биттә).

**3 нче бирем.** Дәреслек тексты, 1 нче һәм 4 нче таблицалар, 26 нчы рәсем һәм шулай ук «Кушымта»дагы 20 нче таблица, атластагы дөнья энергетикасы картасы нигезендә бөтендөнья газ промышленностена тулы характеристика бирегез. Газ чыгаручы «беренче унлык» илләрен күрсәтегез. Дөнья хуҗалыгының бу тармагына характеристика бирегез (177 нче биттәге планны карагыз).

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** 26 нчы рәсемнән файдаланып, төп «газ күперләренә» характеристика бирегез. Аларның кайсыларында газны газүткәргечләр буйлап тапшыралар, ә кайсыларын сыегайтылган табигый газ рәвешендә диңгез юлы белән ташыйлар?

**4 нче бирем.** Дәреслек тексты, 4 нче таблица һәм 27 нче рәсем мәгълүматлары, шулай ук атластагы дөнья энергетикасы картасы, «Кушымта»дагы 20 нче таблица нигезендә бөтендөнья ташкүмер промышленностена тулы характеристика бирегез. Ташкүмер чыгаручы «беренче унлык» илләрен, төп «күмер күперләрен» аерып күрсәтегез. Шуңа бәйле рәвештә сез нинди чагыштырулар тәкъдим итә аласыз? Бөтендөнья хуҗалыгы тармагын сыйфатлаучы махсус планнан файдаланыгыз (177 нче бит).

**5 нче бирем.** Дәреслек тексты, 4 нче таблица һәм «Кушымта»дагы 20, 23, 24 нче таблицалар, атластагы бөтендөнья энергетика картасы мәгълүматларыннан файдаланып, дөнья энергетикасына характеристика бирегез. Төньяк һәм Көньяк илләрендә ҖЭС, ГЭС һәм АЭСлар җитештергән электр энергиясе күләмнәрен чагыштырыгыз.

**6 нчы бирем.** 28 нче рәсемне анализлагыз һәм дөнья тау промышленностенда барлыкка килгән төп «тимер рудасы күперләренә» характеристика бирегез.

**7 нче бирем.** Дәреслек тексты, 5 нче таблица, 28 нче һәм 29 нчы рәсемнәр, шулай ук атластагы бөтендөнья кара металлургия картасы һәм «Кушымта»дагы 20 нче таблица нигезендә бөтендөнья кара металлургиясенә тулы характеристика бирегез. Бөтендөнья хуҗалыгы тармагын сыйфатлаучы планнан (177 нче бит) файдаланыгыз.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Атластагы бөтендөнья кара металлургия картасы буенча: 1) бергә туры килгән ташкүмер һәм тимер рудасы запасларына, 2) ташкүмер запасларына, 3) тимер рудасы запасларына, 4) күмер һәм руда ташуга ориентлашып эшләүче 3—4 районга һәм үзәккә мисал китерегез.

**8 нче бирем.** Атластагы бөтендөнья төсле металлургия картасы буенча төсле авыр металлар коючы төп илләрне ачыклагыз. Шул ук карта буенча: 1) үз чималына, 2) читтән кертелгән чималга ориентлашкан алюминий промышленностена мисаллар китерегез. Бу анализга таянып, мөмкин булган нәтиҗәләр ясагыз. «Кушымта»дагы 20 нче һәм 25 нче таблицаларны да файдаланыгыз.

**9 нчы бирем.** Атластагы бөтендөнья машина төзү промышленносте картасы, 6 нчы таблица һәм «Кушымта»дагы 20 нче һәм 26 нчы таблица мәгълүматларына таянып, дәреслектәге фикерләрне конкретлаштырыгыз. Бу тармакның бөтендөнья хуҗалыгында тигезсез урнашуын сыйфатлаучы мисаллар китерегез.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Атластагы шул ук картадан файдаланып, «Дөньядагы илләрне машина төзүнең үсеш дәрәҗәсе буенча төркемнәргә бүлү» дигән системалаштыру таблицасын дәфтәрләрегездә төзегез. Илләрнең дүрт төркемен аерып күрсәтегез.

Һәр графага мисал өчен биш-алты илнең исемен языгыз. Бу таблицадан нинди мәгълүматлар алырга мөмкин?

**10 нчы бирем.** Атластагы бөтендөнья химия промышленносте картасы буенча бу тармакның урнашуындагы төп үзенчәлекләрне ачыклагыз, дәреслектәге фикерләрне конкретлаштырыгыз. Шулай ук «Кушымта»дагы 27 нче таблицадан файдаланыгыз.

**11 нче бирем.** Атластагы бөтендөнья туку промышленносте картасы буенча бу тармакның урнашуындагы төп үзенчәлекләрне ачыклагыз, дәреслектә китерелгән фикерләрне конкретлаштырыгыз. «Кушымта»дагы 28 нче таблицаны файдаланыгыз.

**12 нче бирем.** Дәреслек тексты, 7 нче таблица, 32, 33 нче рәсемнәр, атластагы бөтендөнья авыл хуҗалыгы картасы, «Кушымта»дагы 20 нче һәм 29 нчы таблица мәгълүматлары нигезендә бөртекле культураларның урнашуындагы төп үзенчәлекләрне конкретлаштырыгыз. Бодай һәм дөге җитештерүче «беренче унлык» илләрен билгеләгез.

**13 нче бирем.** Дәреслек текстын, 36 нчы рәсем һәм атластагы бөтендөнья авыл хуҗалыгы картасын файдаланып, дәфтәрегездә түбәндәге формада «Терлекчелекнең төп тармакларының урнашуы» дигән системалаштыру таблицасын төзегез:

| Терлекчелек тармаклары | Тармак урнашкан төп илләр |
|---|---|
| а) мөгезле эре терлек асраучылык<br>б) дуңгызчылык<br>в) сарык асраучылык | |

Аерым терлекчелек тармакларының шулай урнашуы сәбәпләрен сез ничек аңлатыр идегез?

**14 нче бирем.** Атластагы бөтендөнья транспорты картасыннан файдаланып, Европа, Азия, Африка, Америка, Австралия һәм Океания илләренең коры җир транспорт челтәре белән ни дәрәҗәдә тәэмин ителүләрен чагыштырыгыз. Тимер юллар бөтенләй булмаган илләргә мисаллар китерегез.

**15 нче бирем.** «Кушымта»дагы 32 нче таблица ярдәмендә диңгез флоты тоннажы буенча «беренче унлык» илләренә характеристика бирегез. 37 нче рәсем буенча диңгез суднолары йөри торган төп юнәлешләрне билгеләгез. Бөтендөнья портларына мисаллар китерегез һәм аларның географиясен аңлатып карагыз.

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** Дөньяның сәяси картасында, диңгез трассалары озынлыгы турындагы мәгълүматлардан файдаланып, Сүәеш каналы аша барган очракта, Лондон белән Токио арасындагы ераклыкның күпмегә кыскаруын исәпләп чыгарыгыз. Шул ук картадан иң озын трассаларны табыгыз.

**16 нчы бирем.** 43—44 нче рәсемнәрне һәм «Кушымта»дагы 33 нче таблицаны дәреслек текстын конкретлаштыру өчен файдаланыгыз. Бөтендөнья туризм масштабларын күрсәтегез. Туристларның зур регионнар арасында ничек бүленүен сыйфатлагыз.

**17 нче йомгаклау биреме.** 1. (Дәфтәрдә эшләү.) Дәреслек тексты, таблицалар һәм 5 нче тема рәсемнәре, шулай ук атластагы карталар нигезендә «Промышленность һәм авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү

буенча дөньяда беренче—өченче урыннарны алып торучы илләр» дигән диаграмма төзегез. Бу диаграммага анализ ясап, нинди сораулар куярга мөмкин?

2. Бу теманы өйрәнгәндә файдаланган дәреслек һәм атлас карталарына анализ ясагыз. Аларда картографик сурәтләүнең нинди ысуллары кулланылуын билгеләгез. Алар сезгә нинди мәгълүматлар бирә ала?

3. (Дәфтәрдә һәм контурлы картада эшләү.) Дәреслек тексты, таблицалар һәм 5 нче тема рәсемнәренә, шулай ук атластагы карталарга таянып, «Промышленность һәм авыл хуҗалыгы продукциясен экспортлаучы төп илләр» дигән таблица төзегез.

Сезнеңчә ничек, саналган экспорт товарлары шул илләрнең халыкара специальләшү тармагын күрсәтә дип әйтергә мөмкинме? Бу илләрне контурлы картага төшерегез.

4. (Дәфтәрдә эшләү.) Географиянең шушы һәм алдагы курсларыннан алынган белемнәргә таянып, түбәндәге форма буенча, «Промышленность, авыл хуҗалыгы һәм транспортның мохиткә йогынтысы» дигән системалаштыручы таблица төзегез:

| Тармакларның 1 нче төркеме | Тармакларның 2 нче төркеме | Тармакларның 3 нче төркеме | Тармакларның 4 нче төркеме |
|---|---|---|---|
| Мохиткә тулысынча яки аның күпчелек компонентларына йогынтысы | Күбесенчә һаваны пычрату | Күбесенчә суны пычрату | Күбесенчә җирне пычрату |

Дәреслек текстыннан файдаланып, таблица мәгълүматларын конкрет географик мисаллар китереп тасвирлагыз.

5. 5 нче теманың берәр параграфындагы текст буенча ике-өч сорау әзерләгез. Текстта бу сорауларга туры җавап булмаска тиеш. Аңарга җавап биреп карагыз.

6. Тема ахырында тәкъдим ителгән берәр китап (аның берәр бүлеге яки кисәге) буенча кыскача реферат төзегез.

## ҮЗЕГЕЗНЕҢ ҺӘМ БЕР-БЕРЕГЕЗНЕҢ БЕЛЕМНӘРЕН ТИКШЕРҮ ТУПЛАНМАСЫ

**Ничек аңлатырсыз:**

1. XX гасыр дәвамында бөтендөнья ягулык-энергетика балансы структурасында нинди үзгәрешләр булды һәм ни сәбәпле?

2. Нефть чыгару һәм аны куллану районнары арасында зур территориаль аерма барлыкка килүнең сәбәбе нәрсәдә?

3. Машина төзү һәм химия промышленностеның бөтендөнья картасында үсеп килүче илләр ни өчен тоташ диярлек «ак тап» барлыкка китерәләр?

4. Бөртекле культуралар урнашуның төп үзенчәлекләре нидән гыйбарәт?

**Ничек уйлыйсыз:**

1. Үсеп килүче илләр икътисады структурасында чыгару тармакларының өлеше зур булу белән алга киткән илләр икътисады структурасында аның кискен кимүе арасында нинди бәйлелек бар? Ул нәрсәне күрсәтә?

2. Эре порт, бигрәк тә бөтендөнья порты, илнең икътисадын, шулай ук бөтендөнья хуҗалыгын чагылдыручы барометр дип раслап буламы?

3. Ни өчен Атлантик океан, Ф. Энгельс әйткәнчә, «дөньяның бөек сәүдә юлы» на әверелде?

**Беләсезме:**

1. Түбәндә саналган илләрнең кайсылары ташкүмер чыгару буенча дөньяда беренче ике урынны алып тора: Канада, Кытай, Бөекбритания, Россия, Польша, АКШ?

2. Түбәндә саналган илләрнең кайсыларында: а) кара металлар, б) төсле металлар, в) кара һәм төсле металларны күбрәк коялар: Россия, Украина, Канада, Замбия, Чили, Малайзия, Япония, АКШ?

3. Бирелгән карта-схемада хәрефләр белән билгеләнгән илләрнең кайсылары: 1) бәрәңге, 2) соя, 3) көнбагыш, 4) шикәр чөгендере, 5) шикәр камышы, 6) чәй, 7) кофе, 8) какао, 9) мамык сүсен дөньяда иң күп җитештерүче булып санала?

4. Түбәндәге илләрнең кайсылары бөтендөнья базарына бодай экспортлаучы иң әһәмиятле биш илгә керә: Аргентина, Бөекбритания, АКШ, Һиндстан, Франция, Канада, Австралия, Бразилия, Индонезия, Мисыр?

5. Түбәндә санап үтелгән илләрнең кайсылары нинди төр терлекләр саны буенча дөньяда беренче урыннарны алып торалар: Кытай, Һиндстан, Австралия?

6. Түбәндә саналган илләрнең кайсылары дөньяда иң зур диңгез флотлары булган өч илгә керә: АКШ, Бөекбритания, Греция, Франция, Япония, Либерия, Панама, Норвегия?

**Булдыра аласызмы:**

1. Текстта һәм тексттагы карталарда телгә алынган түбәндәге илләрне дөньяның контурлы картасына хәтердән төшерә аласызмы: Польша, Румыния, Греция, Филиппин, Малайзия, Корея Республикасы, Либерия, Замбия, Чили, Панама?

2. «Иң яңа тармак», «традицион булмаган (альтернатив) энергия чыганагы», «ирекле икътисади зона», «контейнерлаштыру» дигән терминнарга билгеләмә бирә аласызмы?

3. Нефть чыгаручы төп биш илне җитештерү күләме кимү тәртибендә урнаштыра аласызмы: 1) Мексика, 2) Иран, 3) Россия, 4) АКШ, 5) Согуд Гарәбстаны?

4. Электр энергиясе җитештерүче төп биш илне җитештерү күләме арта бару тәртибендә урнаштыра аласызмы: 1) Россия, 2) Япония, 3) АКШ, 4) Кытай, 5) Канада?

5. Машина төзү промышленностеның үсеш дәрәҗәсе югары, уртача һәм түбән булган илләргә икешәр мисал китерә аласызмы?

6. Бөтен дөньядагы иң зур портның исемен әйтеп, картада күрсәтә аласызмы? Европа, Азия, Төньяк Америкадагы дөнья портларына икешәр мисал китерергә.

7. Түбәндәге раслауларның дөреслеген тикшерегез, кирәк урыннарда дөресләп җавап бирегез: 1) дөньяда чыгарыла торган нефтьнең күбрәк өлеше ягулыкның шушы төрен җитештерүче илләрнең үзендә кулланыла; 2) икътисади үсеш алган Көнбатыш илләре арасында Япония корычны иң күп җитештерүче ил булып санала; 3) дөньяда җыела торган барлык дөгенең 9/10 өлеше Азия илләренә туры килә; 4) бөтендөнья тимер юл челтәренең гомуми озынлыгы бик тиз үсә; 5) Австралия экспортының күпчелеген машиналар һәм җиһазлар тәшкил итә.

8. Түбәндәге җөмләләрдә төшеп калган сүзләрне языгыз: 1) Бөтендөнья энергетикасы үзенең үсешендә ________ этап узды. 2) Бөтендөнья машина төзү промышленностеның ________ төп регионы барлыкка килде. 3) Бөртекле культуралар барлык эшкәртелә торган мәйданның ________ били, алар арасында бигрәк тә ________ аерылып тора. 4) «Арзанлы әләмгә» ия булган илләргә ________ ачык мисал булып торалар.

## 5 НЧЕ ТЕМАГА МЕТОДИК АЧКЫЧЛАР

### Боларны исегезгә төшерегез

1. Россия халык хуҗалыгының структурасы һәм иң әһәмиятле тармакара производство комплекслары географиясенең төп үзенчәлекләре. (География, 9 нчы сыйныф.) 2. Материкларда

табигый зоналарның урнашуы. (География, 7 нче сыйныф.) 3. Океаннарда табигый байлыклар һәм хуҗалык эшчәнлеге төрләре. (География, 7 нче сыйныф.) 4. Культуралы үсемлекләрнең килеп чыгуы. (Биология, 7 нче сыйныф.) 5. Нефтьнең составы һәм үзлекләре, тимер һәм алюминийның табигый кушылмалары, ашламалар классификациясе. (Химия, 9, 10 нчы сыйныфлар.) 6. Җылылык двигательләре һәм табигатьне саклау. (Физика, 10 нчы сыйныф.) 7. Бөтендөнья табигый ресурслары һәм экологик проблемалар, производствоны урнаштыру факторлары, халыкара специальләшү тармагы. (География, 10 нчы сыйныф.) 8. Төшенчәләр һәм терминнар: территориаль-производство комплексы (ТПК), эшкәртү промышленносте, чыгару промышленносте, материал һәм энергия сыешлыгы, интенсив һәм экстенсив үсеш юлы, ягулык-энергетика балансы, конструкцион материаллар, йөк әйләнеше, экспорт, импорт. (География, 9 нчы сыйныф.)

## Боларны үзләштерегез

**5 нче теманың төп идеяләре:**

1. ФТР чорында җитештерүче көчләрнең географиясенә фәнни-техник прогресс хәлиткеч йогынты ясый. 2. Дөньякүләм икътисади мөнәсәбәтләрдә актив катнашмаган бер генә ил дә тиз үсә алмый.

**5 нче темадагы төп фәнни белемнәр:**

1. Бөтендөнья ягулык-энергетикасы, металлургия, машина төзү, химия, туку промышленностеның составы һәм урнашу үзенчәлекләре. 2. «Яшел революция» турында төшенчә. 3. Дөньядагы үсемлекчелек һәм терлекчелекнең составы һәм урнашу үзенчәлекләре. 4. Дөньяда коры җир, су һәм һава транспортының составы һәм урнашу үзенчәлекләре. 5. Дөньякүләм икътисади мөнәсәбәтләрнең составы һәм географиясенең төп үзенчәлекләре. 6. Теманың төп төшенчәләре: 1) иске тармак, 2) яңа тармак, 3) иң яңа тармак, 4) бөтендөнья энергетикасы кризисы, 5) традицион булмаган энергия чыганагы, 7) «тау токымнары чыгаручы бөек держава», 8) товарлыклы авыл хуҗалыгы, 9) агробизнес, 10) кулланучы (аз товарлыклы) авыл хуҗалыгы, 11) «яшел революция», 12) бөтендөнья транспорт системасы, 13) региональ транспорт системасы, 14) дөнья порты, 15) дөньякүләм икътисади мөнәсәбәтләр, 16) ачык икътисад, 17) ирекле икътисади зона, 18) туры инвестицияләр.

### Сез нәрсәләр эшли белергә тиеш

1. Үрнәк планнан файдаланып, бөтендөнья хуҗалыгы тармагына характеристика бирергә. 2. Производствоны урнаштыру факторлары һәм халыкара специальләшү тармаклары турындагы белемнәрне бөтендөнья хуҗалыгы тармакларының урнашуын анализлау өчен файдаланырга. 3. Дәреслек текстын, статистик таблицалар, карталар, графиклар, фотоиллюстрацияләрне кулланып, бөтендөнья хуҗалыгы тармакларына характеристика бирергә, аларны системалаштыра, чагыштыра һәм гомумиләштерә белергә. 4. Күп төрле чыганаклардан файдаланып, төрле типтагы таблицалар төзергә. 5. Укылган китапка (бүлек, кисәк) кыскача реферат әзерләргә.

### Мөстәкыйль эш күнекмәләре булдыру буенча күрсәтмәләр һәм планнар

**Бөтендөнья хуҗалыгы тармагына характеристика планы.**

1. Тармакның бөтендөнья хуҗалыгында әһәмияте, аның составы, аның үсешенә ФТРның йогынтысы. 2. Тармакның чимал һәм ягулык ресурслары һәм аларның урнашуы. 3. Продукция җитештерүнең төп географик регионнарга бүленгән күләмнәре. 4. Җитештерүче төп илләр. 5. Төп җитештерү районнары һәм үзәкләре; бу тармакның нәкъ шул районда урнашуына китергән факторлар. 6. Тармак үсешенә бәйле рәвештә туган экологик проблемалар. 7. Продукцияне экспортлаучы төп илләр (районнар). Продукцияне импортлаучы төп илләр (районнар). Бик әһәмиятле йөк агымнары. 8. Тармакның үсеш һәм урнашу перспективалары.

## 6 НЧЫ ТЕМАНЫҢ ПЛАН-СХЕМАСЫ



# II кисәк. ДӨНЬЯ РЕГИОННАРЫНА ХАРАКТЕРИСТИКА

## 6 нчы тема. ЕВРОПА ЧИТ ИЛЛӘРЕ

Европа чит илләре (БДБ илләренә карата) 5,4 млн км$^2$ территория алып тора, халкы 2005 елда 520 млн кеше тәшкил иткән. Монда тарихи язмышлары уртак булган, сәяси, икътисади һәм мәдәни элемтәләр белән тыгыз бәйләнгән 40 лап суверен дәүләт (микродәүләтләрне дә кертеп) урнашкан. Европа чит илләре — бөтендөнья цивилизациясе учакларының берсе. Бөек географик ачышлар, промышленностьта кискен борылышлар, шәһәр агломерацияләре, халыкара икътисади интеграцияләр шушы илләргә туры килә. Белгәнегезчә, «европоцентризм» чоры инде узды, ләкин шуңа карамастан безнең көннәрдә дә бу регионның бөтендөнья сәясәтендә һәм икътисадында әһәмияте бик зур.

### 1. ЕВРОПА ЧИТ ИЛЛӘРЕНӘ ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКА БИРӘБЕЗ

**1. Территориясе, чикләре, урыны: төп ике үзенчәлеге.** Европа чит илләренең территориясе төньяктан көньякка (Шпицберген утравыннан Крит утравына кадәр) 5 мең кмга, ә көнбатыштан көнчыгышка 3 меңнән артыграк километрга сузылган. Европа илләренең азмы-күпме зурраклары да бар, ләкин аларның күбесе чагыштырмача зур түгел. [1].

Бельгиялеләр шаяртып болай сөйлиләр: «Безнең илгә машина белән керсәгез, тормозга басарга онытмагыз, юкса күрше дәүләткә кереп китүегез ихтимал». Дөрестән дә, тиз йөрешле Мәскәү — Лондон поезды Бельгияне 140 минутта кисеп уза. Күп кенә илләрнең поездларында йокы вагоннарының булмавы да юкка гына түгел. Регионның сәяси картасында кечкенә илләр яки микродәүләтләр аерым төркем тәшкил итә. [2].

Европа чит илләренең икътисади-географик урыны төп ике үзенчәлек белән билгеләнә.

Беренчедән, бу илләрнең берберсенә карата *күршедәш булулары*. Территорияләре чагыштырмача кечкенә, эчкәре районнары аз [3], ә транспорт «үтешлеге» яхшы булган шартларда, бу илләр я чиктәш, я бик якын торалар. Өстәвенә арадагы чикләр транспорт өчен артык каршылыклар тудырмый торган табигый уңайлы урыннардан үтә.

Икенчедән, күпчелек илләрнең *диңгез буенда урнашулары*, хәрәкәт аеруча җанлы булган диңгез юлла-

рына якын торулары. Регионның көнбатышында диңгездән 480 км, ә көнчыгышында 600 км дан ераграк урнашкан бер генә урын да юк. Бөекбритания, Нидерланд, Дания, Норвегия, Исландия, Португалия, Испания, Италия һәм Грециянең бөтен тормышлары бик борынгы заманнардан бирле диңгез белән тыгыз бәйләнгән. Ул илләрнең һәрберсен «диңгез кызы» дип әйтергә мөмкин. (1 нче бирем.)

Регионның сәяси картасы XX гасырда өч тапкыр зур үзгәрешләргә дучар булды: Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышларыннан соң һәм 90 нчы елларда (Германиянең берләшүе, Балтия илләренең бәйсезлек алуы, Югославия һәм Чехословакиянең таркалуы, Көнчыгыш Европа илләрендә җәмгыять төзелешенең үзгәрүе). 90 нчы еллар ахырында Европа чит илләренең күбесендә хакимияткә консерваторлар партияләренә алмашка социал-демократик партияләр килде. *Европада куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек оешмасы* (ОБСЕ) регионның сәяси консолидациясенә булышлык итә. Бу оешмага 56 ил (шулай ук АКШ, Канада, БДБ илләре дә) керә. ***Европа Советы***[1] аеруча зур роль уйный башлый. Шуның белән беррәттән, НАТО блогының йогынтысы саклана һәм арта бара.

Европа чит илләре арасында республикалар да, монархияләр дә, унитар һәм федератив дәүләтләр дә бар. (2 нче бирем.)

**2. Табигый шартлар һәм ресурслар: зур эчке аермалар.** Промышленность өчен табигый алшартлар файдалы казылмалар географиясенең көчле йогынтысы астында формалашкан. Ләкин регионның төньяк (платформалы) һәм көньяк (җыерчыклы) өлешләрендә аларның составы нык аерыла.

Төньяк өлештә руда хәлендәге файдалы казылмалар да, шулай ук янучан казылмалар да очрый. Рудалар, нигездә, Балтыйк калканы һәм герцин зонасы җыерчыклыгына, ә янучан казылмалар исә платформа өслегендәге утырмаларга һәм аның бөгелгән кырыйларына «бәйләнгән».

**Мисал.** Ташкүмер бассейннарыннан — ГФРдагы Рур бассейны һәм Польшадагы Югары Силезия бассейннары, нефть-газ бассейннарыннан — Төньяк диңгез бассейны, тимер рудасы бассейннарыннан — Франциядәге Лотарингия һәм Швециядә Кируна бассейннары аеруча аерылып торалар.

Көньяк өлештә магматик һәм утырма чыгышлы (бокситлар) руда ятмалары өстенлек итә, ләкин ягулык ресурсы запаслары монда азрак. *Аерым илләрдә файдалы казылмалар җыелмасының «тулы комплектлы булмавы» шактый дәрәҗәдә территориянең тектоник төзелеше белән аңлатыла.* (3 нче бирем.)

[1] Европа Советы — консультатив сәяси оешма. Ул 1949 елда кеше хокуклары, азатлык һәм парламент демократиясе өлкәсендә интеграцион процессларга булышлык итү йөзеннән оештырыла. Аның секретариаты Франциянең Страсбург шәһәрендә урнашкан. Европа Советына Россия 1996 елда 39 нчы әгъза буларак кабул ителде.

Европа чит илләренең гидроэнергетик ресурслары шактый зур, ләкин ул, нигездә, Альп, Скандинавия һәм Динар таулары районнарына туры килә. Күп кенә илләрдә алар инде тулысынча файдаланылып беткән.

Регионның авыл хуҗалыгы өчен табигый алшартлары чагыштырмача уңайлы һәм күп гасырлар буена файдаланылып киләләр. Нәтиҗәдә җирләр инде күптән эшкәртелеп беткән, башка резервлар юк, ә җиргә «йөкләмә» һаман арта бара. Шуңа күрә зур булмаган диңгез буе илләре, беренче чиратта Нидерланд, диңгез яр буйларын үзләштерүне дәвам итә.

**Мисал.** Йөз еллар буена дамбалар һәм плотиналар кору юлы белән Нидерландның бөтен мәйданының 1/3 өлеше диярлек диңгездән яулап алынган. Монда «Алла Җирне яраткан, ә голландиялеләр — Голландияне», дигән әйтемнең халык теленә керүе юкка гына түгел. Элек диңгез култыгы булган Эйсселмер күлен корыту һәм аны польдерлар системасына әверелдерү эшләре тәгәлләнә. Диңгез буен тулысынча саклауга багышланган «Дельта-план» инде тормышка ашырылып бара. [4].

Агроклиматик ресурслар регионның уртача пояста, ә көньякта субтропик пояста урнашуы белән билгеләнә. Урта диңгез районнарында игенчелек ясалма сугаруга мохтаҗ. Сугарыла торган җирләрнең күпчелек өлеше Италиядә һәм Испаниядә.

Урман хуҗалыгын алып бару өчен иң уңайлы табигый алшартлар Швеция һәм Финляндиядә. Монда типик урман ландшафтлары өстенлек итә: түбәнлекләр, калкулыклар, елга һәм күл буйлары урманнар белән капланган, урманнар торак пунктларга кадәр үк килеп җитә. Халык теленә кергәнчә: «Урмансыз Финляндия йонсыз аю белән бер».

Европа чит илләренең табигыйрекреацион ресурслары да бик күп төрле һәм бай.

**3. Халыкның яңарып торуы, миграциясе, милли составы, урбанизация.** Соңгы вакытларда Европа чит илләрендә халык саны бик акрын үсә башлады. Белгәнегезчә, бу хәл регион халкының яңарып торуы өчен монда демографик шартларның катлаулы булуы белән аңлатыла. Барлыгы 15 илдә («Кушымта»дагы 12 нче таблицаны карагыз) хәтта халыкның табигый кимүе, депопуляция күзәтелә, аны демографик сәясәт чаралары да туктата алмый. Нигезе «тараеп» килгән яшь-җенес пирамидаларында мондый депопуляция ачык чагыла (46 нчы рәсемне карагыз). Бер үк вакытта монда халыкның яшь составы да үзгәрә, өлкән яшьтәгеләрнең өлеше арта бара (12 нче рәсемне карагыз). Нәтиҗәдә, БМОның фаразлавына караганда, XXI гасыр урталарында региондагы күпчелек илләрнең халкы кимеячәк. [5].

Болар барысы бергә бөтендөнья халкының тышкы миграциясе системасында регионның өлеше кискен үзгәрүгә китерде. Бөек географик ачышлар чорыннан бирле эмиграциянең төп үзәге булган *Европа чит илләре хезмәт иммиграциясенең дөньякүләм үзәгенә әверелде.* Хәзер монда якынча

20 млн чит ил эшчесе һәм аларның гаилә әгъзалары исәпләнә. Аларның шактый өлеше бу ил гражданнары түгел, ә вакытлы кунак-эшче (немецча «гастарбайтер») хәлендә яши. Аларның иң күбе Германиядә — 7 млн нан артык яши. [6].

Хезмәт иммигрантларын кабул итүче илләр, шулай итеп, арзан эшче көчләрнең өстәмә чыганагын алалар. Мигрантларның килүе халыкның артуына, аның яшь составына уңай йогынты ясый. Шуның белән бергә, ул халыкның сыйфатын начарайта, күп кенә социаль проблемаларны җитдиләштерә. Соңгы вакытта регионның күп кенә илләрендә җирле халыкның мигрантлар һәм качаклар белән бәрелешләре ешайды. (4 нче бирем.)

Милли составы ягыннан Европа чит илләренең халкы чагыштырмача бертөрле: *регионда яшәүче 62 халыкның күпчелеге һинд-европа телләре семьялыгына керә.* Шул ук вакытта славян, роман, герман төркемнәренең тугандаш телләре арасында охшашлыклар шактый күп. [7]. Бу урал семьялыгы телләренә дә хас. [8]. Шулай булуга карамастан регионның меңнәрчә еллар дәвамында формалашкан этник картасы бик үк гади түгел. Бер милләтле дәүләтләр белән беррәттән, монда милли составы катлаулы дәүләтләр дә шактый. Соңгы вакытларда аларда милләтара мөнәсәбәтләрнең киеренкелеге күзәтелә.

**Мисал.** Бөекбританиядә озак вакытлар инде шундый «кайнар нокта» булып Төньяк Ирландия (Ольстер), Испаниядә Басклар иле санала. Бельгиядә — фламандлылар һәм валлоннар, Румыниядә — румыннар һәм венгрлар, Сербиядә серблар һәм албанлылар арасында төрле аңлашылмаучылыклар яшәп килә. (5 нче бирем.)

Европа чит илләрендә христиан дине өстенлек итә. Көньяк Европада — католик, ә Төньягында протестант дине таралган; Урта өлешендә аларның нисбәте тигез. Римда бөтендөнья католикларының үзәге — Ватикан урнашкан. [9]. Соңгы вакытта мөселман илләреннән мигрантларның артуы «ислам факторының» көчәюенә китерде.

**Мисал.** 2006 елда ЕС илләрендә мөселман илләреннән 20 млн нан артык мигрант булса, 10 елдан аларның саны икеләтә артачак. Роттердам һәм Марсель шәһәрләрендә мөселманнар халыкның 25 % ын, Брюссельдә — 15 % ын, Лондон һәм Парижда 10 % ын тәшкил итә.

Европа чит илләре — дөньяда халыкның иң тыгыз урнашкан регионнарының берсе, халыкның уртача тыгызлыгы 1 км$^2$ га 100 кешедән артыграк. Шуның белән бергә, халыкның урнашуы иң элек шәһәрләр географиясе белән билгеләнә. *Биредә урбанизация дәрәҗәсе дөньяда иң югарылардан санала:* уртача алганда шәһәрләрдә барлык халыкның 78 % ы, ә кайбер илләрдә 80 % тан, хәтта 90 % тан артыгы яши (18 нче рәсемне карагыз). Шәһәрләрнең гомуми саны күп меңнәрчә исәпләнә, аларның челтәре дә шактый тыгыз. Акрынлап, мең еллар дәвамында **шәһәрләрнең Көнбатыш-Европа тибы** формалашкан, аның тамыры Рим империясе чорына һәм Урта гасырларга барып тоташа.

Мондый шәһәрләрнең үзәгендә, гадәттә, ратушалы һәм соборлы (49 нчы рәсемне карагыз) үзәк мәйдан (базар мәйданы) була. Бу мәйданнан радиаль рәвештә тар гына иске шәһәр урамнары сузылып китә. Анда йортлар, кибетләр, элекке цех гильдияләренең биналары тезелеп киткән. Иске шәһәрдә, гадәттә, тарихи-архитектура истәлекләре саклананган. Шәһәрнең башка өлешләрендә соңрак төзелгән биналар өстенлек итә. Көнбатыш Европаның күп кенә иске шәһәрләре киң танылган, хәтта бөтен дөньяга билгеле.

Европа чит илләрендә урбанизациянең үзенчәлекле сыйфаты булып халыкның зур шәһәрләрдә һәм шәһәр агломерацияләрендә бик тыгыз урнашуы торды. Лондон, Париж һәм түбән Рейн-Рур агломерацияләре иң зурлардан санала.

Ләкин узган гасырның 70 нче елларында, шәһәрләр һәм шәһәр агломерацияләренең көчле үсешеннән соң, халыкның үзәктән башта якындагы, аннары ерактагы бистәләргә, ә аннары ераграк вак шәһәрләргә һәм авыл җирләренә күчүе башлана («яшел дулкын»). Нәтиҗәдә Лондон, Париж, Гамбург, Вена, Милан һәм башка күп кенә шәһәрләрнең үзәк районнарында халык саны стабильләшә, хәтта кими башлый. Бу процесс *субурбанизация*[1] дип атала.

Субурбанизация бик күп сәбәпләр белән аңлатыла: алар торак фондының искергәнлеге һәм шәһәр үзәгендә халыкның бик тыгыз яшәве, мохитнең торышы начараюы, предприятиеләрне реконструкцияләү өчен урын җитешмәве, күп кенә эш урыннарының шәһәр читенә күчерелүе, массакүләм автомобиль куллану һәм шулай ук күп кенә гаиләләрнең үз йортлары белән яшәргә омтылуыннан гыйбарәт. Ләкин әле бу урбанизация процессының тукталуы турында сөйләми. Киресенчә, урбанизациянең авыл җиренә дә үтеп керүен күрсәтә һәм шәһәр белән авыл арасындагы чик шартлы күренешкә әйләнә. Хәзерге вакытта авыл халкының фәкать 2/5 өлеше авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнә.

Шул ук вакытта субурбанизация шәһәр халкының «агылып җәелүенә» һәм гаять зур шәһәрләшкән районнар һәм зоналар формалашуга китерә. (6 нчы бирем.)

**4. Хуҗалыгы: дөньяда тоткан урыны, илләр арасында аермалар.** Европа чит илләре, бөтен бер регион буларак, промышленность һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе, товар һәм хезмәт күрсәтү экспорты, алтын һәм валюта запаслары, бөтендөнья туризмының үсеше буенча бөтендөнья хуҗалыгында беренче урынны алып тора.

Аңлашыла ки, *регионның икътисади куәтен беренче чиратта Көнбатышның «зур җиделек» рә-*

---

[1] **Субурбанизация** (лат. *sub* — астында, янында; *urbs* — шәһәр) — шәһәр һәм иярчен шәһәр яңы зоналарының шактый кызу темплар белән барган үсеш процессы, ул халыкның һәм эш урынының үзәктән күчүенә китерә.

## 12 НЧЕ ТУПЛАНМА

46




47






48

49

46 нчы рәсем. ГФРда яшәүчеләрнең яшь-җенес пирамидасы

47 нче рәсем. Европа чит илләрендә башка илдән килгән эшчеләр

48 нче рәсем. Европа чит илләрендәге иң зур шәһәр агломерацияләре

49 нчы рәсем. Шверин шәһәренең үзәге (ГФР)

*тендәге дүрт иле* — ГФР, Франция, Бөекбритания һәм Италия билгели. Нәкъ менә шушы илләр төрле промышленность тармаклары һәм производстволарының иң киң комплексына ия. Ләкин соңгы унъеллыкларда алар арасындагы нисбәт шактый үзгәрде. Лидерлык роле ГФРга күчте, аның икътисады реиндустрияләшү юлында бигрәк тә динамикалы үсә. Ә элеккеге «бөтендөнья остаханәсе» саналган Бөекбритания үзенең күп кенә алдынгы позицияләрен югалтты.

Калган Европа чит илләренең — Испания, Нидерланд, Швейцария, Бельгия һәм Швециянең икътисади куәте шактый зур. Югарыда китерелгән төп дүрт илдән аермалы буларак, аларның икътисады, кагыйдә буларак, Европа яки дөньякүләм казаныш алган, аерым тармаклар буенча специальләшкән.

Кечкенә һәм уртача зурлыктагы илләр халыкара икътисади мөнәсәбәтләргә аеруча киң тартылалар. Бельгия һәм Нидерланд икътисадларының «ачыклык» дәрәҗәсе бигрәк тә югары.

Регионның икътисад картасында Көнчыгыш Европа илләре аерым урын алып тора. Монда 80 нче еллар ахырыннан башлап элекке җәмәгать милке һәм үзәкләштерелгән планлаштыру системасыннан базар принципларына нигезләнгән яңа системага күчү башланды. Алар озак вакытлар буена икътисади-социаль үсеш юлында иң элек Советлар Союзына (Балтия илләре элек аның составында булган) юнәлеш тоткан постсоциалистик илләр, хәзер алар Европаның Көнчыгышына түгел, бәлки күбрәк Көнбатышына «карыйлар». Юнәлешнең шулай үзгәрүе хуҗалыкның тармак һәм территориаль структурасына, тышкы икътисади элемтәләргә зур йогынты ясый.

**5. Промышленность: төп тармаклар.** Европа чит илләренең «йөзе» халыкара географик хезмәт бүленешендә 200 елдан артыграк вакыт дәвамында күбесенчә промышленность үсеше белән билгеләнеп килде, һәм ул хәзер дә шулай билгеләнә.

**Мисал.** Регион металл эшкәртү станокларын, промышленность өчен роботлар, төгәл һәм оптик приборлар, автомобильләр, тракторлар, нефть продуктлары, пластмассалар, химик сүсләрне АКШка караганда күбрәк җитештерә.

Машина төзү — Европа чит илләре өчен төп промышленность тармагы. Европа — машина төзүнең ватаны. Региондагы барлык промышленность продукциясенең 1/3 өлеше һәм экспортның 2/3 өлеше шушы тармакка туры килә.

Автомобиль җитештерү аеруча зур үсеш алды. «Рено» (Франция), «фольксваген» һәм «мерседес» (ГФР), ФИАТ («Фабрика итальяна аутомобиле Торино»), «вольво» (Швеция) автомобиль маркалары бөтен дөньяда дан казанды. Бөекбритания, Бельгия, Испания һәм башка илләрдә «Форд-мотор» компаниясе заводлары эшли. Шулай ук «Тойота», «Хонда», «Ниссан» кебек япон компанияләре күп кенә автомобиль җыю заводлары төзеделәр.

Машина төзү хезмәт ресурсларына, фәнни база һәм инфраструктурага ориентлашкан, күбесенчә зур шәһәрләргә, агломерацияләргә, шул исәптән башкалаларга тартыла. Ләкин шуның белән бергә, машина төзүнең күп санлы тармаклары ориентлашуының үзенчәлекләре бар.

**Мисал.** Бөекбританиядә электротехника, электроника, приборлар төзү, авиаракета-космос промышленностенда — Лондон районы, станоклар һәм автомобильләр төзү өлкәсендә — Бирмингем районы, туку машиналары төзүдә — Манчестер районы, суднолар төзүдә Глазго районы аерылып тора. [10].

Ләкин машина төзү промышленносте бик таралып урнашкан районнар һәм хәтта илләр дә бар. ГФР, Бельгия, Нидерланд, Бөекбритания һәм Чехиядә бу тармак предприятиеләре һәр шәһәрдә диярлек бар.

Европа чит илләрендә химия промышленносте машина төзүдән соң икенче урында тора. Бу бигрәк тә Европада гына түгел, ә бөтен дөньяда иң «химияләшкән» илгә — ГФРга кагыла.

Икенче бөтендөнья сугышына кадәр химия промышленносте ташкүмер һәм соры күмер, калий һәм аш тозы, пирит табуга нигезләнгән һәм шул казылмалар чыгарылган районнарга урнашкан була. *Тармак углеводородлы чималларга ориентлаша башлагач, химия промышленносте «нефтькә таба» күчә.* Регионның көнбатыш өлешендә Темза, Сена, Рейн, Эльба, Рона елгаларының эстуарийларында нефть химиясенең эре үзәкләре үсеп чыга. Бу тармак монда нефтьне эшкәртү белән бергә алып барыла.

**Мисал.** Регионда нефть химиясе производствосының һәм нефть эшкәртү заводларының (НПЗ) иң зур үзәге Нидерландта Рейн һәм Шельда эстуарийларында, шулай ук Роттердам районында барлыкка килгән. Ул, нигездә, барлык Көнбатыш Европага хезмәт күрсәтә.

Регионның көнчыгыш өлешендә «нефтькә таба» күчү магистраль нефть һәм газүткәргеч трассаларында нефть эшкәртү заводлары һәм нефть химиясе комбинатлары төзелүгә китерде.

**Мисал.** Чехия, Словакия, Польша һәм Венгриядәге төп нефть эшкәртүче һәм нефть химиясе предприятиеләре Советлар Союзыннан нефть, табигый газ китерүче «Дуслык» халыкара нефть үткәргече һәм газ үткәргече трассаларында төзелә. Болгариядә дә нефть химиясе шул сәбәпле Кара диңгез буена күчкән.

Европа чит илләренең күпчелегенең ягулык-энергетика хуҗалыгында регионның үзендә чыгарыла торган (Төньяк диңгездә), шулай ук үсеп килүче илләрдән һәм Россиядән китерелә торган нефть, табигый газ төп урынны алды.

**Мисал.** Төньяк диңгез чыганакларыннан нефть һәм табигый газ магистраль торба үткәргечләрнең тулы бер системасы буенча күп кенә илләргә килә. Сыегайтылган газ исә танкер-метановозлар белән Алжирдан китерелә. Ә регионның 20 гә якын илена Россиядән китерелә торган газ тагын да зуррак әһәмияткә ия. [11]. Россия нефте нефтьүткәргечләр буенча да, диңгез аша да китерелә.

Бөекбритания һәм ГФРда күмер чыгару һәм аны куллану кискен кимеде, ә Бельгия, Нидерланд һәм Франциядә аны чыгару бөтенләй туктатылды. Регионның көнчыгышында күмергә ориентлашу саклана, ләкин ташкүмергә түгел (Польша, Чехия), ә күбрәк соры күмергә.

ҖЭСларның да күбесе күмер бассейннарына ориентлашкан. Ләкин алар шулай ук диңгез портларында (читтән китерелгән ягулык исәбенә), зур шәһәрләрдә дә төзелгәннәр. Электр энергетикасы структурасына һәм географиясенә АЭСлар төзү, бигрәк тә Франция, Бельгия, ГФР, Бөекбритания, Швеция, Чехия, Словакия, Венгрия һәм Болгариядә, зур йогынты ясый. Регионда аларның саны 80 нән артыграк. Дунай елгасында һәм аның кушылдыкларында, Рон, Рейн, Дуэро елгаларында ГЭСлар яисә аларның тулы каскадлары корылган.

**Мисал.** Иң зур гидроузел 70 нче еллар башында Дунайдагы Тимер капка тарлавыгында Румыния һәм Югославия белән берлектә төзелә. ГЭСның егәрлеге 2,1 млн кВт, елына 11 млрд кВт электр энергиясе җитештерелә.

Шулай да Норвегия, Швеция һәм Швейцариядән кала, күп илләрдә ГЭСлар ярдәмче рольне генә үти. Регион гидроресурсларының инде 4/5 е файдаланылган булу сәбәпле, соңгы вакытта күбесенчә аеруча экономияле АЭСлар төзелә. XX гасыр башында Италиядә дөньяда беренче геотермаль электр станциясе (ГеоТЭС) төзелә, шулай ук Исландиядә дә геотермаль энергия файдаланыла.

Европа чит илләрендә металлургия промышленносте, нигездә, ФТР чоры башланганчы ук формалаша. Кара металлургия иң элек металлургия ягулыгы һәм (яки) чималы булган илләрдә — ГФР, Бөекбритания, Франция, Испания, Бельгия, Люксембург, Польша һәм Чехиядә нык үсеш ала.

**Мисал.** Польшада Көньяк металлургия базасы Югары Силезия ташкүмер бассейны нигезендә формалаша. Анда ике дистә чамасы завод, шул исәптән ике бик эре комбинат — «Хута-Краков» һәм «Катовице» керә.

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң эре металлургия комбинатлары, читтән кертелгән югарырак сыйфатлы һәм арзанрак тимер рудасы һәм металл ватыклары импортын күздә тотып, диңгез портларында төзелде һәм киңәйтелде.

**Мисал.** Диңгез портларында төзелгән иң зур заманча комбинат — Таранто шәһәрендә (Италия). Ул елына 10 млн т дан артыграк корыч җитештерә.

Соңгы вакытта күбесенчә эре комбинатлар түгел, ә мини-заводлар төзелә.

Алюминий һәм бакыр промышленностьлары — төсле металлургиянең иң мөһим тармаклары. Алюминий җитештерү боксит запаслары зур булган илләрдә (Франция, Италия, Венгрия, Румыния, Греция) һәм шулай ук алюминий чималы булмаган, әмма электр энергиясе күп җитештерелә торган илләрдә

50

50 нче рәсем. Европа чит илләренең промышленность районнары

51 нче рәсем. Испания. Барселонада диңгез порты

52 нче рәсем. Европа чит илләрендә үсемлекчелек

53

53 нче рәсем. Голландиянең данлыклы тюльпан кырлары

54

54 нче рәсем. Роттердам портының планы

55

55 нче рәсем. Мадрид үзәгендә Сервантес һәйкәле фрагменты

(Норвегия, Швейцария, ГФР, Австрия) барлыкка килә. Соңгы вакытта алюминий заводлары үсеп килүче илләрдән диңгез юлы белән китерелә торган чималга ориентлашып төзелә башлады. Бакыр промышленносте ГФР, Франция, Бөекбритания, Италия, Бельгия, Польша [12] һәм Сербиядә аеруча нык үсеш алган.

Чимал чыганакларына нигезләнгән **урман промышленносте** беренче чиратта Швеция һәм Финляндиядә халыкара специальләшү тармагына әверелде, бу илләр күптәннән бирле регионның төп «урман цехы» хезмәтен үтиләр.

Инде белгәнегезчә, Европа чит илләренең индустриясен башлап җибәргән **җиңел промышленность** шактый дәрәҗәдә үзенең элекке әһәмиятен югалтты. Промышленность революциясе таңында ук формалашкан иске туку районнары (Бөекбританиядә — Ланкашир һәм Йоркшир, Бельгиядә — Фландрия, Франциядә — Лион, Италиядә — Милан) һәм XIX гасырда Польшада барлыкка килгән Лодзь районы безнең көннәрдә дә яшәп килә, әлбәттә. Ләкин соңгы вакытта җиңел промышленность арзанлы эшче көчләр резервы булган Көньяк Европага күчә башлады. Шулай итеп, Португалия регионның төп «тегү фабрикасына» әверелде. Ә аяк киемнәре җитештерү буенча (елына 30 млн пар) Италия фәкать Кытайдан гына калыша.

Күп кенә илләрдә өй җиһазлары, музыка кораллары, пыяла һәм металл әйберләр, бизәнү әйберләре, уенчыклар һ.б. җитештерү буенча халыкның бай милли традицияләре сакланып килә. [13]. (7 нче бирем.)

**6. Авыл хуҗалыгының төп өч төре.** Күпчелек илләр авыл хуҗалыгы продукциясенең төп төрләре буенча үзләренең ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерә һәм аны тышкы базарга да чыгарырга тырыша. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң регионның аграр төзелешендә, ***җир биләү*** һәм ***җирдән файдалану***[1] системасында зур үзгәрешләр булды. Алар универсаль вак крестьян хуҗалыгыннан агробизнес системасына кергән югары товарлыклы специальләшкән эре хуҗалыкка күчүдән гыйбарәт. Югары дәрәҗәдә механикалаштырылган эре ферма авыл хуҗалыгы предприятиесенең төп төренә әверелде. Ләкин Көньяк Европада әле алпавыт җирбиләүчелеге һәм вак крестьян-арендаторларның җирдән файдаланулары саклана.

Европа чит илләрендә авыл хуҗалыгының төп тармаклары — үсемлекчелек һәм терлекчелек һәркайда таралган һәм икесе бергә алып барыла. *Табигый һәм тарихи шартлар йогынтысында регионда авыл хуҗалыгының төп өч тибы: 1) Төньяк Европа, 2) Урта Европа һәм 3) Көньяк Европа типлары формалашкан.*

---

[1] Җир биләү ул — билгеле хокукка нигезләнеп җиргә хуҗа булу, җирдән файдалану — закон яки урнашкан гадәт тәртибендә шул җирдән файдалану. Җир дәүләт биләмәсе, хосусый (крестьян, фермер, алпавыт) һәм чиркәү биләмәсе булырга мөмкин. Җирдән файдалануның ике төрен — шәхси милекне һәм аренда юлын аералар.

Төньяк Европа тибы Скандинавия, Финляндия һәм шулай ук Бөекбританиядә киң таралган, аңа интенсив сөт җитештерү терлекчелеге, үсемлекчелектә терлек өчен азык культуралары һәм соры ашлык үстерү хас.

Урта Европа тибы сөт һәм сөтит җитештерү терлекчелеге, шулай ук дуңгыз асрау һәм кошчылыкның өстенлек итүе белән аерылып тора.

**Мисал.** Даниядә терлекчелек аеруча нык үскән, ул биредә күптәннән инде халыкара специальләшү тармагына әверелгән. Дания — май, сөт, сыр, дуңгыз ите, йомырканы дөньяда иң күп җитештерүче һәм экспортлаучы илләрнең берсе. Аны Европаның «сөт фермасы» дип атаулары юкка гына түгел.

Үсемлекчелек халыкның азык-төлеккә булган ихтыяҗларын гына канәгатьләндереп калмый, терлекчелеккә дә «хезмәт күрсәтә». Сөрелгән җирләрнең шактый өлешендә, ә кайчакта хәтта күпчелегендә терлек азыгы культуралары үстерелә.

Көньяк Европа тибына үсемлекчелекнең өстенлек итүе хас, ә терлекчелек икенче урында тора. Җирләрнең күп өлешен бөртекле культуралар алып торуга карамастан, Көньяк Европаның халыкара специальләшүе иң элек җиләк-җимеш, цитруслар, виноград, зәйтүн, чикләвекләр, тәмәке, эфир майлы культуралар үстерү белән билгеләнә. Урта диңгез буе — «Европаның төп бакчасы».

**1 нче мисал.** Испаниянең Урта диңгез буен, бигрәк тә Валенсия районын, гадәттә, «уэрта», ягъни «бакча» дип йөртәләр. Монда төрле җиләк-җимеш һәм яшелчә, күбесенчә әфлисун үстерәләр. Аны җыю декабрьдән мартка кадәр дәвам итә. Бөтендөньяда әфлисун экспортлау буенча Испания беренче урында.

**2 нче мисал.** Грециядә 90 млн нан артыграк зәйтүн агачы үсә. Греклар өчен бу агач үзенә бертөрле милли символга әверелгән. Борынгы Эллада заманнарыннан бирле зәйтүн ботагы — тынычлык билгесе.

Авыл хуҗалыгы күпчелек очракларда тар профильгә специальләшә. Мәсәлән, Франция, Нидерланд һәм Швейцария сыр җитештерүдә дан казана [14], Нидерланд — чәчәк үстерүдә [15] (53 нче рәсемне карагыз), Германия һәм Чехия арпа, колмак үстерү һәм сыра кайнату белән дан тота. [16]. Ә инде виноград шәраблары җитештерү һәм куллану буенча Франция, Испания, Италия, Португалия Европада гына түгел, бәлки бөтен дөньяда аерылып торалар. Шунысы игътибарга лаек: маркалы шәрабка виноград сорты үстерелгән урынның яки торак пунктның исемен бирү әле дә саклана: шампанское (Шампань өлкәсе), кагор һәм коньяк (Франциядәге шәһәрчекләрнең исемнәре), малага һәм херес (Испания шәһәрләре), мадера (Мадейра утравы исеменнән), портвейн (Португалиядәге «Порту шәһәре шәрабы»).

Балыкчылык Норвегия, Дания һәм бигрәк тә Испания өчен инде күптән халыкара специальләшү тармагына әверелде. [17]. (8 нче бирем.)

**7. Транспортның төп магистральләре һәм узеллары.** Регионның транспорт системасы, нигездә, **Көнбатыш Европа тибына** керә. Йөк ташу юлларының озынлыгы ягыннан ул АКШ һәм Россиядән күпкә калыша. Аның каравы транспорт челтәре белән тәэмин ителүе ягыннан дөньяда беренче урынны алып тора. Хәрәкәт тыгызлыгы да, халыкара һәм транзит йөк ташуларның роле дә монда аеруча зур. Араларның артык ерак булмавы автомобиль транспорты үсешенә зур стимул бирде. Хәзер ул пассажирлар ташуда гына түгел, йөк ташуда да төп рольне уйный. Тимер юл челтәре күп илләрдә кыскара бара. 50—70 нче еллардагы зур күләмле яңа төзелешләр Көнчыгыш Европаның кайбер илләре өчен генә хас булды (Польша, Югославия, Албания).

Регионның транспорт челтәре конфигурациясе бик катлаулы. *Ләкин аның төп каркасын халыкара әһәмияткә ия булган киңлек һәм меридиональ юнәлешле магистральләр тәшкил итә.*

**Мисал.** Киңлек юнәлешле төп трансъевропа магистральләре түбәндәгечә уза: 1) Брест — Париж — Берлин — Варшава — Минск — Мәскәү, 2) Лондон — Париж — Вена — Будапешт — Белград — София — Истанбул.

80—90 нчы елларда Европа Союзы кысаларында интеграцион элемтәләрнең үсүе белән транспорт инфраструктурасына аеруча әһәмият бирелә башлады. Шул уңайдан автострадалар, зур тизлекле тимер юллар челтәре киңәя барып, Европаның барлык чит илләрен «каплады».

Зур тизлекле тимер юл магистральләре төзүдә Франция пионер булды. [18]. Аннары алар шулай ук Германиядә, Бөекбритания, Италия, Испания һәм башка илләрдә төзелде. Ә инде шуннан соң халыкара магистральләр төзү башланды.

Елга юллары да меридиан (Рейн) яки киңлек буйлап (Дунай) юнәлгәннәр. Су юлы буларак бигрәк тә Рейнның әһәмияте зур. Бу елга буйлап елына 200 млн тоннадан артык йөк ташыйлар. Көнбатыш Европаның әһәмиятле ике су юлы артериясен тоташтыручы Рейн — Майн — Дунай су юлы 1992 елда эксплуатациягә тапшырылганнан соң, аның әһәмияте тагын да артты.

Коры җир һәм эчке су юллары кисешкән урыннарда эре транспорт узеллары барлыкка килде. Чынлыкта, иң элек халыкара йөк ташуга хезмәт күрсәтүче диңгез портлары да шундый ук узеллар булып торалар. Күп кенә дөнья портлары (Лондон, Гамбург, Антверпен, Роттердам, Гавр) елга тамакларында — эстуарийларда урнашкан, ә елга аларны эчке районнар белән бәйли. Алар барысы **бердәм порт-промышленность комплексларына** әверелделәр. *Бу портлар өчен диңгез хуҗалыгы тармакларының, аеруча читтән, диңгез аръягыннан китерелгән чимал белән эшләүче «порт*

*промышленносте» дип аталган тармакның үсүе характерлы.* Алар арасында иң зурысы — Роттердам.

**Мисал.** Роттердам портының йөк әйләнеше елына 350 млн тонна чамасы тәшкил итә. Рейн елгасы тармакларының берсендә диңгездән 33 км ераклыкта урнашкан бу порт күп кенә Европа илләре өчен төп диңгез капкасы функциясен үти. Эчкәреге районнар белән ул Рейн һәм Мозель су юлы, тимер юл һәм шоссе юллары, нефть һәм газ үткәргечләре аша бәйләнгән (54 нче рәсемне карагыз).

Көнбатыш Европа — транспорт челтәренә табигый каршылыклар да киртә була алмаганның мисалы. Күп санлы тимер юллар, автомобиль юллары һәм үткәргеч торбалар Альп таулары аша уза. Балтыйк, Төньяк һәм Урта диңгез ярларын паромлы кичүләр тоташтыра. Төркиядә Босфор бугазы аша автомобиль юлы күперләре [19], Даниядә Зур Бельт һәм Эресунн бугазлары аша автомобиль һәм тимер юл күперләре салынды. [20]. Шуларга охшаш, әмма үзгә зур әһәмияткә ия булган яңа төзелешләрнең берсе «гасыр проекты» исемен алды. Бу — Ла-Манш астыннан үткән Евротоннель — Франция һәм Бөекбританиянең уртак төзелеше. [21].

90 нчы елларның икенче яртысында Европада бердәм транспорт челтәре төзү буенча искиткеч зур проект төзелә, һәм ул инде тормышка ашырыла башлады. Анда 2010 елга кадәр Европаның Көнбатышы белән Көнчыгышы арасында гомуми озынлыгы 17 мең км чамасы булган тугыз транспорт коридоры төзү планлаштырыла. Һәр коридор автострада һәм тимер юлны үз эченә алган ***полимагистральдән***[1] гыйбарәт. Ә Дунай коридоры су юлын да эченә алган. Бу коридорларның икесе Мәскәү аша узачак: Берлин — Варшава — Минск — Мәскәү һәм Хельсинки — Санкт-Петербург — Мәскәү — Киев — Кишинев — Бухарест. Аерым илләрдә транспорт челтәренең конфигурациясе радиаль (бер үзәкле), мәсәлән, Франциядәге кебек, анда «барлык юллар да Парижга илтә», яисә ГФРдагы шикелле күп үзәкле булырга мөмкин. (9 нчы бирем.)

**8. Фән һәм финанс: технопарклар, технополислар һәм банк үзәкләре.** АКШтагы Силикон үзәннән үрнәк алып, Европа чит илләрендә күп кенә фәнни-тикшеренү парклары, технополислар барлыкка килде. Алар инде төрле илләрдә фәннең географиясен шактый дәрәҗәдә билгели алалар. Мондый паркларның иң зурлары Кембридж янында (Бөекбритания) һәм Мюнхенда (ГФР). Франциянең көньягында, Ницца районында «Югары технология юлы» исемле парк формалаша.

Дөньядагы иң зур 200 банкның 60 ы Европа чит илләрендә урнашкан. Швейцария инде күптән-

---

[1] Полимагистраль — параллель яки параллель диярлек бер яки берничә төр транспорт линияләренең «үрелмәсе». Алар бер үк районнар һәм транспорт узеллары арасында элемтә вазифаларын үтиләр.

нән бирле банкир-илнең эталоны булып санала: дөньядагы барлык кыйммәтле кәгазьләрнең яртысы аның банклары сейфларында саклана. Илнең «икътисади башкаласы» — Цюрих бигрәк тә аерылып тора.

Соңгы вакытта Люксембург та банкир-илгә әверелде. Ләкин иң эре финанс үзәге Лондон булды һәм бу хәзер дә шулай.

**9. Ял һәм туризм: дөньяның төп туризм регионы.** Инде белгәнегезчә, *Европа чит илләре — элек тә, хәзер дә халыкара туризмның төп регионы*, 2005 елда интуристлар саны 400 млн га житте. Монда туризмның барлык төрләре дә үсеш алган, һәм «туризм индустриясе» иң югары дәрәҗәгә ирешкән. Халыкара туризмның иң алдынгы илләре — элек тә һәм хәзер дә Франция, Испания һәм Италия. Туристларны үзенә җәлеп итүче иң популяр илләр рәтенә Бөекбритания [22], ГФР, Австрия, Швейцария, Греция, Португалия, Чехия, Венгрия керә. Андорра, Сан-Марино, Монако кебек микродәүләтләрдә туристларга хезмәт күрсәтү — инде күптәннән бирле төп керем чыганагы. Монда яшәүче һәр кешегә йөз турист туры килә.

Европа чит илләрендә ике тип туризм һәм рекреация районнары бар: диңгез буе һәм тау туризмы районнары.

**1 нче мисал.** Диңгез буе туризмының төп районы — Урта диңгез буе. Анда ел саен 220 млн кеше килә. Лигурий диңгез буендагы төньяктан Альп таулары белән чикләнгән Лазурь яр (Ривьера), аның үзәге — Ницца [23], шулай ук Хорватиядә Әдрән диңгез буе, Испаниянең диңгез буйлары һәм Балеар утраулары — аеруча популяр урыннар.

**2 нче мисал.** Тау туризмының төп районы — Альп таулары. Бирегә ел саен 100 млн кеше килә. Тауларның түбәнге поясы — башлыча дәвалану максатларында һәм җәяүле туризм, урта пояс — чаңгы шуу спорты белән шөгыльләнү, ә өске пояс альпинизм өчен файдаланыла. [24].

«Үзләренең климатларын сатучы» илләрдән тыш, туристларны «Европаның борынгы ташлары» — шәһәрләрнең тарихи истәлекле урыннары үзләренә тарта. Париж, Рим, Мадрид шәһәрләре инде күптән үзенә күрә «туристлар Мәккәсе»нә әверелделәр (55 нче рәсемне карагыз). Июль-август айларында биредә яшәүчеләрнең саны туристлар саныннан, мөгаен, кимрәк була торгандыр. Лондон, Амстердам, Вена, Дрезден, Прага, Будапешт, Венеция, Неаполь һәм Афинада да туристлар гаять күп була. Исебезгә төшерик: Европа чит илләре Бөтендөнья мәдәни мирасы объектлары саны буенча (316) дөнья регионнары арасында конкурентсыз беренче урынны алып тора. Аларның күбесе Урта гасыр дәверенә карый. Әмма Яңарыш, Яңа заман, Антик, борынгы заман дәверләренә караган объектлар шактый исәпләнә. (10 нчы иҗади бирем.)

**10. Мохитне саклау һәм экологик проблемалар: һәлакәт куркынычын бетерү.** Халыкның аеруча тыгыз урнашуы, территориясенең промышленность һәм авыл хуҗалыгы белән күптәннән үзләштерелүе

нәтиҗәсендә, Европа чит илләренең табигый мохите шактый дәрәҗәдә кешелек җәмгыятенең географик мохитенә әверелде. Биредә антропоген ландшафтның барлык төрләре дә киң таралган. Әмма бу хәл бер үк вакытта табигатьне саклау һәм экологик проблемаларның кискенләшүенә дә китерде.

Проблемаларның кайберләре күп көлле (барыннан да бигрәк соры) күмерне ачык ысул белән чыгару, аны яндыру һәм химик эшкәртү белән бәйләнгән. Икенчеләре, күп кенә шәһәрләрне һәм агломерацияләрне, металлургия, нефть, газ эшкәртү һәм нефть химиясе заводларын, атом электростанцияләрен Рейн, Эльба, Дунай, Висла елгалары ярларында һәм диңгез буйларына урнаштыруга, ә өченчеләре, кислоталы яңгырларга бәйле. Дүртенче проблема — һаман үсә барган «автомобильләр тыгызлыгы», күп кенә шәһәр агломерацияләрендә ул 1 $км^2$ га 250—300 машинага җитеп бара. Бишенчесе, туризмның тәртипсез үсеше, ул Альп тауларында да, Урта диңгез буйларында да табигый мохитнең деградациясен китереп чыгарды. Алтынчысы, аеруча Ла-Маншка керү юлларында булгалый торган супертанкерлар катастрофалары табигый мохиткә зур куркыныч тудыра. [25].

*Региондагы барлык илләр дә дәүләткүләм экологик сәясәт алып баралар һәм мохитне саклау өчен хәлиткеч чаралар күрәләр.* Табигатьне саклау буенча катгый законнар кабул ителә, әйләнә-тирәне саклауны максат итеп куйган җәмәгать оешмалары һәм «яшелләр» партияләре барлыкка килә, велосипед куллану пропагандасы алып барыла [26], милли парклар һәм аеруча саклана торган башка территорияләрнең челтәре киңәйтелде. Мохитне саклау чаралары аерым илләр дәрәҗәсендә дә, шулай ук шул илләрнең группалары, аерым диңгезләр, халыкара елгалар һ. б. дәрәҗәсендә дә кабул ителә. Евросоюз, Европа Советы, башка халыкара союзлар һәм оешмалар актив экологик сәясәт үткәрәләр.

Бу чаралар беренче уңай нәтиҗәләргә китерде. Ләкин шулай булуга карамастан күпчелек илләрдә экологик хәл әлегә һаман да катлаулы булып кала. Бу беренче чиратта Бөекбритания, ГФР, Бельгия, Польша һәм Чехиягә карый.

**Мисал.** 80 нче елларда Польшада халыкның 35 %ы яши торган экологик куркыныч астында калган 27 ареал аерып күрсәтелде. Польшада иң эре металлургия комбинаты урнашкан борынгы Краков шәһәре экологик һәлакәт урыны дип игълан ителде.

Тулаем алганда, Европаның көнчыгыш өлешендә экологик хәл көнбатыштагыдан күпкә начаррак.

## 2. ХАЛЫК УРНАШУ ҺӘМ ХУҖАЛЫГЫНЫҢ ГЕОГРАФИК СУРӘТЕН ӨЙРӘНӘБЕЗ

**1. Үсешнең «үзәк күчәре» — регионның территориаль структурасының төп элементы.** Европа чит илләренең халкы һәм

хуҗалыгының территориаль структурасы, нигездә, XIX гасырда ук формалаша. Ул чакта урнашуның төп факторы — табигый-ресурслар факторы булган, һәм Бөекбритания, Франция, Германия, Бельгия, Польша, Чехия һ.б. ның күмер-металлургия районнары барлыкка килгән. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң бу структурага хезмәт ресурслары факторы һәм икътисади-географик урынның отышлы булуы, ә соңгы вакытта шулай ук фәнсыешлык һәм экология факторы зур йогынты ясады.

Регионда барлыгы 400 ләп шәһәр агломерацияләре һәм йөзләп промышленность районы исәпләнә. Аларның иң мөһимнәре **үсешнең «үзәк күчәре»** дип йөртелгән һәм сигез ил территориясе буйлап сузылган чикләрдә урнашкан. Үз чиратында «Европаның төп урамы» булып саналган Рейн — Рона линиясе аның үзәге ролен үти. *Бу «күчәр» чикләрендә 120 млн халык яши, аларның тыгызлыгы 1 км² га 300 кеше. Биредә регионның барлык икътисади потенциалының 2/3 өлеше тупланган һәм төп промышленность районнары урнашкан* (50 нче рәсемне карагыз).

Европа чит илләрендә кечерәк масштабтагы тагын берничә «күчәр» не аерып күрсәтергә мөмкин. Бу — Польша, Чехия һәм ГФРның уртак чикләре буйлап сузылган промышленностьлы шәһәрләр поясы, һәм төп нефтьүткәргечләр буйлап сузылган Дунай «күчәре» һәм кайбер диңгез яны зоналары.

**2. Югары үсеш алган районнар: аларның мисаллары буларак Лондон һәм Париж.** Сезгә билгеле булганча, иң яңа промышленность тармакларын, инфраструктураны, фән һәм мәдәниятне, шулай ук хезмәт күрсәтү сферасын үзендә туплаган Олы Лондон һәм Олы Парижның **башкала регионнары** югары үсеш алган районнарның ачык мисалы булып хезмәт итә ала.

«Башкала регионы» дигән географик төшенчә күп баскычлы структурасы булуы белән характерлана. Дөрестән дә, Лондонның үзәк өлеше мәйданы ягыннан зур түгел, аның халкы 2,5 млн кеше. Ә Олы Лондонның территориясе аннан биш тапкыр чамасы зуррак, анда 7,6 млн кеше яши. Шәһәр яны зонасының эчке поясы белән бергә Олы Лондон халкы 9,8 млн булган Лондон районын хасил итә (56 нчы рәсемне карагыз). Шәһәр яны зонасының тышкы поясын да кертеп исәпләсәк, халык саны 11,2 млн га кадәр арта — менә шул инде Лондон агломерациясе. Парижга карата да шундый ук күп баскычлы схема кулланырга мөмкин. Аның үзәк өлешендә 2,2 млн кеше яши, тар агломерация чикләрендә — 5,1 млн, киң чикләрдә — 11,3 млн, ә Париж башкала регионында халык саны 15 миллионнан артыграк.

Лондон да, Париж да иң элек үз илләренең сәяси-административ үзәкләре буларак үскәннәр, алар бу вазифаны инде сигез гасырдан артыграк үтәп киләләр. (Париж шәһәре гербындагы корабка «Ул

56


57



58

56 нчы рәсем. Лондон һәм Лондон районы

57 нче рәсем. Парижда Елисей кыры һәм Триумфаль арка

58 нче рәсем. Төньяк диңгезнең нефть һәм газга бай районы

чайкала, ләкин батмый» дигән язу үзе бер мәгънәгә ия.) Ике башкала да — эре промышленность үзәкләре, һәм аларда югары технологияле, фәнсыешлы тармаклар зур урын алган, ә «Париж әйберләре» (киемнәр, ювелир әйберләре һ. б.) җитештерү гасырлар буена Парижны бөтен дөньяда «модалар чыгаручы» итеп танытты. Ләкин бигрәк тә әһәмиятлесе — иң эре банклар һәм биржалар, монополияләрнең штаб-квартиралары, алдынгы фәнни учреждениеләр, күп кенә халыкара оешмаларның резиденцияләре монда урнашкан булуы. [28]. Региональ программалар буенча һәр ике башкала регионының үзәк өлешенә йөкләмәне киметү эшләре бара.

Лондон тирәсендә — сигез, Париж тирәсендә биш иярчен шәһәр төзелгән.

Европа чит илләренең нык үсеш алган башка районнарына ГФРның көньяк районындагы — Штутгарт һәм Мюнхен үзәкләре, Италиядәге Милан — Турин — Генуя «промышленность өчпочмагы», Нидерландта Рандстад («бoжрасыман щәһәр») промышленностьлы шәһәр агломерацияләре керә. Алар барысы да үсешнең «үзәк күчәре» чикләрендә урнашкан.

**3. Иске промышленность районнары: Рур мисалында.** Европа чит илләрендәге кебек, *төп тармаклар өстенлек алган иске промышленность районнарының шулкадәр күп санда булуы дөньяның башка бер генә регионында да юк.* Аларның иң зурлары ташкүмер бассейннары базасында барлыкка килгән. Әмма алар арасында да Рур промышленность районы аерылып тора, ул озак вакытлар дәвамында Германиянең индустриаль үзәге булып килде.

Рур бассейны һәм аның тирәсендәге районнар чикләрендә Түбән Рейн-Рур агломерациясе барлыкка килгән. Монда 9 мең $км^2$ мәйданда 11 млн кеше яши, йөзләп шәһәр, шул исәптән 20 зур шәһәр тупланган. *Зур шәһәрләрнең бер территориядә мондый тупланышы, мөгаен, дөньяда беркайда да юктыр.* Агломерациянең кайбер өлешләрендә халык тыгызлыгы 1 $км^2$ га 5 мең кешегә җитә. Агломерациянең Рур өлеше катлаулы шәһәр массивын тәшкил итә, аны, гадәттә, «Рурштадт», ягъни «Рур-шәһәр» дип йөртәләр. Ул,— дөрестән дә, бербөтен шәһәр: Дуйсбург — аның көнбатыш, Дортмунд — көнчыгыш капкалары, Эссен — «башкала»сы, ә Дюссельдорф төп «сейф» хезмәтен үти.

Соңгы вакытта берничә мең предприятиедән торган Рур промышленносте шактый нык реконструкцияләнде. 50—60 нчы елларда Рур классик депрессив район булып саналган. Ләкин безнең көннәрдә аны бу категориягә кертү дөрес булмас. Монда зур экологик программа тормышка ашырылды. Әле күптән түгел генә Европаның пычрак су канавы дип йөртелгән Рейн елгасы чистарды, анда яңадан балык күренә башлады.

Башка иске промышленность районнарына мисал буларак Бөекбританиядә — Ланкашир, Йоркшир, Көнбатыш Мидленд, Көньяк

Уэльсны; Франциядә — Төньяк район, Эльзас һәм Лотарингияне; ГФРда — еш кына «кече Рур» дип йөртелә торган Саарны; Польшада — Югары Силезия районын һәм Чехиядә Острава районын күрсәтергә мөмкин. Ләкин аларның күбесе депрессив категориясенә керә. (11 нче бирем.)

**4. Артта калган аграр районнар: Италиянең Көньягы мисалында.** Европа чит илләре арасында шактый артта калган районнар да аз түгел, алар — күбесенчә аграр районнар. Моның ачык мисалы — Италиянең Көньягы. Ул ил территориясенең 40 % ын алып тора, анда халыкның 35 % ы тупланган, шуларның фәкать 18 % ы гына промышленностьта эшли. Монда җан башына туры килгән керем Төньяктагыга караганда ике тапкыр диярлек ким. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүче халыкның чагыштырмача тыгыз урнашуы аркасында, 5 млн кеше Көньяктан күчеп китте.

Дәүләт Көньякны үстерү буенча региональ сәясәт алып бара. Ул эре металлургия, нефть химиясе һәм башка предприятиеләр төзелүгә китерде. Нәтиҗәдә хәзер Көньяк гел авыл хуҗалыгы районы гына түгел. Ләкин комбинатлар бөтенләй диярлек әйләнә-тирәләре белән бәйләнмәгән, чөнки алар читтән китерелгән чимал белән эшлиләр, һәм җитештерелгән продукция дә илнең башка районнарына һәм чит илләргә озатыла. Аларны италиялеләр юкка гына «чүлдәге чиркәүләр» дип атамаганнар.

Европа чит илләренең артта калган аграр районнарына мисал итеп Франциянең көнбатыш өлешен, Испаниянең үзәк һәм көньяк-көнбатыш өлешен, Португалия һәм Грециянең кайбер өлкәләрен китерергә мөмкин. Аларның барысы да «үзәк көчәрдән» читтә урнашкан. Артта калган районнарны үстерү мәсьәләсе Көнчыгыш Европаның күп кенә илләре өчен тагын да актуальрәк проблема санала.

**5. Яңа үзләштерелгән районнар: Төньяк диңгез мисалында.** Территориясе инде күптән үзләштерелгән Европа чит илләренә яңа районнарны үзләштерү күренеше хас түгел. Гадәттә, аларга Скандинавиянең төньяк өлешен генә кертәләр иде. Ләкин 60 нчы еллар башында Төньяк диңгез акваториясендә эре нефть-газ бассейнын ачу бу хәлне үзгәртте.

90 нчы еллар уртасында бу «алтын диңгез төбендә» 450 дән артык нефть һәм газ чыганагы табылды; аларның иң эреләре — Статфьорд, Экофиск һәм Тролль. [29]. Моннан тыш, Нидерландта диңгез буеннан ерак түгел дөньяда иң зур газ чыганакларының берсе — Слохтерен урнашкан (58 нче рәсемне карагыз). Монда нефть чыгару — 250 млн т дан артык, ә табигый газ чыгару 200 млрд $м^3$ тәшкил итә. Төньяк диңгез районы Европа чит илләренең нефтькә булган ихтыяҗының — 1/3 ен, ә газга ихтыяҗының 2/5 өлешен канәгатьләндерә. Хәзерге вакытта диңгезне бораулау платформалары тутырган, ә диңгез төбеннән меңнәр-

чә километрга торбалар үткәрелгән. Болар барысы да экологик куркыныч тудыра, ә балык тоту турында әйтеп тә торасы юк, чөнки аңа төзәтә алмаслык зыян килде.

**6. Хуҗалыкның территориаль структурасына халыкара икътисади интеграция йогынтысы.** Регионда халыкара икътисади интеграциянең үсеше өчен түбәндәге уңай алшартлар бар: территориаль якынлык, территорияләрнең бик яхшы үзләштерелүе, социаль-икътисади үсеш дәрәҗәсенең югары булуы, транспорт белән яхшы тәэмин ителү, икътисади элемтә традицияләренең күптәннән урнашкан булуы. Европа Союзы яшәп килгән елларда аерым ил *хуҗалыклары территориаль структураларының*, бигрәк тә «үзәк күчәр» чикләрендә, *бер-берләренә үреләп үсүе дәвам итте*. ГФР белән Франция, Франция белән Бельгия, шулай ук Франция белән Италия һәм башкалар арасында чиктәш интеграцион районнар формалашу процессы бара.

## 3. ЕВРОПАНЫҢ СУБРЕГИОННАРЫ ҺӘМ ИЛЛӘРЕ БЕЛӘН ТАНЫШАБЫЗ

**1. Европа чит илләрен субрегионнарга бүлүгә ике караш.** Европа чит илләре территория ягыннан дөньяда иң кечкенә регион булып торса да, эчке яктан ул бөтенләй бериш түгел. Шуңа күрә аны, гадәттә, ике яисә дүрт аерым өлешкә — субрегионга бүлеп өйрәнәләр.

Ике субрегионга бүлгән очракта Көнбатыш һәм Үзәк-Көнчыгыш Европаны аерып күрсәтәләр. Көнбатыш Европа составына гомуми мәйданы 3,7 млн км$^2$, 390 млн халкы булган 24 дәүләт керә (микродәүләтләрне дә кертеп). Бу илләрдә инде күптән базар икътисады, элекке терминология буенча аларны, гадәттә, *капиталистик илләр* дип атыйлар. Үзәк-Көнчыгыш Европага 1,7 млн км$^2$ чамасы территория алып торган, 130 млн халкы булган 16 ил керә. Болары — 80 нче еллар ахырына кадәр бөтендөнья социалистик системасына кергән *постсоциалистик илләр*.

Шулай ук Европа чит илләрен дүрт субрегионга бүлү кабул ителгән: Төньяк, Көнбатыш, Көньяк һәм Көнчыгыш Европа. Бу очракта Төньяк Европага, Скандинавия илләре, Дания, Финляндия һәм Балтия илләре; Көнбатыш Европага — ГФР, Франция, Бөекбритания, Бенилюкс илләре, Австрия һәм Швейцария; Көньяк Европага — барлык Урта диңгез буе илләре; Көнчыгыш Европага Польша, Чехия, Словакия, Венгрия, Румыния һәм Болгария керә.

7 нче сыйныфта бу илләрнең күбесен сез өйрәнгән идегез инде. Алар турында өстәмә социаль-икътисади мәгълүматлар түбәндәге диаграммаларда һәм текстта китерелә. (12 нче бирем.)

**2. Германия Федератив Республикасы.** Германия Федератив Республикасы *Европа чит илләре арасында икътисади яктан иң куәтле дәүләтләрдән санала.* Ул «зур җиделеккә» керә һәм Европада гына түгел, бөтен дөнья икътисадында һәм сәясәтендә гаять зур роль уйный.

## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР

- сөрү җире
- болыннар һәм көтүлекләр
- урманнар
- башка төр җирләр
- шәһәр халкы
- авыл халкы
- җитештермәүче сфера
- промышленность һәм төзелеш
- авыл һәм урман хуҗалыклары

**Төньяк Европа илләре**

| Илләр | Территория ничек файдаланыла | Кешеләр кайда яши | Алар кайда эшли | Ил нәрсә җитештерә һәм экспортлый |
|---|---|---|---|---|
| Швеция | |   |   | Автомобильләр, самолетлар, диңгез суднолары, корал, подшипниклар, урман һәм целлюлоза-кәгазь промышленносте өчен җиһазлар, кәгазь, целлюлоза, тимер рудасы, медикаментлар, терлекчелек продуктлары |
| Финляндия |   |   |   | Агач материаллары, кәгазь, целлюлоза, урман һәм агач эшкәртү промышленносте өчен җиһазлар, диңгез судноларь, сөт продуктлары |

**Көнбатыш Европа илләре**

| Илләр | Территория ничек файдаланыла | Кешеләр кайда яши | Алар кайда эшли | Ил нәрсә җитештерә һәм экспортлый |
|---|---|---|---|---|
| Бөекбритания |   |   |   | Машиналар һәм җиһазлар, самолетлар, автомобильләр, тракторлар, корал, нефть, химикатлар, тукымалар, җиңел промышленность әйберләре |

| Илләр | Территория ничек файдаланыла | Кешеләр кайда яши | Алар кайда эшли | Ил нәрсә житештерә һәм экспортлый |
|---|---|---|---|---|
| Франция |   |   |   | Автомобильләр, самолетлар, диңгез суднолары, корал, АЭС өчен җиһазлар, кара металлар, алюминий, тукымалар, кием, парфюмерия, бодай, сөт һәм ит продуктлары, шикәр, шәраб |
| ГФР | | | | Автомобильләр, станоклар, промышленность җиһазлары, электротехника һәм электроника әйберләре, корал, диңгез суднолары, химикатлар, җиңел промышленность әйберләре |

**Көньяк Европа илләре**

| Илләр | Территория ничек файдаланыла | Кешеләр кайда яши | Алар кайда эшли | Ил нәрсә житештерә һәм экспортлый |
|---|---|---|---|---|
| Испания |   |   |   | Автомобильләр, диңгез суднолары, электр җиһазлары, химикатлар, металл рудалары, җиңел промышленность әйберләре, цитруслар, зәйтүн мае, шәраб |
| Италия |   |   |   | Автомобильләр, мотоцикллар, промышленность җиһазлары, корал, химикатлар, суыткычлар, кер юу һәм контора машиналары, тукымалар һәм тегелгән әйберләр, аяк киеме, яшелчә, җиләк-җимеш, цитруслар, шәраб |

**Көнчыгыш Европа илләре**

| Илләр | Территория ничек файдаланыла | Кешеләр кайда яши | Алар кайда эшли | Ил нәрсә җитештерә һәм экспортлый |
|---|---|---|---|---|
| Польша |   |   |   | Машина һәм җиһазлар, диңгез суднолары, ташкүмер, бакыр, күкерт, медикаментлар, тукыма әйберләр, авыл хуҗалыгы продуктлары |
| Болгария |   |   |   | Электротехника һәм электроника әйберләре, күтәрү-транспорт җиһазлары, авыл хуҗалыгы машиналары, төсле металлар, тегелгән әйберләр һәм тәмәке, консервлар, шәраб |

Германия Федератив Республикасы, Икенче бөтендөнья сугышында җиңелгәннән соң, Германиянең Америка, Бөекбритания һәм Франция оккупацияләгән зоналарын берләштерү юлы белән 1949 елның сентябрендә төзелә. 1949 елның октябрендә Германиянең Советлар Союзы оккупацияләгән көнчыгыш зонасында Германия Демократик Республикасы (ГДР) игълан ителә. ГФР 1990 ел ахырыннан, ягъни ике герман дәүләте берләштерелгәннән соң урнашкан хәзерге чикләрдә яши. Моңа кадәр дәүләт чиге булган данлыклы Берлин стенасы белән икегә бүленгән Берлин шәһәре берләштерелә. 1991 елда Берлин рәсми рәвештә илнең башкаласы дип игълан ителә, ләкин аны Боннан [30] күчерү, асылда, 90 нчы еллар ахырында тормышка ашырыла.

ГФРның икътисади-географик урынының әһәмиятле үзенчәлеге — *аның үзәк* булуы, ягъни киңлек һәм меридиан буенча юнәлгән трансъевропа сәүдә транспорты юлларының кисешкән урынында урнашуы, Балтыйк һәм Төньяк диңгезләргә киң чыгу юллары булуы, Рейн һәм Дунай кебек халыкара елгаларны файдалану мөмкинлеге, Көнбатыш, Төньяк һәм Көнчыгыш Европаның тугыз иле белән коры җирдә турыдан-туры чикләре булуы. Германиянең берләшүе аның икътисади-географик һәм геосәяси хәленең яхшыруына китерде.

Идарә формасы буенча ГФР — парламент республикасы. Ул ике палаталы (бундестаг һәм бундесрат) парламенттан һәм канцлер җитәкчелегендәге хөкүмәттән тора. Ә президент, гәрчә ул рәсми рәвештә дәүләт башлыгы булып саналса да, нигездә, фәкать вәкиллек функцияләрен генә башкара. Административ-территориаль төзелеш формасы буенча ГФР —

федератив дәүләт. Ул 16 тарихи җирдән (өлкәдән) тора һәм аның һәркайсының үз хөкүмәте һәм сайлап куелган закон чыгаручы органнары бар.

ГФРның халкы үзенә генә хас әһәмиятле сыйфатлары булу белән характерлана. Иң элек ул — *Европа чит илләре арасында халыкның иң күп санлысы.* Шуның белән беррәттән *бу илнең демографик хәле аеруча катлаулы,* 70 нче еллар башында ук инде үлүчеләр саны туучылар саныннан артып китте. Мондагы көчле депопуляциядән фәкать хезмәт иммиграциясе һәм соңгы вакытта аңа өстәлгән сәяси качаклар агымы гына котылырга ярдәм итә.

**Мисал.** Иммигрантлар саны буенча ГФР Европада беренче урынны алып тора, алар илдәге халыкның 1/10 өлешен тәшкил итә. Иммигрантларның төп өлеше зур шәһәрләрдә урнаша. Бу яктан эшлекле, финанс һәм әһәмиятле промышленность үзәге саналган Майндагы Франкфурт шәһәре бигрәк тә характерлы.

ГФРда халыкның урнашуы иң элек аның уртача тыгызлыгының гаять зур булуы (1 км$^2$ га 230 кеше) белән аерылып тора. Өстәвенә кайбер аерым районнарда ул 1 км$^2$ га 1000—2000 кешегә җитә һәм аннан да артып китә. Шуның белән беррәттән *ГФР — дөньяда урбанизация дәрәҗәсе иң югары булган илләрнең берсе* (18 нче рәсемне карагыз). Төрле дәрәҗәдәге шәһәр агломерацияләренең саны буенча да ул регионда беренче урынны алып тора.

Германия — борынгы шәһәр культурасы булган ил. Кайбер шәһәрләр Рим империясе вакытында барлыкка килгән, әмма күпчелеге Урта гасырларда крепостьлар, феодал резиденцияләре, университет үзәкләре яисә ирекле шәһәрләр буларак барлыкка килгәннәр. Яңа һәм иң яңа заманда алар үсешләрен дәвам иткәннәр, ләкин шәһәрләрнең тышкы күренешендә элеккеге чорларга хас үзенчәлекләре сакланып калган. Артык зур булмаган кайбер герман шәһәрләре бөтен дөньяга танылган әйберләр җитештерү белән дан казанганнар: Золинген шәһәре — металл әйберләр, Йена — оптика-механика әйберләре, Гота шәһәре — картография һ. б. Ә инде Гейдельберг һәм Гёттинген шәһәрләре үзләренең борынгы университетлары белән билгеле. Веймар шәһәре исә Гёте һәм Шиллер [31] исемнәре белән бәйле шәһәр-музей буларак танылган. Зуррак шәһәрләрдән Ганновер, Кёльн, Майндагы Франкфурт шәһәре һәм Лейпциг Урта гасырларда барлыкка килгән халыкара ярминкәләр үткәрү традициясен дәвам иттерәләр; Лейпцигта мондый ярминкәләр инде 800 елдан артыграк үткәрелә! Дөньяда һәр ун китапның берсе немец телендә басыла.

ГФРның хуҗалыгы үсеше бик югары дәрәҗәгә ирешкән. Тулай эчке продуктның гомуми күләме буенча ГФР фәкать АКШтан, Кытайдан, Һиндстаннан (аларның мәйданнары зуррак һәм халыкларының саны күбрәк) һәм Япониядән генә калыша. Ә тулай продуктның җан башына тигән өлеше буенча ул дөньядагы иң

алдынгы илләрнең «беренче унлыгына» керә. ГФР икътисадының структурасы («Кушымта»дагы 18 нче таблица) *бу илнең постиндустриаль үсеш стадиясендә булуын* аермачык күрсәтә. Европа Союзы әгъзасы буларак, ГФР Көнбатыш Европа интеграциясенә актив катнаша. Транснациональ корпорацияләр илнең икътисадында төп рольне уйный.

Дөньядагы иң зур 50 промышленность компаниясенең җидесе — Германиянеке. Дөнья хуҗалыгының биш тармагында герман компанияләре беренче унлыкка керә. Химия промышленностенда болар — БАСФ, «Хёхст» һәм «Байер» концерннары, электротехникада — «Сименс» һәм «Роберт Бош», автомобиль төзүдә — «Даймлер-Бенц» һәм «Фольксваген», кара металлургиядә — «Тиссен» һәм «Маннесман», җиңел промышленностьта — «Адидас».

**ГФР промышленносте**, тулай эчке продуктта үзенең өлеше акрынлап кими баруга карамастан, илнең дөнья хуҗалыгындагы ролен, аның халыкара географик хезмәт бүленешендәге «йөзе»н билгели. *Промышленность житештерүенең күләме буенча* ГФР АКШ, Кытай һәм Япониядән кала *дүртенче урынны алып тора.* («Кушымта»дагы 21 нче таблицаны карагыз.) Аның структурасында Германия өчен традицион саналган авыр промышленность тармаклары: күмер, металлургия, металлсыешлы машиналар төзү, корал житештерү, электротехника, химия промышленносте озак вакыт төп рольне уйнап килде. Аннары тау промышленносте, шул исәптән күмер чыгару, шулай ук кара металлургия промышленносте әһәмияте сизелерлек кимеде, ә *машина төзү һәм химия промышленносте халыкара специальләшүнең төп тармакларына әверелде.*

ГФРның машина төзү промышленносте күбесенчә фәнсыешлыгы уртача булган продукция: станоклар (Япониядән соң икенче урында), автомобильләр, электротехника әйберләре, шулай ук күп төрле төгәл җиһазлар эшләп чыгара.

**Мисал.** XIX гасырның уртасында Йена шәһәрендә нигез салынган оптик приборлар житештерү остаханәсе дөньядагы иң эре «Карл Цейсс» оптика-механика предприятиесенә әверелде.

Дистәләрчә мең төрле продукция житештерүче күп профильле химия промышленносте да дөньяда әйдәп баручы урын тота.

ГФРның ягулык-энергетика хуҗалыгы җирле ташкүмер һәм соры күмер, шулай ук импортланган нефть һәм табигый газга нигезләнеп эшли. Электр энергетикасында җылылык электростанцияләре төп урынны алып тора, АЭСларның әһәмияте дә шактый зур.

**Мисал.** Германиядә 12 АЭС эшли, һәм алар барлык электр энергиясенең 28 % ын бирә. Аларның шактый өлеше күп халыклы шәһәр агломерацияләрендә урнашкан, өстәвенә күбесенчә Рейн һәм Эльба

елгалары һәм аларның кушылдыклары буйлап тезелгән[1].

ГФРның авыл хуҗалыгы механикалаштыру һәм химияләштерүнең бик югары дәрәҗәдә булуы, шуңа тиңдәшле рәвештә кыр һәм бакча культураларының югары уңышы, ә терлекчелекнең продуктлылыгы белән аерылып тора. Бу тармакта терлекчелек өстенлек итә, һәм ул барлык товарлыклы продукциянең 2/3 өлешен бирә. Монда башлыча сөт бирүче терлекләр һәм дуңгызлар үрчетелә. Үсемлекчелек терлекчелеккә азык белән «ярдәм итеп» кенә калмый, бәлки халыкның туклану продуктларына ихтыяҗларын тулысынча диярлек канәгатьләндерә. Азык культураларыннан бодай, арпа, бәрәңге, шикәр чөгендере аеруча зур әһәмияткә ия. Авыл хуҗалыгы предприятиесенең төп тибы — гаилә фермасы.

ГФР транспорты челтәрнең бик тыгыз булуы белән аерылып тора: илдә торак пунктларның берсе дә коры җир һәм су юлларыннан ерак урнашмаган. Йөк әйләнешендә һәм бигрәк тә пассажирлар әйләнешендә автомобиль транспорты өстенлек итә; ГФР автострадалары («автобан»нар) Европада иң яхшылардан санала, аларда тизлекне сәгатенә 100 км га кадәр җиткерергә рәсми рөхсәт ителә. Тимер юл (зур тизлекле тимер юл төзү турында сез беләсез инде) һәм эчке су юлы кебек транспортның традицион төрләре дә үзләренең әһәмиятләрен югалтмыйлар. [32]. Халыкара сәүдә элемтәләрендә диңгез портлары киң файдаланыла. Германия территориясендә торба үткәргечләрнең куе челтәре салынган, һәм аны күп санлы авиатрассалар кисеп уза.

Постиндустриаль ил буларак, ГФРда җитештермәүче сфера гаять күп эшчәнлек төрләрен эченә алган. Икътисади актив халыкның күп өлеше дәүләт аппаратында, мәгариф өлкәсендә, сәламәтлекне саклауда, күпләп һәм ваклап сәүдә итүдә, туризм һәм кунакханәләр сферасында, фән һәм мәдәният өлкәсендә эшли. Финанс һәм банк өлкәсендә хезмәт күрсәтү бигрәк тә зур роль уйный; дөньядагы иң эре 50 банкның сигезе ГФР банкы булуы (алар арасында иң зурысы «Дойче банк») очраклы хәл түгел. Төрле эшлекле һәм көнкүреш хезмәтләре күрсәтүнең әһәмияте арта бара.

Ачык икътисадлы ил булганга, ГФР өчен тышкы икътисади элемтәләрнең әһәмияте аеруча зур. *Тышкы сәүдәнең гомуми әйләнеше буенча ул дөньяда АКШтан кала икенче урынны алып тора.* Ул — шулай ук дөньяда иң зур капитал экспортерларының берсе. ГФР тышкы икътисади элемтәләре Европа Союзына кергән башка илләр һәм АКШ, Япония, Канада белән аеруча нык. БДБ илләре арасында Россия — аның төп икътисади-сәүдә партнеры.

ГФР хуҗалыгының территориаль структурасы үзенең

---

[1] Ләкин 2001 елда «яшелләр» партиясе таләбе буенча ГФР хөкүмәте АЭСларны акрынлап эксплуатациядән чыгару турында карар кабул итте (реакторларын куллану срогы беткәннән соң).

полицентрик характерлы булуы, мохитнең аеруча көчле «культуралашуы», территориянең үзәк һәм линия элементлары белән туенган булуы белән аерылып тора.

*ГФР хуҗалыгының географик сурәте беренче чиратта* транспорт магистральләре һәм полимагистральләр белән үзара бәйләнгән *төп промышленностьлы шәһәр агломерацияләренең урнашуы белән билгеләнә.* Белгәнегезчә, бу агломерацияләрнең иң зурысы — Рейн-Рур агломерациясе. Ул Төньяк Рейн—Вестфалия җиренең административ үзәген тәшкил итә. Ил территориясенең 1/10 өлешен алып торган бу җирдә халыкның 1/5 е тупланган һәм ул гомумгерман ТЭПының 1/5 ен бирә.

Кара металлургия (Дуйсбург, Дортмунд), авыр машиналар төзү һәм энергетика, шактый дәрәҗәдә Рейнның урта агымында (Людвигсхафен, Майндагы Франкфурт) урнашкан, химия промышленностеның төп житештеру куәтләре нәкъ менә шунда тупланган.

Ләкин хәзер Рейн-Рур агломерациясе илнең башка промышленностьлы шәһәр агломерацияләреннән элеккеге кебек үк «өстенлек» итми. Фәнсыешлы иң яңа производстволарның үсеше ягыннан аны илнең көньяк-көнбатышында Штутгарт һәм көньяк өлешендәге Мюнхен агломерацияләре узып китте. Алар шулай ук автомобиль төзүнең эре үзәкләре булып торалар: Штутгартта данлыклы «мерседеслар», ә Мюнхенда «БМВ» маркалы автомобильләр («Байерише Моторверке») җитештерелә. ГФРның Төньягындагы диңгез портлары территориаль структураның иң әһәмиятле үзәкләре хезмәтен үтиләр, аларның иң зурысы — Гамбург, шулай ук Вольфсбург (анда «фольксваген» автомобильләре җитештерелә) һәм Ганновер. Илнең көнчыгыш өлешендә хуҗалыкның территориаль структурасының әһәмиятле үзәкләре — Берлин, Лейпциг, Дрезден.

**ГФР** хуҗалыгының географик сурәтенә Төньяк-Герман түбәнлегендә, Баварияда Дунай уң як ярында уртача биеклектәге таулар поясында барлыкка килгән эре авыл хуҗалыгы районнарының йогынтысы бар. Шулай ук Балтыйк диңгезе яр буенда, Альп таулары итәгендә, Гарц тауларында һәм Эльбадагы Саксония Швейцариясе дип йөртелә торган җирләрдәге төп рекреация һәм туризм районнары да өлеш кертә. [33].

ГФРда электән үк региональ сәясәткә аеруча игътибар бирелә: аның максаты — депрессив иске промышленность районнарын «реанимацияләү», агломерацияләргә йөкләмәне «җиңеләйтү», илнең аерым районнарының икътисадисоциаль үсеш дәрәҗәләрен тигезләү. Ләкин 1990 елдан соң региональ сәясәт чаралары иң элек ГФР мәйданының 33 % ын; ә халкы 26 % ын тәшкил иткән элеккеге ГДР территориясендә хуҗалыкның гомуми күтәрелешен тәэмин итүгә, структурасын үзгәртеп коруга юнәлтелә. Бу — бик авыр һәм гаять зур капитал кертүләр (элекке ГДРны Германия икътисадының төпсез капчыгы дип юкка гына атамыйлар) һәм күп вакыт таләп итүче мәсьәлә. Бигрәк тә 90 нчы елларда үзгәртеп кору башланган

көнчыгыш җирләрендә житештерү кискен кимеде, ә ул фактта җитди демографик һәм социаль-икътисади кризиска китерде. Алты көнчыгыш җирләренең ГФРның бердәм хуҗалык итү организмына тулысынча кушылып, үсеп китүе өчен әле билгеле бер вакыт таләп ителәчәк. (13 нче иҗади бирем.)

**Төп нәтиҗә.** *Европа чит илләре — дөньяда иң кечкенә территорияле регион, ләкин аның дөнья хуҗалыгында тоткан урыны гаять зур. Соңгы вакытта регионның сәяси һәм икътисади картасында зур үзгәрешләр булып тора.* (14 нче йомгаклау биреме.)

## ӨСТӘМӘ ТЕКСТ (Кызыклы фактлар)

[1] Илнең зурлыгы турында аның мәйданы буенча һәм шулай ук территориясенең никадәр сузылган булуына карап фикерләргә була. Регионда иң «озын» ил — Норвегия, ул төньяктан көньякка 1750 км га сузылган. Франция һәм Бөекбританиянең максималь озынлыгы — 1000 км чамасы, ГФРның — 875 км, Венгрия һәм Болгариянең — 500 км чамасы, Бельгиянең — 230 км.

[2] Микродәүләтләрнең иң «зурысы» — Франция белән Испания арасында урнашкан һәм 467 км$^2$ мәйдан биләгән (Мәскәү шәһәре мәйданыннан ике тапкыр кечерәк) Андорра кенәзлеге. Мәйданы 160 км$^2$ булган, Рейн елгасы буйлап 25 км сузылган, ә киңлеге фәкать 10 км булган Лихтенштейн кенәзлеге Швейцария белән Австрия арасында урнашкан. Сан-Марино Республикасының беренче дәүләт законнары җыелмасы 1263 елга карый, ул Италия территориясе белән әйләндереп алынган һәм 61 км$^2$ мәйдан били. Урта диңгезнең Франция яр буенда урнашкан Монако кенәзлеге 1,9 км$^2$ мәйдан алып тора, һәм ул 2,7 км га сузылган. Римның көнбатыш өлешендә урнашкан шәһәр-дәүләт Ватикан 0,44 км$^2$ мәйдан били.

[3] Чехиядә дәүләт чигеннән — 105 км, Болгариядә — 120 км, Румыниядә — 170 км, Польшада 230 км дан ераграк урнашкан бер генә торак пункт та юк.

[4] 1953 елда һәлакәтле су басудан соң, «Дельта-план» кабул ителә. Су басуы вакытында диңгез суы басымы белән дамбалар һәм шлюзлар җимерелә, һәм су ташкыны Рейн, Маас һәм Шельда елгалары дельталарына бәреп керә, нәтиҗәдә 50 мең йорт җимерелә. Дамбаның җимерек урыннарын кешеләрнең көнетөне томалауларына, ә капитаннарның үзләренең судноларын сай җиргә куеп дулкынны киртәләүләренә карамастан, су үзенекен итә. Бу план дамба һәм шлюзларның барлык елга

һәм канал тамакларын ябуны, аларның фәкать икесен генә ачык калдыруны күздә тота. Дамба төзү өчен таш Швеция һәм Финляндиядән китертелә. «Дельта-план» 1958—1968 елларда тормышка ашырыла.

[5] Беренче чиратта бу 2050 елда халкы 50,1 млн гына калуы мөмкин булган Италиягә, Испаниягә (42,5 млн), Германиягә (78,8 млн) кагыла. Румыниянең халкы 5 млн кешегә, Болгария һәм Венгриянең 2,6 млн, Чехиянең 2 млн, Польшаның 6 млн га кимүе мөмкин.

[6] 2000 елда ГФРда яшәүче халыклар арасында (мең кеше): төрекләр — 2000, югославлар — 660, италиялеләр — 620, греклар — 365, поляклар — 360, хорватлар — 215, австриялеләр — 185, босниялеләр — 155, португалиялеләр — 135, испаннар — 130, руслар — 115, инглизләр — 115, америкалылар — 113, голландлар — 110, иранлылар 105 булган. Моннан тыш, 50 дән 100 меңгә кадәр румыннар, украиннар, вьетнамлылар, марокқашлар, әфганнар, венгрлар, ливанлылар, кытайлылар, македониялеләр, ланкийлылар исәпләнгән.

[7] Көньяк славян халыкларының бер өлеше (болгарлар, серблар, македониялеләр, черногориялеләр) славян графикасын кулланалар; бу телләр рус, украин, белорус телләре белән тугандаш. Мәсәлән, болгар телендәге «ден» — русча «день», «утро» — «утро», «благодаря» — «спасибо», «сладолед» — «мороженое» дигән сүзне аңлата. Башка славян халыклары — поляклар, чехлар, словак, хорват һәм словеннар латин графикасын файдалана. Әмма латин хәрефләре белән язылган чех сүзләре leto, zima, pole, voda, škola, otec — русча «лето», «зима», «поле», «вода», «школа», «отец» сүзләрен аңлата.

[8] Европа чит илләрендә бу семьялыкка фин, венгр һәм эстон телләре керә, ә алар фонетик составының һәм грамматик структурасының үзенчәлеге белән башкалардан аерылып тора. Мәсәлән, аларда род категориясе юк, ә бәйлелек һәм тартым алмашлыгы функцияләрен килеш кушымчалары үти. Сүз уңаенда шуны да әйтик: фин телендә — 15, ә венгр телендә 30 лап килеш бар.

[9] Халкы 1 мең кеше булган шәһәр-дәүләт Ватиканның үз хөкүмәте, банкы, гвардиясе, законнары, валютасы, почта маркалары һәм, иң мөһиме, үз монархы — Рим Папасы бар. Ватиканның төп функциясе — дини, эшчәнлек сферасы — бөтен дөнья, чөнки католик динен тотучыларның саны 1 млрд кеше исәпләнә, ә католик чиркәве аппараты 400 мең руханидан һәм 1 млн нан артык монах һәм ярыммонах орденнарыннан тора. Ватикан зур капиталга һәм шактый зур җир мәйданнарына ия.

[10] Британия пассажир флотының иң зур «Куин Мэри» һәм «Куин Элизабет» суднолары Клайд елгасындагы Глазго шәһәрендә төзелә. Аларның сукуышы 80 мең тоннадан артып киткән, алар барлыгы 4 млн нан артыграк пассажир ташыган. 1944 елда «Куин Элизабет» үзенең бортына иң күп кеше — 15 200 хәрбине алып диңгез кичү тарихында үзенчәлекле бер рекорд куйды. Әмма Гонконг миллионеры тарафыннан 1972 елда сатып алынган бу лайнер янгыннан һәлак була.

[11] 2010 елда Россиядән ГФРга Балтыйк диңгезе төбе буйлап салына торган яңа газ үткәргеч («Төньяк ташкын») сафка басарга тиеш. Шуның буенча газ киләчәктә Дания, Бельгия, Нидерланд, Франция, Бөекбританиягә киләчәк.

[12] 50 нче еллар ахырында Польша геологлары тарафыннан нефть эзләү эшләре үткәрелә һәм нефть урынына бакыр рудасы ятмалары табыла, ә ул Европадагы ятмаларның иң зурысы булып чыга. Бакырлы комлыкларның бик тирәндә ятуына һәм тау-геологик шартларның катлаулы булуына карамастан, бу ятма үзләштерелә һәм Түбән Силезия бакыр рудасы бассейны барлыкка килә.

[13] Бельгия «браунинг» ау мылтыгы җитештерү, алмаз эшкәртү (Антверпен — бөтендөнья бриллиант сәүдәсе үзәге), Австрия — тау чаңгылары, Чехия — бизәнү әйберләре, карандашлар (бөтен дөньяда мәгълүм «Кох-и-Нор» фабрикасы көнгә 1 млн данә 21 төрле катылыкта һәм 64 төстәге карандаш чыгара) эшләп чыгару белән дан тоталар. Лихтенштейнда исә ясалма тешләр җитештерүче дөньяда иң зур предприятие эшли. Аның продукциясе йөздән артыграк илгә озатыла.

[14] Франциядә сырның 400 дән артыграк сорты билгеле. Илнең көньягында Рокфор дигән урында мең ел буена җитештерелә торган «рокфор» сыры аеруча танылды. Сарык сөтеннән ясалган бу сыр табигый җир асты мәгарәләрендә озак вакыт саклана һәм шуңа күрә үзенә генә хас тәмле ис һәм үзенчәлекле сыйфатларга ия була. Швейцариядә сөтне тулысынча диярлек май һәм сыр ясау өчен файдаланалар. Голландиялеләр менюсында сыр булмавын күз алдына китереп булмый.

[15] Нидерланд — дөньяда иң күп чәчәк үстерүче ил. Амстердамнан ерак булмаган Алсмер шәһәрендә чәчәк сату буенча дөньяда иң зур аукцион үткәрелә. Ул мәйданы ягыннан 30 футбол кырына тиңләрлек гаять зур бинага урнашкан. Анда елга 1 млрд тан артыграк роза чәчәкләре генә сатыла. Нидерланд чәчәкләре дөньяның 140 иленә чыгарыла. Илнең үзендә дә чәчәкләрне һәркайда очратырга мөмкин.

[16] Сыра кайнату һөнәрен германлылар бик борынгы заманнардан ук белгәннәр, ул бигрәк тә ГФР һәм Чехиядә киң таралган, биредә сыра чын-чынлап милли эчемлеккә әверелгән.

Колмак җыю буенча, ГФР дөньяда беренче урынны алып тора. Җан башына сыра куллану буенча да ул шулай ук беренче урында (елына 160 л).

[17] Исландиянең балык тоту флоты 1 мең суднодан тора, елына уртача 1,5 млн т, ягъни җан башына 6 т дан артыграк балык тотыла. Элек башлыча дөньяда иң эре саналган исланд сельде һәм треска тоткан булсалар, хәзер исә балык оны хәзерләү өчен мойва тотыла. Балык тоту һәм аны эшкәртү белән илдәге актив халыкның 40 % ы шөгыльләнә. Балык һәм балык продуктлары ил экспортының 3/4 ен тәшкил итә.

[18] 1981 елда ук инде югары тизлекле Париж — Лион линиясе сафка басты һәм шуннан соң ул Марсельгә кадәр озайтылды (878 км). Аннары Париж — Бордо (480 км), Париж — Страсбург (460 км) һәм кайбер башка линияләр төзелде. Бу линияләрдә поездлар тизлекне сәгатенә 250—300 км га кадәр җиткерәләр.

[19] 1973 елда Истанбулда Босфор бугазы аша автомобиль күпере ачылды. Ул Европада иң зур күпер, ә дөньяда дүртенче урында тора. Аның торыгы озынлыгы 1 км. Күпердә алты рәтле хәрәкәт булганлыктан, аның аша тәүлегенә 20 меңләп машина уза. 1988 елда шундый ук икенче күпер эксплуатациягә тапшырылды.

[20] Эресунн бугазы аша Копенгаген һәм швед шәһәре Мальмё арасындагы транспорт кичүе 16 км га якын сузыла, тоннельдән һәм ике катлы күпердән тора. Шуннан дүрт полосалы шоссе һәм тизлекле ике линияле тимер юл үтә.

[21] Ла-Манш астыннан үтәргә тиешле тоннельнең беренче проекты Франциядә XIX гасыр башында тәкъдим ителә. Шуннан соң аңа охшаш проектлар күп тапкыр күтәрелә. Әмма аны төзүне Франция һәм Бөекбритания 1987—1994 елларда гына гамәлгә ашыралар. Фактта бугазның төбе буйлап өч параллель тоннель сузыла: икесе — поездларның ике юнәлештә хәрәкәт итүе һәм берсе аларга хезмәт күрсәтү өчен. Тоннельнең гомуми озынлыгы — 50 км, шуның 37 км ы бугаз төбенә (40 м тирәнлектә) туры килә. Хәзер Евротоннель аша Париждан Лондонга килү өчен 2,5 сәгатьтән кимрәк вакыт җитә. Тоннель эшли башлаганнан бирле, аннан уннарча миллион пассажир файдаланды.

[22] Заманча туризм XIX гасырның 40 нчы елларында Англиядә туган дип исәпләнә. Т. Кук туристик конторага нигез сала. Ял итүгә килгәндә, Англия гольф (1857), футбол (1863), теннис (1875) ватаны булып исәпләнә.

[23] Француз Ривьерасы XIX гасырда ук Бальзак, Флобер, Мопассан кебек француз язучыларының яраткан ял итү урыны була. Биредә рус язучылары һәм артистлары Н. В. Гоголь, Ф. И. Тютчев, А. И. Куприн, А. П. Чехов, И. А. Бунин,

В. В. Маяковский, Ф. И. Шаляпин, С. П. Дягилев яшәгәннәр һәм эшләгәннәр. XX гасырда Америка язучылары: Эрнест Хемингуэй һәм Скотт Фицджеральд Ривьераны тасвирлап калдырганнар.

[24] Франциядәге — Шамони, Швейцариядәге — Давос, Италиядәге — Боромио, ГФРдагы Гармиш-Партенкирхен курортлары иң популяр Альп курортлар исәбенә керәләр. Альп районында туристларны кабул итү өчен урынның гомуми саны 3 млн нан артып китә. Аларның карамагында биредә 12 мең күтәргеч һәм 40 мең чаңгы трассалары исәпләнә.

[25] Фарсы култыгыннан Роттердамга юл тоткан Америка супертанкеры «Амоко Кадис» 1978 елның мартында, Франция яр буена килеп җиткәндә, рифка бәрелә. Аннан 230 мең т нефть агып чыгып, яр буйларына, пляжларга, устрица плантацияләренә, балыкчылар гаваньнарына 200 км га тарала.

[26] Велосипед, массакүләм транспорт чарасы буларак, Нидерландта һәм Даниядә аеруча киң таралган. Норвегиялеләр турында алар аякларына чаңгы киеп туа дисәләр, голландиялеләр һәм даниялеләр турында велосипед белән туа дип сөйлиләр. «Велосипедта монашкалар һәм руханилар, эшләпәле хезмәткәрләр һәм почтальоннар, яшүсмерләр, экстравагант ханымнар, кәрзиннәренә ашамлыклар салынган хуҗабикәләр йөриләр»,— дип яза Нидерланд турында безнең заман сәяхәтчесе.

[27] Европаның чит илләрендә барлыгы 2200 гә якын аеруча саклана торган табигый территория исәпләнә. Аларның гомуми мәйданы 580 мең км$^2$, бу — регионның иң зур иле — Франциянең мәйданыннан да артыграк. Башка илләрдән саклана торган территорияләр саны буенча Германия (472), Швеция (189), Австрия (187), Испания (161), Италия (143), Бөекбритания (131) һәм Швейцария (112) аерылып тора.

[28] Франциянең башкаласында 700 дән артыграк сәяси, икътисади һәм иҗтимагый оешма урнашкан. Алар арасында ЮНЕСКО, Икътисади хезмәттәшлек һәм үсеш оешмасы, Туганлашкан шәһәрләрнең бөтендөнья оешмасы, Халыкара университетлар ассоциациясе, Халыкара сәүдә палатасы, Халыкара энергетика ассоциациясе, Халыкара криминаль полиция ассоциациясе (Интерпол) һәм башкалар. Ә Брюссельдә мондый оешмалар 1400!

[29] Тролль чыганагын үзләштерү өчен 656 мең т авырлыктагы гигант бораулау платформасы төзелә. Аны төзү өчен, 245 мең м$^3$ бетон һәм 100 мең т корыч арматура тотыла, ә ул Эйфель манарасындагы арматура авырлыгыннан 15 тапкыр артып китә. Биеклеге ягыннан (472 м) бу бораулау платформасы Эйфель манарасын гына түгел, бәлки дөньядагы барлык күксөзәрләрне узып китә.

[30] Бонн — Германиянең бик борынгы шәһәрләреннән берсе. Ул 1989 елда 2000 еллыгын билгеләп узган. Аны Рейн елгасында крепость итеп римлылар төзегән. Бонн күп гасырлар буена тыныч кына провинциаль шәһәр булып яши. Монда Бетховен туганга, университетта Карл Маркс һәм Генрих Гейне укыганга гына ул танылып китә. 1949 елда ГФР барлыкка килгәч, нәкъ менә шушы шәһәр башкалага әверелә.

[31] XVI—XIX гасырларда герцоглар резиденциясе булган Тюрингендагы борынгы Веймар шәһәре (1975 елда 1000 еллыгы булды) Иоганн Вольфганг Гёте, Фридрих Шиллер, Ференц Лист, Иоганн Готфрид Гердер исемнәренә бәйле рәвештә мәдәни-тарихи үзәк буларак дан-шөһрәт казана. Шәһәр үзәгендә Гёте яшәгән йорт сакланган, ул анда 1782 елдан 1832 елда вафатына кадәр яшәгән. XIX гасыр ахырында ук бу йорттан музей ясыйлар, анда барлык җиһазлар, библиотека, язучының кабинеты, минераллар коллекциясе һәм ул үлгән бүлмә саклана. Шиллер йортында да мемориаль музей ачылган, ул анда гомеренең соңгы елларында яшәгән һәм үзенең иң соңгы әсәрен — «Вильгельм Телль» драмасын шунда язган.

[32] Рейн елгасы буенда урнашкан Дуйсбург шәһәрен, гадәттә, Рурның «Көнбатыш капкасы» дип атыйлар. Аның, дөрестән дә, шулай булуын причалларның, килеп тукталу юлларының, складларының катлаулы лабиринты раслый. Дуйсбургта Германиянең иң зур металлургия комбинатлары урнашкан, чимал һәм ягулыкны аңа Рейн буенча читтән китертәләр. Шуңа күрә бу елга портының йөк әйләнеше (елына 55 млн т) бөтен дөньяда беренче урынны алып тора. Бу йөк әйләнешенең күләме Германиянең Гамбургтан кала теләсә кайсы диңгез портының йөк әйләнешеннән артып китә.

[33] Аеруча саклана торган табигый территорияләренең саны буенча ГФР барлык Европа чит илләреннән алда. Илдәге мондый территорияләрнең саны 472, аларның гомуми мәйданы 88 мең км$^2$ га җитә яки илнең бөтен территориясенең 1/4 ен алып тора. Саклана торган территорияләрнең күпчелеге — зур булмаган табигый ландшафтлар, ә төп өлешен табигый парклар («натурпарклар») тәшкил итә. Мондый паркларның саны — 61, һәм алар, нигездә, тау-урман районнарында урнашкан (Бавар урманы, Франкон урманы, Тевтобург урманы һ. б.).

**Китап киштәсе**


1. Зарубежная Европа.— М.: Мысль, 1979—1983.— (Серия «Страны и народы»).
2. Максаковский В. П. Географическая картина мира.— М.: Дрофа, 2009.— Ч. 2.— Тема 1.

3. Экономическая и социальная география мира: За страницами учебника: Кн. для учащихся 10 кл./Сост. А.П.Кузнецов.— М.: Просвещение, 2000.— Раздел «Европа».
4. Самые красивые города Европы. Открытия. Путешествия. Отдых. История. Современность.— М., 2000.

## БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘР АЛУ ӨЧЕН ТУПЛАНМА

**1 нче бирем.** Атлас карталарын файдаланып, Европа чит илләренең берәрсенең (үзегез сайлап) икътисади-географик урынына характеристика бирегез. Илнең икътисади-географик урынына характеристика биргәндә, үрнәк планнан файдаланыгыз (222 нче биттәге планны карагыз).

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** Атластагы сәяси картада регионда кайсы илнең күршедәш илләр саны күбрәк булуын билгеләгез. Моның нинди әһәмияте булуы мөмкин?

**2 нче бирем.** Форзацтагы «визит карточкасыннан» файдаланып, Европа чит илләренең дәүләт төзелешләре характеристикасын конкретлаштырыгыз. Тарих курсларыннан алган белемнәрегезгә нигезләнеп, ни өчен дөньяның бер генә өлешендә дә Көнбатыш Европадагы кебек күп конституцион монархияләр сакланып калмавын аңлатыгыз. Контурлы картада республикаларны һәм монархияләрне билгеләгез. Шулай ук «Кушымта»дагы 2 нче таблицаны файдаланыгыз.

**3 нче бирем.** Европа чит илләренең атласта бирелгән файдалы казылмалар картасын файдаланып, региондагы илләрне ягулык, рудалы һәм руда булмаган файдалы казылмаларга ни дәрәҗәдә бай булулары һәм аларның төрлелеге буенча чагыштырыгыз. Илнең (регионның) промышленностен үстерү өчен табигый алшартларга характеристика планыннан файдаланыгыз (222 нче биттәге планны карагыз). Шулай ук «Кушымта»дагы 3—5 нче таблицаларны файдаланыгыз.

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** Атластагы картадан Бөекбритания, ГФР, Франция һәм Италия территорияләренең нинди киңлек чикләрендә ятуларын билгеләгез. Күргәзмәле чагыштыру өчен БДБ илләреннән мисаллар китерегез.

**4 нче бирем.** 47 нче рәсемне файдаланып, Европа чит илләренә, халык иммиграциясенең төп регионы буларак, характеристика бирегез. Халыкның массакүләм иммиграциясе һәм эмиграциясе күзәтелгән илләрне аерып күрсәтегез. 47 нче рәсемнән мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат алыгыз.

**5 нче бирем.** Европа чит илләре халыклары картасы буенча һинд-европа һәм урал семьялыклары халыкларының ничек таралуын

характерлагыз. Халык составы бер милләтле, ике милләтле һәм күп милләтле булган илләрне билгеләгез.

**6 нчы бирем.** 48 нче рәсем буенча дәфтәрегездә «Европа чит илләрендәге «Миллионер-агломерацияләр» таблицасын төзегез һәм шундый шәһәрләр санына карап, аерым илләрне үзара чагыштырыгыз. Сез ничек уйлыйсыз, Европа чит илләрендә урбанизация процессының төп өч үзенчәлеге дә ачык чагыла дип әйтергә мөмкинме?

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** 48 нче рәсемне һәм Европа чит илләренең атластагы физик картасын файдаланып һәм икътисади-географик урынына карап, миллионер шәһәрләрне классификацияләгез. 1) Диңгез ярлары буенда, 2) елга тамагында, 3) диңгездән ерак, ләкин судно йөрешле елгалар янында, 4) диңгездән ерак урнашкан шәһәрләрне билгеләгез. Классификация нәтиҗәләрен таблицада күрсәтегез. Башкалаларның кайсылары илнең географик үзәгенә якын урнашкан?

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** «Европа илләренең башкалалары» темасына кроссворд төзегез.

**7 нче бирем.** Дәреслек текстын һәм рәсемнәрне, шулай ук атластагы карталарны һәм «Кушымта»дагы 23—28 нче таблицаларны файдаланып, Европа чит илләрендәге берәр промышленность тармагының (үзегез сайлап) характеристикасын конкретлаштырыгыз. Төп районнарны һәм эре үзәкләрне яки төп бассейннарны күрсәтегез, илләр арасында аларның бүленешен билгеләгез. 25—29 нчы рәсемнәр ярдәмендә нефть, табигый газ, күмер, тимер рудасы һәм корычның Европа чит илләренә кайдан керүен ачыклагыз.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Атласта бирелгән Европа чит илләре картасын файдаланып, кара металлургия районнарының һәм үзәкләренең: 1) ташкүмер бассейннарына, 2) тимер рудасы бассейннарына, 3) читтән кертелгән ташкүмер һәм тимер рудасына (шул исәптән диңгез буйлап) ориентлашуына мисаллар китерегез.

**8 нче бирем.** 52 нче рәсемнән файдаланып, Урта һәм Көньяк Европа тибындагы илләргә нинди авыл хуҗалыгы культуралары хас булуын билгеләгез. Охшашлык һәм аермалык билгеләрен күрсәтегез. Аңлату өчен атластагы агроклиматик картаны файдаланыгыз.

**9 нчы бирем.** Дәреслек текстын һәм атластагы Европа чит илләренең транспорт картасын файдаланып, төп тимер юл магистральләрен, судно йөрешле елгаларны һәм регионның диңгез портларын контурлы картага төшерегез. Транспорт челтәре бер үзәкле (радиаль) һәм күп үзәкле булган илләргә мисаллар китерегез. Моның шулай формалашуының сәбәпләре турында уйлагыз.

**10 нчы иҗади бирем.** Лондон һәм Парижның үзәк өлешләренең атласта бирелгән планнарын һәм өстәмә мәгълүмат чыганакларын файдаланып, бу шәһәрләрнең мәдәни-тарихи истәлекле урыннары турында чыгыш әзерләгез. Ни өчен аларның эре туризм үзәгенә әверелүләрен аңлатыгыз.

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** Европа чит илләрендә Бөтендөнья мәдәни мирас объектлары белән танышуга багышланган ике атналык каникул үткәрү планын төзегез. Маршрутның бер-ике вариантын тәкъдим итегез.

**11 нче бирем.** Рур промышленность районының атластагы картасын анализлагыз. Аның промышленностеның төп тармакларын һәм промышленность үзәкләрен билгеләгез. Бу тармакларның кайсылары иске, ә кайсылары яңа?

**12 нче бирем.** Европа чит илләренең форзацтагы «визит карточкасын» һәм диаграммалар җыелмасын (203—205 нче битләр) файдаланып, берәр ил турында чыгыш ясагыз (үзегез сайлап алып).

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Атластагы карталарны файдаланып, Европа чит илләреннән берсенең (үзегез сайлап алып) төп промышленность үзәкләрен, авыл хуҗалыгы районнарын, транспорт магистральләрен һәм диңгез портларын контурлы картага төшерегез. Алдарак ясаган чыгышларыгызга өстәмә итеп, эшләнгән карта-схемага анализ ясагыз.

**13 нче бирем.** Дәреслекнең I кисәге, 6 нчы теманың «Европа чит илләре» материалын карап, шулай ук «Кушымта»дагы таблицаларны файдаланып, ГФРга караган барлык мәгълүматларны һәм санлы күрсәткечләрне дәфтәрегезгә языгыз. Конспектны бу илгә тулы икътисади һәм социаль характеристика бирү өчен файдаланыгыз.

**14 нче йомгаклау биреме.** 1. (Дәфтәрдә эшләү.) Европа чит илләрен түбәндәге күрсәткечләр буенча төркемләгез: 1) территориясенең зурлыгы, 2) халык саны, 3) урбанизация дәрәҗәсе. Нәтиҗәләр ясагыз.

2. (Дәфтәрдә эшләү.) 5 нче тема текстын, таблицалар һәм рәсемнәрне файдаланып, региондагы илләрнең кайсылары промышленность һәм авыл хуҗалыгы продукциясенең аерым төрләрен җитештерү буенча бөтендөнья илләре арасында «беренче унлык»ка керүен билгеләгез. Табылган мәгълүматлар буенча таблица төзегез.

3. 6 нчы теманы өйрәнгәндә файдаланган карталарда картографик сурәтләү ысулларын билгеләгез. Аларның кайсылары сезнең өчен яңа?

4. Шушы тема буенча тәкъдим ителгән берәр китапка (яки аның берәр бүлегенә) кыскача рецензия әзерләгез.

## ҮЗЕГЕЗНЕҢ ҺӘМ БЕР-БЕРЕГЕЗНЕҢ БЕЛЕМНӘРЕН ТИКШЕРҮ ТУПЛАНМАСЫ

**Конкрет материалны белүегезне тикшерегез:**

1. Түбәндә саналган Европа чит илләренең кайсыларында конституцион монархия: Норвегия, Бөекбритания, Швеция, Финляндия, Испания, Греция, ГФР?

2. Бу илләрнең кайсылары Дунай су юлын диңгезгә чыгу өчен файдалана: Югославия, Хорватия, Словения, Албания, Румыния, Польша, Венгрия, ГФР?

3. Европа чит илләре портларының кайсылары дөнья порты категориясенә керә: Осло, Глазго, Лондон, Гамбург, Роттердам, Марсель, Барселона, Афина, Гданьск, Констанца?

4. Түбәндә саналган районнарның кайсылары нык үскән районнар рәтенә керә: Мидленд, Көньяк Уэльс, Лондон һәм Париж районнары, Лотарингия, Көньяк Германия?

**Дәреслек текстыннан түбәндәге сорауларга җаваплар табыгыз:**

1. Көнбатыш Европа шәһәренә нинди үзенчәлекләр хас?

2. Көнчыгыш Европа илләренең ягулык-энергетика хуҗалыгы нинди специфик үзенчәлекләргә ия?

3. Файдалы казылмалар җыелмасы буенча Европаның төньяк һәм көньяк өлешләре арасында төп аерма нәрсәдә?

4. Европа чит илләренең транспорт системасына нинди үзенчәлекләр хас?

**Сорауларга картадан файдаланып җавап бирегез:**

1. Европа чит илләренең кайсыларында башкала ролен бу илдә иң зур булмаган шәһәр үти?

2. Регионның кайсы илләрендә халык иң тыгыз урнашкан?

3. Ютландия ярымутравын әйләнеп узмыйча, су юлы белән Төньяк диңгездән Балтыйк диңгезенә ничек чыгарга?

4. 1) Башкала шәһәрләренә, 2) порт шәһәрләренә, 3) күмер бассейннарында формалашкан промышленность районнары һәм узелларына бигрәк тә нинди тармаклар хас?

5. Металлургия комбинатларының кайсылары диңгез аръягыннан китерелгән чимал һәм ягулык белән эшли?

**Аңлатыгыз:**

1. Европа чит илләре кайчан һәм ни сәбәпле халык иммиграциясенең бөтендөнья чыганагына әверелде?

2. Ни өчен Франция һәм Бөекбританиянең башкалалары башка шәһәрләрдән гаять зур булулары белән кискен аерылып тора, ә ГФР һәм Италиядә бу күренеш күзәтелми?

3. Ни өчен Бөекбритания, ГФР, Бельгия һәм Швециядә кулланыла торган суның 60—80 % ы промышленностька, ә Испания, Португалия, Италия һәм Грециядә авыл хуҗалыгына туры килә?

4. Якын һәм Урта Көнчыгыш илләре белән чагыштырганда нефть чыгаруның үзкыйммәте күп тапкырлар югарырак булса да, нефть монополияләре ни сәбәпле нефть эзләү һәм нефть чыгару эшләрен Төньяк диңгездә алып баралар?

5. Ни өчен Норвегия балык тотудан авыл хуҗалыгына караганда күбрәк табыш ала?

6. Ни өчен Рейн елгасы йөк әйләнеше буенча дөньядагы башка елга системаларыннан өстенрәк?

7. Ни өчен Европа халыкара туризмның төп районы булды?

8. Ни өчен депрессив иске промышленность районнарында мохиткә куркыныч яный?

**Күрсәтегез:**

1. Түбәндә саналган илләрнең кайсыларында һинд-европа семьялыгындагы герман төркеме телләрендә сөйләшәләр: Италия, Австрия, Греция, ГФР, Финляндия, Бөекбритания?

2. Түбәндә саналган илләрнең кайсыларына иммигрантлар агылуы хас: Италия, Испания, ГФР, Бөекбритания, Франция, Швейцария?

3. Түбәндә китерелгән илләр өчен раслауларның кайсылары туры килә?

| Илләр | Раслаулар |
|---|---|
| Польша<br>Венгрия<br><br>Франция<br>ГФР<br>Швейцария<br>Финляндия<br>Италия | 1. Бер милләтле ил<br>2. Милли азчылык өлеше шактый зур булган ил<br>3. Күп милләтле ил<br>4. Унитар административ-территориаль төзелешле ил<br>5. Федератив административ-территориаль төзелешле ил |

**Булдыра аласызмы?**

1. Текстта һәм тексттагы карталарда телгә алынган илләрне: Исландия, Дания, Финляндия, Ирландия, Люксембург, Австрия, Венгрия, Болгария, Албания, Португалияне дөньяның контурлы картасына хәтердән төшерә аласызмы?

2. 1) Бары тик ГФР белән генә, 2) Испания белән генә, 3) ГФР, Швейцария, Италия, Словения, Венгрия, Чехия һәм Словакия белән коры җир чиге булган илләрне хәтердән әйтә аласызмы?

3. Текстта һәм текст карталарында телгә алынган шәһәрләрне: Глазго, Роттердам, Марсель, Брюссель, Мюнхен, Неаполь, Краков, Загребны картада күрсәтә аласызмы?

4. Европада бөтенләй диярлек авыл халкы булмаган илне әйтә аласызмы?

5. Түбәндәге исемлектән:

а) бер милләтле илләрне төшереп калдырыгыз: Бельгия, Испания, Норвегия, Португалия, ГФР, Бөекбритания;

б) промышленность производствосы башкала районнарында тыгыз урнашмаган илләрне төшереп калдырыгыз: Чехия, Словакия, Венгрия, Австрия, Италия, Франция, Дания.

**Әзер җавапларның дөресен сайлап алыгыз:**

1. Франция: а) өч ил белән, б) биш ил белән, в) алты ил белән чиктәш.

2. Европа чит илләренең иң зур агломерациясе: Лондон, Париж, Рейн-Рур, Голландия.

3. Башкала регионнары: Мадрид, Париж, Рим, Вена, Стокгольм, Копенгаген, Прага, София, Афина диңгез буенда урнашкан.

4. Европа чит илләрендә нефть иң күбе: Испания, Австрия, Норвегия, Бөекбритания, Румыния, Албаниядә табыла.

## 6 НЧЫ ТЕМАГА МЕТОДИК АЧКЫЧЛАР

### Боларны исегезгә төшерегез

1. Европа чит илләренең сәяси картасы һәм халыклары. (География, 7 нче сыйныф.) 2. Европа чит илләренең физик-географик урыны, рельефы, файдалы казылмалары, климаты, сулары, туфраклары һәм үсемлекләренең үзенчәлекләре, табигый зоналары. (География, 7 нче сыйныф.) 3. XIX гасыр ахырында — XX гасыр башында Европа чит илләренең тарихи үсешендәге үзенчәлекләр. (Тарих, 8, 9 нчы сыйныфлар.) 4. Бу дәреслекнең I кисәк материалы. 5. Төшенчәләр һәм терминнар: икътисади-географик урын, хуҗалыкның территориаль структурасы, производствоның специальләшүе һәм кооперацияләшүе, инфраструктура, регион, субрегион.

### Боларны үзләштерегез

**6 нчы теманың төп идеяләре:**

1. Европа чит илләре — элек тә, хәзер дә бөтендөнья сәясәте һәм икътисадының төп үзәкләреннән берсе. 2. Европаның «иске ташлары» — Европаның гына түгел, бәлки бөтендөнья цивилизациясенең байлыгы.

**6 нчы темадагы төп фәнни белемнәр:**

1. Европа чит илләренең икътисади-географик урынына, табигый ресурслары географиясенә һәм халкына хас үзенчәлекләр. 2. Европа чит илләре халыкларының һәм хуҗалыгының территориаль урнашуында төп үзенчәлекләр. 3. Европа чит илләрендә промышленностьның төп тармакларының структурасы һәм урнашуының үзенчәлекләре, төп промышленность районнары. 4. Европа чит илләрендә авыл хуҗалыгы урнашуының төп

үзенчәлекләре һәм аның типлары. 5. Европа чит илләре региональ транспорт системасының төп үзенчәлекләре. 6. Европа чит илләренең халкы һәм хуҗалыгының географик сурәте. 7. Европа чит илләренең субрегионнары. 8. Германия Федератив Республикасы — Европа чит илләреннән икътисади иң куәтлесе. 9. Теманың төп төшенчәләре: 1) шәһәрләрнең Көнбатыш Европа тибы, 2) субурбанизация, 3) транспорт системасының Көнбатыш Европа төре, 4) промышленность-порт комплексы, 5) «үсеш күчәре», 6) башкала регионы.

## Сез нәрсәләр эшли белергә тиеш

1. Илнең икътисади-географик урынына характеристика бирергә. 2. Илнең (регионның) промышленностен үстерү өчен табигый алшартларга характеристика бирергә. 3. Исбатлау, чагыштыру, конкретлаштыру, таблицалар һәм графиклар төзү, исәпләүләр өчен төрле белем чыганакларын куллана белергә. 4. Яңа үзләштерелгән белемнәрне тирәнәйтү өчен, алда өйрәнгән текстны, график һәм картографик материалларны куллана белергә. 5. Укыган китапка (бүлеккә) рецензия яза белергә.

## Мөстәкыйль эш күнекмәләре булдыру буенча күрсәтмәләр һәм планнар

**1. Илнең (регионның) икътисади-географик урынына характеристика планы.**

1. Күрше илләргә карата урнашуы. 2. Төп коры җир һәм диңгез транспорты юлларына карата урнашуы. 3. Төп ягулык-чимал базаларына, промышленность һәм авыл хуҗалыгы районнарына карата урнашуы. 4. Төп продукция сату районнарына карата урнашуы. 5. Икътисади-географик урынның вакыт эчендә үзгәрүе. 6. Икътисади-географик урынның ил хуҗалыгы үсешенә һәм урнашуына йогынтысы турында гомуми нәтиҗә.

**2. Илнең (регионның) промышленностен үстерү өчен табигый алшартларга характеристика планы.**

1. Файдалы казылма байлыкларның запаслары һәм урнашуы, территориаль бергәлеге. 2. Су, урман ресурслары һәм алардан файдалану мөмкинлекләре. 3. Промышленностьны үстерү һәм аны табигый ресурслар белән тәэмин итү өчен, территориянең табигый ресурслар потенциалын гомуми бәяләү. 4. Промышленностьны үстерү өчен, табигый ресурслардан рациональ яки рациональ булмаган файдалану үзенчәлекләре. 5. Гомуми нәтиҗә. Ресурсларны арттыру һәм алардан файдалану перспективалары.

## 7 нче тема. АЗИЯ ЧИТ ИЛЛӘРЕ. АВСТРАЛИЯ

Азия чит илләре (БДБ илләренә карата) 3,8 млрд халык яшәгән 27,7 млн км$^2$ мәйданны били (2005 ел). Димәк, мәйданы ягыннан ул фәкать Африкадан гына калыша, ә халык саны буенча башка регионнарны шактый узып китә. Азиянең сәяси картасында 39 бәйсез дәүләт бар. Аларның күбесе дөньяда иң борынгылардан санала. Азия чит илләре — кешелек дөньясы барлыкка килгән урыннарның берсе, игенчелек, ясалма сугару, шәһәрләр, күп кенә культура байлыклары ватаны. Региондагы илләрнең күпчелеге үсеп килүче илләр рәтенә керә. Аның составында, гадәттә, дүрт субрегионны: Үзәк һәм Көнчыгыш Азияне, Көньяк-Көнчыгыш Азияне, Көньяк Азияне, Көньяк-Көнбатыш Азияне аерып күрсәтәләр. Көнчыгыш һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия илләре Азия-Тын океан регионына (АТР) керә.

Бу темада Австралия АТРга керүче ил-континент буларак карала.

### 1. АЗИЯ ЧИТ ИЛЛӘРЕНӘ ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКА БИРӘБЕЗ

**1. Территориясе, чикләре, урыны: илләр арасындагы зур аерымлыклар.** Азия чит илләренең территориясе төньяктан көньякка таба 7 меңләп км га, ә көнбатыштан көнчыгышка таба 10 мең км дан артыгракка сузылган. Кытай һәм Һиндстан гигант илләр рәтенә керә, калганнарының күбесе шактый зур илләрдән санала. [1]. Әмма шуның белән беррәттән Азиядә кечкенә илләр дә, микродәүләтләр дә бар. [2]. Күпчелек илләрнең чикләре ачык беленеп торган табигый чикләрдән үтә. Бу кайбер урыннарда, мәсәлән Һималайда, икътисади һәм башка төрле элемтәләр өчен җитди кыенлыклар тудыра.

Регион илләренең ИГУна төп өч билге хас.

Беренчедән, *күршелек:* ул күп яктан Азиянең һәр дүрт субрегион илләрен берләштерә.

Икенчедән, күпчелек илләрнең *диңгез буена урнашуы*, ә бу — иң мөһим сәүдә юллары узучы Тын, Һинд һәм Атлантик океаннар диңгезләренә чыгарга мөмкинлек бирә.

**Мисал.** Вьетнам территориясе Көньяк Кытай диңгезе яры буйлап 1700 км га сузылган тар полоса булып ята. Географлар бу илне юкка гына, образлы итеп, «Һинд-Кытайның Тын океан өстендәге балконы» дип атамыйлар. Вьетнамның башка илләр белән элемтәләре диңгез юллары буйлап тормышка ашырыла.

## 7 НЧЕ ТЕМАНЫҢ ПЛАН-СХЕМАСЫ



Өченче билге — кайбер илләрнең *эчкәре урнашкан булуы*, ә бу алар өчен, тулаем алганда, бик үк отышлы түгел.

**Мисал.** Монголия — материк эчендә урнашкан, диңгезгә чыгу юлы булмаган илләр арасында иң зур территорияле ил. Аның башка илләр белән элемтәсе Россия һәм Кытай транспорт системасы аша башкарыла.

Азия чит илләренең сәяси картасы соңгы вакытта зур үзгәрешләр кичерде. Икенче бөтендөнья сугышы алдыннан колонияләрдә һәм ярымколонияләрдә халыкның 90 % ы яши иде. Хәзер исә региондагы илләрнең һәммәсе диярлек — сәяси яктан бәйсез дәүләтләр. Шуңа да карамастан *Азия чит илләре әле күп кенә территориаль бәхәсләр мәйданы* булып кала. Бу әледән-әле кораллы бәрелешләр һәм хәтта озакка сузылган сугышлар белән барган региональ һәм җирле конфликтларның кискенләшүенә китерә.

Андый территориаль бәхәсләр Иран белән Гыйрак, Гыйрак белән Кувейт, Һиндстан белән Пакистан, Һиндстан белән Кытай, Кытай (КХР) белән Тайвань, Курил утраулары мәсьәләсендә Россия белән Япония, Кипр аркасында Греция белән Төркия арасында яшәп килә. Корея демаркацион чик белән Корея Халык Демократик Республикасына (КХДР) һәм Корея Республикасына бүленгән. Вакытлы Палестина автономиясе оештырылуга карамастан, аның белән Израиль арасындагы мөнәсәбәтләр әле тулысынча көйләнүдән ерак тора, ә Палестина дәүләтенең бәйсезлеккә күчүе инде күп мәртәбәләр кичектерелде.

Европа чит илләрендәге кебек үк, Азия чит илләрендә дә республикалар өстенлек итә, ләкин идарә итүнең монархия формасы сакланып калган илләр дә күп. [3]. (1 нче бирем.)

**2. Табигый шартлар һәм ресурслар: контрастлар регионы.** Тулаем алганда, регион авыр промышленность үсеше өчен база булдырырлык минераль ресурсларның күптөрлелеге белән аерылып тора. Кытай, Һиндстан платформалары чикләрендә ташкүмернең, тимер һәм марганец рудасының, руда булмаган файдалы казылмаларның төп бассейннары тупланган. Альп-Һималай һәм Тын океан руда пояслары чикләрендә төсле һәм сирәк металл рудалары өстенлек ала. *Әмма регионның хезмәтнең халыкара географик бүленешендәге ролен күп яктан билгеләүче төп байлыгы — нефтьтер, мөгаен.*

**Мисал.** Гәрчә Көньяк-Көнбатыш Азиянең күпчелек илләрендәге нефть һәм табигый газ запаслары инде тикшерелгән булса да, төп чыганаклар — Согуд Гарәбстанында, Кувейт, Гыйрак, Иранда, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә. Запаслары күп булу өстенә, алар нефть белән газ чыгару өчен тау-геология шартларының бик отышлы булуы белән дә аерылып торалар. [4].

Нефть һәм газны ныклап эзләүләр Көнчыгыш һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиянең кырый диңгезләренең дөньяда иң эре һәм иң аз өйрәнелгән шельфында алып барыла. (2 нче бирем.)

Регионда авыл хуҗалыгын үстерү өчен табигый-ресурс алшартлары да бик төрле. Шулай да күпчелек илләр өчен төп ике проблема бар.

Беренчедән, *җир ресурсларының җитәрлек булмау проблемасы.* Зур тау массивларының, чүл һәм ярымчүл пространстволарының булуы җир фонды структурасына зур йогынты ясый, анда авыл хуҗалыгы, бигрәк тә сөрүлек җирләрнең өлешен бик нык чикли. Нәтиҗәдә күпчелек илләрдә җан башына сөрүлек җирләр белән тәэмин ителү нибары 0,1—0,2 га тәшкил итә, ә кайвакыт аннан да кимрәк була, өстәвенә халык арткан саен бу сан кими бара.

Икенчедән, *агроклиматик ресурслардан рациональ файдалану проблемасы.* Регион территориясендәге күпчелек урында җылылык запасларының зур булуы авыл хуҗалыгы сезонында һәм хәтта ел буена үсемлекләрнең вегетациясен тәэмин итә. Ә менә дым ресурслары чиктән тыш тигезсез бүленгән. Әгәр дә муссон климатлы районнарда сугару кышкы чорда гына кулланылса, Көньяк-Көнбатыш Азиянең коры тропиклары һәм субтропикларында моны ел буена үткәрергә кирәк. Тулаем алганда, региондагы барлык тотылган су сугару өчен файдаланыла диярлек. *Биредә дөньядагы барлык сугарулы җирләрнең 3/4 өлеше урнашкан.* Мондый җирләрнең гомуми мәйданы буенча Һиндстан дөньяда беренче, Кытай икенче урында тора.

Азия чит илләрендә җирләрне сугару инде 4 мең елдан артык билгеле. Иранда моннан ике мең еллар элек төзелгән сугару системалары сакланып калган. Сүриядә (62 нче рәсемне карагыз), Гыйракта, Төркиядә сугарулы җирләрнең мәйданнарын арттырырга мөмкинлек биргән зур гидроузеллар төзелгән. Ә Фарсы култыгы илләрендә сугару өчен, нигездә, кыйммәткә төшә торган төчеләндерелгән диңгез суы кулланыла; гадәттә аны һәр агачка, һәр түтәлгә яисә клумбага җиткерәләр.

Регион территориясенең шактый өлешендә табигать шартлары (чүлләр, биек таулар) кешеләргә авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы белән шөгыльләнергә бөтенләй мөмкинлек бирми. (3 нче бирем.)

**3. Халкының саны, яңарып торуы, этник һәм дини составы, урнашуы, урбанизация.** Халкының саны буенча Азия чит илләре белән дөньяның бер генә зур регионы да ярыша алмый: дөньядагы халык санында аларның өлеше 60 % ка җитә. Бу *региондагы илләрнең күпчелеге әле демографик күчешнең икенче этабында,* ягъни демографик шартлау стадиясендә (гәрчә ул инде 90 нчы елларда кимүгә таба барса да) булуы белән аңлатыла.

Мондый демографик ситуация Азия чит илләрендәге күп кенә икътисади, социаль һәм экологик проблемаларны катлауландыра. Шуның өстенә, фаразларга караганда, 2025 елга регион халкы 4,6 млрд кешегә җитәргә тиеш.

Бу гомуми нәтиҗә әле аерым субрегионнар арасында шактый зур аермалар булуын инкарь итми. Көнчыгыш Азия илләрендә демографик сәясәт үткәрү тууның һәм халыкның табигый артуының шактый кимүенә китерде. Көньяк-Көнчыгыш Азиядә дә мондый артуның темплары инде шулай ук акрынлап кими башлады. Көньяк Азиядә мондый кимү акрынрак бара. Ә Көньяк-Көнбатыш Азия элеккечә демографик шартлауның үзәгендә тора, өстәвенә аның кайбер илләре «рекордсмен илләр» рәтенә керә. Бу әлеге субрегиондагы ислам динен тотучы гарәп илләренең, гомумән, демографик сәясәт үткәрмәве белән аңлатыла. [5].

Халыкның этник составы Азия чит илләрендә чиктән тыш катлаулы: этнограф-галимнәр бирелә төрле тел семьялыкларына һәм төркемнәренә караган 1 меңнән артык халыклар яши дип исәплиләр. (4 нче бирем.) Алар арасында күп санлы һәм тауларда яшәүче бик аз санлы халыклар да бар. Күпчелек илләр күпмилләтлеләр исәбенә керә.

**Мисал.** Һиндстанда һәм Индонезиядә 150 дән артык, Филиппинда — 100 ләп, Кытай белән Вьетнамда — 60 ка якын, Иран, Әфганстан, Мьянма, Таиландта 30 дан артык халыклар яши.

Азия чит илләре — күп гасырлар, хәтта мең еллар буена сәясәткә, икътисадка, рухи культурага, халыкның яңарып торуына [6], халыкларның гореф-гадәтләренә гаять зур йогынты ясаучы дөньядагы барлык өч диннең, шулай ук күп кенә эре милли һәм региональ диннәренең ватаны. Дин матди культурада да — мөселман мәчетләрендә, индуистлар храмнарында, будда пагодаларында һәм монастырьларында киң кулланыш таба. Әле безнең көннәрдә дә кешеләр тормышының һәр ягына диннең тәэсире бик зур булып кала.

Мөселман илләрендә дин еш кына ир белән хатынның җәмгыятьтә һәм гаиләдә хокукларын һәм вазифаларын бик кырыс тәртипкә сала (мәктәпләрдә һәм университетларда аерым уку, аерым эшләү, җәмәгать урыннарында һәм шәхси йортларда аерым биналар), никах мөнәсәбәтләренә (күп бала табуны яклау, күп хатын алырга рөхсәт итү, туй йолалары), көн тәртибенә (көн саен биш вакыт намаз уку, җомга көн ял көне итеп билгеләнү), туклану рационына (Рамазан аенда ураза тоту, Корбан бәйрәме, хәмер эчү һәм дуңгыз итен ашауны тыю), киемсалымга (хатын-кызларның пәрәнҗә ябынып йөрүе), суд системасына (шәригать хөкеме), тышкы миграцияләрнең характерына йогынты ясый. [7]. Азиядәге күпчелек мөселман илләрендә ислам дине дәүләт дине дип игълан ителгән: Иран, Пакистан, Әфганстанда бу хәл илләрнең рәсми исемнәрендә чагылыш тапкан.

15 НЧЕ ТУПЛАНМА

| Урыны | 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|---|
| Промышленностьта эшләүчеләр саны | Кытай | АКШ | Япония |
| Электр энергиясе җитештерү | АКШ | Кытай | Япония |
| АЭСларда электр энергиясе җитештерү | АКШ | Франция | Япония |
| Корыч | Кытай | Япония | АКШ |
| Җиңел машиналар | Япония | АКШ | ГФР |

| Урыны | 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|---|
| Диңгез суднолары | Япония | Корея Республикасы | Кытай |
| Промышленность роботлары | Япония | АКШ | ГФР |
| Электроника продукциясе | АКШ | Кытай | Япония |
| Пластмассалар | АКШ | Япония | ГФР |
| Фәнни җиһазлар | АКШ | Япония | ГФР |

61


62

59 нчы рәсем. Чит илләр арасында Япония промышленносте

60 нчы рәсем. Шарык базары

61 нче рәсем. Фарсы култыгындагы нефть бассейны

62 нче рәсем. СССР ярдәмендә Сүриядә төзелгән Евфрат гидроузелы

63 нче рәсем. Согуд Гарәбстаны башкаласы Әр-Рияд

64 нче рәсем. Явада дөге кырын эшкәртү


63

64

Кайбер Азия илләренең этник һәм дини составы катлаулы булуы күп кенә **этникара һәм дини конфликтларга** китерә. Алар бигрәк тә Һиндстан, Пакистан, Шри-Ланка, Әфганстан, Филиппинда көчле. Мондый конфликтларның күпчелеге тамырлары белән колониаль һәм ярымколониаль заманнарга барып тоташа, гадәттә, алар сепаратизм лозунглары астында үтә.

**Мисал.** Көрдләр — 20 млн лы халык. Ләкин тарихи шулай килеп чыккан, алар Төркия, Иран, Гыйрак һәм Сүриядә таралып яшиләр. Инде менә шактый озак вакытлар буена көрд милли хәрәкәте җитәкчеләре бәйсез Көрдстан дәүләтен оештырырга (шул исәптән кораллы юл белән дә) омтылалар.

Регион **халык** бик тигезсез **урнашуы** белән дә аерылып тора. Бирeдә бер полюста — халык тыгыз урнашкан диңгез буе тигезлекләре, үзәнлекләр һәм елга тамаклары, икенчесендә — кеше аз яши торган чүлләр һәм ярымчүлләр, биек таулар, тропик урманнар.

**Мисал.** Бангладеш мәйданы буенча дөньядагы илләр арасында — 87 нче, ә халык саны буенча 7 нче урында тора. Үзәнлектә урнашкан бу илдә халыкның тыгызлыгы инде 1 $км^2$ га 1000 кешегә җитте, аерым районнарда 1 $км^2$ га 2000 кешегә җитә! Ә дөньяда халкы иң сирәк урнашкан илләрнең берсе саналган, ә мәйданы буенча Франциядән өч тапкыр зуррак булган Монголиядә 2 $км^2$ га уртача 3 кеше туры килә.

Халыкның регионда урнашуына аның **халыкара миграциясе** билгеле бер йогынты ясый. Бу бигрәк тә Фарсы култыгындагы нефть чыгаручы илләргә карый, алар, инде белүегезчә, хезмәт ресурсларын үзенә җәлеп итүнең иң төп дөнья үзәкләренә әверелделәр. Көньяк һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиядән, шулай ук Төньяк Африкадан күченеп килүчеләрнең гомуми саны биредә 10 млн нан артык кеше тәшкил итә. Аларның яртысы диярлек бу илләрнең иң зурысы Согуд Гарәбстанында үзенә эш таба, 1 млн га якыны Кувейтта эшли. [8].

Эш эзләп килүчеләрнең төп эшчәнлек сфералары — нефть промышленносте, төзелеш, транспорт, хезмәт күрсәтү сфералары. Согуд Гарәбстанында, Кувейтта алар барлык эшләүчеләрнең 60 % ын, ә Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә хәтта 90 % ын тәшкил итәләр. [9].

Әмма Азия чит илләреннән башка регионнарга да эмиграция шактый урын алып тора. Болар легаль һәм легаль булмаган рәвештә Европага китүче көрдләр, һәм «акыл агуы», мәсәлән Һиндстаннан, Филиппиннан.

*Ләкин халыкның урнашуына төп йогынтыны* «шәһәрләр шартлавы» рәвешен алган *урбанизация ясый.* Шәһәр халкының өлеше буенча регионд агы илләрнең күпчелеге уртача урбанизацияләнгәннәр рәтенә керүгә карамастан, халык саны бик күп булганда, абсолют күрсәткечләр шулай ук бик югары булып чыга.

**Мисал.** Бөтен дөньядагы 3,15 млрд шәһәр халкының 1,5 млрд ы Азия чит илләрендә яши. Кытай һәм Һиндстан шәһәр халкының саны буенча беренче һәм икенче урыннарны алып тора. Дөньядагы 21 «иң

зур шәһәр»нең 12 се Азия чит илләрендә урнашкан.

Тарихи-мәдәни һәм табигый шартлары ягыннан гаять күп төрле булган Азия шәһәрләре (алар күп очракта дөньядагы иң борынгы шәһәрләр булып чыга) шулай ук күптөрлелекләре белән аерылып торалар. Тышкы күренештәге үзенчәлекле сыйфатлар Көньяк-Көнбатыш Азиянең гарәп шәһәрләренә, Һиндстан, Кытай, Япония шәһәрләренә хас. Шулай да географик әдәбиятта **шәрык (Азия) шәһәренең** җыелма образы барлыкка килде.

Гадәттә, бу шәһәр өчен иске һәм яңа өлешкә бүленү хас. Иске шәһәрдә иң җанлы урын — базар. Аңа сәүдә урамнары һәм үз товарларын шунда ук сатып торучы һөнәрчеләр яши торган кварталлар килеп тоташкан (60 нчы рәсемне карагыз). Ачык һавада чәчтарашлар, күчереп язучылар эшли, әйбер ташучылар мәш килә. Шәһәрнең яңа өлешендә заманча төзелгән күп катлы йортлар өстенлек итә.

Регионда авыл халкы урнашуга авыл формасы күбрәк хас. Монголларда, әфганнарда, бедуин («баду»—чүл дигән сүздән) гарәпләрендә һәм башка күчмә халыкларда торак булып башлыча җыелма тирмә яисә чатыр хезмәт итә.

Азия чит илләренең социаль-икътисади үсеш перспективалары күп яктан аның урбанизациясе һәм шәһәрләре үсү белән бәйләнгән. (5 нче бирем.)

**4. Дөнья хуҗалыгында үсә баручы роле: икътисади куәтнең биш үзәге.** Инде белгәнегезчә, дөнья хуҗалыгындагы ун буыннан торган структурасыннан чыгып эш иткәндә, аның биш үзәге Азия чит илләрендә булып чыга. Алар арасындагы өчесе аерым илләр — Кытай, Япония һәм Һиндстан һәм ике илләр төркеме — яңа индустриаль һәм нефть экспортлаучылар.

1949 елда халык республикасы дип игълан ителгәннән соң, **Кытай** үзенең социаль-икътисади үсешендә күтәрелешләрне дә, аска тәгәрәүләрне дә бер генә мәртәбә кичермәде. Ләкин 70 нче еллар ахырында илдә — башта авылда, аннары шәһәрдә — планлы һәм базар хуҗалыгын бергә алып баруга нигезләнгән радикаль икътисади реформаны («Гайгэ») тормышка ашыру башланды. Ул икътисадның шундый көчле күтәрелешенә китерде ки, инде 1990 елда ук тулай эчке продукт (ТЭП) күләме буенча Кытай АКШтан һәм Японияләән кала дөньяда өченче урынга чыкты, ә берничә елдан, Японияне дә узып китеп, бөтендөнья икътисади рейтингында икенче урынны яулады. Тулай промышленность продукциясе күрсәткече буенча ул 2006 елда Японияне узып китте.

Гәрчә Кытай әлегә үсешнең индустриаль стадиясендә булса да һәм җан башына туры килә торган икътисади күрсәткечләр буенча Төньяк илләреннән генә түгел, күп кенә Көньяк илләреннән дә калышуына карамастан, *аның шаккатыргыч социаль-икътисади казанышлары күп яктан бөтен Азия-Тын океан регионы прогрессын билгели.* 2020 елга аның ТЭПы 4 тапкыр артырга тиеш.

Икенче бөтендөнья сугышында җиңелгән Япония аннан икътисады җимерелгән хәлдә чыга. Ләкин шуннан соң ул, үз хуҗалыгын аякка бастырып кына калмыйча, аны тамырыннан ук үзгәртеп корып, «зур җиделек»нең Азиядәге бердәнбер әгъзасы булып, дөньяда «2нче номерлы держава»га әверелде. Күп кенә мөһим икътисади күрсәткечләр буенча ул дөнья хуҗалыгында алдынгы позицияләргә чыкты (59нчы рәсемне карагыз). Ләкин Япониянең «икътисади могҗизасы» акрынлап бетә барды, һәм илнең социаль-икътисади үсеш темплары сүлпәнләнде. Ә 90нчы еллар ахырында Көньяк-Көнчыгыш Азиядә туган финанс (валюта) кризисы аның икътисадына нык тискәре йогынты ясады.

Үсеп килүче мөһим илләрнең берсе булган Һиндстан да дөнья икътисадында зур роль уйный. 90нчы елларда базар хуҗалыгын үстерүгә юнәлтелгән икътисади реформа башланганнан соң аның үсеше тизләште. Хәзерге Һиндстан промышленность җитештерүе күләме буенча Кытай һәм «зур җиде» илдән соң дөньяда 9нчы урында тора. Соңгы вакытта ул дөньяда иң эре информацион технологияләр үзәгенә әверелде. Ләкин җан башына туры килгән күрсәткечләр буенча ул әле һаман да дөньядагы илләрнең күпчелегеннән бик нык артка кала.

Азиянең яңа индустриаль илләр төркеме, инде белүегезчә, ике «эшелон»нан гыйбарәт. Аларның беренчесенә Корея Республикасын, Сингапур, Тайвань һәм Сянганны кертү кабул ителгән иде, икътисади сикерешне бик тиз ясау сәбәпле, аларны дүрт «азия юлбарысы» (яки «аждаһалары») дип атап йөртә башладылар. Аннары алар үрнәгенә тагын өч ил — Азиянең яңа индустриаль илләренең «икенче эшелон»ы илләре — Малайзия, Таиланд һәм Индонезия — АСЕАН әгъзалары иярде.

70—80нче елларда бу илләрнең икътисады япон моделе буенча үзгәртеп корылды. Аларда автомобиль төзү, нефть эшкәртү, нефть химиясе, суднолар ясау һәм бигрәк тә электротехника һәм электрониканың эре промышленность үзәкләре барлыкка килде; ел саен бирелә дистәләгән миллион радиоалгыч, телевизор, магнитофон, видеомагнитофон чыгаралар. Бүтән төрле киң кулланыла торган продукция — кием-салым, тукыма, аяк киеме эшләп чыгару да тиз үсә. Бу илләрнең «икътисади могҗиза»сы, җирле эшмәкәрләрнең активлыгы белән бергә, ТНКның иң элек икътисади-географик урыннары отышлы булуга һәм чиктән тыш чыдам, тәртипле һәм шул ук вакытта чагыштырмача арзан эшче көч булуына йөз тотып, аларны үз капиталларын салуның мөһим сферасы сыйфатында сайлап алулары белән аңлатыла. Әмма фәнсыешлы продукциянең барысы да диярлек, шулай ук башка продукция дә Көнбатыш илләре базарларында сату өчен билгеләнгән.

**1нче мисал.** Әле XX гасыр урталарында гына аграр ил булган Корея Республикасы XXI гасыр башына дөньяда диңгез суднолары һәм телевизорлар җитештерү буенча — икенче, пластмасса һәм синтетик сүсләр

житештерүдә — 4 нче, автомобильләр чыгаруда — 5 нче, корыч кою һәм АЭСларда электроэнергия житештерү буенча 6 нчы урынга чыкты.

**2 нче мисал.** Сингапур шәһәр-дәүләте (санскриттан тәрҗемә иткәндә — «арыслан шәһәре») күптәннән инде дөньяда иң зурлардан булган диңгез порты белән танылды, ул — Көнчыгыш өчен Көнбатыш капкасы, ә Көнбатыш өчен Көнчыгыш капкасы булып хезмәт итә, диләр. [10]. Ләкин соңгы вакытта ул сәүдә үзәгеннән индустриаль үзәккә әверелде (нефть эшкәртү, судноლар төзү, электроника һәм электротехника, җиңел промышленность). Ул шулай ук дөньяда иң зур финанс эшчәнлеге үзәге, мөһим туризм объекты булып китте.

Фарсы култыгындагы **нефть экспортлаучы** илләр дөнья икътисадында шулай ук мөһим урын алып торалар. Нефть сатудан алынган гаять зур керемнәргә таянып, бу илләр аз гына вакыт эчендә «гасырлар аша сикереш» ясадылар, шуның аркасында Фарсы култыгы зонасы нефть һәм табигый газ чыгару, нефть химиясе, металлургия һәм башка тармаклары булган иң мөһим промышленность районнарының берсенә әверелде. Урта гасырлардан калган балчык өйләрдән торган шәһәрләр урынында заманча промышленность үзәкләре барлыкка килде. ЭВМ белән көйләнә торган тамчылап сугару киң кулланыла. Мәктәп балаларын кечкенәдән компьютерлар белән эшләргә өйрәтәләр.

**Мисал.** Согуд Гарәбстаны озак вакытлар буена дөяләр үрчетүдән, хөрмә агачлары үстерүдән, хаж кылырга килгән мөселманнарга хезмәт күрсәтүдән алынган керемнәргә яшәде. Хәзер исә аның икътисадының нигезе — нефть чыгару, экспорт акчасының 3/4 ен нефть бирә. Гарәп чүлендә иң заманча автомобиль юллары, аэропортлар, Әл-Җүбәйл һәм Янбу эре промышленность комплекслары, бар уңайлыклары булган шәһәрләр төзелгән. [11]. (6 нчы бирем.)

Азия чит илләренең калганнары арасында икътисади үсеш дәрәҗәсе ягыннан Төркия, Иран, Пакистан, Израиль, КХДР аерылып тора. Ләкин регионда бик аз үсеш алганнар рәтенә керүче илләр дә бар. Көньяк-Көнбатыш Азиядә бу — Йәмән һәм Әфганстан, Көньякта — Бангладеш, Мальдив, Непал һәм Бутан, Көньяк-Көнчыгышта — Мьянма, Лаос һәм Камбоджа.

**5. Авыл хуҗалыгы: төрлечә специальләшкән районнар.** Азия чит илләренең күпчелегендә икътисади актив халыкның төп өлеше авыл хуҗалыгында эшли. Әлбәттә, бу тармак барлык регион өчен хас булган кайбер сыйфатлар белән аерылып тора. Аларга бер үк вакытта товарлыклы һәм кулланучы хуҗалыклар, җирбиләүче алпавытлар һәм җирдән файдаланучы крестьяннар булу, чәчүлекләрдә азык-төлек культураларының өстенлек итүе керә. *Уртаклык шунда: күп илләрдә азык-төлек проблемасы әле хәл ителмәгән.* Беренче чиратта бу Көньяк һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия илләренә кагыла, анда уннарча миллион кеше ачлы-туклы яши.

Шулай да, аңлавыгызча, мондый гаять зур территориядә авыл хуҗалыгы районнары бик күптөрле.

Аларның иң мөһиме — Көнчыгыш, Көньяк-Көнчыгыш һәм Көньяк Азиянең бөтен муссон секторын эченә алган дөге чәчү районы. Ел саен елгаларның ташу сулары белән ашлана торган елга тамаклары һәм Янцзы, Сицзян, Хонгх, Меконг, Иравади, Ганг һәм Брахмапутра үзәнлекләре, Ява утравы (64 нче рәсемне карагыз), Япония түбәнлекләре типик «дөге ландшафтлары»н тәшкил итәләр. Инде меңнәрчә еллар буена дөге бик зур хезмәт сорый торган хуҗалыкны алып баручы йөзләгән миллион кешенең тамагын туйдыра: язгы чәчү артыннан көзгесе, аның артыннан кышкысы килә. [12]. Дөге су баса торган кырларда гына түгел, крестьянның уч төбендә дә үсә, дип тикмәгә генә әйтмиләр. Ә дельта районнарын үзләрен, образлы итеп, дөге савытлары яисә дөге кәрзиннәре дип йөртәләр.

**Мисал.** Вьетнамның төп дөге үстерү җирләре — Хонгх һәм Меконг елгалары тамагының ландшафты турыпочмаклы дөге кырларыннан, плотиналар, дамбалар һәм сугару каналларыннан гыйбарәт. Биредә дөге уңышын елга ике тапкыр — май һәм ноябрь айларында җыеп алалар.

Бу районның югарырак урнашкан өлешенә Кытай, Япония, Һиндстан, Шри-Ланканың «чәй ландшафтлары» хас. [13].

Көтүлек җирләр һәм азык җитәрлек булмаганга, товарлыклы терлекчелек аз таралган, крестьяннар, нигездә, җигелә торган хайван асрыйлар.

Субтропик игенчелек районы Урта диңгез буенда барлыкка килгән.

Регионның калган территориясендә бодай, тары кебек культуралар үстерү, көтүлекле терлекчелек өстенлек итә. Мөгезле эре терлек, сарык, кәҗә, ат, дөя асрыйлар, каракүл, йон, ит продуктлары һәм күн саталар.

Экстенсив ысулларга нигезләнгән терлекчелек әле һаман Монголиянең «визит карточкасы» булып тора. Көньяк-Көнбатыш Азиядә көтүлекле терлекчелек оазислардагы игенчелек белән бергә алып барыла.

**6. Мохитне саклау һәм экологик проблемалар: үзгәртеп коруларның башлануы.** *Кеше эшчәнлегенең мохиткә тискәре йогынтысы Азия чит илләрендә артканнан-арта бара.* Күпчелек илләрдә атмосфера пычрана, су запаслары бетә, туфрак эрозиясе көчәя, җирләр кулланыштан чыга. Моның сәбәбе — кайбер «пычрак» производстволарның үсеше, файдалы казылмаларны ачык ысул белән чыгару, игенчелек һәм терлек асрауны экстенсив юл белән алып бару, шәһәрләрдә заманча коммуналь хуҗалыклар булмау. Һәлакәтле су басулар бигрәк тә Бангладешта һәм Кытайда һаман ешрак була бара. [14]. Зур масштабларда урманнар бетә, шул исәптән Һималай тау итәкләрендә дә. «Урманнар Һиндстанда каты чирлиләр, ә Непалда үлеп баралар» диләр. Япониядә, Кытай һәм Һиндстанда кислоталы явым-төшемнәр ешрак кабатлана.

Табигатьне саклау чараларына Япониядә, Кытай, Сингапур, Фарсы култыгы дәүләтләре, Израильдә зур игътибар бирелә башлады. Ләкин болар җимергеч бәла-казаларны кисәтә алмый. [15].

## 2. КЫТАЙНЫ ӨЙРӘНӘБЕЗ

**1. Территориясе, чикләре, урыны: масштаблыгы һәм составы турында күзаллама.** Кытай Халык Республикасы территориясенең зурлыгы ягыннан дөньяда өченче урында тора. Көнбатыштан көнчыгышка таба ул — 5,7 мең км га, төньяктан көньякка таба 3,7 мең км га сузылган. Кытай коры җир чикләренең озынлыгы буенча (22 мең км) дөньяда беренче урында тора. Ләкин алар күбесенчә үтеп булмый торган табигый чикләр буйлап үткәнлектән, тышкы икътисади элемтәләр өчен башлыча Сары диңгезгә, Көнчыгыш Кытай һәм Көньяк Кытай диңгезләренә чыгу юллары файдаланыла. Эчкәреге районнар диңгезгә Янцзы елгасы буйлап чыгалар.

Административ-территориаль яктан Кытай, Тайваньны да кертеп, халык саны Европа чит илләренең иң эреләрендәге халык санын күпкә артып киткән 23 провинциягә [16], автономияле биш районга һәм үзәккә буйсынучы дүрт шәһәргә: Шанхай, Пекин, Тянцзинь һәм Чунцинга бүленә.

1949 елда Кытайда халык революциясе җиңеп, КХР игълан ителгәннән соң бәреп төшерелгән Гоминьдан режимы калдыклары Тайвань утравына кача. Утрау «Кытай Республикасы» дип игълан ителә. Фактта ул — бәйсез ил. Ләкин Кытай аны үз провинцияләренең берсе дип саный һәм Тайваньның КХР белән тыныч берләшүе курсын үткәрә.

1997 елда, 99 ел буена арендада торганнан соң, Бөекбритания Кытайга үзенең Азиядәге соңгы биләмәсен — зур булмаган, ләкин сәяси, икътисади-сәүдә һәм финанс ягыннан бик мөһим булган Гонконг территориясен кире кайтарып бирде. Сянган (кытайлар Гонконгны шулай дип йөртәләр) КХР составындагы Махсус административ район дип игълан ителде һәм 50 ел буена үзенең гадәттән тыш шул статусын саклаячак.

1999 ел ахырында Кытай суверенитетына шулай ук Аомынь — илнең көньягындагы тагын бер кечкенә генә территория, элеккеге Португалия колониаль империясенең соңгы кисәге дә күчте. (7 нче бирем.)

**2. Халкы: саны, яңарып торуы, этник составы, урнашуы.** *Инде менә ике мең ел буена Кытай Җир шарында халык саны иң күп булган ил булып кала.* Кытай әйтемнәренең берсендә тикмәгә генә «Жэнь шань, жэнь хай» диелми, ә бу «Кеше таулары, кеше диңгезе» дигәнне белдерә.

1949 елда, КХР оешканнан соң, Кытай халкының саны ике мәртәбә артты, һәм 2000 елдагы халык санын алу мәгълүматларына караганда, 1 млрд 284 млн кеше булды. (Тайваньны кертеп), ә 2006 елда 1,3 млрд тан артып китте. Әгәр дә, сез инде белгәнчә, катгый демографик сәясәт үткәрелмәсә, бу сан тагын да зур булыр иде. Шул сәясәт нәтиҗәсендә Кытай кыска гына вакыт эчендә демографик күчешнең өченче фазасына кереп халыкның яңарып торуының икенче тибыннан беренче тибына күчте. Ә шулай да

«кеше диңгезе» *Кытай җәмгыяте тормышының барлык якларында да үзенең эзен калдыра.*

Кытайда 700 млн нан артык хезмәткә яраклы кеше яши, шуның 2/5 өлешеннән артыграгын яшьләр тәшкил итә.

Этник составы ягыннан Кытай халкының иң зур күпчелеге — кытайлар (алар үзләрен «хань», яисә «ханьлылар» дип йөртәләр). Алар илнең бөтен көнчыгышын биләп алганнар.

Кытай телендә җиде төп диалект — пекин, кантон һ.б. диалектлары бар, алар арасында аерма шулкадәр зур ки, сөйләшкәндә төньяк һәм көньяк провинция кешеләре бер-берсен бик авырлык белән генә аңлыйлар. Аңлашу өчен алар бердәм иероглиф язуыннан файдаланалар, аны төрле диалектларда сөйләшкән кытайлылар да белә. [17]. Моннан тыш, халык хакимияте елларында бердәм милли тел «путунхуа» эшләнә («гомуманлаешлы тел»), аның нигезенә пекин диалекты салынган. Әмма илдә укый-яза белмәүчеләр әле 180 млн нан артык исәпләнә.

Кытай халкы арасында милли азчылык чагыштырмача зур булмаса да (8 %), бу илне, гадәттә, күп милләтле илләр рәтенә кертәләр. Беренчедән, бу — кытай булмаган халыкларның һәм этник төркемнәрнең саны 60 ка якынлашканлыктан һәм өстәвенә алар өч төрле тел семьясына кергәнлектән шулай йөртелә. Икенчедән, аларның гомуми саны 100 млн нан артып китә. Өченчедән, алар илнең яртысыннан артыграк территориясен алып торалар.

Региондагы башка илләрдәге кебек үк, Кытай өчен дә халык урнашуына контрастлылык хас: халыкның 90 % ы диярлек илнең 1/3 енә урнашкан. Кытайны әле күптән түгел генә урбанизация дәрәҗәсе түбән илләр рәтенә кертәләр иде. Ләкин «шәһәрләр шартлавы» аңа да кагылды. Бүген исә кечерәк шәһәрләр, зур шәһәрләр (500) һәм миллионер шәһәрләр саны (50), шулай ук шәһәр халкының гомуми саны (515 млн) буенча Кытай дөньяда беренче урында тора. [18]. Шулай ук авыллар саны буенча да Кытай дөнья беренчелеген тота, биредә алар 700 меңләп! (8 нче бирем.)

Кытай — борынгы мәдәният иле. Кытай халкының матди мәдәният истәлекләре булып атаклы бакча-парк ансамбльләре, будда храмнары һәм пагодалары, 4 мең км чамасы озынлыгындагы Бөек Кытай стенасы кебек уникаль корылмалар санала. Безнең көннәргә хәтле сакланып калган рухи мәдәният традицияләре — үзенчәлекле кытай театры, рәсем сәнгате, музыкасы, кухнясы, ушу гимнастикасы, ай календаре. Кытай мәктәбендә укучыларның җаваплары еш кына 100 баллы шкала буенча бәяләнә. Кытай философиясе, астрономиясе, медицинасы бик борынгы заманнардан ук яшәп килә.




65

65 нче рәсем. Кытайның административ-территориаль бүленеше һәм икътисади зоналары

66 нчы рәсем. Пекинда Тяньаньмэнь мәйданы

66

**3. Хуҗалыгы: казанышлары һәм проблемалары.** *Хәзерге Кытай — дөнья хуҗалыгында мөһим позицияләр тоткан куәтле индустриаль-аграр ил.* Инде белүегезчә, бүген ул икътисади куәте буенча дөнья хуҗалыгының өченче үзәген хасил итә. Кытай промышленность һәм авыл хуҗалыгы продуктларының 26 төрен җитештерү буенча дөньяда беренче урынны алып тора. [19]. Биредә иске, традицион тармаклар белән беррәттән, электроника, аэрокосмик һәм башка фәнсыешлы тармаклар шактый үсеш алдылар. Кытай 2003 елның октябрендә бортында кеше булган беренче космик корабль җибәрүне гамәлгә ашырды. Ләкин күп кенә предприятиеләрдә җиһазларның нык искергән булуы, авылларның яртысында диярлек электр энергиясенең булмавы, авыл хуҗалыгында кул хезмәтенең өстенлек итүе белән исәпләшми булмый. (9 нчы бирем.)

Кытайның хәзерге йөзен күбесенчә илдә булган ресурсларга таянучы авыр промышленность билгели.

Кытайның ягулык-энергетика комплексының нигезен күмер промышленносте тәшкил итә. Күмер чыгару күп бассейннарга таралган; аларның иң зурысы Датун илнең төньяк өлешендә урнашкан. Нефть тә төрле урында чыгарыла, әмма аның иң күп чыга торган урыны Дацин, биредә нефтьнең 1/3 өлеше чыга. Диңгезләрнең континенталь шельфларындагы нефть ресурсларын үзләштерү башланды. Электр энергиясе җитештерүнең 4/5 е шулай ук бөтен территория буйлап таралган ҖЭСларга туры килә. Кытайда гидроэнергетика үсешенең иң зур программаларыннан берсе тормышка ашырыла; ГЭСның төп каскадлары Янцзы елгасының югары һәм урта агымында (шул исәптән дөньяда иң эре Санься ГЭСы) һәм Хуанхэ елгасында төзелә. Беренче АЭСлар инде корылган. Илдә традицион булмаган энергия төрләрен — геотермаль, су күтәрелеше энергияләрен файдалану башланды. Соңгы вакытта Кытай чит илләргә нефть һәм сыегайтылган газ чыгаруны арттырды. Көнчыгыш Себердән Дацинга магистраль нефть үткәргеч төзү проекты тормышка ашырыла.

Металлургия комплексының нигезен, инде күз алдына китергәнегезчә, ташкүмер һәм тимер рудасы чыккан урыннарга яисә аларны читтән китерелгән урыннарга йөз тоткан тулы цикллы зур комбинатлар тәшкил итә.

**Мисал.** Кытайның төньяк-көнчыгышындагы иң зур Аньшан металлургия комбинаты кокслана торган җирле күмер һәм тимер рудасын файдалана. Биредә елына 7—8 млн т корыч коялар, ә эшләүчеләр саны 150 мең кешегә җитә.

Машина төзү комплексында, специальләшкән предприятиеләргә караганда, универсаль предприятиеләр күбрәк. Алар барыннан да бигрәк зур шәһәрләрдә, диңгез портларында, металлургия базаларында урнашканнар. Әмма машина төзү акрынлап кечерәк шәһәрләргә дә үтеп керә башлады. Моңа көн-күреш электротехникасының һәм электроникасының, ә соңгы вакытта һәм автомобиль төзүнең үсеше ярдәм итә.

**Мисал.** Әле чагыштырмача күптән түгел Кытайда телевизорлар һәм кер юу машиналары шәһәр кешесе өчен дә сирәк очрый торган әйбер иде, ә 80 нче еллар ахырына аларны җитештерү буенча Кытай дөньяда беренче урынга чыкты.

Химия комплексы кокс һәм нефть химиясе продуктларына, тау химиясе һәм үсемлек чималына таянып эшли. Ике төрле җитештерү аерылып тора: 1) минераль ашламалар (барыннан да бигрәк азотлы ашламалар) җитештерү, 2) көнкүреш химиясе һәм фармацевтика. Бу комплексның урнашуы өчен зур комбинатларның бик күп вак һәм уртача зурлыктагы предприятиеләр белән бергә кушылуы хас.

Туку промышленносте — Кытай җиңел промышленностенең төп тармагы. Ул башлыча эчке базарга эшли; киҗе-мамык тукымадан тегелгән киемнәрне (аларны җитештерү буенча Кытай дөньяда беренче урында тора) халыкның күпчелеге киеп йөри («Кушымта»дагы 28 нче таблицаны карагыз). Традицион тармакларга шулай ук ефәк промышленносте дә керә. (10 нчы бирем.)

Кытай икътисадында **авыл хуҗалыгы** бик зур роль уйный, анда 450 млн нан артык кеше эшли.

80 нче елларда «халык коммуналары»ннан гаилә подряды системасына күчкәннән соң, бу тармак керемлерәк булып китә; төп культураларның уңышы арта. 90 нчы елларның икенче яртысыннан башлап бөртеклеләрне җыеп алу рекордлы дәрәҗәдә тора — елына 400—450 млн тонна иген җыеп алына («Кушымта»дагы 29 нчы таблицаны карагыз).

Төп игенчелек районнары илнең көнчыгыш өлешендә урнашкан. Монысы — «сары Кытай», анда күбрәк бодай, гаолян, кукуруз үстерелә, «яшел Кытай»да исә күбрәк дөге игелә; чәй плантацияләре дә шунда ук урнашкан.

**1 нче мисал.** Янцзы бассейнында, Сицзян елга тамагында үстерелә торган дөге — халыкның төп икмәге. [20]. Дөгенең тәме төрле булган меңнәрчә сортлары билгеле. Дөге саламын терлекләргә һәм кош-кортка ашаталар, кәгазь, эшләпә, чыпта, сумкалар ясау һәм бау ишү өчен файдаланалар. Дөге басуларындагы суда балык үрчетәләр.

**2 нче мисал.** Диңгез буеның калкулыклы урыннарында игелә торган чәй — шулай ук илдә традицион культура. Кытай — чәйнең ватаны, һәм XIX гасыр ахырына кадәр ул дөньяны чәй белән тәэмин итеп торучы бердәнбер зур ил була. Әле хәзер дә ул күк чәйне читкә чыгару буенча монополист булып тора. Кытай крестьяннары чәйнең күп дистәләгән сортларын китереп чыгардылар.

Төньяк-көнбатышта, нигездә, кытай булмаган халыклар (монголлар, тибетлылар, уйгурлар һ. б.) яшәгән «коры Кытай»да, хуҗалык итүнең төп төре — экстенсив күчмә терлекчелек, ара-тирә утрак

тормышлы игенчелек белән шөгыльләнгән урыннар да очрый. Ә көньяк-көнбатышта, «салкын Кытай»да (Тибет) авыл хуҗалыгы гомумән начар үсеш алган. (11 нче бирем.)

Кытай авылына хас сыйфат — кооператив «авыл» промышленностенең үсеше, анда 140 млн кеше эшли; ул ирекле эшче кулларга эш бирә. Аквакультура да киң үсеш алган. Кытай балык, диңгез моллюсклары һәм суүсемнәр үрчетү буенча дөньяда беренче урында тора. Гомумән, кытайлыларның тормышы, иң борынгы заманнардан алып, диңгез белән бәйләнгән. Кытайда күп миллионлаган «диңгез хезмәтчәннәре» исәпләнә.

Мәйданы һәм халык саны ягыннан Кытай кебек шундый зур илдә транспортның роле аеруча зур. Илдә коры җир һәм су транспортының барлык төрләре, шулай ук һава транспорты үсеш алган. Ләкин әле тимер юл транспортында йөкләрне паровоз белән ташу өстенлек итә, автомобильләштерү дәрәҗәсе түбән, һәм кытайлыларның күпчелек өлеше велосипедлардан файдалана. [21]. Илнең көнчыгыш провинцияләре, үзәк һәм көнбатыш провинцияләргә караганда, транспорт белән яхшырак тәэмин ителгән. Шуңа күрә заманча транспорт инфраструктурасы булдыру Кытай өчен иң мөһим мәсьәлә булып кала бирә.

Реформалар чорында Кытайда тышкы икътисади элементларнең әһәмияте шактый артты, аның икътисадының ачыклыгы көчәйде. Кытай башлыча әзер кием-салым, туку промышленносте һәм көнкүреш электроникасы әйберләрен, киң кулланыла торган башка товарларны, шулай ук ягулык һәм чималны читкә чыгара. Ә читтән кертелә торган товарлардан әзер әйберләр, бигрәк тә машиналар һәм җиһазлар өстенлек итә. Кытайның төп сәүдә партнерлары — Япония һәм АКШ. Бу илләрдән Кытайга турыдан-туры инвестицияләр дә җибәрелә. Россия белән товар әйләнеше әле күптән түгел генә бу илләрнең мөмкинлекләреннән калыша иде, әмма 2010 елда аны 60—80 млрд долларга җиткерү күздә тотыла. 2002 елда Кытай Бөтендөнья сәүдә оешмасына (БСО) кабул ителде.

**4. Эчке аерымлыклар һәм шәһәрләр.** Территориаль планлаштыруны камилләштерү максаты белән, 80 нче елларда Кытайда өч икътисади зона билгеләнде: Көнчыгыш, Үзәк һәм Көнбатыш зоналар.

Көнчыгыш (диңгез буе) зона — икътисади яктан иң алга киткәне. Биредә промышленность үзәкләренең һәм узелларының күбесе, күп кенә авыл хуҗалыгы районнары, транспорт магистральләре, барлык диңгез портлары урнашкан. Иң зур шәһәрләр дә шунда ук урнашкан.

Кытай шәһәрләренең иң зурысы — Шанхай. Ул Янцзының су баса торган тамагына коючы Хуанпу елгасы буена, диңгездән 50 км ераклыкта урнашкан (тәрҗе-

мәсе — «диңгез өстендәге»). Бу — дөньядагы иң зур портларның берсе һәм илнең 13 мең предприятиесе булган иң мөһим промышленность үзәге. Соңгы вакытта биредә КХРдагы иң заманча металлургия комбинаты, беренче АЭС төзелде, ирекле икътисади зона булдырылды. Элегрәк Шанхай иң күрексез һәм күп халыклы шәһәрләрнең берсе иде. Халык әле хәзер дә анда чамасыз күп, әмма шәһәр үзгәртеп корыла; анда күп кенә үтә биек йортлар калкып чыкты. Шанхай тирәсендә иярчен-шәһәрләр барлыкка килде.

Халык саны буенча Кытайда икенче шәһәр — **Пекин**. Ул Бөек Кытай тигезлегендә, диңгездән 170 км ераклыкта, илнең халык иң тыгыз утырган районнарының берсендә урнашкан. Төрлечә аталып ул берничә мәртәбә борынгы һәм урта гасырлардагы Кытай дәүләтләренең башкаласы булган, ә XV гасырдан алып хәзерге исемен йөртә (дөресрәге, Бейцзин, ягъни «төньяк башкала»). Шәһәрнең тарихи үзәк өлеше традицион туры сызыклы төзелешен саклап калган. Биредә күп кенә тарихи һәм мәдәни истәлекле урыннар бар.

Пекинның үзәк өлеше Эчке (Тыелган) шәһәрне үз эченә ала, анда элеккеге император сарайлары бар. Аларның исемнәре: Югары гармония палатасы, Тулы гармония палатасы, Гармонияне саклау палатасы. Биредә күп төрле башка корылмалар да сакланып калган, аларның бер өлеше музейга әйләндерелгән. Төп урам Чананьцзедан (Озакка сузылган тынычлык урамы) һәм үзәк мәйдан Тяньаньмэньнан (Күк тынычлыгы мәйданы) көньякка таба Тышкы шәһәр — промышленность, сәүдә-һөнәрчелек һәм торак кварталлары урнашкан. Тяньаньмэнь мәйданы — дөньядагы иң зур мәйдан; анда берьюлы 2 млн кеше сыя (66 нчы рәсемне карагыз). Эчке һәм Тышкы шәһәр бергә Иске Пекинны хасил итә. Ә аларның чикләреннән читтәрәк 1949 елдан соң Яңа Пекин үсеп чыкты.

1984 елда Кытай хөкүмәте турыдан-туры тышкы икътисади бәйләнешләр хокукы алган 14 диңгез буе шәһәрен тышкы дөнья өчен ачарга карар кыла. Шулай ук биш ирекле (махсус) икътисади зона да булдырыла.

**Мисал.** Шуларның иң зурысы — Шэньчжэнь ирекле икътисади зонасы — Сянган белән рәттән урнашкан. Соңгы ике дистә елдан артыграк вакыт эчендә биредә халкы 6—7 меңнән артмаган аулак бер шәһәр урынына күксөзәр йортлар, автострадалары, халыкара аэропорты, технологик парклы булган миллионер шәһәр үсеп чыкты. Шэньчжэньдә 1 мең төрле әйбер һәм товарлар җитештерәләр, әмма югары технология тармаклары өстенлек итә.

Үзәк зонада ягулык һәм энергия, химик продуктлар, чимал һәм ярымфабрикатлар, азык-төлек җитештерү өстенлек итә. Көнбатыш зонада терлекчелеккә, минераль чимал эшкәртүгә игътибар бирелә. (12 нче бирем.)

## 3. ЯПОНИЯНЕ ӨЙРӘНӘБЕЗ

**1. Территориясе, чикләре, урыны: Кояш чыгышы иле.** Территориясенең зурлыгы ягыннан Японияне Көнбатыш Европаның иң зур илләре һәм АКШ штатлары белән чагыштырырга мөмкин. Әмма составы һәм конфигурациясе ягыннан ул алардан бик нык аерылып тора. Япония — ил-архипелаг, ул 4 зур һәм 7 меңләп вак утрауларда урнашкан. Бу чыпчын утраулар дөньясы! Табигый ресурсларга чагыштырмача ярлы Япония үзенең диңгез ярлары белән бай. Яр сызыгының озынлыгы (30 мең км) ягыннан ул АКШ кебек зур илне узып китә һәм бөтен Африка белән чагыштырыла ала.

Япониянең икътисади-географик урыны иң әлек шуның белән үзенчәлекле, ул урнашкан утраулар дугасы Евразия материгы һәм Тын океан чиге буйлап 3,5 мең км га сузыла һәм Азия-Тын океан регионының үзәгендә тора. Бу хезмәтнең халыкара географик бүленешендә илнең катнашуы өчен бик зур мөмкинлекләр ача.

Япония Азиянең иң көнчыгышында урнашканлыктан, аны образлы итеп «Кояш чыгышы иле» дип атыйлар. [22]. (13 нче бирем.)

**2. Халкы: табигый яңарып торуның, милли составының, урнашуының үзенчәлекләре.** Инде белгәнегезчә, Япония халык саны ягыннан дөньядагы илләрнең «беренче унлыгы»н тәгәлли. Әмма соңгы унъеллыкларда халыкның табигый яңарып тору характеры кискен үзгәрде. *Япония, Азиядәге дәүләтләр арасында беренче булып, халкы яңарып торуның икенче тибыннан беренче тибына күчте.*

Бу «демографик революция» бик тә кыска вакыт эчендә булып узды. Ул япон җәмгыятендәге зур социаль-икътисади үзгәртеп коруларның, мәгариф һәм сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышларның нәтиҗәсе иде. Япония — сәламәт милләтле ил, балалар үлеме буенча иң түбән күрсәткеч японнарда. Гомернең уртача озынлыгы буенча иң зур күрсәткеч тә аларныкы («Кушымталар»дагы 15 нче таблицаны карагыз). Дәүләт үткәргән демографик сәясәт тә зур йогынты ясады. Гаилә кору нигезләре буенча дәресләр инде өлкән сыйныфларда ук үткәрелә. Соң өйләнешүләр пропагандалана. Әмма өлкән һәм карт яшьтәгеләрнең өлеше буенча да Япония дөньяда беренче урыннарга чыкты.

Япония халкының милли составы фәкать бертөрле генә. Бу — типик *бер милләтле дәүләт*, японнар илдәге халыкның 99 % ын тәшкил итә. Япон теле бик тә үзенчәлекле, ул тел семьялыкларының берсенә дә керми. Хәзерге япон язуы системасы да бик катлаулы, анда иероглифлар да, иҗекле алфавит та кулланыла.

Илдәге төп ике төрле дин — синтоизм һәм буддизм — феодализмның башлангыч чорында ук барлыкка килгән. Гадәттә, дингә ышанучылар аларның икесен берьюлы тоталар, бу диннәр, йогынты сфераларын үзара бүлешеп, бергә яшиләр. [23].

Япония — югары мәдәниятле һәм тулысы белән укый-яза белүчеләр иле. Анда бала тәрбияләүгә һәм укытуга кече яшьтән үк зур игътибар бирелә. Япониядә университетлар саны бөтен Көнбатыш Европадагыдан күбрәк диярлек. Бу ил — японча яшәү рәвешенең нигезен тәшкил итүче борынгы мәдәният, сәнгать һәм көнкүреш традицияләре иле.

Мондый традицияләргә икебана — чәчәк бәйләмнәре ясау һәм чәчәкләрне, агач ботакларын вазаларга урнаштыру сәнгате, бонсай — кәрлә агачлар үстерү, каллиграфия — пумала һәм тушь белән матур итеп язу, музыка, кәгазьгә һәм ефәккә рәсем төшерү, оригиналь храм һәм бакча-парклар архитектурасы, күләгәләр театры, чәй церемониясе, хатын-кыз киеме кимоно, авыр үлчәүдәгеләр көрәше сумо, дзюдо, карате, азыкны алып ашау өчен кулланыла торган таякчыклар, кухня үзенчәлекләре, табын бизәү үзенчәлекләре һәм күп кенә башка нәрсәләр керә. Иң мөһим традицияләргә өлкәннәрне хөрмәтләү, никахларны ата-аналар килешүе буенча теркәү (соңгы вакытларда компьютерлар да кулланыла), күп санлы ырымнарга ышану, медитация йоласы, төрле календарь системаларын файдалану, рәсми дәүләт бәйрәмнәренең (балалар көнен, балигъ булу көнен, көн һәм төн тигезлеге көннәрен дә кертеп), төрле-төрле фестивальләрнең күплеге дә керә (67 нче рәсемне карагыз). [24]. Тулаем боларның барысын да япон мәдәни феномены дип атау кабул ителгән.

Японнарда яшьтән үк балаларны тәрбияләүдә милли традицияләрнең берсе — табигатькә, агачларга, чәчәкләргә, хайваннарга сакчыл караш. Шуңа күрә Япониядә милли бәйрәмнәрнең берсе — язын кыргый чия (сакура) чәчәк аткан чагында, көзен, өрәңге урманнарының кызыл яфракларына соклану өчен, табигатькә чыгулар бик популяр. Шунысы гаҗәп: хәзер болар барысы заманча Көнбатыш модасы чагылышлары белән бергә үрелеп бара.

Халыкның уртача тыгызлыгы буенча (1 км$^2$ га 340 кеше), Япония — дөньяда беренче урыннарда. Әмма чынлыкта халыкның тыгызлыгы тагын да зуррак, чөнки илдәге барлык халык диярлек диңгез буе түбәнлекләрендә һәм елга үзәннәрендә тупланган.

Соңгы унъеллыкларда Япония урбанизациянең бик югары темпларда баруы белән аерылып торды. *Нәтиҗәдә урбанизация дәрәҗәсе буенча ул дөньяда беренче урыннарга чыкты (18 нче рәсемне карагыз).* Илдә зур шәһәрләрнең саны ике йөздән артык.

Япон шәһәре күп төрле үзенчәлекләргә ия. Шәһәрләрнең күпчелеге әле Урта гасырларда ук феодал замоклары, монастырьлар тирәсендә, почта юллары янында барлыкка килгәннәр. Алар үзләренең гомуми планлаштыру һәм традицион бер һәм ике катлы төзелешләрен әлегә хәтле саклап калганнар. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң күп кенә зур шәһәрләр «америкалаштырыла»: күп катлы йортлар барлыкка килә, аларда хәзер банклар, монополияләрнең штаб-

квартиралары урнашкан. Әмма, кагыйдә буларак, япон шәһәрләрендә бердәм эшлекле үзәк юк.

Хәзер халыкның төп өлеше нәкъ менә зур шәһәрләрдә һәм шәһәр агломерацияләрендә туплана. Иң зурлары Хонсю утравының көньяк диңгез яры буйлап тоташ чылбыр булып сузылган. Алар арасында Токио, Осака һәм Нагоя тирәсендә барлыкка килгән агломерацияләрнең «зур өчлеге» аерылып тора (68 нче рәсемне карагыз). Шулай да, Япония Токиодан башлана, дип юкка гына әйтмиләр.

Токио — дөньядагы иң зур шәһәрләрнең берсе, Япония утрауларындагы иң зур Канто тигезлегендә урнашкан. Ул 1869 елдан илнең башкаласы һәм шул чорда ук «Көнчыгыш башкаласы» мәгънәсендәге хәзерге исемен ала. Токио — дөньяда халык иң тыгыз урнашкан, өстәвенә чиктән тыш сибелеп, буталчык итеп төзелгән шәһәрләрнең берсе. [25]. Ул өскә таба да (антисейсмик фундаментка корылган 50—60 ар катлы йортлар), аска таба да (җир астындагы сәүдә үзәкләре), киңлеккә дә үсә, шул исәптән Токио бугазын корыту юлы белән дә.

Осака, Нагоя һәм кайбер бүтән агломерацияләр белән бергә, Токио агломерациясе тагын да зуррак урбанизацияләнгән «галактика»ны — диңгез яры буйлап 600—700 км га сузылган Токайдо ***мегалополисын***[1] барлыкка китерә. Анда халыкның тыгызлыгы 1 $км^2$ га 800—1000 кеше туры килә, ә гомуми саны 70 млн кешегә җитә, аны Франция һәм Бельгиянең гомуми халкы белән чагыштырырга була.

**3. Хуҗалыгы: XX гасырдан XXI гасырга.** 50 нче еллардан алып чирек гасыр буена диярлек япон икътисадына үсешнең бик югары темплары хас булды. *Кыска гына вакыт эчендә ил фән, техника, мәгариф, промышленность һәм сәүдә өлкәсендә бик югары казанышларга ирешеп, гаять зур юл үтә алды.* Япония дөньяда төп кредитор булып китте. Илдә инде бөтен икътисади тормышны сыйфат ягыннан шактый дәрәҗәдә үзгәртеп кору тормышка ашырылды, постиндустриаль җәмгыять нигезләре булдырылды.

Япониянең промышленносте башта эволюцион юл белән үсә. Читтән кертелгән чимал нигезендә энергетика, металлургия, автомобиль һәм судно төзү, химия, нефть химиясе, төзелеш промышленносте кебек төп тармаклар өр-яңадан булдырылды. Алар барысы да техника һәм технологиянең иң яңа казанышларын исәпкә алып формалаштырылды; бу вакытта күп кенә патентлар һәм лицензияләр чит илдән, бигрәк тә АКШ һәм ГФРдан сатып алынды һәм җирле шартларга яраклаштырылды.

Әгәр элек Япония символлары изге Фудзияма тавы, сакура, гейшалар, самурайлар булса, хәзер инде үсеш алган дөньядагы иң зур АЭС, металлургия комбинатлары [26], супертанкерлар, күперләр [27],

---

[1] Мегалополис (грек. *megalo* — зур һәм *polis* — шәһәр) — янәшә утырган күп санлы агломерацияләрнең кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән шәһәрләрнең иң зур формасы.

тоннельләр, тиз йөрешле тимер юллар, иң заманча «тойота», «хонда», «ниссан» автомобильләре санала.

70 нче еллар уртасындагы энергетика һәм чимал кризисыннан соң *промышленность үсешенең революцион юлы өстенлек ала башлады.* Ил энергиясыешлы һәм металлсыешлы, чит илдән кертелгән ягулык белән чималга бәйле булган производстволарның үсешен чикли, иң яңа фәнсыешлы тармакларга йөз тота. Ул электроника, роботлар техникасы, биотехнология өлкәсендә лидер булды, энергиянең традицион булмаган чыганакларын файдалануга керешә.

Фәнгә тоткан чыгымнар өлеше буенча Япония дөньяда беренче урында тора, ә фәнни хезмәткәрләр һәм инженерлар саны буенча ГФР һәм Франциядән (икесен бергә алганда) калышмый.

Хезмәт иясенең белем дәрәҗәсе, профессиональ квалификациясе югары булу, хезмәт сөючәнлеге, тәртипле булуы, техник яктан үзләрен даими рәвештә камилләштерүгә омтылулары Япония халкы сыйфатының бик югары булуын дәлилли. Кагыйдә буларак, япон эшчесенең профессиональ әзерлеге Америка эшчесенекенә караганда югарырак. Ә хезмәткә түләү җитештерелгән әйбернең күләменә генә түгел, сыйфатына да бәйле, бу исә хезмәт җитештерүчәнлеген даими рәвештә арттыруга китерә. Моннан тыш, япон эшчесе билгеле бер фирмага, гадәттә, «гомерлеккә» урнаша һәм эш урынын бик сирәк алыштыра. Бу аның рационализаторлык белән кызыксынуын арттыра, чөнки «үз» фирмасындагы эш стажы күбрәк булган саен, аның хезмәт хакы да, түләүле ялы да, пенсия пособиесе дә югарырак була.

Авыл хуҗалыгы да Икенче бөтендөнья сугышыннан соң тамырыннан үзгәртеп корылды. «Япониядә игенчелек үзенең интенсивлыгы белән шаккаттыра. Үзәк һәм Көньяк Япониядә файдаланылмаган бер генә карыш җир дә калмаган»,— дип соклана Н. И. Вавилов үзенең 1929 елда Японияга сәяхәтеннән соң язган «Биш континент» дигән китабында. Әлбәттә, хезмәтне күп сорый торган традицион хуҗалыклар әле дә саклана. Әмма 40 нчы еллар ахырында үткәрелгән аграр реформадан соң, алпавыт җирбиләүчелеге бетерелеп, крестьяннар җир хуҗаларына әйләнгәч, фермерлар төп җитештерүче була.

Авыл хуҗалыгының структурасы да үзгәрде. Япония һәрвакыт игенчелек иле булды. Японнарның төп икмәге булган дөге — бөртекле мөһим культура, эшкәртелә торган җирләрнең яртысын диярлек биләп торса да, анда бакчачылык, яшелчәчелек, бигрәк тә мөгезле эре терлек, дуңгыз, кош-корт үрчетү зур үсеш алды. Нәтиҗәдә японнарның туклану рационы европалылар һәм американлылар рационына охшашрак була башлады (әмма әле хәзер дә англияле бер айда ашаган итне япон кешесе бер ел ашый).

Япониянең авыл хуҗалыгында барысы 4 млн кеше эшләп, ә эшкәртелә торган җирләр территориянең нибары 14 % ын тәшкил

67

68

67 нче рәсем. Традицион япон фестивальләренең берсе

68 нче рәсем. Японияенең иң зур шәһәрләре һәм шәһәр агломерацияләре

69 нчы рәсем. Японияенең экспорты һәм импорты

69






70

71

72

73

70 нче рәсем. Япония хуҗалыгының территориаль структурасы

71 нче рәсем. Японияда балык аукционы

72 нче рәсем. «Синкансен» тимер юл магистрале

73 нче рәсем. Япония яр буенда диңгездән «яулап алынган» территория

итсә дә, алар илнең азык-төлеккә булган ихтыяҗының төп өлешен, шул исәптән дөге белән яшелчәләргә булган ихтыяҗны тулысынча тәэмин итәләр.

Япон хуҗалыгының тагын бер мөһим традицион тармагы — балыкчылык. Сез инде балык тоту буенча Япониянең дөньяда беренче урыннарда торуын беләсез. Илдә 3 меңнән артык балык тоту порты бар. Диңгез буе фаунасының гаять бай һәм төрле булуы балыкчылыкның гына түгел, марикультураның да үсүенә китерде. Балык һәм диңгез продуктлары японнарның азык рационында бик зур урын алып тора (71 нче рәсемне карагыз). [28]. Энҗе промыселы да нык үскән. [29].

Япониядә транспортның барлык төрләре дә (елга һәм торба үткәргечләрдән тыш) үсеш алган. Транспорт челтәренең характеры буенча бу ил Көнбатыш Европа илләрен хәтерләтә, әмма йөк ташу һәм бигрәк тә пассажирлар ташу күләме ягыннан ул аларның теләсә кайсын бик күпкә узып китә. [30]. Ә пассажирларны тимер юл буйлап йөртү дәрәҗәсе ягыннан ул дөньяда беренче урында тора. Япония иң зур һәм иң заманча диңгез сәүдә флотына да ия. Ул «арзанлы флаглар»ны да киң файдалана, тоннажның 3/4 өлешен диярлек шул флаглар астында ташый.

*Япония хуҗалыгының бик тә мөһим үзенчәлеге — аның халыкара икътисади элемтәләргә тулы бәйлелеге.* Илнең үз ягулыгы һәм чималы бик аз булганлыктан, ул аның 9/10 өлешен читтән кертергә мәҗбүр. Шуның белән бергә, илнең икътисады әзер әйберләрнең экспортына гадәттән тыш бәйле. Япония актив сәүдә балансына ия. Дөньяның күпчелек илләрендә япон фотоаппаратларын, видеомагнитофоннар, калькуляторлар, сәгатьләр, автомобильләр, мотоциклларын сатып алырга мөмкин. Япония — Азия-Тын океан регионындагы барлык илләрнең диярлек төп сәүдә партнеры. «Сәүдә итәргә яки үләргә»,— диләр япон бизнесменнары. Соңгы вакытта икътисадны үзгәртеп коруга бәйле рәвештә импортта ягулык һәм чимал өлеше сизелерлек кимеде, ә машиналар һәм җиһазлар өлеше артты. Ләкин соңгы вакытта Япония читкә товар чыгарудан капитал чыгаруга таба йөз тота бара. Япониянең турыдан-туры инвестицияләре башлыча Төньяк Америкага, Европага, Азиянең башка илләренә юнәлтелә. (14 нче бирем).

**4. Хуҗалыгының территориаль структурасы: ике «яклы» ил.** Япония өчен «алгы» һәм «арткы» (яки «көяшлы» һәм «күләгәле»)— бер-берсенә бөтенләй охшамаган ике өлештән тору бик тә характерлы.

Япониянең «кояшлы өлеше»н Тын океан поясы барлыкка китерә, ул диңгез буе, бигрәк тә Хонсю утравы түбәнлекләре буйлап, тар гына полоса булып (15—65 км) сузыла (70 нче рәсемне карагыз). *Бу пояс — илнең иң төп социаль-икътисади үзәге.* Биредә төп промышленность районнары — Токио, Осака, Нагоя, Китакюсю, ҖЭС һәм АЭСларның, металлургия, нефть эшкәртү һәм химия комбинатларының, машина төзү заводларының күпчелеге урнашкан. Алар, читтән кертелгән

чимал һәм ягулык белән эшләп, үз продукцияләрен башка илләргә чыгаралар. Төзелеш өчен урын бик кысан булу сәбәпле, күп кенә, шул исәптән иң зур предприятиеләр дә, бөтен яр буена сузылып, диңгездән «яулап алынган» җирләрдә урнашканнар.

Тын океан поясын, гадәттә, промышленность поясы дип йөртәләр, әмма бу дөреслеккә бик үк туры килеп бетми. Биредә интенсив авыл хуҗалыгының күп кенә мөһим районнары да, төп транспорт магистральләре дә, әһәмиятле портлар да урнашкан.

**Мисал.** Япониянең төп транспорт күчәрен бөтен Тын океан поясы буйлап үтүче тиз йөрешле «Синкансен» тимер юл магистрале тәшкил итә (72 нче рәсемне карагыз). [31]. (15 нче бирем.)

60—70 нче елларда халыкның чиктән тыш тыгыз урнашуы һәм «пычрак» производстволарның киң таралуы нәтиҗәсендә Тын океан поясы зонасында экологик хәл бик нык кискенләшә, аның төп промышленность районнарына һәм агломерацияләренә экологик кризис яный башлый. «Когай» — Япониядә мохитнең пычрануын шулай дип йөртәләр — биредә бик куркыныч күләмгә җитә. Дәүләт һәм җәмәгатьчелек күргән чаралар нәтиҗәсендә 80 нче елларда тирә-як мохитнең хәле шактый яхшырса да, экологик проблемалар тулысынча хәл ителүдән әле ерак тора.

Япониянең «күләгәле өлеше»н Хонсю утравының таулы-урманлы районнарын эченә алган периферия зонасы барлыкка китерә. Биредә агач әзерләү, терлекчелек, файдалы казылмалар чыгару, гидроэнергетика өстенлек алган. Әмма рекреация белән туризм аеруча нык үскән. Япон халкының хәрәкәтчәнлеге, «урын алыштыруга һәвәслеге» күп яктан нәкъ менә олыларның да, мәктәп балаларының да массакүләм туризмы белән бәйле.

**Мисал.** Хонсю утравының таулы өлешендәге милли парклар аеруча зур популярлык казанган: халык артык күп яшәгән Токайдо мегалополисы кешеләре үз ялларын шунда үткәрә. Японнарның хаҗ кыла торган урыннары — изге Фудзияма тавы, Никко паркы бигрәк тә данлыклы. «Никкога барып кайтмаган кеше гүзәллек турында сөйли дә алмый» дигән әйтем бар. Күптән түгел Никко паркы Бөтендөнья мирасы объектлары исемлегенә кертелде.

Соңгы вакытта Япониядә дәүләт тарафыннан үткәрелә торган региональ сәясәт экологик яктан чиста периферия зонасын үзләштерүгә бик нык ярдәм итә.

Тын океан поясын бераз бушату максаты белән, технополисларның — фән һәм фәнсыешлы производстволарның яңа үзәкләренең яртысы диярлек Хонсю утравының периферия зонасында төзелә.

Әле күптән түгел генә илнең тыныч почмагы булып саналган Хоккайдо утравын үзләштерүгә дөньяда иң озын Сейкан тимер юл тоннеле төзү ярдәм итәргә тиеш. [32]. Шулай да, тулаем алганда, территориаль тигезсезлекләр шактый акрын бетерелә. (16 нчы иҗади бирем.)

## 4. ҺИНДСТАННЫ «АЧАБЫЗ»

**1. Территориясе, чикләре, урыны: һинд субконтиненты. Дәүләт төзелеше.** Һиндстанның территориясе — нигезе материкка тоташкан һәм Азиянең калган өлешеннән Һималай таулар системасы белән аерылган өчпочмак рәвешендә. Территориясенең зурлыгы һәм азмы-күпме аерымланган булуы аны субконтинент дип атарга мөмкинлек бирә. Төньяктан көньякка таба ил 3,2 мең км га, ә көнбатыштан көнчыгышка 2,9 мең км га сузылган.

Һиндстанның икътисади-географик урыны хуҗалык итү өчен уңайлы. Беренче чиратта ул илнең Урта диңгездән Һинд океанына чыгучы диңгез сәүдә юлларында, Якын һәм Ерак Көнчыгышның арасында урнашканлыгы белән аңлатыла. Коры җир чикләре диңгезнекеннән 2,5 тапкырга озынрак, әмма аларның күп өлеше үтеп керү өчен бик кыен таулы урыннардан уза һәм шуңа күрә илнең икътисади тормышында роле зур түгел.

Һиндстан — дөньядагы иң борынгы дәүләтләрнең берсе. Ул ике гасырга якын Англия колониясе була. 1947 елда бәйсезлек алуга ирешеп, 1950 елда үзен республика дип игълан итә. Һиндстанның дәүләт төзелеше — федератив республика. Ул 28 штаттан тора (аларның өчесе 2000 елда барлыкка килә), һәм мәйданы, һәм халкы буенча алар бик нык аерыла. [33]. Һәр штатның законнар чыгаручы үз җыелышы һәм хөкүмәте бар, әмма көчле үзәк хакимият сакланып калган. Һиндстан ***Бөекбритания җитәкчелегендәге Бердәмлек***[1] составына керә.

**2. Халкы: яңарып торуы, этник составы, урнашу үзенчәлекләре.** Халык саны буенча Һиндстан — Кытайдан кала дөньяда икенче ил. Халык санын алу биредә, 1891 елдан башланып, 10 ел саен үткәрелә. Аларны анализлау халыкның яңарып тору темпларының бик югары булуын күрсәтә. **Мисал.** 1901 елда Һиндстанда — 239 млн, 1951 елда — 361 млн, 1981 елда — 683 млн, 1991 елда — 844 млн, 2001 елда 1 млрд 25 млн кеше яши. Шулай итеп, Һиндстан халык саны буенча дөньяда миллиард чиген узкән икенче ил (Кытайдан соң) булды. 2000 елның маенда миллиардынчы граждан (бу кыз бала була, аңа Аста, ягъни «Ышаныч» дип исем кушалар) дөньяга килә. [34].

Инде белгәнегезчә, үсеп килүче илләр арасында Һиндстан беренче булып гаилә планлаштыру программасын тормышка ашыра башлады. Ләкин иртә яшьтән никахлашуның күпгасырлык традицияләре сак-

---

[1] Бөекбритания җитәкчелегендәге Бердәмлек милләтләрнең Британия Бердәмлеге исеме белән әле 1931 елда ук төзелә. Ул вакытта аңа Бөекбритания һәм биш колония — доминион керә. Икенче бөтендөнья сугышыннан һәм Британия колониаль империясе җимерелгәннән соң, ул Бердәмлек (Commonwealth) итеп үзгәртелә һәм элеккеге Англия колонияләренең күпчелеген берләштерә. Хәзер Бердәмлеккә 53 ил керә. Аның гомуми территориясе 30 млн км$^2$ дан, ә халкы 1,2 млрдтан артып китә.

ланып калган илдә программа җитәрлек нәтиҗәле булып чыкмады.

Һиндстан халкының **этник составы** чиктән тыш төрле: *Һиндстан — дөньяда иң күп милләтле ил!* «Һиндстанлылар» дигән төшенчә социаль-икътисади үсешнең төрле баскычларында торган һәм төрле телләрдә сөйләшүче берничә йөз этносны — милләтләр, кабиләләр һәм халыкларны берләштерә.

**Мисал.** Төп телләр булып 15 тел санала. Ләкин 100 млн лап һинд кешесе башка телләрдә һәм диалектларда сөйләшә, ә диалектларның гомуми саны, галимнәр фикеренчә, 1,6 меңгә җитә. Һиндстанда бер тел дә сөйләшүчеләрнең саны буенча абсолют өстенлек итми.

Дәүләт теле булып һинди — һинд милләтләре арасында иң зурысы булган һиндустанлылар теле санала. Милләтара аралашу теле (бигрәк тә шәһәр җирендә) — инглиз теле. Моннан тыш, һәрбер штатның аеруча кулланыла торган үз теле бар. Һиндстанда икетеллелек киң таралган.

Катлаулы этник состав һиндстанлыларның матди мәдәниятендә нык чагылыш таба. Һиндстанны чын мәгънәсендә ачык һавадагы музей дип атарга була: илдә меңләгән матур храмнар, сарайлар, гүрстаннар (75 нче рәсемне карагыз), мәчетләр, фортлар бар. Шуңа да Һиндстанның Бөтендөнья мәдәни мирасы объектларының саны буенча дөньяда беренче урыннарны алып торуы гаҗәп түгел. Һиндстанның бик бай рухи мәдәнияте — борынгы эпос — һәр һинд кешесенә балачактан ук таныш, рәсем һәм театр сәнгате, классик биюгә һәм башкаларга карата да шуны ук әйтергә мөмкин. Һиндстан — шахмат ватаны, бирелә дистәләп санау системалары, йоглар тәгълиматы барлыкка килгән. Гасырлар буена башка күп кенә традицияләр дә өстәлгән. Мәсәлән, хатын-кыз киеме — сари, кобра еланы культы киң билгеле.

Һиндстанлыларның яшәү рәвешенә, иҗтимагый һәм гаилә мөнәсәбәтләренә [35] **дин** бик зур йогынты ясый: аларның 4/5 өлеше **индуизм** [36] һәм 1/10 еннән артыграк өлеше ислам динен тота. Индуизмның иң мөһим догматларыннан берсе — җәмгыятьне касталарга бүлү, рәсми рәвештә бетерелүгә дә карамастан, бигрәк тә авылларда хәзергә хәтле сакланып калган. Нинди дә булса кастага кертелү кешенең туганнан алып вафатына кадәрге бөтен үз-үзен тотышын билгели. Шуның белән берләттән халыкның катлаулы этник һәм дини составы еш кына милләтара һәм каста каршылыкларының кискенләшүенә, сепаратлык хәрәкәтләре башлануга китерә.

**1 нче мисал.** Джамму һәм Кашмир — Һиндстаннан бәйсез булуны яисә Пакистанга кушылуны яклаучы мөселманнар өстенлек иткән бердәнбер штат. Бу штат аркасында килеп чыккан территориаль бәхәс инде ярты гасыр дәвам итә. Бүленеп чыгуны булдырмас өчен, Һиндстан хөкүмәте Джамму һәм Кашмир штатына гаскәр кертергә мәҗбүр булды.




74



75



76

74 нче рәсем. Һиндстанның халкы

75 нче рәсем. Таҗ-Махал гүрстаны

76 нчы рәсем. Калькутта урамнарында

**2 нче мисал.** Пәнҗәб штатының төп халкын һинд-сикхлар тәшкил итә, алар мөстәкыйль дин булып киткән индуизм диненең бер сектасын гәүдәләндерәләр. 80 нче еллар башыннан алып сикхлар үз бәйсез дәүләтләрен — Халистанны булдыру өчен көрәш алып баралар, һәм бу инде берничә мәртәбә кораллы бәрелешләргә китерде.

Һиндстан халкының урнашуы бик тигезсез булу белән аерылып тора. Уңдырышлы елга дельталары һәм үзәннәрендә, диңгез яр буйларындагы түбәнлекләр һәм тигезлекләрдә халык инде бик күптәннән яши. Соңрак эчкәреге районнар да үзләштерелгән. Әмма әле хәзер дә халык аз утырган һәм хәтта бөтенләй кеше яшәми торган территорияләр бар.

Һиндстанда урбанизация дәрәҗәсе әлегә чагыштырмача түбән. Әмма халкының шундый күп санлы булуы нәтиҗәсендә аның масштаблары шактый тәэсирле. Илдә 4,5 меңнән артык шәһәр бар. Өстәвенә зур шәһәрләр һәм миллионер шәһәрләр саны даими артып тора.

**Мисал.** Зур шәһәрләр саны буенча Һиндстан Кытайдан, ә миллионер шәһәрләр (агломерацияләр) саны буенча Кытай белән АКШтан гына калыша. Шәһәр кешеләренең абсолют саны буенча (310 млн кеше) ул Кытайдан кала дөньяда икенче урында тора («Кушымталар»дагы 17 нче таблицаны карагыз).

Шулай да Һиндстан халкының иң күп өлеше авылларда — башлыча зур, күп кешеле авылларда яши. Авыл йортлары бик төрле булуы белән аерылып тора. Бирелә таш йортлар да, агачтан, балчыктан салынганнарын да, пальма яфраклары белән ябылган алачыкларны да, субайларга утыртылган өйләрне дә очратырга мөмкин. (17 нче бирем.)

**3. Хуҗалыгына гомуми характеристика: контрастлар иле.** Һиндстан, бәйсезлек алганнан соң, икътисади һәм социаль үсештә зур уңышларга иреште. Ул уңышлы рәвештә индустрияләштерү, аграр үзгәртеп корулар үткәрә, космик программаны тормышка ашыра. Илнең хуҗалыгы бишьеллык планнар нигезендә үсеш ала.

Һиндстанның күп кенә товарлары дөнья стандартларыннан калышмый. Бу халыкның зур һөнәр осталары булуы белән дә аңлатыла. Һиндстанда балаларны хезмәткә бик кечкенәдән өйрәтәләр, моның сәбәбе мохтаҗлык һәм ярлылык кына түгел, ә хезмәт кешесенең дәрәҗәсе, хезмәткә хөрмәтнең зур булуында да.

*Шулай да Һиндстан әле бик зур контрастлар иле булып кала.* Җитештерүенең күләме буенча ул дөньяда 9 нчы урында, ләкин җан башына милли керем дәрәҗәсе буенча 102 нче урында гына тора. Халыкның 1/4 өлеше диярлек рәсми ярлылык дәрәҗәсеннән түбәнрәк шартларда яши.

Техниканың соңгы казанышлары буенча җиһазландырылган куәтле предприятиеләр биредә бары тик кул хезмәтен генә файдаланучы («өй промышленносте») уннарча мең

вак һәм бик вак предприятиеләр белән янәшә тора. Дәүләт һәм хосусый капиталистик эре фермалар һәм плантацияләр белән беррәттән, җирсезлектән яисә аның азлыгыннан интеккән миллионлаган вак крестьян хуҗалыклары булу да — гадәти күренеш. Һиндстан өстеннән самолетта очканда карасаң, ул кечкенә-кечкенә корамалардан торган сыман күренә — шәхси җир участоклары шулкадәр кечкенә. Бу хуҗалыкларда агротехника дәрәҗәсе дөньяда иң түбәннәрдән санала. Күпчелек авылларда электр юк.

Һиндстан мөгезле эре терлекнең баш саны буенча дөньяда беренче урында булса да, ит продуктлары куллану буенча иң соңгы урыннарның берсендә тора. [37]. Ул Азиядә тимер юлларның озынлыгы ягыннан беренче урынны ала, әмма аларның яртысы тар колеялы. Фәнни-техник белгечләр саны буенча Һиндстан дөньяда күренекле урын алып тора, әмма «миләр китүе» аның фәне һәм техникасының барлык өлкәләренә кагылды. Кинофильмнар чыгару буенча (елына 750) дөньяда бер генә ил дә Һиндстан белән ярыша алмый, ләкин илдәге халыкның яртысы укыйяза белми. Зур шәһәрләрдә заманча уңайлы, матур кварталлар белән янәшә җимерек алачыклар (басти) урнашкан, аларда миллионлаган йорт-җирсез кешеләр көн күрә.

Барлык бу контрастларны бетерү өчен никадәр күп вакыт кирәк булачагын сез инде аңлыйсыздыр.

**4. Промышленносте: тармак структурасы һәм географиясенең төп сыйфатлары.** Һиндстанның промышленностенда актив халыкның 1/5 е эшли. Җиңел һәм азык промышленносте иленнән ул нык үскән авыр индустрия иленә әверелде. Хәзерге Һиндстан станоклар, тепловозлар, автомобильләр, тракторлар, телевизорлар гына түгел, иң яңа электрон техника, АЭС һәм космик тикшеренүләр өчен җиһазлар да җитештерә. Атом промышленностеның үсеше буенча ул үсеп килүче илләр арасында алдынгы урында бара.

Һиндстанның индустрияләштерү юлына басуы ягулык һәм чимал ресурсларының әһәмиятен нык арттырды. Төрле файдалы казылмалары бергә урнашкан территорияләр промышленность өчен аеруча уңайлы районнар булып торалар; алар, нигездә, Декан яссытаулыгына карый. Шуңа күрә дә төп промышленность узеллары, авыр индустриянең иң мөһим төзелешләре шунда барлыкка килгән, аларны бәйсез Һиндстанның беренче премьер-министры Дж. Неру образлы итеп «яңа Һиндстан храмнары» дип атады. Чынлап та, алар үзенә бертөрле ***«үсеш полюслары»н***[1] тәшкил итәләр.

**Мисал.** Бхилаи һәм Бокаро эре металлургия комбинатлары Һиндстанда мөһим «үсеш полюслары» булып китте. Аларның беренчесе Декан яссытаулыгының элек

[1] «Үсеш полюсы» — тирә-юнь районның үсешенә этәргеч бирүче шәһәр, яңа зур промышленность төзелеше.

артта калган үзәк өлешендә икътисадның үсешенә, ә икенчесе шул ук яссытаулыкның көнчыгыш өлешендә, Дамодар елгасы үзәнендә урнашкан төп күмер-металлургия базасын ныгытуга ярдәм итте.

Һиндстанда җиңел промышленностьның төп тармаклары — киҗе-мамык һәм джут житештерү. Соңгы вакытта электроника һәм информатика зур тизлек белән үсә.

**5. Авыл хуҗалыгы: табигый шартлары, игенчелек зоналары.** Авыл хуҗалыгында Һиндстан актив халкының 2/3 өлеше эшли. Дәүләтнең капитал салулары, «яшел революция» казанышларын файдалану нәтиҗәсендә, бөртекле культуралар, бигрәк тә бодай уңышы шактый артты, һәм ил, нигездә, үзен икмәк белән тәэмин итә башлады, шулай да аны куллану дәрәҗәсе әле бик түбән (җан башына 250 кг).

Һиндстан территориясенең күп өлешендә авыл хуҗалыгын үстерү өчен табигый шартлар шактый әйбәт. Илнең җир фонды зур, сөрүлек җирләрнең мәйданы буенча ул АКШтан гына калыша, ә алар исә территориянең 1/2 өлешен били.

Һиндстанда төп ике авыл хуҗалыгы сезоны — җәйге һәм кышкы. Җәйге сезон (хариф) май ахырыннан сентябрь-октябрьгә хәтле сузыла. Иң мөһим культураларны, җәйге муссон вакытында үсеп калсыннар өчен, гадәттә хариф башланганда чәчеп калдыралар, ә уңыш җәйге муссон ахырында җыеп алына. Кышкы сезон (раби) сентябрь-октябрьдән март-апрельгә кадәр сузыла. Бу сезонда һава коры һәм кояшлы була, шунлыктан чәчүлекләрнең күбесенә ясалма сугару таләп ителә.

Шушы сезоннарга бәйле рәвештә Һиндстанда төп ике игенчелек зонасы формалашкан, алар Һинд-Ганг түбәнлегендә урнашканнар.

Әлеге түбәнлекнең көньяк-көнчыгыш өлешендә *Һиндстанның төп дөге игү зонасы* формалашкан, анда дөгене хариф сезонында муссон яңгырлары астында һәм раби сезонында ясалма сугарып игәләр. Игенчелекнең мондый системасы елына ике, хәтта өч уңыш алырга мөмкинлек бирә.

Бу түбәнлекнең төньяк-көнбатыш өлешендә — Пәнҗәбтә (Бишьелга) *төп бодай зонасы* урнашкан. Бодайны раби сезонында, башлыча сугарулы җирләрдә игәләр. Шушы максат белән гидротехник корылмалар төзелгән, аларның иң зурысы — Бхакра-Нангал. Күпчелеге эре капиталистик хуҗалыклардан торган бу зонада «яшел революция» әлегрәк һәм зуррак масштабларда чагылыш тапкан. Һиндстанда бу — төп товарлыклы игенчелек районы.

Болардан тыш, илдә сүсле, майлы, шикәрле, тонус күтәрүче культуралар игүнең шактый зур ареаллары бар. (18 нче бирем.)

**6. Һиндстан хуҗалыгының һәм халык урнашуының географик сурәте: үсеш үзәкләре һәм «коридорлары».** Һиндстанда хуҗалыкның аны башка күп кенә үсеп килүче илләрдән аерып торучы территориаль структурасы барлыкка килде. *Илдә өстенлек итә торган бердәм үзәк юк.* Илнең

көнбатышында, көнчыгышында, төньягында һәм көньягында дүрт «икътисади башкала»сы бар.

Мумбаи[1] — Һиндстанның иң зур шәһәре, промышленность һәм сәүдә-финанс үзәге. Биредә машина төзү, нефть химиясе, киҗе-мамык предприятиеләре, атом энергиясен тыныч максатларда файдалану үзәге, илдәге иң зур киностудияләр урнашкан. Мумбаи порты — илнең төп диңгез капкасы. Тирә-яктагы шәһәрләре белән бергә Мумбаи илдәге иң зур промышленность үзәген тәшкил итә.

Иң элек шәһәр Гарәп диңгезендә ярдан ерак түгел урнашкан берничә зур булмаган утрауда барлыкка килә. Вакыт үтү белән аларны, җир өемнәре белән кушып, бер утрауга әвереллерәләр, аннары аны яр белән тоташтыралар. Элекке утрау өлешендә иске форт сакланган. Биредә үк 1911 елда төзелгән «Һиндстан капкасы», эшлекле, хакимият һәм промышленность кварталлары, шулай ук порт урнашкан. Материк өлешендә төп промышленность районнары тупланган.

Колката XVII гасыр ахырында инглизләрнең Ост-Һинд компаниясе факториясе урынында калкып чыга һәм гасыр ярым буена диярлек Британия Һиндстанының административ үзәге була. Бу Мумбаидан кала икенче промышленность шәһәре һәм порты, ул джут эшкәртү һәм аны читкә чыгару белән бигрәк тә аерылып тора.

Колката Һиндстанның төп мәдәни үзәге булып санала. Аның Ганг тамагындагы бер тармак булып сузылган агломерациясе бер-берсенә кушылып киткән күп кенә шәһәрләрне берләштерә. Колката өчен бик кискен социаль каршылыклар хас. Ун меңләгән йортсыз-җирсез кешеләр шәһәрнең «урам халкы»н тәшкил итә.

Дәһли — индус-мөселман архитектурасы истәлекләренә бай булган дөньяда иң борынгы шәһәрләрнең берсе. 1911 елдан — Һиндстанның башкаласы.

Бәйсезлек алгач, шәһәр бик тиз үсә. Ул эре транспорт, промышленность һәм мәдәният үзәге булып китә. Әмма аның сәяси һәм административ функцияләре тагын да әһәмиятлерәк.

Дәһли шәһәре ике төрле өлештән тора. Аның төньяк өлеше, ягъни Иске Дәһли, шәрык шәһәрләренә хас булган тар урамнардан, кустарь остаханәләреннән тора, анда халык гадәттән тыш тыгыз урнашкан. Көньяк өлеше, ягъни Яңа Дәһли (Нью-Дели), инде XX гасырда Европа

---

[1] Бомбей, Калькутта һәм Мадрас — Һиндстанның Дәһли кебек бу өч иң зур шәһәренең исемнәре үзгәртелеп, алар хәзер Мумбаи, Колката, Ченнаи дип аталалар.

стилендә, Британия Һиндстанының башкаласы буларак төзелә. Яңа Дәһли Һиндстан Республикасының рәсми башкаласы булып исәпләнә.

Ченнаи — Һиндстанның төп промышленность үзәкләреннән һәм портларыннан берсе, Көньякның «икътисади башкаласы».

*Мумбаи, Колката, Дәһли, Ченнаи — дүрт төп промышленность үзәге — Һиндстанның Көнбатышына, Көнчыгышына, Төньягына һәм Көньягына, шактый гына дәрәҗәдә бөтен илгә йогынты ясый.* Алар, зур дүртпочмаклыкның түбәләрен хасил итеп, бер-берсе белән «үсешнең төп көчәрләре» (коридорлары) ролен үтәүче иң мөһим транспорт магистральләре аша тоташканнар.

## 5. АВСТРАЛИЯ БЕЛӘН ТАНЫШАБЫЗ

**1. Гомуми мәгълүматлар.** Австралия — бөтен континентны берүзе биләгән дөньядагы бердәнбер ил (якындагы утраулар белән). Территориясенең зурлыгы ягыннан ул гигант илләр рәтенә керә.

«Бу таныш булмаган Көньяк җир»не голландиялеләр әле XVII гасыр башында ук ачалар, ләкин аны инглизләр инде XVIII гасыр ахырына үзләштерә башлыйлар. [38]. Метрополиядән 20 мең км ераклыкта урнашкан яңа колония озак вакытлар буена каторга һәм сөрген урыны булып хезмәт итә. Ләкин XIX гасырның беренче яртысында «җир бизгәге», шул ук гасырның уртасында «алтын бизгәге» башлана, алар материкның зур киңлекләрен үзләштерүне һәм шунда күчеп утыруны тизләтәләр. Шул рәвешле, Австралия «күчеп утырган капитализм» иленә әверелә. Ә 1901 елда биредә инглиз ***доминионы***[1] Австралия Союзы барлыкка килә.

Дәүләт төзелеше буенча хәзерге Австралия чынлыкта суверен дәүләт. Ләкин Бөекбритания җитәкләгән Бердәмлек составына кергәнлектән, аның рәсми башлыгы булып Англия королевасы санала, ә аның вәкиле — генерал-губернатор. Австралия — алты штаттан һәм ике территориядән торган федератив дәүләт. Алар бергә Австралия Союзын тәшкил итәләр.

Австралиянең **халкы** 20 млн кешедән гыйбарәт, бу Мәскәү халкыннан ике тапкыр күбрәк һәм дөньяның иң эре шәһәрләрендәге халык санына тигез. Шул исәптән шәһәрләрдә һәм резервацияләрдә яшәүче материкның төп халкы (аборигеннар) 250 мең (1,5 %). Димәк, аның бөтен халкы — күчеп утыручыларның, башлыча Европадан күчеп килүчеләрнең токымнары һәм хәзерге иммигрант-

---

[1] Доминион (лат. *dominium* — биләмә) — элеккеге Британия империясе составына кергән, үзенең башлыгы итеп Англия королен (королевасын) санаган, чынлыкта үзидарәле дәүләт.

лар. Австралиядәге халыкның уртача тыгызлыгы — 1 км$^2$ га 2 кешедән аз гына артыграк. *Ләкин халык чиктән тыш тигезсез урнашкан* (16 нчы рәсемне карагыз). Австралия — дөньяда иң нык урбанизацияләнгән илләрнең берсе (18 нче рәсемне карагыз).

**2. Хуҗалыгы.** ТЭПның гомуми күләме буенча Австралия дөньяда 16 нчы урында тора. Ләкин аның дөнья хуҗалыгындагы роле шактый зур булган халыкара специальләшкән тармаклары бар.

Беренчедән, *бу — тау казылмалары чыгару промышленносте.* Сез инде Австралиянең дөньядагы чыгару промышленносте нык үскән «бөек державалар» рәтенә керүен беләсез. Күмер, тимер рудасы, бокситлар, уран, алтын, алмазлар чыгару буенча ул илләрнең «беренче унлыгы»на гына түгел, ә хәтта «беренче өчлеге»нә керә. [39]. Австралиянең өлеше экспортта тагын да зуррак: төп диңгез «күперләре» — боксит, тимер рудасы, күмер күперләренең күбесе нәкъ менә биредә башлана, һәм алар башлыча Азия һәм Европа илләренә илтә.

Икенчедән, *бу — авыл хуҗалыгы.* Сарыкларның баш саны буенча дөньяда (Кытайдан кала) Австралия икенче урында (илдәге һәр кешегә 6,5 әр баш туры килә, ягъни барысы 125 млн сарык), сарык йоны җитештерү һәм экспортында шундый ук хәл. Бодай, ит, шикәр, җиләк-җимеш, шәраб җитештерү һәм сатуда дөньяда сизелерлек роль уйный.

**3. Эчке аерымлыклары.** *Австралиянең төп икътисади районы — Көньяк-Көнчыгыш район.* Ул бүтән районнардан алдарак колонияләштерелгән һәм хәзер анда халыкның 70% ы, промышленность һәм авыл хуҗалыгы производствосының, йөк һәм пассажир ташуның төп өлеше туплаган. Биредә илнең иң зур шәһәрләре: Сидней (Яңа Көньяк Уэльс штатының административ үзәге) һәм Мельбурн (Виктория штатының административ үзәге), шулай ук башкала функцияләрен үтәү өчен махсус төзелгән Канберра урнашкан.

Австралиянең калган районнарыннан төньяк-көнчыгыш, көньяк һәм көньяк-көнбатыш яр буйлары күбрәк үзләштерелгән, ә эчкәреге һәм төньяк районнарда халык яки бик аз, яки бөтенләй дә кеше яшәми. Бары тик тау казылмалары чыгару промышленностеның аерым участоклары гына аерылып тора. Ә коры далаларда һәм ярымчүлләрдә экстенсив рәвештә сарык үрчетү алып барыла. Меринос сарыкларны эре һәм бик эре фермаларда — сарык үрчетү станцияләре дип йөртелгән урыннарда («шипстейшнз») асрыйлар, алар шәхси хуҗалар яки компанияләр кулында. Андый станцияләрдә сарыклар ел буена табигый көтүлекләрдә йөриләр. [40]. (19 нчы бирем.)

**Төп нәтиҗә.** *Азия чит илләре — халык саны буенча дөньяда иң зур регион, һәм аның икътисади, социаль, экологик проблемалары демографик шартлау белән бәйле. Регион территориясенең гаять зур булуы да аның икътисади-географик урынына, табигать шартларына һәм ресурсларына, халкына һәм хуҗалыгына караган зур аерымлыкларны билгели. Материк-ил Австралия Азия-Тын океан регионында сизелерлек роль уйный.*

## ӨСТӘМӘ ТЕКСТ (Кызыклы мәгълүматлар)

[1] Индонезия көнбатыштан көнчыгышка таба 5 мең км дан артыкка сузыла. Монголия — 2,4 мең км, Төркия — 1,6 мең км, Япония төньяктан көньякка таба — 3,5 мең км га, Филиппин — 1,8 мең км га, Таиланд 1,7 мең км га сузыла. Монголия территориясе берүзе Европа чит илләренең 1/3 енә диярлек тигез.

[2] Шәһәр-дәүләт Сингапур 680 км$^2$ мәйдан били, бу Мәскәү мәйданының 2/3 өлеше дигән сүз, ә халкы 4,2 млн кеше тәшкил итә. Аның сызыкча үлчәмнәре: 23×42 км. Территориянең бер өлеше, Чанги халыкара аэропортын да кертеп, диңгездән яулап алынган.

[3] Бөтен дөньяда монарх хакимияте нәселдән-нәселгә тапшырыла. Ләкин Малайзиядә король (югары хаким) биш ел саен илдәге тугыз штатның башында торган солтаннар арасыннан сайлап куела. Монархның тулы титулы менә болай яңгырый: Дули Янг Маха Мулиа Шри Падука Багинда Янг Ди Пертуан Агунг. Малайя теленнән аны «Баш хаким галиҗәнаплары» дип тәрҗемә итәргә була.

[4] Дөньяда тикшереп табылган 30 гигант нефть ятмасыннан 15 е Фарсы култыгы бассейнында. Әмма алар арасында да Согуд Гарәбстанындагы 12 млрд т нефть запасы булган Гавар һәм Кувейттагы 8—9 млрд т нефте булган Эль-Буркан гигант ятмалары аерылып тора. Фарсы култыгындагы бассейн ятмаларында скважиналар фонтан кебек эшли: алардан нефтьнең тәүлегенә уртача чыгышы (дебит) 1—2 мең т тәшкил итә. Скважиналарның гомуми саны — 5 мең. Чагыштыру өчен: АКШта андый скважиналар 615 мең, ә бер скважинаның уртача тәүлеклек дебиты — 1—2 т.

[5] Безнең көннәрдә күп кенә мөһим демографик күрсәткечләр буенча үзенә күрә дөньяның абсолют рекордсмены булып Палестина автономиясе санала. Газа секторында бала туу күрсәткече 52 % ка, ә халыкның уртача артуы 4,6 % ка җитә. Дөньяда башка бер генә территориядә дә бала яшендәгеләрнең барлык халыкның 52 % ын тәшкил иткәне, ә бала тудыру яшендәге һәр хатын-кызга 8 бала туры килгәне юк.

[6] 1921 елгы революция алдыннан Монголиядә 1800 дән артык төрле храм һәм 750 лама (ламаизм — буддизмның бер төре) монастырьлары булган. Ул монастырьларга малайларны 6—8 яшьтән мәҗбүриләп биргәннәр, ил буйлап уртача алганда, һәр икенче малай монастырьга эләккән. Нәтиҗәдә лама монахлары һәм руханилары ир-атларның 40 % ын диярлек тәшкил иткән. Аларның гаилә кормаска дигән антлары бу

халыкның табигый артуына бик нык тәэсир иткән. Демографлар исәпләвенчә, ламаизм булмаса, хәзер Монголия халкы 2,6 млн урынына 10 млн га җитәр иде.

[7] Һәр елны Мөселман календары буенча соңгы айның 7 сеннән алып 13 енә кадәр мөселман дөньясының барлык илләреннән 2 млн нан артык кеше Мәккәгә хаҗ кылырга килә. Мөхәммәд пәйгамбәрнең үзе тарафыннан билгеләнгән хаҗ кылу гамәле атнаның һәр көне өчен билгеләнә. Беренче көнне хаҗ кылучылар ислам дине өчен иң изге саналган һәм Зур мәчеттә урнашкан Кәгъбә (гарәпчәдән куб) ташын җиде тапкыр әйләнеп үтәргә тиешләр. Ә соңгы көнне алар Корбан чалу — альуджа бәйрәмен (төркичә Корбан бәйрәмен) билгеләп үтәләр. Гадәттә, хаҗ кылучылар күршедәге Мәдинә шәһәренә дә баралар. Анда Мөхәммәд пәйгамбәр күмелгән. Согуд Гарәбстанында хаҗ кылу эшләре буенча махсус министрлык бар.

[8] 90 нчы еллар башында Кувейтта 300 мең иорданияле, 170 мең мисырлы, 160 мең индус, 90 мең ланкийлы, 70 мең Бангладеш кешесе, 45 мең иранлы, 35 мең филиппинлы, 35 мең сүрияле, 25 мең ливанлы, 20 мең суданлы, 30 мең башка ил кешесе эшләгән.

[9] БГӘдә һәр кеше чит илдән килгән дүрт эшчене «яллый» ала. Мәскәү журналистларыннан берсе илнең башкаласы Әбү-Дабины менә болай сурәтли: «Оманлыларның төрле төстәге чалмалары, сикхларның тюрбаннары күзгә чалына. Биредә пакистанлыларны, кореялыларны, малайзиялеләрне, таиландлыларны, гарәп илләре кешеләрен күрергә була. Ял көнне яр буйлап бөтен Шәрык халкы парад булып үтә диярсең». Җирле халык илдәге халыкның 1/6 өлешен тәшкил итә. Шушы азчылык кына өстенлекләргә ия.

[10] 90 нчы елларның ахырында Сингапур порты йөк әйләнеше буенча Роттердамны куып җитте һәм дөньяда беренче урынга чыкты (2005 елда — 400 млн т). Аның судно әйләнеше — елына 130 мең, яки уртача бер тәүлеккә 400 судно туры килә. Гадәттә, портның үзендә һәм Сингапур бугазындагы рейдында дөньяның дистәләрчә илләреннән бер үк вакытта 700—800 судно була. Ә контейнерлар ташу буенча Сингапур Сянган белән дөньяда беренче-икенче урыннарны бүлешә.

[11] Согуд Гарәбстаны башкаласы «Әр-Рияд — дөньяның динамик үсүче шәһәрләренең берсе. 1960 елда анда 160 мең кеше яшәсә, 1990 елда 2 млн нан артып китте, ә 2000 елда — 3,2 млн булды. Министрлык, кунакханә, банк бинналары, гадәттә, 7—8 катлы, әмма алар архитектура үзенчәлекләре белән аерылып торалар (63 нче рәсемне карагыз). Промышленность предприятиеләре шәһәр читенә чыгарылган, шәһәр урамнарында яшеллек

бик күп. Транспортның тармаклану урыннары ике һәм өч катлы.

[12] Көнчыгыш һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиядә яшәүче һәр кеше елына уртача 100—300 кг дөге куллана. Азык рационы структурасында дөгегә барлык калориянең якынча 3/4 өлеше туры килә. Димәк, дөге һәм аннан әзерләнгән ашамлыклар һәр көнне иртәнге ашка да, көндезге һәм кичке ашка да кертелә, ә калган барлык ашамлык төрләре өстәмә генә булып хезмәт итә дигән сүз.

[13] Шри-Ланкага бөтен дөньяда җитештерелгән чәйнең 1/10 е чамасы, ягъни 180—200 мең т туры килә. Әгәр дә моны 50 шәр граммлы чәй капларына күчерсәң, аларның саны 3,8 млрд булыр, һәм Җир шарындагы һәр кешегә 2/3 төргәк диярлек туры килер иде.

[14] 1998 елда Кытайда су басудан теге яки бу дәрәҗәдә 400 млн кеше зыян күрде, хәтта күпләре һәлак булды. 5 млн йорт җимерелде, гомуми зыян 36 млрд доллар тәшкил итте.

[15] 2004 елның 26 декабрендә Суматра утравы ярлары буенда бик көчле җир тетрәү булды һәм кешелек тарихында иң җимергеч цунами барлыкка китерде. Ул Һинд океаны ярлары буенда урнашкан 14 ил, әмма бигрәк тә Индонезия, Һиндстан, Шри-Ланкага нык кагылды. Һәлак булганнарның саны төрле чыганакларда 150, 250 һәм 300 мең кеше дип бәяләнә.

[16] Хэнань, Шаньдун һәм Сычуань провинцияләре халык саны буенча (97, 91 һәм 87 млн кеше ) Европадагы халык саны иң зур ил — Германияне узып китә. Ә Хэбэй, Цзянсу, Аньхой, Хубей, Хунань, Гуандун провинцияләрендә халык саны Франция, Бөекбритания һәм Италиягә караганда күбрәк.

[17] Кытай иероглифлы язуында 50 мең тамга бар, шул исәптән иң киң кулланыла торганнары — 7 мең. Башлангыч мәктәпне тәмамлаган кеше 3,5 мең иероглиф белергә тиеш; аларның һәрберсендә сызыклар саны 30 га җитәргә мөмкин. Кытай телендәге һәр иероглиф билгеле бер музыкаль тон белән әйтелә. Бу вакытта бер үк төрле авазлар ярдәмендә, ләкин төрле тоннарда әйтелә торган күп кенә сүзләр төрле мәгънәдә булырга мөмкин. Беренче тон белән әйтелә торган «ма» иҗеге — «әни» дигән мәгънәне, икенче тонда — «киндер», өченче тонда — «ат», дүртенче тонда әйтелгәне «тиргәү, әрләү» дигән мәгънәне белдерә.

[18] Кытайда шәһәр чикләренә киң күләмдә янәшә авыл территорияләрен керткән административ реформа үткәрелде. 1997 елда илдәге үзәккә буйсынган шәһәрләр арасында Чунцин дүртенче булды, аның составына Сычуань провинциясенең шактый өлеше — 82 мең км$^2$ ы керде (бу Австрия яки Чехия кебек илләрнең мәйданына тиң). Әлеге чикләрдә Чунцин

провинциясенең халкы 30 млн кеше тәшкил итте! Шуның бары тик 6 млн ы гына шәһәрдә (шәһәр яннарын да кертеп) яши.

[19] Болар күмер, тимер рудасы, чуен, корыч, беренчел алюминий, вольфрам, цинк, минераль ашламалар, химик сүсләр, цемент, радиоалгычлар, телевизорлар, кер юуу машиналары, велосипедлар, аяк киеме, бөртекле культуралар, бәрәңге, арахис, җимешләр, яшелчәләр, майлы орлыклар, мамык, ит, йомырка, балык һәм диңгез продуктлары, сигаретлар.

[20] Татар телендәге «ашау» сүзенә кытай телендә ике сүз туры килә — «чи фань», сүзгә-сүз тәрҗемә иткәндә ул «дөге ашау» дигәнне аңлата. Иртәнге аш кытайча «цзао фань» — «иртәнге дөге», төшке аш — «у фань» яисә «төшке дөге», кичке аш — «вань фань» яисә «кичке дөге».

[21] 80 нче еллар уртасында дөньяда барлыгы 800 млн велосипед исәпләнгән, шул исәптән 300 млн — Кытайда (АКШта — 100 млн, Япониядә — 60 млн). Велосипед җитештерү буенча (елына 40 млн нан артык) Кытай дөньяда беренче урында тора.

[22] Японнар үз илләрен борынгы заманнардан бирле Ниппон (яки Нихон) дип йөртәләр. Бу атама ике иероглиф тамгасыннан тора, аларның беренчесе — «кояш», икенчесе «нигез» дигәнне аңлата. Япониянең читләтеп әйтелгән «Кояш чыгышы иле» дигән атамасы шуннан килеп чыккан. Япон флагындагы кызыл кояш түгәрәге һәм дәүләт гербындагы түгәрәк хризантема (японнарның милли чәчәге) шулай ук чыгып килүче кояшны белдерә.

[23] Синтоизм («синто» сүзеннән, «илаһи юл» дигән мәгънәдә) төп дини-көнкүреш йолаларына, барыннан да элек туй йолаларына хезмәт күрсәтә; алар һәрвакыт синтоист храмнарында үтә. Буддизм, киресенчә, мәет күму һәм күмгәннән соңгы йолаларны үзенә ала.

[24] Япониядә ел саен 40 тан артык төрле фестивальләр үткәрелә. Аларның берсе — «ак утрау» Хоккайдода үткәрелә торган данлыклы кар фестивале. Фестиваль көннәрендә Саппороның төп урамында кардан 300 дән артык сын төзелә. Болар — әкият персонажлары, әдәби геройлар, атаклы һәйкәлләр һәм архитектура корылмаларының копияләре.

[25] Токио урамнарының гомуми озынлыгы 22 мең км, ягъни экватор озынлыгының яртысыннан артыгын тәшкил итә; шәһәрдә 4 млн йорт бар. Күпчелек урамнар исемсез. Санлы тактачыклар район номерын (алар шәһәрдә 23), блокны, квартираларның тәртип номерларын күрсәтә. Токиода тиешле адресны табу, хәтта полициягә һәм югары сыйфатлы хезмәт күрсәтүләре белән аерылып торган таксистларга да җиңел түгел,

кунаклар һәм килгән кешеләр турында инде әйтеп тә торасы юк. Шәһәрнең аерым өлешләре үзара тиз йөрешле автомобиль эстакадалары белән тоташкан, әмма алар да 5 млн автомобиль хәрәкәтен бик авырлык белән генә тәэмин итеп торалар.

[26] Токиодан 200 км төньяктарак урнашкан Фукусимадагы дөньяда иң зур АЭСның егәрлеге, 1998 елда җиденче реакторы эшли башлагач, 8,2 млн кВт ка җитте. Ә эчке Япон диңгезе ярында урнашкан, дөньяда иң зур Фукуяма металлургия комбинатының куәте елга 16 млн т корыч коярга мөмкинлек бирә.

[27] 1988 елда ун ел дәвамында төзелгән уникаль Сэто — Охаси күпере файдалануга тапшырылды. Эчке Япон диңгезе аркылы салынган бу кичү Хонсю һәм Сикоку утрауларын тоташтырды. Аның озынлыгы 12 км һәм фактта аерым-аерым берничә күпердән гыйбарәт. Аның югары өлеше дүрт полосалы автомагистраль, ә аскысы буенча «Синкансен» системасындагы югары тизлекле тимер юл экспресслары уза.

[28] Җан башына балык куллану буенча (70 кг чамасы) Япония дөньяда беренче урында. Гәрчә япон кухнясында пешереп, табада яисә күмер өстендә кыздырып әзерләүнең күп кенә ысуллары булса да, японнар балык һәм башка диңгез продуктларын — сигезаяклылар, кальмар, моллюск, эре креветкаларны чи килеш, сирәк очракта киптереп ашарга яраталар. Шулай тукланганга күрә дә японлылар атеросклероз белән авырмыйлар диярлек.

[29] Чагыштырмача тирән сулыклардагы энҗе кабырчыкларын тотуда борын-борыннан Көньяк Япониядәге халыкның ама дигән этник төркеме специальләшкән, өстәвенә су төбенә чумучы һөнәренә күбрәк хатын-кызлар ия. Су төбенә чумучылар 30 м тирәнлеккә кадәр төшә һәм анда бер минуттан артыграк тора ала. Соңгы вакытта бу промыселлар урынына энҗене ясалма рәвештә үстерү буенча зур предприятиеләр барлыкка килде. Моның өчен махсус салларның асларына энҗе үстерүче кабырчыклар тутырылган кәрзиннәр беркетәләр.

[30] Тимер юлларның пассажир әйләнеше буенча (385 млрд пассажир-километр) Япония, Россиягә караганда 2,2, ә АКШка караганда 16 тапкыр өстенрәк булып, дөньяда өченче урынны тота. Бу күрсәткеч буенча ул бары тик Кытай һәм Һиндстаннан гына калыша. Мондый саннар да игътибарга лаек: һәр японлы уртача елына тимер юл буйлап 1920 км ара узса, шул ук вакытта швейцарияле — 1700 км, француз — 1000, россияле — 1150 км уза.

[31] «Синкансен» («Яңа линия») магистраленең гомуми озынлыгы 1100 км га якын. Бу юлдан поездлар сәгатенә

уртача 200 км һәм аннан да зуррак тизлек белән йөриләр. Токио — Осака юлында (515 км) хәрәкәт аеруча зур, аның аша тәүлегенә 120 пар поезд уза, елына 120 млн пассажирга хезмәт күрсәтелә, бу — илдәге барлык халык саны дигән сүз. Токио һәм Осака шәһәрләре арасын «Хикари» («Яктылык») экспрессы, 66 тоннель һәм 3 мең күпер аша чыгып, 2 сәгать 15 минутта уза.

[32] «Сейкан» тоннелен 1970 елдан 1988 елга кадәр төзеделәр. Ул Цугару бугазы аша су астыннан 100 м тирәнлектә салынган һәм Хонсю утравы белән Хоккайдо утравын тоташтыра. Тоннельнең озынлыгы 54 км, шуның 23 км ы су асты өлешенә туры килә. Тоннель Токио — Саппоро юлында поездларның тизлеген күпкә арттырды (16 сәгать урынына 6 сәгать).

[33] Һиндстанның иң зур штаты Раджастхан 342 мең км$^2$ мәйданны били. Моны Германия, Финляндия, Вьетнамның мәйданы белән чагыштырырга мөмкин. Ә иң кечкенә Гоа штатының мәйданы бары 3,7 мең км$^2$. Уттар Прадеш штатында 166 млн кеше яшәсә, кайбер зур булмаган штатлардагы халык бары 0,5—1 млн кеше генә исәпләнә.

[34] Һиндстанның демограф-статистиклары 70—80 нче елларда Һиндстан халкының сәгать саен — 1,9 мең кешегә, тәүлек саен — 46 мең, ә ел саен кимендә 17 млн кешегә артуын исәпләп чыгарганнар. Халык саны арту темпы 80 нче еллар дәрәҗәсендә калса, Һиндстан халкы XXI гасыр урталарына 3 млрд кешегә җитәр иде. Инде хәзер, коры җир мәйданының 2,4 % ын биләгән бу ил территориясендә бөтендөнья халкының 16,6 % ы тупланган.

[35] Һиндстандагы никахларның 9/10 ын ата-аналар «оештыра». Моның өчен якшәмбе саен барлык газеталар бастырып чыгара торган никах белдерүләре киң кулланыла. Газетада бастырылган белдерүгә йөзләрчә җавап алгач, кияү егетенең яисә кәләшнең әтисе иң лаек дип тапкан кандидатларны сайлый һәм шулар арасыннан берсен аерып ала. Бу процедура, гадәттә, яшьләр катнашыннан башка үткәрелә. Ә кияү белән кәләшнең бер-берсен туйда гына күрү очраклары еш була.

[36] Һиндстанның бөтен тарихы һиндстанлыларның изге елгасы булып саналган Ганг елгасы белән тыгыз бәйләнгән. Миллионлаган кеше «чистарыну» йоласын (ритуаль юыну) үтәр өчен шушы елгага килә. Индуизм динен тотучы һәркем үзенең гомер юлы Ганг ярларында тәгәлләнүен, гәүдәсен яндырганнан соң, көлен елга өстенә сибүләрен тели; ә кайберәүләрне исә кремация ясап тормыйча гына, аның суларына күмәләр. Хаҗ кылу өчен иң танылган урын булып Варанаси (Бенарес) шәһәре

санала, аның Һиндстанның «мәңгелек» шәһәрләреннән берсе дигән даны чыккан.

[37] Һиндстан кешесе елга уртача нибары 1,5—2 кг ит ашый. Бу, товарлыклы терлекчелекнең булмавыннан бигрәк, вегетарианлыкны төрлечә яклаган, сыер итен ашауны һәм сыерларны үтерүне тыйган (Борынгы Һиндстанда алар уңдырышлылык һәм муллык символы булып хезмәт иткәннәр) индуизм карашлары белән аңлатыла. Дин кануннарына буйсынып, һинд крестьяннары картайган терлекләрне суймыйлар, ишегалдыннан куып кына чыгаралар. Нәтиҗәдә миллионлаган «изге» сыерлар, юл хәрәкәтенә комачаулап һәм чәчүлекләрне таптап, әмма беркемнән дә курыкмыйча, юлларда, кырларда, шәһәр урамнарында йөриләр (76 нчы рәсемне карагыз).

[38] Беренче тапкыр сөргенгә куылучылар төялгән 11 паруслы судно материкның көньяк-көнчыгыш ярына 1788 елда сигез ай йөзгәннән соң килеп җитә. Биредә Бөекбританиянең ул вакыттагы колония министры хөрмәтенә Сидней исеме алган торак пунктка нигез салына. 1988 елда Австралиянең 200 еллыгын бәйрәм иткәндә инглизләр «Беренче флотның» юлын төп-төгәл итеп кабатладылар. Ә 26 гыйнвар бу флот үзенең йөзүен төгәлләгән көн шул дәвердән бирле Австралиянең милли бәйрәме итеп үткәрелә.

[39] Көнбатыш Австралиядә алмазлар 1976 елда гына ачыла, ә ун елдан соң ул алмазлар чыгару буенча дөньяда беренче урынга чыга.

[40] «Шипстейшнз»ның мәйданы, кагыйдә буларак, бик зур: алар дистәләрчә, хәтта йөзләрчә мең гектар җир билиләр, ә иң зур станция 2 мең км² дан артык мәйдан били, ягъни Люксембургтан аз гына калыша. Андый станцияләрдә сарыкларның баш саны 10—20 меңгә һәм хәтта 50—100 меңгә җитә. Биредә башлыча нәфис йонлы меринос сарыкларының Австралия токымын үрчетәләр, алар иң югары сыйфатлы йон бирә. Гоулберн дигән кечкенә генә шәһәрдә күптән түгел сарыкларга Зур Меринос дигән һәйкәл куелган.

**Китап киштәсе**


1. Зарубежная Азия.— М.: Мысль, 1979—1982.— (Серия «Страны и народы»).
2. Максаковский В. П. Географическая картина мира.— М.: Дрофа, 2009.— Ч. 2.— Тема 2.
3. Экономическая и социальная география мира. За страницами учебника: Кн. для учащихся 10 кл./Сост. А. П. Кузнецов.— М.: Просвещение, 2000.
4. Пронников В. А., Ладанов И. Д. Японцы.— М.: ВиМ, 1996.

## БЕЛЕМ һӘМ КҮНЕКМӘЛӘР АЛУ ӨЧЕН ТУПЛАНМА

**1 нче бирем.** Азия чит илләренең дәреслек форзацындагы «визит карточкалары» ярдәмендә аларның дәүләт төзелеше характеристикасын конкретлаштырыгыз. Тарих дәресләрендә алган белемнәргә таянып, ни өчен дөньяның бер генә өлешендә дә Азиядәге кадәр абсолют монархияләр сакланып калмаганын аңлатып бирегез. Республика һәм монархияләрне контурлы картага төшерегез. Анда шулай ук федератив дәүләтләрне дә билгеләгез. «Кушымта»дагы 2 нче таблицаны да файдаланыгыз.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** «Кушымта»дагы 1 нче таблицаны файдаланып, Азия чит илләренең контурлы картасына Икенче бөтендөнья сугышыннан соң сәяси бәйсезлек алганнарын төшерегез. Бәйсезлек алуның даталарын куегыз һәм шулар буенча дүрт субрегион илләрен чагыштырыгыз.

**2 нче бирем.** Атлас карталарын файдаланып, Азия чит илләрендә нинди файдалы казылмалар барлыгын билгеләгез. Аларны төп илләр арасында бүлегез һәм минераль ресурсларның «комплектлы» һәм «комплектсыз» булуы турында нәтиҗәләр ясагыз. Бу ресурсларның территориаль яктан туры килүенә мисаллар китерегез. Шулай ук «Кушымта»дагы 3, 4 нче һәм 5 нче таблицалардан да файдаланыгыз.

**3 нче бирем.** Дәреслек тексты, Азия чит илләренең физик картасы, шулай ук атластагы җир, су һәм агроклиматик ресурслар карталары, «Кушымта»дагы 6 нчы таблица нигезендә Азия чит илләрендә авыл хуҗалыгы үсеше өчен табигый шартларга характеристика бирегез. Илнең (регионның) авыл хуҗалыгы үсеше өчен табигый шартларга характеристика бирүнең үрнәк планын кулланыгыз (272 нче бит). 7 нче сыйныфта материклар һәм океаннар географиясен өйрәнгәндә алган белемнәрне дә файдаланыгыз.

**4 нче бирем.** Атласның дөнья халыклары картасын файдаланып, Көнчыгыш, Көньяк-Көнчыгыш, Көньяк һәм Көньяк-Көнбатыш Азия илләре халыкларының нинди тел семьялыкларына керүен билгеләгез. Аерым бер семьялыклар төзегән иң зур халыкларны атагыз.

**5 нче бирем.** Азия чит илләре халкына характеристиканы дәреслектәге 17, 18 нче рәсемнәр һәм 2, 3 нче таблицалардагы, шулай ук атлас карталарындагы һәм «Кушымта»дагы 11—17 нче таблицаларда китерелгән саннар һәм фактлар белән тулыландырыгыз.

**6 нчы бирем.** Көньяк-Көнбатыш Азиянең атластагы икътисади картасы һәм дәреслектәге 61 нче рәсем буенча бу субрегионда нефть промышленностеның ничек урнашуына характеристика бирегез. Төп нефть чыганакларын, нефть эшкәртү үзәкләрен, нефть үткәргечләрне, нефть читкә чыгарыла торган диңгез портларын атагыз.

**7 нче бирем.** Атластагы картасын файдаланып, Кытайның кайсы дәүләтләр белән коры җир чикләре булуын билгеләгез. Аны күрше илләр саны буенча Россия белән чагыштырыгыз.

**8 нче бирем.** Дәреслек текстын, форзацтагы «визит карточкасы»н, дәреслектәге рәсемнәрне, «Кушымта»дагы таблицаны һәм атлас картасын файдаланып, Кытай халкына характеристика бирегез. Төп фактларны әйтегез, нәтиҗәләр ясагыз. Ил (регион) халкына характеристиканың үрнәк планыннан файдаланыгыз (272 нче бит).

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** Түбәндәге топонимик сүзлектән файдаланып, 65 нче рәсемдә күрсәтелгән кайбер Кытай провинцияләренең исемнәрен аңлатыгыз: «бэй» — төньяк, «нань» — көньяк, «дун» — көнчыгыш, «си» — көнбатыш, «шань» — тау, «юань» һәм «нин» — тигезлек, «хэ» һәм «цзян» — елга, «ху» — күл, «юнь» — болыт.

Мәсәлән, «Хэбэй» — «елгадан төньякка таба» (Хуанхэ).

**9 нчы бирем.** Дәреслекнең I өлешендәге рәсемнәр һәм таблицаларны, шулай ук «Кушымта»дагы 23 нче таблицаны, Япониягә караган 59 нчы рәсем үрнәген файдаланып, Кытай буенча таблица-диаграмма төзегез.

**10 нчы бирем.** Атлас карталарын файдаланып, Кытай авыр промышленностеның төп тармакларын гәүдәләндергән иң зур промышленность үзәкләренә мисаллар китерегез.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Бу үзәкләрне контурлы картага төшерегез. Аларның барлыкка килү сәбәпләре турында уйлагыз.

**11 нче бирем.** Дөньяның агроклиматик картасын һәм атластагы Үзәк һәм Көнчыгыш Азиянең икътисади карталарын файдаланып билгеләгез:

1) Кытай территориясе нинди агроклиматик поясларда урнашкан; 2) аның өчен нинди авыл хуҗалыгы культуралары характерлы; 3) аларны үстерүче төп районнар кайда урнашкан. Мондый специальләшүнең төп сәбәпләрен әйтергә тырышыгыз.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Контурлы картага Кытайда дөге, бодай һәм чәй үстерүнең төп районнарын төшерегез. Аларның нигә алай урнашуын аңлатыгыз.

**12 нче бирем.** Дәреслектәге текстны, 65 нче рәсемне һәм атлас карталарын файдаланып, Кытайның өч икътисади зонасына характеристика бирегез.

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** Үзегезне экскурсовод итеп һәм сезгә Пекин үзәге буйлап экскурсия үткәрергә кушылган дип күз алдыгызга китерегез.

Дәреслек текстын, Пекинның атластагы планын һәм өстәмә информация чыганакларын файдаланып, шундый экскурсия өчен материал әзерләгез һәм аны иптәшләрегез өчен «үткәрегез».

**13 нче бирем.** Дәреслек текстын, дөньяның сәяси картасын һәм Япониянең атластагы икътисади картасыннан файдаланып, Япониянең икътисади-географик урынына характеристика бирегез. Илнең (регионның) 222 нче биттәге характеристикасының үрнәк планын кулланыгыз.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Дәреслектәге текст һәм рәсемнәрне, шулай ук атлас карталарын файдаланып, Япония һәм Бөекбритания ИГУна чагыштырма характеристика бирегез; охшашлыклар һәм аерымлыкларны билгеләгез.

**14 нче бирем.** Дәреслектәге текст һәм 69 нчы рәсем ярдәмендә Япониянең экспорт һәм импорт структурасына характеристика бирегез. 5 нче тема рәсемнәрен файдаланып, Япониягә чит илдән ягулык һәм чимал кертүнең төп юлларын тасвирлагыз.

**15 нче бирем.** Дәреслек текстын һәм 70, 72 нче рәсемнәрне файдаланып, Япониянең Тын океан поясына гомуми характеристика бирегез. Япониянең атластагы икътисади картасы ярдәмендә дәреслектәге түбәндәге тасвирлауларны ачыклагыз: 1) «ҖЭСлар, АЭСлар, металлургия, нефть эшкәртү һәм химия комбинатлары, машина төзү заводларының күпчелеге шунда урнашкан»; 2) «Интенсив авыл хуҗалыгының күп кенә төп районнары, төп транспорт магистральләре, иң мөһим портлар да биредә урнашкан».

**16 нчы иҗади бирем.** Япония буйлап гадәти туристик маршрутка Токио, Осака, Киото, Хиросима керә. Әмма бу маршрут кына ил турында тулы күзаллау бирә алмый. Дәреслек текстын һәм рәсемнәрне, шулай ук өстәмә мәгълүматларны файдаланып, Япониянең ике йөзен дә күрсәтә алырлык маршрут төзегез.

**17 нче бирем.** Дәреслек текстын, 74 нче рәсемне, «Кушымта»дагы 14, 16, 17 нче таблицаларны һәм атластагы Һиндстан халыклары картасын файдаланып, Һиндстан халкына характеристика бирегез. Миллионер шәһәрләрне атагыз, 1951, 1981, 1991 һәм 2001 елларда халыкның уртача тыгызлыгы күрсәткечен исәпләп чыгарыгыз. Килеп чыккан мәгълүматларны чагыштырыгыз һәм аларның нәрсә турында сөйләвен аңлатыгыз.

**18 нче бирем.** Дәреслек текстын, Азиянең физик картасын, Көньяк һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиянең атластагы икътисади картасын файдаланып, Һиндстанның авыл хуҗалыгына характеристика бирегез. Илнең (регионның) авыл хуҗалыгы характеристикасының үрнәк планын (242 нче бит) файдаланыгыз.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Атластагы картаны файдаланып, контурлы картага дөге, бодай, тары, мамык, джут, шикәр камышы, чәй игү ареалларын төшерегез. Һиндстанда Азия авыл хуҗалыгының нинди районнары (типлары) барлыгын билгеләгез.

**19 нчы иҗади бирем.** Дәреслекнең I кисәгендәге текстларны һәм рәсемнәрне игътибар белән карагыз һәм аннан Австралиягә кагылган барлык материалны аерып алыгыз. Австралия буенча атлас карталарын һәм «Кушымта»дагы таблицаларны файдаланыгыз. Шушы материаллар нигезендә бу илнең кыскача социаль-икътисади характеристикасын тулыландырыгыз.

**20 нче йомгаклау биреме.** 1. (Дәфтәрдә эшләү.) 7 нче тема параграфларыннан берсенә логик конспект төзегез.

2. (Контурлы карта белән эшләү.) Дәреслектәге текст һәм рәсемнәрне файдаланып, «Азия чит илләреннән дөнья базарына чыгарыла торган иң мөһим продукция» дигән карта-схема төзегез. Тау промышленносте, эшкәртү промышленносте һәм авыл хуҗалыгы продукцияләрен читкә чыгаруны уклар белән күрсәтегез.

3. Азия чит илләреннән үзегез барырга теләгән берәр илне сайлап алыгыз. Бу ил буенча кызыклы материал әзерләгез. Аны, үз күзең белән күргән кебек итеп, сыйныфташларыгызга сөйләп күрсәтегез.

4. 7 нче теманы өйрәнгәндә, дәреслектәге һәм атластагы тематик карталарның нинди төрләрен файдалануыгызны билгеләгез.

5. Дәреслектәге 73 нче рәсемне файдаланып, Японияләнең диңгез яр буеннан «яулап алынган» территориясен тасвирлагыз.

## ҮЗЕГЕЗНЕҢ ҺӘМ БЕР-БЕРЕГЕЗНЕҢ БЕЛЕМНӘРЕН ТИКШЕРҮ ТУПЛАНМАСЫ

**Җавап бирергә тырышыгыз:**

1. Ни өчен барлык икътисади үсеш алган илләр арасында «диңгезгә таба күчү» Японидә иң ачык чагылыш тапкан? Ни өчен супертанкерлар, күмер, руда, автомобиль ташучы суднолар төзүдә нәкъ менә Япония пионер булган?

2. Ни өчен Көньяк һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиядә халыкның тыгызлыгы елга үзәннәре һәм дельталарында аеруча зур?

3. Ни өчен терлекчелек Монголия хуҗалыгында төп тармакка әйләнә?

4. Ни өчен Меконг елгасын «Азия Дунае» дип атарга була?

5. Төньяктан көньякка таба Кытайда авыл хуҗалыгы специальләшүе ничек үзгәрә? Көнчыгыштан көнбатышка таба?

6. Ни өчен Япония промышленносте структурасында файдалы казылмалар чыгару тармакларына нибары 0,3 % кына туры килә?

7. Ни өчен «Һиндстанны белү өчен авылда яшәргә кирәк» диләр?

8. Ни өчен Австралиядә башлыча океан буе территорияләре үзләштерелгән?

**Түбәндәге фикерләрнең дөреслеген тикшерегез, кирәк урыннарда дөресләп җавап бирегез:**

1. Җирдәге һәр бишенче кеше — кытай.

2. Азиянең башка илләреннән аермалы буларак, Япония өчен халык яңарып торуының беренче тибы характерлы.

3. Көньяк Азия — дөньяның иң күп милләтле һәм иң күп телле районы.

4. Ресурсларның бердәнбер төре — хезмәт ресурслары гына булган хәлендә, Япония иң алдынгы индустриаль илгә әверелде.

5. Азиянең муссонлы өлкәләрендә крестьяннар бодай һәм арпа үстерәләр.

6. Австралия — сарыкларның баш саны буенча дөньяда икенче, ә йон җитештерү буенча беренче урында тора.

**Дөрес җавапны сайлап алыгыз:**

1. Көньяк-Көнбатыш Азия илләре нефтькә, табигый газга, тимер рудасына, уранга, төсле металл рудаларына бай.

2. Көньяк Азиядә авыл хуҗалыгы продуктларыннан: дөге, банан, хөрмә, бодай, чәй, мамык, йон аерылып тора.

3. Японияиең төп дүрт утравы арасыннан кайсысы икътисади яктан алга киткән булып санала: 1) Хоккайдо утравы, 2) Хонсю утравы, 3) Кюсю утравы, 4) Сикоку утравы?

**Ялгыш җавапларны төшереп калдырыгыз:**

Япония: кара металларны, автомобильләр, диңгез суднолары, электроника әйберләрен, күмер, нефть, тимер рудасы, агач материаллар, терлекчелек продуктларын читкә чыгара.

**Булдыра аласызмы:**

1. Текстта һәм тексттагы карталарда телгә алынган түбәндәге илләрне: Монголия, КХДР, Таиланд, Сингапур, Әфганстан, Иран, Гыйрак, Сүрия, Төркия, Израильне дөньяның контурлы картасына хәтердән төшерә аласызмы?

2. Текстта һәм тексттагы карталарда искә алынган Шанхай, Осака, Джакарта, Бангкок, Мумбаи, Кабул, Эр-Рияд, Истанбул, Сидней, Мельбурн шәһәрләрен картада күрсәтә аласызмы?

3. Түбәндә саналган илләрнең: КХДР, Камбоджа, Корея Республикасы, Сингапур һәм Гыйракның кайсылары яңа индустриаль илләргә керүен әйтә аласызмы?

4. Түбәндә саналган башкаларның кайсылары диңгез буе шәһәрләре икәнен әйтә аласызмы: Улан-Батор, Пекин, Токио, Сеул, Ханой, Дәһли, Багдад, Әнкара, Бәйрут?

5. Австралиянең биш зур шәһәрен атый аласызмы?

**Түбәндәге фикерләр кайсы илләргә кагыла:**

1. Халык тыгызлыгы буенча ил дөньяда беренче урында тора (микродәүләтләрдән башка).

2. Нефть запаслары буенча ил дөньяда беренче урында тора.

3. Сугарулы җир мәйданнары буенча ил дөньяда беренче урында тора.

4. Бердәмлек составына кергән материк-ил.

## 7 НЧЕ ТЕМАГА МЕТОДИК АЧКЫЧЛАР

### Боларны исегезгә төшерегез

1. Азия чит илләре, аларның сәяси картасы һәм халыклары. (География, 7 нче сыйныф.) 2. Азия чит илләренең һәм Австралиянең физик-географик урыны, рельефы, файдалы казылмалары, климаты, сулары, туфрагы һәм үсемлекләр дөньясының үзенчәлекләре, алар эчендәге табигый зоналар. (География, 7 нче сыйныф.) 3. Азиянең борынгы һәм урта гасырлардагы дәүләтләре. (Тарих, 5, 6 нчы сыйныфлар.) 4. XIX гасыр ахыры — XX гасыр башында Кытай, Һиндстан һәм Япониянең тарихи үсеш үзенчәлекләре. (Тарих, 8, 9 нчы сыйныфлар.) 5. Дәреслекнең I кисәгендәге материаллар. 6. Төшенчәләр һәм терминнар: климатик пояслар, муссоннар, туфрак эрозиясе, мелиорация, сугарылусыз игенчелек, резервация.

### Боларны үзләштерегез

**7 нче теманың төп идеяләре:**

1. Соңгы унъеллыкларда Азия чит илләренең һәм Азия-Тын океан регионының дөнья сәясәтендәге һәм икътисадындагы роле һаман арта бара. 2. Азия чит илләре территориясендә тарихи аерым зур мәдәни регионнар барлыкка килгән.

**7 нче темадагы төп фәнни белемнәр:**

1. Азия чит илләренең һәм аның дүрт субрегионының икътисади-географик урыны, табигый шартлары һәм ресурслары географиясе, халкы, промышленносте, авыл хуҗалыгы, табигатьне саклау проблемаларының характерлы сыйфатлары. 2. Кытайның икътисади һәм социаль-географик

характеристикасы. 3. Япониянең икътисади һәм социаль-географик характеристикасы. 4. Һиндстанның икътисади һәм социаль-географик характеристикасы. 5. Австралиянең кыскача характеристикасы. 6. Теманың төп төшенчәләре: 1) этникара һәм дини конфликт, 2) сепаратизм, 3) шәһәрнең шәрык (Азия) тибы, 4) мегалополис, 5) «үсү полюсы».

## Боларны эшли белергә кирәк

1. Ил (регион) авыл хуҗалыгының үсеше өчен кирәкле табигый алшартларга характеристика бирә белергә. 2. Ил (регион) авыл хуҗалыгына характеристика бирә белергә. 3. Ил (регион) халкына характеристика бирә белергә. 4. Дәреслек текстының бер өлешенә логик конспект төзи белергә. 5. Карта-схемалар төзи белергә.

## Мөстәкыйль эш күнекмәләре булдыру буенча күрсәтмәләр һәм планнар

**1. Ил (регион) авыл хуҗалыгы өчен табигый шартларга характеристика планы:**

1. Территориянең рельеф шартлары һәм аларның авыл хуҗалыгы урнашуга йогынтысы. 2. Территориягә агроклиматик характеристика. 3. Территориянең туфрак-үсемлек шартлары. 4. Авыл хуҗалыгын үстерү өчен табигый алшартларга гомуми бәя бирү.

**2. Ил (регион) авыл хуҗалыгы характеристикасы планы:**

1. Тармакның әһәмияте һәм продукциянең күләмнәре. 2. Тармакның үсүе өчен табигый шартлар. 3. Аграр мөнәсәбәтләрнең үзенчәлекләре. 4. Тармакның структурасы, үсемлекчелек һәм терлекчелекнең нисбәте. 5. Үсемлекчелек һәм терлекчелек географиясе, авыл хуҗалыгы районнары (зоналары). 6. Илнең авыл хуҗалыгы продукциясен чит илләрдән кертүгә һәм чыгаруга бәйлелеге. 7. Гомуми нәтиҗә һәм тармак үсешенең перспективалары.

**3. Ил (регион) халкына характеристика планы:**

1. Халык саны, халык яңарып торуның тибы, демографик сәясәт. 2. Халыкның яше һәм җенси составы, хезмәт ресурслары белән тәэмин ителеш. 3. Халыкның милли (этник) составы. 4. Халыкның иҗтимагый-сыйнфый составы. 5. Халык урнашуның төп билгеләре, бу урнашуга миграциянең йогынтысы. 6. Урбанизация дәрәҗәсе, темплары һәм формалары, төп шәһәрләр һәм шәһәр агломерацияләре. 7. Авыл халкының урнашуы. 8. Гомуми нәтиҗә. Халык саны үсү һәм хезмәт ресурслары белән тәэмин ителү перспективалары.

# 8 нче тема. АФРИКА

Африка 30,3 млн км$^2$ мәйданны били, халкы 905 млн кеше (2005 ел). Дөньяда колониаль изүдән һәм коллар белән сәүдә итүдән Африка кебек газап чиккән бүтән континент юк. XX гасыр башына Африка тулысынча колониаль материкка әверелде, һәм бу күп яктан аның артта калуына сәбәп булды.

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң колониаль система акрынлап бетерелде, һәм хәзер континентның сәяси картасында — 54 мөстәкыйль дәүләт (утраудагылары белән). Аларның барысы да диярлек үсеп килүче илләр рәтенә керә. Көньяк Африка Республикасы икътисади үсеш алган дәүләтләр тибына керә.

Икътисади һәм социаль үсешнең төп күрсәткечләре буенча Африка башка эре регионнардан сизелерлек артта, өстәвенә бу артталык кайбер илләрдә һаман көчәя бара.

## 1. АФРИКАГА ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКА БИРӘБЕЗ

**1. Территориясе, чикләре, урыны: зур эчке аерымлыклар. Дәүләт төзелеше.** Африка территориясе төньяктан көньякка 8 мең км га, ә көнбатыштан көнчыгышка 7,5 мең км га сузылган. Африка илләренең күбесе Европа илләреннән зуррак.

**Мисал.** Африканың мәйданы ягыннан иң зур иле — Судан (2,5 млн км$^2$). Ул Европа илләреннән иң зуры булган Франциядән 4,5 мәртәбә зуррак. Алжир, Конго ДР, Ливия, Ангола, Эфиопия, КАР мәйданнары Франциянекеннән ике-өч тапкыр зуррак.

Африка илләренең икътисади-географик урынына бәя бирү өчен, төрле критерийларны файдаланырга мөмкин. Иң мөһимнәреннән берсе — диңгезгә чыгу-чыкмавы. Башка бер генә континентта да диңгезләрдән еракта урнашкан (кайвакыт 1,5 мең км) илләрнең саны Африкадагы кебек күп түгел — 15 ил. Континент эчендәге илләрнең күпчелеге иң артта калган илләр санына керә.

Дәүләт төзелеше буенча Африка илләре бер-берсеннән бик аз аерыла: өчесендә генә идарә итүнең монархия формасы сакланып калган («Кушымта»ның 2 нче таблицасын карагыз), калганнары — республикалар, барысы да диярлек президент республикалары. Әмма идарә итүнең республика формасы астында еш кына хәрби, диктатор сәяси режимнары яшеренгән була. Бик еш кына

## 8 НЧЕ ТЕМАНЫҢ ПЛАН-СХЕМАСЫ



биредә дәүләт переворотлары булып тора. [1].

*Африка — территориаль бәхәсләр һәм чик буе конфликтлары киң таралган тагын бер регион.* Күп очракта алар бу континент илләренә колониаль үткәннәреннән мирас булып калган чикләргә бәйле рәвештә барлыкка килә. Мондый кискен конфликтлар Эфиопия һәм Сомали, Марокко һәм Көнбатыш Сахара, Чад һәм Ливия һ.б. арасында яшәп килә. [2]. Шуның белән беррәттән, Африка өчен озакка сузылган гражданнар сугышларына китерүче *эчке сәяси конфликтлар* характерлы.

**Мисал.** Анголада гражданнар сугышы берничә дистә елларга сузылды. Анда хөкүмәтнең сәяси группировкаларына каршы оппозицион группировка (УНИТА) күтәрелеп чыкты. Бу сугышта йөзләрчә мең кеше һәлак булды.

Континенттагы дәүләтләрнең бердәмлеген һәм хезмәттәшлеген ныгыту, аларның бербөтенлеген һәм бәйсезлеген саклау, неоколониализмга каршы тору өчен ***Африка бердәмлеге оешмасы***[1] булдырылды, 2002 елда ул ***Африка Союзы*** итеп үзгәртелә. (1 нче бирем.)

**2. Табигый шартлары һәм ресурслары: Африка илләре үсешенең иң мөһим факторы.** Африка төрле файдалы казылмаларга искиткеч бай. Башка континентлар арасында ул марганец рудалары, хромитлар, бокситлар, алтын, платиноидлар, алмаз, кобальт, фосфорит запаслары буенча беренче урынны алып тора. Өстәвенә минераль чималның югары сыйфатлы булуы игътибарга лаек, еш кына ул ачык ысул белән табыла.

**Мисал.** Африканың файдалы казылмаларга иң бай иле — КАР. Анда нефть, табигый газ, бокситлардан кала казылма ресурсларның бөтен җыелмасы диярлек бар. Бигрәк тә алтын, платина, алмаз запаслары зур. [3].

Ләкин Африкада файдалы казылмаларга ярлы илләр дә бар, һәм бу аларның үсешен тоткарлый. (2 нче бирем.)

Африканың җир ресурслары зур. Биредә яшәүче һәр кешегә эшкәртелә торган җир мәйданы Көньяк-Көнчыгыш Азиядә яисә Латин Америкасындагыга караганда күбрәк туры килә. Өстәвенә континентта әлегә авыл хуҗалыгы өчен яраклы җирләрнең нибары 1/5 е генә эшкәртелә. Әмма җирләрнең деградацияләнүе Африкада да бик зур мәйданда бара. Инде 30 нчы елларда ук Бельгия географы Жан-Поль Гарруа Африкада җирләрнең деградациясе турында «Африка — үлеп баручы җир» дигән китап язган. Ул вакыттан бирле хәл тагын да начарланды. Дөньядагы корылыклы җирләрнең 1/3 е Африкага туры

---

[1] Африка бердәмлеге оешмасы (ОАЕ — Организация африканского единства) 1963 елда оешкан. Аңа Африканың 51 иле керә. ОАЕ штаб-квартирасы Аддис-Абеба шәһәрендә. 2001—2002 елларда ОАЕ Евросоюз үрнәгендә Африка Союзы итеп үзгәртелде. Аның рамкаларында гомумафрика парламенты, бердәм банк, валюта фонды һәм башка дәүләттән өстә торган структураларны булдыру күздә тотыла.

килә. Территориясенең 2/5 өлешенә чүлләнү куркынычы яный.

Африканың **агроклиматик ресурслары**н бер төрле генә бәяләп булмый. Сез Африканың Җирдә иң эссе материк икәнен беләсез, шуңа күрә җылылык ресурслары белән ул тулысынча тәэмин ителгән. Әмма су ресурслары анда чиктән тыш тигезсез бүленгән. *Бу авыл хуҗалыгына, гомумән, кешеләрнең яшәешенә начар тәэсир итә.* Шуңа күрә «Су ул — тормыш» дигән канатлы әйтем Африкага, мөгаен, беренче чиратта туры киләдер. Аның арид өлешләре өчен ясалма сугару зур әһәмияткә ия (әлегә җирнең фәкать 3—4 % ы гына сугарыла). Ә экваториаль пояста, киресенчә, дымлылыкның гадәттән тыш зур булуы яшәү һәм хуҗалык эшчәнлеге өчен төп кыенлыкларны тудыра. Конго бассейнына Африка гидроэнергия потенциалының яртысы диярлек туры килә. [4].

**Урманнарның** гомуми мәйданы ягыннан Африка бары тик Латин Америкасы белән Россиядән генә калыша. Әмма урманнар белән уртача капланганлыгы ягыннан ул нык артта. Өстәвенә урманнарны кисүнең аларның табигый үсешеннән артып китүе нәтиҗәсендә, урманнарның сирәкләнүе куркыныч масштаблар ала. (3 нче бирем.)

**3. Халкы: яңарып торуы, составы һәм урнашу үзенчәлекләре.** Белгәнегезчә, Африка **халкы яңарып торуның** бик югары темплары белән бөтен дөньяда аерылып тора. Шактый дәрәҗәдә бу элек-электән килгән күпбалалык традицияләре белән бәйләнгән. Африкада «акчаң булмау — бәла, әмма балаларың булмау — икеләтә ярлы булу»,— диләр. Өстәвенә континенттагы илләрнең күпчелеге актив демографик сәясәт алып бармый, һәм биредә туу күрсәткечләре югары булып кала бирә.

**Мисал.** Нигер, Чад, Ангола, Сомали, Малида 1 мең кешегә 45—50 яшь бала туры килә, ягъни ул Европадагыга караганда дүртбиш, ә уртача дөнья күрсәткечләренә караганда ике мәртәбә артыграк. Эфиопия, Мали, Уганда, Converting Бенинда бер хатын-кызга 7 һәм күбрәк бала туры килә.

Африка илләре халыкның табигый үсешенең саны буенча да лидерлыкны тоталар («Кушымта»дагы 13 нче таблицаны карагыз).

Менә шуңа күрә, Африка үлүчеләр саны ягыннан әле һаман беренче урында торучы регион булып калса да, аның халык саны бик тиз үсә. *Димәк, Африка әле демографик күчешнең икенче этабында* тора. Бу яшь балалар санының бик югары булып калуын, эш табу, белем бирү һәм сәламәтлек саклау проблемаларының бик нык кискенләшәчәген билгеләр. Өстәвенә Африкадагы халыкның сыйфаты бик түбән: олы яшьтәге кешеләрнең 1/3 дән артыгы укый-яза белми, СПИД белән авыручылар һаман арта бара. [5]. Ир-атларның уртача гомер озынлыгы — 51, хатын-кызларныкы — 52 яшь.

Африкада халыкның **этник составына** бәйле проблемалар да аз түгел. Галим-этнографлар континентта 300—500 һәм аннан да артыграк этнос билгелиләр.

Аларның кайберләре, бигрәк тә Төньяк Африкада, зур милләтләр булып оешкан, ләкин күпчелеге әле халык дәрәҗәсендә; ыруг-кабилә строе калдыклары да сакланып калган.

*Азия чит илләре кебек үк, Африка — күп санлы этник, дәрәсрәге, этник-сәяси конфликтлар таралган регион,* алар аеруча кискен төстә әледән-әле Судан, Кения, Конго Демократик Республикасы, Нигерия, Чад, Ангола, Руанда, Либериядә кабынып торалар. Еш кына алар чын ***геноцид***[1] рәвешен ала.

**1 нче мисал.** 80 нче еллар ахырында Либериядә башланган гражданнар сугышы нәтиҗәсендә, барлыгы 2,7 млн халкы булган илдә 150 мең кеше һәлак булды, 500 мең кеше яши торган урыннарын ташлап китәргә, 800 мең кеше күрше илләргә качарга мәҗбүр булды.

**2 нче мисал.** 1994 елда халык тыгыз урнашкан Руандада тутси һәм хуту кабиләләре арасында бик кискен конфликт килеп чыкты. Шуның нәтиҗәсендә 1 млн кеше һәлак булды, ил эчендәге качакларның саны 500 меңнән алып 2 млн га җитте, тагын 2 млн кеше күршедәге илләргә качарга мәҗбүр булды.

Тулаем алганда, дөньядагы барлык качакларның һәм мәҗбүри күченеп китүчеләрнең яртысы чамасы Африкага туры килә, өстәвенә аларның күпчелеге — нәкъ менә «этник качаклар». Андый мәҗбүри миграцияләр һәрвакыт ачлык, эпидемияләргә сәбәпче була, сабыйларның һәм, гомумән, кешеләрнең үлемен арттыра.

Күп кенә Африка илләрендә дәүләт (рәсми) теле булып элеккеге метрополияләрнең телләре — инглиз, француз, португал теле калу да — үткән заманнар мирасы. [6].

Африканың мәдәни мирасы гаять зур. Мәсәлән, халык авыз иҗаты — фольклор, Борынгы Мисырда туган монументаль архитектура, кыяларга сурәт төшерү сәнгатенең борынгы традицияләрен саклап калган декоратив-гамәли сәнгать. Африкада һәр халыкның диярлек үз музыкаль мәдәнияте бар, һәр халык җыр һәм бию, музыкаль инструментлар үзенчәлекләрен саклый. Бик борынгы заманнардан ук театрлаштырылган йолалар, ритуаллар, ритуаль битлекләр һәм башкалар яшәп килә. Африкада Бөтендөнья мирасының 109 объекты аерымланган («Кушымта»дагы 10 нчы таблицаны карагыз). Алар арасында мәдәни мирас объектлары өстенлек итә, табигый объектлар да күп. [7].

Африкада **халыкның уртача тыгызлыгы** (1 км$^2$ га 30 кеше) Европа һәм Азия чит илләренә караганда берничә мәртәбә кимрәк. Азиядәге кебек үк, аңа да халыкның таралып утыруына бик кискен аерымлыклар хас. Сахарада дөньяның бөтенләй кеше яшәми

---

[1] **Геноцид** (грек. *genos* — ыруг, кабилә һәм лат. *caedo* — үтерәм) — раса, милләт, этник һәм дини билгеләр буенча халыкның бөтен бер төркемнәрен юк итү.

торган иң зур урыннары бар. Дымлы тропик урманнар зонасында да халык сирәк утырган. Әмма кеше бик күп яши торган урыннар да бар, бигрәк тә диңгез буйларында. Аерым илләр өчен тагын да кискенрәк капма-каршылыклар хас.

**Мисал.** Мисыр — моңа классик мисал. Чынлыкта аның халкы тулысынча диярлек (80 млн кеше) барлык мәйданның нибары 4 % ын тәшкил иткән Нил дельтасы һәм үзәнлегендә яши (1 млн км²). Бу — 1 км² га биредә 2000 кеше туры килә дигән сүз, ә чүлдә 1 кеше дә туры килми.

Урбанизация дәрәҗәсе буенча Африка әле һаман да башка регионнардан нык артта. Бу — шәһәр халкы өлешенә дә, зур шәһәрләр һәм миллионер шәһәрләр санына да кагыла. Африкада шәһәр агломерацияләре оешу әле башланып кына килә. *Әмма урбанизация биредә дөньяда иң югары темплар белән бара;* кайбер шәһәрләрнең халкы 10 ел саен икеләтә арта.

Моны миллионер шәһәрләрнең үсеш мисалында да күзәтергә мөмкин. XX гасырның 20 нче елларында шундый шәһәрләрнең беренчесе Каһирә булды. 1950 елда алар икәү генә иде, ә инде 1980 елда 8 гә, 1990 елда 27 гә җитте, аларда яшәүчеләр саны шуңа тәңгәл рәвештә 3,5 млн нан 16 һәм 60 млн кешегә җитте. XXI гасыр башында Африкада инде 1 млн нан артык кеше яшәгән 40 агломерация исәпләнә иде. Аларда шәһәр халкының 1/3 өлеше тупланган. Бу агломерацияләрнең икесе (Лагос һәм Каһирә) 10 млн нан артык кеше яшәгән бик эре шәһәрләр «категориясенә» чыктылар. Мондый «шәһәрләр шартлавы» тискәре нәтиҗәләргә дә китерә. Нигездә, башкала шәһәрләре һәм «икътисади башкалалар» үсә, һәм әлеге үсеш бертуктаусыз агылып торган авыл халкы исәбенә бара, ә бу халыкның яшәү чыганаклары юк, һәм алар шәһәр читләрендәге корылган алачыкларда урнашалар.

**Мисал.** Соңгы вакытта халык саны буенча Лагос (Нигерия) Африкада Каһирәдән соң икенче урынга чыкты. Әле 1950 елда гына аның халкы 300 меңгә дә җитми иде, ә бүген ул (агломерация чикләрендә) 10 млн нан артып китте! Ләкин халкы гаять тыгыз булган бу шәһәрдә (өстәвенә үз вакытында ул португалиялеләр тарафыннан кечкенә генә утрауда салына башлаган) тормыш шартлары шулкадәр начар ки, 1992 елда башкала бүтән шәһәргә — Абуджага күчерелә.

Континентның аерым субрегионнары арасында урбанизация дәрәҗәсе буенча Төньяк һәм Көньяк Африка аерылып тора. Тропик Африкада ул түбәнрәк дәрәҗәдә. Әмма шәһәр халкы санында башкала шәһәрләренең өлеше гипертрофияләнгән югарылыгы буенча Тропик Африканың кайбер илләренә тиңнәр юк. (8).

Шәһәрләрнең гаять тиз үсүенә карамастан, африкалыларның 2/3 се әле һаман авыл җирендә яши. (4 нче бирем.)

**4. Хуҗалыгы: тармак һәм территориаль структурасы, Африканың дөньяда тоткан урыны.** Бәйсезлек яулап алганнан соң, Африка илләре тырышлыкларын гасырлар буе

яшәп килгән артталыкны бетерүгә юнәлттеләр. Табигый ресурсларны национальләштерү, аграр реформа үткәрү, икътисадны планлаштыру, милли кадрлар әзерләү үзенә бертөрле әһәмияткә ия булды. Нәтиҗәдә үсеш темплары тизләште. Тармакларны һәм хуҗалыкның территориаль структурасын үзгәртеп кору башланды.

Тармак структурасында промышленностьның, житештермәүче сфераның өлеше артты. Шуңа да карамастан күпчелек илләрдә әле **хуҗалыкның тармак структурасының колониаль тибы** сакланып кала. Аны аерып торучы билгеләр: 1) аз товарлыклы, түбән продуктлы авыл хуҗалыгының өстенлек итүе, 2) эшкәртү промышленностеның аз үсеш алуы, 3)транспортның нык артталыгы, 4) житештермәүче сфераның башлыча сәүдә һәм хезмәт күрсәтүләр белән чикләнгәнлеге. Тармак структурасынын колониаль тибы өчен шулай ук икътисадның берьяклы гына үсеше хас. Күп илләрдә мондый берьяклылык **монокультура** дәрәҗәсенә җитте. *Монокультуралы (монотоварлыклы) специальләшү ул — ил хуҗалыгының бертөр, кагыйдә буларак, чимал яки азык-төлек җитештерү буенча тар специальләшүе, башлыча алар читкә чыгару өчен билгеләнә.*

Монокультура — табигый күренеш кенә түгел, бәлки тарихи һәм социаль күренеш тә. Африка илләренә ул әле колониаль чорда ук тагылган иде. Һәм бүген шундый тар халыкара специальләшү нәтиҗәсендә дистәләгән илләрнең бөтен тормышы читкә чыгарыла торган бер-ике товарга — кофе, какао, мамык, арахис, май пальмасы җимешләре, шикәр, тере терлек һ. б. дөнья соравының нинди булуына, ягъни аның ни дәрәҗәдә кирәклегенә бәйле булып кала. [9]. Монокультура илләре күп тармаклы икътисад булдырырга омтылалар, ләкин әле бик азлары гына бу юлда уңышка ирешге.

Дөнья хуҗалыгында Африканың урыны менә ни өчен башлыча тармакларның ике төркеме белән билгеләнә. Аларның беренчесе — тау казылмалары чыгару промышленносте. Безнең көннәрдә файдалы казылмаларның күп кенә төрләрен чыгару буенча Африка мөһим, ә кайвакыт хәтта дөньяда монополия урынын алып тора (8 нче таблицаны карагыз). Табылган ягулык һәм чималның төп өлеше дөнья базарына чыгарылганлыктан, *хезмәтнең халыкара географик бүленешендә Африканың урынын беренче чиратта нәкъ менә файдалы казылмаларны табу һәм чыгару промышленносте билгели.* Африканың дөнья хуҗалыгындагы урынын билгели торган икенче тармак — тропик һәм субтропик игенчелек (8 нче таблицаны карагыз). Ул да продукцияне читкә чыгаруга юнәлтелгән. (5 нче бирем.)

Африка хуҗалыгының территориаль структурасында да кайбер үзгәрешләр булды. Югары товарлыклы үсемлекчелек һәм экстенсив көтүлекле терлекчелек

77

77 нче рәсем. Африкадагы монокультура илләре

78 нче рәсем. Алжирда гарәп шәһәре

8 нче таблица

**Деньяның тау казылмалары чыгару промышленносте һәм авыл хуҗалыгы продукцияләрендә Африканың өлеше**

| Тау промышленносте | Өлеше % ларда | Авыл хуҗалыгы | Өлеше % ларда |
|---|---|---|---|
| Алмаз | 48 | Какао | 65 |
| Алтын | 33 | Маниока | 54 |
| Кобальт рудалары | 75 | Сизаль | 26 |
| Хромитлар | 44 | Пальма чикләвеге төше | 39 |
| Марганец рудасы | 33 | Арахис | 22 |
| Уран | 37 | Кофе | 18 |
| Фосфоритлар | 28 | Тары һәм сорго | 15 |
| Бакыр рудалары | 12 | Зәйтүн | 15 |
| Бокситлар | 18 | Чәй | 15 |



78

районнары белән беррәттән, берничә шактый зур чыгару промышленносте районы да оешты. Ләкин эшкәртү промышленностеның кустарь-һөнәрчелек дәрәҗәсендәге роле хуҗалыкның географик сурәтен болдыру өчен җитәрлек түгел. Транспорт инфраструктурасы да нык артта калган.

Тулаем алганда, социаль-икътисади үсеше ягыннан дөньяның зур регионнары арасында Африка соңгы урынны алып тора. Сахарадан көньяктарак урнашкан Африканың дөнья ТЭПда өлеше бары 1,2 %.

80 нче елларда тирән кризиска тарыгач, Африканың социаль-икътисади хәле бигрәк тә начарланды. Үсеш темплары акрынайды. Азык-төлек җитештерү белән (еллык үсеш 2 %) халык ихтыяҗлары арасындагы аерма (үсеш 3 %) зурайды; нәтиҗәдә ашлыкны читтән кертү артты. Өстәвенә Африкада моңарчы күрелмәгән корылык булды. Ул континентның яртысыннан артыгын биләп алды һәм турыдантуры 200 млн кешегә кагылды. Африканың Көнбатыш илләренә дә бурычы күп иде. Менә шуңа күрә дә аны еш кына «бәла-казалы континент» дип атап йөртә башладылар.

90 нчы елларда Африка континентында гомуми социаль-икътисади хәл бераз яхшыра төште. Ләкин бер үк вакытта үсеш темпларын тизләтүгә ирешкән һәм элеккечә «аутсайдерлар» хәлендә калган илләр арасында аерма артты. (6 нчы бирем.)

## 2. ТӨНЬЯК ҺӘМ ТРОПИК АФРИКА СУБРЕГИОННАРЫН ЧАГЫШТЫРЫП КАРЫЙБЫЗ. КАР

**1. Африканы субрегионнарга бүлү: төп ике субрегион.** Африканың икътисади районнарга бүленүе әле тәмамланмаган. Дәреслекләрдә, шулай ук фәнни әдәбиятта аны, гадәттә, ике зур табигый һәм мәдәни-тарихи субрегионга: Төньяк Африкага һәм Тропик Африкага (яисә «Сахарадан көньяктарак Африка»га) бүләләр. Тропик Африка составында үз чиратында Көнбатыш, Үзәк, Көнчыгыш һәм Көньяк Африканы (әмма КАРдан башка) аерып күрсәтү кабул ителгән.

**2. Төньяк Африка территориясе рәвеше.** Төньяк Африканың гомуми мәйданы 10 млн км$^2$ га якын, халкы 200 млн га якын. Субрегионның урынын иң элек аның Урта диңгезгә караган «фасады» билгели, шул сәбәпле Төньяк Африка Көньяк Европа һәм Көньяк-Көнбатыш Азия белән күрше диярлек, һәм ул Европадан Азиягә илтә торган төп диңгез юлына чыга. Регионның «тыл»ын Сахараның кеше аз яши торган урыннары тәшкил итә.

Төньяк Африка — Борынгы Мисыр цивилизациясенең бишеге, аның дөнья мәдәниятенә керткән өлешен сез инде беләсез. Антик чорда Урта диңгез буе Африкасы Римның мул иген үстерүче өлкәсе булып саналган;

жансыз ком һәм ташлар арасында җир астында су җыю галереялары, башка төрле корылмаларның эзләрен әле бүгенге көнгә кадәр очратырга була. Диңгез буендагы күп кенә шәһәрләр борынгы Рим һәм Карфаген бистәләреннән калкып чыккан. Халыкның этник составына, аның мәдәниятенә, диненә һәм яшәү рәвешенә VII—XII гасырлардагы гарәп колонизациясе гаять зур йогынты ясаган. Төньяк Африканы әле безнең көннәрдә дә гарәп Африкасы дип йөртәләр: аның бөтен халкы диярлек гарәп телендә сөйләшә [10] һәм ислам динен тота.

*Төньяк Африканың хуҗалык тормышы диңгез буе полосасында тупланган.* Эшкәртү промышленностеның төп үзәкләре, субтропик игенчелекнең төп районнары, шул исәптән сугарулы җирләрдәге игенчелек районнары да шушында урнашкан. Региондагы барлык халыкның диярлек шул полосада тупланאיы табигый. Авыл җирендә кешеләр яссы түбәле, җир идәнле балчык өйләрдә яшиләр.

Шәһәрләрнең дә тышкы күренеше бик үзенчәлекле. Шуңа күрә географлар һәм этнографлар аерым бер **шәһәрнең гарәпчә тибын** аерып күрсәтәләр, аның өчен, Шәрыктагы башка шәһәрләрдәге кебек үк, ике өлешкә — иске һәм яңага бүленү хас.

Шәһәрнең иске өлешенең үзәге булып гадәттә *касба* — калку урынга урнашкан ныгытма (цитадель) хезмәт итә. Касбаны тыгыз бөҗра булып яссы түбәле, тоташ коймалы тәбәнәк кенә йортлардан торган кварталлар уратып алган. Ул шәһәрләрнең иң күренекле урыны — утә чуар шәрык базарлары. Иске шәһәр еш кына саклагыч стеналар белән уратып алынган була, бу шәһәрне *мәдинә* дип йөртәләр, гарәпчә ул «шәһәр» дигән сүз (78 нче рәсемне карагыз). Мәдинәдән соң ук шәһәрнең яңа, заманча өлеше башлана.

Барлык бу контрастлар тышкы күренешләрендә милли үзенчәлекләр генә түгел, космополитик үзенчәлекләр дә чагылган иң зур шәһәрләрдә күбрәк күренә. Мөгаен, беренче чиратта бу Мисырда гына түгел, ә бөтен Африкадагы иң зур шәһәргә — барлык гарәп дөньясының мөһим сәяси, мәдәни һәм дини үзәге булган Каһирәгә кагыладыр. Каһирә гаять уңайлы урында — Нилның тар гына үзәне уңдырышлы Дельтага — дөньяда иң яхшы озын сүсле мамык үстерелә торган төп мамык игү районына күчкән урында утырган. Бу өлкәне Дельта дип Геродот атаган, конфигурациясе белән ул борынгы грекларның «дельта» хәрефен хәтерләтә (атластагы картаны карагыз). 1969 елда Каһирә үзенең 1000 еллыгын билгеләп үтте.

Субрегионның көньяк өлешендә халык бик аз яши. Иген игүче халык оазисларга тупланган, анда кулланыла һәм сатыла торган төп культура — хөрмә пальмасы. Калган территориядә (анда да бөтен урында түгел) фәкать дөя үрчетүче күчмә халык кына яши, ә Сахараның Алжир һәм Ливия өлешендә нефть һәм газ промыселлары урнашкан.

Чүл патшалыгына бары тик Нил үзәне буйлап сузылган тар

гына «тормыш полосасы» көньякка таба еракка үтеп керә. СССРның икътисади һәм техник булышлыгы белән Нилда Асуан гидроузелын төзү бөтен Югары Мисырның үсеше өчен бик зур әһәмияткә ия булды. [11]. (7 нче бирем.)

**3. Тропик Африка территориясе рәвеше.** Тропик Африканың гомуми мәйданы 20 млн км$^2$ дан артык, халкы — 600 млн. Аны тагын «кара Африка» дип тә атыйлар, чөнки субрегион халкының төп өлеше экваториаль расага (негроид) керә. Әмма этник составы ягыннан Тропик Африканың аерым өлешләре шактый нык аерыла. Барыннан да бигрәк ул Көнбатыш һәм Көнчыгыш Африкада катлаулы, анда, төрле расалар һәм тел семьялыклары кисешкән урында, иң күп этник һәм сәяси чикләр барлыкка килгән. Үзәк һәм Көньяк Африка халкы банту («кешеләр» дигән сүз) семьялыгына керә торган кардәш, ләкин бик күп төрле телләрдә (диалектлар белән бергә 600 гә кадәр) сөйләшә. Суахили теле бигрәк тә киң таралган. Ә Мадагаскар халкы австронезия семьялыгына керә торган телләрдә сөйләшә. [12].

Тропик Африка илләренең хуҗалыгы һәм халкының урнашуында да уртак яклар күп. *Тропик Африка — барлык үсеп килүче дөньяның иң артта калган өлеше,* анда иң түбән үсешле 29 ил урнашкан. Бүгенге көндә бу — дөньяда материаль җитештерүнең төп сферасы авыл хуҗалыгы булып калган бердәнбер зур регион.

Авылда яшәүчеләрнең яртысы диярлек натураль авыл хуҗалыгы, калганнары түбән товарлыклы хуҗалык алып бара. Туфракны китмән белән эшкәртү өстенлек итә, сука юк диярлек; китмәннең кайбер Африка илләренең дәүләт гербына игенчелек хезмәтенең символы буларак керүе очраклы түгел. Барлык төп авыл хуҗалыгы эшләрен хатын-кызлар һәм балалар башкара. Алар тамыразыклар һәм бүлбеле яшелчәләр игәләр (маниока яисә кассава, ямс, батат), шулардан он, ярма ясыйлар, ботка, тәбикмәк пешерәләр, шулай ук тары, сорго, дөге, кукуруз, банан, яшелчә үстерәләр. Терлекчелек аз үсеш алган, шул исәптән цеце чебене аркасында да, ә инде шактый зур роль уйнаган очракта да (Эфиопия, Кения, Сомали), чиктән тыш экстенсив алып барыла. Экватор урманнарында аучылык, балыкчылык, җыючылык белән көн күрүче кабиләләр әле дә бар. Саванналар һәм дымлы тропик урманнар зонасында кешеләр, үз тамакларын туйдыру өчен, урманнарны яндырып һәм төпләп, иген чәчәләр.

Күпьеллык үсемлекләр — какао, кофе, арахис, гевея, май пальмасы, чәй, сизаль, тәмләткечләр өстенлек иткән товарлыклы үсемлекчелек гомуми фонда нык аерылып тора. Бу культураларның кайберләре плантацияләрдә, ә кайберләре крестьян хуҗалыкларында игелә. Кайбер илләрнең монокультурага специальләшүен беренче чиратта нәкъ менә алар билгели дә инде.

Тропик Африканың күпчелек халкы авыл җирендә яши. Саванналарда — елга буйларында урнашкан зур авыллар, ә тропик урманнарда

кечкенә авыллар өстенлек итә. Авыл халкының көнкүреше натураль хуҗалык белән тыгыз бәйләнгән, ул шуның белән көн күрә. Халык арасында җирле традицион йолалар: ата-бабалар культы, фетишизм, табигать рухларына, магия, сихер, төрле бөтиләргә ышану киң таралган. Африкалылар үлгәннәрнең рухлары җирдә кала, ата-бабалар рухы тереләрнең кылган эш-гамәлләрен бик җентекләп күзәтеп тора һәм әгәр дә берәр традицион йола бозыла калса, үзләренә зарар китерә ала дип ышаналар. Тропик Африкада шулай ук Европа белән Азиядән кергән христиан [13] һәм ислам дине дә киң таралган. [14].

*Тропик Африка — доньяда (Океанияне исәпкә алмаганда) иң начар индустрияләштерелгән регион.* Биредә тау казылмалары чыгару промышленностенең бер шактый эре районы — Бакыр поясы Конго Демократик Республикасы һәм Замбиядә урнашкан. Бу тармакның бераз кечерәк берничә ареал барлыкка китерүе турында сез инде беләсез.

*Тропик Африка — дөньяның иң аз шәһәрләшкән регионы* (18 нче рәсемне карагыз). Аның нибары сигез илендә генә миллионер шәһәрләр бар, гадәттә, алар күп санлы провинция шәһәрләре арасыннан ялгыз пәһлеваннар булып калкып торалар. Моңа мисал итеп Сенегалдагы Дакарны, Конго Демократик Республикасындагы Киншасаны, Кениядәге Найробины, Анголадагы Луанданы китерергә була.

Тропик Африка транспорт челтәренең үсеше буенча да бик нык артта калып килә. Бер-берсе белән тоташмаган тимер юллар портлардан эчкәре урнашкан районнарга китә. Күп кенә илләрдә тимер юллар бөтенләй юк. Кечерәк йөкләрне баш түбәсенә куеп, кайвакыт 30—40 км га кадәр ташыйлар.

*Һәм, ниһаять, Тропик Африкада тирә-як мохитнең сыйфаты бик тиз начарлана бара.* Чүлләрнең артуы, урманнарның бетүе, флора һәм фаунаның ярлылануы нәкъ менә биредә куркыныч масштабларга җиткән.

**Мисал.** Корылык һәм чүлләнүнең төп районы — Сахель зонасы, ул Сахараның көньяк чикләре буйлап Мавританиядән Эфиопиягә кадәр уннарча ил территориясе буенча сузыла. 1968—1974 елларда биредә бер генә тамчы да яңгыр төшмәгән, һәм Сахель көйгән-корыган җир зонасына әйләнгән. 80 нче елларның беренче яртысында һәм уртасында коточкыч корылык тагын кабатлана. Миллионлаган кешеләрнең гомере өзелә. Терлекләрнең баш саны бик нык кими.

Бу районда булган хәлне «Сахель фаҗигасе» дип йөртә башладылар. Әмма моңа табигать кенә гаепле түгел. Сахараның «һөҗүме» көчәя баруга терлекләрне бер урында озак көтү, урманнарны барыннан да бигрәк утын өчен юк итү дә «ярдәм итә». [15].

Тропик Африканың кайбер илләрендә флора һәм фаунаны саклау чаралары күрелә, милли парклар булдырыла. Беренче чиратта бу Кениягә кагыла, анда халыкара туризм керемнәре кофены читкә чыгару керемнәреннән генә калыша. [16]. (8 нче иҗади бирем.)

**4. КАР — ике төрле икътисадлы ил.** Сахарадан көньяктарак урнашкан Африка илләре арасында КАР аерым урын алып тора. Беренчедән, урыны буенча ул инде Тропик Африкада түгел.

Икенчедән, ул үсеп килүче илләр рәтенә керми. Инде белгәнегезчә, КАР — континенттагы икътисади үсеш алган бердәнбер ил. Икътисади үсешнең барлык күрсәткечләре буенча Африкада ул беренче урынны алып килә.

**Мисал.** КАР өлешенә территориянең бары тик 5,5 % ы, Африка халкының 5 % ы гына, ә тулай эчке продуктның 1/3 е, ә эшкәртү промышленносте һәм автомобиль паркының 2/5 се туры килә.

Хезмәтнең халыкара географик бүленешендә КАРның йөзен авыр промышленность, барыннан да элек тау казылмалары — алтын [17], платина, алмаз, уран [18], тимер, хром, марганец рудалары, күмер чыгару, шулай ук эшкәртү промышленносте — кара металлургия, машина төзү, химия производстволары билгели. КАРда Африканың иң эре промышленность районы — Витватерсранда барлыкка килде, аның үзәге — Йоханнесбург, ул илнең «икътисади башкаласы» ролен үйный. Авыл хуҗалыгы да шактый зур үсеш дәрәҗәсенә җиткән (бөртекле, субтропик культуралар, нәфис йонлы сарык үрчетү, мөгезле эре терлек асрау).

КАРда континенттагы иң куе транспорт челтәре, зур диңгез портлары, шул исәптән специальләшкән портлар бар (Ричардс-Бей ташкүмерне читкә чыгара).

*Ләкин хәзерге КАРдагы тормышның барлык якларына бу илнең сәяси һәм социаль-икътисади тарихы гаять зур эз салган.*

Бөекбритания, XIX һәм XX йөзләр чигендә Голландиядән күчеп утырган кешеләр — бурлар (африканерлар) яши торган Көньяк Африка территорияләрен басып алып, 1910 елда биредә үзенең доминионын — Көньяк Африка Союзын (КАС) оештыра, һәм ул тагын бер «күчеп килгән капитализм» иленә әверелә. 40 нчы елларда КАС башында торган аз санлы ак тәнлеләр (халыкның 12 % ы) җирле халыкка карата ачыктан-ачык расачыл сәясәт үткәрә башлыйлар, ул барлык сәяси һәм икътисади хакимиятнең ак тәнлеләр кулында туплануына нигезләнгән. Ил территориясенең кечкенә генә бер өлешен биләгән уңдырышсыз җирләрдә башта бантустан дип йөртелгән ун оешма, аннары дүрт «бәйсез дәүләт» һәм алты «үзидарәсез территория» — чынлыкта кара тәнлеләр өчен резервацияләр оештырыла. 1961 елда расачыл Көньяк Африка үзен Көньяк Африка Республикасы (КАР) дип игълан итә һәм Милләтләрнең Британия Бердәмлегеннән чыга.

90 нчы еллар башында гына африкалыларның милли-азатлык хәрәкәте иске расачыл режимның бәреп төшерелүенә һәм ***апартеид***[1]

[1] Апартеид (африкаанс телендә *apartheid* — аерым үсеш) — расачыл дискриминациянең иң соңгы чиккә җиткән формасы. Халыкның нинди дә булса бер төркемен, аерым урыннарда аны территория ягыннан чикләүгә кадәр, сәяси, икътисади һәм гражданлык хокукларыннан мәхрүм итүне яисә шактый сизелерлек чикләүне белдерә.

сәясәтен рәсми рәвештә бетерүгә китерә. КАРны федерализм элементлары булган унитар республика дип игълан иткән яңа Конституция кабул ителә. Яңа административ-территориаль бүленешкә ярашлы рәвештә, КАР тугыз провинциягә бүленә. Ул яңадан Бердәмлек әгъзасы була, ә БМО бу илгә каршы сәяси һәм икътисади санкцияләрне кире ала.

*Әмма, бер яктан, «аклар», икенче яктан, «каралар» һәм «төсле тәнлеләр» арасында зур социаль-икътисади аермалар әле сакланып кала.* Алар тормыш шартларында, хезмәткә түләүдә бигрәк тә нык сизелә. Авыл хуҗалыгындагы Европа секторында югары керемле зур фермалар, ә Африка секторында җирне китмән белән эшкәртү өстенлек итә. *Менә ни өчен КАРны ике икътисадлы ил дип йөртәләр.* Аңа икътисади үсеш алган илләр сыйфатлары да, үсеп килүче илләрнеке дә хас.

**Төп нәтиҗә.** *Гаять зур табигать һәм кеше потенциалына карамастан, Африка дөнья хуҗалыгының иң артта калган өлеше булып кала. Шуңа күрә хәзерге этапның төп бурычы — социаль-икътисади үзгәртеп коруларны тизләтү. Бу катлаулы демография, азык-төлек һәм экология проблемаларын хәл итүгә булышачак.* (8 нче йомгаклау биреме.)

## ӨСТӘМӘ ТЕКСТ (Кызыклы мәгълүматлар)

[1] Бары тик 1970—1990 елларда гына Африкада 25 президентның гомерен өзгән 78 дәүләт перевороты була.

[2] Исәпләүләргә караганда, Африкадагы төрле территориаль бәхәсләр бу континет территориясенең 1/5 өлешенә кагыла. Шуның өстенә дәүләт чикләренең бөтен озынлыгының 40 % ында бөтенләй демаркировка ясалмаган, 44 % ы меридиан һәм параллельләр буенча механик рәвештә, 30 % ы дуга рәвешендәге һәм кыек линияләр буенча үткәрелгән, бары тик 26 % ы гына табигый чикләр, өлешчә этник чикләр белән туры килә торган итеп үткәрелгән.

[3] Көньяк Африкада беренче алмазны 1869 елда көтүче малай таба. Бер елдан биредә Кимберли шәһәренә нигез салына, алмазлы токым шул шәһәр исеменнән кимберлит дип атала башлый. Кимберлитта алмаз бик аз — 0,0000073 % тан артмый, бу — һәр 3 тонна кимберлитта 0,2 г яисә 1 карат алмаз бар дигән сүз. Бүгенге көндә Кимберлида истәлекле урыннарның берсе — алмаз эзләүчеләр казыган 400 м тирәнлектәге «Зур чокыр».

[4] Конго елгасы океанга Амазонкадан биш тапкыр азрак су агызса да, аның гидроэнергетик потенциалы югарырак. Бу аның түбәнге агымындагы 300 км арада елганың 275 м га

түбән төшүе һәм 32 шарлавык булуы белән аңлатыла. Биредә 80—90 млн кВт куәтле гидроэлектростанцияләр төзергә мөмкин, ә бу якынча АКШның барлык гидроэлектростанцияләре куәтенә тигез.

[5] СПИДның ватаны — Тропик Африка хәзергәчә аны таратуның эпицентры (үзәге) булып кала. Әгәр дә алга киткән илләрдә өлкән яшьтәгеләрнең СПИД вирусы белән зарарлану 1 % дәрәҗәсендә калса, Ботсванада бу күрсәткеч 39 %! Зимбабве, Намибия, Замбия, Свазиленда һәм башка илләрдә ул аз гына кимрәк. Әгәр дә хәл үзгәрмәсә, бу илләр якындагы унъеллыклар эчендә СПИДтан балигъ булган халыкның 1/5 өлешен югалтырга мөмкин. Бары тик 2001 елда гына Африкада бу авырудан 2,2 млн кеше үлде (бөтен дөньяда — 3 млн).

[6] Африканың 17 илендә дәүләт теле булып (рәсми тел) француз теле, 11 илдә — инглиз һәм 5 илдә португал теле кала. Шуның өстенә алар күп кенә илләрдә җирле телләр белән бергә кулланыла.

[7] Мәдәни мирас объектлары арасында бөтен дөньяга танылганнары — Борынгы Мисыр (Зур пирамидалар, Луксор, Карнак, борынгы Фив урынындагы Патшалар үзәне, Нубия һәйкәлләре), Төньяк Африкада Рим империясе шәһәрләренең хәрабәләре, Каһирәдә мөселман һәйкәлләре, күп кенә сәяхәтчеләр тарафыннан тасвирланган Малидагы Томбукту, Зимбабведагы Бөек Зимбабве шәһәрләре. Табигый мирас объектлары арасында Серенгети, Нгоро-Нгоро, Килиманджаро, Маунт-Кения, Рувензори милли һәйкәлләре һәм резерватлары, КАРдагы Дракон таулары. Ә Алжирның танылган Тассилин-Аджеры Сахараның борынгы кешеләренең кыя ташларындагы рәсемнәре белән мәдәнитабигый мирас объектларына кертелде.

[8] Бурундиның башкаласы Бужумбурда бу илдәге шәһәр халкының 100 % ы тупланган, Гвинея башкаласы Конакрида — 81 % ы, Конго башкаласы Браззавильдә — 67 % ы, Ангола башкаласы Луандада — 61 % ы, Чад башкаласы Нджаменда — 55 % ы, Буркина-Фасо башкаласы Уагадугуда — 52 % ы.

[9] Африка өчен күп кенә традицион культуралы үсемлекләрнең рәсемнәрен дәүләтләрнең гербларында табарга мөмкин. Кофе агачының рәсеме Кения, Уганда, Танзания гербларын бизи; какао агачы — Гана гербын, майлы пальма — Котд'Ивуар, Либерия, Конго, Руанда гербларын; зәйтүн яки лавр — Алжир, Ливия, Мисыр, Эфиопия гербларын; мамык — Ангола, Танзания, Зимбабве гербларын; шикәр камышы — Маврикий, Мозамбик гербларын; бодай — Алжир, Зимбабве, КАР гербларын; дөге — Мадагаскар гербын, сорго Ботсвана һәм Буркина-Фасо гербларын бизи.

[10] Гарәп телендә уңнан сулга таба язалар. Гарәп алфавитында тартыкларны һәм озын сузык авазларны белдерүче 28 хәреф бар. Сүздәге урыннарыка бәйле рәвештә хәрефләрнең икедән дүрткә хәтле язылышы була ала. Гарәп теленнән Европа телләренә бик күп сүзләр кергән, мәсәлән: алгебра, зенит, магазин, адмирал, тариф, хәлвә, кофе. Урта гасырларда Европа гарәпләрдән цифрлар системасын алган.

[11] 1971 елда Асуан плотинасын сафка керткәннән соң, 500 км озынлыктагы һәм 5 мең км$^2$ дан артык мәйдан биләгән «Насер» сусаклагычы булдырылды. Күләме ягыннан (157 км$^3$) ул дөньяда дүртенче урында тора. Бу сусаклагыч өстәмә рәвештә 800 мең га җирне ел буе сугарырга мөмкинлек бирде, анда елына ике-өч уңыш алалар.

[12] Австронезия телләренең үзенчәлеге географик атамаларда да чагыла. Африканы өйрәнүче язучы С. Кулик Мадагаскардагы торак пунктларның шундый исемнәрен мисалга китерә: Амбинанибеанатсиндраву, Тратрамарананиндрангаронто, Марумиандрахимахавелона.

[13] 1983 елда Кот-д'Ивуарның башкаласын Абиджаннан Ямусукрога күчерү турында карар кабул иткәннән соң, яңа башкалада гаҗәеп Нотр-Дам-де-ла-Пә (Дөнья Алла анасы) католик соборы төзелә, ул зурлыгы буенча Римдагы Изге Петр соборыннан да зуррак. Католиклар бу илдә яшәүчеләрнең 1/5 өлешен генә тәшкил итсә дә, эшләр менә шулай.

[14] Тропик Африканың мөселман илләрендә әле күп хатын алу шактый киң таралган (полигиния). Элегрәк зур кабиләләрдә кайбер башлыкларның берничә йөз хатыны булган; бер ирнең берничә дистә хатыны булу исә гадәти күренеш саналган. Безнең көннәрдә дә шәригать кануны нигезендә мөселман кешесе дүрт хатын алырга хокуклы.

[15] Сахель зонасындагы 10 кешедән тугызының тормышы азык әзерләү һәм торакларын җылыту өчен ягулыклары булу-булмауга бәйле. Гәрчә хатын-кызлар һәм балалар елның 100 көненнән алып 300 көненә кадәр чыбык-чабык эзләп уздырсалар да, алар үзләренең минималь ихтыяҗларын ягулыкка агач-куакларны чиктән тыш күп кискән очракта да канәгатьләндерә алмыйлар. Мондый шартларда суны кайнатып эчү урынсыз кылану булып санала һәм озаграк әзерләнә торган туклыклырак продуктларга, мәсәлән борчакка караганда, тиз пешеп чыга торган бөртекклеләргә өстенлек бирелә.

[16] Кениядә милли парклар һәм тыюлыклар ил территориясенең 15 % ын алып тора. Аларда филләр, мөгезборын, зебра, буйвол, антилопа, жираф, арыслан, леопардлар, күп төрле кошлар яши. Шулай да браконьерлык аркасында филләр кәтүе

соңгы 20 ел эчендә 65 меңнән 20 мең башка гына калды. Илдә хәзер ел саен Фил көне үткәрелә; бу көнне Кения президенты браконьерлардан тартып алынган фил казык тешләреннән торган учакны үзе кабыза.

[17] КАРда алтын чыгару 1886 елда башлана. XIX гасыр ахырына кадәр ул елына 20—50 т дәрәҗәсендә кала, әмма XX гасыр башында 200—300 т га күтәрелә, ә XX гасыр уртасында 600—800 т га җитә (1970 ел рекордлы ел була — 1 мең т). XXI гасыр башында аны чыгару 295 тоннага кадәр кимеде, ләкин КАР бу күрсәткеч буенча дөньяда беренче урында кала.

[18] КАРда уран концентратлары җитештерү 50 нче елларда максимумга (6 мең т) җитә, әмма хәзер ул берничә мәртәбә кимеде. КАР уранының үзенчәлеге шунда: рудада уран чиктән тыш аз микъдарда — уртача бары тик 0,017 % кына. Бу башка илләрнеке белән чагыштырганда күпкә түбән. Мондый хәл биредә уранның, алтынлы рудаларны эшкәрткәндә, өстәмә продукт буларак табылуы белән аңлатыла.

**Китап киштәсе**


1. Африка.— М.: Мысль, 1979—1982.— (Серия «Страны и народы»).
2. Африка: Энциклопедический справочник.— М.: Сов. энциклопедия, 1986—1987.— Т. 1, 2.
3. Максаковский В. П. Географическая картина мира.— М.: Дрофа, 2009.— Ч. 2.— Тема 3.
4. Экономическая и социальная география мира. За страницами учебника: Кн. для учащихся 10 кл./ Сост. А. П. Кузнецов.—М.: Просвещение, 2000.
5. Васильев А. М. Египет и египтяне.—М.: Классика плюс, 2000.


## БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘР АЛУ ӨЧЕН ТУПЛАНМА

**1 нче бирем.** «Кушымта»дагы 1 нче таблицадан файдаланып, контурлы картага Икенче бөтендөнья сугышыннан соң сәяси бәйсезлек алган Африка илләрен төшерегез. Бәйсезлек алу даталарын күрсәтегез һәм шушы нисбәттән Төньяк һәм Тропик Африка илләрен чагыштырыгыз.

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** Дәреслек форзацындагы «визит карточкасы» ярдәмендә Африка илләренең һәм Европа чит илләренең территорияләре буенча бертигез чамада булган тиешле «парлар»ын сайлап алыгыз.

**2 нче бирем.** Атлас карталарын һәм «Кушымта»дагы 3—5 нче таблицаларны файдаланып, Африка илләрен файдалы казылмаларга ни дәрәҗәдә бай булуына карап классификацияләгез. Таблицаны түбәндәге формада төзегез:

| Төрле минераль чимал ресурсларының күп төрләренә бай илләр | Минераль чималның бер-ике төренә бай илләр | Минераль чималга ярлы илләр |
|---|---|---|
| | | |

Авыр промышленностьны үстерү өчен, бу илләрнең чимал һәм ягулык белән тәэмин ителеше турында нәтиҗәләр ясагыз.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Шул ук чыганаклар буенча файдалы казылмаларның төп территориаль бергәлекләрен билгеләгез. Аларның һәркайсындагы казылмаларның составын тасвирлагыз; моны территориянең тектоник төзелеше белән бәйләргә тырышыгыз. Бу бергәлекләрне контурлы картага төшерегез.

**3 нче бирем.** 7, 8, 9 нчы рәсемнәр, «Кушымта»дагы 6, 7, 8 нче таблицалар һәм атлас карталары ярдәмендә Африканың дәреслек текстындагы җир, су һәм агроклиматик ресурслары характеристикасын конкретлаштырыгыз һәм тулыландырыгыз.

**4 нче бирем.** 3 нче таблицаны файдаланып, Африкада «шәһәрләр шартлавы»на санлы характеристика бирегез. Бу исәп-хисапларга таянып нинди нәтиҗәләр ясарга була?

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** «Африка халкы» дигән темага доклад конспекты әзерләгез. Дәреслектәге 3 нче һәм 8 нче темалар текстын һәм рәсемнәрне, атлас карталарын, «Кушымталар»дагы таблицаларны, өстәмә әдәбиятны файдаланыгыз.

**5 нче бирем.** 77 нче рәсемгә анализ ясагыз. Африканың атласта бирелгән икътисади картасын файдаланып, графикта күрсәтелгән һәр илнең монокультурага специальләшүен нинди руда һәм руда булмаган нинди файдалы казылмалар, азык-төлек товарлары һәм авыл хуҗалыгы чималының кайсы төрләре билгеләгәнлеген конкрет күрсәтегез.

**6 нчы бирем.** Африканың атласта бирелгән физик һәм икътисади карталары буенча түбәндәгеләрне билгеләгез: 1) Африканың тау казылмалары промышленностеның төп районнарын һәм аларның специальләшүен, 2) товарлыклы игенчелекнең төп районнарын һәм аларның специальләшүен, 3) трансафрика транспорт магистральләрен. Шулай ук дәреслекнең 5 нче тема рәсемнәрен дә файдаланыгыз.

**Өстәмә иҗади бирем.** Атлас карталарын файдаланып, дәфтәрегездә түбәндәге форма буенча «Африкада читкә чыгарыла һәм кулланыла торган авыл хуҗалыгы культураларының зоналар буенча специальләшүе» дигән таблица төзегез:

| Табигый зона | Читкә чыгарыла торган культуралар | Кулланыла торган культуралар |
|---|---|---|
| 1. Субтропиклар<br>2. Ярымчүлләр һәм чүлләр<br>3. Саванналар һәм сирәк урманлы җирләр<br>4. Дымлы экватор урманнары | | |

Шушы таблицаны анализлап, мөмкин булган барлык нәтиҗәләрне ясагыз.

**7 нче иҗади бирем.** Дәреслектәге текстны һәм атластагы Каһирә планын файдаланып, «Каһирә — Төньяк Африкадагы гарәп шәһәре» дигән темага чыгыш әзерләгез. Шулай ук өстәмә чыганаклар да файдаланыгыз.

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** Үзегезне Нил буйлап Асуаннан елга тамагына хәтле сәяхәткә чыккан дип күз алдына китерегез. Сәяхәтегезне иптәшегезгә язган хатта тасвирлагыз. Бу территорияне ачык күз алдына китерерлек итеп язарга тырышыгыз.

**8 нче иҗади бирем.** Киләчәктә «Сахель фаҗигасе» кабатланмасын өчен, сезнеңчә, нәрсәләр эшләргә кирәк? Үзегезнең «проект»ны нигезләгез.

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** Жюль Верн үзенең «Һава шарында үткән биш атна» дигән романында Африка буйлап сәяхәт итүе хакында сөйли. Бу сәяхәтнең маршрутын «кабатлагыз». Язучы тасвирлаган Африка районнары бүген кайсы илләрдә урнашкан, һәм алар хәзер нинди?

**9 нчы йомгаклау биреме.**

1. (Дәфтәрдә эшләү.) Халкын һәм хуҗалыгын характерлаучы кайбер күрсәткечләр буенча Тропик, Төньяк Африка илләрен һәм КАРны чагыштырыгыз. Охшаш һәм аермалы якларын билгеләгез. Кирәкле мәгълүматларны таблица рәвешендә күрсәтегез.

2. Төньяк Африка һәм Көньяк-Көнбатыш Азиянең файдалы казылмалар чыгару промышленностеның төп тармакларын чагыштырыгыз. Бу чагыштырудан нинди нәтиҗә ясарга була?

3. Тропик Африка һәм Көньяк Азиянең читкә чыгарыла торган төп авыл хуҗалыгы культураларын чагыштырыгыз. Бу чагыштырудан нинди нәтиҗә ясарга була?

4. Дәреслектә күрсәтү өчен «Почта маркаларында Африка географиясе» дигән зур булмаган альбом әзерләгез.

## ҮЗЕГЕЗНЕҢ ҺӘМ БЕР-БЕРЕГЕЗНЕҢ БЕЛЕМНӘРЕН ТИКШЕРҮ ТУПЛАНМАСЫ

**Түбәндәге сорауларга җавап бирегез:**

1. Ни өчен Африкада Азия чит илләренә караганда халык океан һәм диңгез буйларына азрак тартылган?

2. Бакыр поясы районыннан промышленность продукциясен чыгару өчен, Конго елгасы нигә файдаланылмый?

3. Каһирәне нигә «Дельтаның алмаз төймәсе» дип атыйлар?

4. Сенегалны ни өчен «арахис республикасы» дип атыйлар?

**Түбәндәге фикерләрнең дөреслеген тикшерегез:**

1. Африка илләренең күпчелеге бәйсезлекне XX гасырның икенче яртысында алды.

2. Африка — дөньяда туучылар һәм үлүчеләр саны иң зур булган регион.

3. Африка илләре өчен урбанизациянең югары темплары хас.

4. Нигериянең төп файдалы казылмалары — бокситлар.

**Дөрес җавапны сайлап алыгыз:**

1. Халкы ягыннан Африкада иң зур ил ... (Мисыр, Эфиопия, Нигерия, КАР).

2. Төньяк Африканың иң әһәмиятле файдалы казылмалары ... (күмер, тимер рудасы, бокситлар, нефть, табигый газ, фосфоритлар).

3. Иң аз үсеш алган Африка илләренә ... (Алжир, Эфиопия, Чад, Нигер, Сомали, КАР) керә.

4. Тропик Африканың читкә чыгарыла торган төп авыл хуҗалыгы культуралары ... (бодай, тары, мамык, цитруслар, арахис, кофе, какао, натураль каучук, сизаль).

**Булдыра аласызмы:**

1. Текстта һәм текст карталарында телгә алынган Ливия, Алжир, Судан, Гана, Конго, Ангола, Зимбабве, Намибия, Мозамбик, Мадагаскар кебек илләрне хәтерегездән дөньяның контурлы картасына төшерә аласызмы?

2. Текстта һәм карталарда телгә алынган Каһирә, Киншаса, Аддис-Абеба, Найроби, Лагос, Дакар, Луанда, Йоханнесбург шәһәрләрен картадан күрсәтә аласызмы?

3. Түбәндәге төшенчәләр һәм терминнарның мәгънәсен аңлата аласызмы: монокультура, натураль хуҗалык, апартеид?

4. Түбәндә санап кителгән илләрнең кайсылары какаоны төп җитештерүчеләр һәм читкә чыгаручылар икәнен күрсәтә аласызмы: Кот-д'Ивуар, Гана, Нигерия, Танзания, Ангола?

**Түбәндәге раслаулар туры килгән илләрне билгеләгез:**

1. 600 мең км$^2$ мәйданлы утрауда урнашкан ил.

2. КАР территориясе «эчендә» урнашкан илләр.

3. Нигер елгасының урта агымында урнашкан һәм диңгезләргә чыгу юлы булмаган ил.

4. Башкаласы Найроби булган ил.

5. Халкының 98 % ы гомуми мәйданының 4 % тан да кимрәк территориясендә урнашкан ил.

**Түбәндәге җөмләләрне тутырып языгыз:**

1. Бакыр поясы Замбиядән ... көньяк-көнчыгыш өлешенә сузыла.

2. ... — Африкадагы иң күп нефть чыгаручы һәм аны экспортлаучы ил, ОПЕК әгъзасы.

3. КАР Африканың бөтен эшкәртү промышленносте продукциясенең ... җитештерә.

## 8 НЧЕ ТЕМАГА МЕТОДИК АЧКЫЧЛАР

### Боларны исегезгә төшерегез

1. Африканың сәяси картасы һәм халыклары. (География, 7 нче сыйныф.) 2. Африканың физик-географик урыны, рельефы, файдалы казылмалары, климаты, сулары, туфрагы һәм үсемлекләр дөньясының үзенчәлекләре, табигый зоналары. (География, 7 нче сыйныф.) 3. Борынгы Мисыр. (Тарих, 5 нче сыйныф.) 4. Африка халыкларының XIX гасыр ахырында — XX гасыр башында милли азатлык өчен көрәшенең төп эчтәлеге. (Тарих, 8 нче сыйныф.) 5. Дәреслекнең I кисәге материалы. 6. Төшенчәләр һәм терминнар: колония, бантустан, платформа, чүл, саванна, экватор урманы, кимберлит, милли парк.

### Боларны үзләштерегез

**8 нче теманың төп идеяләре:**

Африканың социаль-икътисади структурасын үзгәртеп кору Африка һәм бөтендөнья бердәмлеге халыкларыннан зур көч таләп итә.

**8 нче темадагы төп фәнни белемнәр:**

1. Африканың икътисади-географик урынының, табигый шартлар һәм ресурслар географиясенең, халкы, промышленносте, авыл хуҗалыгы, табигатьне саклау проблемаларының үзенчәлекле сыйфатлары. 2. Монокультура турында күзаллау. 3. Төньяк Африка территориясенең рәвеше. 4. Тропик Африка территориясенең рәвеше. 5. КАРга кыскача характеристика 6. Теманың төп төшенчәләре: 1) тармак структурасының колониаль тибы, 2) монокультура, 3) шәһәрнең гарәпчә тибы.

### Сез нәрсәләр белергә тиеш

1. Дәреслек һәм атласны файдаланып, характеристика бирү өчен кирәкле белемнәрне мөстәкыйль рәвештә табарга. 2. Тармаклар, регионнар һәм шәһәрләргә чагыштырма характеристика бирә белергә. 3. Бирелгән тема буенча докладның конспектын төзи белергә.

# 9 НЧЫ ТЕМАНЫҢ ПЛАН-СХЕМАСЫ



## 9 нчы тема. ТӨНЬЯК АМЕРИКА

Икътисади һәм социаль географиядә «Төньяк Америка» төшенчәсе сезгә 7 нче сыйныфта мәгълүм булганнардан бераз аерыла. Гадәттә, аңа фәкать АКШ белән Канаданы гына кертәләр. Бу регион шушы чикләрдә 331 млн халкы булган 19,6 млн км$^2$ территорияне били (2005 ел). 1992 елда Христофор Колумбның Американы ачуына 500 ел тулу тантаналы төстә билгеләп үтелде. Төньяк Америка дөнья эшләрендә күренекле урын алып тора.

XX гасырда аның роле аеруча үсте. АКШ белән Канаданың «зур җиде» Көнбатыш илләренә керүен исегезгә төшерегез. Бергәләп алар Европа белән беррәттән дөнья хуҗалыгында бик мөһим үзәк булып торалар.

### 1. АМЕРИКА КУШМА ШТАТЛАРЫНА ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКА БИРӘБЕЗ

**1. Территориясе, чикләре, урыны: уңайлы алшартлар. Дәүләт төзелеше.** Территориясенең зурлыгы ягыннан АКШ дөньядагы илләр арасында дүртенче урында тора. Аның составына өч өлеш керә: 1) көнчыгыштан көнбатышка 4,7 мең км га, ә төньяктан көньякка 3 мең км га сузылган зур дүртпочмаклык формасындагы төп территория (яки АКШ үзе) [1], 2) Аляска, 3) Тын океандагы Гавай утраулары.

АКШның икътисади-географик урыны шактый уңайлы, барлык этапларда да ул илнең үсешенә ярдәм итте. Бу барыннан да элек киң диңгез чикләренең (12 мең км), уңай табигый гаваньнарның булуы һәм бигрәк тә төп территориянең ике океан арасында урнашкан булуы белән аңлатыла. Канада һәм Мексика белән коры җир чикләре шартлы сызыклар, елгалар һәм күлләр буйлап үтә, алар сәүдә-икътисади элемтәләрнең үсешенә ярдәм итә. (1 нче бирем.)

Дәүләт төзелеше буенча АКШ — 50 штаттан торган федератив республика [2] (атлас картасын карагыз). Һәр штатның үз конституциясе, закон чыгаручы һәм башкарма хакимият органнары, сайлап куелган губернаторы, шулай ук үз символикасы бар. [3]. Моннан тыш, территориясендә илнең башкаласы Вашингтон урнашкан Колумбия федераль округы аерылып тора.

Илнең сәяси тормышында төп рольне ике зур партия — демократик һәм республика партияләре уйный.

**2. Халкы: саны, яңарып торуы, тышкы миграцияләр, милли**

**составы, урнашуы.** Халык саны буенча АКШ дөньяда өченче урында тора. Аның халкы ГФР, Франция, Бөекбритания һәм Италия халкының барысын бергә кушып исәпләгәннән дә күбрәк. XX гасыр дәвамында бу сан 3,7 тапкыр артты.

Ләкин АКШның, яшь милләт буларак, халыкның табигый артуы буенча дөньяда беренче урыннарны алып торган вакыты күптән үтте. XX гасыр ахырында бу үсеш сизелерлек кимеде, һәм бу үз чиратында яшь һәм җенес пирамидасында да чагылыш тапты (79 нчы рәсемне карагыз). Бу — АКШ инде хәзер демографик күчешнең өченче этабында тора дигән сүз. Шулай да халыкның еллык уртача абсолют артуы хәзер дә әле 2—2,5 млн кеше тәшкил итеп, киңәйтелгән яңарып торуны тәэмин итә.

Ләкин бер үк вакытта бу үсешнең 40 % ы халыкның табигый артуы исәбенә түгел, ә АКШның халык саны арту тизлегенә һәрвакыт зур йогынты ясап килә торган иммиграция аркасында икәнлеген күздә тотарга кирәк.

**Мисал.** XIX гасыр башыннан алып бу илгә 70 кә якын илдән 60 млн кеше күчеп килде. Әле безнең көннәрдә дә, кайбер чикләүләргә дә карамастан, ел саен 1 млн диярлек кеше легаль рәвештә килә.

Массакүләм иммиграция АКШ халкының милли составын формалаштыруда хәлиткеч рольне уйнады. *Хәзерге Америка милләте ул,— барыннан да элек, дөньяның төрле кисәкләреннән, аеруча Европадан [4] һәм Африкадан күчеп килүчеләрнең этник катнашуы һәм кушылуы нәтиҗәсе.*

XX гасырның икенче яртысында Европадан күчеп килүчеләр саны сизелерлек кимеде, аның каравы Азиядән һәм Латин Америкасыннан килүчеләр саны артты. Соңгылары арасында мексикалылар күбрәк; миллионнарча мексикалы, яшәү чыганагы эзләп, чикне легаль рәвештә дә, яшерен дә үтеп керә. Аларны «брасерос» дип йөртәләр («үз кулларын тәкъдим итүчеләр» дигән сүз). 2000 елда европалылар барлык иммигрантларның 16 % ын гына тәшкил итсә, Латин Америкасыннан чыгучылар — 51 %, Азиядән 27 % ка җитте.

Гәрчә бүген АКШта йөздән артык этнос вәкилләре яшәсә дә, этнограф-галимнәр аларны төп өч этник төркемгә берләштерә: 1) АКШ америкалылары, яки америкалылар, ягъни күчеп килгән төрле милләт вәкилләренең нәселләре, алар өчен инглиз теле хәзер туган тел булып исәпләнә; 2) АКШка чагыштырмача күптән түгел күчкән һәм әле бу илгә «ияләшеп» өлгермәгән күчеш иммигрант төркемнәре; 3) җирле халык — аборигеннар (индеецлар, эскимослар һ. б.).

АКШ америкалылары барлык халыкның якынча 9/10 өлешен тәшкил итә. Әмма бу этник группа бер төрле түгел: ак һәм ак булмаган америкалылардан тора. Шунысы характерлы: акларның өлеше акрынлап кими бара, ә кара һәм төсслеләрнең арта.

Америка милләте составында кара тәнле америкалылар (афроамерикалылар) аерым зур төркем тәшкил итә, аларга Америка халкының 13 %ы туры килә. Элегрәк афроамерикалыларның төп өлеше Көньякта, «кара пояс» дип йөртелгән, XIX гасырда коллык бетерелгәнгә хәтле плантация хуҗалыгы хакимлек иткән җирләрдә яшәгән. Соңгы унъеллыкларда негрларның яртысы Төньяк һәм Көнбатыш шәһәрләренә күчеп урнашты (80 нче рәсем), көньяк штатларда да алар хәзер башлыча шәһәрләрдә яши. [5].

АКШның бөтен тарихында бу илдә афроамерикалыларга карата, хәзер аларның күпчелеге мулатлар, раса дискриминациясе яшәп килгән. Мондый дискриминация еш кына раса ***сегрегациясе***[1], ягъни негрлар белән ак тәнлеләрне аерым яшәтү һәм укыту рәвешен алды, ә бу, табигый ки, кара тәнле халыкларның америка милләтенә тулысынча кушылуына комачаулык итте. XX гасырның икенче яртысында негрларны расачыл дискриминацияләү һәм сегрегацияләүне тыя торган кайбер законнар кабул ителде. Ләкин чынбарлыкта аларның калдыклары әле сакланып калган. Өстәвенә афроамерикалылар арасында ярлылар һәм эшсезләр саны күбрәк.

Чыгышы белән Латин Америкасы илләреннән булган америкалыларның өлеше бик тиз арта, хәзер инде аларның өлеше афроамерикалыларның өлешен узып китте. АТР илләреннән чыгучылар 4 % диярлек. Иммигрантлар һәм күчеш группаларының АКШ халкындагы өлеше — 10 %, ә аборигеннар — 1 %. Халыкның милли составы белән аның дини составы да тыгыз бәйләнгән. [6].

Дөньяда халык аеруча тыгыз урнашкан 20 ил арасында халыкның уртача тыгызлыгы күрсәткече буенча АКШ 18 нче урында тора (1 км² га 31 кеше). Халыкның ил эчендә урнашуында аермалар бик зур.

**Мисал.** АКШның 70 % диярлек халкы ил территориясен нибары 12 %ын биләгән өлешендә яши. Диңгез буендагы (күл буйларындагы) һәм таулы штатлары арасындагы аермалар бигрәк тә зур: 1 км² га 350—400 кешедән 2—5 кешегә кадәр.

Соңгы вакытта халыкның, бигрәк тә пенсионерларның, Төньяк штатлардан («карлы пояс») Көньяк штатларга («кояшлы пояс») эчке миграциясе көчәйде. Тулаем алганда, Техас, Флорида һәм бигрәк тә Калифорния халкы тиз арта.

АКШ халкының урнашуы барыннан да элек шәһәрләр географиясенә бәйле, аларның гомуми саны — 9 мең чамасы. **Шәһәрләрнең Төньяк Америка тибы** үзенчәлекле сыйфатлары белән аерылып тора, аларның күбесе шәһәрләрнең чагыштырмача яшь булуы белән аңлатыла.

[1] Сегрегация (лат. *segregatio* — бүленеп чыгу) — раса яки этник билге буенча халыкның нинди дә булса төркемен мәҗбүри аеру сәясәте.

79

80

81

82

79 нчы рәсем. АКШның яшь-җенес пирамидасы

80 нче рәсем. Афроамерикалыларның АКШта таралып урнашуы

81 нче рәсем. Сан-Францисконың үзәк эшлекле районы

82 нче рәсем. Чикаго шәһәре янында шәхси йортлар

83

84




85




86

83 нче рәсем. АКШтагы «миллионер» агломерацияләр

84 нче рәсем. Нью-Йорк

85 нче рәсем. АКШ мегалополислары

86 нчы рәсем. АКШның Төньяк-Көнчыгыш мегалополисы

Америка шәһәрләренә төгәл турыпочмаклы планлаштыру хас. Гадәттә, үзәк район, яки «даунтаун», аерылып тора, анда идарә итү органнары, банклар, массакүләм информация һәм хезмәт күрсәтү чаралары урнашкан. Зур шәһәрләрнең йөзен, гадәттә, үтә биек биналар (күксөзәрләр) билгели, алар аның көчен һәм куәтен күрсәтеп, чәчәк атуын билгертеп торалар сыман. Шәһәрнең калган урыннарында 3—5 катлы йортлар, ә үзәктән тагын да ераграк шәхси йортлар урнашкан (82 нче рәсем). Бу шәһәрләрнең бик нык «җәелүенә» һәм шәһәр агломерацияләре формалашуга китерә.

*АКШ — типик шәһәр агломерацияләре иле.*

**Мисал.** 1950 елда АКШта 170 шәһәр агломерациясе бар иде, ә 90 нчы еллар ахырына алар 300 гә җитте. Миллионер шәһәрләр АКШта 10 гына, ә миллионер агломерацияләр — 50. Аларда АКШтагы шәһәр халкының яртысы яши.

Бер үк вакытта агломерацияләрнең үзәкләре һәм периферия өлешләре арасындагы нисбәт тә үзгәрде. Җиргә бәянең өзлексез арта баруы, шәхси транспортның күбәюе нәтиҗәсендә, агломерация үзәкләрендә экология һәм транспорт ситуацияләренең начарлануы, урта американың, кечкенә булса да, үз йортында яшәргә омтылуы шәһәр яны зоналарының бик нык зураюына китерде. Хәзер шундый «бер катлы Америкада» барлык гаиләләрнең 2/3 өлеше яши, ә шул ук вакытта шәһәрләрнең үзәк өлешендә халык саны кими башлады. Инде белгәнегезчә, бу процесс *субурбанизация* дип атала.

50 нче елларда Америка географлары АКШта тагын да эрерәк шәһәр төркемнәре — *мегалополислар* формалашуын билгеләделәр. Хәзерге көндә илдә шундый өч мегалополис бар: Төньяк-Көнчыгыш, Күл буе һәм Калифорния мегалополислары. Аларның беренчесен, Бостоннан Вашингтонга кадәр сузылганын, кыскартып «Босваш» дип, икенчесен, Чикаго белән Питтсбург арасында урнашканын, «Чипитс», ә өченчесен (Сан-Франциско — Сан-Диего) «Сансан» дип йөртәләр.

АКШның авыл халкы башлыча аерым урнашкан фермаларда яши. Әмма көнкүреш шартлары буенча авыл тормышы шәһәрнекеннән әллә ни аерылып тормый. *Шунлыктан бөтен илдә шәһәрчә яшәү рәвеше хакимлек итә.* (2 нче иҗади бирем.)

**3. Хуҗалыгына гомуми характеристика: АКШның дөнья икътисадындагы әйдәп баручы урыны.** Инде XIX гасыр ахырында ук, Бөекбританияне узып китеп, АКШ промышленность җитештерүенең күләме буенча дөньяда беренче урынга чыкты. Бүген дә ул икътисадның масштаблары буенча дөньядагы теләсә нинди илдән алда бара һәм үзенең постиндустриаль үсеш дәрәҗәсе буенча лидер илләр төркеменә керә.

АКШның ТЭПы 12,5 трлн долларга җитә, бу дөнья ТЭПының 20 % ын тәшкил итә. Промышленностьның җитештерү күләме («Кушымта»дагы 21 нче таблицаны карагыз), фәнни-техник по-

тенциалы һәм югары технологияле фәнсыешлы продукция эшләп чыгару дәрәҗәсе, җитештермәүче сфераның үсеше, финанс куәте һәм дөнья хуҗалыгы элементларенә тәэсир итү дәрәҗәсе ягыннан (бигрәк тә АКШ долларының, асылда, дөнья валютасына әйләнүен исәпкә алганда) АКШ дөньяда беренче урында тора. АКШның эре транснациональ корпорацияләре (ТНК), турыдан-туры инвестицияләр бирү юлы белән, башка илләрдә күп санлы төрле производстволар булдырдылар, аларны АКШның **«икенче икътисады»** дип атау кабул ителгән. Менә ни өчен бу илгә карата тулай эчке продукт күрсәткечен ***тулай милли продукт***[1] күрсәткеченнән аеру шул дәрәҗәдә мөһим.

Дөнья икътисадында АКШның чагыштырмача өлеше кимесә дә, XXI гасыр башында да бу ил төп социаль-икътисади күрсәткечләр буенча дөньяда әйдәп баручы урынын саклап кала.

АКШның промышленносте югары дәрәҗәдә булуы, җитештерү һәм территория ягыннан тупланганлыгы белән аерылып тора. Ул массакүләм, серияле, шулай ук аеруча катлаулы, уникаль продукция чыгаруны да күздә тота. «АКШта эшләнгән» дигән маркалы әйберләр югары сыйфатлы булулары белән аерылып тора һәм дөнья базарында югары бәяләнә.

АКШ промышленностенда производствоның гамәлдәге барлык тармаклары, кече тармаклары һәм төрләре керә. Шулай да арада бөтендөнья хуҗалыгында илнең «йөз»ен беренче чиратта билгели торганнары аерылып тора. Бу — АКШ өчен инде күптән традиция булып киткән автомобиль төзү. Шулай ук инде Икенче бөтендөнья сугышыннан соң барлыкка килгән авиаракета-космос промышленносте һәм электроника. Нефть промышленностеның әһәмияте бик зур. Автомобиль һәм һава транспортының үсеше, стратегик ихтыяҗларны тәэмин итү белән тыгыз бәйләнгән бу тармак күп яктан илнең икътисади тормышын гына түгел, сәяси тормышын да билгели. АКШ шулай ук микропроцессорлар, мохитне саклау чараларын җитештерүдә, биотехнология һәм биоиндустриядә, информацион технологияләр өлкәсендә дә алда бара.

**Мисал.** 2007 елда АКШта «Интернет»тан файдаланучылар 210 млн нан артып китте. Һәр 1000 кешегә туры килә торган шәхси компьютерлар саны буенча (800) АКШ Япония һәм Көнбатыш Европа илләреннән күпкә өстен.

Авыл хуҗалыгы җитештерүе күләмнәре буенча АКШ дөньядагы теләсә нинди илдән шактый өстен. АКШ агробизнеска беренче булып күчте. АПК сферасында хезмәт җитештерүчәнлеге промышленностька караганда хәтта тизрәк үсә. Күп тармаклы авыл хуҗалыгы, ил ихтыяҗларын гына канәгатьләндереп калмыйча, экспорт

---

[1] Тулай милли продукт (ТМП) — бу әлеге илдә чит ил компанияләре алган табышны чигереп, ләкин әлеге илнең эшкуарлары чит илләрдә алган табышларны кушып саналган тулай эчке продукт.




87

88

87 нче рәсем. АКШның нефть промышленносте

88 нче рәсем. АКШта кара металлургиянең төп районнары

89 нчы рәсем. АКШның промышленность пояслары




90




91

92

90 нчы рәсем. АКШта үсемлекчелек

91 нче рәсем. Европа белән чагыштырганда АКШның географик урыны

92 нче рәсем. Лос-Анджелес. Автомобиль юлларының күпкатлы тармаклануы

93 нче рәсем. АКШның макрорегионнары

93

өчен дә шактый күп продукция җитештерә. Дөньядагы бөртекле ашлык экспортының яртысы чамасы АКШка туры килә.

АКШта авыл хуҗалыгы предприятиесенең төп тибы — продукциясенең төп өлешен сатуга чыгаручы ферма. Агробизнес шартларында **стадияләп специальләштерү** зур үсеш алды, ягъни бу вакытта бердәм җитештерү процессы аерым звеноларга бүленә.

**Мисал.** Помидор үрентеләрен көньяк-көнчыгыш штатлардагы фермерлар үстерә. Аннары бу үрентеләрне самолетлар белән тараталар: Калифорниядә помидорның ашау өчен билгеләнгән сортларын, ә Техаста томат согы өчен үстерәләр.

Фермаларның болай специальләшүе табигый шартлардан иң нәтиҗәле рәвештә файдаланырга, продукциянең арзан һәм югары сыйфатлы булуына ирешергә мөмкинлек бирә. Әмма мондый специальләшү фермаларны базарга һәм әледән-әле үзгәреп торган бәяләргә бик нык бәйләп тә куя.

Транспортның барлык төрләре үсеше буенча да АКШ теләсә нинди башка илне узып китә: Көнбатыш илләрендәге транспорт челтәренең гомуми озынлыгының 1/3 е һәм барлык йөк ташуларның 1/4 е аңа туры килә. *АКШның транспорт системасы (Канада белән бергә) аерым бер* **Төньяк Америка тибын** барлыкка китерә. Аңа транспортның барлык төрләренең үсеше, йөк һәм пассажирлар ташуның бик зур күләмнәрдә булуы, йөкләрнең ерак араларга ташылуы, автомобиль транспортының аерым роль уйнавы хас. XXI гасыр башында илнең автомобиль паркы 230 млн машинадан артып китте («Кушымта»дагы 31 нче таблицаны карагыз).

АКШта автомобиль юл йөрүнең чын-чынлап массакүләм чарасы, американча яшәү рәвеше дип йөртелә торган күренешнең аерылгысыз билгесе булып китте. Эш, ял итү, әйбер сатып алу, күңел ачулар берсе дә автомобильдән башка күз алдына китерелә алмый, автомобиль культы әле XX гасырның 20 нче елларында ук оеша башлаган иде. Махсус кинотеатрлар, банклар һәм хәтта чиркәүләр дә бар: аларда барлык операцияләрне машинадан чыкмыйча гына башкарып була. АКШта *автомобиль — транспорт чарасы гына түгел, ә җәмгыятьтә тоткан урынның үзенә күрә бер символы да.* Барлык гаиләләрнең 4/5 енең автомашинасы бар. Автомобиль аркасында америкалылар дөньяда иң хәрәкәтчел милләткә әверелде. Биредә кешеләр ераклыктан курыкмый. Америкалы үз гомерендә башка ил кешесеннән 13 тапкыр ешрак урыннан урынга күченә. [7].

Материаль булмаган җитештерү һәм хезмәт күрсәтү сферасы бик нык үсеш алган, ТЭПта аның өлеше 79 % тан артып китте («Кушымта»ның 18 нче таблицасын карагыз). Бу АКШның җәмгыятьнең постиндустриаль стадиясенә аяк басуын күрсәтә.

АКШта технопарк һәм технополислар бик күп, аларның күпчелеге университетларда, шул исәптән Гарвард, Йель, Принстон, Стенфорд кебек танылган университетлар каршысында төзелгән.

АКШ хуҗалыгының территориаль структурасына XX гасыр урталарына кадәр территория, табигый ресурслар, транспорт, хезмәт ресурслары, концентрация факторлары аеруча йогынты ясады. ФТР чорында фәнсыешлылык, экология, икътисади-географик урын факторлары аеруча зур әһәмияткә ия. *АКШ хуҗалыгының хәзерге географик сурәте өчен, Европа чит илләреннән аермалы буларак, икътисади тормышның үзәктән «читтәге» районнарда, океан һәм күл буйларында туплануы хас.* Ул шәһәр халкы концентрациясе белән турыдан-туры бәйләнгән: өч мегалополиста илдәге барлык промышленность продукциясенең 3/5 өлеше җитештерелә.

Икътисади алга киткән башка илләрдәге кебек үк, АКШта да шактый көчле *территориаль диспропорцияләр* яшәп килә, нык үскән районнар еш кына депрессив районнар белән күрше була. Илдә шушы диспропорцияләрне киметүгә юнәлтелгән *региональ сәясәт* үткәрелә, ул инде кайбер нәтиҗәләрен дә бирде. Мәсәлән, җитештерүче көчләрнең төньяк штатлардан көньяк һәм көнбатыш штатларга күчә баруы ачык күренеп тора. Әмма депрессив һәм артта калган районнарның күтәрелүе шактый акрын бара. (3 нче бирем.)

**4. Промышленность географиясе: табигый-ресурс алшартлары, төп тармаклар һәм районнар.** АКШта промышленностьның үсеше өчен табигый-ресурс алшартлары бик тә уңайлы.

**Мисал.** Көнбатышның икътисади үсеш алган илләре арасында АКШ табылган күмер запаслары (250 млрд т), нефть (3,0 млрд т), табигый газ (5,6 трлн м$^3$), уран, молибден рудасы, фосфоритлар, күкерт, шулай ук гидроэнергия (375 млрд кВт·сәг) запаслары буенча беренче урында тора.

Файдалы казылмаларның бассейннары һәм чыгу урыннары бөтен ил буйлап таралган, мәсәлән, күмер һәм нефть запаслары 30 дан артык штатта табылды. Тектоник төзелеш үзенчәлекләреннән чыгып, АКШ территориясен ике зур өлешкә бүләргә була: көнчыгыш (платформалы) һәм көнбатыш (җыерчыклы) өлешләр. Көнчыгыш өлешендәге төп байлык — янучан файдалы казылмалар, ә көнбатыш өлешендә — рудалар.

Илдә геологик-эзләү һәм геологик-тикшерену эшләре «тирәнлеккә» дә, «киңлеккә» дә үткәрелә. Алар нәтиҗәсендә нефтьнең перспективалы запасларының яртысы Мексика култыгында континенталь шельф чыганакларына, Калифорния һәм Аляска яр буйларына туры килүе мәгълүм. АКШның төп яңа үзләштерү районында — Алясканың яр буенда — илдәге иң зур нефть чыганагы Прадхо-Бей табылды. [8].

Шуңа да карамастан соңгы вакытларда илдә ресурслар белән тәэмин ителүнең күп кенә проблемалары кискенләште, кайбер чыганаклар бик нык ярлыланган

булып чыкты. Нәтиҗәдә 70 нче елларда дөньяның табигый ресурсларга иң бай илләренең берсе, үз тарихында беренче мәртәбә бу ресурсларның кытлыгы белән очрашты. Бүген ягулык (нефть буенча 60 % ка) һәм чималга булган ихтыяҗларының шактый өлешен АКШ импорт исәбенә канәгатьләндерә. (4 нче бирем.)

Төп тармаклар географиясе. АКШ промышленносте картасына күз салсаң, барлык төп тармакларның күп кенә штатларда нык үскәнлеген күрергә була. Әмма шул фонда, гадәттә, ике-өч штат нык аерылып тора.

Бу ягулык-энергетика промышленностена кагыла.

**1 нче мисал.** Күмер 15 тән артык штатта чыгарыла, әмма илдәге төп «күмер штатлары» — Кентукки, Көнбатыш Виргиния, Пенсильвания; бу штатларда иң эре Аппалач күмер бассейнының бер өлеше урнашкан. Соңгы вакытларда Көнбатыштагы Вайоминг штатының әһәмияте үсә бара, анда күмер ачык ысул белән чыгарыла һәм күкертнең аз булуы белән аерылып тора.

**2 нче мисал.** Электр энергиясе илнең барлык штатларында җитештерелә, әмма электр станцияләренең иң эре тупланмалары Теннесси һәм Вашингтон штатларында. Аларның беренчесендә әле 30 нчы елларда ук Теннесси елгасында ГЭСлар каскады төзелә башлады, соңрак ул тирәдә күп санлы ҖЭСлар һәм АЭСлар калкып чыкты. Ә икенчесендә, Колумбия елгасында, 20 млн кВт куәтле, дөньяда иң зур ГЭСлар каскады корылды.

Нефть промышленносте да шуңа ук охшаш ачык мисал булып тора. (5 нче бирем.)

Кара металлургия турында да шуны ук әйтергә була. Ул илнең Төньягында барлыкка килгән һәм бүгенге көнгә кадәр башлыча Иллинойс, Индиана, Огайо, Пенсильвания, Мэриленд штатларында тупланган. (6 нчы бирем.) Төсле металлургиядә исә төп роль Таулы штатларга туры килә.

Машина төзү промышленностеның урнашуы, нигездә, шәһәрләр һәм агломерацияләрнең урнашуы белән тәңгәл килә. АКШның өч мегалополисына бу бигрәк тә кагыла, чөнки алар төп өч машина төзү районын тәшкил итәләр. Предприятиеләрнең күптөрле булуына карамастан, аерым штатлар тар специальләшүләре белән аерылалар.

**1 нче мисал.** Автомобиль заводлары 26 штатта урнашкан 125 шәһәрдә бар. Әмма автомобильләр Күл буе мегалополисында барыннан да күбрәк җитештерелә. Биредә төп «автомобиль штаты» Мичиган һәм АКШның «автомобильләр башкаласы» Детройт урнашкан. [9].

**2 нче мисал.** Авиаракета-космос һәм электрон промышленностеның эре үзәкләре шулай ук күп кенә штатларда бар. Әмма Тын океан штатлары һәм иң элек Калифорния аерым урын алып тора, анда АКШның «авиаракета-космос башкаласы» Лос-Анджелес урнашкан. Дөньяда иң зур «Боинг» компаниясенең төп биләмәсе булган Сиэтл да зур роль уйный, ул дөньядагы авиалайнерларның 1/2 ен диярлек эшләп чыгара.

Станоклар төзү башлыча Күл буе һәм Төньяк-Көнчыгыш мегалополисларында, авыл хуҗалыгы — Күл буе, судно төзелеше Төньяк-Көнчыгыш мегалополисында тупланган, электроника барлык өч мегалополиста да бар. АКШ промышленностеның күп тармаклары дөньяда иң эре хәрби-промышленность комплексы белән тыгыз бәйләнгән. (7 нче бирем.)

Химия промышленносте — шулай ук дөньяда иң эре промышленность, дистәләгән үзәкләрдә урнашкан, аңа да аерым районнарда аеруча тыгыз туплану хас.

**Мисал.** АКШның төп нефть химиясе һәм газ промышленносте районы Мексика култыгындагы нефть-газ бассейны чикләрендә барлыкка килгән. Биредә 200 дән артык предприятие эшли һәм АКШның «нефть химиясе башкаласы» Хьюстон урнашкан.

Туку промышленносте ике гасыр буена Төньяк Атлантика штатлары — «Яңа Англия»дә (үзәге Бостонда) тупланган иде. Әмма соңгы вакытта бу тармак Көньяк Атлантика штатларына — арзанрак эшче куллар, мамык һәм синтетик сүс җитештерү районнарына, базарга якынрак җирләргә күченде.

**Промышленность районнары һәм пояслары.** АКШ кебек илдә төрле рангта күп кенә промышленность районнарын аерып күрсәтергә мөмкин. Арада иң зурлары өчәү — Нью-Йорк, Лос-Анджелес һәм Чикаго районнары. АКШтагы промышленность районнарының күбесе тагын да эрерәк оешмаларга — промышленность поясларына керә. АКШта дүрт **промышленность поясы** исәпләнә.

Атлантик океаннан Миссисипига хәтле 1,5 мең км га сузылган элекке *Төньяк промышленность поясының роле аеруча зур.* Аңа берничә иске промышленность районы һәм дистәләгән промышленность үзәкләре керә. Гәрчә бу поясның илдәге промышленность җитештерүендә өлеше кими барса да, *ул дөньяда иң зур индустриаль өлкә булып тора.* Соңгы унъеллыкларда формалашкан Көньяк-Көнчыгыш промышленность поясы хезмәтне һәм энергияне күп сорый торган продукция чыгаруда специальләшә, Мексика култыгы (аны гадәттә «Галф» — култык дип йөртәләр) ярларында шулай ук чагыштырмача яңа район нефть эшкәртү һәм нефть химиясе буенча специальләшә. Ә Калифорниядә иң яңа, фәнсыешлы тармаклар өстенлек итә. (8 нче бирем.)

**5. Авыл хуҗалыгы географиясе: табигый алшартлары, төп тармаклары һәм районнары.** Табигать, авыл хуҗалыгын үстерү өчен бик тә уңайлы табигый-ресурс алшартлары булдырып, АКШ территориясен юмарт бүләкләгән.

Илнең җир ресурслары зур, җир фонды структурасы отышлы; эшкәртелә торган җирләр, болыннар һәм көтүлекләр АКШның төп территориясенең 1/2 ен диярлек алып тора. Уңдырышлы Үзәк тигезлекләрдә сөрү җирләре 80—90 % ка кадәр җитә. Авыл хуҗалыгы өчен уңайсыз җирләр Аляскада, Кордильер поясының

биек таулы һәм чүлле районнарында гына өстенлек алган.

АКШның агроклиматик ресурслары да бик бай. Сез моны, АКШ белән Европаның географик урыннарын чагыштырып караганнан соң, әйбәтрәк күз алдына китерә аласыз (91 нче рәсемне карагыз). Температура шартлары биредә уртача һәм субтропик поясларда үсә торган барлык авыл хуҗалыгы культураларын, ә Флориданың көньягында һәм Гавай утрауларында тропик культуралар үстерергә мөмкинлек бирә. Илнең көнчыгыш өлешендә дым белән тәэмин ителеш әйбәт. Әмма 100° меридианнан (ул үзенә бертөрле климатик чик булып исәпләнә) көнбатышка таба игенчелек ясалма сугарганда гына тотрыклы булырга мөмкин. Сугарыла торган барлык җирләрнең 3/4 е менә шуның өчен көнбатыш штатларга туры килә.

АКШта **үсемлекчелек** профилен беренче чиратта барлык мәйданнарның 2/3 сен алып торган бөртекле культуралар билгели. Төп азык культурасы — бодай, әмма терлек азыгы культураларын (кукуруз, сорго) күбрәк җыеп алалар. Майлы культуралар арасында беренче урын соягa туры килә, аның җыемы соңгы унъеллыкларда бик нык артты. Аны азык өчен дә (киң таралган соя мае рәвешендә), терлекләргә ашату өчен дә файдаланалар. Сүсле культуралардан XIX гасырда төп экспорт товары саналган мамык аерым роль уйный. Шикәрле культуралар арасында шикәр чөгендере һәм шикәр камышы чама белән тигез урын тота. Күпчелек американлыларның көндәлек рационына кергән җиләк-җимеш һәм яшелчәләрнең әһәмияте аеруча зур.

АКШта **терлекчелек** профилен иң элек сөт һәм ит өчен мөгезле эре терлек үрчетү билгели. Дуңгыз һәм йорт кошлары үрчетү дә киң таралган. Ит чебешләре (бройлерлар) җитештерү — АКШ авыл хуҗалыгының иң нык индустрияләшкән тармагы, аны авыл җирендә урнашкан промышленность тармагы дип карау дөресрәк булыр. Ел саен 4 млрд ка хәтле бройлер җитештерелә. Аларны теләсә нинди ашханәдә сатып алырга була.

**Авыл хуҗалыгы районнары.** АКШта икътисади үсеш алган илләрдә очрый торган барлык төп авыл хуҗалыгы тармаклары бардыр, мөгаен; галимнәр илдә шундый 13 типны аерып күрсәтәләр. Табигый шартларның гаять төрле булуы, югары товарлылык, авыл хуҗалыгы йөкләрен күпләп ташырга мөмкинлек бирүче транспортның үсеше аерым фермаларның гына түгел, АКШта **авыл хуҗалыгы пояслары** дип йөртелә торган бөтен районнарның да шактый тар специальләшүе өчен алшартлар тудыра. Мәсәлән, Бөек тигезлекләрдә барлыкка килгән бодай поясы. Биредә фермалар бик нык механикалаштырылган, алар — чып-чын «ашлык фабрикалары», ул фермалар еш кына күпләгән мең гектар җир биләп торалар. Шулай ук кукуруз поясы, ул шушы культураны үстерү өчен, искиткеч уңайлы туфрак-климат шартларына ия булган

Үзәк тигезлекләрдә барлыкка килгән; Күл буе һәм Төньяк-Көнчыгыш штатларындагы сөт поясы; Миссисипиның түбәнге агымы буйлап урнашкан мамык поясы; Бөек тигезлекләрнең төньяк өлешендә һәм Таулы штатлар ранчоларындагы терлекчелек поясы. Шулай ук арахис, тәмәке, дөге, җиләк-җимеш һәм яшелчә үстерү буенча специальләшкән районнар хакында да әйтергә мөмкин. [10]. (9 нчы бирем.)

**6. Транспорт географиясе: төп магистральләр һәм узеллар. Тышкы сәүдә.** АКШта транспорт челтәре каркасын Атлантик океаннан Тын океанга һәм Канада чигеннән Мексика чигенә кадәр сузылган киңлек һәм меридиан юнәлешләрендәге трансконтиненталь магистральләр барлыкка китерә. Эчке су юллары челтәре шуларны кабатлаган кебек урнашкан. Киңлек юнәлешендә ул барыннан да элек — 50 нче еллар ахырында тирән су юлына әвереләдерелгән Изге Лаврентий елгасы һәм Бөек күлләр системасы (38 нче рәсемне карагыз). Меридиан юнәлешендә «Америка Иделе» — Миссисипи. Коры җир һәм су магистральләре һәм һава юллары кисешкән урыннарда зур транспорт узеллары барлыкка килгән.

**Мисал.** АКШта иң зур транспорт узелы — Чикаго. Биредә уннарча тимер юл һәм автомобиль юллары бергә килеп тоташа, бик күп төрле йөкләр күчерелә. Чикагодагы «О'Хэйр» аэропорты соңгы вакытларга кадәр дөньяда иң эресе иде. Хәзер беренчелек Атлантага күчте.

Эре транспорт узеллары илнең Атлантик һәм Тын океан яр буйларында, шулай ук АКШның «өченче диңгез яр буе» — Бөек күлләрдә урнашкан күп кенә диңгез портларында барлыкка килгән. Илдә барлыгы йөзгә якын эре порт бар. Порт-промышленность комплексларының иң мөһимнәре — уңайлы табигый гаваньнары булган Атлантик океан яр буеның төньяк участогында һәм Мексика култыгында урнашкан (37 нче рәсемне карагыз).

Эчке базарының бик сыешлы булуы аркасында АКШның икътисады, Европа чит илләре һәм Япония икътисады белән чагыштырганда, ачыклыгы кимрәк булу белән аерылып тора. Шулай да тышкы икътисади элемтәләр бу ил өчен дә зур әһәмияткә ия. *Тышкы сәүдә әйләнешенең күләмнәре буенча АКШ дөньяда беренче урында тора.* Аның товар экспорты промышленность һәм авыл хуҗалыгы продукциясеннән гыйбарәт.

**Мисал.** Тулаем алганда, турыдан-туры яисә читләтеп экспортка промышленность продукциясенең 15 % чамасы чыгарыла (шул исәптән металларның 1/4 е, машиналар һәм химия товарларының 1/5 е). Авыл хуҗалыгы продукциясе күбрәк экспортлана һәм бодайның 1/2, соя борчагы һәм тәмәкенең 1/3, кукурузның 1/5 өлешен тәшкил итә.

Шулай ук АКШ хезмәт күрсәтүләр экспорты буенча да дөньяда беренче урында тора.

АКШ импортында чимал, машиналар һәм җиһазлар өстенлек

итә. Бәясе буенча импорт экспортны узып китә, шуңа күрә илнең сәүдә балансы, гадәттә, пассив. АКШның тышкы сәүдә географиясе исә беренче чиратта аның НАФТАның ике бүтән әгъзасы — Канада һәм Мексика, шулай ук Европа Союзы һәм Япония белән элемтәләре аша билгеләнә.

АКШ — капиталны күпләп читкә чыгаручы ил, башлыча ул Көнбатыш илләренә чыгарыла. Ләкин Европа илләре һәм Японияпең АКШка капитал кертүе дә бик зур. Ул инде АКШ капиталын читкә чыгару белән тигезләште диярлек. Шуңа күрә, әйтүләренчә, «ике як хәрәкәтле урам» формалашты. [11].

**7. Ял һәм туризм географиясе: төп районнар.** Халыкара туризмның үсеше буенча АКШ Европадан шактый калыша, әмма шуңа да карамастан илгә ел саен 40 млн га якын кеше килә. Канада белән күршелек туризмы — иң нык үскән туризм. Эчке туризм, «кунакчыллык индустриясе» (автосервисны да кертеп) бик нык үсеш алган.

АКШ бик зур һәм күп төрле ресурсларга ия, алар нигезендә эре табигый-рекреацион районнар барлыкка килгән. Диңгез буе туризмының төп районнары — Флорида, Калифорния һәм Гавай, тау туризмыныкы — Көнбатыш штатлар, бигрәк тә Кыялы таулар чикләрендә, күл буе туризмыныкы — Күл буе штатлары.

АКШта 50 милли парк бар, аларга ел саен 300 млн нан артык турист килә. Аларның иң атаклылары Көнбатышта — Йеллоустон, Йосемит, Секвойя, Глейшер, Колорадодагы Зур каньон, Аппалачта Грейт-Смоуки-Маунтинс парклары.

Милли парклардан, табигый резерватлар һәм тыюлыклардан тыш, АКШтагы туристлык-рекреацион территорияләр системасына «милли мемориал», «милли тарихи парк», «сугыш кыры милли паркы» кебек категорияләр дә керә һ. б. [12].

**8. Мохитне саклау һәм экологик проблемалар: иң начары артта калды.** 60—70 нче елларда АКШның ныграк индустрияләштерелгән һәм урбанизацияләнгән кайбер районнары экологик кризис чигенә җитте. Файдалы казылмаларны ачык ысул белән чыгаруның киңәюе — «бедленд» мәйданнарының артуына, җылылык энергетикасын үстерү — кислоталы яңгырлар таралуга, автомобильләрнең бик нык артуы — кайбер шәһәрләрнең «корым полисларына» әверелүенә китерде. [13]. Бөек күлләрдә, бигрәк тә Эри күлендә, органик тормыш сүнә башлады. Америка әдәбиятында искитәрлек хәл — яр буенда Кливленд промышленность шәһәре урнашкан елганың... яна башлавы сурәтләнә,— елга суы шулкадәр дәрәҗәдә нефть белән туендырылган дигән сүз!

Шушы шартларда АКШта әйләнә-тирәгә карата милли сәясәт турында федераль закон, соңрак чиста һава турында закон, чиста су турында закон кабул ителде. Табигатьне саклау чараларына чыгымнар арттырылды. Яңа технология кертелә башлады. Илдә куәтле экоиндустрия булдырылды. Җәмәгатьчелек тә шактый активлашты.

Яшьләрнең экологик белемнәрен күтәрү һәм тәрбияләү яхшырды. Нәтиҗәдә әйләнә-тирә мохитнең торышы акрынлап яхшыра башлады. Бөек күлләр һәм аларга коя торган елгалар чистарды, яңадан форель үрчи башлады, Нью-Йорк, Чикаго һ.б. шәһәрләрнең һавасы чистарды. Әмма кайбер районнарда экологик хәл һаман катлаулы булып кала. [14].

## 2. АКШ МАКРОРАЙОННАРЫН ТИКШЕРӘБЕЗ

**1. АКШны макрорайоннарга бүлү: төп дүрт өлеш.** Соңгы елларга кадәр АКШны төп өч икътисади районга бүлеп йөрттеләр: Төньяк, Көньяк һәм Көнбатыш. Әмма 80 нче елларда Америка статистикасы тарихи-мәдәни үзенчәлекләре белән дә, хәзерге социаль-икътисади үсеш характеры белән дә үзгә булган дүрт макрорайонны аерып күрсәтә башлады: Төньяк-Көнчыгыш, Урта Көнбатыш, Көньяк һәм Көнбатыш макрорайоннары (93 нче рәсем).

**2. Төньяк-Көнчыгыш: «милләтнең остаханәсе».** Төньяк-Көнчыгыш — мәйданы ягыннан АКШның иң кечкенә макрорайоны. Ләкин аның ил тормышындагы роле чиктән тыш әһәмиятле булып килде һәм шулай булып кала да.

1620 елда Массачусетс култыгы яр буена Англиядән беренче күчеп килүчеләрне төягән «Мейфлауэр» судносы килеп туктый. АКШның бишеге дип атарга мөмкин булган Яңа Англия менә шулай барлыкка килә; төп америкалыларны билгеләрә торган «янки» сүзе нәкъ менә аларга кагыла. Яңа Англиянең үзәге Бостон — яңа җирләрдә барлыкка килгән беренче шәһәр. АКШта иң элек төзелгән Гарвард университеты да биредә урнашкан (1636 ел). Күчеп килүче инглизләр берникадәр вакыттан соң голландиялеләрдән Манхаттан утравындагы Яңа Амстердам бистәсен сатып алалар һәм аны Англия короле Карл II нең абыйсы, флот командующие герцог Йоркский хөрмәтенә Нью-Йорк дип атыйлар. Тагын да соңрак Филадельфиягә нигез салына, анда 1776 елда АКШның бәйсезлеге турындагы Декларация игълан ителә.

Озак вакытлар буена Төньяк-Көнчыгыш башка районнарга караганда тизрәк үсә. Моңа аның ИГУның уңайлылыгы, ташкүмергә бай булуы, колонияләштерү үзенчәлекләре ярдәм итә. АКШның бу районын «милләтнең остаханәсе»нә әверелдергән промышленность поясы нәкъ менә Төньяк-Көнчыгышта барлыкка килә. XXгасырның икенче яртысында аның күп кенә күрсәткечләре кимесә дә, *ул илнең бик мөһим икътисади районы булып кала.* Халык урнашуның һәм хуҗалыкның географик сурәтен беренче чиратта илнең «Төп урамы» дип йөртелә торган (*Main Street*) Төньяк-Көнчыгыш мегалополисы билгели. Анда илнең икътисади башкаласы Нью-Йорк һәм сәяси башкаласы Вашингтон урнашкан. Алар арасындагы юлны пассажир

экспрессы өч сәгать чамасы вакытта уза.

Нью-Йорк — АКШның иң зур финанс, промышленность, транспорт, сәүдә һәм мәдәният үзәге. Аңа илдәге барлык тулай эчке продуктның 1/10 е туры килә. *АКШның төп финанс үзәге буларак Нью-Йоркның әһәмияте аеруча зур.* Биредә иң эре банклар һәм иминият компанияләренең идарәләре урнашкан. Нью-Йоркның фонд һәм товар биржалары — АКШта гына түгел, бөтен дөньяда иң эре финанс-банк операцияләре үзәкләре.

Нью-Йорк промышленностенда өч төркем тармаклар аерылып тора. Беренчедән, шәһәрнең порт функциясе һәм диңгез юлы белән килә торган чималны — нефть, төсле металларны эшкәртүче авыр промышленность тармаклары. Икенчедән, эшче көчкә һәм кулланучыга йөз тотып урнашкан тармаклар — машина төзү, тегү, азык-төлек тармаклары. Нью-Йоркның «мода чыгаручы» һәм «кулинария башкаласы» дигән даны тикмәгә генә чыкмаган. Өченчедән, аңа шулай ук «яңалыклар башкаласы» дигән шөһрәт китергән полиграфия промышленносте. [15]. Нью-Йорк мәдәният һәм тамашалар дөньясында «закон чыгаручы» ролен уйный. [16].

Нью-Йорк шәһәре үзе биш районнан тора, аларның күбесе Гудзон елгасы тамагындагы утрауларда урнашкан (84 нче рәсем).

Аларның иң танылганы — Манхаттан утравында урнашкан Манхаттан районы. Утрау буйлап сузылган 11 киң авеню һәм аларга перпендикуляр урнашкан 200 тар «стрит» аңа турыпочмаклык формасы бирә. Манхаттанның кайчандыр голландиялеләрнең Яңа Амстердамы булган көньяк өлешендә эшлекле Үзәк район («даунтаун») урнашкан. Биредә иң эре банклар, транснациональ корпорацияләрнең штаб-квартиралары, фонд биржасы, муниципаль учреждениеләр урнашкан; кыска һәм тар Уолл-стрит урамы бигрәк тә яхшы билгеле. Манхаттанның тышкы күренешен үтә биек йортлар (күксөзәрләр) билгели, аларның утызы 200 м дан да биегрәк. Әгәр дә элегрәк шәһәр силуэтында барыннан да бигрәк 30 нчы елларда төзелгән Эмпайр Стейт Билдинг өстенлек итсә, соңрак аңа үзәк эшлекле районда калкып чыккан, Бөтендөнья сәүдә үзәгенең ике игезәк манарасы (110 катлы, 412 м биеклегендә) кушылган. [17]. Әмма бу үзәк 2001 елның 11 сентябрендә террористик акт вакытында җимерелде.

АКШның «баш капкасы» буларак, илгә күчеп килгән иммигрантларның 90 % ын үткәргән Нью-Йоркның халкы милли составы гаять күптөрле һәм чуар булуы белән аерылып тора, анда 177 милләт вәкиле яши, аларның кимендә 2/5 өлешен чагыштырмача күптән түгел күчеп килгән иммигрантлар һәм аларның балалары тәшкил итә. [18]. Нью-Йорк газеталары 15 телдә чыга.

В а ш и н г т о н — 1800 елдан бирле АКШның башкаласы. Нью-Йорктан аермалы буларак, аның төп продукциясе,— образлы итеп әйткәндә, законнар һәм хөкүмәт карарлары. Вашингтон АКШның

башка шәһәрләренә караганда Европа шәһәрләренә күбрәк охшаган. Бу — АКШның үтә биек йортлары булмаган бердәнбер шәһәре, чөнки биредә ил конгрессы резиденциясе Капитолийдан да биегрәк биналар төзү тыелган. Вашингтонда промышленность предприятиеләре аз, нигездә, алар шәһәр халкының ихтыяҗларын канәгатьләндерәләр, аларга хезмәт күрсәтәләр. Бу — эре фән һәм мәдәният үзәге.

Вашингтон шәһәренең нигезе 1791 елда, Потомак елгасының түбәнге агымында АКШның беренче президенты Джордж Вашингтон тарафыннан салына. Башкалага Мэриленд һәм Виргиния штатлары, ягъни Төньяк һәм Көньяк чигендә 10×10 миль зурлыктагы участок бирелә. Шәһәр төгәл турыпочмаклык рәвешендә, ул Капитолийдан һәм президент резиденциясеннән — Ак йорттан башланучы киң авенюлар белән тулыландырылган. [19].

Әгәр дә Яңа Англия озак вакытлар буена АКШның җиңел промышленность районы булса, «Америка Руры» шөһрәтен әле XIX гасырда ук Пенсильваниянең көнбатыш өлеше яулап ала, анда Аппалач бассейны базасында промышленность поясының бер үзәге формалаша. Огайо елгасы буена урнашкан, күмер-металлургия базасының төп үзәге Питтсбург АКШның «металлургия башкаласы» титулын яулап алган.

Әмма менә инде озак вакытлар буена бу иске промышленность районы артка калып килә һәм хәзер депрессив районнар исәбенә керә. Металлургия заводларының барысы да диярлек ябылган, хәзер биредә башка тармаклар һәм хезмәт күрсәтү сферасы үсеп килә. (10 нчы иҗади бирем.)

**3. Урта Көнбатыш: эре промышленность һәм авыл хуҗалыгы районы.** Урта Көнбатышка халык инде XIX гасырда ук күчеп утыра һәм аны үзләштерә башлый. Промышленность поясы территориясе Нью-Йорк һәм Бостоннан акрынлап көнбатышка таба җәелә, ул үз эченә «Америка Урта диңгезе» дип тә йөртелүче Күл буен да ала. Биредә бай ягулык һәм чимал ресурслары һәм икътисади-географик урынның отышлы булуы аркасында Чикаго, Детройт, Кливленд кебек эре промышленность үзәкләре формалаша. XX гасырның икенче яртысында Күл буе мегалополисы барлыкка килә.

Чикагоны хаклы рәвештә Урта Көнбатышның башкаласы дип атарга мөмкин. Моннан 150 еллар элек Бөек күлләр һәм уңдырышлы прерияләр чатында барлыкка килгән бу шәһәр инде күптән куәте һәм динамизмы ягыннан Американың үзенә бертөрле символы, ашлык һәм терлекнең төп базары булып китте.

Ул — шулай ук бик эре финанс, сәүдә һәм мәдәният үзәге һәм, инде белгәнегезчә, АКШтагы иң зур транспорт үзәге. Чикаго — субурбанизациянең бик ачык мисалы. Аның агломерациясенә уннарча иярчен шәһәрләр, «йокы шәһәрләре» керә.

Ләкин Урта Көнбатыш күмер белән тимер рудасына гына бай

түгел. Аның төп байлыкларыннан берсе — чиктән тыш уңайлы туфрак һәм агроклиматик шартлары. *Менә ни өчен Урта Көнбатыш инде күптәннән илнең чынчынлап ишлык келәтенә әверелде.* АКШның нибары 1/5 территориясен биләгән бу өлкә авыл хуҗалыгы продукциясенең яртысы чамасын бирә. Шушы макрорайонда урнашкан эре фермалар, аларның көмеш сыман гөмбәзле силос башнялары әлеге сөт поясының характерлы билгеләре; сөт, май, сыр биредән бөтен илгә тарала. Кукуруз поясы да шунда ук, күп фермалар анда ит өчен дуңгыз һәм башка терлек асрыйлар.

Американы өйрәнүче географ Л. В. Смирнягин кукуруз поясын менә болай тасвирлый: «Бу якларның тышкы күренеше иртә көздә бик тә тәэсирләндергеч: 2—3 м лы мәһабәт кукуруз басуы диңгезне түгел, ә бөтен бер океанны хәтерләтә, анда җил гаять зур дулкыннар кузгата; куе яшел төстәге сорго утраулары, иксез-чиксез сусыл соя кырлары, киртәләр эчендә тук маллар, фермаларның ак һәм кызыл төстәге корылмалары. Болар һәммәсе дә бик әйбәтләп каралган, гөрләп чәчәк атып утыра дигән тәэсир калдыра, һәм бу юкка гына түгел: җирле банк фермерга бирергә җыенган кредит ферманың тышкы күренешенә дә бәйле була».

Язгы бодай поясы да шушында, ул прерияләрнең табигый ландшафтын инде күптән кысрыклап чыгарган. Аларның күз күреме җитмәс киңлекләре буйлап фермалар һәм бетон элеваторлы кечкенә генә шәһәрләр таралган, ул элеваторларга фермерлар үз продукцияләрен илтәләр. Ә көньяктарак — уҗым бодае поясы.

**4. Көньяк: зур үзгәрешләр макрорайоны.** Америка Көньягында озак вакытлар буена башлыча колбиләүчелек плантация хуҗалыгы өстенлек итү аркасында, ул Төньяк-Көнчыгышка һәм Урта Көнбатышка караганда шактый акрын үсте. Гасыр ярым буена биредә «мамык-патша» биләмәләре хакимлек итте. Соңрак та әле Көньяк ныграк үскән макрорайоннарның аграр-чимал өстәмәсе ролен үтәде. Көньяк дигәч, күз алдына ярлылык, артка калганлык, чиктән тыш рәхимсез расизм күренешләре килеп баса иде.

Әмма соңгы унъеллыкларда Көньякның бу традицион образы шактый дәрәҗәдә тарихка гына кереп калды. Регион илдә нефть, табигый газ [20], күмер, фосфоритлар чыгару, электр станцияләре, нефть химиясе комбинатлары куәте буенча беренче урынны алды. Биредә илдә җитештерелгән тукымаларның, тәмәке әйберләренең 9/10 өлеше тупланган.

Мамык поясының күләме бик нык кимеде, аның каравы авыл хуҗалыгы күп тармаклы һәм интенсив булып китте. Муллык дәрәҗәсе ягыннан әле Көньяк башка макрорайоннардан калыша, беренче чиратта бу негрлар иң күп яши торган Миссисипи һәм Алабама штатларына кагыла.

Көньякны күп йөзле дип атарга була. Географ-галимнәр анда берничә өлешне аерып күрсәтәләр.

Бу — *Иске Көньяк*, ул үзенең тәмәке плантацияләре белән дан тота; «Мальборо» сигаретлары нәкъ менә шунда уйлап табыла һәм әле хәзер дә чыгарыла. Бройлер чебешләрен җитештерүнең төп районы да шушында. Бу — мамык монокультурасы белән танылган *Эчкәреге Көньяк*. Аның тиз үсүенең символы булып Атланта шәһәре хезмәт итә. [21]. Бу —«кояшлы штат» Флорида, аңа ел саен 50 млн турист һәм ял итүче килә, һәм шунлыктан Майами дөньядагы иң зур курортлардан санала; биредән цитрус җимешләре бөтен ил буйлап тарала. Канаверал борынында АКШның төп космодромы урнашкан. Бу — *Яңа Көньяк* (Техас), ул «нефть бизгәге»ннән соң АКШның иң бай һәм чәчәк атучы районнарыннан берсенә әверелде. Аның төп үзәкләре — ультразаманча Даллас һәм Хьюстон шәһәрләре. Эре аэрокосмик производство, космик очышлар белән идарә итү урыннары биредә урнашкан.

**5. Көнбатыш — АКШның иң яшь һәм динамик макрорайоны.** Көнбатыш — үзләштерелү вакыты ягыннан АКШның иң яшь, территориясе ягыннан иң зур макрорайоны. *Шуңа күрәдер, мөгаен, бу макрорайонда контрастлар аеруча нык сизелә.* Биредә — илдәге иң биек таулар, иң тирән тар каньоннар, иң зур чүлләр (Аризона штатын тикмәгә генә «Америкадагы Мисыр» дип йөртмиләр) һәм иң уңдырышлы үзәнлекләр. Биредә инглиз-америка, испан-америка, азия-америка һәм индеецлар мәдәниятләре ныграк кушылган, катнашкан; гаять зур шәһәрләр һәм җансыз диярлек пространстволар бергә үрелеп яши. Биредә яшәүчеләрнең тормыш дәрәҗәсендәге аермалар да шактый.

Көнбатыш озак вакытлар буена файдалы казылмалар чыгару промышленносте һәм көтүлекле терлекчелек буенча специальләште. Бу район бары тик Икенче бөтендөнья сугышыннан соң гына тиз үсә башлады. Хәзер ул икътисади үсеш темплары буенча башка макрорайоннардан алда бара.

Шактый ук уртак билгеләре булуга карамастан, Көнбатышның эчке дөньясы бертөрле түгел. Анда *Ерак Көнбатышны* (илнең көнчыгыш өлешенә карата) аерып күрсәтү кабул ителгән, ул Бөек тигезлекләрдәге прерияләрне били. Иркен көтүлекләр, мөгезле эре терлек һәм сарык үрчетү, ранчолар, ковбойлар һәм аларның традицион родео ярышлары ягы ул. Шуннан соң *Таулы Көнбатыш* китә, монысы — Кыялы таулар һәм чүлләр, күп кенә бакыр, молибден, уран, алтын рудниклары һәм күмер ятмалары ягы, сугарулы игенчелек, милли парклар, таучаңгы курортлары һәм ел әйләнәле туризм ягы. [22]. Бу, ниһаять, *Тын океан Көнбатышы*, аның үзенең төрле өлешләре бар, әмма «алтын штат» Калифорния бигрәк тә нык аерылып тора.

Калифорнияне еш кына «дәүләт эчендәге дәүләт» дип йөртәләр. Чынлап та, мәйданы ягыннан бу штат чама белән Япониягә, ә халкы ягыннан Канадага тиң. *Калифорния — АКШның төп фәнни һәм хәрби-промышленность*

*арсеналы.* Калифорния — шулай ук илнең төп авыл хуҗалыгы штаты; моның төп сәбәбе — 700 км га сузылган җиләк-җимеш бакчасын хасил иткән Үзәк үзәнлекнең булуы. Калифорниядә автомобильләр илнең калган барлык 49 штатына караганда ике мәртәбәгә генә ким.

Калифорниянең йөзен күп яктан андагы иң зур Лос-Анджелес шәһәре билгели. 1781 елда испан миссионерлары нигез салган бу шәһәр [23] башта авыл хуҗалыгы, аннары алтын, кинематография (Голливуд), нефть, ә соңгы вакытларда — хәрби юнәлешләрдәге тармаклар комплексы: самолетлар, ракеталар, космик корабльләр, шулай ук алар өчен приборлар һәм электроника җиһазлары җитештерү аркасында үсте. Промышленность үзәге буларак, ул бары тик Нью-Йорктан гына калыша.

Лос-Анджелес — мәйданы ягыннан дөньяда иң зур шәһәрләрнең берсе, ул океан яры буйлап 100—120 км га сузылган, ә аның урам-шосселарындагы йорт номерлары 12, хәтта 16 меңгә җитә. Ул шулай ук АКШтагы шәһәрләр арасында бер катлы йортлар өстенлек итүе белән аерыла. Лос-Анджелес агломерациясенә 220 дән артык торак пункт керә, һәм халыкның 3/4 е шәһәр читендә яши. Шуңа күрә: «Лос-Анджелес — ул үз шәһәрен эзләүче бистәләр»,— дип сөйлиләр.

Калифорниянең икенче әһәмиятле үзәге — Сан-Франциско, ул — АКШның иң матур шәһәрләреннән берсе, ә Лос-Анджелес күтәрелгәнче Калифорниянең генә түгел, бөтен Көнбатышның икътисади һәм мәдәни башкаласы булган. Сан-Франциско янында атаклы Силикон үзән урнашкан. [24].

Көнбатыш составына шулай ук АКШтагы яңа үзләштерелгән төп ресурслар районы Аляска һәм туризм белән дан тоткан Гавай утраулары керә.

Аляскада тау промышленностеның үсешенә бәйле рәвештә Төньякның җиңел җәрәхәтләнә торган табигатен саклау буенча аерым чаралар күрелә, әмма экологик катастрофалардан тулысынча котылуга ирешә алмыйлар әле. [25]. (11 нче иҗади бирем.)

## 3. КАНАДА БЕЛӘН ТАНЫШАБЫЗ

**Гомуми мәгълүматлар.** *Канада — мәйданы ягыннан Россиядән кала дөньяда икенче ил.* Төньяктан көньякка аның территориясе 4600 км, көнчыгыштан көнбатышка 5100 км га сузыла. Канада өч океанга чыга, һәм яр буе сызыгының гомуми озынлыгы (250 мең км) буенча дөньяда аңа тиңнәр юк. Канаданың икътисади-географик урыны шактый дәрәҗәдә көньякта АКШ белән коры җир буйлап чикнең бик озын булуы, Атлантик һәм Тын океаннарга киң чыгу юллары булу белән билгеләнә.

Инде 1867 елда ук Канада Британия империясе составындагы беренче доминион булды. Бүгенге көндә дәүләт төзелеше буенча аны суверен дәүләт дип әйтергә була. Ләкин Канада Бөекбритания җитәкләгән Бердәм-

лек составына кергәнлектән, дәүләт башлыгы булып формаль рәвештә Англия королевасы исәпләнә, ул, премьер-министр тәкъдиме буенча, Канаданың генерал-губернаторын билгеләп куя. Канада — федератив дәүләт, ул ун провинциядән һәм ике территориядән гыйбарәт, аларга 1999 ел башында тагын бер федератив субъект — эскимослар (иннуитлар) яши торган Нунавут территориясе өстәлде. [26].

Канаданың халкы 30 млн нан аз гына артык. Озак вакытларга сузылган колонизация чорында халыкның яртысы гына табигый арту исәбенә үсте, икенче яртысын массакүләм иммиграция тәэмин итте, ул әле хәзер дә халыкның абсолют үсешенең 1/3 ен тәэмин итә.

*Канадада тарихи төп ике милләт: инглиз-канадалылар һәм француз-канадалылар оешты,* аларның үзара мөнәсәбәтләре, инде белгәнегезчә, шактый зур каршылыклар белән аерылып тора. Аборигеннар (индеецлар, эскимослар) — 800 мең кеше. Канадада халыкның уртача тыгызлыгы (1 $км^2$ га 3 кеше) — дөньяда иң түбәннәрнең берсе, ул халык урнашып утыруның реаль картинасын бик аз чагылдыра. Канада — бик нык урбанизацияләнгән ил, аның зур шәһәрләреннән Торонто, Монреаль, Ванкуверны атарга була. Илнең башкаласы — Оттава, ул, нигездә, административ функцияләр башкара. [27].

**Хуҗалыгы.** Канада — базар икътисадлы нык үсеш алган, постиндустриаль үсеш дәрәҗәсенә җиткән ил. Ул Көнбатыш илләрнең «зур җиделеге» составына һәм НАФТАның интеграцион төркеменә керә, ТЭП күләме буенча да, җан башына исәпләнгән ТЭП зурлыгы буенча да Канада дөньядагы илләрнең «беренче унлыгы»на керә. Шуның белән беррәттән дөнья хуҗалыгында һәм хезмәтнең халыкара географик бүленешендә аның үз «йөз»е бар, *аны халыкара специальләшү тармакларының дүрт төркеме билгели.*

Беренчедән, Канаданың бик бай минераль ресурсларыннан файдаланып, аны «тау токымнары чыгаручы бөек держава»га әйләндерергә ярдәм итүче чыгару промышленносте бар.

**Мисал.** Уран, кобальт, калий тозы һәм асбест чыгару буенча Канада дөньяда — беренче, цинк рудалары һәм күкерт табу буенча — икенче, табигый газ, платиноидлар буенча — өченче, бакыр рудасы һәм алтын буенча — дүртенче, кургаш рудалары буенча — бишенче һәм көмеш табу буенча җиденче урында тора.

Әйдәп баручы тау промышленносте тармакларына шулай ук нефть-газ тармагы да керә.

Икенчедән, бу,— эшкәртү промышленностеның төп тармакларыннан берсе буларак, төсле металлургия. Биредә Канада никель, бакыр, цинк, кургашны үз чималыннан, алюминийны читтән кертелгән чималдан кою күләме буенча аеруча нык аерылып тора («Кушымта»дагы 25 нче таблица).

Өченчедән, бу — агач эшкәртү һәм целлюлоза-кәгазь промышленносте, ул Канада-

ның гаять зур урман ресурсларын файдалана, агач материаллары һәм кәгазь җитештерү буенча алга киткән. [28].

Дүртенчедән, бу — **авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек промышленносте.** Канада, барыннан да элек, бөртекле ашлыклар (бодай) җитештерү буенча специальләшә, ләкин шулай ук кайбер майлы культуралар, җиләк-җимеш, ит продукциясе җитештерү буенча алдынгы илләр рәтенә керә.

**Эчке аерымлыклары.** *Эчке аерымлыклар Канадада бик ачык чагыла.* Халкының һәм хуҗалыгының төп өлеше чагыштырмача тар (200—500 км) көньяк полосада, АКШ чиге буйлап тупланган. Монда халыкның тыгызлыгы 1 $км^2$ га 10 нан алып 50 кешегә кадәр тирбәлә. Канаданың төп икътисади районнары да биредә урнашкан: 1) Үзәк район (Онтарио һәм Квебек провинцияләренең көньяк өлешләре) илнең төп шәһәрләре һәм промышленность үзәкләре белән, 2) тау промышленносте, бөртекле ашлык хуҗалыгы һәм терлекчелеге нык үскән Дала районы (Манитоба, Саскачеван һәм Альберта провинцияләре), 3) илнең төп «урман цехы» булган Тын океан районы (Британия Колумбиясе провинциясе) һәм 4) мәйданы буенча иң кечкенә һәм социаль-икътисади үсеш дәрәҗәсе ягыннан депрессив, дүрт провинцияне үз эченә алган Атлантика районы.

Канада территориясенең 2/5 өлеше чамасын халык аз яши торган һәм начар үзләштерелгән Төньяк алып тора, анда 100—200 $км^2$ мәйданга 1 кеше туры килә. Канада Төньягында, гомумән яңа үзләштерелә торган районнарга хас булганча, **территорияне учаклап үзләштерү төре** өстенлек итә. Хуҗалык эшчәнлеге учаклары биредә, нигездә, файдалы казылмалар чыгару промышленносте һәм иң зур ГЭСлар белән бәйләнгән. (12 нче иҗади бирем.)

**Төп нәтиҗә.** *Кушма Штатларның дөнья хуҗалыгындагы өлеше беркадәр кимүгә карамастан, ул иң икътисади үскән дәүләт булып кала. Канада белән бергә бу Англо-Америка бөтен дөньядагы ике иң куәтле икътисади регионның берсен барлыкка китерә.* (13 нче йомгаклау биреме.)

## ӨСТӘМӘ ТЕКСТ (Кызыклы мәгълүматлар)

[1] АКШ территориясе биш вакыт поясында ята, алар (көнбатыштан көнчыгышка таба) Тын океан, таулы, үзәк, көнчыгыш һәм Атлантик вакытны билгелиләр. Бөтен ил территориясен кисеп самолетта очып үтү өчен 5—5,5 сәгать вакыт кирәк.

[2] АКШның федератив төзелеше илнең 1776 елда бәйсезлек игълан ителгәч тә расланган дәүләт флагында чагылыш тапкан. Флагның өске сул почмагында биш почмаклы ак йолдызлар төшерелгән зәңгәр турыпочмаклык урнаштырылган, йолдызларның саны федерациягә кергән штатлар санына тигез; ул акрынлап арта

барган. 50 нче йолдыз әләмгә 1959 елда Гавай утрауларына штат статусы бирелгәннән соң төшерелде. Флагның тукымасы үзе чиратлашып килгән 13 ак һәм кызыл полосадан гыйбарәт, алар бердәм дәүләткә берләшкән беренче 13 штатны белдерәләр.

[3] Штатларның символикасы, гадәттә, аларның тарихи һәм табигый үзенчәлекләре белән бәйле. Мәсәлән, Нью-Йорк штатын «империя штаты» дип йөртәләр, чөнки АКШның бәйсезлеге игълан ителгәндә, ул 13 штат арасында иң зурысы була; аның символы итеп, бакчачылык штатларының берсе буларак, алма сайлап алынган. Дэлавэр штатын «беренче штат» дип йөртәләр, чөнки ул Конституцияне беренче булып ратификацияли. Субтропик Флориданы «кояшлы штат» диләр. XIX гасыр уртасында алтын табылган Калифорнияне — «алтын штат», Аризонаны — «Зур каньон штаты», Мэнны — «нарат штаты», Канзасны — «көнбагыш штаты», Миссисипины «магнолия штаты» дип йөртәләр. Моннан тыш, һәр штатның үз девизы, җыры, агачы, чәчәге, кошы бар.

[4] Европадан киткән кешеләр белән бергә АКШка күп кенә Европа шәһәрләренең исемнәре дә «күчеп килә». АКШның хәзерге картасында Афина, Кембридж һәм Оксфорд исемле — 13, Берлин — 9, Варшава — 8, Лиссабон, Мәскәү, Париж — 7, Неаполь — 6, Рим — 5, Мадрид һәм Лондон исемле 4 торак пунктны табарга була.

[5] Типик «афроамерика» шәһәрләре исәбенә, гадәттә, Вашингтон, Детройт, Балтимор, Филадельфия һәм Нью-Йоркны кертәләр. Әгәр дә инде барлык «ак булмаган» яшәүче халыкны күз алдында тотсак, Нью-Йоркта ул 61 % тәшкил итә, Яңа Орлеанда — 68, Атлантада — 70, Вашингтонда — 73, Детройтта — 84, ә Майамида хәтта 91 %!

[6] АКШта 260 лап төрле чиркәү теркәлгән, шуларның 86 сының 50 меңнән артык тарафдары бар. Америкалыларның нинди дин тотуы, гадәттә, аларның чыгышы белән тыгыз бәйләнгән: Италия, Испания, Польшадан чыгучылар — католиклар, Бөекбритания белән Скандинавия илләреннән чыгучылар — протестантлар, Россия һәм Грециядән чыгучылар — православие динендә.

[7] 1900 елда АКШның һәр гражданы, нигездә, өй белән эш арасында бер ел эчендә уртача 698 км юл үткән. 80 нче елларда юл йөрүләр елга 19,2 мең км га җиткән, гасыр башыннан алып ул 27,5 тапкыр диярлек арткан. Көнбатыш Европада шундый ук күрсәткечләр 1,5—2 тапкырга кимрәк.

[8] Аляскада нефть ятмалары Икенче бөтендөнья сугышы беткәннән соң күп тә үтми табыла, әмма чыганаклар чагыштырмача кечкенә булып чыга. 60 нчы елларда нефть эзләүне яңадан башлыйлар һәм 2 млрд т запаслы, күләме ягыннан уникаль

Прадхо-Бей ятмалары табыла. Ул Бофорт диңгезе яры буенда Барроу борынынннан 300 км көньяк-көнчыгышка, мәңгелек туңлык зонасында урнашкан. Кышкы температура биредә –45—50 °С ка җитә. 70 нче елларда мәңгелек туңлыкның читен шартларында 1288 км га сузылган Трансаляска нефть үткәргече төзелә. Ул Прадхо-Бей чыганагын Аляскаының көньяк яры буендагы Валдиз порты белән тоташтыра.

[9] 1896 елда Детройт читендәге Дирборнда үзлегеннән өйрәнеп механик булган Генри Форд үзе ясаган автомобильне сынап карый. Аннары ул АКШта беренче булып «калай Лиззи» кушаматы алган арзанлы автомобильләрне сериялэп (конвейерда) чыгару эшен җайга сала. Шул чордан алып «Форд мотор компани» иң эре транснациональ корпорацияләрнең берсенә әверелә, аның бөтен дөньяга таралган предприятиеләрендә 0,5 млн кеше эшли. Әмма Форд компаниясенең төп штаб-квартирасы элеккечә Дирборнда урнашкан.

[10] АКШта җиләк-җимеш һәм яшелчә үстерүче төп район — Калифорния, аны тикмәгә генә 350 кояшлы көн иле дип атамыйлар. Калифорния дөнья күләмендә җыелган лимонның 1/2 ен, апельсинның 1/3 ен бирә. АКШта җыелган виноградның 9/10 ы, персик, груша, слива, помидорның 1/2 е аңа туры килә, җиләк-җимеш һәм яшелчә консервларының 1/3 е анда эшләнә.

[11] Чит илләргә салына торган 2,5 млрд доллар Америка капиталының якынча 1/2 өлеше Көнбатыш Европага (беренче чиратта Бөекбритания, Германия, Нидерланд, Франция һәм Швейцариягә) туры килә. Икенче урында — Латин Америкасы илләре, өченчедә — АТР илләре. Америка икътисадына салынган капиталның күләме буенча Япония беренче урында тора, аннары Бөекбритания, Германия, Канада бара.

[12] Милли тарихи паркларның мисаллары булып Бостон һәм Филадельфия, Аляскадагы Клондайк, милли мемориалларның мисалы булып Вашингтондагы Вашингтон, Линкольн, Джефферсон мемориаллары, сугыш кыры милли паркларының мисалы булып 1861—1865 еллардагы Гражданнар сугышы вакытында төньяклылар белән көньяклыларның бәрелешкән урыннары хезмәт итә.

[13] Лос-Анджелеста чынлыкта бердәнбер юл йөрү чарасы — җиңел автомобиль. Әгәр шәһәрдәге барлык 5 млн автомобильне дүрт рәткә бамперга-бампер тезеп куйсаң, бу колонна Лос-Анджелестан Нью-Йоркка кадәр сузылыр иде! Автомобильләргә барлык шәһәр мәйданының яртысы диярлек бирелгән (92 нче рәсем). Әмма коры климат шартларында автомобильләрдән чыккан газлар фотохимик корымга әйләнә. Америка астронавтлары

космостан бу шәһәр урнашкан районның зур кара тап булып күренүен берничә тапкыр билгеләп үттеләр.

[14] Гаять зур күләмдәге промышленность һәм көнкүреш калдыклары АКШ өчен мөһим проблема тудыра. Илдә һәр елны шәһәрләргә керү юлында гаять зур өем-свалкалар хасил иткән әчемлекләрдән бушаган 65 млрд металл савыт, 30 млрд шешә, 65 млрд т кәгазь, 100 млн иске автомобиль покрышкалары, 5 млн срогы чыккан автомобиль, 7,5 млн иске телевизор чыгарып ташлана.

[15] Америка газеталары бик зур күләмле булулары белән аерылып торалар. Хәтта кечкенә шәһәрләрдә дә көндәлек газеталар 3—4 секцияле була (сәясәт, бизнес, спорт, күңел ачулар һ.б.), аларның һәркайсы 20 ләп һәм аннан да артыграк полосадан тора. Зур шәһәрләрдә газеталар 80—120 полосалы булып чыга, ә якшәмбе көннәрендә аларның күләмнәре тагын да зуррак була. Реклама кушымталары белән бергә газетаның авырлыгы 2—3 кг га җитә.

[16] Нью-Йоркта 400 картина галереялары, 200 китапханә, дистәләгән концерт заллары бар. Аның төп урамы Бродвейда гына да («киң юл» дип тәрҗемә ителә) 40 театр бар.

[17] Эмпайр Стейт Билдинг биналарында — 25 мең эш урыны. Бөтендөнья сәүдә үзәгенең ике манарасында 65 мең эш урыны булган; алар көнгә 80 мең кеше кабул итүгә исәпләнгән булган. Сәүдә үзәге биналарында 44 мең тәрәзә саналган. Йөздән артык лифт персоналны санаулы секундлар эчендә кирәкле катка менгереп куйган. Урамда яңгыр яуганда күксөзәрләрнең өске катларында якты кояш балкыган чаклар да булган.

[18] Нью-Йоркта пуэрторикалылар саны Сан-Хуандагыга караганда, ирландиялеләр — Дублиндагыга, яһүдләр Тель-Авивтагыга караганда күбрәк. Негрларның саны ягыннан Нью-Йорк АКШ шәһәрләре арасында беренче урында тора. Манхаттанның төньяк өлешендә, 110 нчы һәм 155 нче урамнар арасында, негрларның иң эре районы — Гарлем урнашкан.

[19] АКШ президенты резиденциясе — Ак йортка 1792 елда ук нигез салынган, ул — шәһәрнең иң борынгы бинасы. 1812—1814 елларда инглизләр белән америкалылар сугышында инглиз десанты Вашингтонны ала һәм шул чагында президент резиденциясе дә зыян күрә. Торгызганнан соң бинаны ак буяу белән буйыйлар. «Ак йорт» дигән атама менә шуннан килеп чыккан да инде.

[20] АКШның диңгез яры буенда Мексика култыгында нефть һәм табигый газның 700 гә якын ятмасы табылды, һәм бу акватория хәзер чып-чын җир-су пространствосына әверелде. Биредә 20 меңләп нефть һәм газ скважинасы казылган. Алар бер-

берсе һәм яр буе белән торба үткәргечләрнең катлаулы челтәре аша бәйләнгән, һәр платформада 15—50 кешелек вахта эшли, алар ике атна хезмәт иткәннән соң алышыналар.

[21] XIX гасыр ахырында Атлантада яшәүче бер аптекарь кока-кола дигән эчемлек уйлап таба һәм шәһәр шуның белән танылып китә. Чәчәк атучы бу корпорация хәзер дә үзенең штаб-квартирасын Атлантада тота. Соңгы вакытларда Атланта үтә биек йортлар, күп санлы конгресслар һәм фестивальләр шәһәре булып китте. 1996 елда монда XXVI җәйге Олимпия уеннары үткәрелде. Атланта аэропорты пассажирлар саны ягыннан дөньяда иң беренче урыннарны алып тора.

[22] Таулы штатларның берсе Невада үзенең атом-төш полигоны һәм «күңел ачуларның бөтендөнья башкаласы» Лас-Вегас шәһәре белән киң танылган, шәһәр рулетка һәм башка отышлы уеннар исәбенә яши. Бирегә читтән тыш гадиләштерелгән (башка штатлар белән чагыштырганда) никахлашу һәм аерылышу процедуралары аркасында да киләләр. (Шул сәбәпле Невадада 1000 кешегә никахлашучылар саны Америка буенча уртача саннан — 20, ә аерылышучылар саны 4—5 мәртәбә күбрәк.) Лас-Вегаска ел саен бөтен Америкадан 10—15 млн кеше килә.

[23] Испаннар шәһәргә биргән тулы исем — *Pueblo de Nuestra Señora la Reine de los Angeles* — «безнең фәрештәләр королевасы шәһәре» булып яңгырый. Шушы озын атаманың бары тик ахыры гына сакланып калган.

[24] Силикон үзән 60 нчы елларда атаклы Стэнфорд университеты нигезендә барлыкка килә. Биредә электрон-хисаплау техникасын уйлап табу, камилләштерү һәм җитештерү белән шөгыльләнүче 2 меңнән артык фирма урнашкан, ә анда эшләүчеләрнең саны 200 меңгә җитә. Шуңа күрә дә бу комплекс Силикон, яки Кремний үзәне дигән исем алган («Силикон вэлли»).

[25] 1989 ел башында Алясканың көньяк яр буйларында Америка супертанкеры «Валдиз» рифларга бәрелә, һәм аннан агып чыккан нефть океанның 800 км$^2$ ын каплап ала. Бу АКШ тарихында иң зур экологик һәлакәтләрнең берсе була.

[26] Нунавута (эскимосчадан тәрҗемәсе «Безнең җир») территориясе Төньяк-Көнбатыш территориясеннән аерылып чыккан һәм 2 млн км$^2$ җир, яки Канаданың бөтен мәйданының 1/5 ен били. Әмма монда бары 30 мең кеше яши. Бу — биредә халыкның уртача тыгызлыгы 100 км$^2$ га бары тик бер кеше икәнен аңлата.

[27] 1867 елда Канада доминионы оештырылгач, аның нигезен элеккеге ике колония — инглиз телендә сөйләшүче Онтарио һәм француз телендә сөйләшүче Квебек тәшкил итә. Башкала ролен

өч шәһәр — Торонто, Монреаль һәм Квебек даулый. Шуннан соң Англия королевасы Виктория компромисслы карар кабул итә — башкала итеп ул чагында зур булмаган, Онтарио һәм Квебек провинцияләре читендә урашкан Оттава бистәсен билгели.

[28] Бер кешегә агач әзерләү буенча (елына 6—7 $м^3$) Канада дөньяда беренче урында тора. Илдә 1,5 меңнән артык такта яру заводы эшли; Британия Колумбиясе провинциясендә алар барыннан да күбрәк. Канадада дөньяда иң зур целлюлоза-кәгазь комбинаты эшли. Чит илләр арасында бу ил барлык газета кәгазенең 40 % ын җитештерә һәм кәгазь экспортының 60 % ын тәшкил итә. АКШта күп кенә газеталар Канада кәгазендә басыла.

**Китап киштәсе**


1. Америка. Общий обзор. Северная Америка.— М.: Мысль, 1989.— (Серия «Страны и народы»).
2. Максаковский В. П. Географическая картина мира.— М.: Дрофа, 2009.— Ч. 2.— Тема 4.
3. Экономическая и социальная география мира. За страницами учебника: Кн. для учащихся 10 кл. / Сост. А. П. Кузнецов.— М.: Просвещение, 2000.
4. Кулышев Ю.А. Канада.— М.: Мысль, 1989.— (Серия «У карты мира»).


## БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘР АЛУ ӨЧЕН ТУПЛАНМА

**1 нче бирем.** Дәреслек текстыннан һәм атлас карталарыннан файдаланып, АКШның икътисади-географик урынына характеристика бирегез. Ул чынлап та отышлымы? Сез ни өчен шулай уйлыйсыз? Илнең (регионның) икътисади-географик урынының үрнәк характеристикасын кулланыгыз (222 нче бит).

**2 нче иҗади бирем.** Дәреслек текстын һәм 83—86 нчы рәсемнәрне файдаланып, АКШның иң эре шәһәр агломерацияләре һәм мегалополисларына характеристика бирегез. Илнең мәйданы һәм халык санында өч мегалополисның өлешен исәпләп чыгарыгыз. Аларның халык тыгызлыгын илдәге уртача күрсәткечләр белән чагыштырыгыз, нәтиҗәләр ясагыз. 3 нче тема текстыннан һәм рәсемнәреннән АКШтагы урбанизацияне сыйфатлау өчен файдаланырлык мәгълүматларны сайлап алыгыз.

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** «АКШның штатлары һәм шәһәрләре» дигән кроссворд төзегез.

**3 нче бирем.** 5 нче тема таблицаларын һәм рәсемнәрне, «Кушымта»дагы таблицаларны файдаланып, кирәкле исәпләүләрне эшләгез. Дәфтәрдә продукциянең аерым төрләре буенча АКШның дөньякүләм промышленность һәм авыл хуҗалыгы җитештерүендәге өлешен күрсәтүче баганалы яисә түгәрәк диаграмма төзегез. Аларга анализ ясагыз.

**4 нче бирем.** Дәреслек тексты һәм АКШның атластагы минераль ресурслар картасын файдаланып, аларның күп тармаклы промышленностьны үстерүгә ярдәм итүен исбатлагыз. Дәреслектәге «Көнчыгыш өлешнең төп байлыгы — янучан казылмалар, көнбатышныкы — рудалы казылмалар» дигән фикерне тасвирлап бирегез. Ил (регион) промышленностеның үсеше өчен табигый алшартлар характеристикасының үрнәк планын файдаланыгыз (228—229 нчы бит).

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** АКШта күмер, нефть, табигый газ, тимер рудасы запаслары һәм аларны чыгару турындагы мәгълүматларны файдаланып, алар белән тәэмин ителешне (елларда) исәпләп чыгарыгыз. Дәреслек тексты һәм 1 нче таблица мәгълүматларын файдаланып, күмер, нефть, табигый газ, тимер рудасының бөтендөнья гомумгеологик запасларында АКШның өлешен исәпләп чыгарыгыз. Бу анализдан нинди нәтиҗәләр ясарга мөмкин?

**5 нче бирем.** 87 нче рәсемне файдаланып, АКШның иң мөһим биш «нефть штаты»н атагыз. Аларның кайсыларында нефть чыгаруның континенталь шельфта да алып барылуын билгеләгез. Нефтьүткәргечләр системасының гамәлдәге конфигурациясен, 70 нче елларда Трансаляска нефть үткәргечен төзү сәбәпләрен аңлатырга тырышыгыз. 25 нче рәсем ярдәмендә АКШның нефтьне һәм нефть продуктларын кайсы илләрдән кертүен билгеләгез. Бу нәрсә белән аңлатыла? Ил (регион) промышленносте тармагына характеристиканың үрнәк планын кулланыгыз.

**6 нчы бирем.** 88 нче рәсемне файдаланып, дәфтәрегезгә «АКШта кара металлургиянең төп районнары» дигән белешмә-конспект таблица төзегез:

| Район исеме | Ориентлашу тибы | Төп үзәкләре |
|---|---|---|
| | | |

28 нче рәсем буенча, АКШның тимер рудасын кайсы илләрдән кертүен билгеләгез. Моның сәбәпләре нәрсәдә?

**7 нче бирем.** Дәреслек текстындагы машина төзү характеристикасын конкретлаштыру өчен, АКШның атластагы икътисади картасын һәм дөньяда машина төзү картасын файдаланыгыз. Шулар

буенча бу тармакның иң эре үзәкләрен билгеләгез. Дәреслектәге «АКШның төп машина төзү районнары мегалополислар белән тәңгәл килә» дигән фикерне тасвирлап күрсәтегез.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Шул ук карталардан файдаланып, дәфтәрдә «АКШта машина төзүнең иң эре үзәкләрендә машина төзү тармагының структурасы» дигән белешмә таблица төзегез.

**8 нче бирем.** Дәреслек текстын, 89 нчы һәм башка рәсемнәрне, шулай ук атласта АКШ икътисади картасын файдаланып, дәфтәрегезгә «АКШның промышленность пояслары» дигән белешмә-конспект таблица төзегез:

| Пояснын исеме | Промышленностьның әйдәп баручы тармаклары | Төп үзәкләре |
|---|---|---|
| | | |

**9 нчы бирем.** Нәтиҗәләр чыгарып, дәфтәрегезгә язып куегыз.

90 нчы рәсем буенча АКШта үсемлекчелекнең урнашуын тасвирлагыз. 90 нчы рәсемне һәм АКШның атластагы административ-территориаль бүленеше картасын чагыштырып: 1) ике иң мөһим «бодай» штатын (берсе — сабан, икенчесе уҗым бодае буенча), 2) төп «кукуруз» штатын билгеләгез.

**10 нчы иҗади бирем.** Нью-Йоркның һәм Вашингтонның атластагы үзәк өлешләре планнарын һәм өстәмә мәгълүматлар файдаланып, бу шәһәрләрнең берсенең мәдәни-тарихи һәм архитектура истәлекләре турында чыгыш әзерләгез. «Гид» булып, шәһәр буйлап кечкенә генә «экскурсия» үткәрегез.

**11 нче иҗади бирем.** Дәреслектәге текст һәм рәсемнәр, шулай ук атлас карталары нигезендә АКШ макрорайоннарының берсен (үзегез сайлап алыгыз) язма рәвештә кыскача тасвирлагыз.

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** Төньяк киңлекнең 40° параллеле һәм көнбатыш озынлыкның 100° меридианы буйлап АКШка «сәяхәт»кә чыктык дип күз алдына китерегез. Маршрутларны тасвирлагыз. Өстәмә әдәбияттан файдаланыгыз.

**12 нче иҗади бирем.** Дәреслекнең I кисәгендәге текстларны, рәсемнәрне һәм «Кушымта»дагы таблицаларны игътибар белән карап чыгыгыз, шулар арасыннан Канадага караганнарын сайлап алыгыз. Канаданың атластагы картасын файдаланыгыз. Шул материаллар нигезендә бу илнең кыскача социаль-икътисади характеристикасын тулыландырыгыз. Аерым бер илгә үрнәк характеристика планын файдаланыгыз (329 нчы бит).

**13 нче йомгаклау биреме.** 1. (Дәфтәрдә эшләү.) 9 нчы тема материалларын файдаланып, АКШ һәм Канада халкының һәм хуҗалыгының төп типик

сыйфатларын атагыз. Аларны түбәндәге таблица рәвешендә күрсәтегез:

| Илләр | Халыкның яңарып тору тибы | Халыкның милли составы | Урбанизация дәрәҗәсе | Хуҗалыкның үсеш дәрәҗәсе | Хуҗалыкның тармак структурасы | Хуҗалыкның территориаль структурасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| АКШ<br>Канада | | | | | | |

Бу таблица белән эшләп, гомумиләштерү ясагыз.

2. (Контурлы карта белән эшләү.) Төньяк Американың контурлы картасына (үзегез сайлап алып) түбәндәгеләрне билгеләгез: 1) иң эре шәһәрләр, 2) төп диңгез портлары, 3) трансконтиненталь тимер юллар. Бу исемлекне үзегез теләгәнчә озайта аласыз.

3. Бу теманы өйрәнгәндә, дәреслектәге һәм атластагы тематик карталарның нинди төрләрен файдаландыгыз? Аларның кайсылары сезнең өчен яңа булды?

4. Дәреслек текстына һәм 81 нче рәсемгә нигезләнеп, Америка шәһәренең үзәк эшлекле районын тасвирлагыз.

## ҮЗЕГЕЗНЕҢ ҺӘМ БЕР-БЕРЕГЕЗНЕҢ БЕЛЕМНӘРЕН ТИКШЕРҮ ТУПЛАНМАСЫ

**Ничек аңлатырга:**

1. Ни өчен АКШның Төньяк-Көнчыгышы «милләтнең остаханәсе» дигән исем алган?

2. Ни өчен АКШ һәм Канададагы авыр промышленностьның шактый өлеше Бөек күлләр районында туплана?

3. АКШның алюминий заводлары ни өчен Теннесси һәм Колумбия елгалары үзәннәренә урнашкан?

4. Ни өчен АКШ һәм Канадада авыл хуҗалыгының специальләшүе көнчыгыштан көнбатышка таба үзгәрә бара?

5. Ни өчен Флорида, Калифорния һәм Гавай утрауларына туристларны иң күп җәлеп итә?

6. Ни өчен соңгы унъеллыкларда АКШ белән Канадада Төньяк районнарны үзләштерүгә кызыксыну артты?

**Нинди проблемалар барлыкка килә:**

1. АКШның Көньягын һәм Көнбатышын тизләтелгән индустрияләштерү белән бәйле рәвештә?

2. АКШның икътисады нефть, тимер рудасы һәм башка төрле чимал һәм ягулыкны читтән кертүгә һаман күбрәк бәйле була барган шартларда?

**Түбәндәге фикерләр белән килешәсезме:**

1. «Босваш» мегалополисы — АКШта иң зур урбанизацияләнгән зона.

2. Соңгы вакытларда Аляска АКШта нефть чыгаруның әһәмиятле районына әйләнде.

3. АКШта һәм Канадада авыл хуҗалыгының фермерлык тибы өстенлек итә.

4. АКШның транспорт системасы Европа чит илләренең транспорт системасы белән бер үк типта.

5. Изге Лаврентий елгасы Бөек күлләрне Нью-Йорк белән тоташтыра.

6. Атлантада дөньяның иң эре аэропорты урнашкан.

7. Канада халкы АКШ халкының 1/2 ен тәшкил итә.

**Булдыра аласызмы:**

1. 9 нчы теманың төп текстында искә алынган АКШ шәһәрләрен картадан табып, аларны хәтердән көнчыгыштан көнбатышка таба урнаштыра аласызмы?

2. АКШның «сөт», «кукуруз», «бодай», «апельсин», «ананас», «алма», «мамык» штатларына мисаллар китерә аласызмы?

3. Контурлы картага Яңа Англияне, Ерак Көнбатышны, Калифорнияне төшерә аласызмы?

4. Түбәндә китерелгән күрсәткечләрнең кайсысы Көнбатышның барлык ил мәйданында тоткан өлешен күрсәтә (% ларда): 20, 36, 49, 64?

5. Канада дөньякүләм җитештерүче һәм читкә чыгаручы булган минераль чимал төрләрен санап күрсәтә аласызмы?

**Түбәндәге сорауларга җавап бирү өчен дәреслек текстын һәм карталарын файдаланыгыз:**

1. АКШның кайсы тармакларында эшләүчеләр саны күбрәк: 1) нефть чыгаруда, 2) авиаракета-космос промышленностенда, 3) бройлер чебешләр үстерүдәме?

2. Киңлек юнәлешендә АКШ һәм Канаданы кайсы трансконтиненталь тимер юллар аркылы кисеп үтә?

3. АКШның Төньяк-Көнчыгышы үсешенә нинди табигый, социаль-икътисади һәм тарихи сәбәпләр ярдәм иткән?

**Күз алдыгызга китерегез:**

1. АКШның яисә Канаданың зур шәһәрләреннән берсенә бардыгыз, ди. Аны тасвирлап күрсәтегез.

2. АКШ промышленносте белән танышырга телисез, ди. 1) Авиация заводында, 2) электрон әйберләр җитештерүче эре предприятиедә, 3) автомобиль заводында, 4) нефть химиясе комбинатында, 5) кара металлургия комбинатында булу өчен сезгә нинди шәһәрләргә барырга туры килер иде?

3. Сезгә: 1) терлек үрчетү ранчосында, 2) тәмәке плантациясендә, 3) агач кисү заводында эшләү мөмкинлеге туды, ди. Моның өчен сезгә АКШ яисә Канаданың кайсы штатларына һәм провинцияләренә барырга туры килер иде?

**Түбәндәге җөмләләрне тутырып языгыз:**

1. АКШның икътисади башкаласы булып ... исәпләнә, әмма ... аның белән һаман ныграк көндәшлек итә.

2. Урта Көнбатыш территориясенең зур өлеше ... һәм ... — Төньяк Американың төп ике су артериясенә чыга.

3. АКШның Көньягындагы әһәмиятле авыл хуҗалыгы культураларына ... керә.

4. Канаданың ... провинциясендә яшәүчеләрнең күбесе француз телендә сөйләшәләр.

## 9 НЧЫ ТЕМАГА МЕТОДИК АЧКЫЧЛАР

### Боларны исегезгә төшерегез

1. Төньяк Американың сәяси картасы һәм халыклары. (География, 7 нче сыйныф.) 2. Төньяк Американың физик-географик урыны, рельефы, файдалы казылмалары, климаты, сулары, туфрагы һәм үсемлекләренең үзенчәлекләре. (География, 7 нче сыйныф.) 3. XIX гасыр ахыры — XX гасыр башында Төньяк Американың тарихи үсеш үзенчәлекләре. (Тарих, 8, 9 нчы сыйныфлар.) 4. Дәреслекнең I кисәге материаллары. 5. Төшенчәләр һәм терминнар: тыюлык, фермер.

### Боларны үзләштерегез

**9 нчы теманың төп идеяләре:**

1. Бөтендөнья социалистик системасы һәм Советлар Союзы таркалу нәтиҗәсендә, АКШның дөнья сәясәтендәге һәм икътисадындагы роле үсте. 2. Россия һәм көчле икътисадлы бүтән илләр белән АКШ арасындагы яңа мөнәсәбәтләр халыкара стабильлекнең мөһим факторы булып китте, бөтен дөньядагы сәяси хәлне яхшы якка үзгәртте.

**9 нчы теманың төп фәнни белемнәре:**

1. АКШның икътисади-географик урыны, табигый ресурслар географиясе һәм халыкның характерлы сыйфатлары. 2. АКШ хуҗалыгына гомуми характеристика. 3. АКШның промышленность географиясе, авыл хуҗалыгы, транспорт, табигатьне файдалануның төп сыйфатлары, төп промышленность һәм авыл хуҗалыгы районнары. 4. АКШны макрорайоннарга бүлү һәм һәр дүрт макрорайонның тышкы күренеше. 5. Канаданың кыскача икътисади-географик характеристикасы. 6. Теманың төп төшенчәләре: 1) шәһәрнең Төньяк

Америка тибы, 2) «икенче икътисад», 3) тулай милли продукт, 4) стадиялəп специальлəшү, 5) транспорт челтəренең Төньяк Америка тибы, 6) промышленность поясы, 7) авыл хуҗалыгы поясы, 8) территорияне урыны-урыны белəн (учаклап) үзлəштерү төре.

## Сез нəрсəлəр белергə тиеш

1. Шəһəр агломерациялəре һəм мегалополисларга характеристика бирергə. 2. Илнең промышленность тармагына характеристика бирергə. 3. Илгə кыскача икътисади-географик характеристика бирергə. 4. Язма рəвештə икътисади-географик тасвирлама төзергə.

## Мөстəкыйль эш күнекмəлəре булдыру буенча инструкциялəр һəм планнар

**1. Илнең (регионның) промышленносте тармагына характеристика бирү планы:**

1. Тармакның əһəмияте һəм аның продукциясе күлəме. 2. Тармакны үстерү өчен табигый алшартлар. 3. Тармакның структурасы. 4. Тармакны урнаштыруга йогынты ясый торган төп факторлар, тармак географиясенең төп сыйфатлары; тармак промышленносте районнары. 5. Тармакның экспорт һəм импортка бəйле булуы. 6. Гомуми нəтиҗə; тармакның үсеш перспективалары.

**2. Аерым бер илгə характеристика бирү планы:**

1. Икътисади-географик урынының төп билгелəре. 2. Табигый шартларына һəм ресурсларына хуҗалык ягыннан бəя бирү. 3. Халкы яңарып торуның, структурасының һəм урнашуының төп билгелəре. 4. Хуҗалыгына гомуми характеристика. 5. Промышленность урнашуының төп билгелəре. 6. Авыл хуҗалыгы урнашуының төп билгелəре. 7. Транспорт географиясенең төп сыйфатлары. 8. Төп икътисади районнар. 9. Тышкы икътисади элемтəлəрнең роле һəм географиясе. 10. Гомуми нəтиҗə; үсеш перспективалары.

## 10 НЧЫ ТЕМАНЫҢ ПЛАН-СХЕМАСЫ

# 10 нчы тема. ЛАТИН АМЕРИКАСЫ

7 нче сыйныфта сез Көньяк Американы Җирдәге алты материкның берсе буларак өйрәндегез. Икътисади һәм социаль географиядә өйрәнү объекты булып, гадәттә, Латин Америкасы регионы хезмәт итә. Башка зур регионнарның күпчелегеннән аермалы буларак, аны аерып күрсәтүнең нигезе булып беренче чиратта колонияләштерү үзенчәлекләре һәм роман төркеме телләренең (латин теле нигезендә) таралуы карала. Латин Америкасы халыкларының күпчелеге әле XVI—XVII гасырларда ук Испания һәм Португалия тарафыннан яулап алынган була һәм XIX гасыр башында гына азатлык ала. Бүгенге көндә регионда 46 ил һәм территория бар. Бәйсез 33 дәүләтнең барысы да үсеп килүче илләр рәтенә керә. Регион 561 млн халык яшәгән 21 млн км$^2$ мәйданны алып тора (2005 ел).

Латин Америкасы составында берничә субрегионны аерып күрсәтәләр: Урта Америка илләре (Мексика, Үзәк Америка һәм Вест-Индия илләре); Анд илләре (Венесуэла, Колумбия, Эквадор, Перу, Боливия, Чили); Ла-Плата бассейны илләре (Парагвай, Уругвай, Аргентина). Бразилия дә еш кына субрегион буларак карала.

## 1. ЛАТИН АМЕРИКАСЫНА ГОМУМИ ХАРАКТЕРИСТИКА БИРӘБЕЗ

**1. Территориясе, чикләре, урыны: зур эчке аерымлыклар. Дәүләт төзелеше.** Латин Америкасының территориясе төньяктан көньякка 13 мең км га, ә көнбатыштан көнчыгышка максималь 5 мең км га сузыла. Мәйданы ягыннан бу регион илләрен бик зур (Бразилия), зур һәм уртачага (Мексика һәм Көньяк Америка илләренең күпчелеге), чагыштырмача зур булмаган (Үзәк Америка илләре һәм Куба) һәм бик кечкенәләргә (Вест-Индия утраулары) бүләргә мөмкин. Материк илләре арасындагы чикләр күбесенчә тау сыртлары һәм зур елгалар буйлап үтә.

Латин Америкасының икътисади-географик урыны аның АКШка чагыштырмача якын, әмма башка зур регионнардан читтә урнашкан булуы белән билгеләнә. [1]. Шулай да бу уңайсызлык өлешчә күп кенә мөһим диңгез юлларының Панама каналына «тартылуы» белән кими. Өстәвенә регионд агы барлык илләр (Боливия һәм Парагвайдан кала) океаннар һәм диңгезләргә киң чыгу юлларына бай яисә утрауларда урнашканнар.

**Мисал.** Куба — региондагы иң зур утрау дәүләте, 1250 км га сузылган. Ул, Кариб диңгезе белән Мексика култыгы кисешеп, «Америка Урта диңгезе»н барлыкка китергән урында утырган. Ил гербына ясалган ачкыч — Колумб 1492 елда ачкан утрауның йөз еллар буена Яңа Дөньяга үзенә бертөрле ачкыч булып хезмәт итүенең билгесе.

Дәүләт төзелеше буенча Латин Америкасының барлык бәйсез дәүләтләре — я республикалар, я Бөекбритания җитәкләгән Бердәмлек составындагы дәүләтләр. Калганнары арасында — Бөекбритания, АКШ, Нидерландның Вест-Индиядәге зур булмаган биләмәләре, Франциянең «диңгез аръягы департаментлары». (1 нче бирем.)

**2. Табигый алшартлары һәм ресурслары: байлыгы һәм төрлелеге.** Латин Америкасының файдалы казылмаларының байлыгы һәм төрлелеге аның зур территориясенең геологик һәм тектоник төзелешенең үзенчәлекләре белән аңлатыла. Кара һәм төсле металлар, бигрәк тә тимер рудасы, литий, молибден, бакыр, никель, аккургаш бассейннары һәм чыганаклары, испан конкистадорларын үзенә тарткан алтын һәм көмеш чыганаклары — Көньяк Америка платформаларының кристаллик нигезе, шулай ук Кордильер тауларының һәм Андның җыерчыклы поясы белән бәйле. Ә бу поясның читтәге һәм тау араларындагы сыртларында нефть һәм табигый газның зур ятмалары барлыкка килгән.

**Мисал.** Регионда иң зур нефтьгаз бассейннары Венесуэлада һәм Мексикада. Венесуэлада ул — Кариб диңгезенә чыгучы таулар арасы үзәгендә урнашкан Маракайбо бассейны. Нефть биредә коры җирдә дә, Маракайбо күле акваториясендә дә бар. Мексикада ул коры җирдә дә, Мексика култыгындагы шельфта да урнаша.

Латин Америкасы бокситларга да бай, аларның барлыкка килүе җилдән яргаланудан ясалган латерит кабыгы белән һәм күп кенә руда булмаган файдалы казылмалар, бигрәк тә селитра һәм күкерт белән бәйле. (2 нче бирем.)

Регионның торгызыла торган табигый ресурсларга байлыгы һәм аларның төрлелеге беренче чиратта аның экваториаль, тропик һәм субтропик климатлы поясларда урнашкан булуы белән бәйле.

Әмма рельеф, океан агымнары һәм башка факторлар үз эзләрен калдыра: «тьерра кальенте» (эссе җир) һәм «тьерра темплада» (уртача җир) белән беррәттән, биредә «тьерра фриа»ны да (салкын җир) очратырга мөмкин. Аерым елларда көньяктан үтеп кергән салкын һава массалары авыл хуҗалыгына һәлакәтле йогынты ясый. [2]. Өстәвенә явым-төшемнең еллык бүленеше шушы күренешкә мөһим төзәтмәләр кертә, һәм артык дымлы зоналар (Амазония) белән беррәттән, Мексика, Чили, Аргентинада ясалма сугару таләп итеглә торган районнар да бар. Шуның өстенә *Эль-Ниньо күренеше* кебек табигый катастрофаларның кабатланып торуы бигрәк тә Латин Америкасы өчен хас. Бу — Тын

океан яры буйларындагы, гадәттә, шактый салкын өске катлам суларының аномаль җылынуы белән бәйләнгән. [3].

*Су ресурслары белән тәэмин ителеше ягыннан Латин Америкасы дөньядагы эре регионнар арасында беренче урында тора*, ә икътисади гидроэнергетик потенциалының зурлыгы ягыннан ул Азия чит илләреннән генә калыша.

Латин Америкасының гаять зур байлыгы — регион территориясенең яртысыннан күбрәген алып торган урманнар. [4]. В. Терешкова күзәтүләре буенча, Латин Америкасының космостан яшел континент булып күренүе очраклы түгел, ә шул ук вакытта Азия — куе көрән, Африка сары төстә булып күренә. Регионның хайваннар дөньясы да шулай ук бик бай һәм күптөрле. [5].

*Тулаем алганда, Латин Америкасы территориясенең күп өлешендә табигый шартлар кешеләрнең яшәве һәм аларның хуҗалык эшчәнлеге өчен уңайлы.* Әмма күп кенә очракларда алар җитәрлек рациональ файдаланылмый, ә кайвакыт бу ресурсларны ерткычларча файдаланалар. (3 нче бирем.)

**3. Халкы: яңарып торуы, этник составы, урнашуы, урбанизация.** Инде белгәнегезчә, Латин Америкасы өчен халык яңарып торуының икенче тибы хас. Гәрчә демографик шартлауның иң югары ноктасы биредә әле 50—60 нчы елларда ук үтелгән булса да, Үзәк Американың кайбер илләрендә, Көньяк Американың ярлырак илләрендә (Боливия, Парагвай) халыкның артуы елына 2—2,5 % тәшкил итә. Бу халык санына гына түгел, яшь структурасына да йогынты ясый, эшли торган халыкка карата балаларның нисбәтен арттыра. (4 нче бирем.)

Латин Америкасы халкының хәзерге этник составы өч төрле компонент тәэсирендә формалашкан.

*Беренче компонентны* регион территориясендә европалылар килгәнгә кадәр яшәгән *индеец кабиләләре һәм халыклары хасил итә.* Алар арасында югары игенчелек цивилизацияләрен булдырган Мексикадагы ацтеклар һәм майялар, Үзәк Андтагы инклар була. Безнең көннәрдә региондагы индеецлар төп халыкның 15 % ын тәшкил итә. Латин Америкасындагы бик күп географик атамалар, Төньяк Америкадагы кебек үк, индеецлар теленнән алынган. [6].

*Икенче компонентны Европадан,* иң элек Испаниядән һәм Португалиядән, *күчеп килгән халыклар барлыкка* китерә (аларны креоллар дип йөртәләр). [7]. XIX гасыр башына кадәр Европадан иммиграция чагыштырмача аз була, әмма соңрак ул зур масштабларга җитә.

*Өченче компонентны африкалылар тәшкил итә,* аларны XVI гасырдан башлап, плантацияләрдә эшләтү өчен, колонизаторлар Бразилиягә, Вест-Индиягә һәм кайбер башка илләргә китерәләр. Өч гасыр буена коллар белән сәүдә итү сәбәпле хәзер Латин Америкасында негрлар барлык халыкның 1/10 ен тәшкил итә.



94



95

96

94 нче рәсем. Трансамазонка шоссесы

95 нче рәсем. Лимада ярлыларының тораклары

96 нчы рәсем. Аргентинаның тимер юллар челтәре

97 нче рәсем. Амазонияне үзләштерү

98 нче рәсем. Бразилиа шәһәренең планы

9 нчы таблица

**Латин Америкасында иң зур шәһәр агломерацияләренең үсеше (млн кеше)**

| Агломерацияләр | 1920 | 1950 | 1970 | 1980 | 1990 | 2005 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Мехико | 0,7 | 3,1 | 9,1 | 13,9 | 16,9 | 18,9 |
| Сан-Паулу | 0,6 | 2,4 | 8,1 | 13,0 | 17,1 | 19,6 |
| Рио-де-Жанейро | 1,3 | 5,0 | 7,0 | 8,7 | 9,8 | 11,2 |
| Буэнос-Айрес | 2,3 | 5,3 | 8,4 | 10,0 | 10,5 | 13,0 |

97



КОЛУМБИЯ
Боа-Виста
АТЛАНТИЧЕСКИЙ ОКЕАН
Макапа
Белен
Сантарен
Алтамира
Сан-Луис
Манаус
Итайтуба
ТРАНСАМАЗОНСКОЕ ШОССЕ
Амазонка
Журуа
Мадейра
Тапажос
Шингу
Тукуруи
Сьерре-дус-Каражас
Арагуая
Токантинс
в Лиму
Порту-Велью
Риу-Бранку
БОЛИВИЯ
Журуэна
Куяба
БРАЗИЛИА
240 км
Амозониянең Бразилия өлеше чикләре
Гамәлдәге шоссе һәм грунт юллар
Төзелә торган шоссе-һәм грунт юллар
Үзләштерелгән һәм халык урнашкан территорияләр
Үзләштерү һәм халык урнашу өчен проектлаштырылган полосалар
Проектлаштырыла һәм төзелә торган ГЭСлар
Проеклаштырылган промышленность объектлары
Терлекчелек хуҗалыклары (гамәлдәге һәм проектлаштырылганы)
Файдалы казылмалар
тимер рудалары
марганец рудалары
кургашын рудалары
бокситлар
алмазлар




98
ПЕНИНСУЙЛА
Акампоменту
РАСГАДУ
ГАМА
ПАРАНОА
оз. Параноа
Гама
0
2,5 км
Торак кварталлар
Җәмәгать һәм мәдәният үзәкләре
Шәһәр яны зонасы
Промышленность районнары
Саннар белән билгеләнгән:
1. Зоопарк
2. Университет
3. Вокзал
4. Аэропорт
5. Телевизион үзәк
6. Обсерватория
7. Стадион
8. Ботаника бакчасы
9. Плотина
10. Хөкүмәт учреждениеләре
11. Президент резиденциясе

Регион халкының яртысыннан артыгы — катнаш никах токымнары: метислар, мулатлар. Шуңа күрә барлык Латин Америкасы милләтләре катлаулы этник нигезгә ия. Мексикада һәм Үзәк Америка илләрендә, нигездә, метислар; Гаити, Ямайка, Кече Антиль утрауларында негрлар өстенлек итә. Анд илләренең күбесендә индеецлар һәм метислар күпчелекне тәшкил итә, Аргентина, Уругвай һәм Коста-Рикада — испан телле креоллар, ә Бразилиядә мулатлар һәм негрлар ак тәнлеләргә караганда бик азга гына кимрәк яши.

Латин Америкасын колонизацияләү тарихы регионның тел составына да [8], дини составына да хәлиткеч йогынты ясады. Латин Америкасы халкының күбесе католик динен тота. Ул заманында бердәнбер рәсми дин буларак кертелгән, ә инде башка төрле диннәргә ышанучыларны инквизиция эзәрлекләгән. (5 нче бирем.)

Латин Америкасына үзенә бертөрле мәдәниятләр дуализмы хас. Биредә, бигрәк тә индеецлар һәм метислар арасында, тамырлары белән Колумбка кадәрге заманнарга барып тоташучы төп халыкның үзенчәлекле мәдәнияте сакланып калган. Болар — мифологик һәм тарихи эпос, музыка һәм биюләр, шулай ук тарих һәм архитектура истәлекләре: ацтеклар, тольтеклар һәм майяларның Мексикадагы пирамидалары һәм сарайлары, инкларның Перудагы Мачу-Пикчу шәһәр-крепосте. Алар Бөтендөнья мирасына кертелгән. [9]. Бу — шулай ук Европа мәдәни хәзинәләренә юнәлеш тотып, әдәбият, сәнгать, музыка, театр, архитектурада чагылыш тапкан яңарак мәдәният. Дини бәйрәмнәрдән тыш, төрле карнаваллар, коррида, родео да киң таралган. Футбол искиткеч зур популярлык казана.

Латин Америкасы халкы урнашуының өч төп үзенчәлеге бар. Беренчедән, ул — дөньяның иң аз халыклы регионнарының берсе, анда 1 км$^2$ га уртача 27 кеше туры килә. Икенчедән, анда халыкның тигез урнашмавы башка зур регионнарга караганда күбрәк чагыла. Өченчедән, *дөньядагы башка бер генә регионда да халык яссытаулыкларны шулкадәр күп үзләштермәгән һәм тауларга шулкадәр биеккә менмәгән.* [10]. (6 нчы бирем.)

Урбанизация күрсәткечләре ягыннан Латин Америкасы үсеп килүче илләрне түгел, ә икътисади үсеш алган илләрне хәтерләтә: регионда урбанизациянең уртача дәрәҗәсе бик югары (80 %), ә темплары хәзер инде акрынайган. Халык бигрәк тә зур шәһәрләрдә (300 дән артык) һәм миллионер шәһәрләрдә (40 тан артык) күбрәк туплана. Регионда үзенчәлекле **шәһәрләрнең Латин Америка тибы** барлыкка килде.

Колониаль шәһәрләр Испания белән Португалия үз биләмәләре өчен эшләгән бердәм план буенча салынган. Шәһәрнең үзәге булып гадәттә үзәк мәйдан («пласа майор») хезмәт итә, анда ратуша, чиркәү, административ биналар урнаша.

Урамнар, шул мәйданнан туры почмак ясап таралып, «шахмат» челтәре барлыкка китерәләр. Соңгы унъеллыкларда заманча төзелгән йортлар да шунда урнаша.

*Латин Америкасында шәһәр агломерацияләре формалашуның актив процессы бара.* Аларның дүртесе гадәттән тыш зур шәһәрләр исәбенә керә (9 нчы таблица). Бу рәттә беренче урын Олы Мехикога бирелә. Ил территориясенең 0,5 % ын биләп, ул халыкның 1/5 еннән артыгын үзендә туплый. Гаять зур бу агломерациянең тиз үсүе мигрантлар агымы исәбенә бара: ел саен бирегә 250—300 мең кеше килә!

Олы Мехико таулар арасындагы казанлыкта, диңгез тигезлегеннән 2250 м биеклектә урнашкан. Ул — Америка башкалаларының иң борынгысы. 1176 елда индеецлар кечкенә генә күл уртасындагы утрауда Теночтитлан шәһәренә нигез салалар. Испаннар аның урынында чынлыкта яңа шәһәр — үз урбанистик стиленең барлык кагыйдәләрен саклап, Яңа Испания колониясенең башкаласын төзиләр. Бүгенге көндә Мехиконың үзәк районнарында бай һәм урта хәллеләр өстенлек итсә, ә читтә, «хәерчелек пояслары»нда, ярлылар яши.

Континентның көньяк өлешендә иң зур агломерация — Олы Буэнос-Айрес. [11]. Анда ил халкының 1/3 е тупланган. Кайбер галимнәрнең фикеренчә, Мексика, Бразилия һәм Аргентинада беренче мегалополислар оеша башлаган.

Латин Америкасында дөньяның үсеп килүче башка регионнарына да хас булган һәм, гадәттә, **«ялган урбанизация»** дип йөртелгән үзенчәлек бигрәк тә ачык чагылыш тапкан. *«Ялган урбанизация» ул — шәһәр халкының өлеше икътисади яктан актив, ягъни җитештерүче һәм җитештермәүче сфераларда эшләүче халык өлешеннән күпкә артып киткән урбанизация төре.* «Ялган урбанизация»нең төп сәбәбе — шәһәрләргә ярлы авыл халкының туктаусыз агылып торуы һәм хакимиятнең аларны эш белән дә, торак белән дә тәэмин итә алмавы. Алачыклар, «хәерчелек пояслары» барлыкка килү нәкъ менә шундый урбанизация белән бәйләнгән, ул алачыкларда күп кенә зур шәһәрләрнең 30—50 % халкы яши (95 нче рәсем). (7 нче бирем.)

**4. Хуҗалыкның үсеш каршылыклары.** Территориясе һәм халык күләме ягыннан Азия белән Африкадан калышкан *Латин Америкасы социаль-икътисади үсеш дәрәҗәсе ягыннан алардан өстен.* 80 нче еллардагы авыр кризистан соң (бирeдә аны «югалган унъеллык» дип йөртәләр), регион мөһим сәяси һәм социаль-икътисади реформалар — җәмгыять төзелешен демократияләштерү, базар икътисадын үстерү, дөнья хуҗалыгындагы элемтәләргә күбрәк тартылу, интеграцион төркемнәр булдыру юлына аяк басты. Нәтиҗәдә 90 нчы елларда Латин Америкасының дөнья хуҗалыгындагы роле үсә башлады.

Ләкин әле барлык социаль-икътисади проблемалар да чишелә алмады. Аерым илләрдә (мәсәлән, Аргентинада) булып торган икътисади кризислар шул турыда сөйли. Күп илләрнең Көнбатышка булган зур финанс бурычы аларның икътисадына авыр йөк булып ята. [12]. Хәзерге вакытта регионның күпчелек илләре дәүләт милкен хосусыйлаштыру, чит ил капиталын җәлеп итү юлына басты.

Латин Америкасының промышленностена озак вакытлар буена беренче чиратта тау казылмалары чыгару промышленносте тармакларының үсеше хас булды. Алар әле хәзер дә үзләренең әһәмиятен саклап кала. (8 нче бирем.) Шуның белән бергә, соңгы вакытларда, Африкадан аермалы буларак, *алдынгы роль эшкәртү промышленностена күчте,* шул исәптән аның төп тармакларына (кара һәм төсле металлургия, нефть эшкәртү) һәм ФТРның авангард тармакларына.

**Мисал.** Бразилиядә — электроника, автомобиль, судно, самолет төзү, Мексикада — автомобиль, станоклар җитештерү, электр техникасы, электроника, Аргентинада автомобиль, станоклар җитештерү үсеш алган.

Шуңа да карамастан барлык эшкәртү промышленностеның 4/5 е регионда «зур өчлек»кә — Бразилия, Мексика һәм Аргентинага туры килә.

Региондагы авыл хуҗалыгына бигрәк тә кискен үсеш каршылыклары хас, ул *бөтенләй капма-каршы ике сектордан тора.*

Беренче сектор — югары товарлыклы, башлыча плантацияләр хуҗалыгы. Ул күп кенә илләрдә, бигрәк тә районнарда монокультура характерын алды.

**1 нче мисал.** Бананны дөньяда иң күп җитештерүчеләр — Бразилия, Коста-Рика, Колумбия, Эквадор, Мексика. Җыеп алынган бөтен банан уңышы диярлек бередән судно-рефрижераторларда Европага, АКШка чыгарыла, юлда алар тәмам өлгереп җитә.

**2 нче мисал.** Кубада 1959 елгы революциягә кадәр шикәр җитештерү һәм аны читкә чыгару монокультура булып торды. Бүгенге көндә дә шикәр камышы плантацияләре ил территориясендәге эшкәртелә торган җирләрнең 1/2 ен били. 150 дән артык шикәр заводы («сентраль») елына 3,5—4 млн т шикәр чималы җитештерә. Шикәр камышы үстерү һәм шикәр промышленносте — Кубаның халыкара специальләшү тармагы.

Латин Америкасының уртача климатлы зонасында урнашкан Аргентина Пампасында азык-төлек һәм чимал җитештерү, эшкәртү һәм аны читкә чыгару буенча иң эре агропромышленность комплексы барлыкка килде.

Әле XIX гасыр башында ук очсыз-кырыйсыз Пампа далаларында кеше бик аз яши, аларны көтү йөртү өчен файдаланалар: моның белән җирле ковбой-гаучолар шөгыльләнә иде. Әмма инде гасыр ахырында Пампа Аргентинаның экспорт өчен бодай, кукуруз, ит җитештерүче төп авыл хуҗалыгы районына әверелә. Яшь терлекләрне Коры Пампада —

аның читтәге, корылыклы өлешләрендә үстерәләр, ә Дымлы Пампаның бай көтүлекләрендә терлекләрне симертәләр. Менә ни өчен Пампаны еш кына «ит фабрикасы» дип атыйлар, ә терлекләрне төп сую урыны булган Буэнос-Айресны «ит башкаласы» яисә «Аргентина Чикагосы» дип йөртәләр.

Икенче сектор — аз товарлыклы, кулланучы авыл хуҗалыгы, «яшел революция» аңа бөтенләй кагылмаган. Анда эшләүче крестьяннар кукуруз, маниока, фасоль, яшелчә, бәрәңге үстерәләр. [13]. (9 нчы бирем.)

*Регион авыл хуҗалыгының артка калуының төп сәбәпләреннән берсе — җир биләү һәм җирдән файдалануның искергән формалары сакланып калуда.* Эре алпавыт җирбиләүчелеге биредә әле колония чорында ук оеша, ул чагында Мексикада — гасиендалар, Бразилиядә — фазендалар, Аргентинада эстансияләр барлыкка килә. Андый эре утарларны ***латифундияләр***[1] дип атау кабул ителгән. Аларда җир чиктән тыш нәтиҗәсез файдаланыла, аның бик аз өлеше генә эшкәртелә. Икенче полюста исә — вак крестьян җирбиләүчелеге (минифундияләр) һәм миллионлаган бөтенләй җирсез крестьяннар.

Латин Америкасының транспорты да зур каршылыклы булуы белән аерылып тора. Тимер юлларның шактый озын булуына карамастан, аларның техник тәэмин ителеше түбән. Эчке су юллары, торбаүткәргечләр дә җитәрлек үсмәгән, һава һәм автомобиль транспорты чагыштырмача яхшырак үсеш алган. [14]. Диңгез портлары зур роль уйный, тышкы икътисади элемтәләр шулар аша башкарыла. Ә Панама, белгәнегезчә, диңгез флотының тоннажы буенча дөньяда беренче урында тора.

Мексика һәм кайбер Вест-Индия илләре икътисадында туризм зур урын алган. Аларның кайберләрен (Багам утраулары) хәтта «фатиргә кертүче илләр» дип тә йөртәләр.

**5. Хуҗалыкның территориаль структурасы: «бер ил эчендә ике ил».** Белгәнегезчә, бу әйтем хуҗалыкның территориаль структурасының колониаль тибы сакланып калган үсеп килүче күп кенә илләрдә хуҗалык һәм халык урнашуының географик сурәтенең төп үзенчәлеген тасвирлый. Латин Америкасы илләрендә дә башкала яки «икътисади башкала», кагыйдә буларак, барлык территориянең төп үзәге, «фокусы» ролен үти.

**Мисал.** Мехикога, Лима, Сан-Паулу, Буэнос-Айреска илләрдә җитештерелгән барлык промышленность продукциясенең 1/2 өлешеннән артыгы, ә Монтевидеога хәтта 3/4 е туры килә.

Бу илләрдә дә минераль чимал һәм ягулык табуга яисә плантация культуралары игүгә специальләшкән күп кенә районнар эчкәреге өлешләрдә урнашкан.

[1] Латифундия (грек. *latos* — зур һәм *fundus* — биләмә) — хосусый милекченең зур җир биләмәсе.

Шуңа күрә әле XIX гасыр ахыры — XX гасыр башында ук төзелгән тимер юллар челтәре еш кына үзенә бер төрле агач (җилпәзә) рәвешендәге структурага ия (96 нчы рәсем), ә аның «үсеш ноктасы» булып диңгез порты хезмәт итә.

Регионның күп кенә илләрендә территориаль диспропорцияләрне киметүгә юнәлтелгән региональ сәясәт үткәрелә.

**Мисал.** Мексикада җитештерүче көчләр төньякка, АКШ чигенә таба [15], Венесуэлада — көнчыгышка, ресурсларга бай Гуаяна районына, Бразилиядә — көнбатышка, Амазониягә, Аргентинада көньякка, Патагониягә таба күчә башлады.

Мондый күчүне тизләтү өчен, Бразилиядә башкаланы Рио-де-Жанейродан яңа шәһәргә — Бразилиага күчерделәр. Аргентинада да шундый күченү күздә тотыла. (10 нчы иҗади бирем.)

**6. Мохитне саклау һәм экологик проблемалар.** Әле күптән түгел бу проблемаларга регионда чагыштырмача аз игътибар бирелә иде. Бу хәл урманнарның контрольсез киселүенә, хайваннарның генофонды кимүенә, туфрак эрозиясе процессларының тизләнүенә, кислоталы яңгырлар явуга китерде. Төп промышленностьлы шәһәр агломерацияләрендә бигрәк тә куркыныч экологик ситуация туды.

**Мисал.** Лос-Анджелес кебек ук, Мехиконы да «корым полисы» дип атыйлар: һаваның пычрануы (шәһәрдә 3 млн нан артык автомобиль бар) рөхсәт ителгән нормаларны күп мәртәбәләр узып китә. Моннан тыш, Мехико грунт суларын шулкадәр күп чыгара, хәтта аның территориясе инде берничә метрга түбәнгә иңгән.

Соңгы елларда гына табигатьне саклау һәм экология проблемаларына күбрәк игътибар бирелә башлады.

## 2. БРАЗИЛИЯ БЕЛӘН ТАНЫШАБЫЗ

**1. Бразилия — тропик гигант.** Бразилия — Латин Америкасында иң зур ил-субрегион, анда бөтен регионга хас булган күп кенә сыйфатлар ачык чагыла.

Бразилия — дөньяда табигый ресурсларга иң бай илләрнең берсе. Биредә минераль чималның 50 гә якын төрен чыгаралар, бигрәк тә рудалы төрләр күп чыгарыла. Эшкәртелә торган җирләрнең мәйданы ягыннан ил алдынгы урыннарның берсен алып тора. Аның су ресурслары, шул исәптән гидроэнергетика, урман ресурслары бик зур. Болар һәммәсе дә икътисади үсеш өчен бик тә уңайлы алшартлар тудыра.

Бразилия халкы ел саен 2,5 млн га артып тора, ул «беренче бишлек» илләренә керә. Бу да икътисади үсешкә ярдәм итә, әмма шул ук вакытта эшсезлек, «ялган урбанизация» һәм башка проблемаларны кискенләштерә.

*Бразилия — үсеп килүче дөньяның лидерлары арасында төп урынны тотучы илләрнең берсе.* ТЭП күләме буенча ул Латин Америкасында беренче, үсеп килүче илләр арасында өченче урында (Кытай һәм Һиндстаннан кала) тора,

ә промышленность җитештерүе күләме буенча, инде белгәнегезчә, дөньяда ун үзәкнең берсен тәшкил итә.

Колонияләштерүнең беренче этабында португаллар, Бразилия урманнарында кызыл агач әзерләп, аннан буяу алалар. [16]. Аннары XVII гасыр ахырына кадәр дәвам иткән һәм илнең Төньяк-Көнчыгышының үсешенә булышкан «шикәр бизгәге» башлана. XVIII гасыр тулысы белән Рио-де-Жанейродан төньяктарак урнашкан Минас-Жерайс штатына («Төп рудниклар») кагылган «алтын бизгәге» билгесе астында үтә. Ә XIX гасыр уртасында кофе шаукымы башлана, һәм икътисади тормыш үзәге бу юлы Сан-Паулу штатына күчә. [17]. Моңа тагын каучук, какао шаукымын өстәгез. Шулай итеп, берничә йөз ел буена Бразилиянең халыкара специальләшү тармаклары алмашынып тора.

Бразилия ел саен 2 млн нан артык автомобиль җитештерә, алар (сыек ягулыкка экономия ясау өчен) шикәр камышыннан алына торган этил спиртында эшләүгә көйләнгән. Электр техникасы һәм электроника югары дәрәҗәдә үсеш алган; фәнсыешлы башка производстволар да үсә. Эре хәрби промышленность булдырылган. Дөньяда иң зур ГЭСлар төзелгән. [18]. Шулар белән беррәттән Бразилия кофе, шикәр камышы, банан җитештерү буенча дөньяда беренчелекне саклап килә, ә соя, апельсин уңышы ягыннан АКШтан гына калыша.

Шуңа да карамастан Бразилия икътисадының тармак структурасы әле җитәрлек дәрәҗәдә камилләшмәгән. Беренче чиратта бу авыл хуҗалыгына кагыла, анда зур мәйданнарны аз продуктлы куллану культуралары алып тора. 1998 елда башланган финанс кризисы ил икътисадына тискәре йогынты ясады.

**2. Хуҗалыкның территориаль структурасындагы үзгәрешләр: көнбатышка таба күчү.** *Бразилия — халыкның һәм хуҗалыкның урнашуы буенча океан яны тибына керә торган ил.*

**Мисал.** Океан ярының 300—350 км киңлегендә Бразилия халкының һәм производствосының 9/10 ы тупланган. Ә аның эчке территорияләре начар үзләштерелгән, һәм анда халык аз яши. Рио-де-Жанейро районында халык Амазониядәгегә караганда 800 мәртәбә тыгызрак урнашкан.

Рио-де-Жанейро, Сан-Паулу һәм Белу-Оризонти шәһәрләре арасындагы районны Бразилиянең «индустриаль өчпочмагы» дип атыйлар. Аның һәр «түбәсе»нең үз специальләшүе һәм үз йөзе бар.

Рио-де-Жанейро шәһәре озак вакытлар буена Бразилиянең башкаласы булып килде. Ул — зур порт шәһәре, шәһәр-банкир, туризм шәһәре. Әмма башкаланы 1960 елда бүтән шәһәргә күчергәннән һәм Сан-Паулуның көндәшлек куәте үсә башлаганнан соң, аның әһәмияте беркадәр кимеде.

Рио-де-Жанейро дөньядагы иң матур шәһәрләрнең берсе булып санала. Ул киң Гуанабара бухтасы яр буена урнашкан, яр буйлап атаклы Копакабана пляжы, торак йорт кварталлары, порт һәм промышленность

районнары сузылган. [19]. Шәһәрдән Корковадо тавында Христосның 40 метрлы сыны күренеп тора. Рио (бу шәһәрне Бразилиядә, гадәттә, шулай дип атыйлар) олы пост алдыннан дүрт көн һәм биш төнгә сузылган карнаваллары, дөньяда иң зур, Мәскәүдәге «Лужники» стадионына караганда ике тапкыр зуррак, 200 мең кеше сыйдырышлы «Маракана» футбол стадионы белән дан тота. Әмма бер үк вакытта ул — зур социаль каршылыклар шәһәре дә. Алачыклар («фавел») кварталларында йөз меңләгән ярлылар — «фавеладослар» яши.

Сан-Паулу — Бразилиядәге иң зур шәһәр һәм аның «икътисади башкаласы». Аны Бразилия икътисадының бөтен составын тартып баручы локомотив дип йөртәләр. Әле XIX гасыр урталарында ул кечкенә генә провинциаль шәһәр була. Кофе шаукымы һәм Европа белән Япониядән иммигрантлар агылу аркасында ул бик тиз үсеп китә. *Акрынлап биредә Бразилиянең, бөтен Латин Америкасының, шулай ук көньяк ярымшарның төп промышленность районы барлыкка килә.* Биредә фәнсыешлы тармак предприятиеләре, шулай ук банклар һаман күбрәк туплана.

Сан-Паулу — үтә биек йортлар шәһәре, шуңа күрә аны Латин Америкасының Нью-Йоркы дип йөртәләр. Безнең журналистларның берсе: «Күз күреме җиткән хәтле җирдә, бер-берсенә сыенып, егерме, утыз, иллешәр катлы күксөзәрләр тора: бар җирдә — өскә таба сузылган турыпочмаклыклар, түгәрәк манаралар, бөгелгән синусоидалар»,— дип яза. Биредә корпорацияләр, банк, биржаларның (шул исәптән кофе биржасының) штаб-фатирлары, ә промышленность предприятиеләре Олы Сан-Паулуның периферия өлешләрендә, иярчен шәһәрләрендә урнашкан. Периферия зонасы ул — бик кысан, тыгыз шартларда көн күрүче ярлыларның яшәү урыны.

Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Бразилия үз территориясенең 3/5 ен биләп торган Амазонияне үзләштерүгә һәм анда халыкны күчереп утыртуга юнәлдерелгән региональ сәясәт үткәрә башлады. Шушы максат белән яр буеннан мең ярым км ераклыкта илнең яңа башкаласы — Бразилиа төзелде, ул илнең үзенә бертөрле яңа символы булып китте. [20].

70 нче елларда Трансамазонка шоссесы — 5,5 мең км озынлыктагы төп «әчкә үтеп керү юлы» салынды. Шоссе буйлап тау казылмалары чыгару (тимер рудасы чыгаруга, эшкәртүгә һәм аны экспортка җибәрүгә нигезләнгән «Зур Каражас» проекты), агач әзерләү предприятиеләре, терлекчелек ранчолары, агробистәләр, зур ГЭСлар төзелә башлады. Әмма Амазонияне үзләштерү, бирегә халыкны күчереп утырту шактый ук тәртипсез бара, һәм ул экологик тигезләнешнең инде бик куркыныч төстә бозылуына китерде. (11 нче иҗади бирем.)

**Төп нәтиҗә.** *Латин Америкасы чагыштырмача югары икътисади үсеш дәрәҗәсе белән аерылып тора. ул үсеп килүче һәм үсеш алган илләр арасындагы урта бер урынны алып тора сыман.* (12 нче йомгаклау биреме.)

## ӨСТӘМӘ ТЕКСТ (Кызыклы мәгълүматлар)

[1] Мәскәү — Гавана авиарейсы — 14, Мәскәү — Буэнос-Айрес рейсы 19 сәгать дәвам итә. Одесса — Буэнос-Айрес диңгез трассасы 14 мең км га тигез.

[2] 1975 елның җәендә Антарктидадан килгән салкын һава дулкыны Бразилиянең 3,5 млрд кофе агачының шактый өлешен юк итте яисә зарарлады. Бу хәл кофе җитештерүнең бик нык кимүенә һәм дөньяда аңа бәяләрнең артуына китерде. 1994 елдагы салкыннар 200 мең кофе агачын һәлак итте, бу да бөтендөнья базарында кофега бәяләрнең артуына китерде.

[3] Эль-Ниньо күренеше соңгы тапкыр бик көчле формада 1997—1998 елларда күзәтелә. Аның аяныч нәтиҗәләре итеп Перу яр буе суларында анчоуслар тотуның тулысынча диярлек тукталуын, Амозония, Мексика, АКШның Көньягындагы урман янгыннарын, Бразилиядә, Колумбия, Үзәк Америка илләрендә корылык һәм көчле яңгырлардан кофе, Кубада шикәр камышы җыюның кискен кимүен күрсәтергә кирәк. Бу күренешнең аяныч нәтиҗәләре Америкада гына түгел, ә Африкада, Азиядә дә сизелерлек булды. Аннан килгән гомуми зыян 50 млрд долларда бәяләнә.

[4] Күп кенә агач токымнары: кызыл агач, сандал агачы, бик җиңел үзагачлы бальс агачы («Кон-Тики» салын төзегәндә Тур Хейердал нәкъ менә бальс агачын файдалана) аеруча кыйммәтле үзагач бирәләр. Ылыслы токымнарның реликтлары — Бразилия һәм Чили араукариясе — шулай ук төзелеш һәм столярлык өчен үзагачы белән дан тота.

[5] Шунысы кызыклы: Латин Америкасы илләренең дәүләт гербларында хайваннар дөньясының күп вәкилләренең сурәтләрен очратырга мөмкин: Перу гербында — лама, Гайанада — ягуар, Ямайкада — крокодил, Гренада гербында — бронялы. Әмма шулай да гербларда кош сурәтләре аеруча еш очрый: Мексика, Панама, Колумбия, Эквадор, Боливиядә — кондора яисә бөркет, Барбадоста — пеликан, Доминикада — попугай, Багам утрауларында — фламинго, Тринидад һәм Тобагода — колибри һәм ал тәкәрлек.

[6] Гватемала, Никарагуа, Панама, Куба, Ямайка, Перу, Парагвай кебек илләрнең, Мехико, Куско, Гуаякиль, Пернамбуку,

Тегусигальпа кебек шәһәрләрнең исемнәре индеецлар теленнән кергән. Алар кайбер табигать объектларының исемнәрендә дә сакланганнар, мәсәлән, Орисаба, Попокатепетль вулканнары, Маракайбо һәм Титикака күлләре, Парана һәм Ориноко елгалары, Юкатан ярымутравы, Атакама чүле һ. б.

[7] Латин Америкасына Испаниядән конкистадорлар белән бергә бик күп географик исемнәр дә күчеп килгән. Мәсәлән, Мексикадагы Гвадалахара, Саламанка, Вальядолид, Мерида шәһәрләре, Венесуэладагы Валенсия һәм Барселона, Колумбия һәм Уругвайдагы — Толедо, Аргентина һәм Перудагы Кордова шәһәрләренең исемнәре шундыйлар.

[8] Латин Америкасының 33 бәйсез дәүләтенең 18 ендә (барлык халыкның 63 % ы) рәсми тел булып — испан теле, Бразилиядә (регион халкының 34 % ы) португал теле санала. Халыкның калган 3 % ы кечкенә илләрдә яши, аларда рәсми тел булып инглиз, француз һәм голланд телләре санала.

[9] Бөтендөнья мирасы объектларының гомуми саны буенча Латин Америкасы бары тик Европа чит илләре һәм Азия чит илләреннән генә калыша («Кушымта»дагы 10 нчы таблицаны карагыз). Аның якынча 2/3 өлеше мәдәни мирас объектларына карый, күбесе Колумбка кадәрге дәверне чагылдыра. Болар — Мексикада Паленке, Чичен-Ица, Ушмаль кебек майя шәһәрләре, ацтекларның Теотиуакан шәһәре калдыклары, Перудагы инклар дәүләтенең борынгы башкаласы — Куско шәһәре фрагментлары, Наска чүленең табышмактай рәсемнәре, Боливиядә — Титикака күле буендагы Тиуанако археологик резерват. Тын океандагы Тур Хейердал тарафыннан тасвирланган Пасха утравының танылган таш сыннары да Колумбка кадәрге чорга карый.

[10] Боливиядәге Ла-Пас шәһәре диңгез өслегеннән 3630 м биеклектә урнашкан; бу — дөньяда иң биек утырган башкала. Анд тауларындагы аерым авыллар 4500—5000 м биеклектә урнашкан. Перуда әле XIX гасыр ахырында ук дөньяда иң биектә урнашкан тимер юл салына, ул 4800 м биеклектә, Монблан биеклегендә диярлек.

[11] 1536 елда испан конкистадоры Педро де Мендоса Ла-Платаның уң як ярында авыл төзи, аны Сьюдад-де-ла-Сантисима-Тринидад-и-Пуэрто-де-Нуэстра-Сеньора-де-Санта-Мария-де-лос-Буэнос-Айрес дип атый, мәгънәсе: «Изге Троица шәһәре һәм уңай җилләр хуҗасы изге Мария гаване». XIX гасыр башына шушы озын исемнең соңгы ике сүзе генә кала.

[12] 2005 елда Бразилия үзенең тышкы бурычларының күләме буенча (235 млрд доллар) дөньяда беренче урынны тоткан. Мексика (140 млрд) алтынчы, Аргентина (165 млрд) дүртенче урында булган.

[13] Бәрәңгенең ватаны — Перу таулыклары. Әле хәзер дә Перу базарларында сатыла торган төрле төстәге, зурлыктагы һәм формадагы бәрәңге бүлбеләре бирегә килгән кешеләрне хәйран калдыра.

[14] Дөньяда иң озын Панамерика шоссесы (аны төзү әле 1930 елда ук башлана) күп кенә Латин Америкасы илләренең башкалаларын тоташтыра. Аның гомуми озынлыгы — 33 мең км дан артык — АКШның Мексика белән чигеннән алып Буэнос-Айреска кадәр. Бу шоссе Панама каналын «Америкалар күпере» дип аталган күпер буйлап кисеп үтә.

[15] Мексика белән АКШның бөтен чиге буйлап «икеләтелгән шәһәрләр» рәте калкып чыкты, аларга Америка капиталыннан һәм арзанлы Мексика эшче көченнән файдаланучы промышленность предприятиеләренең үзенә бертөрле тибы хас. Алар автомобильләр өчен узеллар, көнкүреш электр техникасы һәм электроникасы, җиһаз һ.б. җитештерәләр, капиталны күп таләп итүче операцияләр — төньякта, бу шәһәрләрнең Америка өлешендә, ә хезмәтне күп сорый торганнары көньякта, Мексика өлешендә башкарыла. Андый предприятиеләрнең (аларны «макиладорас» дип атыйлар) бөтен продукциясе АКШ базарына килә.

[16] 1500 елда бүгенге Бразилия ярларына барып җиткән Португалия диңгезчесе Педру Кабрал ул вакыттагы традиция буенча үзе ачкан илгә Чын Тәре (Истинный Крест) Җире дигән исем бирә. Әмма инде тиздән аңа Бразил (Бразил Җире) дигән исем ныгып кала. Бу исем өчен ил кызыл сандал агачына бурычлы; португалиялеләр аны бразил дип атаганнар, аның кызгылт-сары үзагачы буяу эшендә кулланылган. Португалиягә Азиядән кайтартыла торган бу кыйммәтле агач Бразилия урманнарында табыла, һәм колонизациянең беренче этабында ул читкә чыгарыла торган төп предмет булып хезмәт итә.

[17] XVIII гасыр башында Голландиядәге ботаника күргәзмәсенә Явадан кофе агачы алып киләләр. Берничә елдан голландиялеләр аның үсентеләрен француз короле Людовик XIV гә бүләк итәләр. Кариб диңгезендәге бер француз колониясенең хәрби губернаторы яшь үсентеләрне Вест-Индиягә алып кайта. Кофе агачы шуннан француз Гвианасына, аннары инде Бразилиягә килеп эләгә, шунда ул икенче ватанын таба.

[18] Дөньядагы иң зур «Итайпу» ГЭСын Парана елгасының Бразилия-Парагвай участогында (атаклы Игуасу шарлавыгыннан ерак түгел) 1975 елда төзи башлыйлар. Станция беренче токны 1983 елда бирә, ә 90 нчы еллар башына барлык 18 агрегат та сафка баса, һәм аның гомуми куәте 12,6 млн кВт га җитә. 196 м биеклегендәге плотина 200 км озынлыктагы сусаклагыч барлыкка китерә. Токантинс елгасында 8 млн кВт егәрлекле «Туркуруи» ГЭСын кору дәвам итә.

[19] Педру Кабрал Бразилияне ачып ике ел үткәннән соң, Португал диңгезчесе Гонсалу Куэлью аның ярлары буйлап йөзеп үтә. Гуанабара бухтасын ул зур елганың тамагы дип уйлый һәм аны Рио-де-Жанейро, ягъни «гыйнвар елгасы» дип атый.

[20] Архитекторлар Л. Коста һәм О. Нимейер төзегән проект буенча, бу шәһәрнең планы самолетка охшаган, аның «фюзеляж»ына — административ һәм җәмәгать биналары, «канатлары»на — торак кварталлар, ә «пилот кабинасы»на президент, милли конгресс һәм хөкем итү сарайлары урнашкан (98 нче рәсем). Шунысы кызык: Бразилиа шәһәре — цивилизациянең хәзерге этабының Бөтендөнья мирасына кертелгән бердәнбер объекты.

**Китап киштәсе**


1. Америка. Общий обзор Латинской Америки. Средняя Америка. Южная Америка.— М.: Мысль, 1981—1983.— (Серия «Страны и народы»).
2. Максаковский В. П. Географическая картина мира.— М.: Дрофа, 2009.— Ч. 2 .— Тема 5.
3. Экономическая и социальная география мира: За страницами учебника: Кн. для учащихся 10 кл. / Сост. А. П. Кузнецов.— М.: Просвещение, 2000.— Раздел «Америка».
4. Весенский В. Огни больших городов: Очерки о Латинской Америке. — М.: Мысль, 1990.


## БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘР АЛУ ӨЧЕН ТУПЛАНМА

**1 нче бирем.** Дәреслек форзацындагы «визит карточкасы» буенча Латин Америкасы илләренең идарә итү формаларын һәм административ-территориаль төзелешен билгеләгез; дәфтәрдә таблица төзегез. Бу илләрне Азия чит илләре һәм Африка илләре белән чагыштырыгыз, аермаларны аңлатырга тырышыгыз.

**2 нче бирем.** Атластагы дөньяның минераль ресурслар картасын һәм Латин Америкасының икътисади картасын, «Кушымта»дагы 3, 4 нче һәм 5 нче таблицаларны файдаланып, аның аерым субрегионнарындагы файдалы казылмалар составына характеристика бирегез. Охшаш һәм аермалы якларны аңлатырга тырышыгыз.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Латин Америкасындагы файдалы казылмаларның бергә килгән төп территорияләрен билгеләгез һәм аларны контурлы картага төшерегез. Промышленностьны үстерү, яңа ресурслы районнарны үзләштерү өчен, алар нинди алшартлар тудыра?

**3 нче бирем.** Дәреслектәге 7—9 нчы рәсемнәрне, «Кушымта»дагы 6, 7 нче һәм 8 нче таблицаларны һәм атластагы җир, агроклиматик һәм су ресурслары карталарын файдаланып, регионның торгызыла торган табигый ресурсларына характеристиканы конкретлаштырыгыз.

**4 нче бирем.** Дәреслектәге 12—14 нче рәсемнәрне һәм атластагы туу, үлү һәм халыкның табигый арту карталарын файдаланып, халыкның яңарып торуына кагылышлы дәреслек материалларын конкретлаштырыгыз.

**5 нче бирем.** Атластагы бөтендөнья халыкларының һәм диннәренең карталары буенча Латин Америкасы халыкларының тел семьялыклары һәм төркемнәре, диннәренең төп үзенчәлекләрен конкретлаштырыгыз.

**Катлауландырылган өстәмә бирем.** Аерым илләрдә индеецларның өлеше гомуми халык санына карата түбәндәгечә (% ларда): Боливиядә — 63, Гватемалада — 54, Перуда — 47, Эквадорда — 40, Мексикада — 15, Чилида — 9, Панамада — 6, Венесуэла, Колумбия, Никарагуа, Сальвадор, Гондурас, Аргентинада — 2—4. Шушы мәгълүматларны файдаланып, регионның контурлы картасында картограмма төзегез. 350 нче биттәге күрсәтмәне кулланыгыз.

**6 нчы бирем.** Атластагы халык тыгызлыгы картасын файдаланып, Латин Америкасы халкының дәреслектә әйтеп үтелгән төп урнашу билгеләрен конкретлаштырыгыз.

**7 нче бирем.** Дәреслектәге 17, 18 нче рәсемнәрне һәм 3, 9 нчы таблицаларны, «Кушымта»дагы 16, 17 нче таблицаларны, шулай ук атластагы урбанизация картасын файдаланып, Латин Америкасында урбанизация процессына характеристиканы конкретлаштырыгыз. Күбрәк һәм азрак урбанизацияләнгән илләрне билгеләгез. Урбанизация дәрәҗәсе һәм темплары буенча Латин Америкасын Азия чит илләре һәм Африка белән чагыштырыгыз.

**8 нче бирем.** Дәреслек текстын, атластагы Латин Америкасының икътисади картасын файдаланып, регионның контурлы картасына түбәндәге казылмаларны чыгаруга һәм экспортлауга специальләшкән төп илләрне төшерегез: нефть, тимер рудасы, бакыр рудасы, боксит, кургаш рудасы, күкерт, селитра. Мондый специальләшүнең сәбәпләрен күрсәтегез.

**9 нчы бирем.** Дәреслек текстын, Латин Америкасының атластагы физик һәм икътисади карталарын файдаланып, регионның контурлы картасына кофе, какао, шикәр, банан, бодай, кукуруз, ит җитештерү буенча специальләшкән төп илләрне төшерегез. Мондый специальләшүнең сәбәпләрен күрсәтегез.

**Кызыксынучыларга өстәмә бирем.** «Латин Америкасы портларында диңгез судноларына нәрсә төйиләр?» дигән сорауга җавап бирергә тырышыгыз. Экспортка

чыгарыла торган товарларны һәм аларны чыгаручы портларны мөмкин кадәр күбрәк атап, иптәшләрегез белән ярышыгыз.

**10 нчы бирем.** Дәреслектәге 22 нче рәсемне карагыз. Аны нинди дә булса бер Латин Америкасы иле (үзегез сайлап алып) мисалында конкретлаштырыгыз.

**11 нче иҗади бирем.** Дәреслек текстын һәм 97 нче рәсемне, шулай ук өстәмә мәгълүматлар файдаланып, «Амазонияне үзләштерү» дигән темага чыгыш әзерләгез. Бу уңайдан Бразилия, Латин Америкасы һәм бөтендөнья өчен нинди проблемалар килеп чыгуын аңлатыгыз.

**12 нче йомгаклау биреме.** 1. География һәм тарих буенча белемнәрегезгә нигезләнеп, Латин Америкасының ни өчен социаль-икътисади үсеш дәрәҗәсе буенча үсеп килүче дөньяның башка регионнарыннан алда торуын аңлатыгыз.

2. (Дәфтәрдә эшләү.) Дәреслектәге текст һәм рәсемнәрне, шулай ук атлас карталарын файдаланып, Мексика, Бразилия һәм Аргентина арасындагы охшаш һәм аермалы якларны билгеләгез.

3. Дәреслек текстын һәм өстәмә мәгълүматлар файдаланып, түбәндәге шәһәрләрнең икесенә (үзегез сайлап алып) кыскача чагыштырма характеристика бирегез: Мехико, Гавана, Рио-де-Жанейро, Сан-Паулу, Бразилиа, Буэнос-Айрес.

4. Панамерика шоссесы буйлап автомашинада сәяхәт итәсез һәм көндәлек язмалар алып барасыз дип күз алдыгызга китерегез. Шундый бер көнлек язмага мисал китерегез (үзегез сайлап алып).

5. Дәреслек текстыннан һәм 98 нче рәсем буенча Бразилиа шәһәренә тасвирлама бирегез.

## ҮЗЕГЕЗНЕҢ ҺӘМ БЕР-БЕРЕГЕЗНЕҢ БЕЛЕМНӘРЕН ТИКШЕРҮ ТУПЛАНМАСЫ

**Ничек аңлатырсыз:**

1. «Латин Америкасы» дигән географик термин ничек килеп чыккан?

2. Латин Америкасында башкала шәһәрләренең аеруча зур ролен ничек аңлатып була?

3. Регионның транспорт челтәре конфигурациясендә аның дөнья базарына бәйле булуы ничек чагыла?

4. Бразилиянең яңа башкаласы нинди максат белән төзелә?

**Ничек аңлыйсыз:**

1. Латин Америкасының башкала һәм периферия шәһәрләрендә хезмәтнең географик бүленеше «шәһәр ил өчен түгел», ә «ил шәһәр өчен» принцибына нигезләнә дигән раслауны сез ничек аңлыйсыз?

2. «Рио-де-Жанейро — яшәүдән ләззәт таба торган, ә Сан-Паулу — яшәү өчен акча эшли торган шәһәр» дигән әйтемне ничек аңлыйсыз?

3. «Кофега бәяләр үссә, Бразилия дә үсә» дигән әйтемне ничек аңлыйсыз?

4. Танылган швед язучысы А. Лундквистның Буэнос-Айресны «илне чорнап алган пәрәвез читендә утыручы» гаять куәтле үрмәкүч белән чагыштыруын ничек аңлыйсыз?

5. «Панама ул — иң элек канал» дигән әйтемне ничек аңлыйсыз?

**Булдыра аласызмы:**

1.Текстта һәм текст карталарында телгә алынган Гватемала, Никарагуа, Коста-Рика, Колумбия, Суринам, Эквадор, Перу, Боливия, Парагвай, Уругвай илләрен дөньяның контурлы картасына хәтердән төшерә аласызмы?

2. Текстта һәм текст карталарында искә алынган Мехико, Гавана, Каракас, Лима, Сан-Паулу, Монтевидео, Буэнос-Айрес, Сантьяго шәһәрләрен картада күрсәтә аласызмы?

3. Түбәндәге илләрнең кайсыларында испан теле дәүләт теле булып саналуын әйтә аласызмы: Куба, Венесуэла, Бразилия, Аргентина, Чили?

4. Латин Америкасы илләренең экспортында: бакыр, бокситлар, аккургаш, нефть, кофе, ит, йон, балык зур урын алып торганнарына мисал китерә аласызмы?

**Түбәндәге фикерләрнең дөреслеген тикшереп, кирәк урыннарда дөресләп җавап бирегез:**

1. Аргентина һәм Уругвай — Латин Америкасында иң «ак» илләр.

2. Мексика — дөньяның испан телендә сөйләшә торган иң зур иле.

3. Бразилия — дөньяның иң зур католик иле.

4. Рио-де-Жанейро — Латин Америкасында иң эре шәһәр агломерациясе.

5. Венесуэла — Латин Америкасында ОПЕКка керә торган бердәнбер ил.

6. Бразилия һәм Колумбия — дөньяда кофе җитештерүче иң зур илләр.

**Түбәндәге раслаулар туры килә торган илләрне әйтегез:**

1. Үзәк Америкада Кариб диңгезенә чыкмый торган бердәнбер ил.

2. Анд субрегионында диңгезгә чыгу юлы булмаган бердәнбер ил.

3. Халыкның 4/5 е диңгез өсте тигезлегеннән 3 мең м биеклектә яши торган ил.

4. Португалиядәгегә караганда португал телендә 17 мәртәбә күбрәк кеше сөйләшә торган ил.

## 10 НЧЫ ТЕМАГА МЕТОДИК АЧКЫЧЛАР

### Боларны исегезгә төшерегез

1. Латин Америкасының сәяси картасы һәм халыклары. (География, 7 нче сыйныф.) 2. Латин Америкасының физик-географик урыны, рельефы, файдалы казылмалары, климаты, сулары, туфрагы һәм үсемлекләр дөньясының үзенчәлекләре. (География, 7 нче сыйныф.) 3. Латин Америкасының XIX гасырда тарихи үсеше үзенчәлекләре. (Тарих, 8 нче сыйныф.) 4. Дәреслекнең I кисәге материаллары. 5. Төшенчәләр һәм терминнар: биеклек пояслары, экватор урманы, елга агымы, һава массалары, метислар, мулатлар.

### Боларны үзләштерегез

**10 нчы теманың төп идеяләре:**

Латин Америкасы илләре элеккеге колониаль тармак һәм территориаль хуҗалык структурасын үзгәртеп кору юлына аяк бастылар һәм бу юлда билгеле бер уңышларга ирештеләр.

**10 нчы темадагы төп фәнни белемнәр:**

1. Латин Америкасының икътисади-географик урыны, табигый шартлары һәм ресурслары, халкы, хуҗалыгының тармак һәм территориаль структурасы, табигатьне саклау проблемаларының үзенчәлекләре. 2. Бразилия ил-субрегионның икътисади-географик характеристикасы. 3. Теманың төп төшенчәләре: 1) шәһәрләрнең Латин Америкасы тибы, 2) «ялган урбанизация», 3) латифундия, 4) хуҗалыкның территориаль структурасының колониаль тибы.

### Сез нәрсәләр белергә тиеш

1. Дәреслектәге рәсемнәрне, шулай ук атлас карталарын файдаланып, дәреслекнең төп положениеләрен конкретлаштырырга. 2. Шәһәрләргә кыскача характеристика бирергә. 3. Картограмма төзергә.

### Мөстәкыйль эш күнекмәләре булдыру буенча күрсәтмәләр һәм планнар

**Картограмманы ничек төзергә һәм анализларга. Эш тәртибе:**

1. Контурлы картада анализланырга тиешле территорияләрнең чикләрен билгеләргә. 2. Картограмма өчен кирәкле күрсәткечләрнең статистик яки башка чыганакларын анализларга, кирәкле күрсәткечләрне язарга. 3. Бу күрсәткечләрне билгеле бер интерваллар буенча төркемләргә. 4. Картограмманың легендасын төзергә, анда куерак төсләр яисә ешрак штрихлар күренешнең интенсивраклулуын аңлата, һәм киресенчә. 5. Контурлы картаны буярга яки штрихларга. 6. Картограмманы анализларга, нәтиҗәләр ясарга.

# III КИСӘК. КЕШЕЛЕКНЕҢ ГЛОБАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ (белемнәрне гомумиләштерү)

## 11 нче тема. КЕШЕЛЕКНЕҢ ГЛОБАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Соңгы вакытта сез ***глобальләшү*** (ингл. *global* — бөтендөнья, галәм, дөньякүләм) турында торган саен ешрак ишетәсез. Ул илләр, халыклар һәм аерым кешеләр арасындагы үзара бәйләнеш, үзара элемтәләрне кискен киңәйтү һәм тирәнәйтүне белдерә. Глобальләшү сәясәт, икътисад, мәдәният сфераларын үз эченә ала. Ә аның нигезендә сәяси, икътисади союзларның, ТНКларның эшчәнлеге, глобаль мәгълүмат киңлеге, глобаль финанс капиталы булдыру ята. Әмма әлегә глобальләшүнең файдасын иң күп дәрәҗәдә *«алтын миллиард»* кына үзләштерә ала. Гомуми саны 1 млрд ка якынлашкан һәм югары үсешкә ирешкән Көнбатышның постиндустриаль илләрендә яшәүчеләрне шулай дип атыйлар. Менә шундый тигезсезлек *антиглобалистларның* (глобальләшүгә каршы чыгучыларның) массакүләм хәрәкәтен яшәүгә чакырды.

Галимнәрнең, сәясәт эшлеклеләренең һәм киң җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә калган кешелекнең глобаль проблемалары да глобальләшү процесслары белән бәйле. Аларны күп кенә фәннәр, шул исәптән география дә өйрәнә. Бу проблемаларның һәркайсының географик аспекты бар, һәм алар дөньяның төрле регионнарында төрлечә чагылалар. Әле Н. Н. Баранскийның ук географларны «континентларны күздә тотып фикер йөртергә» чакыруын искә төшерик. Әмма безнең көннәрдә бу гына җитәрлек түгел. Глобаль проблемаларны фәкать «глобаль рәвештә» яисә «региональ» хәл итү генә ярамый. Аларны хәл итүне илләрдән һәм районнардан башларга кирәк. Менә ни өчен галимнәр «Глобаль фикер йөртергә, локаль эш итәргә!» дигән лозунгны алга куйдылар.

Глобаль проблемаларны тикшергәндә, сез дәреслектәге барлык темаларны өйрәнгәндә алган белемнәрегезне гомумиләштерергә тиеш буласыз. Димәк, бу — тагын да катлаулырак гомумиләштерүче материал. Ләкин аңа саф теоретик материал дип карарга ярамый. Чөнки глобаль проблемалар, бердәм һәм күп төрле кешелек дөньясының бер бәләкәй «кисәкчеге» буларак, сезнең һәрберегезгә турыдан-туры кагыла.

### 1. КЕШЕЛЕКНЕҢ ГЛОБАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫН НИГЕЗЛИБЕЗ

**1. Глобаль проблемалар төшенчәсе.** XX гасырның соңгы дистәеллары бөтендөнья халыклары алдына күп кенә кискен һәм катлаулы проблемалар куйды, алар глобаль дип аталды.

## 11 НЧЕ ТЕМАНЫҢ ПЛАН-СХЕМАСЫ



**Глобаль проблемалар дип бөтен дөньяны, бөтен кешелекне чолгап алган, аның хәзергесе һәм киләчәге өчен куркыныч тудырган, аларны хәл итү өчен барлык дәүләтләр һәм халыкларның бердәм тырышлыгын, бергәләп эш итүен таләп иткән проблемаларны атыйлар.**

Фәнни әдәбиятта глобаль проблемаларның төрле исемлекләренә тап буласың, аларның саны 8—10 нан алып 40—45 кә кадәр тирбәлә. Бу шуның белән аңлатыла: төп, өстенлекле глобаль проблемалар белән беррәттән (алга таба алар дәреслектә каралыр) күбесенчә шәхсирәк, әмма шулай ук бик мөһим проблемалар да шактый: мәсәлән, җинаятьчелек, наркомания, сепаратизм [1], демократия дефициты, техноген һәлакәтләр, табигать бәла-казалары. Инде билгеләп үтелгәнчә, соңгы вакытта *халыкара терроризм проблемасы* аеруча актуальләште, фактта иң өстенлекле проблемага әверелде.

Глобаль проблемаларны төрлечә классификацияләү дә яшәп килә. Ләкин, гадәттә, алар арасында түбәндәгеләрне аерып күрсәтәләр: 1) иң «универсаль» характердагы проблемалар, 2) табигый-икътисади характердагы проблемалар, 3) социаль характердагы проблемалар, 4) катнаш характерлы проблемалар. «Искерәк» һәм «яңарак» глобаль проблемаларны да аерып күрсәтәләр. Аларның приоритетлык дәрәҗәсе вакыт узу белән шулай ук үзгәрергә мөмкин. Мәсәлән, XX гасыр ахырында беренче планга экология һәм демография проблемалары чыкты, ә өченче бөтендөнья сугышын булдырмый калу проблемасы элеккечә үк кискен тормый.

**2. Экологик проблема: «Җир ул берәү генә!»** Әле 40 нчы елларда ук академик В. И. Вернадский (1863—1945), ноосфера (акыл сферасы) турындагы тәгълиматка нигез салган галим, кешеләрнең хуҗалык эшчәнлеге географик мохиткә табигатьнең үзендә бара торган геологик процесслардан да кимрәк тәэсир ясамаганын язган иде. Шул вакыттан бирле җәмгыять белән табигать арасындагы «матдәләр алмашы» күп мәртәбәләр артты һәм глобаль күләмнәр алды. Әмма, табигатьне «яулап алабыз» дип, кешеләр үзләренең яшәешләренең табигый нигезләрен шактый какшаттылар.

Табигатьтән рациональ, дөрес файдаланмау туфрак эрозиясенең киңәюе, чүлләнү, урманнар бетү һ.б. нәтиҗәсендә тирә-як мохитнең ярлылануы, аның каты, сыек һәм газ рәвешендәге калдыклар белән пычрануы һәм, алай гына да түгел, радиоактив һәм башка бик агулы матдәләр белән «агулануы» инде глобаль экологик системаның шактый дәрәҗәдә деградациясенә китерде. Белгәнегезчә, кайбер илләрдә экологик ситуация, **экологик кризис** дәрәҗәсенә җитеп, бик зур киеренкелек белән характерлана башлады. **Кризислы (критик) экология районы**, ә кайбер очракларда **һәлакәтчел** экологик ситуация районы төшенчәсе барлыкка килде.

**Мисал.** 1986 елда Чернобыль АЭСында булган авария нәти-

җәсендә радиоактив матдәләр белән пычранудан элеккеге СССРның Украина, Белоруссия һәм Россия составына кергән 17 млн халык яшәгән 11 өлкәсе зыян күрде. Россиядә генә цезий-137 белән пычранган гомуми мәйдан 60 мең км$^2$ тәшкил итте.

Җирнең климаты үзгәрү, стратосфераның озон катлавы җимерелү кебек күренешләр бөтендонья экологиясенә зур куркыныч тудырды. Мондый куркыныч кешеләрнең хәзерге буынына гына түгел, киләчәк буынына да яный. Галимнәр билгеләвенчә, соңгы чирек гасырда Җирдәге эре табигый һәлакәтләрнең уртача саны елына 10 нан 100 гә кадәр артты. Су басу, тропик циклоннар, корылык, урман янгыннары — барысы да диярлек климатның җылынуы белән бәйле. [2].

Россия галим-географлары цивилизациянең биосфера белән иң зур «бәрелешүе» нәтиҗәсендә экосистеманың бозылуы һәм әйләнә-тирә мохитнең стабильлеге югалуы күзәтелгән өч төп үзәкне (регион) аерып карыйлар. Бу 8 млн км$^2$ мәйданны биләгән Европа үзәге, Азия үзәге (7 млн) һәм Төньяк Америка үзәге (9 млн). Бу үзәкләрнең һәркайсында табигый экосистемалар территориянең 5—10 % ында гына сакланган.

*Менә ни өчен бүгенге көндә экологик проблема кешелек исән калуның төп проблемасы булып тора.*

Безнең көннәрдә һаман күбрәк илләр аны хәл итү өчен үз тырышлыкларын берләштерә башлады. Озакка сузыла торган экологик хәвефне булдырмау белән беррәттән, гадәттән тыш экологик ситуацияләрдә дә ярдәм оештырыла. Аеруча саклана торган табигый территорияләрнең саны арта.

**Мисал.** XXI гасырның башында дөньядагы мондый территорияләр саны 12 меңгә җитә, ә гомуми мәйданы 12 млн км$^2$ дан артып китә. Димәк, тулаем алганда, алар кеше яши торган коры җирнең якынча 9 % ын били дигән сүз.

Болар һәммәсе дә БМО әле 70 нче елларда ук алга куйган «Җир ул бер генә!» дигән девизны үтәүне белдерә. Ә 2000 елда БМО тагын бер мөһим документ — «Җир декларациясен» кабул итте. Дөнья бердәмлеге шуннан чыгып эш итә: *экологик проблеманы хәл итүнең төп юлы — кешеләрнең җитештерүче һәм җитештермәүче эшчәнлеген әйләнә-тирә мохитнең нормаль «экоүсеш»ен, саклануын, үзгәртеп корылуын бөтен кешелек һәм һәр кеше мәнфәгатьләрен тәэмин итәрлек итеп оештыру.* (1 нче иҗади бирем.)

**3. Демографик проблема — тагын бер глобаль проблема.** Демографик проблема — кешелек исән калуның тагын бер приоритетлы проблемасы.

Инде белгәнегезчә, бөтен дөньяда демографик шартлау ачыктан-ачык кимү ягына таба авышты. Ләкин Африкада мондый кимү әле беленеп кенә килә. 60 нчы еллар башында дөнья халкы елга уртача 2 % ка артса, 80 нче еллар ахырында арту 1,7 %, 90 нчы еллар ахырында 1,4 % булды. XXI гасыр башында да кимү дәвам итәчәк. Шулай да демографик шартлау инерциясе

беренче чиратта (яшьләрнең) өлеше бик зур булуы үзен әле бик озак сиздерәчәк.

БМО даими рәвештә ясый торган демографик фаразлар шул турыда сөйли. Фаразларга караганда, 2025 елга Җирдәге халык саны 7,8, ә 2050 елга 9 млрд кешегә җитәчәк. Шул ук вакытта икътисади үсеш алган илләрнең өлеше тагын да кимеячәк, ә үсеп килүче илләрнең артачак. Аерым илләрнең тәртип номерлары да үзгәрәчәк. [3]. Шул ук вакытта шәһәрләр шартлавының дәвам итүе нәтиҗәсендә Көньяк илләрендә шәһәр халкының өлеше һәм миллионер шәһәрләр саны даими үсәчәк. [4].

Демографик проблеманы хәл итү өчен БМО «Халыкның урнашуы өлкәсендә бөтендөнья эш планы»н кабул итте, аны тормышка ашыруда географлар да, демографлар да катнаша. Монда прогрессив көчләр гаиләне планлаштыру программаларын халык яңарып торуының яхшыруына ярдәм итү мөмкинлегеннән чыгып эш йөртәләр. *Әмма бер демографик сәясәт кенә җитәрлек түгел. Ул кешеләрнең икътисади һәм социаль тормыш шартларын яхшырту белән бергә алып барылырга тиеш.* (2 нче иҗади бирем.)

**4. Коралсызлану һәм Җирдә тынычлыкны саклау проблемасы.** Барлык тарихи чорларда да сугышларның кешелек цивилизациясе үсешенә шактый йогынты ясаганы яхшы мәгълүм. XX гасырда гына да ике бөтендөнья сугышында һәм күп кенә җирле сугышларда 100 млн нан артык кеше һәлак булды. Ләкин элек бөтен бер илләрне һәм хәтта континентларны юк итүнең реаль мөмкинлеге беркайчан да булмаган. Ул фәкать XX гасырның икенче яртысында гына, баллистик ракеталар белән бергә атом-төш коралы булдыруга бәйле рәвештә барлыкка килде. *Һәм берничә дистә еллар дәвамында яшәп килгән «салкын сугыш» вакытында сугыш һәм тынычлык, бөтендөнья атом-төш конфликтын булдырмый калу 1 нче номерлы проблема булды.* Дөнья шундый бер критик ноктага килеп җитте ки, Гамлетның атаклы «Булыргамы, булмаскамы?» дигән соравы инде аерым кешеләр төркеме алдына түгел, ә бөтен кешелек алдына куелды.

Яхшы якка таба хәл бары тик 80 нче еллар ахыры — 90 нчы еллар башында гына үзгәрә башлады. Ә XX һәм XXI гасырлар чигендә хәрби куркынычсызлык факторының роле инде шактый дәрәҗәдә үзгәрде. Коралларның глобаль арсеналын күпләп кыскарту бара, хәрби чыгымнар туктаусыз кими, ракета атом-төш һәм гадәти коралларны һәм коралды көчләрнең шәхси составын кыскарту тормышка ашырыла. Хәрби-промышленность комплексларын конверсияләү процессы бара. СССР, ә соңыннан Россия һәм АКШ арасындагы стратегик һөҗүм итү коралларын кыскарту һәм чикләү турындагы ике Килешү (СНВ-1 һәм СНВ-2) аеруча әһәмияткә ия булдылар.

*Нәтиҗәдә бөтендөнья атом-төш конфликтының реаль куркынычы инде артта калды.*

Шулай да сугыш куркынычының аерым аспектлары әле сакланып

кала. Инде белгәнегезчә, бу — күп санлы региональ һәм локаль конфликтлар, хәтта сугышлар, атом-төш коралы таралуы, хәрби блокларның сакланып калуы. Боларга тагын корал белән сәүдә итүне (елына 25—30 млрд доллар), дөнья күләмендә бик зур хәрби чыгымнар булуны (елына 1 трлн доллардан артык, шуның 47 % ы АКШка туры килә) һәм тагын дөньяда 20 млн кешенең «кораллы» булуын өстәргә кирәк.

*Димәк, тулы күләмдәге куркынычсызлык системасын булдыру, атом-төш арсеналларын этаплап юк итү, корал сатуны кыскарту, икътисадны демилитаризацияләү бурычы әле кала бирә.* (Знче бирем.)

**5. Азык-төлек проблемасы — Җирнең һаман арта барган халкын ничек азык-төлек белән тәэмин итәргә?** Борынгы бер мәкальдә: «Кеше ашар өчен яшәми, яшәр өчен ашый»,— диелә. Гадәти тормыш эшчәнлеге алып бару өчен кирәкле азыкның күләме кешенең җенесенә, яшенә, авырлыгына, хезмәтенең характерына һәм шартларына, көнкүреш шартларына, территориянең климат үзенчәлекләренә бәйле. Галимнәр исәпләвенчә, азыкның медицина нормасы буенча калориялелеге тәүлегенә 2300—2600 ккал, ә аксымы 70—100 г булырга тиеш. Әмма хәзерге вакытта, БМО мәгълүматлары буенча, *1,2 млрд кеше азык-төлек даими рәвештә җитешми торган илләрдә яши.* Менә ни өчен азык-төлек проблемасын глобаль проблема дип санарга кирәк.

Билгеле, монда Төньяк илләренә ачлык, азыкка кытлык күренеше тулаем алганда хас түгел икәнен истә тотарга кирәк. Бу илләр хәзер дөньядагы азык-төлекнең 3/4 ен җитештерәләр һәм кулланалар, ә бит аларда Җирдәге халыкның 15 % ы гына яши. Күпчелек алга киткән илләрдә туклануның уртача калориялеге тәүлегенә 3000 ккал дан артып китте. Киресенчә, бу илләрдә тән массасы артык булган, кирәгеннән күп ашаучылар һаман күбәя. [5]. Көньяк илләрендә, туклануның уртача калориялеге сизелерлек үсүгә карамастан, бу күрсәткеч медицина нормасына җитеп бетми, ә Африканың Сахарадан көньягында ул тәүлегенә 2000 ккал гына. Менә нигә азык-төлек проблемасын хәл итү өчен кешелек үсемлекчелек, терлекчелек һәм балыкчылык ресурсларын тулырак файдаланырга тиеш. Моны ике юл белән эшләп була.

Экстенсив юл сөрү, көтүлек һәм балык тоту җирләрен тагын да киңәйтә барудан гыйбарәт.

**Мисал.** Авыл хуҗалыгы өчен файдаланырга яраклы җирләр мәйданы безнең планетада 3,2—3,4 млрд га тәшкил итә, хәзергә әле аларның яртысыннан кимрәге генә кулланыла. Мондый җирләрнең төп резервлары Африкада Сахарадан көньяктарак һәм Латин Америкасында урнашкан.

Әмма, барлык уңдырышлы һәм уңайлы җирләр инде үзләштерелеп беткәнлектән, бу юл гаять зур чыгымнар таләп итә.

Интенсив юл әлек эшкәртелеп килгән җирләрнең биологик нәтиҗәлелеген күтәрүдән гыйбарәт.

Аның өчен биотехнология, югары уңыш бирә торган яңа сортларны һәм туфрак эшкәртүнең яңа методларын куллану, механикалаштыру, химияләштерү, шулай ук мелиорацияне (аңа инде берничә мең ел, ул Месопотамия, Борынгы Мисыр һәм Һиндстан заманнарыннан ук килә) тагын да ныграк үстерү хәлиткеч әһәмияткә ия булачак.

**Мисал.** XX гасыр дәвамында гына да сугарыла торган җирләрнең мәйданы 40 млн га дан 270 млн га җитте. Бүгенге көндә бу җирләр эшкәртелә торган җирләрнең 20 % ын били, ә авыл хуҗалыгы продукциясенең 40 % ын бирә. Сугарулы игенчелек 135 илдә кулланыла, барлык сугарулы җирләрнең 3/5 өлеше Азиядә урнашкан.

Азык-төлек җитештерүнең яңа традицион булмаган ысулы да эшләнә, ул натураль табигый чималдан алынган аксым нигезендә ясалма азык продуктлары «ясау»дан гыйбарәт.

Галимнәр Җирдәге халыкны азык-төлек белән тәэмин итү өчен XX гасырның соңгы чирегендә авыл хуҗалыгы җитештерүен 2 тапкыр, ә XXI гасыр уртасына 5 тапкыр арттырырга кирәклеген санап чыгарганнар. Исәпләүләр күрсәткәнчә, әгәр барлык илләрдә дә күп кенә алга киткән илләрдә ирешелгән авыл хуҗалыгы дәрәҗәсе булса, 10 млрд һәм хәтта аннан да күбрәк кешенең азыктөлеккә булган ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндереп булыр иде. [6]. Димәк, *интенсив юл кешелекнең азык-төлек проблемасын хәл итүдә төп юл булып тора.* Инде хәзер үк ул игенчелек продукциясе үсешенең 9/10 ын бирә. (4 нче иҗади бирем.)

**6. Энергетика һәм чимал проблемалары: сәбәпләре һәм хәл итү юллары.** Бу,— барыннан да элек, кешелекне ягулык һәм чимал белән ышанычлы рәвештә тәэмин итү. Ресурслар белән тәэмин итү проблемасы элегрәк тә билгеле бер кискен төс алган вакытлар булгалады. Ләкин бу гадәттә табигый ресурсларның «комплект» составы тулы булмаган аерым районнарга һәм илләргә кагылды. Глобаль масштабларда исә беренче мәртәбә ул проблема 70 нче елларда чагылыш тапкандыр, мөгаен. Моның берничә сәбәбе бар.

Алар арасында — тикшерелгән нефть, табигый газ һәм кайбер башка ягулык һәм чимал төрләренең чагыштырмача чикләнгән булуы [7], аларны чыгаруда таугеологик шартларның начарлануы, чыгара һәм куллана торган районнар арасындагы территориаль өзеклекнең артуы, аларны чыгаруның табигать шартлары бик катлаулы булган яңа үзләштерелә торган районнарга күченүенә карамастан казылмаларны чыгаруның бик тиз үсүе. Димәк, безнең чорда, элек беркайчан да булмаганча, минераль ресурсларны рациональ файдаланырга кирәк, ә алар, белгәнегезчә, бетә торган һәм торгызыла алмый торган категориягә керә.

## 23 НЧЕ ТУПЛАНМА

99


99 нчы рәсем. Кешеләрнең туклануында географик аермалар

100 нче рәсем. АКШта космик корабль җибәрү

100 

10 нчы таблица

**Үсеп килүче илләрнең XXI гасыр башына артка калу масштаблары**

| Артка калу төрләре | Халык, млн кеше |
|---|---|
| Чиктән тыш хәерчелек шартларында яшәүчеләр | 1200 дән артык |
| Ачлык кичерүчеләр | 800 дән артык |
| Җитәрлек күләмдә тукланмаучылар | 3000 |
| Медицина ярдәменнән мәхрүм ителгәннәр | 1500 |
| Өлкән яшьтәгеләр арасында укый-яза белмәүчеләр | 900 дән артык |
| Мәктәпкә йөрү мөмкинлеге булмаган балалар | 300 дән артык |
| Су белән ышанычлы тәэмин итәлү чыганаклары булмаганнар | 1200 |
| Ягу өчен утын кулланучылар | 1800 |

*Моның өчен ФТР гаять зур мөмкинлекләр ача, һәм бу технологик чылбырның барлык стадияләрендә дә шулай.* Җир куеныннан файдалы казылмаларны мөмкин кадәр тулырак чыгару зур әһәмияткә ия.

**Мисал.** Нефтьне хәзерге ысуллар белән чыгару коэффициенты 0,25—0,45 чикләрендә тирбәлә, ә бу һич тә җитәрлек түгел, һәм аның геологик запасларының күбрәк өлеше җир астында кала дигән сүз. Нефть чыгару коэффициентын 1 % ка гына күтәрү дә зур икътисади нәтиҗә бирә.

Инде табылган ягулык һәм чималдан файдалану коэффициентын күтәрүдә зур резервлар бар. Хәзерге техника һәм технология шартларында бу коэффициент, гадәттә, 0,3 чамасы гына. Шуңа күрә әдәбиятта бер инглиз физигының, хәзерге заман энергетика җиһазларының нәтиҗәлелеге бер дуңгыз түшкәсен кыздырыр өчен бөтен бер йортны яндырган кебек булыр иде, дигән тәгъбирен очратырга мөмкин... Соңгы вакытларда энергия һәм материаллар табуны арттыруга караганда аларны саклап тотуга аеруча зур игътибар бирелүе гаҗәп түгел. Күп кенә Төньяк илләрендә ТЭПның үсүе инде күптәннән чынлыкта ягулык һәм чимал куллануны арттырмыйча алып барыла. Нефтьнең кыйммәтләнүе сәбәпле, күп кенә илләр традицион булмаган торгызыла торган энергия чыганакларын — җил, кояш, геотермаль, биомасса энергияләрен файдаланалар. Бу чыганаклар бетми торган һәм экологик чиста булулары белән аерылалар. Атом энергетикасының нәтиҗәлелеген һәм ышанычлылыгын арттыру буенча эшләр дәвам итә. Инде МГД-генераторларын, водород энергетикасын һәм ягулык элементларын файдалана башладылар. [8]. Алда идарә ителә торган термиктөш синтезына ия булу көтелә, ә ул пар машинасы яисә компьютер уйлап табу белән чагыштырырлык дәрәҗәдә революция булачак. (8 нче иҗади бирем.)

**7. Кешеләрнең сәламәтлеге проблемасының глобаль аспекты.** Соңгы вакытларда дөнья практикасында кешеләрнең яшәү сыйфатын бәяләгәндә, алгы планга аларның сәламәтлеге килеп баса. Һәм бу очраклы түгел: нәкъ менә сәламәтлек һәр кешенең һәм, гомумән, җәмгыятьнең тулы канлы тормышы һәм эшчәнлеге өчен нигез булып тора бит.

XX гасырның икенче яртысында күп кенә авырулар — чума, ваба, чәчәк, сары бизгәк, полиомиелит һ.б. белән көрәштә зур уңышларга ирешелде.

**Мисал.** 60—70 нче елларда Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы (БСО) чәчәк авыруы белән көрәштә медицина чараларының киң челтәрен тормышка ашырды: ул 2 млрд халкы булган 50 дән артык илне үз эченә алды. Нәтиҗәдә безнең планетада бу авыру чынлыкта юк ителде. [9].

*Шулай да әле кешеләргә күп кенә авырулар яный, еш кына алар чын-чынлап глобаль рәвештә таралалар.* Йөрәк-кан тамырлары авырулары шундыйлардан, алардан ел саен 15 млн кеше үлә. Яман шеш, венерик авырулар, наркомания,

бизгәкне дә шулар исәбенә кертергә була. [10]. Йөзләрчә миллион кешеләрнең сәламәтлегенә тәмәке тарту зур зыян китерә. [11]. Әмма СПИД исә кешелек дөньясы өчен бөтенләй үзгә куркыныч булып яный.

**Мисал.** Әле 80 нче елларда гына күренә башлаган бу авыруны хәзер инде «XX гасыр чумасы» дип йөртәләр. БСО мәгълүматларына караганда, 2005 елның ахырында СПИД белән йогышланучы кешеләр саны 45 млн нан артып китте, ә миллионнарча кешеләр бу авырудан һәлак булдылар. БМО инициативасы белән ел саен СПИДка каршы көрәш көне үткәрелә.

Бу теманы тикшергәндә, сез кешенең сәламәтлегенә бәя биргән чагында аның физиологик сәламәтлеге белән генә чикләнергә ярамаганлыгын истә тотарга тиешсез. Бу төшенчә шулай ук әхлакый (рухи), психик сәламәтлекне дә үз эченә ала, аның белән дә эш бик үк шәптән тормый (шул исәптән Россиядә дә). *Менә ни өчен кеше сәламәтлеге иң мөһим глобаль проблемаларның берсе булып кала бирә.* (6 нчы иҗади бирем.)

**8. Дөнья океанын файдалану проблемасы: яңа этап.** Җир өслегенең 71 % ын биләп торган Дөнья океаны халыклар һәм илләрнең аралашуында һәрвакыт мөһим роль уйнады. Ләкин XX гасыр урталарына кадәр Океандагы кешелек эшчәнлегенең барлык төрләре дөнья күләмендәге керемнең нибары 1—2% ын гына биреп килде. Ә ФТР ныграк үскән саен Дөнья океанын тикшерү һәм үзләштерү бөтенләй башка масштаблар алды.

Беренчедән, глобаль энергетик һәм чимал проблемаларының кискенләшүе диңгездә файдалы казылмалар чыгару һәм диңгез химия промышленносте, диңгез энергетикасы барлыкка килүгә китерде. ФТР казанышлары нефть һәм газ, тимер-марганец конкрецияләре чыгаруны тагын да арттыру, диңгез суыннан водород изотобы — дейтерий табу, гаять зур су күтәрелеше электр станцияләре [12] төзү, диңгез суын төчеләндерү өчен гаять зур перспективалар ача.

Икенчедән, глобаль азык-төлек проблемасының кискенләшүе океанның биологик ресурслары белән кызыксынуны арттырды, алар әле хәзергә кешелекнең азык-төлек «паегының» нибары 2 % ын гына, ә хайваннардан алына торган аксымның 12—15 % ын тәэмин итә. Әлбәттә, балык тоту һәм диңгез продуктлары табуны арттырырга мөмкин һәм кирәк. Аларны инде урнашкан балансны бозмыйча гына табуның потенциаль мөмкинлекләрен төрле илләрнең галимнәре 100 дән алып 150 млн т га кадәр дип билгелиләр. Өстәмә резерв булып *марикультураны* үстерү хезмәт итә. [13]. Май һәм холестерины аз булган балык «XXI гасыр тавыгы» булачак дип юкка гына әйтмиләр.

Өченчедән, халыкара географик хезмәт бүленешенең тирәнәюе, дөнья сәүдәсенең тиз үсүе диңгездә йөк ташу күләмнәренең артуы белән бара. Бу үз чиратында җитештерүнең һәм халыкның диңгезгә таба күченүенә һәм кайбер диңгез буе районнарының бик нык үсүенә китерде. Мәсәлән, күп кенә эре

диңгез портлары промышленность-порт комплексларына әверелде, алар өчен судно төзү, нефть эшкәртү, нефть химиясе, металлургия кебек тармаклар күбрәк хас, ә соңгы вакытларда иң яңа тармаклар үсә башлады. Диңгез буе урбанизациясе гаять зур масштаблар алды.

Океан «халкы» үзе дә артты (судно экипажлары, бораулау платформалары персоналы, пассажирлар һәм туристлар), бүгенге көндә алар 2—3 млн кешегә җитә. Стационар яисә йөзмә утраулар (Жюль Вернның «Йөзмә утрау» романындагыча) төзү проектлары аларны киләчәктә тагын да ныграк арттырыр, ихтимал. [14]. Океанның телеграф һәм телефон элемтәсендә мөһим чара булуын да онытмаска кирәк; аның төбеннән күп санлы кабель юллары уза. [15].

Бөтен фәнни һәм җитештерү эшчәнлеге нәтиҗәсендә Дөнья океаны һәм океан — коры җир бәйләнешләре зонасы чикләрендә дөнья хуҗалыгының аеруча мөһим состав өлеше — **диңгез хуҗалыгы** барлыкка килде. Ул чыгару һәм эшкәртү промышленностен, энергетика, балык тоту, транспорт, сәүдә, рекреация һәм туризмны үз эченә ала. Тулаем алганда, диңгез хуҗалыгында кимендә 100 млн кеше эшли.

Ләкин шул ук вакытта мондый эшчәнлек Дөнья океанының глобаль проблемасын да тудырды. Аның асылы Океан ресурсларын чиктән тыш тигезсез үзләштерүдән, диңгез мохитенең һаман ныграк пычрана баруыннан, аны хәрби эшчәнлек аренасы буларак файдаланудан гыйбарәт. Нәтиҗәдә соңгы унъеллыкларда Дөнья океанында тереклек интенсивлыгы 1/3 гә кимеде. Менә ни өчен 1982 елда БМО кабул иткән диңгез хокукы буенча конвенция бик зур әһәмияткә ия, аны «Диңгезләр хартиясе» дип йөртәләр. Ул диңгез яры буеннан 200 миль ераклыкта икътисади зоналар билгеләде, диңгез буендагы дәүләт андагы биологик һәм минераль ресурслардан файдалануга суверен хокукларын тормышка ашыра ала. *Дөнья океаныннан файдалану проблемасын хәл итүнең төп юлы — океан табигатеннән нәтиҗәле файдалану аның байлыкларына баланслы, комплекслы якын килү, бөтендөнья бердәмлеге тырышлыкларын берләштерүгә нигезләнгән булырга тиеш.* (5 нче иҗади бирем.)

**9. Космосны тынычлык максатларында үзләштерү: яңа офыклар.** Космос кешелек дөньясының глобаль мохите, уртак байлыгы булып тора. Хәзер, космик программалар шактый катлауланганнан соң, аларны тормышка ашыру күп илләр һәм халыкларның техник, икътисади, интеллектуаль тырышлыкларын бергә туплауны сорый. Шуңа күрә космосны үзләштерү иң мөһим халыкара, глобаль проблемаларның берсенә әверелде.

XX гасырның икенче яртысында космос киңлекләрен өйрәнү һәм файдалануда төп ике юнәлеш билгеләнде: *космостан торып Җирне өйрәнү һәм космоста җитештерү.*

Алар икесе дә баштан ук һәм икеяклы, һәм аеруча күпьяклы хезмәттәшлек аренасы булдылар.

**1 нче мисал.** Штаб-квартирасы Мәскәүдә булган халыкара «Интерспутник» оешмасы әле 70 нче елларның башында ук оештырыла. Безнең көннәрдә «Интерспутник» системасы аша космик элемтә белән 100 дән артык дәүләт һәм шәхси компанияләр файдалана.

**2 нче мисал.** АКШ, Россия, Европа космик агентлыгы, Япония, Канада тарафыннан гамәлгә ашырылган «Альте» Халыкара космик станциясен (МКС) төзү эшләре тәгәлләнде. [16]. Соңгы күренешендә МКС 36 блок-модульдән тора. Станциядә халыкара экипажлар эшли. Ә аның Җир белән элемтәсе Американың йөк ташучы корабльләре «Спейс шаттл» һәм Россиянең «Союз»лары ярдәмендә тормышка ашырыла.

Космосны тынычлык максатларында үзләштерү, хәрби программаларны кире кагып, фән һәм техниканың, производство һәм идарә итүнең иң яңа казанышларын файдалануга нигезләнә. Ул хәзер үк инде Җир һәм аның ресурслары турында гаять зур космик мәгълүмат бирә. Киләчәктә космик индустриянең, космик технологиянең, 36 км биеклектәге гелиоцентрик орбитага урнаштырылачак гигант Кояш электростанцияләре ярдәмендә космик энергия ресурсларын файдалануның билгеләре һаман ачыграк күренә бара.

**10. Глобаль проблемаларның үзара бәйләнеше. Үсеп килүче илләрнең артталыгын бетерү — иң зур дөньякүләм проблема.** Үзегез күргәнчә, кешелекнең һәр глобаль проблемасының үз конкрет эчтәлеге бар. Әмма алар барсы да бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән: энергетика һәм чимал проблемасы экологик проблема белән, экологик проблема демографик проблема белән, демографик проблема азык-төлек проблемасы белән һ. б. Кешелекнең глобаль проблемалары арасында яңа бөтендөнья сугышын булдырмау проблемасы аерым урын алып тора, ә ул турыдан-туры башка проблемаларга кагыла. Әмма хәзер, коралланну икътисадыннан коралсызлану икътисадына күчкән чорда, *күп кенә глобаль проблемаларның авырлык үзәге үсеп килүче илләргә һаман күбрәк күчә бара.* Аларның артта калганлык масштаблары, чыннан да, гаять зур (10 нчы таблица).

Бу артталыкның төп чагылышы һәм бер үк вакытта сәбәбе — ярлылык, хәерчелек. Азия, Африка һәм Латин Америкасы илләрендә чиктән тыш хәерчелек шартларында 1,2 млрд кеше, ягъни бу региондагы халыкның 22%ы яши. Шуларның яртысы көненә бер долларга, икенче яртысы 2 долларга көн күрә. Ярлылык һәм хәерчелек бигрәк тә Тропик Африка илләренә хас. Аларда халыкның яртысы диярлек көненә 1—2 долларга яши. Шәһәрдәге алачыкларда һәм ерак авылларда яшәүчеләр иң бай илләрдә яшәүчеләрнең тормыш дәрәҗәсенең 5—10%ы белән канәгатьләнергә мәҗбүрләр. [19].

*Үсеп килүче илләрдә азык-төлек проблемасы — иң драматик, хәтта һәлакәтчел характер алган проблемадыр, мөгаен.* Әлбәттә,

ачлык һәм ачлы-туклы яшәү кешелек тарихы башланганнан бирле килә. Инде XIX—XX гасырларда Кытай, Һиндстан, Ирландия, Африканың күп кенә илләрендә һәм Советлар Союзында ачлык күп миллионлаган кешеләрнең гомерен өзде. Ләкин ФТР һәм алдынгы Көнбатыш илләрендә азык-төлекне кирәгеннән артык күп җитештерү чорында ачлыкның яшәп килүе — безнең заманның, чынлап та, гаҗәеп бер парадоксларыннан берсе. Ачлыкны шулай ук үсеп килүче илләрнең арттальгы һәм ярлылыгы да тудырды, ә болар авыл хуҗалыгы җитештерүенең аның продукциясенә булган ихтыяҗдан бик нык артта калуына китерде.

Безнең көннәрдә «ачлык географиясе»н иң элек үтә артта калган, «яшел революция» кагылмаган Африка һәм Азия илләре билгели, аларда халыкның шактый өлеше ачтан үлү куркынычы астында яши. Үсеп килүче 70 тән артык ил азык-төлекне читтән кертергә мәҗбүр.

Ачлы-туклы яшәү, ачлык һәм чиста су җитмәү белән бәйләнгән авырулардан үсеп килүче илләрдә ел саен 40 млн кеше (моны Икенче бөтендөнья сугышында корбан булганнар саны белән чагыштырырга була), шул исәптән 13 млн бала үлә. БМОның Балалар фонды плакатында сурәтләнгән кыз баланың «Үскәч кинди булырга телисең?» дигән сорауга: «Исән булырга!» — дип җавап бирүе очраклы түгел.

*Азык-төлек проблемасы белән үсеп килүче илләрнең демографик проблемасы да тыгыз бәйләнгән.* Демографик шартлау аларга ике яклап тәэсир итә. Бер яктан, ул яңа эшче көчләр килеп торуын, хезмәт ресурсларының үсүен тәэмин итә, ә икенче яктан, икътисади артталыкны бетерү өчен көрәштә өстәмә кыенлыклар тудыра, күп кенә социаль мәсьәләләрне хәл итүне кыенлаштыра, ирешелгәннәрнең күп өлешен «ашый», территориягә «йөкләмә»не арттыра. Азия, Африка, Латин Америкасының күпчелек илләрендә халык арту темплары азык-төлек җитештерү темпларын узып китә.

Сез инде соңгы вакытларда үсеп килүче илләрдәге демографик шартлауның «шәһәр шартлавы» формасын алганын беләсез. Әмма шуңа да карамастан аларның күбесендә авыл халкының саны кимеми генә түгел, хәтта арта да. Димәк, болай да бик күп санлы авыл халкы һаман арта бара, бу авыллардан зур шәһәрләрнең «хәерчелек пояслары»на да, чит илләрдәге баерак илләргә дә миграция дулкынына кимергә бирми. Качакларның төп өлешенең үсеп килүче илләргә туры килүе гаҗәп түгел. Соңгы вакытларда икътисади качаклар агымына экологик качаклар һаман күбрәк кушыла бара.

Сезгә инде мәгълүм булганча, үсеп килүче илләрдәге хезмәткә яраклы һәр кешегә ике эшләмәүче туры килә. [20]. Мондый үзенчәлекле яшь составы демографик шартлау белән турыдан-туры бәйләнгән. Яшьләр саны чагыштырмача югары булу да күп кенә социаль проблемаларны читтән тыш кискенләштерә.

*Экологик проблема да азык-төлек һәм демографик проблема белән турыдан-туры бәйләнгән.* Әле 1972 елда ук Һиндстанның премьер-министры Индира Ганди хәерчелекне мохитне иң нык пычратучы дип атады. Чынлап та, бу илләрнең күбесе шулкадәр ярлы ки, ә халыкара сәүдә шартлары алар өчен шулкадәр җайсыз, аларга болай да сирәкләнгән урманнарын кисүдән, терлекләргә көтүлекләрне таптарга ирек бирүдән, киләчәк турында уйламыйча, «пычрак» производстволарны күчерүдән башка юл калмый. Чүлләнү, урманнарның бетүе, туфрак деградациясе, фауна һәм флора составының төрләре азаю, су һәм һава пычрану кебек процессларның беренчел сәбәбе нәкъ менә шунда. Тропиклар табигатенең бигрәк тә тиз зарарланучан булуы тискәре нәтиҗәләрне тирәнәйтә генә.

*Үсеп килүче илләрнең авыр хәле гомуми кешелек, дөнья күләмендәге иң зур проблемага әверелде.* Әле 1974 елда ук БМО 1984 елда бер генә кеше дә ач килеш йокларга ятмаска тиешлеген күздә тоткан программа кабул итте.

Менә ни өчен үсеп килүче илләрнең артталыгын бетерү әлеккечә чиктән тыш актуаль мәсьәлә булып кала. *Аны хәл итүнең төп юллары — бу илләрдә барлык тормыш һәм эшчәнлек даирәләрендә тамырдан социаль-икътисади үзгәртеп корулар үткәрүдә, фәнни-техник прогрессны, халыкара хезмәттәшлекне үстерүдә, коралсызлануда.* (8 нче иҗади бирем.)

## 2. ГЛОБАЛЬ ФАРАЗЛАР, ГИПОТЕЗАЛАР ҺӘМ ПРОЕКТЛАР БЕЛӘН ТАНЫШАБЫЗ

**1. Глобаль фаразлар: ике төрле караш.** Галимнәр кешелекнең якын һәм ераграк киләчәктә ничек үсәчәге турында шактый гына **глобаль фаразлар** эшләделәр. Аларда пессимистик һәм оптимистик дип атап була торган принципиаль аермалы ике карашны билгеләргә була.

Пессимистик караш 70 нче елларда Рим клубында[1] катнашучылар эшләгән глобаль сценарийларда аеруча ачык чагылды. Алардан инде XXI гасыр уртасында ук Җирнең күп кенә табигый ресурслары бетәчәк, ә мохитнең пычрануы коточкыч дәрәҗәгә җитәчәк дигән нәтиҗә ясап була иде.

Шуннан соң глобаль ресурс, экологик һәм азык-төлек кризисы туачак. Бер сүз белән әйткәндә, «ахырзаман» җитәчәк, ә безнең планета халкы акрынлап юкка чыгачак. Мондый галимнәрне алармистлар дип йөртә башладылар (франц. *alarme* — хафалану). Көнбатышта бик зур күләмдә алармистик әдәбият басылып чыкты.

[1] Рим клубы — кешелекнең глобаль проблемаларын өйрәнү һәм бөтендөнья үсеш системасын фаразлау, аның моделен эшләү буенча хөкүмәтнеке булмаган халыкара оешма. Аңа 1968 елда Рим шәһәрендә 10 ил вәкилләре тарафыннан нигез салынган. Галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре үзләренең тикшеренүләрен Рим клубына отчет рәвешендә нәшер итәләр.

Буржуаз футуролог-галимнәрнең китап исемнәре бик характерлы: «Үсеш чикләре», «Исән калу стратегиясе», «Кешелек — борылыш пунктында», «Йомыла торган түгәрәк», «Алда — упкын», «Халык арту бомбасы» һ. б. Бу хезмәтләрнең гомуми рухы Көнбатыш басмаларының берсендә чыккан пародиядә чагылыш тапкан: «Озакламый соңгы кеше, соңгы чеметем үләнне пешереп, соңгы күсене кыздырып ашар өчен, соңгы тамчы нефтьне файдаланачак».

Бу галимнәрнең киңәшләре халык санының да [21], җитештерүнең дә үсешен чикләүгә, ә иң яхшысы, бөтенләй туктатуга кайтып кала.

80 нче елларда дөнья футурологиясендә киләчәккә оптимистик бәя бирүгә күчү башланды. Мондый карашлы галимнәр кешелекнең глобаль проблемалары бик катлаулы булуын инкарь итмиләр. 1987 елда әйләнә-тирә мохит проблемалары буенча Халыкара комиссия үзенең «Безнең уртак киләчәгебез» дигән докладында экологик кризис һәм үсеш кризисы мөмкинлеге турында җитди кисәтү ясады.

Шулай да галимнәр Җир астында һәм Дөнья океанында әле бик күп файдаланылмаган һәм ачылмаган байлыклар саклануы, традицион ресурсларга алмашка яңа ресурслар килүе, ФТРның җәмгыять белән табигать арасындагы экологик тигезлекне яхшыртырга ярдәм итәчәге, ә хәзерге заман демографик шартларының мәңгелек күренеш булмавыннан чыгып эш итәләр. *Глобаль проблемаларны хәл итүнең төп юлын алар халыкны һәм җитештерүне кыскартуда түгел, ә кешелекнең фәнни-техник прогресс белән берлектә социаль прогрессында, дөнья сәяси климатының җылынуында һәм коралсызлануда күрәләр.*

90 нчы елларда да күп кенә экологик һәм икътисади фаразлар барлыкка килде. Икътисади фаразларга караганда, XXI гасырның беренче дистә ярым елында постиндустриаль илләрнең саны артачак. «Алтын миллиард» илләре дип йөртелгән илләр элеккечә югары тормыш дәрәҗәсен тәэмин итәчәкләр. Көньяк илләре «поезд»ы үзенең тизлеген арттырачак, аларның иң бай һәм иң ярлыларга аерылуы алга таба дәвам итәчәк, ул инде безнең көннәрдә үк күренә башлады. Шуңа нисбәтле рәвештә Төньяк белән Көньяк арасындагы икътисади упкын беркадәр кимеячәк, бигрәк тә абсолют һәм өлешле күрсәткечләрне исәпкә алганда. Ләкин ТЭПның җан башына исәпләнгән күрсәткечләрендә аерма бик зур булып калачак. Шулай ук геосәяси фаразлар да төзелә. [22].

**2. Глобаль гипотезалар: галимнәр нәрсә турында бәхәсләшә?** Кешелекнең киләчәк үсешенең кайбер аспектлары **глобаль фәнни гипотезаларда** да чагылыш таба.

Сез инде үзебезнең һәм чит ил галимнәре сөйләгән парник эффекты турындагы фәнни гипотезаны беләсез, алар климатның җылынуы арта бару нәтиҗәсендә аның глобаль үзгәрешләрен фаразлыйлар.

Чынлап та, соңгы йөз елда Җирдә уртача температура 0,6 °С ка

күтәрелде. Исәпләүләр күрсәткәнчә, парник эффекты үскәндә, температура 10 ел саен 0,5°С ка артырга һәм бу күп кенә тискәре нәтиҗәләргә китерергә мөмкин.

Әгәр дә глобаль температура хәтта 3—4°С ка гына күтәрелсә дә, климатик зоналар йөзләрчә километрга күчәр, игенчелек чикләре ерак төньякка таба авышыр, гаять зур мәйданнарда мәңгелек туңлык эрер иде. Төньяк Боз океаны җәен бозлардан ачылыр һәм суднолар йөрү өчен яраклы булыр иде. Икенче яктан, Мәскәү климаты хәзерге Кавказ арты климатына охшаячак. Африкадагы экваториаль зона Сахара районнарына күчәр иде. Антарктида һәм Гренландия бозлыклары эреп, Дөнья океаны «ярларыннан ташып чыгар» (аның тигезлеге 66 метрга күтәрелергә мөмкин) һәм яр буе түбәнлекләрен (ә анда хәзер кешелекнең 1/4 е яши) су басар иде.

Мондый алармистик фаразлар 60—70 нче елларда ясалды. Хәзерге фаразларга караганда исә, XXI гасыр уртасына кадәр уртача глобаль температура алай нык күтәрелмәячәк, ә Дөнья океанының күтәрелеше, мөгаен, уннарча сантиметрлар белән үлчәнер. Сүз уңаеннан әйткәндә, Океанның шул дәрәҗәгә генә күтәрелүе дә кайбер илләр өчен, бигрәк тә үсеп килүче илләр өчен, һәлакәтчел булырга мөмкин. [23]. (9 нчы бирем.)

Икенче бер кызыклы фәнни гипотеза — Җирдәге халык санының тотрыклануы гипотезасы. Мондый тотрыклылык (яки буыннарның гади алышынуы) демографик күчешнең дүртенче стадиясенә таңгәл килә, һәм ир-ат һәм хатын-кызларның уртача гомер озынлыгы 75 ел чамасы, ә туу һәм үлү күрсәткечләре 1000 кешегә 13,4 кеше булган шартларда урнашачак. Хәзерге вакытта демографларның күбесе шул фикердә. Әмма алар арасында мондый тотрыклылык нинди дәрәҗәдә һәм кайчан булачак дигән сорауларда бердәмлек юк. Күренекле совет демографы Б. Ц. Урланис (1906—1981) фикере буенча, ул XXI гасыр уртасыннан алып (Европа, Төньяк Америка) һәм XXII гасырның беренче чирегендә (Африка), кешелек 12,3 млрд ка җиткән вакытта булачак. Башка галимнәр 8 дән 15 млрд ка хәтле диләр.

Тагын бер фәнни гипотеза — Ойкуменополис гипотезасы (яки дөнья шәһәре), ул мегалополисларның кушылуы нәтиҗәсендә барлыкка киләчәк. Аны бөтен дөньяга танылган грек галиме К. Доксиадис тәкъдим итә.

**3. Глобаль проектлар: саклык кирәк!** Җирдәге зур регионнарның табигатен үзгәртеп коруның инженерлык проектлары да шактый күп, аларны **глобаль (дөньякүләм) проектлар** дип йөртәләр. Аларның күбесе Дөнья океаны белән бәйләнгән.

**Мисал.** Әле XX гасыр башында ук Гибралтар бугазында 29 км озынлыктагы плотина кору проекты әзерләнә. XX гасыр уртасында Беринг бугазында плотиналар кору проектлары тәкъдим ителә. Америка инженерлары Гольфстрим агымыннан энергия алу, хәтта

кирегә бару проектын эшлиләр. [24]. Конго бассейнында ясалма диңгез булдыру проекты да бар.

Бу проектларның бер өлешен безнең көннәрдә фәнни фантастика дип атарга мөмкин. Ләкин аларның кайберләре ФТР чорында техник яктан тормышка ашырылырга мөмкин. Әмма хәзерге заманның техник куәтләре белән табигать процессларына тыкшынуның мөмкин булган экологик нәтиҗәләрен дә исәпкә алмый ярамый.

## 3. ТОТРЫКЛЫ ҮСЕШ СТРАТЕГИЯСЕ БЕЛӘН ТАНЫШАБЫЗ

**1. Тотрыклы үсеш төшенчәсе.** ***Тотрыклы үсеш***[1] термины БМО документларында 80 нче еллар урталарында пәйда булды. Ләкин дәүләти һәм фәнни әйләнешкә ул киң рәвештә БМОның Рио-де-Жанейрода тирә-як мохит һәм үсеш буенча үткән конференциясеннән соң керде (1992 ел). Күп кенә илләр, Россияне дә кертеп, җәмгыятьне тотрыклы үсешкә юнәлткән законнар кабул итте.

**Тотрыклы үсеш — җәмгыять һәм табигать үсешенең идарә ителә торган процессы. Ул, хәзерге һәм киләчәк буыннарны да күздә тотып, табигатьне саклауны да һәм кешеләрнең яшәеше өчен уңайлы шартларны да тәэмин итәргә тиеш.**

Бүтәнчә әйткәндә, тотрыклы үсеш стратегиясе тирә-як мохитнең алга таба деградациясен булдырмауга, ә киләчәктә табигать мохите белән җәмгыять арасында тотрыклы оптималь нисбәт тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

**2. Тотрыклы үсеш: төп өч компонент.** Тотрыклы үсеш стратегиясе төп өч компонентны үз эченә ала.

*Беренчедән, бу — экологик яктан тотрыклы үсеш.* Кешелек дөньясы биосфера сыйдырышлыгы белән билгеләнә торган чикләрдә яшәргә өйрәнергә, табигатьтән алына торган ресурсларның да, шулай ук үзенең яшәве һәм эшчәнлеге нәтиҗәсендә табигатькә кире кайтарыла торган калдыкларның да күләмен киметергә тиеш.

*Икенчедән, бу — икътисади тотрыклы үсеш.* Ул дөнья икътисадында структур һәм территориаль үзгәрешләрне, хуҗалыкның интенсивлыгын һәм продуктлылыгын күтәрүне, табигать белән җәмгыять арасындагы тигезлекне саклау күзлегеннән чыгып оптималь икътисади үсеш темпларына ирешүне күздә тота.

*Өченчедән, бу — тотрыклы социаль үсеш.* Ул демографик проблемаларны, эш белән тәэмин итү проблемаларын, тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын баланслы хәл итүне, белем алу мөмкинлеген, мәдәният кыйммәтләренә якынаю мөмкинлеген киңәйтүне, кешеләрнең гражданлык хокукларын һәм шәхси хәвефсезлеген тәэмин итүне белдерә.

---

[1] Тотрыклы үсеш — инглиз термины *sustainable development* ның тәрҗемәсе. Күп кенә галимнәр балансланган үсеш турында сөйләү дөресрәк булганлыктан, аны бик үк төгәл түгел диләр.

Шул рәвешле, тотрыклы үсеш үзенә бертөрле өч юнәлешле бердәм системага тирә-як мохитне, икътисадны һәм кешеләрнең иминлеген үзара берләштергән сыман була. *Аңа ачкыч барлык дәрәҗәләрдә:* глобаль, региональ, милли (дәүләт) һәм локаль дәрәҗәләрдә *табигатьтән файдалану, икътисад һәм җәмгыять белән идарә итүне камилләштерүдә яшеренгән.* Мондый стратегияне гамәлгә ашыру аеруча глобаль дәрәҗәдәге әһәмияткә ия дип икрар итсәк хата булмас.

«Без берләшергә һәм табигатькә, кешенең универсаль хокукларына, икътисади гаделлеккә һәм дөнья мәдәниятенә хөрмәт белән карауга нигезләнгән глобаль җәмгыять төзергә тиешбез»,— диелә инде искә алынган «Җир декларациясе»ндә (яисә «Җир хартиясе»). 2002 елның сентябрендә Йоханнесбургта (КАР) тотрыклы үсеш проблемалары буенча Бөтендөнья конференциясе булды.

**3. Тотрыклы үсеш һәм география.** Тотрыклы үсеш стратегиясен фәнни белемнәр белән тәэмин итүдә географлар да актив катнаша. Алар күптөрле халыкара фәнни программаларны тормышка ашыруда катнашалар. Шундыйлар исәбенә физик, химик, геологик, биологик, географик һәм социаль процессларны өйрәнүгә, шулай ук глобаль үзгәрешләрне прогнозлауга юнәлтелгән «Халыкара геосфера-биосфера программасы» да керә. Башка фән белгечләреннән аермалы буларак, географлар бу проблемага физик география ягыннан гына түгел, ә социаль-икътисади география ягыннан да комплекслы якын киләләр. Алар кешенең табигатькә йогынтысы, урманнарның бетүе, чүлләр барлыкка килү һәм демографик шартлаулар, шәһәрләрнең үсүе һәм киңәюе, кешеләрнең сәламәтлеге, бөтендөнья хуҗалыгы һәм тагын да киңрәк — бөтендөнья бердәмлеге белән бәйле глобаль үзгәрешләрне өйрәнәләр.

1995 елда Мәскәүдә «Глобаль үзгәрешләр һәм география» дигән Халыкара география конференциясе булып узды. Бу конференциядә ясаган докладында ***Халыкара Географик Союзның***[1] шул чагындагы президенты Голландия географы Г. Верстаппен болай дигән иде: «Географлар Җир шарының барлык почмакларында — поляр районнардан алып дымлы тропик урманнарга кадәр һәм яр буе зоналарыннан алып дөньядагы иң биек тау түбәләренә кадәр эшлиләр. Шуңа күрә алар глобаль үзгәрешләрнең пространство аспектларын тикшерүгә үз өлешләрен уңышлы төстә кертәләр, шул рәвешле безнең Җир турындагы белемнәребезнең киңәюенә һәм тирәнәюенә ярдәм итәләр».

---

[1] Халыкара Географик Союз (ХГС) — дөнья географларының 1922 елда нигез салынган фәнни оешмасы. Аның максатлары — география проблемаларын, аеруча халыкара хезмәттәшлекне таләп итүче сорауларны өйрәнүгә ярдәм итү; аларны фәнни тикшерүне тәэмин итү һәм нәтиҗәләрне бастырып чыгару. Конгресслары дүрт елга бер тапкыр уздырыла.

**Төп нәтиҗә.** *Глобаль проблемалар кайбер фәнни, техник, икътисади һәм башка мәсьәләләрне хәл итү белән бәйләнгән, ләкин алар — беренче чиратта социаль проблемалар. Тынычлык һәм фәнни-техник революция шартларында кешелек цивилизациясенә халык артык күп булудан, ресурслар җитмәүдән һәм мохитнең пычрануыннан һәлакәт янамый.* (10 нчы йомгаклау биреме.)

## ӨСТӘМӘ ТЕКСТ (Кызыклы мәгълүматлар)

[1] XX һәм XXI гасырлар чигендә галимнәр дөньяда сепаратизмның 53 төп учагын аерып күрсәтәләр. Алар 220 млн халкы булган 12,7 млн км$^2$ территорияне били. Мондый учаклар бигрәк тә Европа, Азия һәм Африкада күп. Аларның 20 сендә, бигрәк тә Азия һәм Африкада, конфликтлар коралы характер йөртә.

[2] 2002 елда су басу нәтиҗәсендә 80 илдә 17 млн кеше йортҗирсез калды, 3 меңнән артыгы һәлак булды. 2005 елда «Катрина» давылы Америкадагы Яңа Орлеанны җимерде һәм 100 млрд долларлык зыян китерде.

[3] 2025 елда Кытай үзенең 1490 млн халкы белән, Һиндстанны (1330 млн) узып, беренче урында калачак. Әмма 2050 елда беренче урынга Һиндстан чыгачак. Аның халкы 1600 млн га җитәчәк, ә Кытайда 1400 млн кеше яшәячәк.

[4] Исәпләүләр буенча 2010 елда шәһәр халкы барлык халыкның 53 % ын тәшкил итәчәк, ә 2025 елда — 61 % (шул исәптән Төньяк һәм Латин Америкасында — 85 %, Европа чит илләрендә — 83 %, Азия чит илләрендә һәм Африкада — 54 %). 2010 елда инде дөньядагы 27 гадәттән тыш зур шәһәрнең 20 се Көньяк илләрендә булачак.

[5] Кирәгеннән артык ашаучы кешеләрнең саны дөньяда 600 млн кеше булыр дип исәпләнә. Бәяләүләргә караганда АКШта кирәгеннән артык авырлыгы булган халык 25—30 %, Германиядә 50 % тәшкил итә. Россиядә гражданнарның 1/3 өлеше шушы категориягә туры килә.

[6] Һиндстанда авыл хуҗалыгында эшләүче бер кеше 5 кешене туйдырса, ГФРда — 50, АКШта — 80, Бельгиядә 100 кешене ашата. Әлбәттә, биредә фермерлар һәм крестьяннарны гына түгел, АПКда эшләүче барлык кешене күздә тотарга кирәк.

[7] Бары тик 1960—1980 елларда гына да Җир куеныннан XX гасырның башыннан бирле алынган барлык бакыр һәм цинкның 50 % ы, тимер рудасының 55 % ы, алмазларның 60 % ы, никель, калий тозы һәм фосфоритларның 65 % ы, бокситларның 80 % ы чыгарыла.

[8] Япониядәге «Мазда» автомобиль фирмасы әле 90 нчы елларның беренче яртысында ук дөньяда беренче водород двигательле

автомобильне төзи һәм сынап карый. Яңадан ягулык салмыйча, ул 230 км бара һәм тизлеген 170 км/сәг кә җиткерә ала. Автомобильгә гадәти түгел, ә 130 а. е. роторлы двигатель куелган. 1996 елда водородлы ягулык элементлары куелган автомобильне Германиядәге «Даймлер-Бенц» автомобиль концерны чыгарды.

[9] 1967 елда чәчәк авыруы белән бөтен дөньяда 10 млн нан алып 15 млн га кадәр кеше авырды. Аларның 2 млн ы вафат булды, ә исән калган миллионлаган кеше сукырайды яисә гарипләнде. Халыкны тулысынча вакцинацияләүдән соң чәчәк белән авыруның мәгълүм соңгы очрагы 1977 елда Сомалида теркәлгән.

[10] Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы мәгълүматларына караганда, дөньяда ел саен бизгәк белән 110 млн лап кеше авырый, 1 млн нан 2 млн га кадәр кеше үлә. 100 дән артык тропик һәм субтропик илне үз эченә алган «хәвефлелек зонасы»нда 2 млрд тан артык кеше яши.

[11] Исәпләүләргә караганда, хәзер Җирдә яшәүче балигъ булганнарның якынча 40 % ы тәмәке тарта. Тәмәке тарту буенча дөньяда беренче урында — Кытай, икенче — АКШ, өченче — Япония. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасының отчетларыннан күренгәнчә, Җирдә яшәүче һәр 12 нче кеше никотиннан үлә. Шуңа күрә АКШта һәм Көнбатыш Европада соңгы вакытта тәмәке тартуга каршы актив көрәш башланды, һәм моның инде уңай нәтиҗәләргә китерүе гаҗәп түгел.

[12] СССРда Ак диңгездә Мезень (10—15 млн кВт) һәм Беломор (14 млн кВт) су күтәрелешле электр станцияләре кору, Охота диңгезендә тагын да зуррак Пенжин (30—100 млн кВт), Франциядә Ла-Манш яр буенда (50 млн кВт), Бөекбританиядә — Бристоль култыгында (Северн елгасы тамагында), Һиндстанда Гарәп диңгезенең Кач култыгында шундый ук электр станцияләре төзү мөмкинлеге каралды.

[13] Япониядә диңгез фермаларын һәм плантацияләрен киңәйтү программасы тормышка ашырыла. Ул «диңгез хәзинәсе»ннән 8—9 млн т продукция алырга һәм халыкның балыкка һәм диңгез продуктларына булган ихтыяҗының яртысын канәгатьләндерергә исәп тота. АКШ, Һиндстан, Филиппин диңгез фермаларында креветкалар, крабълар, мидияләр, Франциядә устрицалар үрчетәләр. Тропик илләрдә кит һәм дельфин фермалары булдыру өчен мәрҗән (коралл) утрауларыннан файдалану күздә тотыла.

[14] Тулысынча автономияле, 500 меңнән алып 1 млн га кадәр кеше сыешлы 25 км$^2$ лы йөзмә шәһәр проектын Япониядә эшләделәр. Шәһәр урнашачак ясалма утрау 10 мең корыч терәктә һәм гаять зур буйлардан торачак. Проект буенча, ул берничә «палуба»дан торырга тиеш. Америка фирмасы 1 км озынлыктагы 90 мең яшәүчегә исәпләнгән корабль-утрау төзи башлады.

[15] Трансатлантик кабельнең беренче проектын әле 1843 елда ук телеграфны уйлап тапкан Самуил Морзе тәкъдим итә. Әмма аны 1858 елда гына салалар. Европа һәм Төньяк Америка беренче телефон кабеле белән 1955—1956 елларда тоташтырыла. Ә 90 нчы еллар башында беренче су асты оптика линияләренең икесе салына: АКШ — Гавай утраулары — Япония (11,5 мең км) һәм АКШ — Көнбатыш Европа (6,5 мең км).

[16] Әзер хәлдә космик станциянең авырлыгы 454 т («Мир» Россия космик станциясе 140 т авырлыкта иде), аның озынлыгы — 120 м, киңлеге — 24 м, биеклеге — 21,5 м, конструкцияләрне беркетү өчен фермаларының колачы — 108,5 м, кояш батареяларыныкы 72 м булырга тиеш. МКСның беренче модуле «Альфа» Байконур космодромыннан 1998 елның декабрендә җибәрелде.

[17] Монда инде төп игътибар планеталарны тикшерү-өйрәнүгә бирелә. Мәсәлән, Америка «вояджерлары» Юпитер, Сатурн, Уран һәм Нептунга космонавтика тарихында иң озакка сузылган очыш ясадылар. Ә 2006 елда зондлы ракета җибәртелде, ул 2015 елда Плутонга барып җитәргә тиеш. АКШ, ЕС, Россия, Кытай кешенең Айга яңа очышларын XXI гасырның 20 нче елларында планлаштыралар.

[18] Шундый ярлы илләргә мисал итеп, барлык халыкның 70 % ы көненә 1 долларга яшәүче Нигерия һәм Нигер, Үзәк Африка Республикасы (66 %), Малави (60 %), Бурунди һәм Сьерра-Леоне (67 %), Мадагаскар (50 %) ны күрсәтергә мөмкин.

[19] Җир ресурсларын шведлар, швейцариялеләр, американлылар сомалилыларга караганда 40 мәртәбә күбрәк тоталар, һиндләргә караганда итне 75 мәртәбә күбрәк ашыйлар. Уртача американлы елына 174 йомырка ашаса, ә индус бары тик 25 кенә (яки ике атнага бер йомырка). Япониядә яшәүче Танзаниядә яшәүчегә караганда азык-төлеккә 20 тапкыр күбрәк акча тота.

[20] Үсеп килүче илләрдә эшли ала торган яшьтәге 1000 кешегә уртача 680 бала туры килә. Хәтта балалар эшләүчеләргә караганда күбрәк булган яки аларның саннары тигез булган илләр дә бар: Иордания, Сүрия, Алжир, Ливия, Кения, Зимбабве, Бурунди, Мадагаскар, Гондурас, Никарагуа. Чагыштыру өчен: Европа чит илләрендә эш яшендәге 1000 кешегә уртача — 360, АКШта, Канадада, Япониядә 380 бала туры килә.

[21] Көнбатыш галимнәре һәм җәмәгать эшлеклеләре халык артуны чикләүнең нинди генә ысулларын тәкъдим итеп карамадылар! Гаилә корырга бай кешеләргә генә рөхсәт бирү дисеңме, мәҗбүри стерилизация дисеңме, бала тудыруга төрле тыюлар дисеңме! Хәтта ирләр өчен махсус даруларга хәтле уйлап чыгардылар, аны кулланса, туган барлык балаларның 90 % ы малай була, имеш.

[22] Бер Америка географының исәпләвенчә, әгәр дә дәүләтләрдә безнең көннәр өчен характерлы таркалу процессы киләчәктә дә дәвам итсә, тагын 20—30 елдан суверен дәүләтләрнең саны 300 гә җитәргә мөмкин. Монда ул бүгенге Бельгия, Бөекбритания, Франция, Испания, Һиндстан, Әфганстан, Конго Демократик Республикасы, Канада һәм кайбер башка илләрнең таркалу мөмкинлегеннән чыгып шундый нәтиҗәгә килә. Ә тагын бер Америка футурологы 2100 елга дөньядагы илләрнең саны 2000 гә җитәргә мөмкин дип фаразлый!

[23] Дөнья океаны хәтта 50 см га күтәрелгәндә дә Мальдив утраулары, Мисырда Нил үзәнлекләре тулысынча диярлек су астында калырга мөмкин. Ә инде аның 1 метрга күтәрелүе Бангладешның 20 млн кеше яши торган диңгез буе өлешен су басуга китерер иде.

[24] АКШта эшләнгән инженерлык проекты буенча, Флорида агымының су ташкынына бик зур диаметрлы (80 м га кадәр) эченә куәтле гидротурбиналар куелган 200 торба урнаштырылырга һәм якорьлар белән беркетеп куелырга тиеш. 30 метрдан алып 120 м тирәнлектә һәм бер-берсеннән 20 км ераклыкта урнаштырылган бу турбиналар Гольфстримның бушлай энергиясенең бары тик 4 % ын файдаланырга мөмкинлек бирсә дә, алынган энергия 25 млн кВт тәшкил итәр иде. Америка белгечләре шулай ук Гольфстрим агымын төньякка бору проектын эшләделәр. Бу Төньяк Американың көнчыгыш ярлары буендагы климатны яхшыртырга мөмкинлек бирер иде.

**Китап киштәсе**

1. Земля и человечество. Глобальные проблемы.— М.: Мысль, 1985.— Введение.— Ч. IV.— (Серия «Страны и народы»).
2. Максаковский В. П. Географическая картина мира.— М.: Дрофа, 2009.— Ч. I.— Тема 6.
3. Максаковский В. П. Новое в мире: цифры и факты: Дополнительные главы к учебнику 10 кл.— М.: Дрофа, 1999.— Раздел VI.
4. Моисеев Н. Н. Быть или не быть... человечеству?— М., 1999.
5. Родионова И. А. Глобальные проблемы человечества.— М.: Аспект Пресс, 1994.
6. Гладкий Ю. Н., Лавров С. Б. Дайте планете шанс!: Кн. для учащихся.— М.: Просвещение, 1995.

## БЕЛЕМ ҺӘМ КҮНЕКМӘЛӘР АЛУ ӨЧЕН ТУПЛАНМА

**1 нче иҗади бирем.** 2 нче теманы һәм дәреслектәге башка темаларның эчтәлеген файдаланып, дәфтәрдә «Җәмгыятьнең мохиткә тәэсир итү факторлары һәм формалары» дигән схема төзегез. Тирә-якны саклау проблемаларын хәл итүнең планетабызда яшәгән һәр кешенең, шул исәптән үзегезнең дә, тырышлыгына ни дәрәҗәдә бәйле булуын уйлап карагыз.

**2 нче иҗади бирем.** 3 нче һәм дәреслектәге бүтән темаларның эчтәлеген, «Кушымта»дагы 11, 16, 17, 34 нче һәм 35 нче таблицаларны файдаланып, планетаның безнең көннәрдәге һәм XXI гасырның беренче чирегендәге «демографик портреты»н телдән сурәтләгез.

**3 нче иҗади бирем.** Дәреслектәге 1 нче һәм башка темаларның эчтәлеген, шулай ук вакытлы матбугатта чыккан материалларны файдаланып, «Атом-төш коралы булмаган, куркынычсыз дөнья төзү юлында» дигән темага чыгыш (язма реферат) әзерләгез.

**4 нче иҗади бирем.** 99 нчы рәсемне, шулай ук 2, 5 нче һәм башка темаларның эчтәлеген файдаланып, глобаль азык-төлек проблемасының географик аспектларын тасвирлагыз. Дөньяда азык-төлек җитмәү иң элек табигый сәбәпләр белән түгел, ә социаль-икътисади сәбәпләр белән аңлатылуын исбатлагыз. Азык-төлек проблемасын хәл итүдә катнашучы хуҗалык тармакларын әйтегез.

**5 нче иҗади бирем.** 2, 4 нче һәм 5 нче темаларның эчтәлеген, шулай ук курсның региональ өлешен һәм атлас карталарын файдаланып, кешелекнең энергетик һәм чимал проблемаларының географик аспектларын формалаштырыгыз. Сезнеңчә, аларны хәл итүнең мөмкин булган юллары нинди?

**6 нчы иҗади бирем.** Дәреслектәге 2, 3 нче темаларны һәм массакүләм мәгълүмат чаралары материалларын файдаланып, «Кеше сәламәтлеге һәм озын гомерлеге проблемалары» дигән темага диспут әзерләгез.

**7 нче иҗади бирем.** 1—5 нче темалар эчтәлеген диңгез хуҗалыгы төшенчәсен аңлату өчен файдаланыгыз. Дәфтәрдә бу төшенчәнең схемасын төзегез. Дөньякүләм диңгездә нефть чыгару һәм дөньякүләм диңгез балыкчылыгы карталарын чагыштырыгыз һәм диңгездә нефть чыгару һәм балык тоту территориаль яктан бергә туры килүләреннән туган проблеманы мөстәкыйль рәвештә формалаштырыгыз. Аны хәл итү юлларын тәкъдим итегез.

**8 нче иҗади бирем.** 11 нче теманың эчтәлеген файдаланып, дәфтәрдә «Үсеп килүче илләрнең артталыгын бетерү проблемасының кешелекнең башка глобаль проблемалары белән бәйләнеше» схемасын төзегез.

**Кызыксынучыларга 9 нчы бирем.** Дөньяның һәм регионнарның физик карталарын анализлагыз һәм Дөнья океанының 1—1,5 м га гына күтәрелеп территорияне су басу аркасында нинди илләргә һәлакәтле нәтиҗәләр янавын билгеләгез.

**10 нчы йомгаклау биреме.** 1. 11 нче теманың график конспектын төзегез.

2. (Дәфтәрдә эшләү.) Тупланган белемнәр нигезендә «Кешелекнең глобаль проблемаларына характеристика» дигән белешмә таблица төзегез. Таблица материалларын гомумиләштерегез.

## ҮЗЕГЕЗНЕҢ ҺӘМ БЕР-БЕРЕГЕЗНЕҢ БЕЛЕМНӘРЕН ТИКШЕРҮ ТУПЛАНМАСЫ

**Ничек уйлыйсыз:**

1. Әгәр дә сез нефть ятмаларының нефть бирешен 20 % ка күтәрә алсагыз, бу Көнбатыш Себер бассейны белән чагыштыра алырлык нефть бассейны «ачу»га тиң булыр идеме?

2. Үсеп килүче илләрнең ягулык-чимал ресурслары нибары «айсбергның түбәсе» генә дигән образлы әйтем нәрсәне белдерә? Бу «айсберг»ны тулысынча файдалану өчен нәрсә эшләргә кирәк?

3. «Без Җирне ата-бабалардан мирас итеп алмадык. Без аны киләчәк буыннардан бурычка алдык» дигән әйтем нәрсәне белдерә?

4. Ни өчен глобаль проблемаларны хәл итү дәүләтләр һәм хөкүмәтләрдән генә түгел, ә барлык Җирдә яшәүчеләрдән дә, һәр аерым кешедән, шул исәптән сездән дә тора?

## 11 НЧЕ ТЕМАГА МЕТОДИК АЧКЫЧЛАР

### Боларны исегезгә төшерегез

Дәреслектәге 1—10 нчы темаларның барлык материалын.

### Боларны үзләштерегез

**11 нче теманың төп идеяләре:**

1. Хәзерге чор — каршылыклы, әмма һаман бербөтенрәк була барган дөньяның үсә барган үзара бәйлелеге чоры.

2. Барлык глобаль проблемалар комплексының үзәге һәм берләштерүче буыны булып кеше һәм аның киләчәге тора.

**11 нче темадагы төп фәнни белемнәр:**

1. Кешелекнең глобаль проблемалары төшенчәсе. 2. Бу проблемаларның һәркайсының асылы, барлыкка килү сәбәбе һәм хәл итү юллары. 3. Тотрыклы үсеш стратегиясе төшенчәсе. 4. Тотрыклы үсеш һәм география. 5. Теманың төп төшенчәләре: 1) глобальләшү, 2) «алтын миллиард», 3) глобаль проблема, 4) экологик кризис, 5) экологик кризислы (критик) район, 6) диңгез хуҗалыгы, 7) глобаль фараз, 8) глобаль фәнни гипотеза, 9) глобаль (дөньякүләм) проект, 10) тотрыклы үсеш.

### Сез нәрсәләр белергә тиеш

1. Кешелекнең глобаль проблемаларына характеристика бирергә, алар арасында үзара бәйләнеш урнаштырырга. 2. Дәреслек текстының график конспектын төзергә. 3. Бирелгән темага дискуссия (диспут) оештырырга.

# XXI гасыр башындагы дөньяны аңлыйбыз. (Йомгаклау урынына)

Безнең дөнья, күпьяклы һәм каршылыклы дөнья, яңа гасыр һәм яңа меңьеллыкка аяк басты.

Ул сәяси, икътисади һәм социаль характердагы катлаулы проблемаларга бай, аларның күбесенең мөһим территориаль, географик аспектлары бар.

Бөтендөнья хуҗалыгының ФТРның хәзерге этабы белән бәйләнгән яңа үсеш стадиясенә керүе XXI гасыр башында һәр илнең икътисади куәте иң әлек аның фән һәм техникадагы иң яңа казанышларны ничек үзләштерүе, халык тормышын яхшырту максатларында хезмәт җитештерүчәнлеген ни дәрәҗәдә күтәрүе белән билгеләнәчәген аңлата. Моңа бәйле рәвештә гаять зур бурычлар кеше гакылының иң тулы чагылышы булган фән алдына да килеп баса.

Башлыча тасвирлау фәне булган география фәне дә акрынлап конструктив-үзгәртүләр фәненә әйләнә бара. Ул географик мохитнең яңа торышын, географик тышчаны өйрәнү һәм фаразлау, табигатьне антропоген үзгәртүнең критик чикләрен урнаштыру, аның белән җәмгыять арасындагы үзара йогынтыны оптимальләштерү белән шөгыльләнә, халыкны һәм хуҗалыкны рациональ урнаштыруда катнаша.

Үз чиратында бөтендөнья икътисадын үзгәртеп кору, фәнни-техник прогресс, мәгълүмат алмашуның тизләшүе, кешеләрнең һәм товарларның күченүе тизләнү, — бер сүз белән әйткәндә, кешелек цивилизациясенең бөтен үсеше дөньяның һаман да берләшә баруына, континентлар, регионнар һәм илләр арасында үзара бәйлелеккә илтә. Менә ни өчен безнең тормышыбызга гомумкешелек характерындагы мәнфәгатьләр һаман күбрәк үтеп керә һәм тагын да ачыграк чагыла бара. Беренче чиратта алар кешелекнең глобаль проблемаларында чагылыш табалар, ә алар, инде белгәнегезчә, дәүләтләр һәм халыкларның бөтен планета масштабларында конструктив, иҗади якын килеп аралашуларын таләп итә.

*Каршылыклы, әмма бербөтен булып барган дөньяның үзара тыгыз бәйлелеге — хәзерге дөнья үсешенең иң мөһим сыйфаты.* Ул XX һәм XXI гасырлар чикләрендә сыйфат ягыннан яңа, гомумдөнья цивилизациясе формалашу тенденциясе көчәюен күрсәтә. «Без барыбыз да — Җир исемле корабль пассажирлары» — француз язучысы Антуан де Сент-Экзюперины бу образлы гыйбарәсе нәкъ менә бүген аеруча актуаль. Шулай булгач, әйдәгез, бу корабль уңышлы йөзсен өчен, үзебезнең кулдан килгән бар нәрсәне дә эшлик!

## КУРСНЫ ТИРӘНРӘК ҮЗЛӘШТЕРҮ ӨЧЕН ӨСТӘМӘ ӘДӘБИЯТ


1. Алисов Н. В., Хорев Б. С. Экономическая и социальная география мира (общий обзор): Учеб. для вузов.— М.: Гардарики, 2000.
2. Баранчиков Е. В. Справочные материалы по экономической географии России и мира.— М.: Федеральный центр тестирования, 2005.
3. Бахчиева О. А. Экономическая и социальная география мира: 10 кл.: Учеб. пособие.— М.: Дрофа, 2005.
4. Большой энциклопедический словарь. — М.: БРЭ, 2005.
5. География: Пособие для поступающих в вузы. — М.: Дрофа, 2006.
6. География: Учеб. для студентов / Под ред. Е. В. Баранчикова.— М.: Academia, 2005.
7. Гладкий Ю. Н., Соколов О. В., Файбусович Э. Л. Экономическая и социальная география: Пособие для поступающих в вузы.— М.: Просвещение, 1999.
8. Гладкий Ю. Н., Сухоруков В. Д. Общая экономическая и социальная география зарубежных стран: Учеб. для студентов. — М.: Academia, 2006.
9. Голубчик М. М., Евдокимов С. А. География: Учеб. для экологов и природопользователей.— М.: Аспект Пресс, 2003.
10. Копылов В. А. Экономическая и социальная география. Мир. Россия: Пособие для поступающих в вузы.— М.: Маркетинг, 2001.
11. Колосов В.А., Мироненко Н.С. Геополитика и политическая география.— М.: Аспект Пресс, 2001.
12. Лавров С.Б., Гладкий Ю.Н. Глобальная география.— М.: Дрофа, 2001.
13. Лаппо Г. М. География городов.— М.: ВЛАДОС, 1997.
14. Липец Ю. Г., Пуляркин В. А., Шлихтер С. Б. География мирового хозяйства.— М.: ВЛАДОС, 1999.
15. Любимов И. М. Общая политическая, экономическая и социальная география: Учеб. пособие.— М.: Гелиос АРВ, 2001.
16. Любимов И. М. Экономическая география: Самоподготовка в вуз.— М.: Гелиос АРВ, 2002.
17. Максаковский В. П. Всемирное культурное наследие.— М.: Просвещение, 2003.
18. Максаковский В. П. Географическая культура.— М.: ВЛАДОС, 1998.
19. Максаковский В. П. Литературная география: Кн. для учителя.— М.: Просвещение, 2005.
20. Максаковский В. П. Общая экономическая и социальная география: Курс лекций.— М.: ВЛАДОС, 2008.— Ч. I.
21. Народонаселение: Энциклопедический словарь.— М.: БРЭ, 1994.
22. Перцик Е. Н. Города мира. География мировой урбанизации.— М.: Международные отношения, 1999.

23. Пивоваров Ю. Л. Основы геоурбанистики: Учеб. для вузов.— М.: ВЛАДОС, 1999.
24. Поспелов Е. М. Школьный словарь географических названий.— М.: Профиздат, 2000.
25. Родзевич Н. Н. Геоэкология и природопользование: Учеб. для вузов.— М.: Дрофа, 2003.
26. Социально-экономическая география зарубежного мира: Учеб. для вузов / Под ред. В. В. Вольского.— М.: Дрофа, 2001.
27. Страны мира: Энциклопедия.— М.: Олма-Пресс, 2006.
28. Холина В. Н. География человеческой деятельности.— М.: Просвещение, 2001.
29. Холина В. Н., Бунакова Т. М. География: Пособие для поступающих в вузы.— М.: Дрофа, 2004.
30. Холина В. Н., Наумов А. С., Родионова И. А. Социально-экономическая география: Справочное пособие.— М.: Дрофа — ДиК, 2006.
31. Черников Г. П., Черникова Д. А. Европа на рубеже XX—XXI вв. Проблемы экономики: Пособие для вузов.— М.: Дрофа, 2006.
32. Экономическая, социальная и политическая география мира. Регионы и страны: Учеб. для вузов / Под ред. С. Б. Лаврова, Н. В. Каледина.— М.: Гардарики, 2002.
33. Энциклопедия стран мира.— М.: Экономика, 2004.

## ТЕРМИННАР ҺӘМ КЫСКАРТУЛАР КҮРСӘТКЕЧЕ
## (саннар дәреслекнең битләрен күрсәтә)


Азия-Тын Океан регионы (АТР) 107
Аквакультура 150
Апартеид 285
Африка бердәмлеге оешмасы (ОАЕ), Африка Союзы (АС) 275
Бөекбритания җитәкчелегендәге Бердәмлек 250
Бөтендөнья банкы 163
Генофонд 38
Геноцид 277
Геоинформатик система (ГИС) 97
Гринпис 45
Демография 57
Депопуляция 59
Депрессив район 110
Доминион 257
Европа Союзы (ЕС) 101
Җир биләү һәм җирдән файдалану 192
Икътисади актив халык 67
Контейнерлаштыру 151
Көньяк-Көнчыгыш Азия дәүләтләре Ассоциациясе (АСЕАН) 101
Латин Америкасы интеграциясе ассоциациясе (ЛАИ) 101
Латифундия 339
Мегалополис 244
Мониторинг 47
Нефть экспортлаучы илләр оешмасы (ОПЕК) 102
Полимагистраль 195
Ресурс циклы 46
Рим клубы 464
Сәүдә балансы 162
Сегрегация 297
Сепаратизм 16
Субурбанизация 183
Суверен дәүләт 9
Табигый ресурс потенциалы (ТРП) 46
Теократик монархия 18
Технопарк 114
Технополис 114
Тотрыклы үсеш 367
Төньяк Атлантика Килешүе Оешмасы (НАТО) 14
Транснациональ корпорация (ТНК) 102
Тулай милли продукт (ТМП) 301
Тулай эчке продукт (ТЭП) 11
Унитар дәүләт 19
Уртача гомер озынлыгы 65
«Үсеш полюсы» 254
Фәнсыешлык 93
Федератив дәүләт 19
Халыкара валюта фонды (МВФ) 163
Халыкара Географик Союз (ХГС) 368
Этнология (этнография) 57
Этнос 68
Ягулык-энергетика балансы электрлашуы 130

# КУШЫМТА

1 нче таблица

**Икенче бөтендөнья сугышыннан соң сәяси бәйсезлеккә ирешкән илләр**

| Ил (элеккеге исеме) | Дөнья кисәге | Бәйсезлек игълан итү елы | Ил-метрополия |
|---|---|---|---|
| 1. Корея (Корея Респ. һәм КХДР) | Азия | 1945 | Япония |
| 2. Вьетнам | Азия | 1945 | Франция |
| 3. Индонезия | Азия | 1945 | Нидерланд |
| 4. Иордания | Азия | 1946 | Бөекбритания |
| 5. Ливан | Азия | 1946 | Франция |
| 6. Сүрия | Азия | 1946 | Франция |
| 7. Филиппин | Азия | 1946 | Испания, АКШ |
| 8. Һиндстан | Азия | 1947 | Бөекбритания |
| 9. Пакистан | Азия | 1947 | Бөекбритания |
| 10. Мьянма (Бирма) | Азия | 1948 | Бөекбритания |
| 11. Израиль (1948 елга кадәр ул территориядә Палестина була) | Азия | 1948 | Бөекбритания |
| 12. Шри-Ланка (Цейлон) | Азия | 1948 | Бөекбритания |
| 13. Лаос | Азия | 1949 | Франция |
| 14. Ливия | Африка | 1951 | Италия |
| 15. Камбоджа | Азия | 1953 | Франция |
| 16. Марокко | Африка | 1956 | Испания, Франция |
| 17. Тунис | Африка | 1956 | Франция |
| 18. Судан | Африка | 1957 | Бөекбритания белән Мисырның уртак биләмәсе |
| 19. Гана (Алтын Яр) | Африка | 1957 | Бөекбритания |
| 20. Малайзия | Азия | 1957 | Бөекбритания |
| 21. Үзәк Африка Республикасы (Убанги-Шари) | Африка | 1958 | Франция |
| 22. Гвинея (Франц. Гвинеясы) | Африка | 1960 | Франция |
| 23. Кот-д' Ивуар (Фил Сөяге Яры) | Африка | 1960 | Франция |
| 24. Буркина-Фасо (Югары Вольта) | Африка | 1960 | Франция |
| 25. Габон | Африка | 1960 | Франция |
| 26. Бенин (Дагомея) | Африка | 1960 | Франция |
| 27. Камерун | Африка | 1960 | Германия, Бөекбритания, Франция |

*Дәвамы*

| Ил (элеккеге исеме) | Деньяa кисәге | Бәйсезлек игълан итү елы | Ил-метрополия |
|---|---|---|---|
| 28. Конго Демократик Республикасы (Заир, Бельгия Конгосы) | Африка | 1960 | Бельгия |
| 29. Конго Халык Республикасы (Урта Конго) | Африка | 1960 | Франция |
| 30. Мавритания | Африка | 1960 | Франция |
| 31. Мали | Африка | 1960 | Франция |
| 32. Мадагаскар | Африка | 1960 | Франция |
| 33. Нигер | Африка | 1960 | Франция |
| 34. Нигерия | Африка | 1960 | Бөекбритания |
| 35. Сенегал | Африка | 1960 | Франция |
| 36. Сомали (Сомали — итал., Сомали — брит.) | Африка | 1960 | Италия, Бөекбритания |
| 37. Того (Тоголенд) | Африка | 1960 | Германия, Франция, Бөекбритания |
| 38. Чад | Африка | 1960 | Франция |
| 39. Кипр | Азия | 1960 | Бөекбритания |
| 40. Кувейт | Азия | 1961 | Бөекбритания |
| 41. Сьерра-Леоне | Африка | 1961 | Бөекбритания |
| 42. Танзания (Танганьика) | Африка | 1961 | Германия, Бөекбритания |
| 43. Йәмән Гарәп Республикасы[1] | Азия | 1962 | Бөекбритания |
| 44. Алжир | Африка | 1962 | Франция |
| 45. Бурунди | Африка | 1962 | Германия, Бельгия |
| 46. Руанда | Африка | 1962 | Германия, Бельгия |
| 47. Уганда | Африка | 1962 | Бөекбритания |
| 48. Тринидад һәм Тобаго | Америка | 1962 | Бөекбритания |
| 49. Ямайка | Америка | 1962 | Бөекбритания |
| 50. Самоа | Океания | 1962 | Германия, АКШ |
| 51. Кения | Африка | 1963 | Бөекбритания |
| 52. Замбия (Төньяк Родезия) | Африка | 1964 | Бөекбритания |
| 53. Малави (Ньясаленд) | Африка | 1964 | Бөекбритания |
| 54. Мальта | Европа | 1964 | Бөекбритания |
| 55. Мальдив Республикасы | Азия | 1965 | Бөекбритания |
| 56. Сингапур | Азия | 1965 | Бөекбритания |
| 57. Гамбия | Африка | 1965 | Бөекбритания |
| 58. Гайана (Брит. Гвианасы) | Америка | 1966 | Бөекбритания |
| 59. Ботсвана (Бечуаналенд) | Африка | 1966 | Бөекбритания |
| 60. Лесото (Басутоленд) | Африка | 1966 | Бөекбритания |

[1] 1990 елда Йәмән Гарәп Республикасы һәм ЙХДР бердәм Йәмән Республикасына берләшә.

| Ил (элеккеге исеме) | Дөнья кисәге | Бәйсезлек игълан итү елы | Ил-метрополия |
|---|---|---|---|
| 61. Барбадос | Америка | 1966 | Бөекбритания |
| 62. ЙХДР (Аден) | Азия | 1967 | Бөекбритания |
| 63. Маврикий | Африка | 1968 | Бөекбритания |
| 64. Науру | Океания | 1968 | Бөекбритания, Яңа Зеландия һәм Австралия |
| 65. Свазиленд | Африка | 1968 | Бөекбритания |
| 66. Экваториаль Гвинея | Африка | 1968 | Испания |
| 67. Тонга корольлеге | Океания | 1970 | Бөекбритания |
| 68. Фиджи | Океания | 1970 | Бөекбритания |
| 69. Бахрейн | Азия | 1971 | Бөекбритания |
| 70. Катар | Азия | 1971 | Бөекбритания |
| 71. Берләшкән Гарәп Әмирлеге (Килешүле Оман) | Азия | 1971 | Бөекбритания |
| 72. Бангладеш (Көнчыгыш Пакистан) | Азия | 1973 | Бөекбритания |
| 73. Багам Утраулары Бердәмлеге | Америка | 1973 | Бөекбритания |
| 74. Гвинея-Бисау (Порт. Гвинеясы) | Африка | 1974 | Португалия |
| 75. Гренада | Америка | 1975 | Бөекбритания |
| 76. Мозамбик | Африка | 1975 | Португалия |
| 77. Кабо-Верде (Яшел Култык Утраулары) | Африка | 1975 | Португалия |
| 78. Сан-Томе һәм Принсипи | Африка | 1975 | Португалия |
| 79. Комор утраулары | Африка | 1975 | Франция |
| 80. Папуа — Яңа Гвинея | Океания | 1975 | Бөекбритания һәм Германия, аннары Австралия |
| 81. Ангола | Африка | 1975 | Португалия |
| 82. Суринам | Америка | 1975 | Нидерланд |
| 83. Сейшель утраулары | Африка | 1976 | Бөекбритания |
| 84. Джибути (Сомалиның Франция яры) | Африка | 1977 | Франция |
| 85. Соломон утраулары | Океания | 1978 | Бөекбритания |
| 86. Тувалу | Океания | 1978 | Бөекбритания |
| 87. Доминика | Америка | 1978 | Бөекбритания |
| 88. Сент-Люсия | Америка | 1979 | Бөекбритания |
| 89. Кирибати (Гилберт утраулары) | Океания | 1979 | Бөекбритания |
| 90. Сент-Винсент һәм Гренадин | Америка | 1979 | Бөекбритания |
| 91. Зимбабве (Көньяк Родезия) | Африка | 1980 | Бөекбритания |
| 92. Вануату (Яңа Гебрид утраулары) | Океания | 1980 | Бөекбритания һәм Франция |

| Ил (элеккеге исеме) | Дөнья кисәге | Бәйсезлек игълан итү елы | Ил-метрополия |
|---|---|---|---|
| 93. Белиз (Британия Гондурасы) | Америка | 1981 | Бөекбритания |
| 94. Антигуа һәм Барбуда | Америка | 1981 | Бөекбритания |
| 95. Сент-Китс һәм Невис | Америка | 1983 | Бөекбритания |
| 96. Бруней | Азия | 1984 | Бөекбритания |
| 97. Микронезия Федератив Штатлары (Каролин утраулары) | Океания | 1986 | Германия, Япония, АКШ опекасы |
| 98. Маршалл Утраулары Республикасы | Океания | 1986 | Германия, Япония, АКШ опекасы |
| 99. Намибия (Көньяк-Көнбатыш Африка) | Африка | 1990 | Германия, КАР опекасы |
| 100. Эритрея | Африка | 1993 | Италия (1950 елдан Эфиопия составында була) |
| 101. Палау Республикасы | Океания | 1994 | Германия, Япония, АКШ опекасы |
| 102. Көнчыгыш Тимор | Азия | 2002 | Португалия (аннары Индонезия басып ала, БМО идарә итә) |

2 нче таблица

**Идарә итү формасы монархия булган илләр**

| Илләр | Идарә итү формасы | Илләр | Идарә итү формасы |
|---|---|---|---|
| **Европа чит илләре** | | **Азия чит илләре** | |
| Андорра | Кенәзлек | Бахрейн | Әмирлек |
| Бельгия | Корольлек | Бруней | Солтанлык |
| Ватикан | Теократик монархия | Бутан | Корольлек |
| Бөекбритания | Корольлек | Иордания | Корольлек |
| Дания | Корольлек | Камбоджа | Корольлек |
| Испания | Корольлек | Катар | Әмирлек |
| Лихтенштейн | Кенәзлек | Кувейт | Әмирлек |
| Люксембург | Бөек герцоглык | Малайзия | Солтанлык |
| Монако | Кенәзлек | Оман | Солтанлык |
| Нидерланд | Корольлек | Берләшкән Гәрәп Әмирлекләре | Әмирлек |
| Норвегия | Корольлек | Согуд Гәрәбстаны | Корольлек |
| Швеция | Корольлек | Таиланд | Корольлек |
| | | Япония | Империя |

| Илләр | Идарә итү формасы | Илләр | Идарә итү формасы |
|---|---|---|---|
| **Африка** | | **Океания** | |
| Лесото | Корольлек | Тонга | Корольлек |
| Марокко | Корольлек | | |
| Свазиленд | Корольлек | | |

3 нче таблица

**Иң зур нефть запасларына ия булган илләр**

| Илләр | Тикшерелгән запаслар, млрд т | Илләр | Тикшерелгән запаслар, млрд т |
|---|---|---|---|
| Согуд Гарәбстаны | 35,4 | Венесуэла | 11,4 |
| Канада | 28,3 | Ливия | 5,1 |
| Иран | 18,2 | Нигерия | 4,8 |
| Гыйрак | 15,5 | Казахстан | 4,2 |
| Россия | 14,7 | Кытай | 3,9 |
| Кувейт | 14,0 | АКШ | 3,0 |
| БГӘ | 12,9 | Мексика | 2,0 |

4 нче таблица

**Иң зур табигый газ запасларына ия булган илләр**

| Илләр | Тикшерелгән запаслар, трлн $м^3$ | Илләр | Тикшерелгән запаслар, трлн $м^3$ |
|---|---|---|---|
| Россия | 47,5 | Австралия | 4,0 |
| Иран | 26,5 | Гыйрак | 3,2 |
| Катар | 25,8 | Төркмәнстан | 2,9 |
| Согуд Гарәбстаны | 6,7 | Норвегия | 2,1 |
| БГӘ | 6,1 | Мисыр | 2,0 |
| АКШ | 5,6 | Индонезия | 1,9 |
| Нигерия | 5,1 | Үзбәкстан | 1,9 |
| Алжир | 4,9 | Канада | 1,7 |
| Венесуэла | 4,2 | Нидерланд | 1,6 |

5 нче таблица

**Иң зур күмер һәм тимер рудасы запасларына ия булган илләр**

| Илләр | Тикшерелгән күмер запаслары, млрд т | Илләр | Тикшерелгән тимер рудасы запаслары, млрд т |
|---|---|---|---|
| АКШ | 250 | Россия | 33 |
| Россия | 195 | Бразилия | 21 |
| Кытай | 115 | Австралия | 18 |
| Һиндстан | 84 | Украина | 15 |
| Австралия | 82 | Кытай | 15 |
| ГФР | 66 | АКШ | 7 |
| КАР | 50 | Һиндстан | 7 |
| Украина | 34 | Швеция | 4 |
| Казахстан | 34 | Казахстан | 4 |
| Польша | 22 | Венесуэла | 2 |

6 нчы таблица

**Дөньяның зур регионнары буенча сөрүлек җирләр белән тәэмин ителү (җан башына)**

| Регионнар | Тәэмин ителү, га | Регионнар | Тәэмин ителү, га |
|---|---|---|---|
| БДБ | 0,80 | Төньяк Америка | 0,60 |
| Европа чит илләре | 0,25 | Көньяк Америка | 0,35 |
| Азия чит илләре | 0,13 | Австралия һәм Океания | 1,80 |
| Африка | 0,22 | Бөтен дөнья | 0,20 |

7 нче таблица

**Дөньядагы икътисади гидропотенциал һәм аны файдалану**

| Регионнар | Барысы | | Шул исәптән файдаланылганы, % |
|---|---|---|---|
| | млрд кВт · сәг | % ларда | |
| БДБ | 1250 | 15,6 | 20 |
| Европа чит илләре | 700 | 8,8 | 72 |
| Азия чит илләре | 2250 | 28,1 | 18 |
| Африка | 1100 | 13,8 | 8 |
| Төньяк Америка | 1000 | 12,5 | 70 |
| Латин Америкасы | 1600 | 20,0 | 32 |
| Австралия һәм Океания | 100 | 1,2 | 40 |
| Бөтен дөнья | 8000 | 100,0 | 30 |

8 нче таблица

**Дөньяның урманга иң бай һәм иң ярлы илләре**

| Урманга иң бай илләр | Урманлы өлеше, % | Иң аз урманлы илләр | Урманлы өлеше, % |
|---|---|---|---|
| Суринам | 95 | Оман | 0,0 |
| Папуа — Яңа Гвинея | 84 | Кувейт | 0,1 |
| Гайана | 83 | Үзәк Африка Республикасы | 0,2 |
| Габон | 78 | | |
| Конго ДР | 77 | Согуд Гарәбстаны | 0,6 |
| Финляндия | 76 | Иордания | 0,8 |
| Камбоджа | 76 | Исландия | 1,0 |
| КХДР | 75 | Мисыр | 1,0 |
| Швеция | 68 | БГӘ | 1,0 |
| Япония | 67 | Гаити | 1,5 |
| Корея Республикасы | 66 | Нигер | 1,6 |
| Лаос | 66 | Алжир | 2,0 |
| Бразилия | 65 | Әфганстан | 2,9 |
| Индонезия | 63 | КАР | 3,7 |
| Гвинея | 60 | Сүрия | 3,9 |

9 нчы таблица

**Атмосферага иң күп углерод диоксидын чыгаручы илләр**

| Илләр | Чыгаруның күләме, млн т | Илләр | Чыгаруның күләме, млн т |
|---|---|---|---|
| АКШ | 5500 | Канада | 400 |
| Кытай | 4300 | Италия | 400 |
| Россия | 1800 | Франция | 350 |
| Япония | 1200 | Польша | 350 |
| ГФР | 800 | Мексика | 330 |
| Һиндстан | 750 | Казахстан | 300 |
| Украина | 600 | КАР | 300 |
| Бөекбритания | 500 | Корея Республикасы | 300 |

10 нчы таблица

**Бөтендөнья мирасы объектларының дөньяның эре регионнары буенча бүленеше**[1]

| Регионнар | Объектлар саны | Аларның гомуми сандагы өлеше, % |
|---|---|---|
| БДБ | 47 | 5,4 |
| Европа чит илләре | 345 | 39,3 |
| Азия чит илләре | 193 | 22,0 |
| Африка | 115 | 13,2 |
| Төньяк Америка | 33 | 3,8 |
| Латин Америкасы | 120 | 13,7 |
| Австралия һәм Океания | 23 | 2,6 |
| Бөтен дөньяда | 878 | 100,0 |

[1] 2008 ел ахырына.

11 нче таблица

**1950–2006 елларда дөньяда халык санының үсеше**

| Ел | Барлыгы, млн кеше | Еллык үсеш, млн кеше | Ел | Барлыгы, млн кеше | Еллык үсеш, млн кеше |
|---|---|---|---|---|---|
| 1950 | 2527 | 40 | 1988 | 5110 | 86 |
| 1955 | 2779 | 53 | 1989 | 5196 | 86 |
| 1960 | 3060 | 54 | 1990 | 5284 | 88 |
| 1965 | 3345 | 70 | 1991 | 5367 | 83 |
| 1970 | 3727 | 78 | 1992 | 5450 | 83 |
| 1975 | 4086 | 72 | 1993 | 5531 | 81 |
| 1976 | 4159 | 73 | 1994 | 5611 | 80 |
| 1977 | 4231 | 72 | 1995 | 5691 | 80 |
| 1978 | 4301 | 75 | 1996 | 5769 | 78 |
| 1979 | 4380 | 79 | 1997 | 5847 | 78 |
| 1980 | 4457 | 77 | 1998 | 5915 | 68 |
| 1981 | 4533 | 76 | 1999 | 6003 | 78 |
| 1982 | 4614 | 81 | 2000 | 6071 | 68 |
| 1983 | 4695 | 91 | 2001 | 6148 | 77 |
| 1984 | 4775 | 80 | 2002 | 6225 | 77 |
| 1985 | 4856 | 81 | 2003 | 6301 | 76 |
| 1986 | 4932 | 76 | 2004 | 6378 | 77 |
| 1987 | 5024 | 92 | 2005 | 6464 | 86 |
| | | | 2006 | 6525 | 88 |

12 нче таблица

**Халыкның табигый үсеше тискәре булган Европа илләре, 2005 ел**

| Илләр | Табигый үсеш, ‰ | Илләр | Табигый үсеш, ‰ |
|---|---|---|---|
| Австрия | -0,9 | Эстония | -3,3 |
| Румыния | -1,0 | Венгрия | -3,4 |
| Словения | -1,3 | Белоруссия | -3,4 |
| Чехия | -1,4 | Латвия | -4,7 |
| Италия | -1,4 | Болгария | -4,6 |
| Хорватия | -1,8 | Россия | -5,5 |
| Германия | -1,8 | Украина | -5,9 |
| Литва | -2,3 | | |

13 нче таблица

**Халыкның табигый үсеше зур булган үсеп килүче илләр, 2005 ел**

| Илләр | Табигый үсеш, ‰ | Илләр | Табигый үсеш, ‰ |
|---|---|---|---|
| Йәмән | 35 | Гвинея | 27 |
| Уганда | 35 | Әфганстан | 26 |
| Оман | 33 | Либерия | 26 |
| Мадагаскар | 30 | Судан | 26 |
| Конго ДР | 30 | Кения | 26 |
| Чад | 30 | Буркина-Фасо | 26 |
| Мавритания | 29 | Эритрея | 25 |
| Сомали | 29 | Сенегал | 25 |
| Гватемала | 29 | Лаос | 24 |
| Бенин | 28 | Гондурас | 23 |
| Мали | 28 | Того | 22 |
| Согуд Гарәбстаны | 27 | Пакистан | 22 |
| Гыйрак | 27 | Бутан | 21 |
| Нигер | 27 | Никарагуа | 21 |

14 нче таблица

**Дөньяның иң күп халыклы илләре**

| Илләр | 1990 елда халык саны, млн кеше | Илләр | 2006 елда халык саны, млн кеше |
|---|---|---|---|
| Кытай | 1120 | Кытай | 1344 |
| Һиндстан | 830 | Һиндстан | 1095 |
| Советлар Союзы[1] | 289 | АКШ | 298 |
| АКШ | 250 | Индонезия | 245 |
| Индонезия | 180 | Бразилия | 188 |
| Бразилия | 150 | Пакистан | 166 |
| Япония | 124 | Бангладеш | 148 |
| Пакистан | 112 | Россия | 143 |
| Бангладеш | 112 | Нигерия | 132 |
| Нигерия | 90 | Япония | 127 |
| Мексика | 86 | Мексика | 107 |
| ГФР | 80 | Филиппин | 89 |
| Вьетнам | 68 | Вьетнам | 84 |
| Филиппин | 60 | ГФР | 83 |
| Төркия | 59 | Мисыр | 79 |
| Италия | 58 | Эфиопия | 75 |
| Таиланд | 58 | Төркия | 70 |
| Бөекбритания | 57 | Иран | 69 |
| Франция | 56 | Таиланд | 65 |
| Украина | 52 | Франция | 61 |

[1] Шул исәптән Россия — 148.

15 нче таблица

**Иң зур һәм иң аз гомер озынлыгы көтелә торган илләр (2005 ел)**

| Илләр | Көтелә торган гомер озынлыгы, яшь | Илләр | Көтелә торган гомер озынлыгы, яшь |
|---|---|---|---|
| Япония | 81,6 | Замбия | 32,4 |
| Швеция | 80,1 | Сьерра-Леоне | 34,2 |
| Исландия | 79,8 | Лесото | 35,7 |
| Испания | 79,3 | Малави | 37,5 |
| Канада | 79,3 | Мозамбик | 38,1 |
| Израиль | 79,2 | Руанда | 39,3 |
| Австралия | 79,2 | ҮАР | 39,5 |
| Швейцария | 79,1 | Ботсвана | 39,7 |
| Франция | 79,0 | Ангола | 40,1 |
| Норвегия | 78,9 | Бурунди | 40,9 |
| Бельгия | 78,8 | Кот-д'Ивуар | 41,0 |
| Италия | 78,7 | Либерия | 41,4 |
| Австрия | 78,5 | Конго ДР | 41,8 |
| ГФР | 78,3 | Әфганстан | 43,1 |
| Нидерланд | 78,3 | | |

16 нчы таблица

**Дөньяның иң зур шәһәр агломерацияләре (2005 елда)**

| Агломерация | Халык саны, млн кеше | Агломерация | Халык саны, млн кеше |
|---|---|---|---|
| Токио | 26,9 | Джакарта | 13,2 |
| Сан-Паулу | 19,6 | Буэнос-Айрес | 13,0 |
| Мехико | 18,9 | Шанхай | 12,8 |
| Мумбаи (Бомбей) | 18,3 | Карачи | 11,4 |
| Нью-Йорк | 17,2 | Осака | 11,2 |
| Дакка | 15,9 | Рио-де-Жанейро | 11,2 |
| Дәһли | 15,3 | Пекин | 10,8 |
| Колката (Калькутта) | 14,3 | Каһирә | 10,8 |
| Лос-Анджелес | 13,8 | Манила | 10,4 |
| Мәскәү | 13,4 | Лагос | 10,1 |
| | | Сеул | 10,0 |

17 нче таблица

**Шәһәр халкының саны буенча дөньяның иң зур илләре (2005 елда)**

| Илләр | Шәһәр халкы, млн кеше | Шәһәр халкының өлеше, % |
|---|---|---|
| Кытай | 515 | 39 |
| Һиндстан | 310 | 28 |
| АКШ | 240 | 80 |
| Бразилия | 155 | 83 |
| Россия | 105 | 73 |
| Индонезия | 103 | 46 |
| Япония | 101 | 79 |
| Мексика | 81 | 76 |
| ГФР | 73 | 88 |
| Нигерия | 62 | 47 |
| Бөекбритания | 53 | 89 |
| Төркия | 48 | 66 |
| Франция | 46 | 76 |
| Филиппин | 51 | 61 |
| Италия | 39 | 67 |

18 нче таблица

**Дөньяның кайбер илләренең ТЭП структурасы (2005 ел)**

| Илләр | % | | |
|---|---|---|---|
| | авыл хуҗалыгы | промышленность | хезмәт күрсәтү сферасы |
| Кувейт | 1 | 52 | 47 |
| ГФР | 1 | 29 | 70 |
| Бөекбритания | 1 | 25 | 74 |
| Италия | 1 | 30 | 69 |
| Япония | 1 | 25 | 74 |
| АКШ | 1 | 20 | 79 |
| Франция | 3 | 20 | 77 |
| Нидерланд | 2 | 24 | 74 |
| Австралия | 3 | 26 | 71 |
| БГӘ | 4 | 59 | 37 |
| Чехия | 3 | 40 | 57 |
| Польша | 3 | 32 | 65 |
| Канада | 2 | 29 | 69 |
| Венесуэла | 5 | 48 | 47 |
| Россия | 5 | 35 | 60 |
| Бразилия | 10 | 39 | 51 |
| Литва | 6 | 32 | 62 |
| Румыния | 13 | 34 | 53 |
| Украина | 18 | 35 | 47 |
| Кытай | 14 | 53 | 33 |
| Индонезия | 15 | 45 | 40 |
| Һиндстан | 21 | 28 | 51 |
| Нигерия | 27 | 49 | 24 |
| Гана | 5 | 26 | 39 |
| Камбоджа | 33 | 29 | 38 |
| Үзбәкстан | 38 | 26 | 36 |
| Уганда | 31 | 22 | 47 |
| Танзания | 43 | 17 | 40 |
| Мали | 45 | 17 | 38 |
| Эфиопия | 40 | 13 | 47 |

19 нчы таблица

**Дөнья хуҗалыгының ун үзәге (2005 ел)**

| Үзәкләр | ТЭП, млрд долл. ППС | Дөнья ТЭПындагы өлеше, % |
|---|---|---|
| Төньяк Америка | 13 500 | 22,6 |
| Көнбатыш Европа | 11 570 | 19,4 |
| Кытай | 8160 | 13,7 |
| Япония | 3680 | 6,5 |
| Һиндстан | 2810 | 6,2 |
| Азиянең яңа индустриаль илләре | 3870 | 5,3 |
| БДБ | 1810 | 3,9 |
| Бразилия | 1560 | 2,6 |
| Фарсы култыгы илләре | 1190 | 2,0 |
| Мексика | 1070 | 1,8 |

20 нче таблица

**Дөнья хуҗалыгы үсешенең кайбер иң мөһим күрсәткечләре**

| Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | 1950 ел | 1960 ел | 1970 ел | 1980 ел | 1990 ел | 2005 ел |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Нефть чыгару | млн т | 535 | 1060 | 2270 | 3000 | 3180 | 3900 |
| Табигый газ чыгару | млрд $м^3$ | 200 | 450 | 1050 | 1500 | 2050 | 2760 |
| Күмер чыгару | млн т | 1820 | 2575 | 2860 | 3750 | 4620 | 5850 |
| Электр энергиясе җитештерү | млрд кВт·сәг | 950 | 2300 | 5000 | 8250 | 11 800 | 18 200 |
| Тимер рудасы чыгару | млн т | 250 | 500 | 710 | 900 | 980 | 1520 |
| Корыч коюю | млн т | 190 | 300 | 600 | 715 | 770 | 1100 |
| Алюминий коюю | млн т | 1,5 | 4,6 | 10,2 | 16,1 | 19,3 | 31,0 |
| Җиңел автомобильләр җитештерү | млн данә | 8,1 | 15,5 | 23,8 | 28,4 | 35,7 | 46,0 |
| Киҗе-мамык тукымалар җитештерү | млрд $м^2$ | 30 | 40 | 45 | 55 | 77 | 90 |
| Бөртекләрнең тулай җыемы | млн т | 630 | 850 | 1100 | 1450 | 1950 | 2350 |
| Балык тоту һәм диңгез продуктлары табу | млн т | 21 | 40 | 69 | 75 | 80 | 95 |
| Автомобиль юлларының озынлыгы | млн км | 15,5 | 17,0 | 19,7 | 22,3 | 23,6 | 32,5 |
| Дөнья автопаркы | млн данә | 50 | 120 | 245 | 370 | 520 | 800 |
| Авиация белән пассажирлар йөртү | млн кеше | 30 | 70 | 340 | 750 | 1150 | 3000 |
| Бөтендөнья сәүдә әйләнеше | млрд доллар | 125 | 260 | 650 | 4050 | 6980 | 29 200 |

21 нче таблица

**Промышленность житештерүенең күләме буенча дөньяның беренче ун иле**

| Бөтендөнья, илләр | Продукция, млрд долл. | Дөнья күрсәткечена карата, % |
|---|---|---|
| Бөтен дөнья | 15 000 | 100 |
| АКШ | 2685 | 17,9 |
| Япония | 1235 | 8,3 |
| Кытай* | 1235 | 8,3 |
| Германия | 835 | 5,6 |
| Бөекбритания | 600 | 4,0 |
| Италия | 520 | 3,5 |
| Франция | 445 | 3,0 |
| Бразилия | 370 | 2,4 |
| Һиндстан | 360 | 2,4 |
| Канада | 320 | 2,1 |

* Сянганны кертеп.

22 нче таблица

**Кайбер илләрдә беренчел энергоресурсларны җан башына куллану**

| Илләр | Куллану, кг шартлы ягулык елына | Илләр | Куллану, кг шартлы ягулык елына |
|---|---|---|---|
| **Бик югары дәрәҗәдә** | | Таиланд | 1500 |
| (5000 кг нан артык) | | Бразилия | 1100 |
| Канада | 11 250 | Мисыр | 1000 |
| АКШ | 11 000 | **Түбән дәрәҗәдә** | |
| БГӘ | 10 500 | (100—1000 кг) | |
| Австралия | 8200 | Кытай | 980 |
| Согуд Гарәбстаны | 6200 | Төркия | 800 |
| Россия | 5900 | Һиндстан | 450 |
| Германия | 5700 | Пакистан | 400 |
| **Югары дәрәҗәдә** | | Гана | 300 |
| (2500—5000 кг) | | **Бик түбән дәрәҗәдә** | |
| Корея Республикасы | 4800 | (100 кг нан түбән) | |
| Италия | 4200 | Сомали | 90 |
| Испания | 3900 | Танзания | 50 |
| Польша | 3200 | Конго ДР | 25 |
| **Уртача дәрәҗәдә** | | Чад | 8 |
| (1000—2500 кг) | | | |
| Аргентина | 2200 | | |
| Ливия | 1800 | | |

23 нче таблица

**2005 елда электр энергиясе җитештерү буенча дөньяның беренче ун иле**

| Илләр | Җитештерү | |
|---|---|---|
| | барлыгы, млрд кВт·сәг | җан башына, мең кВт·сәг |
| АКШ | 4240 | 14250 |
| Кытай | 2445 | 1870 |
| Япония | 1140 | 6960 |
| Россия | 950 | 6650 |
| Һиндстан | 680 | 630 |
| ГФР | 620 | 7560 |
| Канада | 600 | 18750 |
| Франция | 575 | 9600 |
| Бөекбритания | 405 | 5780 |
| Бразилия | 400 | 2180 |

24 нче таблица

**Дөньядагы иң зур гидроэлектростанцияләр**

| ГЭСларның исеме | Куәте, млн кВт | Ил | Елга |
|---|---|---|---|
| Санься | 18,2 | Кытай | Янцзы |
| Итайпу | 12,6 | Бразилия/Парагвай | Парана |
| Гранд-Кули | 10,8 | АКШ | Колумбия |
| Гури | 10,3 | Венесуэла | Кароно |
| Тукуруи | 8,0 | Бразилия | Токантинс |
| Саян-Шуша | 6,4 | Россия | Енисей |
| Красноярск | 6,0 | Россия | Енисей |
| Ла-Гранд-2 | 5,3 | Канада | Ла-Гранд |
| Черчилл-Фолс | 5,2 | Канада | Черчилл |
| Братск | 4,5 | Россия | Ангара |
| Усть-Илим | 4,3 | Россия | Ангара |

25 нче таблица

**2005 елда алюминий җитештерү буенча дөньяның беренче ун иле**

| Илләр | Җитештерү, млн т | Илләр | Җитештерү, млн т |
|---|---|---|---|
| Кытай | 8,7 | Бразилия | 1,5 |
| Россия | 3,7 | Норвегия | 1,4 |
| Канада | 3,0 | Һиндстан | 1,0 |
| АКШ | 2,3 | КАР | 0,9 |
| Австралия | 1,9 | Бахрейн | 0,8 |

26 нчы таблица

**2005 елда станоклар җитештерүнең күләме буенча дөньяның беренче ун иле**

| Илләр | Җитештерү, млрд долл. | Илләр | Җитештерү, млрд долл. |
|---|---|---|---|
| Япония | 13,2 | АКШ | 3,2 |
| ГФР | 9,5 | Корея Республикасы | 2,8 |
| Кытай | 5,0 | Швейцария | 2,6 |
| Италия | 4,9 | Испания | 1,1 |
| Тайвань | 3,3 | Канада | 0,9 |

27 нче таблица

**2005 елда химик сүсләр җитештерү буенча дөньяның беренче ун иле**

| Илләр | Җитештерү, млн т | Илләр | Җитештерү, млн т |
|---|---|---|---|
| Кытай | 11,0 | Индонезия | 1,3 |
| Тайвань | 3,5 | Япония | 1,2 |
| АКШ | 2,9 | ГФР | 0,9 |
| Корея Республикасы | 2,4 | Таиланд | 0,9 |
| Һиндстан | 2,1 | Төркия | 0,8 |

28 нче таблица

**2005 елда киҗе-мамык тукымалар җитештерүнең күләме буенча дөньяның беренче ун иле**

| Илләр | Җитештерү, млн м$^2$ | Илләр | Җитештерү, млн м$^2$ |
|---|---|---|---|
| Кытай | 24,5 | Пакистан | 0,6 |
| Һиндстан | 18,0 | Тайвань | 0,6 |
| АКШ | 8,0 | Япония | 0,5 |
| Россия | 2,8 | ГФР | 0,5 |
| Мисыр | 1,5 | Франция | 0,5 |

29 нчы таблица

**2005 елда бөртеклеләрнең тулай җыемы буенча дөньяның беренче ун иле**

| Илләр | Тулай җыем | |
|---|---|---|
| | барлыгы, млн т | җан башына, кг |
| Кытай | 420 | 310 |
| АКШ | 390 | 1300 |
| Һиндстан | 230 | 210 |
| Россия | 78 | 545 |
| Франция | 73 | 1200 |
| Бразилия | 67 | 360 |
| Индонезия | 63 | 260 |
| Канада | 57 | 1675 |
| Украина | 42 | 890 |
| Бангладеш | 41 | 280 |

30 нчы таблица

**2005 елда балык тоту һәм диңгез продуктлары табу күләмнәре буенча дөньяның беренче ун иле**

| Илләр | Тоту, табу, млн т | Илләр | Тоту, табу, млн т |
|---|---|---|---|
| Кытай | 41,5 | АКШ | 5,2 |
| Перу | 8,4 | Индонезия | 4,8 |
| Япония | 5,9 | Россия | 4,0 |
| Һиндстан | 5,4 | Таиланд | 3,6 |
| Чили | 5,3 | Норвегия | 3,1 |

31 нче таблица

**2005 елда автомобиль паркының зурлыгы буенча дөньяның беренче ун иле**

| Илләр | Автопарк, млн машина | |
|---|---|---|
| | барлыгы | шул исәптән җиңел машиналар |
| АКШ | 230 | 135 |
| Япония | 73 | 55 |
| ГФР | 48 | 45 |
| Италия | 38 | 35 |
| Франция | 35 | 30 |
| Бөекбритания | 33 | 30 |
| Россия | 31 | 26 |
| Бразилия | 28 | 23 |
| Испания | 23 | 19 |
| Канада | 20 | 17 |

32 нче таблица

**2005 елда диңгез сәүдә флотының зурлыгы буенча дөньяның беренче ун иле**

| Илләр | Тоннажы, млн бр.-рег. т[1] | Илләр | Тоннажы, млн бр.-рег. т |
|---|---|---|---|
| Панама* | 130 | Мальта* | 23 |
| Либерия* | 55 | Маршалл утраулары* | 22 |
| Багам утраулары* | 34 | Кипр* | 21 |
| Греция | 32 | Кытай | 19[2] |
| Сингапур | 25 | Норвегия | 18 |

[1] Брутто-регистр тонналарында (бр.-рег. т) диңгез судноларының сыйдырышлылыгы үлчәнә; 1 бр.-рег. т = 100 куб. фут, яки 2,83 $м^3$.

[2] Сянган флотыннан башка (25 млн бр.-рег. т).

* «Уңайлы флаглар».

33 нче таблица

**2005 елда халыкара туризм аеруча нык үскән илләр**

| Илләр | Килгән туристлар саны, млн кеше | Илләр | Килгән туристлар саны, млн кеше |
|---|---|---|---|
| Франция | 75,5 | Канада | 19,2 |
| Испания | 53,5 | Төркия | 16,8 |
| АКШ | 46,1 | Малайзия | 15,7 |
| Кытай | 41,8 | Польша | 14,3 |
| Италия | 37,1 | Греция | 14,0 |
| Бөекбритания | 27,8 | Венгрия | 12,2 |
| Сянган (КХР) | 21,8 | Таиланд | 11,7 |
| Мексика | 20,6 | Португалия | 11,6 |
| Германия | 20,1 | Нидерланд | 9,2 |
| Австрия | 19,4 | | |

34 нче таблица

**2025 елга Җирдәге халык санын фаразлау**

| Бөтен дөнья, регионнар | Халык саны, млн кеше | Бөтен дөнья, регионнар | Халык саны, млн кеше |
|---|---|---|---|
| Бөтен дөнья | 7825 | Африка | 1300 |
| Икътисади үсеш алган илләр | 1215 | Төньяк Америка | 365 |
| | | Латин Америкасы | 695 |
| Үсеп килүче илләр | 6610 | Австралия һәм Океания | 40 |
| БДБ | 290 | | |
| Европа чит илләре | 505 | | |
| Азия чит илләре | 4630 | | |

35 нче таблица

**Дөньяның иң зур егерме илендә 2025 ел өчен халык санын фаразлау**

| Илләр | Халык саны, млн кеше | Илләр | Халык саны, млн кеше |
|---|---|---|---|
| Кытай | 1490 | Япония | 120 |
| Һиндстан | 1330 | Эфиопия | 115 |
| АКШ | 346 | Вьетнам | 110 |
| Индонезия | 275 | Филиппин | 110 |
| Пакистан | 265 | Конго ДР | 105 |
| Бразилия | 220 | Иран | 95 |
| Нигерия | 215 | Мисыр | 95 |
| Бангладеш | 180 | Төркия | 88 |
| Россия | 130 | ГФР | 80 |
| Мексика | 130 | Таиланд | 73 |

Учебное издание

**Максаковский** Владимир Павлович

**ГЕОГРАФИЯ**
**ЭКОНОМИЧЕСКАЯ И СОЦИАЛЬНАЯ ГЕОГРАФИЯ МИРА**

Учебник для 10 класса
татарской средней общеобразовательной школы

Казань. Издательство «Магариф». 2009

*Перевод с русского на татарский язык*

Уку-укыту басмасы

**Максаковский** Владимир Павлович

**ГЕОГРАФИЯ**
**ДӨНЬЯНЫҢ ИКЪТИСАДИ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ГЕОГРАФИЯСЕ**

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
10 нчы сыйныфы өчен дәреслек

Редакция мөдире *Л. Х. Мөхәммәтҗанова*
Редакторы *Г. И. Фазлыйәхмәтова*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучысы *Н. А. Казакова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*
Корректорлары *С. З. Гыймалетдинова, Р. Ә. Фәйзуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 17.12.2009. Форматы $70 \times 90\ ^1/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 29,25 + форз. 0,29.
Нәшер-хисап табагы 24,66 + форз. 0,43.
Тиражы 7300 д. Заказ В-1851.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20а.
Тел./факс (843) 277-52-88; 277-52-62.
E-mail: magarif@mail.ru
http://www.magarif.com

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

## Халкы 1 млн кешедән арткан илләрнең «ВИЗИТ КАРТОЧКАЛАРЫ»

| Илләр | Дәүләт флагы | Мәйданы, мең км² | Халкы, млн кеше | Башкаласы | Идарә итү формасы | Админ.-террит. төзелеш формасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Оман | | 212 | 3,1 | Маскат | АМ | У |
| Йәмән | | 528 | 21,5 | Сана | Р | У |
| **АФРИКА** | | | | | | |
| Мисыр | | 1002 | 78,9 | Каһирә | Р | У |
| Судан | | 2506 | 41,2 | Хартум | Р | У |
| Ливия | | 1760 | 5,9 | Триполи | Р | У |
| Тунис | | 164 | 10,2 | Тунис | Р | У |
| Алжир | | 2382 | 32,9 | Алжир | Р | У |
| Марокко | | 447 | 33,3 | Рабат | КМ | У |
| Маври-тания | | 1031 | 3,2 | Нуакшот | Р | У |
| Сенегал | | 196 | 12,0 | Дакар | Р | У |
| Гвинея | | 246 | 9,4 | Конакри | Р | У |
| Сьерра-Леоне* | | 72 | 5,0 | Фритаун | Р | У |
| Либерия* | | 111 | 3,0 | Мон-ровия | Р | У |
| Кот-д'Ивуар | | 322 | 17,7 | Яму-сукро | Р | У |
| Мали | | 1240 | 11,7 | Бамако | Р | У |
| Буркина-Фасо | | 274 | 13,9 | Уага-дугу | Р | У |
| Гана* | | 238 | 22,3 | Аккра | Р | У |
| Того | | 56 | 5,5 | Ломе | Р | У |

| Илләр | Дәүләт флагы | Мәйданы, мең км² | Халкы, млн кеше | Башкаласы | Идарә итү формасы | Админ.-террит. төзелеш формасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Бенин | | 113 | 7,9 | Порто-Ново | Р | У |
| Нигерия* | | 924 | 132,0 | Абуджа | Р | Ф |
| Нигер | | 1267 | 12,9 | Ниамей | Р | У |
| Камерун* | | 475 | 17,3 | Яунде | Р | У |
| Чад | | 1284 | 9,7 | Нджа-мена | Р | У |
| ҮАР | | 623 | 4,3 | Банги | Р | У |
| Габон | | 268 | 1,4 | Либре-виль | Р | У |
| Конго | | 342 | 3,7 | Бразза-виль | Р | У |
| Конго ДР | | 2345 | 62,7 | Киншаса | Р | У |
| Ангола | | 1247 | 12,1 | Луанда | Р | У |
| Эфиопия | | 1107 | 74,6 | Аддис-Абеба | Р | Ф |
| Сомали | | 638 | 9,0 | Мога-дишо | Р | У |
| Кения* | | 583 | 34,7 | Найроби | Р | У |
| Уганда* | | 236 | 28,2 | Кампала | Р | У |
| Руанда | | 26 | 8,6 | Кигали | Р | У |
| Бурунди | | 28 | 8,1 | Бужум-бура | Р | У |
| Танзания* | | 945 | 37,4 | Додома | Р | У |
| Замбия* | | 753 | 12,2 | Лусака | Р | У |
| Малави* | | 119 | 13,0 | Лилон-гве | Р | У |

## Халкы 1 млн кешедән арткан илләрнең «ВИЗИТ КАРТОЧКАЛАРЫ»

| Илләр | Дәүләт флагы | Мәйданы, мең км² | Халкы, млн кеше | Башкаласы | Идарә итү формасы | Админ.-террит. төзелеш формасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Мозамбик | | 783 | 20,0 | Мапуту | Р | У |
| Зимбабве* | | 389 | 12,2 | Хараре | Р | У |
| Ботсвана* | | 600 | 1,6 | Габе-роне | Р | У |
| Намибия* | | 824 | 2,0 | Виндхук | Р | У |
| КАР | | 1221 | 44,2 | Прето-рия | Р | Ф |
| Лесото* | | 30 | 2,0 | Масеру | КМ | У |
| Мада-гаскар | | 596 | 18,6 | Антана-нариву | Р | У |
| Маврикий* | | 2 | 1,2 | Порт-Луи | Р | У |
| **ТӨНЬЯК ҺӘМ ЛАТИН АМЕРИКАСЫ** | | | | | | |
| АКШ | | 9628 | 298,4 | Вашинг-тон | Р | Ф |
| Канада | | 9976 | 33,4 | Оттава | • | Ф |
| Мексика | | 1973 | 107,4 | Мехико | Р | Ф |
| Гватемала | | 109 | 12,3 | Гвате-мала | Р | У |
| Гондурас | | 112 | 7,3 | Тегуси-гальпа | Р | У |
| Сальвадор | | 21 | 6,6 | Сан-Сальва-дор | Р | У |
| Никарагуа | | 130 | 5,6 | Манагуа | Р | У |
| Коста-Рика | | 51 | 4,1 | Сан-Хосе | Р | У |
| Панама | | 77 | 3,2 | Панама | Р | У |
| Куба | | 111 | 11,4 | Гавана | Р | У |

| Илләр | Дәүләт флагы | Мәйданы, мең км² | Халкы, млн кеше | Башкаласы | Идарә итү формасы | Админ.-террит. төзелеш формасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Гаити | | 28 | 8,3 | Порт-о-Пренс | Р | У |
| Доминик. Республ. | | 49 | 9,2 | Санто-До-Минго | Р | У |
| Ямайка* | | 11 | 2,8 | Кинг-стон | Р | У |
| Тринидад* һәм Тобаго | | 5 | 1,1 | Порт-оф-Спейн | Р | У |
| Колумбия | | 1139 | 43,6 | Санте-Фе-Богота | Р | У |
| Венесуэла | | 912 | 25,7 | Каракас | Р | Ф |
| Эквадор | | 284 | 13,5 | Кито | Р | У |
| Перу | | 1285 | 28,3 | Лима | Р | У |
| Боливия | | 1097 | 9,0 | Сукре (Ла-Пас) | Р | У |
| Чили | | 757 | 16,1 | Сантья-го | Р | У |
| Бразилия | | 8512 | 188,1 | Брази-лиа | Р | Ф |
| Парагвай | | 407 | 6,5 | Асун-сьон | Р | У |
| Уругвай | | 178 | 3,4 | Монте-видео | Р | У |
| Аргентина | | 2777 | 39,9 | Буэнос-Айрес | Р | Ф |
| **АВСТРАЛИЯ ҺӘМ ОКЕАНИЯ** | | | | | | |
| Австралия | | 7687 | 20,3 | Кан-берра | • | Ф |
| Яңа Зеландия | | 269 | 4,1 | Веллинг-тон | • | У |
| Папуа-Яңа Гвинея | | 462 | 5,7 | Порт-Морсби | • | У |

Р – республика; КМ – конституцион монархия; АМ – абсолют монархия; У – унитар дәүләт; Ф – федератив дәүләт; * – Бөекбритания Бердәмлеге составындагы дәүләт.

ISBN 978-5-7761-2027-5